НОВЫЙ ЗАВЕТ ГОСПОДА НАШЕГО ИИСУСА ХРИСТА

на кряшенском языке

ХОДАЙЫБЫЗ ИИСУСЪ ХРИСТОСНЫН ЖАНА ЗАКОН

СЮЗ БАШЫ

Ходайда тороучы сөйөклө кряшен туганнарыбыз!

Сезнен кулыгыздагы бу книгя сезнен өчөн бик кадерле, бәйәляб бетергесез книгя. Анын ўзенен ўткяне бар. Профессор Николай Иванович Ильминскій (1822-1891) Казан духовная академиясендя укыткан жылларында кряшеннярне очоратыб, аларны жяняшялярендя тороб өйрянгян чагында ул кряшеннярнен балалар сымак чиста кюнѣлле, ышаныучан булыуларына, жыуашлыгына, телляренен боронгодан килгян чисталыгына, жомошаклыгына исе китеб, эясеня китерергя жалтраб жаткан алтын табкандый, эч кюнѣле белян сөйөб кабыл алган; аларны ўз баласыдый жакын кюреб, ўз эченя жомолган калыкнын кюнѣлеля ачкыч табкан, жаннарын тын ашамныгы белян туйындырыу өчөн бар гумерен биргян. Кайчандыр Христосъ денендя булыб та, инде язычествога ауышыб беткян диярлек кряшеннярне жанадан Эяляреня - Христоска китереўгя, Изге Жазыуларны бу калыкнын ўз теленя - кряшенчягя кючереўгя булган гумерен, жегярен куйган Николай Ильминскій. Без аны кряшенняр апостолы диб атаб жөртябез.

Ўткян XIX гумердя Н.И.Ильминскій жазыуы булмаган кряшеннярга жазыу төзөб, кириллицаны кулланыб төзөгян әлеге кряшен жазыуына грекъ теленнян, ц-славянъ теленнян Христосъ өйрятеўе книгялярен кючергян: 1865-1891 жылларда ул кряшенняр өчөн Дюрт Евангеліе (1891), Псалтырь (1891), келяў итеў ряте, Часословъ, каноннар, тропарлярне кряшен теленя кючереб, бастырыб чыгарган. Кючереў эшлярендя ул жяш ўсмер кряшен Василій Тимофеевка таяныб, энже бөртөкляредяй татлы чын кряшен сюзляре кулланыб эшлягян. 1869 жылда архіепископъ Антоній II (Амфитеатров) Василій Тимофеевны священникка кул салган, Василій әтей безнен беренче кряшен священнигебез.

Н.И.Ильминскійдан сун, ул башлаган изге эшне туктатмый-

чы, 1907 жылда Святый апостолларнын эшляре дигян книгяне кряшенчягя кючереб бастырганнар. Алтыннан артык бу дяўлятле книгяляр ăр кряшен өйөндя булыб, дауыллы совет чоронда да алар бик кадерляб сакланыб калынганнар, шулай калалар да. 1910 жылда Новый Заветнын ăле кряшенчягя кючерелмягян книгялярен кючереў өчөн архиепископъ Никаноръ (Каменскій) Мамадышта 22 кряшен священниген жыйган. Алар белян киняшеб, ин элек Изге апостолларнын арыу жыйынга жибяргян жазыулары белян апостолъ Павелнын жибяргян жазыуларын кючерергя киряк дигян уйга килгянняр. Тик дöньяляр болганыб китеб, бу эш эшлянмей калган.

Чиркяўлярне жимергян совет чоронда, аннан сунгы жылларда (1917-1996) бу эш тукталган. Ул чорда 50 кряшен чиркяўеннян, 2 кряшен монастырыннан берсе дя калмаган. Ăммя ышаныучылар чиркяў бяйрямнярен калдырмаганнар, жяшертен жыйылыб öйлярдя, öйлярдян кыуганда зиратларда ўткяргянняр. Христосъ денен, кряшеннекне тырышыб саклаганнар, жяшлярга табшырыб килгянняр. Кряшен дигян сюзне ăйтергя дя жарамаган ул жылларда зур оло азаблар кюреб, кряшенняр сакланыб кала алганнар. 1981 жылда Казандагы бер типографиядя ышаныучыларга оло сöйöнöч булыб Дюрт Евангеліе белян Псалтырь кюн тышлы книгя итеб жяшертен бастырылган.

Ходайнын изгелеге белян кабат ышаныучыларга ирек килеб, чиркяўляр ачыла башлагач, 1989 жылда Казанда кряшенчя келяў ўткяреля башлый. 1992 жылда Греция илендя Дюрт Евангеліенен, 1994 жылда Псалтырьнын репринт басмалары протоіерей Павелъ Павловнын тырышлыгы арткылы бастырылыб кайта.

Ходайнын оло изгелеге белян 1996 жылда Новый Заветтагы ăле кряшенчядя булмаган жазыуларны кючереў эше Тихвинъ исемендяге Алла Анасы чиркяўе настоятеле протоіерей Павелъ Павловъ инициативасы белян торгозола. Шушы жылда приходка жöрöўче педагог Мария Матвеева Изге апостолларнын арыу жыйынга жибяргян жазыуларын кряшенчягя кючереўне башлый. Көз-кыш буйы-

на М.Матвеева бу эшне эшляб, черновой вариантын äзерлей, 1997-2000 жыллар эчендя Библія ойошмасы белян (Российское Библейское общество) берлектя редакциялей. Iисусъ Христосъ жир öстöня килеўнен 2000 жыллык оло юбилеена книгя Библія ойошмасы исябеня бастырылыб, С-Петербургтан шул жылнын 23 декабрендя кряшеннярга кайтыб житя.

2005 жылда беренче кат тулысынча кряшен телендя Жаңа Законъ (Новый Завет) басылыб чыга. Новый Заветка кергян 15 книгя Зяй каласында служить иткян протоіерей Михаилъ Чурашовъ кöчö белян, 7 книгя педагог Мария Матвеева кöчö белян кряшенчягя кючерелеб, Библія ойошмасы белян берлектя редакцияляня. Житеб бетмягян Новый Завет книгялярен кючереўнен тöб кызмятне протоіерей Михаилъ Чурашов башкара, ул апостолъ Павелнын барлык посланиелярен (барысы 14), Апокалипсисны кряшенчягя кючеря, анын Изге апостолларнын арыу жыйынга жибяргян жазылары кючермясе дя була, кючереў эшляре буйынча Казанга круглый столга килгяч ул аны кюрсятя, тик протоіерей Павелъ Павловъ Тихвинъ Алла Анасы чиркяўенен дя эшлягян эше жукка булмасын диб, Новый Завет книгяселя М.Матвеева эшлягян кючермя кертеля.

2005 жылда бастырган тулы Новый Завет книгясендяге Дюрт Евангеліе - Н.И.Ильминскій ўз чоронда кряшенчягя кючергян кызмятляр, Святый апостолларнын эшлярен кряшенчягя кючергян авторлар исемняре сакланмыйчы калган, апостолъ Павелнын барлык посланиеляре белян Апокалипсисъ - протоіерей Михаилъ Чурашовъ кряшенчягя кючергян оло кызмятляр, Изге апостолларнын арыу жыйынга жибяргян жазылары - М.Н.Матвеева кряшенчягя кючергян кызмятляр. Книгянен стилистический радакциясе Л.Д.Белоусова кызмяте. Алланын булышлыгы белян, 2005 жылда кряшенняр тулы Жаңа Законъ книгясен (Новый Завет) кулларына алалар. Бу книгяне Библія ойошмасы (Российское Библейское общество) ўз исябеня бастырыб чыгара.

2012 жылда Жаңа Законъ книгясен протоіерей Павелъ

Павловъ икенче табкыр бастырыб чыгара.

Казер бастырган Новый Завет княгясендя Изге апостолларнын арыу жыйынга жибяргян жазылары, апостолъ Павелнын жибяргян жазылары, Апокалипсисъ - тулысы белян барысы да (22 княгя) протоіерей Михаилъ Чурашовнын кряшенчягя кючергян эшляре. Бу княгяляр 2005 жылда кебек Библія ойошмасы белян редакциялянмягян.

Кряшен туганнарыбыз! Сезнен кулыгыздагы бу княгя Н.И.Ильминскій башлаб жибяргян сауаблы эшнен - кряшеннярне тын ашамныгы белян туйындырыунын аннан башка, анын традициясе буйынча чыкканы. Сöйöклö апостолыбызнын бу дöньядян кючеуеня 100 жылдан артык багыт ўтся дя, анын эше жяшей, анын арыулыклары шушы кючерелгян княгяляр аркылы безгя килеб житя. Княгядя сез бу жалганчы дöньянен алдандырыуыннан жаныгызны саклаб калыб, аны мянге терелеккя кертер öчöн пайдалы ўгет сюзляр табарсыз. Ходайыбызнын апостоллары мяндяляр какында кöйöнöб, алар жаннарын жугалтмасын öчöн шушы ўгет сюзлярне жазыб калдырганнар. Бу сюзляр ич тя кöчöн жугалтмыйчы, жаннарны сауыктыра, аны мянге тормошка äзерлей. Эй туганнар! Чын дöрöс денебездя нык торогоз, без котолсон öчöн мянге терелеккя жул кюрсяткян Ходай Iисусъ Христоска тау итегез, Ходай Iисусъ Христосъ белян булыр öчöн, мянге терелеккя керер öчöн аны кулланыгыз.

Ходайыбыз Iисусъ Христоснын дяўляте, Алла Атанын сöйöўлеге, Святый Тыннын катышыулыгы сезнен барыгыз белян булсын (2 Кор. 13,13).

МАТӨЕЙ ЖАЗГАН АРЫУ ЕВАНГЕЛІЕ

1-нче бюлем

Зач.1. 1 Авраамъ Улы, Давидъ Улы Іисусъ Христоснын тӧб аталарын äйтеӱ: 2 Авраамъ Исаакны тыудырган; Исаакъ Іаковны тыудырган; Іаковъ Іуда белян анын ага-энелярен тыудырган. 3 Іуда Ӧамарадан Фаресъ белян Зараны тыудырган; Фаресъ Эсромны тыудырган; Эсромъ Арамны тыудырган; Арамъ Аминадавны тыудырган. 4 Аминадавъ Наассонны тыудырган; Наассонъ Салмонны тыудырган. 5 Салмонъ Рахавадан Воозны тыудырган; Воозъ Руӧтян Овидны тыудырган; Овидъ Іессейне тыудырган. 6 Іессей Давидъ падшаны тыудырган, Давидъ падша элеке Урія катыны булган катыныннан Соломонны тыудырган. 7 Соломонъ Ровоамны тыудырган; Ровоамъ Авіяны тыудырган; Авія Асаны тыудырган. 8 Аса Іосафатны тыудырган; Іосафатъ Іорамны тыудырган; Іорамъ Озіяны тыудырган. 9 Озія Іоаӧамны тыудырган; Іоаӧамъ Ахазны тыудырган; Ахазъ Езекіяны тыудырган. 10 Езекія Манассіяны тыудырган; Манассія Амонны тыудырган; Амонъ Іосіяны тыудырган. 11 Вавилонга кючяр алдыннан, Іосія Іехонія белян анын ага-энелярен тыудырган. 12 Вавилонга кючкяч, Іехонія Салаӧіилне тыудырган; Салаӧіилъ Зоровавелне тыудырган. 13 Зоровавель Авіудны тыудырган; Авіудъ Еліакимны тыудырган; Еліакимъ Азорны тыудырган. 14 Азоръ Садокны тыудырган; Садокъ Ахимны тыудырган; Ахимъ Еліудны тыудырган. 15 Еліудъ Елеазарны тыудырган; Елеазаръ Матӧанны тыудырган; Матӧанъ Іаковны тыудырган. 16 Іаковъ Марія ире Іосифны тыудырган; Маріядан Христосъ диб äйтелгян Іисусъ тыуган. 17 Шулай Авраамнан Давидка чаклы ун дюрт быуын; Давидтан Вавилонга кючкенче тагы ун дюрт быуын; Вавилонга кючкяннян ары Христоска чаклы тагы ун дюрт быуын.

Зач.2. 18 Іисусъ Христоснын тыуыуы былай булган: Анын анасы Маріяны Іосифка жяряшкяч, алар бергя кушылмаган көйө, Святый Тыннан булыб Маріянын буйында бары беленгян. 19 Анын ире Іосифъ изге кеше икян; ул Маріяны оятлы итмейем диб, аны жяшертен айырыб жибярмякче булган. 20 Тик ул шулай диб уйлагач, Ходай пяриштясе анар төшөндя кюренеб айткян: эй Давидъ улы Іосифъ! син катынын Маріяны кабыл алыб, ўзендя тотарга курыкма, анын буйындагы Святый Тыннан шул; 21 Ул Ул тыудырыр, син Аны Іисусъ диб атарсын; Ул Ўз калкын жазыкларыннан коткарыр, дигян. 22 Бу бар да Ходайнын пагамбяр арткылы айткян сюзе жиреня килер өчөн булды, пагамбяр айтя: 23 Мына кыз буйга узыб Ул тыудырыр, Анын исемен Еммануилъ диб атарлар, Еммануилъ дигяне: Алла безнен белян дигян сюз, диб[1]. 24 Іосифъ жокодан торгач, Ходай пяриштясе кушканча кылган: катынын кабыл алыб ўзендя тоткан. 25 Алай да анар жакыннашмаган. Шуннан ары Марія элек Улын тыудырган; Іосифъ Аны Іисусъ диб атаган.

[1] Ис 7:14.

2-нче бюлем

Зач. 3. 1 Иродъ падша багытында Іудея Виөлеемендя Іисусъ тыугач, жондозчылар кояш чыгышыннан Іерусалимга килеб айткянняр: 2 Іудеянен жаңа тыуган Падшасы кайда? без кояш чыгышында Анын жондозон кюргянгя кюря, Анар башырырга килдек, дигянняр. 3 Мыны эшетеб, Иродъ та, анын белян бөтөн Іерусалимъ дя жөдяб киткянняр. 4 Иродъ бар баш священниклярне, калык укымышларын жыйыб, алардан: Христосъ кайда тыуасы? диб сораган. 5 Алар анар айткянняр: Іудея Виөлеемендя тыуасы, пагамбяр арткылы былай жазылган шул: 6 Син дя Виөлеемъ, Іуда жире, Іуданын оло калаларыннан ич тя ким төгөл: синнян башлык чыгар шул, Ул Минем калкым Израилне көтөб жөртөр, дигян[2]. 7 Шуннан суң Иродъ жондозчыларны жяшертен чакырыб алыб, алардан жондоз кюренгян багытны элпяляб сораган. 8 Аннары аларны Виөлеемгя жибяргян чагында аларга айткян: барыгыз,

[2] Мих 5:2.

Бала турысында айырмачык белегез, Аны табкач, миңа да хабяр итегез, мин дя барыб Аңар башырыр ыйым, дигян. 9 Алар падшаны тыңнаб киткянняр; кояш чыгышында кюренгян жондоз шундук алар алдыннан бара башлаган; барыб житкяч, Бала торган урын östöндя туктаган. 10 Жондозны кюреб, алар бик сöйöнгянняр. 11 Öйгя кергяч, анасы Марія белян Баланы кюреб, Аңар жыгылыб башырганнар; сауытларын ачыб, алтын, ладанъ, смирна алыб, Аңар бюляк итеб биргянняр. 12 Төшляренда Иродка кайтмаска хабяр алыб, бютян жул белян ўз жакларына кайтыб киткянняр.

Зач. 4. 13 Алар киткяч, Ходай пяриштясе Іосифка төшöндя кюренеб äйткян: тор, Баланы да, анасын да алыб, Египеткя кач, мин синa äйткенче шунда тор, Иродъ Баланы ўтерер öчöн эзлямякче була шул, дигян. 14 Ул тönня тороб, Баланы да, Анын анасын да алыб, Египеткя киткян. 15 Иродъ ўлгенче шунда торган; шулай итеб, Ходайнын пагамбяр арткылы: Египеттян Улымны чакырыб алдым, дигян сюзе жиреня килгян[1]. 16 Жондозчылар мыскылга калдырганны кюргяч, Иродъ бик ачыуы килеб, Виөлеемдагы, анын буган тиря жюнендяге бар балаларны, жондозчылардан сораб айырмачык белгян багытка чамалаб, ике жяштягелярен, аннан кечелярен дя ўтерергя жибяргян. 17 Шул чакта Іеремія пагамбяр арткылы äйтелгян сюз жиреня килгян; ул äйтя: 18 Рама каласында бик тилмереб, ўкереб жылаган ауаз эшетелгян: Рахиль балалары öчöн жылаб, алар жукка кюря, тыйыласы килмягян, диб[2]. 19 Иродъ ўлгяч, Египеття Ходай пяриштясе Іосифка төшöндя кюренеб, 20 Тор, Баланы да, анасын да алыб, Израиль жиреня кайт, Бала жанын эзляўчеляр инде ўлделяр шул, дигян. 21 Ул тороб, Баланы да, Анын анасын да алыб, Израиль жиреня кайткан. 22 Іудеядя Архелай ўз атасы Иродъ урнында падшалык иткянне эшетеб, ул анда барырга курыккан; төшöндя хабяр алыб, Галилея тирясеня киткян. 23 Анда баргач, Назаретъ дигян калага урыннашкан; шунын белян пагамбярляр арткылы: Ул Назорей диб аталыр дигян сюз жиреня килгян.

[1] Ос 11:1.

[2] Іер 31:45.

3-нче бюлем

Зач. 5. 1 Бердя бер көннярдя чумылдырыучы Іоаннъ Іудеянын буш кырына килеб, сөйляб жөргян: 2 Тяўбя итегез, инде кюк падшалыгы жакыннашты шул, дигян. 3 Исаія пагамбярнен: Ходайга жул äзерлягез, Анар туры сукмаклар жасагыз диб, буш кырда кычкырыучынын ауазы, диб äйткяне шул ўзе булган[1]. 4 Іоаннын ўзенен östöндяге кейеме дöя жононнан, билендяге эзяре тиредян булган; ашамныгы сикерткя белян кыр балы булган. 5 Шул чагында Іерусалимнян, бötön Іудеядян, Іорданнын буган тиряляреннян чыгыб, анар килгянняр; 6 Жазыкларын äйтеб, аннан Іорданъ сыуында чумылдырылганнар. 7 Іоаннъ кюб фарисейляр, саддукейляр анар чумылырга килгянне кюреб, аларга äйткян: эй жылан тыумалары! буласы кыйыннан качарга сезгя кем äйтте? 8 Тяўбягя тейешле жимеш булдырыгыз; 9 Безнен атабыз Авраамъ диб кюнелегездя уйламагыз; мин сезгя äйтямен: шушы ташлардан Авраамга балалар булдырырга Алланын кыуатыннан киля, дим. 10 Балта инде агач тöбöндя жата: арыу жимеш китермей торган агачнын äр-кайсын кисяляр дя утка ташлыйлар. 11 Мин сезне, тяўбягя китерер öчön, сыуга чумылдырам, äммя минем артымнан Килеўче миннян кыуатлы; мин Анын аягына кея торган нястясен кулыма тотоб (салгызырга) да тормоймын; Ул сезне Святый Тын белян, ут белян чумылдырыр. 12 Анын көряге кулында, Ул ындырын äрчер, бодайын клятеня жыяр, кибяген сюнмяс утка жандырыр, дигян.

Зач. 6. 13 Шул чакта Іисусъ Галилеядан Іорданъ жанына Іоаннан чумылдырылырга килгян. 14 Äммя Іоаннъ Аны туктатыб äйткян: мин Синнян чумылдырылырга тейеш, Син Ўзең миня килясен, дигян. 15 Іисусъ анар жауаб биреб äйткян: туктатма äле, безгя шулай итеб äрбер дöрöслökне кыларга тейеш, дигян; аннары Іоаннъ Аны туктатмаган. 16 Іисусъ чумылгач, тизюк сыудан чыккан; шул сяттюк Анар кюкляр ачылган; (Іоаннъ) Анын östöня Алла Тыны кюгярчен ряўешле булыб ингянне кюргян. 17 Шул чагында кюктян ауаз килгян: Шушы Минем сöйökле Улым, Анда Минем ризалыгым, диб.

---

[1] Ис 40:3.

4-нче бюлем

Зач. 7. 1 Шуннан суҥ Тын, шайтанга сынатыр өчөн, Іисусны буш кырга алыб барган. 2 Анда (Іисусъ) кырык көн, кырык төн ураза тоткан, калдыгында ачыккан. 3 Сынаучы Анын катына килеб äйткян: ägяр Син Алла Улы булсаҥ, äйт, бу ташлар икмяк булсыннар, дигян. 4 Ул жауаб биреб äйткян: кеше икмяк белян гня тора алмас, ämмя Алла ауызыннан чыккан äр-бер сюз белян (торор), диб жазылган, дигян[1]. 5 Аннары шайтан Аны арыу калага алыб барган; анда Аны чиркяў тюбясенен кырыйына бастырыб, 6 Аҥар äйткян; ägяр Син Алла Улы булсаҥ, тюбян сикер; жазылган ич: Сине Ўз пяриштяляреня саклатыр, Сине алар кулларына кютяреб барырлар, аягыҥ ташка сёртёнмяс, диб[2]. 7 Іисусъ аҥар äйткян: тагы жазылган ич: Алла Ходайыҥны сынама, диб[3]. 8 Жяня тагы шайтан Аны бик бейек тау östöня алыб барган, (шуннан) дöньядяге бар падшалыкларны, аларнын эямен кюрсятеб, 9 Аҥар äйткян: ägяр миҥа жыгылыб башырсаҥ, шушыларны барысын да Синҥа бирем, дигян. 10 Шунда Іисусъ аҥар äйткян: кит миннян шайтан, жазылган ич: Ходай Аллаҥа гна башыр, бер Аҥар гна кызмят ит, диб[4]. 11 Аннары шайтан Анын жаныннан киткян; шундук пяриштяляр килеб Аҥар кызмят иткянняр.

Зач. 8. 12 Іисусъ Іоаннын (ötörмянгя) жабылганын эшеткяч, Галилеяга киткян. 13 Аннары Назаретны ташлаб, Завулонъ белян Нефөалимъ тиряляреня, дингез жарындагы Капернаумга барыб урыннашкан. 14 Шулай Исаія пагамбяр арткылы äйтелеў жиреня килгян, ул äйткян: 15 Завулонъ жире, Нефөалимъ жире, дингез жулында, Іорданъ буйындагы жалган деннеляр торган Галилея, 16 Карангыда утырыучы калык зур жактыны кюргян, ўлем карангысы торган жакта утырыучыларга жакты жакгырган, дигян[5]. 17 Шул чактан Іисусъ сöйляб жöрöй башлаган: тяўбя итегез, кюк падшалыгы жакынашты инде, диб.

Зач. 9. 18 Галилея дингезе жаныннан ўткян чагында (Іисусъ) ике ага-энене Петръ дигян Симонны, анын энесе Андрейне кюргян; алар балыкчылар икян, дингезгя ау салалар икян. 19 Ул аларга äйткян: Минем артым-

[1] Втор 8:3.
[2] Пс 90:11-12.
[3] Втор 6:16.
[4] Втор 6:13.
[5] Ис 9:1-2.

нан барыгыз, Мин сезне кешелярне тотоучы итярмен, дигян. 20 Алар шундук ауларын калдырыб, Анын артыннан киткянняр. 21 Аннан китеб бара торгач, Ул тагы ике ага-энене, Зеведей Іаковын, анын энесе Іоанны кюргян; алар аталары Зеведей белян кимядя ауларын тӧзятяляр икян; Ул аларны да чакырган. 22 Алар шундук аталарын да кимяне дя калдырыб, Анын артыннан киткянняр. 23 Іисусъ синагогаларда ӧйрятеб, Алла падшалыгынын изге хабярен сӧйляб, кешеляр арасындагы тӧрлӧ чирне, какшаулыкны тӧзятеб, бӧтӧн Галилеяны жӧрӧб бетергян. 24 Бӧтӧн Сирія жирендя Анын турысында эшетеб, Анар бар чирлелярне, тӧрлӧ ауырыуларны, ӳз чирлелярне, женнелярне, жаңа ай белян азаблана торганнарны, сансызларны китергянняр, Ул аларны тӧзяткян.

Зач. 10. 25 Анын артыннан Галилеядан, Ун кала (дигян жирдян), Іерусалимнян, Іудеядян, Іорданнын ары жагыннан да кюб калык жӧргян.

5-нче бюлем

1 Іисусъ калыкларны кюреб, тау ӧстӧня менеб утыргач, Анын жанына ӧйрянеӳчеляре килгянняр. 2 Ул аннары ауызын ачыб, аларны былай диб ӧйрятя башлаган: 3 Жыуаш кюңеллеляр бахетле: кюк падшалыгы аларныкы шул. 4 Жылаучылар бахетле: алар сӧйӧнӧч табарлар шул. 5 Сабырлыклылар бахетле: аларга жир теяр шул. 6 Дӧрӧслӧккя ачыгыб, сыусаб тороучылар бахетле: алар тукланырлар шул. 7 Изгелеклеляр бахетле: алар жарлыкаулы булырлар шул. 8 Таза кюңеллеляр бахетле: алар Алланы кюрерляр шул. 9 Татыуландырыучылар бахетле: алар Алла уллары диб аталырлар шул. 10 Дӧрӧслӧк ӧчӧн кыуылыучылар бахетле: кюк падшалыгы аларныкы шул. 11 Ӓгяр Минем какымда сезнен ӧстян жалганнаб, тӧрлӧ усал сюз ӓйтсяляр, сезне курласалар, сезне кыусалар, сез бахетле. 12 Сӧйӧнӧгӧз, кыуаныгыз: сезгя кюктя теясе сауаб бик оло шул; сездян элеке булган пагамбярлярне дя шулай кыуганнар. 13 Сез жир тозо; тоз ӳз кыуатын жугалтса, ней белян тозло итярсен? ул аннары бер нястягя дя жараусыз булыр, ул тик тышка чыгарыб, кеше аяк астына ташларга гна жарар.

Зач. 11. 14 Сез дӧнья жактысы. Тау тюбясендяге кала кюренмей тора алмас. 15 Эшямне дя

жандыргач, сауыт астына угыртмыйлар, ämмя эшямдялгя (утырталар), ул аннары öйдягелярнен барысына да жактыртыб тора. 16 Сезнен жактыгыз да кешеляр алдында шулай жактырсын: алар сезнен арыу эшлярегезне кюреб, кюктяге Атагызны даннасыннар ыйы. 17 Мин законны, пагамбярляр (сюзлярен) бозарга килгян диб уйламагыз, бозарга килмядем, ämмя тутырырга килдем. 18 Чыннаб äйтямен сезгя: кюк белян жир ўзгяргенче законнын бер сюзе дя, бер сызыгы да ўзгярмяс, ämмя барысы да жиреня килер. 19 Кем дя кем шушы кечкеня гня бойорокларнын берсен ўзе бозоб, кешелярне да шулай öйрятся, ул кюк падшалыгында иң кечегя саналыр; ämмя кем дя кем (аларны) ўзе кылыб, (бютяннярне дя) öйрятся, ул кюк падшалыгында олога саналыр.

Зач. 12. 20 Сезгя äйтямен: ägяр сезнен дöрöслöгöгöз княгячелярнекеннян, фарисейлярнекеннян артык булмаса, сез кюк падшалыгына керя алмассыз. 21 Сез эшеткянсез боронголарга äйткянне: ўтермя, кем ўтерся, хокömгя тейешле була, дигянне[1]. 22 Ämмя Мин сезгя äйтямен: ўз туганына жукка ўпкя тотоучы äр-кем хокömгя тейешле; кем ўз туганына: эй жюнсез диб äйтся, ул оло хокömгя тейешле; кем: эй тиле диб äйтся, ул тамук утына тейешле. 23 Син бюлягеңне алтарга алыб баргач, анда туганыңнын синя ўпкясе бары исеня төшся, 24 Бюлягеңне алтарь алдында калдыр да, барыб элеке туганың белян татыуланыш, аннары кайтыб бюлягеңне китер. 25 Даучың белян жулда чагындук тизеряк татыуланыш, жугыйса даучың сине тюрягя бирмясен, тюря сине кызмятчесеня биреб, öтörмянгя жабтырыр. 26 Чыннаб äйтямен синя: калдык тейенеңне биреб бетермейче, аннан чыга алмассын.

Зач. 13. 27 Сез эшеткянсез боронголарга äйткянне: уйнашлык итмя, дигянне[2]. 28 Ämмя Мин сезгя äйтямен: катын-кызга азгын няпес белян караучы äркем ўз кюңелендя анын белян уйнашлык итеб бетергян була. 29 Ägяр уң кюзең сине кызыктырса, син аны ўзеңнян сыуырыб алыб ташла: бötön тянең тамук утына ташланасы булгынчы, саннарыңнын берсе гня бетеўе синең öчön жакшырак ич. 30 Ägяр сине уң кулың кызыктырса, син аны ўзеңнян кисеб ташла: бötön тянең тамук утына ташланасы

[1] Исх 20:13.

[2] Исх 20:14.

булгынчы, саннарыңнын берсе гня бетеўе синең өчөн жакшырак ич. 31 Тагы айтелгян: кем катынын айырса, анар айырыу жазыуын биреб жибярсен диб. 32 Ämмя Мин сезгя айтямен: кем ўз катынын уйнашлык айыбы булмаган көйö айырыб жибярся, ул аны уйнашлыкка сала; кем айырыб жибяргян катынны алса, ул да уйнашлык итя.

Зач. 14. 33 Тагы эшеткянсез боронголарга айткянне: иткян антыңны бозма, Ходайга адарынганыңны кыл, дигянне. 34 Ämмя Мин сезгя айтямен: ич тя карганма; кюк белян дя: ул Алла престолы шул; 35 Жир белян дя: ул Анын аяк асты шул; Іерусалимъ белян дя: ул оло Падшанын каласы шул. 36 Ўз башыңг белян дя карганма: син шул бер гня чячеңне дя ак та кара да итя алмассын. 37 Сезнен сюзегез: эйе, эйе, жя жук, жук дейеў гня булсын; аннан артыгы жаманнан. 38 Сез эшеткянсез: кюзгя карышы кюз, тешкя карышы теш, дигянне. 39 Ämмя Мин сезгя айтямен: усалга карышы килмя. Беряў синең уң жанагына сукса, анар икенчесен дя бороб тот. 40 Беряў синең белян даулашыб, кюлмягеңне аласы ится, син анар öст кейемеңне дя бир. 41 Беряў сине ўзе белян бер чакырым барырга иректезляся, анын белян икене бар.

Зач. 15. 42 Синнян сорагангa бир, синнян äжяткя аласы килгяннян боролоб китмя. 43 Сез эшеткянсез: жакыныңны сöй, дошманыңны кюрялма, дигянне. 44 Ämмя Мин сезгя айтямен: дошманнарыгызны сöйöгöз, сезне каргаучыларга арыулык телягез, сезне кюрялмый торганнарга жакшылык кылыгыз, сезне кыйырсытыучылар öчöн, сезне кыуыучылар öчöн теляк итегез, диб. 45 (Шулай итсягез), сез кюктяге Атагызнын уллары булырсыз: Ул шу кояшын усалларга да, арыуларга да жактырта; жангырын гаделлярга дя, гадел төгöллярга дя жаудыра. 46 Äгяр сез ўзегезне сöйгяннярне гня сöйсягез, сезгя нейдей сауаб булыр? мытарлар[1] да шулай кылалар төгöл ме? 47 Сез дустларыгыз белян гня исянняшсягез, ней артык кыласыз? Жалган деннеляр дя шулай кылынышалар төгöл ме? 48 Кюктяге Атагыз арыулыкка ничек тулы, сез дя шулай тулы булыгыз.

[1] Мытарь дигяне имана жыйыучы кеше.

6-нче бюлем

Зач. 16. [1] Сак булыгыз, сезне кеше кюрсен диб, садакагызны кеше алдында бирмягез: алай итсягез, сезгя кюктяге Атагыздан сауаб булмас. [2] Шуңар кюря син дя садака биргян чагында, кюз алдында гна кылыныучылар кюк ўз алдыңнан жангыртма, алар ўзлярен кешеляр мактасыннар диб, синагогаларда, урамнарда шулай кылыналар. Чыннаб äйтямен сезгя; алар инде ўзляреня теясене алалар. [3] Ämмя син садака биргяндя уң кулың ней кылганны сул кулың белмясен. [4] Синең садака биреўең жяшерен булсын; жяшерендяген кюреўче Атаң синға ачыкта кайтарыр. [5] Син теляк иткян чагында да кюз алдында гна кылыныучылар кюк булма: алар кешеляр кюрсенняр диб, синагогаларда, урам чатларында туктаб келяў итеўне сöяляр. Чыннаб äйтямен сезгя: алар инде ўзляреня теясене алалар. [6] Ämмя син теляк итяр чагында бюлмяңя кер дя, ишегеңне жабыб, жяшерендяге Атаңа инял, жяшерендяген кюреўче Атаң синға ачыкта кайтарыр. [7] Теляк иткяндя, жалган деннеляр кюк, артыгын äйтмягез, алар кюб сюз äйтеў арткылы эшетелербез диб уйлыйлар шул. [8] Аларга ошаулы булмагыз: (кюктяге) Атагыз сезгя ней киряген сез сорагынчук белядер шул. [9] Сез былай диб телягез: эй кюктяге Атабыз, данны булыб торсон исемең Синең. [10] Килсен падшалыгың Синең; жирдя дя кюктягечя булсын иркең Синең. [11] Бöгöн көннöк икмягебезне бир безгя. [12] Бурычларыбызны кичер, без дя безгя бурычлы булганнарга кичергян кюк. [13] Безне алданырга ирек жибярмя; жаманнан коткар безне. Падшалык, кыуат, ололок гумергя Синеке шул. Аминь.

Зач. 17. [14] Сез кешелярга жазыкларын кичерсягез, кюктяге Атагыз сезгя дя кичерер. [15] Ämмя сез кешелярга жазыкларын кичермясягез, кюктяге Атагыз сезнен жазыкларыгызны да кичермяс. [16] Сез ураза тоткан чагында да кюз алдында гна кылыныучылар кюк моңайыб жöрмягез; алар шу кешелярга ураза тоткан булыб кюренер öчöн гня, чырайларын карангыландырыб жöрöйляр. Чыннаб äйтямен сезгя: алар инде ўзляреня теясене алалар. [17] Син ураза тоткан чагында башыңны майла; битеңне жыу; [18] Кешеляр алдында ураза тоткан булыб кюренмя, тик жяшерендяге Атаңа гна кюрен; жяшерендяген кюреўче Атаң синға ачыкта кай-

тарыр. 19 Жир өстөндя ўзегезгя мал жыймагыз, мында кöя дя (тея), тутыгыб та бетя, бурлар да казыб кереб урлыйлар. 20 Ämмя ўзегезгя малны кюктя жыйыгыз, анда кöя дя (теймей), тутыкмый да, бурлар да казыб кереб урламыйлар. 21 Малыгыз кайда булса, кюнелегез дя шунда булыр шул.

Зач. 18. 22 Тян жактырткычы кюз; ägяр синең кюзең таза булса, бöтöн тянең дя жакты булыр. 23 Ägяр кюзең начар булса, бöтöн тянең дя карангы булыр. Ägяр эчендяге жактың карангы булса, синдя карангылык ней катле булыр? 24 Беряў дя ике байга кызмят итя алмас; жя берсен жаратыр, икенчесен жаратмас; жя берсеня кюнелдян жöрöр, икенчесеня кюнелсез гня жöрöр; сез дя Аллага да, байлыкка да кызмят итя алмассыз. 25 Шунар кюря сезгя äйтямен: ней ашарбыз, ней эчярбез диб жаныгыз öчöн кöймягез, тянегез öчöн дя ней кеярбез диб (кöймягез); жан ашамныктан, тян кеймнян оло тöгöл ме? 26 Ауа кошларына карагыз: алар чячмейляр дя, урмыйлар да, амбарга да жыймыйлар, алай да кюктяге Атагыз аларны туйдыра; сез алардан кюб кадерле тöгöл ме? 27 Кем сезнен арадан кöйöнöб, ўз буйын бер гня терсяк буйы арттыра алыр? 28 Кейем öчöн дя ник кöясез? Кырдагы чячяклярга карагыз, алар ничек ўсяляр? эшлямейляр дя, эрлямейляр дя. 29 Мин сезгя äйтямен: Соломонъ бик данныклы булса да, аларнын берсе чаклы да кейеня алмаган. 30 Ägяр дя бögöн бар, иртягя пичкя ташларлык кыр ўлямен Алла шундый кейендергяч, эй аз ышаныучылар, сезне бигряктя жакшырак (кейендермяс) меней?

Зач. 19. 31 Шулай, сез ней ашарбыз, ней эчярбез, ней кеярбез диб кöйöнмягез. 32 Быларнын барын да жалган деннеляр эзлейляр шул; ул нястяляр барысы да сезгя киряк икянне кюктяге Атагыз белядер. 33 Иң элеке (Алла) падшалыгын, Анын дöрöслögöн эзлягез, аннары ул нястяляр бар да сезгя östяб бирелер. 34 Шулай, сез иртяге кöн öчöн кöйöнмягез, иртяге кöн ўзе öчöн ўзе кöйöнöр. Äр-бер кöнгя ўзе öчöн ўз кöйögö житяр.

7-нче бюлем

Зач. 20. 1 Ўзегезне тикшермясенняр дисягез, сез дя тикшермягез. 2 Кешене ничек тикшереў белян тикшерсягез, сезне дя (шулай) тикшererляр шул; кешегя ничек ўлчяў бе-

лян ўлчясягез, сезгя дя шулай ўлчярляр. 3 Ник туганың кюзендяге ботакка карыйсын, ämмя ўз кюзеңдяге бюряняне сизмейсен? 4 Жя ўз кюзеңдя бюряня булгач, туганыңа ничек äйтерсен: кая, мин синең кюзеңдяге ботакны алыйым? диб. 5 Эй кюз алдында гна кылыныучы! элеке ўз кюзеңдяге бюряняне ал, аннары туганыңнын кюзендяге ботакны алырга кюрерсен. 6 Арыуны этлярга бирмягез, энжегезне дунгызлар алдына ташламагыз, алар аны аяклары белян табтамасыннар, боролоб ўзегезне özгяляб бетермясенняр. 7 Сорагыз, бирелер сезгя; эзлягез, табарсыз; кагыгыз, ачарлар сезгя: 8 Äр-бер сораучы аладыр шул, эзляўче табадыр, кагыб тороучыга да ачалар. 9 Жя сезнен арада улы икмяк сораса, анар таш биреўче кеше бар мы? 10 Жя балык сораса, анар жылан бирер меней? 11 Шулай, сез ўзегез жаман булыб та, балаларыгызга жакшыны биря белгяч, кюктяге Атагыз Ўзеннян сораучыларга жакшыны бигряк тя бирер.

Зач. 21. 12 Äр-бер турыда кешеляр сезгя ней кылганны телясягез, сез дя аларга шулай кылыгыз: законъ да, пагамбярляр дя шулай (кушалар) шул. 13 Тар кабкадан керегез: киң кабка, иркен жул жукка чыгарырга алыб баралар шул; кюбесе шулардан барадыр. 14 Тар кабка, кысан жул терелеккя алыб баралар; аларны äзляр гня очраталар.

Зач. 22. 15 Жалган пагамбярлярдян сакланыгыз; алар сезнен катыгызга тышларыннан сарыктый (жыуаш) булыб киляляр, ämмя ўзляре эчлярендя талаучы бюреляр кюк. 16 Сез аларны жимешляреннян белерсез; чянечкеле агачтан жözöм жыялар мы? жя тигяняк сабыннан смоква жыялар мы? 17 Шулай, äр-бер жакшы агач жакшы жимеш китеря, ämмя начар агач начар жимеш китеря. 18 Жакшы агач начар жимеш китермяс, ämмя начар агач жакшы жимеш китермяс. 19 Жакшы жимеш китермей торган äр-бер агачны кисеб утка ташлыйлар. 20 Шулай, сез аларны жимешляреннян белерсез.

Зач. 23. 21 Мине: Ходай, Ходай, диб äйтеўче бар да кюк падшалыгына кермяс, тик кюктяге Атамнын иркен кылыучы гна (керер). 22 Шул көннö кюбесе Мина äйтерляр: эй Ходай, эй Ходай, без Синең исемең белян пагамбярлек иттек тöгöл ме? женнярне дя Синең исемең белян чыгардык тöгöл ме? Синең исемең белян кюб кодрятляр кылдык тöгöл ме? дирерляр. 23

Шул чагында аларга äйтерем: Мин сезне бер чакта да белмядем, эй законсызлык кылыучылар, Миннян китегез, дирем.

Зач. 24. 24 Минем шушы сюзляремне тыңнаб, аларны кылыучынын äр-берсен, öйöн таш öстöня торгозган акыллы кешегя ошатырмын. 25 Жангыр жауыб, иңешляр ташыб, жилляр жилляб (барысы да) шул öйгя бярелгянняр, шунда да ул, нигезен таш öстöня корганныктан, аумаган. 26 Äммя Минем шушы сюзляремне эшетеб, аларны кылмаган äр-кем, öйöн ком öстöня торгозган исябсез кешегя ошар. 27 Жангыр жауыб, иңешляр ташыб, жилляр жилляб, (барысы да) шул öйгя бярелгянняр; ул öй шундук ауыб, бötöнняй жимерелеб беткян. 28 Iисусъ шушы сюзлярне äйтеб бетергяч, Анын öйрятеуеня калыкнын исе киткян: 29 Ул шу аларны кодряте барын тойдорыб öйряткян, äммя книгячеляр белян фарисейляр кюк тöгöл.

8-нче бюлем

1 Iисусъ таудан тöшкяч, Анын артыннан кюб калык баргган. 2 Шунда тяне кутырлаган бер кеше Анын жанына килеб, Аңар башырыб äйткян: эй Ходай! телясяң, Син мине тазарта алыр ыйың, дигян. 3 Iисусъ кулын сузыб, аңар тейенеб äйткян: телеймен, тазарын, дигян: шул сяттюк ул кутырыннан тазарган. 4 Iисусъ аңар äйткян: аң бул, беряўгя дя äйтмя; тик барыб ўзеңне священникка кюрсятеб, Моисей законында кушканча, аларга таныклыкка бюляк китер, дигян.

Зач. 25. 5 Iисусъ Капернаумга кергяч, Анын катына бер сотникъ килеб, 6 Аңар ўтенгян: Эй Ходай! öйдя кызмятчем сансызланыб жата, каты азаблана, дигян. 7 Iисусъ аңар äйткян: Мин барыб, аны тöзятермен, дигян. 8 Сотникь Аңар жауаб биреб äйткян: эй Ходай! Син минем öйömя керергя мин тейешле тöгöл, Син тик сюз гня äйт, шул сяттюк кызмятчем сауыгыр, дигян; 9 Мин шу ўзем кеше кул астындагы кеше булсам да, Ўз кулымда салдатлар тотам; берсеня: бар, дисям, бара; икенчесеня: кил, дисям, киля; кызмятчемя: мыны кыл, дисям, ул кыладыр, дигян. 10 Iисусъ мыны эшеткяч, исе китеб, артыннан килеўчелярга äйткян: чыннаб äйтямен сезгя: Израилдя дя бу катле ышаныуны табмадым, дигян. 11 Сезгя äйтямен: кюбесе кояш чыгышыннан,

кояш байышыннан килеб, Авраамъ белян, Исаакъ белян, Іаковъ белян бергя кюк падшалыгында урыннашырлар. 12 Әммя бу падшалыкнын уллары тыштагы карангылыкка кыуыб чыгарылырлар, анда жылаб, теш шыкырдатыу булыр, дигян. 13 Іисусъ аннары сотникка әйткян: бар, ышанганынча синға булсын, дигян; анын кызмятчесе шул сяттюк сауыккан.

Зач. 26. 14 Іисусъ Петръ өйöня килгяч, анын катынынын анасын тир кастасы белян жаткынын кюргян. 15 Іисусъ анын кулына тейенеўе белян тир кастасы беткян; шундук тороб, ул Анар кызмят иткян. 16 Кич булгач, Іисусъ жанына кюб женнянгян кешелярне китергянняр; Ул сюзе белян женнярне кыуыб чыгарган; чирлелярне барысын да тöзяткян. 17 Шулай Исаія пагамбяр арткылы әйтелеў жиреня килгян; ул әйткян: әлсезлегебезне Ул Ўз öстöня алыб, чирляре безне кютярде, дигян. 18 Іисусъ Ўз әйлянясендя калык кюбне кюреб, (öйрянеўчеляреня) икенче жакка чыгарга кушкан. 19 Шунда бер укымыш кеше Анар килеб әйткян: эй Öйрятеўче! Син кая гна барсаң да, мин артыннан барым, дигян. 20 Іисусъ анар әйткян: тölкölярнен önняре бар, ауа кошларынын да оялары бар, әммя Ädям Улынын баш салыб жатыр урны да жук, дигян. 21 Тагы öйрянеўчеляренен берсе Анар әйткян: эй Ходай! миңа элеке, кайтыб атамны кюмяргя роксят бирче, дигян. 22 Іисусъ анар әйткян: Минем артымнан бар, ўлеклярен кюмяргя ўлектейляргя калдыр, дигян.

Зач. 27. 23 Іисусъ кимягя кергяч, Анын артыннан öйрянеўчеляре дя кереб, Анын белян барганнар. 24 Шул чакта дингез öстöндя бик каты дауыл чыгыб, тулкыннар кимяне баса башлаганнар, әммя Ул жоклаган икян. 25 Öйрянеўчеляре килеб, Аны уятыб әйткянняр: эй Ходай, бетябез, безне сакла, дигянняр. 26 Ул аларга әйткян: эй аз ышаныучылар, сез ник алай куркыучан? дигян. Аннары Ул тороб, жилне дя, дингезне дя тыйыуы белян, тыб-тыныч булган. 27 Кешеляр исляре китеб әйтешкянняр: бу кем, жил дя, дингез дя Аны тыңныйлар? дигянняр.

Зач. 28. 28 Іисусъ (дингезнен) икенче жагындагы Гергесинъ жиреня баргач, Аны ўлек куя торган урыннардан чыккан ике женнянгян кеше очратканнар; алар бик усал икян, шунныктан ул жулдан беряў дя ўтеб жöрöй

алмаган. 29 Алар кинят кычкырганнар: эй Алла Улы Іисусъ, Синең бездя ней эшең бар? Син мында безне багыт житмяс борон азабландырырга килгянең, дигянняр. 30 Алардан жыраграк зур табын дунгыз көтяляр икян. 31 Женняр Аңар ӳтенгянняр: Син безне кыуыб чыгарсаң, безгя дунгыз көтӧӳеня барырга кушсана, дигянняр. 32 Ул аларга әйткян: барыгыз, дигян; алар чыгыб, дунгыз көтӧӳеня киткянняр; шундук бӧтӧн дунгыз көтӧӳе текя жардан дингезгя атылыб, сыуга батыб беткян. 33 Әммя көтӧӳчеляр жӧгӧрӧб калага кайтканнар да, ней булганны барын да белдергянняр, женнеляргя ней булганны да (әйткянняр). 34 Аннары бӧтӧн кала Іисусъ карышысына чыккан; Аны кюргяч, безнен тирядян китсяня диб, Аңар ӳтенгянняр.

9-нчы бюлем

Зач. 29. 1 Ул аннары кимягя кереб, (дингезне) кичеб, кире Ӳз каласына кайткан. 2 Шунда Аңар бер сансызны жаткан урны белян кютяреб китергянняр; Іисусъ аларнын ышаныуын кюреб, сансызга әйткян: улым, курыкма! синға жазыкларың кичереля, дигян. 3 Шунда книгячелярнен кайсылары ӳз кюңелляренда: Ул Алланы курлый, дигянняр. 4 Іисусъ аларнын уйлаганнарын белеб әйткян: сез кюңелегездя ник жаманны уйлыйсыз? 5 Ней асатрак әйтергя: синға жазыкларың кичереля диб ме? әлля тор да, жӧрӧ диб ме? 6 Әммя Ядям Улынын жир өстӧндя жазыклар кичерергя кыуаты барын сез белсен диб, (әйтямен дигян дя сансызга әйткян): тор да, урнынгны алыб, өйӧңя кайт, дигян. 7 Ул торган да, (урнын алыб) өйӧня киткян. 8 Калык мыны кюргяч, исе китеб, кешеляргя шундый кыуат биргян Алланы даннаган.

Зач. 30. 9 Іисусъ аннан китеб барышлый сатлык мал акчасын жыя торган тӧштя утырган, Матөей атлы кешене кюреб, аңар әйткян: Минем артымнан бар, дигян; ул тороб, Анын артыннан киткян. 10 Іисусъ бер өйдя утырган чакта, кюб мытарлар белян жазыклылар килеб, Анын белян, өйрянеӳчеляре белян бергя утырганнар. 11 Шуны кюреб, фарисейляр Анын өйрянеӳчеляреня әйткянняр: сезнен Өйрятеӳчегез ник алай мытарлар белян, жазыклылар белян бергя ашый, эчя? дигянняр. 12 Іисусъ мыны эшетеб, аларга әйткян: сауларга лекарь киряк тӧгӧл, әммя чирле-

лярга (киряк). 13 Барыгыз, Мин изгелек телеймен, ӓммя корман тӧгӧл, дигяннен ней икяняня ӧйрянегез. Мин жазыклыларны тяўбягя ӧндярга килдем шул, ӓммя гаделлярне тӧгӧл, дигян.

Зач. 31. 14 Шул чакта Іоаннъ ӧйрянеўчеляре Іисуска килеб ӓйткянняр: без дя, фарисейляр дя кюб ураза тотабыз, ӓммя Синеӈ ӧйрянеўчеляреӈ ней ӧчӧн ураза тотмойлар? дигянняр. 15 Іисусъ аларга ӓйткян: туйдагы кодаларга, кеяў алар белян бергя чагында, кайгырыб тороргa мӧӈким ме? алардан кеяў алыныр кӧнняр килеб житкяч, алар шунда ураза тота башларлар. 16 Беряў дя тузган кеймегя агартмаган киндердян жамау салмый: жаӈа жамау тузган кеймне айырыр да, жыртыгы элекегедян дя чагырак булыр шул. 17 Жаӈа аракыны да иске турсыкка [1] салмыйлар: салсаӈ, турсык жарылыр да, аракысы тюгелер, турсыгы да жарамаска чыгар; ӓммя жаӈа аракыны жаӈа турсыкка тутыралар, аннары алар икесе дя бӧтӧн кӧйӧ торалар, дигян.

Зач. 32. 18 Ул аларга мыны сӧйлягян чагында, Анын жанына бер башлык килеб, Аӈар башырыб ӓйткян: минем кызым инде ӱлгяндер дя, Син барыб анын өстӧня кулыӈ салсана, ул аннары терелер эйе, дигян. 19 Іисусъ тороб, ӧйрянеўчеляре белян анын артыннан барган. 20 Шул чакта ун ике жыл кан агыуы белян азабланган бер катын Анын артыннан жакыннашыб, кейеменен кырыйына тейенгян. 21 Ул кюӈеленда: Анын кейеменя гня тейенсям дя сауыгырмын, диб ӓйткян икян. 22 Іисусъ боролоб караган да, аны кюреб ӓйткян: кызым, курыкма! сине ышаныуыӈ коткарды, дигян; катын шул сяттюк сауыккан. 23 Іисусъ башлык ӧйӧня кергяч, быргычыларны, калык болганганны кюреб, 24 Аларга ӓйткян: мыннан чыгыгыз, кыз ӱлмягяння баса, жоклой ич, дигян; алар Аннан кӧлгянняр. 25 Ул калыкны чыгаргач, кереб кызнын кулыннан тотоу белян кыз торган. 26 Бу эш турысында хабяр шундагы бар жиргя жяйелгян.

Зач. 33. 27 Іисусъ аннан китеб барганда, Анын артыннан ике сукыр кеше: эй Давидъ Улы, (Іисусъ), безне жарлыка, диб кычкырыб барганнар. 28 Ул бер ӧйгя кергяч, Анын жанына сукырлар да килгянняр. Іисусъ аларга ӓйткян: бу эшне булдырырыма ышанасыз мы? дигян. Алар Аӈар ӓйткянняр: эйе шул, Ходай, (ышанабыз), дигянняр. 29 Шуннан суӈ кюзляреня тейенеб,

[1] Тере кабчык.

Ул аларга äйткян: ышаныуыгыз буйынча сезгя булсын, дигян. 30 Шундук аларнын кюзляре ачылган. Іисусъ аларга кисятеб äйткян: карагыз, мыны беряў дя белмясен, дигян. 31 Ämмя алар чыгыб, шундагы бар жиргя Аны даныктырганнар. 32 Алар чыгыб килгян чакта, Анґар бер женнянгян телсез кешене китергянняр. 33 Женен чыгаргач, телсез сöйляшя башлаган. Калык исе китеб äйткян: мындый эш Израилдя бер чакта да булганы жук ыйы, дигянняр. 34 Ämмя фарисейляр äйткянняр: Ул женнярне женняр башлыгынын кöчö белян чыгара, дигянняр. 35 Іисусъ бар калаларда, ауылларда, андагы синагогаларда öйрятеб, Алла падшалыгынын изге хабярен сöйляб, кешеляр арасындагы äр-бер чирне, какшаулыкны тöзятеб жöргян.

Зач. 34. 36 Іисусъ жыйын калыкны кюреб, кötöўчесез сарыклар кюк таралышыб жöдяб жöрöйляр диб, аларны кызганган. 37 Шул чакта Ул öйрянеўчеляреня äйткян: урасы ашлык кюб, ämмя эшчеляр äз, дигян. 38 Шунґар кюря ашлык Эясеня ўтенегез, Ул урагына эшчеляр жибярсен, дигян.

10-нчы бюлем

1 Іисусъ ун ике öйрянеўчелярен чакырыб алыб, аларга женнярне чыгарырга, äр-тöрлö чирне, какшаулыкны тöзятергя кыуат биргян. 2 Ун ике Апостолларнын атлары блай: элекегесе Петръ дигян Симонъ, анын энесе Андрей; Зеведей улы Іаковъ, анын энесе Іоаннъ; 3 Филиппъ, Варөоломей; Өома, мытарь Матөей, Алөей улы Іаковъ, Өаддей дигян Леввей; 4 Кананитъ (дигян) Симонъ, Искаріотъ Іудасы, шушысы Іисусны тотоб биргян. 5 Шушы ун икене жибяргян чакта Іисусъ аларга бойороб äйткян: жалган деннеляр жулына бармагыз, Самарія каласына да кермягез, 6 Ämмя бигряк Израиль жортонын жугалган сарыкларына барыгыз. 7 Кюк падшалыгы жакыннашты диб сöйляб жöрögöз. 8 Чирлелярне тöзятегез, кутырлы тяннелярне тазартыгыз, ўлгяннярне терелтегез, женнярне кыуалаб чыгарыгыз; буш алдыгыз, буш бирегез, дигян.

Зач. 35. 9 Эзярегезгя ўзегез белян алтын, кömöш, бакыр алмагыз. 10 Жулга кабчык та, икешяр кейем дя, башмак та, таяк та (алмагыз): эшляўчегя (тормошына) киряклене бире-

ргя тейеш ич. 11 Нейдей калага, жя ауылга керсягез дя, анда кем жарардый икянне сораб белегез дя, киткенче шунда торогоз. 12 Ойгя кергяндя: бу ойгя тынычлык булсын диб айтеб, ойдягеляр белян исянняшегез. 13 Ягяр ул ой тейешле булса, (телягян) тынычлыгыгыз анар килер, ягяр ул тейешсез булса, (телягян) тынычлыгыгыз ызегезгя кайтыр. 14 Ягяр кем дя кем сезне кабыл алмаса, сюзлярегезне дя тынамаса, сез шул ойдян, жя каладан чыгышлый, аяклярыгыздагы тупракны селкеб тошорогоз. 15 Чыннаб айтямен сезгя: сорау конондя Содомъ белян Гоморра жиреня ул калага караганда жинелеряк булыр, дигян.

Зач. 36. 16 Мына Мин сезне сарыкларны бюреляр арасына жибяргяндей жибярямен: шунар кюря сез жылан кюк хайляле булыгыз, кюгярчен кюк таза кюнелле булыгыз. 17 Кешелярдян сакланыгыз: алар шул сезне хокомгя бирерляр, синагогаларында сезне кыйнарлар. 18 Минем сяятлей сезне тюрялярга, падшаларга житякляб итярляр, алар алдында, жалган деннеляр алдында (Минем турда) таныклык итяр очон. 19 Сезне тотоб биргян чакта, ничек айтербез диб койонмягез: шул сагаття айтясе сюз сезгя бирелер. 20 Айтеучеляр сез булмассыз, аммя Атагызнын Тыны сезнен эчегездя айтеб торор. 21 Агасы энесен, атасы улын тотоб улемгя бирер, балалары ата-аналарына карышы тороб, аларны утererляр. 22 Минем исемем очон сезне бар да кюрялмаслар, алайда калдыкка чаклы тюзгяне котолор, дигян.

Зач. 37. 23 Сезне бер каладан кыусалар, сез икенчегя китегез. Чыннаб айтямен сезгя: сез Израиль калаларын жороб бетеря алмассыз, аммя Адям Улы килер. 24 Ойрянеуче ойрятеучедян оло тогол, кызмятче дя эясеннян оло тогол. 25 Ойрянеучегя ойрятеучесе кюк булса, кызмятчегя эясе кюк булса, житяр. Ойнен эясен веельзевулъ [1] диб атагач, анын ойондягелярен бигеряк тя шулай атарлар тогол ме? 26 Шунар кюря сез алардан курыкмагыз: жяшергян нястянен ич-берсенен кюренмей калганы жук, жяшерендягенен беленмей калганы да жук шул. 27 Мин сезгя карангыда айткянне сез жактыда айтегез, колагызга гна эшеттергянне сез ой тюбясеня менеб сойлягез. 28 Тянне утереучелярдян, аммя жанны утеря алмый торганнардан ку-

[1] Веельзевулъ-женняр башлыгы.

рыкмагыз; бигеряк жанны да, тянне дя тамукта харяб итяргя кыуаты бардан куркыгыз. 29 Ике чыбчык бер гня ассарійг[1] тора тӧгӧл ме? Алайда аларнын берсе дя Атагызнын (ирке) булмаса, жиргя жыгылмас. 30 Ӓммя сезнен башыгыздагы чячегез дя барысы да санаулы. 31 Шунар кюря сез курыкмагыз: сез кюб чыбчыклардан кадерлеряк, дигян.

Зач. 38. 32 Кем дя кем Мине кешеляр алдында йайтеб белдерся, Мин дя аны кюктяге Атам алдында йайтеб белдерем. 33 Ӓммя кем дя кем Мине кешеляр алдында таңса, Мин дя аны кюктяге Атам алдында таңарым. 34 Мине жиргя тынычлык китерергя килгян диб уйламагыз, Мин тынычлык китерергя килмядем, ӓммя кылыч (китерергя килдем)[2]. 35 Мин шу кешене атасыннан, кызын анасыннан, киленен бейеменнян айырырга килдем. 36 Кешенен дошманнары ӱз ӧйӧндягеляре, дигян.

Зач. 39. 37 Ӱз атасын, жя анасын Миннян артык сӧйгян кеше, Миңа жараулы тӧгӧл; ӱз улын, жя кызын Миннян артык сӧйгян кеше дя Миңа жараулы тӧгӧл. 38 Ӱз качын алыб, Минем артымнан бармаган кеше дя Миңа жараулы тӧгӧл. 39 Жанын саклаган кеше аны жуяр, ӓммя жанын Минем ӧчӧн жуйган кеше аны табар. 40 Сезне кабыл алган кеше Мине кабыл ала, ӓммя Мине кабыл алган кеше Мине Жибяреӱчене кабыл ала. 41 Пагамбярне пагамбярлеге какына кабыл алган кеше, пагамбяргя теярдей сауабны алыр; гаделне гаделлеге какына кабыл алган кеше дя гаделгя теярдей сауабны алыр. 42 Шушы кечкенялярнен берсеня ӧирянеӱчелеге какына бер гня сауыт салкын сыу эчерткян кеше дя, чыннаб йайтямен сезгя: сауабын алмый калмас, дигян.

[1] Ике тейен.

[2] Мында Іисусъ Христосъ Ӱзеня ышанган кешелярга ышанмаган кешелярдян кысаннык буласысын йайтя.

11-нче бюлем

1 Іисусъ ун ике ӧйрянеӱчесеня бойороб бетергяч, аннан аларнын калаларында ӧйрятергя, сӧйлярга барган.

Зач. 40. 2 Іоаннъ ӧтӧрмяндя чагында, Христосъ кылган эшлярне эшеткяч, ике ӧйрянеӱчесен жибяреб, 3 Аңар йайттергян: Килясе[3] дигян Син ме, ялля бютянне кӧтӧйӧк ме?

[3] Килясе диб пагамбярляр Христосны йайткянняр. Пс 39:8; Мал 3:1.

диб. 4 Іисусъ аларга жауаб биреб
äйткян: кайтыгыз да, ней кюргя-
негезне, ней эшеткянегезне Іо-
аннга äйтегез: 5 Сукырлар кюря-
ляр, аксаклар (төзөк) жөрөйляр,
кутырлы тяннеляр тазаралар,
санраулар эшетяляр, ўлгянняр
тереляляр, жарлылар изге хабяр
сöйлöйляр, диб. 6 Ämмя Минем
турда шиклянмягян кеше бахет-
ле, дигян. 7 Алар киткяч, Іисусъ
калыкка Іоаннъ турысында äйтя
башлаган: сез буш кырга ней
кюрергя бардыгыз? жилдян тир-
бянгян камышны мы? 8 Суң ней
кюрергя бардыгыз? Жомошак
кейем кейгян кешене ме? Жо-
мошак кейем кейеўчеляр пад-
ша жортонда торалар ич. 9 Ней
кюрергя бардыгыз суң? Пагам-
бярне ме? эйе, сезгя äйтямен:
пагамбярдян дя олоно. 10 Мына
Мин Синең алдыңнан Ўз пя-
риштямне жибярямен, ул Синең
алдыңнан жулыңны äзерляб
куяр диб жазылган ўзе шушы
шул[1]. 11 Чыннаб äйтямен сез-
гя: катыннардан тыуганнар ара-
сында чумылдырыучы Іоаннан
оло булмады, ämмя кюк падша-
лыгындагыларнын иң кечесе ан-
нан оло. 12 Чумылдырыучы Іо-
аннъ көнняреннян бирле älегя
чаклы кюк падшалыгын алырга
бик тырышалар; тырышыучы-
лар аны алалар. 13 Бар пагамбяр-
ляр дя, законъ да буласыны Іоан-
нга чаклы гна äйттеляр. 14 Тагы,
кабыл аласы итсягез, ул килясе
дигян Илія ўзе. 15 [2]Эшетергя ко-
лагы бар кеше эшетсен, дигян.

Зач. 41. 16 Бу тыуманы кем-
гя ошатыйым суң? ул урам-
нарда утыра торган балаларга
ошаулы; алар ўз иптяшляреня
боролоб, 17 Äйтяляр: без сезгя
сыбызгы уйнадык, сез бейемя-
дегез; без сезгя жыларлык жы-
рыулар жырладык, сез жылама-
дыгыз, дейляр. 18 Іоаннъ килде,
ашамый да эчмей дя, анда жен
бар, дейляр. 19 Ädям Улы килде,
ашый да эчя дя, Аны äйтяляр:
мына ашауны, эчеўне жарата
торган кеше, мытарларнын, жа-
зыклы кешелярнен дусы, дей-
ляр. Белемнекне ўз оланнары
дöрöсляделяр, дигян.

Зач. 42. 20 Шуннан суң Іису-
съ Ўзенен бик кюб кодрятлярен
кюрсяткян калаларны, тяўбягя
килмягянняре öчöн, äрлей баш-
лаган. 21 Айгай синға, Хоразин-
ъ! айгай синға, Виөсаида! äгяр
сездя булган кодрятляр Тиръ бе-
лян Сидонда булган булсалар,
алар инде кюбтян алама кейем
кейеб, (башларына) көл сибеб,
тяўбя итярляр эйе шул. 22 Тагы-
нук сезгя äйтямен: Тиръ белян

[1] Мал 3:1.

[2] Мал 4:5-6.

Сидонга сорау көнөндя сезгя кюря жиңелеряк булыр. 23 Син дя эй кюккя чаклы кютярелгян Капернаумъ, тамукка чаклы төшөрөлөрсен; ägяр синдя булган кодрятляр Содомда булган булсалар, ул бögöнгя чаклы торор ыйы. 24 Тагынук сезгя äйтямен: сорау көнөндя Содомъ жиреня сезгя кюря жиңелеряк булыр, дигян. 25 Шул чакта Іисусъ сöйляўеннян туктамыйчы äйткян: эй Ätей, эй кюкнен, жирнен Ходайы! Син мыны белемнелярдян, акыллылардан жяшереб, балаларга кюрсяткянең öчöн Сине данныймын. 26 Эйе, Ätей! Синең иркең шулай булды шул, дигян.

Зач. 43. 27 Миңа Атамнан äрней бирелде; Улны Атадан бютян беряў дя белмей, Атаны да тик Улы гна беля, тагы Улы кемгя белдерясе кился, шул гна. 28 Эй читеннектя тороучылар, ауырлык кюреўчеляр, барыгыз да Миңа килегез, Мин сезне тынычландырым. 29 Минем жögömне кютярегез, Миннян öйрянегез: Мин сабырлыклы шул, жыуаш кюңелле; шуннан жаныгызга тынычлык табарсыз. 30 Минем жögöм арыу, Минем кютярямем жиңел шул, дигян.

12-нче бюлем

Зач. 44. 1 Шул чакта Іисусъ суббота көннö ашлык басыуыннан ўтеб барган; öйрянеўчеляре карыннары ачкач, ашлык башларын öзöб-öзöб ашый башлаганнар. 2 Фарисейляр мыны кюреб, Аңар äйткянняр: мына Синең öйрянеўчелярең суббота көннö кыларга тейеш тögölне кылалар, дигянняр. 3 Ämмя Ул аларга äйткян: Давидъ ўзе дя, анын белян булган кешеляр дя ачыккач, ул ней кылганны укымадыгыз мы älля? 4 Ничек ул Алла öйöня кереб, ўзеня дя, анын белян булганнарга да ашарга тейеш тögöл, тик священниклярга гня ашарга тейешле китереб куйылган икмяклярне ашаганны[1]. 5 Тагы сез суббота көннярдя чиркяўдя священникляр субботаны бозсалар да, айыблары жукны законда укымадыгыз[2] мы älля? 6 Мин сезгя äйтямен: мында чиркяўдян дя Оло бар. 7 Ägяр сез: Мин изгелек телеймен, ämмя корман тögöл[3], дигяннен ней икянен белсягез, айыбсызларны айыбламас ыйыгыз. 8 Ädям Улы субботага да башлык шул, дигян.

---

[1] 1Цар 21:1-6. Лев 24:1-9.
[2] Числ 28:9.
[3] Ос 6:6.

Зач. 45. 9 Шуннан китеб Ул
аларнын синагогаларына кер-
гян. 10 Анда кулы короган бер
кеше булган. Іисусны айыблар
өчөн, Аннан сораганнар: суббо-
та көннө (чирлелярне) төзятергя
мөңким ме? дигянняр. 11 Ул
аларга әйткян: кем сезнен ара-
да бердян бер сарыгы булыб, ул
суббота көннө базга төшся, аны
аннан чыгарыб алмас? 12 Кеше
сарыктан кюб артык төгөл ме?
Алай булгач, суббота көннө из-
гелек кыларга мөңким, дигян. 13
Аннары Ул шул кешегя әйткян:
кулыңны суз, дигян; ул сузган;
сузгачук анын кулы сауыгыб,
икенчесе кюк булган.

Зач. 46. 14 Фарисейляр ба-
рыб, Іисусны ничек итеб бете-
ргя киңяш иткянняр, әммя Ул
аны белеб, аннан киткян. 15 Анын
артыннан бик кюб калык барган,
Ул аларнын (чирлелярен) бары-
сын да төзяткян. 16 Аларга Ўз
турысында беряўгя дя әйтергя
кушмаган. 17 Шулай итеб, Исаія
пагамбяр арткылы әйтелеў жи-
реня килгян; ул әйтя: 18 Мына
Минем сайлаб алган Мяндям,
жаным жараткан сөйөклөм; Мин
Аңар Ўз Тынымны салырым,
Ул кешелярга дөрөслөк белде-
рер. 19 Ул карышы сюз әйтмяс,
кычкырмас, Анын тауышын
урамнарда беряў дя эшетмяс. 20
Дөрөслөкнө өскя чыгаргынчы,
Ул имгянгян камышны да сын-
дырмас, пыскыб торган житен-
не дя сюндермяс. 21 Калыклар
Анын исеменя өмөт тотарлар[1],
дигян. 22 Шул чакта Анын жа-
нына бер женнянгян, сукыр, тел-
сез кешене китергянняр; Ул аны
төзяткян; шундук сукыр, тел-
сез кеше сөйляшя дя, кюря дя
башлаган. 23 Бар калык исе ки-
теб әйткян: Давидъ улы Хрис-
тосъ шушы төгөл микян? диб.
24 Фарисейляр мыны эшетеб,
әйткянняр: Ул женнярне жен-
няр башлыгы веельзевулъ көчө
белян кыуыб чыгара, дигянняр.
25 Әммя Іисусъ аларнын уйла-
рын белеб, аларга әйткян: әр-бер
падшалык ўзе ўз алдына айыры-
лышса, буш калыр; әр-бер кала-
нын да, әр-бер жортнын да ўзе
ўз алдына айырылышканы тора
алмас. 26 Әгяр шайтан шайтанны
кыуыб чыгарса, ул ўзе ўзендя
айырылган була; алай булгач,
анын падшалыгы ничек тора
алыр суң? 27 Әгяр Мин женнярне
веельзевулъ көчө белян кыуыб
чыгарам икян, сезнен улларыгыз
кем көчө белян кыуыб чыгара-
лар суң? Шул сяятлей алар сезгя
хокөм итярляр. 28 Әгяр Мин жен-
нярне Алла Тыны белян кыуыб
чыгарам икян, инде айса сезгя

[1] Ис 42:1-4.

Алла падшалыгы килеб житкян. 29 Жя кем кӧчлӧ кешенен ӧйӧня кереб, элеке кӧчлӧнӧн ӱзен бяйлямяся, анын нястялярен ничек талый алыр? шул чакта гна анын ӧйӧн талый алыр ич, дигян.

Зач. 47. 30 Минем белян тӧгӧлӧ, Миңа карышы; Минем белан бергя жыймаганы, тарата. 31 Шуңар кюря сезгя äйтямен: äр-бер жазык та, курлау да кешелярга кичерелер, ämмя (Святый) Тынны курлау кешелярга кичерелмяс. 32 Äгяр кем Ädям Улына (курлык) сюз äйтся, анар кичерелер, ämмя кем Святый Тынны (курлаб) äйтся, анар бу дӧньядя дя, буласы дӧньядя дя кичерелмяс. 33 Агачын жакшыга куйсагыз, жимешен дя жакшыга куйыгыз; жя агачын начарга куйсагыз, жимешен дя начарга куйыгыз: агач жимешеннян беленя шул. 34 Эй жылан тыумалары! сез ӱзегез усал булгач, арыуны ничек сӧйлярсез? Ауыз кюнгел тулылыктан сӧйляшя шул. 35 Жакшы кеше жакшы сауытыннан[1] жакшыны чыгара, ämмя жаман кеше жаман сауытыннан жаманны чыгара. 36 Сезгя äйтямен: кешеляр бушка äйткян äр-бер сюзляре ӧчӧндя сорау кӧнӧндя жауаб бирерляр. 37 Ӱз сюзеңнян дӧрӧскя чыгарсын, ӱз сюзеңнянӱк айыбланырсын шул, дигян.

Зач. 48. 38 Шул чакта книгячеляр белян фарисейлярнен кайсылары äйткянняр: эй Ӧйрятеӱче, без Синнян бер тӧрлӧ билге кюрясебез киля, дигянняр. 39 Ämмя Ул аларга жауаб биреб äйткян: усал, азгын тыума билге эзлей, тик анар Иона пагамбяр билгесеннян бютян билге бирелмяс: 40 Иона китъ эчендя ӧч кӧн, ӧч тӧн торган кюк, Ädям Улы да жир эчендя ӧч кӧн, ӧч тӧн торор. 41 Ниневія кешеляре бу тыума белян сорауда тороб, аны айыбларлар, алар шу Иона (пагамбяр) сӧйляӱеннян тяӱбягя килделяр, ämмя мында Іонадан да Оло бар. 42 Тӧшлӧк жагындагы катын падша, бу тыума белян сорауда тороб, аны айыблар; ул шу Соломонъ белемнеген эшетергя жир читляреннянӱк килде[2], ämмя мында Соломоннан да Оло бар. 43 Жен кеше эченнян чыккач, сыусыз жирлярдян ӱзеня тыныч урын эзляб жӧрӧй, тик таба алмый. 44 Аннары äйтя: кая кабат ташлаб чыккан ӧйӧмя кайтыйым, дей; кайткач аны буш кӧйӧ, себергян кӧйӧ, матурлаган кӧйӧ очрата. 45 Ул аннары барыб, ӱзе белян бергя тагы ӱзеннян дя жаманырак бютян жиде женне эяртеб киля дя анар кереб тора-

[1] Кюнгеленнян.

[2] 3Цар 10.

лар; ул кешегя сунгысы элекегесеннян дя кыйынырак була. Бу жаман тыумага да шулай булыр, дигян.

Зач. 49. 46 Ул калык белян сöйляшеб торган чакта, анасы да, агалары да Анын белян сöйляшяселяре килеб, тышта торалар икян. 47 Шунда беряў Анăар äйткян: мына анаң да, агаларың да, Синең белян сöйляшяселяре килеб, тышта торалар дигян. 48 Ämмя Ул мыны äйтеўчегя жауаб биргян: кем Минем анам? кем Минем агаларым? дигян. 49 Аннары öйрянеўчеляреня таба кулын сузыб äйткян: мына Минем анам, мына Минем агаларым, диб. 50 Кем дя кем Минем кюктяге Атамнын иркен кылса, шул Миңа ага-эне, тута-сенгел, ана да, дигян.

13-нче бюлем

1 Шул көннö Iисусъ öйдян чыгыб, дингез жарына барыб утырган. 2 Анын жанына кюб калык жыйылган, шунныктан Ул кимягя кереб утырган; калык бар да жар читендя торган. 3 Ул аларны кюб мясялляр äйтеб былай öйряткян: мына чячеўче чячяргя чыккан.

Зач. 50. 4 Чячкян чагында кайсы бöртöкляре жул кырыйына тöшкянняр; кошлар килеб, аларны чюбляб бетергянняр. 5 Кайсылары ташлык жиргя тöшкянняр, анда балчык аз гна булган, балчык сай булганныктан алар тизюк тишелеб чыкканнар. 6 Кояш чыккач, алар шиңеб беткянняр дя, тамырлана алмаганга кюря, короганнар. 7 Кайсылары тигняклекка тöшкянняр; тигняк ўсеб житкяч, аларны басыб бетергян. 8 Кайсылары жакшы жиргя тöшкянняр дя, жимеш китергянняр: кайсысы жöз бöртöк, кайсысы алтмыш бöртöк, кайсысы утыз бöртöк. 9 Эшетергя колагы бар кеше эшетсен, дигян.

Зач. 51. 10 Анын жанына öйрянеўчеляре килеб, Анăар äйткянняр: ник Син аларга мясялляр белян сöйлöйсен? дигянняр. 11 Ул аларга жауаб биреб äйткян: сезгя кюк падшалыгынын жяшереннярен белергя бирелгян шул, ämмя аларга бирелмягян. 12 Барга бирелер, арттырылыр да, ämмя жуктан ней бары да алыныр. 13 Алар караб та кюрмейляр, тыңнаб та эшетмейляр, анăамыйлар да, шунныктан аларга мясял белян äйтямен. 14 Исаія пагамбярнен алдан äйтеўе аларга туры киля, ул äйткян: эшетеўен эше-

терсез, ӓммя аңнамассыз; карауын карарсыз, тик кюрмяссез. 15 Бу кешелярнен кюнгелляре катыланган; алар колаклары белян дя кӧчкя эшетяляр, кюзлярен дя жомганнар, кюзляре белян кюрмяс ӧчӧн, колаклары белян тыңнамас ӧчӧн, кюнгелляре белян аңнамас ӧчӧн, Миңа кайтмас ӧчӧн, ӓммя Мин аларны тӧзятер эйем[1], дигян. 16 Ӓммя сезнен кюзлярегез, кюреб торганнарына кюря, колакларыгыз да, эшетеб торганнарына кюря, бахетле. 17 Чыннаб ӓйтямен сезгя: кюб пагамбярляр, кюб гадел (кешеляр) сез кюря торганны кюряселяре килде, алайда кюрмяделяр; сез эшеткянне эшетяселяре килде, тик эшетмяделяр. 18 Сез инде чячеӳче турысында ӓйткян мясялнен (аңын) тыңнагыз. 19 Падшалык турысында ӓйтелгян сюзне эшетеб, аны аңнамаган ӓр-бер кешегя шайтан килеб, анын кюнгеленя чячкянне алыб китя: мына жул кырыйына чячелгяне шул. 20 Ташлык жиргя чячелгяне бу була: беряӳ сюзне эшеткяч, аны тизюк сӧйӧнӧч белян кабыл ала. 21 Тик жяйелгян тамыры жукка кюря, ныклыгы да булмаганга кюря, анар эшеткян сюзе ӧчӧн кайгы, жя кысаннык кюреpгя туры кился, шундук шикляня башлый. 22 Тигяняклеккя чячелгяне бу була: беряӳ сюзне эшетеӳен эшетя, тик бу гумернен сагышлары, байлыкка алданыулык (эшеткян) сюзен басыб бетеря, аннары ул сюз жимеш китермей. 23 Ӓммя жакшы жиргя чячелгяне бу була: беряӳ сюзне эшетеб, аны аңнаб ала да, жимеш китеря; кайсысы жӧзярне, кайсысы алтмышарны, кайсысы утызарны (китеря) дигян.

Зач. 52. 24 Ул аларга тагы бютян мясял ӓйткян: кюк падшалыгы басыуына арыу орлок чячкян кешегя ошой. 25 Кешеляр жоклаган чагында, анын дошманы килеб, бодай арасына бакралар чячеб киткян. 26 Бодай ӳсеб, баш чыгара башлагач, бакралар да кюренгянняр. 27 Кызмятчеляр эяляреня килеб ӓйткянняр: эй кужа! син басыуыңа жакшы орлок кна чячкян эйең тӧгӧл ме? анда бакралар каян булган суң? дигянняр. 28 Ул аларга ӓйткян: мыны дошман кеше кылган, дигян; кызмятчеляре тагы анар ӓйткянняр: телясяң, без барыб аларны утар ыйык? дигянняр. 29 Ӓммя ул (аларга) ӓйткян: жук, сез бакраларны утаган чакта, алар белян бергя бодайны да жолкорсыз. 30 Урыр багыт житкенче икесен дя бергя ӳсяргя калдырыгыз; урган чак-

[1] Ис 6:9-10.

та мин уракчыларга äйтерем: элеке бакраларны, утка жагарга диб, жыйыб көлтялягез, аннары бодайны келятемя жыйыб куйыгыз, дирем.

Зач. 53. 31 Ул аларга жяня бютян мясял äйткян: кюк падшалыгы бер кеше алыб барыб, басыуына чячкян горчица орлогона ошой: 32 Ул бар орлоклардан да ыуак орлок булса да, ӱсеб житкяч, бар ӱлямнярдян дя узыб, агач була, ботаклары-на ауа кошлары очоб килеб, кунакларлык була, дигян. 33 Жяня тагы аларга бютян мясял äйткян: кюк падшалыгы ачеткеч апарага ошой: аны бер катын алган да, öч ӱлчяӱ онга катыштырыб, бары бергя ачеб житкенче, ачергя куйган. 34 Быларны Иисусъ калыкка барын да мясял белян сöйлягян, ämмя мясялсез аларга ич нястя дя сöйлямягян. 35 Шулай итеб, пагамбяр арткылы äйтелгян сюз жиреня килгян; ул äйткян: ауызымны мясялляр китереб сöйлярга ачармын, дöнья жаралганнан бирле жяшерен торганнарны äйтермен[1], дигян. 36 Аннары Иисусъ калыкны жибяреб, бер öйгя кергян.

Зач. 54. Öйрянеӱчеляре Иисусъ жанына килеб äйткянняр: басыудагы бакралар турысында äйткян мясялне безгя анатчы, дигянняр. 37 Ул аларга жауаб биреб äйткян: жакшы орлок чячеӱчесе Ädям Улы; 38 Басыу дигяне-дöнья, жакшы орлок дигяне-падшалык уллары, ämмя бакралар дигяне-жаманнык уллары; 39 Бакралар чячкян дошман дигяне-шайтан, урыр багыт дигяне-дöнья бетеӱе, уракчылары-Пяриштяляр. 40 Бакраларны жыйыб, утка ничек жандыралар, шулай булыр шул бу дöнья беткян чагында да. 41 Ädям Улы Ӱз Пяриштярен жибярер, алар Анын падшалыгындагы бар алдаучыларны, законсызлык кылыучыларны жыярлар да, 42 Аларны утлы пичкя ыргытырлар, анда жылау, теш шыкырдатыу булыр. 43 Шул чакта гаделляр ӱз Аталарынын падшалыгында кояш кюк жалтраб торорлар. Эшетергя колагы бар кеше эшетсен, дигян.

Зач. 55. 44 Жяня тагы кюк падшалыгы басыуга кюмгян малга ошойдыр: аны бер кеше табыб, беряӱгя дя äйтмейче, анар сöйöнöб кайта да, бар нястясен сатыб, шул басыуны аладыр. 45 Кюк падшалыгы тагы жакшы энжеляр эзляӱче куписки ошой: 46 Ул бик кыйбатлы бер энжене табкач, кайтыб, бар нястясен саткан да шул энжене алган.

[1] Пс 77:2.

47 Жяня тагы кюк падшалыгы дингезгя салган, төрлӧ балыклар кергян ауга ошой; 48 Ул тулгач, аны жар кырыйына тартыб чыгарганнар; аннары утырыб, жакшыларын сайлаб, сауытка тутырганнар, ӓммя начарларын читкя ташлаганнар. 49 Дӧнья беткян чагында да шулай булыр: Пяриштяляр чыгыб, усалларны гаделлярдян айырыб алырлар да, 50 Аларны утлы пичкя ыргытырлар; анда жылау, теш шыкырдатыу булыр, дигян. 51 Аннары Іисусъ аларга ӓйткян: сез быларны барын да анӈадыгыз мы? дигян. Алар Анӈар: эйе, Ходай, (анӈадык), дигянняр. 52 Ул аларга тагы ӓйткян: шунӈар кюря кюк падшалыгына ӧйрянгян ӓр-бер укымыш кеше, ӱз сауытыннан жанӈаны да, искене дя ала торган жорт-эясе кешегя ошой, дигян.

Зач. 56. 53 Іисусъ шушы мясяллярне ӓйтеб бетергяч, аннан киткян. 54 Ул аннары ӱскян жиреня барыб, алар синагогасында [1] аларны ӧйряткян; алар: Анын бу катле белемнеге дя, кыуаты да каян икян диб, ислярe китеб ӓйткянняр: 55 Ул балта остасынын улы тӧгӧл меней сунӈ? Марія диб Анын анасын атыйлар тӧгӧл ме? Іаковъ та, Іосій дя, Симонъ да, Іуда да Анын агалары ич. 56 Туталары да безнен арадала баса, Анын бу (белемнеге, бу кыуаты) бар да кайдан сунӈ? дигянняр. 57 Шулай итеб, Анын турысында шик тотканнар. Ӓммя Іисусъ аларга ӓйткян: пагамбяр ӱскян жирендяге чаклы, ӧйӧндяге чаклы бер жирдя дя кадерсез булмый, дигян. 58 Ышанмаганнарына кюря анда кодрятлярне кюб кылмаган.

[1] Іудейлярнен теляк итяргя, Алла законына тынӈарга жыйыла торган ӧйляре.

14-нче бюлем

Зач. 57. 1 Шул багытта (падшалыкнын) дюртенче ӧлӧшӧн биляб тороучы Иродъ, Іисусъ турысында сӧйляшкянне эшетеб, 2 Колларына ӓйткян: бу чумылдырыучы Іоанндыр, ул ӱлгяненнян терелеб торгандыр, шунӈар кюря кодрятляр кыладыр, дигян. 3 Иродъ ӱз агасы Филиппь катыны Иродіада какында, Іоанны тотоб, бяйлятеб ӧтӧрмянгя жабтырган икян: 4 Іоаннъ Иродка: синӈа аны катын итеб торорга жарамый диб онгай ӓйткялягян шул. 5 Ул аны ӱтермякче дя булган, тик калыктан курыккан: калык аны пагамбяргя санаган шул. 6 Иродъ ӱзе тыуган кӧннӧ

бяйрям иткян чагында, Иродіада кызы кунаклар алдында бейеб, Ироднын кюнгелен булдырган. 7 Шунын өчөн Иродъ анар ней гня сораса да бирмякче булыб карганган. 8 Кыз, анасы өйряткян буйынча, йткян: миня мында чумылдырыучы Іоаннын башын табак белян бир, дигян. 9 Падша кайгыга төшкян; алайда карганганы буйынча, бергя утырыучылар алдында оятка калмас өчөн, анар бирергя кушкан. 10 Аннары жибяреб, өтөрмяндя Іоаннын башын кистергян. 11 Анын башын табак белян китереб, кызга биргянняр, ул аны анасына итеб биргян. 12 Іоаннын өйрянеўчеляре килеб, анын тянен алыб кюмгяч, Іисуска барыб белдергянняр. 13 Іисусъ мыны эшеткяч, аннан жангызы гна кайыкка утырыб, буш кырга кичкян; калык Ул киткянне эшетеб, калалардан чыгыб, Анын артыннан жяяўляб барган.

Зач. 58. 14 (Кайыктан) чыккач, Іисусъ кюб калыкны кюргян; Ул аларны кызганыб, аларнын чирлелярен тёзяткян. 15 Кич булгач, өйрянеўчеляре Анар килеб йткянняр: мында буш кыр, казер инде кич була; Син калыкны жибяр, алар ауылларга барыб, ўзляреня ашамнык алсыннар, дигянняр. 16 Ямма Іисусъ аларга йткян: алар китмясенняр, аларга ашарга сез бирегез, дигян. 17 Алар Анар йткянняр: безнен мында биш икмяк белян ике балык кна, дигянняр. 18 Ул йткян: аларны Миня мында китерегез, дигян. 19 Аннары калыкка ўлям өстөня утырырга кушкан. Биш икмяк белян ике балыкны алыб, кюккя таба караб бахиллягян, аннары икмякляре сындырыб өйрянеўчеляреня биргян, өйрянеўчеляре калыкка (өляшкянняр). 20 Барысы да ашаб туйганнар; калган сыныкларны ун ике карнаша[1] тулук жыйганнар. 21 Ашаучылар катын-кыздан, балалардан башкасы биш мең кешеляб булганнар.

Зач. 59. 22 Шул сяттюк Іисусъ, калыкны жибяреб бетергенче, өйрянеўчеляреня кимягя утырыб, Ўзеннян алдан икенче жакка чыгыб китяргя кушкан. 23 Калыкны жибяреб бетергяч, Ул аулакта теляк итяргя тау өстөня менгян; кич тя Ул анда жангызы гна булган. 24 Жил карышы булганныктан, дингез уртасында кимяне тулкыннар бяря башлаган. 25 Төннөн дюртенче бюлемендя Іисусъ өйрянеўчеляре жанына дингез өстөннян жяяўляб барган. 26 Өйрянеўчеляре Анын дин-

[1] Кызау.

гез öстöннян жяяўляб килгянен кюреб, жöдяшеб äйткянняр: бу кеше шяўляседер диб, куркыуларыннан кычкыра башлаганнар. 27 Іисусъ шул сяттюк алар белян сöйляшя башлаб, äйткян: ныкторогоз; бу Мин, курыкмагыз, дигян. 28 Петръ Анґар жауаб биреб äйткян: эй Ходай, Син булсаґ, миґа Ўз катыґа сыу öстöннян жяяўляб барырга бойорсана, дигян 29 Іисусъ äйткян: кил, дигян; шул сяттюк Петръ кимядян чыгыб, Іисуска таба сыу öстöннян жяяўляб бара башлаган. 30 Тик кыуатлы жилне кюреб курыккан да, бата башлагач: эй Ходай, мине коткар диб кычкырган. 31 Шул сяттюк Іисусъ кулын сузыб, аны тотоб äйткян: эй аз ышаныучы! син ник шикляндеґ? дигян. 32 Алар кимягя кергяч, жил басылган. 33 Кимядягеляр Іисусъ жанына килеб, Анґар башырыб äйткянняр: чыннаб Син Алла Улы, дигянняр. 34 Аннары аннан кичеб, Геннисаретъ жиреня килгянняр.

Зач. 60. 35 Ул жирнен кешеляре Іисусны белеб, бар тиряляреня дя хабяр жибяргянняр; аннары Анґар бар чирлелярне китергянняр. 36 Алар Анґар кейеменен читеня гня тейенейек диб ўтенгянняр; тейенгянняре сауыкканнар.

15-нче бюлем

1 Шул чакта Іисусъ жанына Іерусалимдяге книгячеляр белян фарисейляр килеб äйткянняр: 2 Синеґ öйрянеўчеляреґ ней öчöн картлар кушканны тотмойлар, кулларын жыумыйчы икмяк ашыйлар? дигянняр. 3 Ул аларга жауаб биреб äйткян: ней öчöн сез дя картларыгыз кушканны кылар öчöн, Алла бойорогоннан жазасыз? 4 Алла бойороб äйткян ич: атаґны, анаґны санна, тагы: атасына, анасына жаман äйтеўче ўтерелсен[1], дигян. 5 Ämмя сез äйтясез: кем атасына, жя анасына: мин синґа бирясене (Аллага) адарындым дигяч, 6 Ул атасын, жя анасын саннамаса да жарый, дейсез. Шулай итеб, сез картларыгыз кушканны кылыб, Алла бойорогон чиття калдырасыз. 7 Эй кюз алдында гна кылыныучылар! Исаія пагамбяр сезнен турда дöрöс äйткян: 8 Бу кешеляр ауызлары белян Миґа жакыннашалар, телляре белян Мине кадерлейляр; тик кюґелляре Миннян жырак тора; 9 Кеше уйлаб чыгарган бойорокларга, кеше öйряткянгя öйрятеб,

[1] Исх 20:12; 21:16.

алар Мине пайдасыз санныйлар[1], дигян. 10 Аннары чакырыб, калыкка йӑткян: тыҥнагыз да аҥнаб алыгыз! 11 Кешене ауызга кергян нястя шакшыландырмый, ӑммя ауыздан чыкканы кешене шакшыландыра, дигян.

Зач. 61. 12 Шул чакта Анын жанына ӧйрянеӳчеляре килеб, Аҥар йӑткянняр: бу сюзлярне эшеткяч, фарисейляр жӧдягянне белясен ме? дигянняр. 13 Ул аларга жауаб биреб йӑткян: Минем кюктяге Атам утыртмаган ӑр-бер агач тамыры белян кубарылыр. 14 Аларга теймягез: алар сукырларны житякляб жӧртӧӳче сукырлар; ӑгяр сукыр сукырны житякляб барса, икесе дя чокорга жыгылырлар, дигян. 15 Петръ Аҥар жауаб биреб йӑткян: бу мясялне безгя аҥнатчы, дигян. 16 Иисусъ йӑткян: ӑле сез дя аҥнамыйсыз меней? 17 Ӑлля сез ауызга кергяне барысы да карынга тӧшкянне, аннары тышка чыкканны ӑле дя аҥыша алмыйсыз? 18 Ӑммя ауыздан чыкканы кюҥелдян чыга; анысы кешене шакшыландыра. 19 Усал уйлар, кеше ӳтереӳ, азгыннык итеӳ, уйнашлык, урлау, жалган таныклык итеӳ, курлау, (барысы да) кюҥелдян чыга шул. 20 Шушылар кешене шакшыландыралар, ӑммя кул жыумыйчы ашау кешене шакшыландырмый, дигян.

Зач. 62. 21 Аннан чыккач, Иисусъ Тиръ белян Сидонъ жагына киткян. 22 Шунда бер Хананея катыны шул жирдян чыгыб, Аҥар: эй Давидъ Улы Ходай! мине жарлыка, минем кызым женнянеб каты азаблана диб кычкырган. 23 Иисусъ аҥар бер сюз дя йӑтмягян, ӧйрянеӳчеляре Анын жанына килеб, Аҥар ӳтенгянняр: аны жибяр, ул безнен арттан кычкырыб киля, дигянняр. 24 Ӑммя Ул аларга жауаб биреб йӑткян: Мин Израиль жортонын жугалган сарыкларына гна жибярелдем, дигян. 25 Катын килеб, Аҥар башырыб йӑткян: эй Ходай! миҥа булыша кюр, дигян. 26 Ул жауаб биреб йӑткян: икмякне балалардан алыб, этлярга ташлауы жакшы тӧгӧл, дигян. 27 Катын йӑткян: анысы дӧрӧс, эй Ходай, алайда этляр дя эяляренен өстяленнян тӧшкян ыуалчыкларны ашыйлар ич, дигян. 28 Шуннан суҥ Иисусъ аҥар жауаб биреб йӑткян: эй катын! синеҥ ышаныуыҥ бик зур, синҥа телягяненчя булсын, дигян. Шул сяттюк анын кызы сауыккан.

Зач. 63. 29 Шуннан китеб, Иисусъ Галилея дингезе жанына барыб, тау өстӧня менеб утыр-

[1] Ис 29:13.

ган. 30 Шунда Анын жанына кюб калык килгян; алар ўзляре белян бергя аксакларны, сукырларны, телсезлярне, гареблярне, тагы бютян тӧрлӧ кюб (чирлелярне) алыб килеб, аларны Иисусъ аягы жанына салганнар; Ул аларны тӧзяткян. 31 Телсезлярнен сӧйляшеўен, гареблярнен тӧзялгянен, сукырларнын кюреўен, аксакларнын жӧрӧўен кюреб, калык исе киткян, Израиль Алласын даннаган.

Зач. 64. 32 Иисусъ ӧйрянеўчелярен чакырыб алыб, аларга äйткян: Мин бу калыкны кызганамын, алар Минем катымда инде ӧч көннян бирле торалар, ашар нястяляре дя жук; ämмя аларны, жулда халляре бетмясен диб, ач кӧйӧ жибярясем килмей, дигян. 33 Ӧйрянеўчеляре Аңар äйткянняр: бу катле калыкны туйдырырлык икмяк буш кырда без каян алыйык? дигянняр. 34 Иисусъ аларга äйткян: сезнен ничя икмягегез бар? дигян. Алар: жидяў, тагы бер-аз ыуак балык бар, дигянняр. 35 Аннары Иисусъ калыкка жиргя утырырга кушкан. 36 Ӱзе жиде икмяк белян балыкларны алыб, (Аллага) тау иткян дя, сындырыб ӧйрянеўчеляреня биргян, ӧйрянеўчеляре калыкка (ӧляшкянняр). 37 Барысы да ашаб туйганнар, калган сыныкларны жиде карнаша тулук жыйганнар. 38 Ашаучылары катын-кызлар белян балалардан башкасы дюрт мең кеше булган. 39 Аннары калыкны жибяргяч, (Иисусъ) кимягя кереб утырган да, Магдала тиряляреня барган.

16-нчы бюлем

Зач. 65. 1 Фарисейляр белян саддукейляр Иисусъ жанына килеб, Аны сынаб, безгя кюктян билге кюрсятче, дигянняр. 2 Иисусъ аларга жауаб биреб äйткян: кичтян сез, кюк кызарыб торганга кюря, иртягя аяз булыр, дейсез, 3 Иртя белян: кюк кызгылтсарангы булыб торганны кюреб, бӧгӧн жангыр жауар, дейсез. Эй кюз алдында гна кылыныучылар! сез кюкнен тӧсӧн айыра белясез, ämмя багыт билгелярен аңыша алмыйсыз меней? 4 Усал, азгын тыума билге эзлей, тик аңар Иона пагамбяр билгесеннян бютян билге бирелмяс, дигян. Аннары аларны калдырыб, аннан киткян. 5 Ӧйрянеўчеляре ары жакка кичеб чыкканда икмяк алырга онотканнар.

Зач. 66. 6 Иисусъ аларга äйткян: карагыз, фарисейляр белян саддукейляр äчеткеченнян

сакланыгыз, дигян. 7 Алар ўз кюнелляpендя уйлаганнар: без икмяк алмаганны айтеўедер диб. 8 Іисусъ мыны белеб, аларга айткян: эй аз ышаныучылар, ник сез икмяк алмадык диб ўз кюнелегездя уйлыйсыз? 9 Әле дя анамыйсыз меней, биш икмяк биш мең (кешегя) житкянне, аннары ўзегез ничя карнаша жыйыб алганыгыз исегездя тёгёл меней? 10 Тагы жиде икмяк дюрт мең (кешегя) житкянне, аннары ничя карнаша жыйыб алганыгызны (оноттогоз меней)? 11 Мин сезгя: фарисейляр белян саддукейляр ачеткеченнян сакланыгыз диб, икмяк турысында айтмягянемне сез ничек анамыйсыз? дигян. 12 Шунда алар Анын икмяк ачеткеченнян сакланырга айтмягянен, ямма фарисейляр белян саддукейляр ёйряткяннян (сакланырга кушканын) анаганнар.

Зач. 67. 13 Іисусъ Филиппъ Кесаріясе тирясеня баргач, ёйрянеўчеляреннян сораган: Мин Ядям Улын кешеляр кем диб айтяляр? дигян. 14 Алар айткянняр: кайсылары чумылдырыучы Іоаннъ дейляр, кайсылары Илія дейляр, ямма кайсылары Іеремія дейляр, жя пагамбярлярнен берседер диб айтяляр, дигянняр. 15 Ул аларга айткян: сез ўзегез Мине кем диб белясез? дигян. 16 Петръ (дигян) Симонъ жауаб биреб айткян: Син Христосъ, Син тере Алланын Улы, дигян. 17 Аннары Іисусъ анар жауаб биреб айткян: эй Іона улы Симонъ, син бахетле; синга мыны тян белян кан белдермяделяр, ямма Минем кюктяге Атам белдерде шул, дигян. 18 Мин дя синга айтямен: син Петръ, [1] Мин шушы таш östöня жыйынымны корормын, аны тамук кабкасы [2] да жиня алмас. 19 Синга кюк падшалыгынын ачкычларын бирем: син жирдя нейне бяйлясянг, ул кюктя дя бяйляўле булыр, ямма жирдя нейне чишсянг, ул кюктя дя чишеўле булыр, дигян.

Зач. 68. 20 Шул чакта Іисусъ ёйрянеўчеляреня Ўзенен Іисусъ Христосъ икянен беряўгя дя айтергя кушмаган. 21 Шул багыттан Іисусъ Ўзенен Іерусалимгя барыб, анда калык башлыкларыннан, архіерейлярдян, книгячелярдян кюб азабланасын, ўтерелясен, ёчёнчё könöндя терелеб торасын ёйрянеўчеляреня айырмачык айтя башлаган. 22 Петръ Аны читкяряк алыб китеб, кире кагыб Анар айтя башлаган: Ходай сакласын, Синга

[1] Петръ дигяне таш.

[2] Кабка дигяне тамук кыуаты.

бу эш булмасын, дигян. 23 Ämмя Ул боролоб Петрга äйткян: кит Миннян шайтан, син Мине алдандырасын: син шу Аллага жараганны уйламыйсын, ämмя кешегя жараганны (уйлыйсын), дигян.

Зач. 69. 24 Шуннан суң Іисусъ öйрянеўчеляреня äйткян: Минем артымнан барасы килгян кеше, ўз иркен кылыуны ташласын да, качын алыб, Минем артымнан барсын. 25 Жанын саклясы килгян кеше, аны жуяр шул, ämмя жанын Минем öчöн жуйган кеше, аны табар. 26 Кеше бötöн дöньяне жыйыб алса да, ämмя ўз жанына зыян китерся, анҕар ней пайда булыр? Жя кеше ўз жанын ней биреб жола алыр? 27 Ädям Улы Ўз Атасынын олологында пяриштяляре белян бергя килер, килгяч äр-кемгя эшляреня караб кайтарыр. 28 Чыннаб äйтямен сезгя: мында тороучыларнын кайсылары, Ўз падщалыгында килеўче Ädям Улын кюрмейче ўлмясляр, дигян.

17-нче бюлем

Зач. 70. 1 Аннары алты кöн ўткяч, Іисусъ Петрны, Іаковны, анын энесе Іоанны алыб китеб, аларны гна алыб бейек тау öстöня менгян. 2 Ул анда алар алдында ўзгяргян: жöзö кояш кюк жактырган, кейемняре жакты кюк агарган. 3 Шунда аларга Моисей белян Илія кюренеб, Іисусъ белян сöйляшеб торганнар. 4 Шул чакта Петръ Іисуска äйткян: эй Ходай! безгя мында тороргa жакшы; телясяҕ, без мында öч чатыр корор ыйык: берсен Синҕа, берсен Моисейгя, берсен Иліягя, дигян. 5 Ул äйткян чагындук, кинят аларны жакты болот каблаган, шундук болоттан: Шушы Минем сöйöклö Улым, Анда Минем ризалыгым, Аны тыҥнагыз диб ауаз булган. 6 Öйрянеўчеляре мыны эшетеб, жöз тюбян жыгылыб киткянняр, алар бик курыкканнар шул. 7 Іисусъ жакын килеб, аларга тейенеб äйткян: торогоз, курыкмагыз, дигян. 8 Алар кюзлярен кютяреб карагач, Іисустан бютянне беряўне дя кюрмягянняр. 9 Тау öстöннян тöшкян чакта, Іисусъ аларга кисятеб äйткян: Ädям Улы ўлгян жиреннян терелеб торгончы, бу кюргянегезне беряўгя дя äйтмягез, дигян.

Зач. 71. 10 Шул чакта öйрянеўчеляре Аннан сораганнар: бу ничек книгячеляр элеке Илія килясе дейляр? 11 Іисусъ аларга жауаб биреб äйткян: эйе, Илія элеке килеб, барын да рятлярга тейеш.

12 Ämмя Мин сезгя äйтямен: Илія
инде килде, тик аны танымадылар, ämмя анҕар ўзляре телягянчя
кылдылар; Ädям Улы да шулай
алардан азаб кюрер, дигян. 13
Шунда öйрянеўчеляре Ул аларга чумылдырыучы Іоаннъ турысында äйткянне анҕаганнар.

Зач. 72. 14 Алар калык катына килгяч, бер кеше Іисусъ жанына килеб, Анҕар тезлянеб башырыб, 15 Äйткян: эй Ходай!
улымны жарлыка, ул шу жанҕа
ай сайын женнянеб, каты азаблана; онҕай жя утка, жя сыуга жыгыла. 16 Мин аны Синеҥ
öйрянеўчеляреҥя китергян эйем,
тик алар аны тöзятя алмадылар,
дигян. 17 Іисусъ жауаб биреб
äйткян: эй ышаныусыз, азгын
тыума! кайчанга чаклы сезнен
белян торойом? кайчанга чаклы сезгя чыдыйым? аны мында
Миҥа китерегез, дигян. 18 Китергяч Іисусъ аны тыйган; шундук
жен анын эченнян чыккан, жегет
шул сяттюк сауыккан. 19 Аннары
öйрянеўчеляре Іисуска аулакта
килеб äйткянняр: без нейлектян
аны чыгара алмадык? дигянняр.
20 Іисусъ аларга äйткян: ышанмаганыгызга кюря, дигян; чыннаб
äйтямен сезгя: ägяр сезнен ышаныуыгыз горчица бöртöгö кюк
кня булса да, сез шушы тауга:
мыннан тегендя кюч дисягез, ул
кючяр; сез булдыра алмаслык
ич нястя дя булмас. 21 Бу (жен)
заты тик теляк белян гня, ураза
тотоу арткылы гна кыуыб чыгарыла дигян. 22 Алар Галилеядя
чагында Іисусъ аларга äйткян:
Ädям Улы кешеляр кулына тотоб бирелер; 23 Аны ўтererляр,
Ул öчöнчö кöнöндя терелеб торор, дигян. Шуннан суҥ алар
бик кайгырганнар.

Зач. 73. 24 Алар Капернаумга килгяч, Петръ жанына дидрахма [1] жыйыучылар килеб
äйткянняр: сезнен Öйрятеўчегез
дидрахма бирмяс ме? дигянняр. 25 Ул äйткян: эйе, (бирер),
дигян. Петръ öйгя кергяч, Іисусъ ул äйткенче анҕар äйткян:
синҕа ничек тея, Симонъ? жирдяге падшалар сатлык мал акчасын, жя имананы кемнян алалар:
ўз улларыннан мы? älля жатлардан мы? дигян. 26 Петръ Анҕар
äйткян: жатлардан, дигян. Іисусъ анҕар äйткян: айса ўз уллары
жарлыкаулы; 27 Алайда аларны
жöдяўгя калдырмас öчöн, син
дингез жанына барыб кармак
сал да иҥ элеке эляккян балыкны ал, анын ауызын ачкач, анда
бер статириъ [2] табарсын; аны
алыб, Минем öчöн дя, ўзеҥ öчöн
дя аларга бир, дигян.

[1] Дидрахмада 43 тейен.
[2] Статирда 2 дидрахма.

18-нче бюлем

Зач. 74. 1 Шул чакта ӧйрянеўчеляре Іисуска килеб ӓйткянняр: кюк падшалыгында кем олорак? дигянняр. 2 Іисусъ бер баланы чакырыб алыб, аны аларнын уртасына торгозоб, 3 Ӓйткян: чыннаб ӓйтямен сезгя: ӓгяр сез ўзегезне ўзгяртеб, балалар кюк булмасагыз, кюктяге падшалыкка керя алмассыз. 4 Шулай, кем ўзен ўзе шушы бала кюк кечеляндерся, ул кюк падшалыгында олорак. 5 Тагы шушындый баланы Минем исememя кабыл алыучы, Мине кабыл ала. 6 Ӓммя кем шушы Миңа ышаныучы кечкенялярнен берсен алдандырса, ул кешегя муйнына тегермян ташы асыб, аны дингез тугайына батырсалар, жиңелеряк булыр ыйы. 7 Алданыулар дӧньягя кыйын, алданыулар булырга тейеш шул, алайда алдандырыучы кешегя читен булыр. 8 Ӓгяр сине кулың, жя аягың алдандырса, син аларны ўзеңнян кисеб ташла: ике кулың белян, ике аягың белян мянге утка ташланасы булгынчы, сыңар куллы, сыңар аяклы кӧйӧ терелеккя кереўе синя жакшырак ич. 9 Ӓгяр сине кюзең кызыктырса, син аны ўзеңнян сыуырыб алыб ташла: ике кюзең белян тамук утына ташланасы булгынчы, сыңар кюз белян терелеккя кереўе синя жакшырак ич, дигян.

Зач. 75. 10 Карагыз, бу кечкенялярнен берсен дя ким кюрмягез; сезгя ӓйтямен шул: аларнын пяриштяляре кюклярдя кюктяге Атамнын жӧзӧн жалан кюреб торалар диб. 11 Ӓдям Улы жугалганны эзляб табарга, аны сакларга килде шул. 12 Сезгя ничек тея? ӓгяр беряўнен жӧз сарыгы булыб, аларнын берсе адашса, ул туксан тугызын таулар арасында калдырыб, адашканын эзлей бармас меней? 13 Ӓгяр дя аны табса, чыннаб ӓйтямен сезгя: ул аңар адашмаган туксан тугыз сарыкларына сӧйӧнгяннян артыгырак сӧйӧнӧр. 14 Шулай, кюктяге Атагыз бу кечкенялярнен берсен дя жугалтасы килмей. 15 Ӓгяр туганың синя карышы жазыкланса, син ўзең гня барыб, аны аулакта оялт; ӓгяр ул сине тыңнаса, туганыңны табыуың шул. 16 Ӓгяр ул сине тыңнамаса, син ўзең белян бергя тагы бер кеше, жя ике кеше алыб бар; ике, жя ӧч таныкчынын ӓйткяне белян ӓр-бер сюз беркелсен. 17 Ӓгяр аларны да тыңнамаса, жыйынга ӓйт; ӓгяр жыйынны да тыңнамаса, ул аннары синең ӧчӧн жалган денне кеше кюк, мытарь кюк булсын, дигян.

Зач. 76. 18 Чыннаб äйтямен сезгя: сез жир östöндя нейне бяйлясягез, ул кюктя дя бяйляўле булыр; сез жир östöндя нейне чишсягез, ул кюктя дя чишеўле булыр. 19 Тагы да чыннаб äйтямен сезгя: ägяр жирдя сезнен арадан икяў бер киңяш белян бер-бер нястя сорасы булсалар, ней гня сорасалар да кюктяге Атамнан аларга бирелер. 20 Кайда булса да Минем исемемя икяў, жя öчяў бергя жыйылсалар, анда алар уртасында Мин шул, дигян. 21 Шул чакта Петръ Аңар жакын килеб äйткян: эй Ходай! миңа карышы жазыклы булган туганыма ничя табкыр кичерейем? жидегя чаклы мы? дигян. 22 Iисусъ аңар äйткян: жидегя чаклы димейем синға, ämмя жиде табкыр житмешкя чаклы (кич), дигян.

Зач. 77. 23 Шунныктан кюк падшалыгы ўз колларыннан исяб аласы булган падшага ошой. 24 Ул исябляшя башлагач, анын жанына аңар ун меҥ талантъ [1] бирясе бар кешене китергянняр. 25 Анын тюляр нястясе булмагач, падша анын ўзен дя, катынын да, балаларын да, тагы ней нястясе бар, барын да сатыб, тюлярга кушкан. 26 Шунда ул кол аңар жыгылыб башырыб äйткян: эй падша! миңа тюзя кюрсяня, мин синға барын да тюлярем, дигян. 27 Падша ул колны кызганыб, аңар бурычын кичереб, аны жибяргян. 28 Бу кол (падша катыннан) чыккач, ўзеня жöз динарій [2] бирясе бар бер иптяшен табкан; аны тоткан да: миңа бирясеҥне бир диб, аны быуа башлаган. 29 Шунда иптяше анын аягы астына жыгылыб, миңа тюзя кюрсяня, мин синға барын да бирем диб, аңар ўтенгян. 30 Тик ул тыңнамаган, ämмя барыб, бурычын тюляб бетергенче (тотарга) аны öтöрмянгя жабтырган. 31 Иптяшляре бу эшне кюреб, мыңар бик рянжегянняр дя падшаларына барыб, ней булганны барысын да äйткянняр. 32 Шуннан суҥ падшасы аны чакыртыб, аңар äйткян: эй жаман кол! Син миңа жалынгач, мин синға бар бурычыңны кичердем; 33 Мин сине жарлыкаган кюк, синға да иптяшеҥне жарлыкарга тейеш эйе töгöл ме? дигян. 34 Падшасы аңар ачыуы килеб, бурычын тюляб бетергенче тотарга аны азаблаучылар кулына биргян. 35 Сезнен дя äр-кайсыгыз ўз туганына жангышларын чын кюҥелдян кичермяся, кюктяге Атам сезгя дя (шул падша) кюк кылар.

[1] Талантта 1300 сумга жакын.

[2] Динарійдя 21 тейен.

19-нчы бюлем

1 Шушы сюзлярне айтеб бетергяч, Іисусъ Галилеядян чыгыб, Іорданнын ары жагы белян Іудея тиряляреня килгян. 2 Анын артыннан кюб калык барган, Ул аларнын (чирлелярен) тӧзяткян.

Зач. 78. 3 Анын жанына фарисейляр килеб, Аны сынаб, Аңар айткянняр: яр-бер айыбы ӧчӧн дя кешегя ӳз катынын айырырга мӧңким ме? дигянняр. 4 Ул аларга жауаб биреб айткян: Булдырыучы баштук аларны ирле катынны итеб булдырганны сез укымадыгыз [1] меней? 5 Тагы айткян: шуңар кюря кеше ӳз атасын, анасын калдырыр да катынына кушылыр, аннары икесе дя бер тян булырлар, [2] дигян. 6 Шунныктан алар инде икяӳ тӧгӧл, ӓммя бер тян. Алай булгач, Алла кушылдырганны кеше айырмасын, дигян. 7 Алар Аңар айткянняр: ник суң Моисей (катынга) айырыу жазыуын биреб, аны айырыб жибярергя бойорган? дигянняр. 8 Ул аларга айткян: кюңелегез катыга кюря Моисей сезгя катыныгызны айырыб жибярергя ирек иткян; ӓммя башта алай тӧгӧл эйе. 9 Ӓммя Мин сезгя айтямен; кем ӳз катынын уйнашлык айыбы булмаган кӧйӧ айырыб, бютян катын алса, ул уйнашлык итя; айырыб жибяргян катынны алыучы да уйнашлык итя, дигян. 10 Ӧйрянеӳчеляре Аңар айткянняр: кеше ӳз катынына шулай булырга тейеш булгач, айса ӧйлянмей тороу жакшырак, дигянняр. 11 Ул аларга айткян: мыны барысы да сыйыштыра алмас, тик кемгя бирелгян, шул гна (сыйыштырыр). 12 Катынга жакыннашырга жараусыз тӧрлӧ кешеляр бар: кайсылары ана эченнян шулай тыуганнар; кайсыларын кеше шулай иткян; кайсылары кюк падшалыгы ӧчӧн ӳзлярен ӳзляре шулай иткянняр. (Бу сюзне) сыйдыра алырлыгы сыйдырсын, дигян. 13 Шул чакта Аңар балаларны китергянняр, Ул алар ӧстӧня кулын салыб, теляк итсен диб, ӓммя ӧйрянеӳчеляре аларны туктатыб торганнар. 14 Іисусъ аларга айткян: балаларны ирек жибярегез, аларга Миңа килергя кумачау итмягез, кюк падшалыгы шундыйларныкы шул, дигян. 15 Ул аннары алар ӧстӧня кулын салыб, аннан киткян.

Зач. 79. 16 Мына беряӳ килеб, Аңар айткян: эй изге ӧйрятеӳче! мянге тормошны алыйым дисям, мин ней жак-

[1] Быт 1:27.
[2] Быт 2:24.

шылык кылыйым? дигян. 17 Ул анҕар äйткян: ник син Мине изге диб äйтясен? беряў дя изге тöгöл, тик бер Алла гна (изге). Мянге тормошка керясеҥ кился, бойорокларны кыл, дигян. 18 Ул Анҕар: ничеклярне? дигян. Іисусъ äйткян: ўтермя, уйнашлык итмя, урлама, жалган таныклык итмя; 19 Атаҥны, анаҥны санна, жакынынҥны ўзеҥне сöйгян кюк сöй, [1] дигян. 20 Бу жегет Анҕар äйткян: мин быларнын барын да жяштянюк тоттом, тагы миҥа ней житмей? дигян. 21 Іисусъ анҕар äйткян: äгяр бöтöнняй (арыулыкка) тулы буласын кился, кайтыб малынҥны сат та жарлыларга öляш, синеҥ малыҥ кюктя булыр, аннары килеб, Минем артымнан жöр, дигян. 22 Мыны эшеткяч, жегет (Анын жаныннан) кайгырыб киткян: анын малы кюб икян. 23 Іисусъ öйрянеўчеляреня äйткян: чыннаб äйтямен сезгя: бай кешегя кюк падшалыгына кереўе читен, дигян. 24 Тагы да äйтямен сезгя: бай кешегя кюк падшалыгына кереўдян дöягя иня кюзеннян ўтеўе асатрак, дигян. 25 Öйрянеўчеляр мыны эшетеб, бик исляре китеб äйткянняр: алай булгач, кем котола алыр суҥ? дигянняр. 26 Іисусъ аларга караб äйткян: кешеляргя бу мöҥким тöгöл, ämмя Аллага бар да мöҥким, дигян. 27 Шунда Петръ жауаб биреб, Анҕар äйткян: мына без барысын да калдырыб, Синҕа эярдек, суҥ инде безгя ней булыр? дигян. 28 Іисусъ аларга äйткян: чыннаб äйтямен сезгя: сез Миҥа эяргянняр, тагы-булыуда, Ädям Улы Ўз олологынын престолына утыргач, сез дя ун ике престолга утырыб, Израилнен ун ике рыуына хокöм итярсез. 29 Öйлярен, жя ага-энелярен, жя тута-сеҥнелярен, жя атасын, жя анасын, жя катынын, жя балаларын, жя жирен-сыуын Минем исемем öчöн кем гня калдырса да жöз табкыр артык алыр, мянге тормошка урыннашыр. 30 Алдагылар кюбесе артта булырлар, ämмя арттагылар алда булырлар, дигян.

[1] Исх 20:12-16. Лев 19:18.

20-нче бюлем

Зач. 80. 1 Кюк падшалыгы жорт эясе кешегя ошой: ул бик иртюк ўзенен жöзöм бакчасында (эшлярга) эшчеляр жалларга чыккан. 2 Эшчеляр белян кöнöня бер динарійгя килешеб, аларны ўзенен жöзöм бакчасына жибяргян. 3 Öчöнчö сагаття чыгыб,

урамда эшсез тороучыларны кюргян. 4 Ул аларга да айткян: сез дя минем жөзөм бакчама барыб эшлягез, мин сезгя теярен бирем, дигян; алар барганнар. 5 Тагы алтынчы сагаття дя, тугызынчы сагаття дя чыгыб, шулай кылган. 6 Калдыгында ун беренче сагаття чыгыб, ул тагы эшсез тороучы бютяннярне очратыб, аларга айткян: сез мында ник кён буйы эшсез торасыз? дигян. 7 Алар анар: безне беряў дя жалламады, дигянняр. Ул аларга айткян: сез дя минем жөзөм бакчама барыб эшлягез, ўзегезгя теярен алырсыз, дигян. 8 Кич булгач, бакча эясе ўз жортон караучыга айткян: эшчелярне чакырыб китер дя аларга эш какы бир, сунгыларыннан башлаб, элекегеляре белян бетер, дигян. 9 Ун беренче сагаття килгянняре беряр динарій алганнар. 10 Инг алдан килгянняре без артыгырак алырбыз диб уйлаганнар, тик алар да беряр гня динарій алганнар. 11 Алгач, жорт эясеня зарлана башлаб, 12 Айткянняр: бу сунгылар бер гня сагат эшляделяр, ämмя син аларны без кён буйы кызыуга чыдаб эшлягянняр белян тинг иттенг, дигянняр. 13 Ул аларнын берсеня сюз кайтарыб айткян: эй дус! мин сине читлямейем, син минем белян бер динарійгя килештенг тögöл ме? 14 Ўзенгнекен ал да кит; мин бу сунгыга да синга биргян чаклы бирясем киля. 15 Älля минем ўз нястямя телягянемне кыларга иркем жук? Минем жакшылыгыма кюзенгнен кончölögö киля меней? дигян. 16 Шулай, арттагылар алда булырлар, алдагылар артта булырлар; чакырылганнар кюб, ämмя сайланганнар аз шул, дигян.

Зач. 81. 17 Iисусъ Iерусалимгя менеб барган чакта, жулда ун ике öйрянеўчесен аулакка алыб китеб, аларга айткян: 18 Мына без Iерусалимгя менеб барабыз, анда Ädям Улы архiерейляр, книгячеляр кулына тотоб бирелер, алар Аны ўтерергя хокöм итярляр; 19 Аны жалган деннелярге мыскылларга, кыйнарга, кадакларга тотоб бирерляр; Ул öчöнчö кönöндя терелеб торор, дигян. 20 Шул чакта Зеведей улларынын анасы ўз уллары белян Iисусъ жанына килеб, Аннан башырыб бер нястя сораган. 21 Iисусъ анар: син ней телейсен? дигян. Ул Анар айткян: минем ике улыма падшалыгында берсеня унг жагына, икенчесеня сул жагына утырырга айтче, дигян. 22 Iисусъ сюз кайтарыб айткян: ней сораганыгызны ўзегез белмейсез. Мин эчясе сауыттагын

эчя алырсыз мы? Мин чумыла торган чумылыу белян чумыла алырсыз мы? дигян. Алар Анҕар: алырбыз, дигянняр. 23 Аннары Ул аларга äйткян: Минем сауытымдагын эчярсез, Мин чумыла торган чумылыу белян дя чумылырсыз, тик Ўземнен уҥ жагыма, сул жагыма утыртыу Минем иркемдя тöгöл, ämмя Атам кемгя äзерлягян, шул (утырыр), дигян. 24 Мыны эшетеб, унысы ике агаэнене ошатмаганнар. 25 Іисусъ аларны чакырыб алыб äйткян: калык тюряляре калыкларга тюрялек иткянне, ололары аларны кул астларында тотканны сез белясез. 26 Сезнен арагызда алай булмасын, ämмя сезнен арада кем олорак буласы кился, ул сезгя кызмятче булсын. 27 Кем сезнен арада баш буласы кился, ул сезгя кол булсын. 28 Шулай, Äдям Улы да Ўзеня кызмят иттерер öчöн килмяде, ämмя Ўзе кызмят итяр öчöн, кюб (кешелярне) жолар öчöн Ўз жанын бирергя (килде), дигян.

Зач. 82. 29 Алар Іерихоннан чыккан чакта, Анын артыннан кюб калык барган. 30 Шунда жул буйында утырыучы ике сукыр кеше Іисусъ узыб барганны эшетеб, кычкырганнар: эй Давидъ Улы Ходай, безне жарлыка диб. 31 Калык аларга кычкырырга кушмаган, ämмя алар: эй Давидъ Улы Ходай, безне жарлыка диб бигеряк тя нык кычкыра башлаганнар. 32 Іисусъ туктаб, аларны чакырыб алыб äйткян: Мин сезгя ней кылсын диб телейсез? дигян. 33 Алар Анҕар: эй Ходай! кюзляребез ачылсын ыйы диб (телейбез), дигянняр. 34 Іисусъ аларны кызганыб, кюзляреня тейенгян; шул сяттюк аларнын кюзляре кюря башлаган; шуннан ары алар Анҕар эяреб киткянняр.

21-нче бюлем

Зач. 83. 1 Іерусалимгя жакыннашарак, Елеонъ тауына, Виөсфагія атлы ауылга килеб житкяч, Іисусъ ике öйрянеўчесен жибяреб, 2 Аларга äйткян: шушы алдыгыздагы ауылга барыгыз, баргачтук анда бяйляб куйган ишякне колоны белян очратырсыз, чишеб (аларны) Миҥа алыб килегез. 3 Äгяр беряў сезгя бербер сюз äйтся, алар Ходайга киряк дигез, ул шул сяттюк аларны биреб жибярер, дигян. 4 Бу барда пагамбяр арткылы äйтелеў жиреня килер öчöн булган, ул äйткян: 5 Сіонъ кызына äйтегез: мына синеҥ падшаҥ, жигеля торган ишякнен колонона атла-

ныб, синеҥ жанына жыуашлык белян киля [1] диб. 6 Ойрянеўчеляр барыб, Іисусъ кушканча кылганнар. 7 Ишякне колоны белян алыб килеб, алар өстөня ўзляренен кеймнярен салганнар, Іисусъ кеймняр өстөня атланган. 8 Кюб калык ўз кеймнярен жул өстөня жяйеб барганнар, кайсылары агачлардан жапраклы чыбыклар кисеб алыб, жулга тюшяб барганнар. 9 Калыкнын алдан барыучылары да, арттан барыучылары да: Осанна Давидъ Улына! Ходай исеменя килеўче даннаулы, эй жугарыдагы Осанна! диб кычкырыб барганнар. 10 Ул Іерусалимгя кергяч, бөтөн кала кузгалган, бер берсеннян: Бу кем? диб сорашканнар. 11 Калык йяткян: Бу Іисусъ, Галилеядяге Назареттан (чыккан) пагамбяр, дигянняр. 12 Іисусъ Алла чиркяўеня кергяч, чиркяўдя сатыу итеўчелярне, алыучыларны барысында кыуыб чыгарган; акча алыштырыучыларнын өстяллярен, кюгярчен сатыучыларнын скямьялярен аударыб бетергян. 13 Аннары аларга йяткян: жазылган ич: Минем өйөм теляк өйө диб аталыр, ямма сез аны талаучылар оясы кюк иткянегез диб, [2] дигян. 14 Шул чакта чиркяўдя Анын жанына сукырлар, аксаклар килгянняр. Ул аларны тёзяткян. 15 Архіерейляр, книгячеляр, Ул кылган кодрятлярне кюреб, тагы: Осанна Давидъ Улына! диб чиркяўдя кычкырыучы балаларны кюреб, ачыулары килеб, 16 Анар йяткянняр: алар ней йяткянне эшетясеҥ ме? дигянняр. Іисусъ аларга йяткян: эйе, сез ялля: жяш балаларнын, имчяк имя торганнарнын ауызыннан Син Ўзеҥне мактаттыҥ, [3] дигянне бер чактада укымадыгыз мы? дигян. 17 Аннары аларны калдырыб, каладан чыгыб, Виөаніягя киткян, төннө шунда ўткяргян.

Зач. 84. 18 Иртя белян калага кайткан чакта ашасы килгян. 19 Жул буйында бер смоква агачын кюреб, анын жанына барган; анда жапракларыннан бютян нястя табмагач, анар йяткян: синдя мыннан блай гумергя жимеш булмасын, дигян. Смоква агачы шундук короган. 20 Ойрянеўчеляр мыны кюреб, исляре китеб йяткянняр: бу смоква агачы ничек кинят короды? дигянняр. 21 Іисусъ аларга жауаб биреб йяткян: чыннаб йятямен сезгя: ягяр сез шиклянмейче ышансагыз, смоква агачына кылганны гна кылмассыз, ямма

[1] Зах 9:9.

[2] Ис 56:7. Іер 7:11.

[3] Пс 8:3.

шушы тауга: кютярелеб, дингезгя атыл дисягез, (ул да) булыр. 22 Телягегездя ышаныб ней гня сорасагыз да, барын да алырсыз, дигян.

Зач. 85. 23 Аннары чиркяўгя килеб ӧйряткян чагында, Анын жанына архіерейляр, калык башлыклары килеб айткянняр: Син мыны кем бойороуы белян кыласын? мындый кыуатны Синга кем бирде? дигянняр. 24 Іисусъ аларга жауаб биреб айткян: Мин дя сездян бер сюз соройом, сез Миңа шунар (жауаб) айтсягез, Мин дя сезгя мыны кем бойороуы белян кылганымны айтермен. 25 Іоаннъ чумылдырырга (бойорок) кайдан алды? кюктян ме, алля кешелярдян ме? дигян. Алар ўз аралый уйлаганнар: ягяр кюктян дисяк, Ул безгя: ник суң анар ышанмадыгыз, дирер. 26 Ягяр кешелярдян дисяк, калыктан куркабыз, Іоанны бар да пагамбяргя саныйлар шул диб. 27 Аннары жауаб биреб, Іисуска айткянняр: белмейбез, дигянняр. Ул да аларга айткян: Мин дя сезгя мыны кем бойороуы белян кылганымны айтмям, дигян.

Зач. 86. 28 Сезгя ничек тея? Бер кешенен ике улы булган; ул элекесеня килеб айткян: улым! бар, бөгён минем жӧзӧм бакчамда эшляче, дигян. 29 Улы жауаб биреб айткян: бармам, дигян; ўкенеб, суңыннан барган. 30 Икенчесеня килеб, анар да шулай айткян; анысы жауаб биреб: эй ятей, барым, дигян, тик бармаган. 31 Икесенен кайсысы атасы кушканны кылган? дигян. Алар Анар: элекегесе, дигянняр. Іисусъ аларга айткян: чыннаб айтямен сезгя: мытарлар, азгын торган катын-кызлар Алла падшалыгына сездян алдан керяляр. 32 Іоаннъ сезгя дӧрӧслӧк жулы белян килде, сез анар ышанмадыгыз, мытарлар, азгын торган катын-кызлар анар ышандылар, ямма сез мыны кюргячтя тяўбягя килмядегез, анар ышанмадыгыз шул, дигян.

Зач. 87. 33 Икенче мясял тынгнаб алыгыз: бер жорт эясе булган; ул жӧзӧм агачлары утыртыб, айлянясен койма белян айляндергян; эчендя (жӧзӧм сыуын) агызгыч жасаган, башня торгозган, аннары бакчаны бакчачыларга табшырыб, киткян. 34 Жимешен жыяр багыт житкяч, ул ўз кызмятчелярен бакчачылардан жимешен алырга жибяргян. 35 Бакчачылар анын кызмятчеляреня жабышыб, кайсын кыйнаганнар, кайсын ўтергянняр, кайсысын таш белян атыб ўтергянняр. 36 Ул тагы элекегелярдян дя кюберяк ўнгя

кызмятчеляр жибяргян; аларга да шулай кылганнар. 37 Улымнан оялырлар диб, калдыгында ул аларга ўз улын жибяргян. 38 Ämмя бакчачылар анын улын кюреб, бер берсеня äйткянняр: бу атасы урнына каласы, äйдягез ўтерейек аны, аннары анăр каласы малны ўзебезгя алырбыз, дигянняр. 39 Аны тотканнар да бакчадан чыгарыб ўтергянняр. 40 Бакчанын эясе килгяч, бу бакчачыларга инде ней кылар? дигян. 41 Алар Анăр äйткянняр: бу усалларны азаблаб харяб итяр, бакчасын багытында анăр жимешен бирерлек бютян бакчачыларга табшырыр, дигянняр. 42 Iисусъ аларга äйткян: сез ялля: öй салыучылар жараусыз кюреб ташлаган таш почмак астына нигез булган, Ходайдан булган бу, безнен кюз алдыбызда ис китярлек [1] дигянне жазыуда бер чакта да укымадыгыз мы? дигян.

Зач. 88. 43 Шунныктан сезгя äйтямен: Алла падшалыгы сездян алыныр да жимешен китерерлек калыкка бирелер. 44 Бу таш öстöня жыгылган кеше уатылыр, ämмя кем öстöня бу таш тöшся, аны сытар, дигян. 45 Архiерейляр белян фарисейляр Анын мясяллярен эшеткяч, Ул алар турысында äйткянне анăнаганнар. 46 Аннары алар Аны тотоб алмакчы булганнар, тик калык Аны пагамбяргя санаганга кюря, калыктан курыкканнар.

[1] Пс 117:22-23.

22-нче бюлем

Зач. 89. 1 Iисусъ тагы мясяллярнең китереб, аларга äйткян: 2 Кюк падшалыгы улын öйляндергяндя туй жасаган падша кешегя ошой: 3 Туйга öндялгяннярне чакырырга ул ўзенен колларын жибяргян; öндялгяннярнен киляселяре килмягян. 4 Ул аннары жанăдан бютян колларын былай äйтеб жибяргян: чакырылганнарга: мына инде ашым äзер, симерткян бызауларымны, тагы бютян тöрлö жяннекляремне дя суйдырдым, барда äзер инде, туйга барыгыз диб äйтегез, дигян. 5 Ämмя чакырылганнар саннамыйчы кайсысы басыуына, кайсысы сатыуына киткян; 6 Кайсылары анын колларын тотоб, аларны кадерсез итеб ўтергянняр дя. 7 Падшанын мыны эшеткяч, ачыуы килгян; ўз командасын жибяреб, шул ўтереўчелярнен ўзлярен ўтерттергян, калаларын да жандырткан. 8 Аннары ўз колларына äйткян: туй ашы инде äзер, тик чакырылганнар тейешле булмадылар. 9 Сез инде жул чатлары-

на барыгыз, анда кемне гня очратсагыз да, барысын да туйга чакырыгыз, дигян. 10 Ул коллар жулларга чыгыб, туры килгянне барысын да: жакшыларын да, жаманнарын да жыйганнар; туй (өйө) кунаклар белян тулган. 11 Падша кунакларны кюрергя кергяч, анда туй кеймен кеймягян кешене кюреб, 12 Анғар йткян: эй дус! син мында туй кеймен кеймягян көйө ничек керясе иттең? дигян; ул дяшмягян. 13 Шунда падша ўз коллары на йткян: мынын кулларын, аякларын бяйлягез дя, алыб аны тыштагы карангылыкка чыгарыб ташлагыз; анда жылау, теш шыкырдатыу булыр, дигян. 14 Чакырылганнар кюб, ммя сайланганнар аз шул, дигян.

Зач. 90. 15 Шул чакта фарисейляр китеб, ничек булса да Іисусны сюзеннян эляктерейек диб кинғш иткянняр дя, 16 Анын жанына ўз йрянеўчеляре белян иродныкыларны былай диб йтергя жибяргянняр: эй Йрятеўче! без Синең туры кеше икянеңне белябез, Син Алла жулына дөрөс йрятясен, беряўгя дя (жумалаб) жараулы булыйым диб, кешесеня караб (кылмыйсын) шул. 17 Йтче безгя, Синға ничек тея? Кесаргя имана бирергя тейеш ме, ялля жук мы? дигянняр. 18 Іисусъ аларнын жаман уйларын белеб йткян: эй жумачылар! ник сез Мине сыныйсыз? 19 Иманага биря торган тянкяне Миңа кюрсятегез але, дигян. Алар Анғар динарій китереб биргянняр. 20 Ул аларга йткян: мында кем төсө, кем исеме жазылган? дигян. 21 Алар Анғар: Кесарнеке, дигянняр. Шунда Ул аларга йткян: алай булгач, Кесарнекен Кесаргя, ммя Алланыкын Аллага бирегез, дигян. 22 Мыны эшеткяч, алар исляре китеб, Анын жаныннан киткянняр.

Зач. 91. 23 Шул көннө Анын жанына терелеб тороу булмас диб йтеўче саддукейляр килеб, Аннан сораганнар: 24 Эй Йрятеўче! Моисей йткян: ягяр кем балалары булмый ўлся, анын катынын энесе алыб, агасына нясел булдырсын, [1] дигян. 25 Мына безнен жиде ага-эне бар ыйы; элекегесе йлянгяч ўлде, балалары калмады, анын катынын энесе алды. 26 Шулай икенчесе дя, өчөнчөсө дя, жидесе дя (аны алыб йлянделяр дя ўлделяр). 27 Барысыннан сың катын да ўлде. 28 Терелеб торгач, ул жидесенен кайсына катын булыр сың? ул аларнын барысынында катыны булган ыйы,

[1] Втор 25:5-6.

дигянняр. 29 Іисусъ аларга жауаб биреб äйткян: Алла жазыуын, Алла кыуатын белмягяннектян жангышасыз сез. 30 Терелеб торгач, öйлянмейляр дя, кеяўгя дя китмейляр, ämмя кюктя Алла пяриштяляре торган кюк торалар. 31 Ämмя ўлгянняр терелеўе турысында сезгя Алла äйткянне: 32 Мин Авраамъ Алласы, Исаакъ Алласы, Іаковъ Алласы, [1] дигянне сез укымадыгыз меней? Алла ўлгянняр Алласы тögöл, ämмя тереляр Алласы, дигян. 33 Калык мыны эшеткяч, Анын öйряткяненя исляре киткян.

Зач. 92. 34 Іисусъ саддукейлярне курлыкка калдырганны эшеткяч, фарисейляр бергя жыйылганнар. 35 Шунда аларнын берсе, законга öйрятеўчесе Аны сынаб сораган: 36 Эй Öйрятеўче, законда иң оло бойорок кайсы? дигян. 37 Іисусъ анга äйткян: Алла Ходайыңны бар кюңелең белян, бар жаның белян, бар уйың белян сöй. [2] 38 Шушы баш бойорок, иң оло бойорок. 39 Икенчесе дя шуңар ошаулы: жакыныңны ўзеңне сöйгян кюк сöй. [3] 40 Бötön законнын да, пагамбярлярнен дя öйряткяне шушы ике бойорокта тора, дигян. 41 Фарисейляр жыйылгач, Іисусъ алардан сораган: 42 Христосъ турысында сез ней уйлыйсыз? Ул кем Улы? дигян. Алар Анга: Давидь улы, дигянняр. 43 Ул аларга äйткян: ничек суң Давидъ Тын тойдорган буйынча Аны Ходай дей? ул äйтя: 44 Ходай минем Ходайыма äйткян: Мин дошманнарыңны аягың астына салгынчы, Минем уң жагымда утыр, [4] дей. 45 Давидъ Аны Ходай диб äйткяч, Ул ничек суң анын улы була? дигян. 46 Анга карышы беряў дя, бер сюз дя äйтя алмаган; шул көннян суң Аннан ич кем (сынаб) сорарга кыймаган.

[1] Исх 3:6.

[2] Втор 6:5.
[3] Лев 19:18.
[4] Пс 109:1.

23-нче бюлем

Зач. 93. 1 Шул чакта Іисусъ калыкка да, öйрянеўчеляреня дя былай диб äйтя башлаган: 2 Моисей урнына книгячеляр белян фарисейляр утырганнар. 3 Алар сезгя кыларга кушканны барын да тотогоз да, кылыгыз да, тик алар кылынганча кылынмагыз: алар ўзляре äйткянне ўзляре кылмыйлар шул. 4 Алар, кютяреб жöрöй алмаслык, ауыр кютярям бяйляб, кешеляр жилкя-

сеня салалар, ӓммя ӱзляре аны бармаклары белян дя кузгатасылары килмей. 5 Алар бар эшлярен кешеляр кюрсенняр диб кня кылалар; (мангайларына, кулларына) бяйляўечляр кинг итеб бяйлейляр, кейем кырыйларына зур чуклар тагалар. [1] 6 Тагы ашка жыйылган жирдя тюргя утырыуны, синагогаларда алда утырыуны сӧяляр. 7 Урамнарда кеше башырганны, ӱзлярен: ӧйрятеўче, ӧйрятеўче диб кублаганны жараталар. 8 Ӓммя сез ӱзегезне ӧйрятеўче дигянне телямягез: сезнен Ӧйрятеўчегез бер Христосъ кна шул, ӓммя сез барыгыз да бер туганнар кюк. 9 Жир ӧстӧндя беряўне дя ата диб ӓйтмягез: сезнен Атагыз беряў гня шул, Ул кюктя. 10 Ӱзегезне ӱгетляўче дигянне дя телямягез: сезнен Ӱгетляўчегез бер Христосъ кна шул. 11 Сезнен арада ологоз, сезгя кызмятче булсын. 12 Кем ӱзен ӱзе кютярся, ул кечегя калыр, ӓммя кем ӱзен ӱзе кечеляндерся, ул ололаныр, дигян.

Зач. 94. 13 Айгай сезгя книгячеляр, фарисейляр, жумачылар! сез кешелярга кюк падшалыгын жабыб торасыз: ӱзегез дя кермейсез, керясе килгянняр-не дя кертмейсез. 14 Айгай сезгя книгячеляр, фарисейляр, жумачылар! сез тол катыннарнын жортларын ашаб бетерясез шул; кюренер ӧчӧн гня озаклаб теляк итясез: шунын ӧчӧн сез артыгырак айыбланырсыз. 15 Айгай сезгя книгячеляр, фарисейляр, жумачылар! сез беряўне-беряўне ӱз денегезгя ауыштырыр ӧчӧн, дингезлярне, коро жирне жӧрӧб бетерясез; ауыштыргач, аны ӱзегездян ике ӧлӧш жаманырак тамук улы итясез. 16 Айгай сезгя сукыр жӧртӧўчеляр! сез ӓйтясез: кем чиркяўне алыб ант ится, кылмаса да жарый, ӓммя кем чиркяў алтынын алыб ант ится, кыларга тейеш, дейсез. 17 Эй акылсызлар, сукырлар! ней олорак: алтын мы, ӓлля алтынны арыуландыра торган чиркяў ме? 18 Тагы (ӓйтясез): кем корман урны белян ант ится, кылмаса да жарый, ӓммя кем анын ӧстӧндяге корман белян ант ится, кыларга тейеш дейсез. 19 Эй акылсызлар, сукырлар! ней олорак: корман мы, ӓлля корманны арыуландыра торган урын мы? 20 Корман урны белян ант итеўче, урны белян дя, анын ӧстӧндя ней бар, барысы белян дя ант итя. 21 Чиркяў белян ант итеўче, анын ӱзе белян дя, эчендя Тороучы белян дя ант итя. 22 Кюк бе-

[1] Кинг бяйляўечляр, зур чуклар белян фарисейляр Алланы кадерляўне кюрсяткянняр. Втор 6:8. Числ 15:38-39.

лян ант итеўче, Алла престолы белян дя, анын östöндя Утыручы белян дя ант итя.

Зач. 95. 23 Айгай сезгя, книгячеляр, фарисейляр, жумачылар! сез бötнöктян, анистан, тминнан унынчы өлөшөн бирясез, әмма законда гынын иң ололарын: турылыкны, изгелекне, ышаныуны калдырганыгыз; быларны да кыларга киряк, тегелярен дя калдырырга киряк мяс. 24 Эй сукыр жөртөўчеляр! сез черкейне сөзясез, әмма дөяне жотасыз. 25 Айгай сезгя, книгячеляр, фарисейляр, жумачылар! сез табак-сауытларыгызнын тышларын тазартасыз, әмма эчляре талаб алган нястя белян, дөрöссөзлөк белян тулы. 26 Эй сукыр фарисей! элеке табак-сауытынгнын эчен тазарт, аннары аларнын тышы да таза булыр. 27 Айгай сезгя, книгячеляр, фарисейляр, жумачылар! сез тышларын буяган гробларга ошаулы: алар тышларыннан матур кюреняляр, әмма эчляре ўлек сöяге белян, äр-тöрлö шакшылык белян тулы. 28 Шулай сез дя тышыгыздан кешелярга гадел кюк кюренясез, әмма эчегез жумалау белян, законсызлык белян тулы, дигян.

Зач. 96. 29 Айгай сезгя, книгячеляр, фарисейляр, жумачылар! сез пагамбярлярга каберляр торгозасыз, гаделлярнен памятникларын [1] матурлыйсыз. 30 Сез äйтясез: ägяр без аталарыбыз көнняренда торган булсак, пагамбярлярнен каннарын тюгярга аларга катышмаган булыр ыйык, дейсез. 31 Шулай итеб ўзегезне ўзегез пагамбярлярне ўтереўчелярнен уллары икянегезне кюрсятясез. 32 Сез дя инде аталарыгызнын ўлчяўен тутырыгыз. 33 Эй жыланнар, эй ехидна [2] тыумалары! сезне тамукка тöшöртясе хокömнян ничек качарсыз? 34 Мына Мин сезгя пагамбярлярне, белемне кешелярне, укымышларны жибярям; сез аларнын кайсыларын ўтерерсез, качка кадакларсыз, әмма кайсыларын синагогаларыгызда кыйнарсыз, каладан калага кыуарсыз. 35 Жир östöндя гаделлярнен (айыбсыз) тюгелгян каны, гадел Авель каныннан башлаб, корман урны белян келяў öйö арасында сез ўтергян Варахія улы Захаріянын канына чаклы, барысыда сезгя тöшсön. 36 Чыннаб äйтямен сезгя: бу барда шушы тыумага килер. 37 Эй пагамбярлярне ўтереб бетереўче, синга жибярелгяннярне таш белян атыб ўтереўче Іерусалимъ,

[1] Иския тöшöргöч.
[2] Загяр жылан.

Іерусалимъ! тауык ўз чебешлярен канаты астына жыйган кюк, Мин синең балаларыңны ничя табкыр Ўз катыма жыясым килгян эйе, ämмя сез телямядегез. 38 Мына инде бу жортогоз сезгя буш кала. 39 Сезгя äйтямен: Ходай исеменя Килеўче даннаулы диб äйткенче, сез Мине мыннан былай кюрмяссез, дигян.

24-нче бюлем

Зач. 97. 1 Іисусъ чиркяўдян чыгыб, китеб барганда, öйрянеўчеляре Аңар чиркяў каралдыларын кюрсятмякче булыб, 2 Анын жанына килгянняр. Іисусъ аларга äйткян: быларнын барысында кюрясез ме? чыннаб äйтямен сезгя: мында таш östöндя таш та калмас, барысында жимереб бетererляр, дигян.

Зач. 98. 3 Ул Елеонъ тауы östöндя утырганда, öйрянеўчеляре Анын жанына килеб, аулакта сораганнар: äйтче безгя, ул кайчан булыр, тагы килеўеңнен, дöнья бетеўенен билгесе ничек булыр? дигянняр. 4 Іисусъ аларга жауаб биреб äйткян: сак булыгыз, беряў-беряў сезне жангыштырмасын. 5 Кюбесе Минем исемем белян, мин Христосъ диб килерляр шул, кюбесен жангыштырырлар да. 6 Тагы сугышлар булганны, сугыш хабярлярен эшетersез; карагыз, курыкмагыз, былар барысыда булырга тейеш шул, алайда ул äле бетеў тöгöл. 7 Калык калыкка, падшалык падшалыкка жабышыр, ачлыклар, ўлятляр булырлар, урны-урны белян жир титряр. 8 Былар барысыда азабларнын башланыуы гна. 9 Шул чакта сезне тотоб азабка бирерляр, сезне ўтererляр, Минем исемем öчön сезне бар калыклар да кюрялмаслар. 10 Шул чагында кюбесе алданырлар, бер берсен тотоб бирерляр, бер берсен кюрялмаслар. 11 Кюб жалган пагамбярляр чыгарлар, кюбесен жангыштырырлар. 12 Законсызланыу кюбяйгяннектян кюбесендя сöйöўлек бетяр, дигян.

Зач. 99. 13 Калдыкка чаклы тюзгяне котолор. 14 Алла падшалыгынын шушы Евангеліесе бар калыкларгада таныклыкка, бöтöн дöньягя жяйелер, шуннан суң бетеў булыр. 15 Даніилъ пагамбяр äйткянчя, арыу урында жирянгеч нястяляр торганны [1] кюрersез; укыган кеше аңнасын. 16 Шул чакта Іудеядягеляр тауларга качсыннар. 17 Öй тюбясендя булганы, öйöмнян бер-бер нястя алыб китейем диб, төшмясен. 18 Басы-

[1] Дан 9:27.

уда булганы, кейемняремне алыб китейем диб, кире кайтмасын. 19 Ул көннярдя ауырлы катыннарга, имчяк имезеўчелярга читен булыр. 20 Качарыгызга кыш, жя суббота кön туры килмясен эйе диб телягез. 21 Ул чакта бик зур кайгы булыр, анын кюк кайгы дöнья булдырылганнан башлаб, ялегя чаклы да булганы жук, булмас та. 22 Ягяр шул көнняр кыскармасалар, бер тян дя котолмас ыйы, тик сайланганнар какына ул көнняр кыскарыр. 23 Шул чакта беряў сезгя: мына мында Христосъ, жя ана тегендя дейся, ышанмагыз. 24 Жалган христослар, жалган пагамбярляр чыгарлар; мöнким булса сайланганнарны да жангыштырыр öчön, зур кодрятляр, билгеляр кюрсяткян булырлар. 25 Мына Мин сезгя алданук яйттем. 26 Шулай, сезгя: мына Ул буш кырда дейсяляр, чыкмагыз; мына Ул аулак бюлмялярдя дейсяляр, ышанмагыз, дигян.

Зач. 100. 27 Жяшен ничек кояш чыгышыннан чыгыб, кояш байышына чаклы жяшняб кюреня, Ädям Улынын килеўе дя шулай булыр. 28 Ўлякся жаткан тöшкя бöркöтляр жыйылыр. 29 Шул кайгылы көннярдян сун, кинят кояш карангыланыр, ай ўз жактысын жактыртмас, жондозлар кюктян койолорлар; кюктяге чиреўляр кузгалышырлар. 30 Шул чагында кюктя Ädям Улынын билгесе кюренер, аннары жирдяге няселляр барысыда жылаша башлярлар; кюк болотлары öстöндя кодрят белян, оло дан белян килеўче Ädям Улын кюрерляр. 31 Ул Ўз пяриштялярен зур тауышлы бырылар белян жибярер; алар дöньянен дюрт жагыннан, кюкнен бер кырыйыннан башлаб, икенче кырыйына чаклы Анын сайлаганнарын жыярлар. 32 Смоква агачыннан ошаш алыгыз: анын ботаклары жомошаб, жапрак жара башлагач, жяй жакын икянне белясез. 33 Шунын кюк быларнын барысында кюргяч, инде жакын, ишек тöбöндя диб белегез.

Зач. 101. 34 Чыннаб айтямен сезгя: шушы тыума беткенче былар барысыда булыр. 35 Кюк белян жир бетярляр, ämмя Минем сюзлярем торор.

Зач. 102. 36 Ул көннö, ул сагатне беряў дя белмей, кюктяге пяриштяляр дя (белмейляр), тик бер Атам гна беля. 37 Ной көннярендя ничек булган, Ädям Улы килгян чагында да шулай булыр: 38 Жирне сыу басар көнняр алдыннан Ной кимягя керер көнгя чаклы, кешеляр ашаганнар, эчкянняр, öйлянгянняр,

кеяўгя киткянняр; 39 Сыу килеб барысын да басыб бетергенче, бер дя белмягянняр, Ädям Улы килгян чагында да шулай булыр. 40 Шул чакта икяў басыуда булсалар, берсе алыныр, икенчесе калдырылыр. 41 Ике катын (кул) тегермяне тартсалар, берсе алыныр, икенчесе калдырылыр.

Зач. 103. 42 Алай булгач, сез уяу торогоз, Ходайыгыз кайсы сагаття килясен белмейсез шул. 43 Сез мыны белясез: ägяр жорт эясе бурнын тönня кайсы багытта килясен белся, ул уяу торор ыйы, ўз жортона казыб керергя ирек бирмяс эйе. 44 Шунăр кюря сез дя äзер булыгыз, Ädям Улы сез уйламаган сагаттюк килер шул. 45 Кызмятчеляреня багытында ашамнык бирсен диб, эяляре аларга башлык итеб куйган, акыллы, гадел кол кюк кем? 46 Ул кол, эясе килгян чакта, анăр шулай кылыб, туры кился, бахетле. 47 Чыннаб äйтямен сезгя: ул аны бар малына баш итеб куяр. 48 Ägяр ул кол усал булыб, кюнеленди эям тиз килмяс äле диб, 49 Ўз иптяшлярен кыйнарга тотонса, эчкечеляр белян ашый, эчя башласа, 50 Ул колнын эясе, кол кötмягян көннö, ул уйламаган сагаття килер дя, 51 Аны уртара чабыб özяр, аннары аны алдаучыларга теясе азабка ташлар; анда жылау, теш шыкырдатыу булыр, дигян.

25-нче бюлем

Зач. 104. 1 Ул чакта кюк падшалыгы, жактырткычлар алыб, кеяўгя карышы чыккан ун кызга ошаулы булыр. 2 Аларнын бишесе акыллы, бишесе уйсыз булганнар. 3 Уйсызлары жактырткычларын алыб, ўзляре белян май алмаганнар. 4 Ämмя акыллылары жактырткычларын да, сауытлар белян май да алганнар. 5 Кеяў озаклагач, барысында жокомсраганнар да жоклаганнар. 6 Тön уртасында: мына кеяў киля, анăр карышы чыгыгыз дигян тауыш эшетелгян: 7 Шунда ул кызлар барысыда тороб, жактырткычларын тözяткянняр. 8 Уйсызлары акыллыларына äйткянняр: безгя май бирчегез, безнен жактырткычларыбыз сюня, дигянняр. 9 Ämмя акыллылары аларга жауаб биргянняр: безнен дя, сезнен дя житмяс булмасын, алай иткенче сез ўзегезгя сатыучылардан барыб алыгыз, дигянняр. 10 Алар сатыб алырга киткяч, кеяў килгян; äзерляре анын белян бергя туйга кергянняр, алар кереў белян ишекне биклягянняр. 11 Суңыннан теге

кызлар килеб äйткянняр: эй Ходай, эй Ходай, безгя ачсана, дигянняр. 12 Ämмя Ул жауаб биргян: чыннаб äйтямен сезгя, мин сезне белмеймен, дигян. 13 Алай булгач, инде уяу торогоз: Ädям Улынын килясе кönön, сагатен белмейсез шул, дигян.

Зач. 105. 14 Бер кеше чит жиргя киткян чакта, колларын чакырыб алыб, аларга малын биреб калдырган. 15 Берсеня биш талантъ биргян, икенчесеня икене, öчönчöсеня берне; äр кайсына кöчöня караб биргян дя, ўзе тизюк киткян. 16 Биш талантъ алганы китеб, аларны эшкя тотоб, тагы биш талантъ табыш табкан. 17 Ике талантъ алганы да шулай тагы ике талантъ табыш табкан. 18 Ämмя бер талантъ алганы киткян дя, аны жиргя кюмеб куйган, шулай итеб эясенен кömöшön жяшергян. 19 Байтак багыттан сунӈ, шул колларнын эяляре кайтыб, алардан исяб сорой башлаган. 20 Биш талантъ алганы тагы биш талантъ китереб, жакын килеб äйткян: эй кужа! син минӈа биш талантъ бирдеӈ, мына мин алар белян тагы биш талантъ табтым, дигян. 21 Эясе анӈар äйткян: жакшы, ышангышлы, арыу колом! äздя дöрöс булдыӈ, сине кюбкя баш итеб куярым; инде мин эяӈ белян бергя сöйön, дигян. 22 Ике талантъ алганы да шулай жакын килеб äйткян: эй кужа! син минӈа ике талантъ бирдеӈ, мына мин алар белян тагы ике талантъ табтым, дигян. 23 Эясе анӈар äйткян: жакшы, ышангышлы, арыу колом! äздя дöрöс булдыӈ, сине кюбкя баш итеб куярым; инде мин эяӈ белян бергя сöйön, дигян. 24 Бер талантъ алганы да жакын килеб äйткян; эй кужа! мин синеӈ каты кеше икяненӈне, чячмягян жирдян урганыӈны, тюкмягян жирдян жыйганыӈны белеб, 25 Курыктым да, китеб талантыӈны жиргя кюмдем; мя синӈа ўзенӈекен, дигян. 26 Эясе анӈар жауаб биреб äйткян: эй жалкау, жаман кол! син чячмягян жирдян урганымны, тюкмягян жирдян жыйганымны белгяч, 27 Айса кömöшömне акча белян сатыу итеўчелярга биреў киряк эйе; мин кайткач, аны табышы белян алыр ыйым. 28 Инде талантны аннан алыгыз да, ун талантлыга бирегез. 29 Барга äр-берсеня бирелер, арттырылыр да, ämмя жукнын нейе бар, анысы да алыныр шул. 30 Бу жараусыз колно тыштагы карангылыкка ташлагыз; анда жылау, теш шыкырдатыу булыр. (Быларны äйткяч, Iисусъ тауыш кютяреб äйткян: эшетергя колагы бар кеше эшетсен, дигян).

Зач. 106. 31 Ädям Улы Ўз
олологында, бар арыу пяриштяляре белян килгяч, Ул Ўз олологынын престолына утырыр;
32 Аннары Анын карышысына
бар калыклар да жыйылырлар;
Ул аларны, көтөўче сарыкларны кязялярдян айырган кюк, бер
берсеннян айырыр: 33 Сарыкларны уң жагына, ämмя кязяляр-
не сул жагына куяр. 34 Шул чакта Падша уң жагындагыларга
äйтер: эй Атамнын бахиллягянняре! килегез, дөнья булдырылганнан бирле сезгя äзерляб
куйган падшалыкка урыннашыгыз. 35 Ачыккан чагымда сез
Миңа ашарга бирдегез, кибенгян чагымда Миңа эчерттегез;
чит жирдя жöргян чагымда сез
Мине кабыл кюрдегез; 36 Жалангач чагымда Мине кейендердегез, чирлягян чагымда Мине карадыгыз, өтөрмяндя чагымда сез
Минем жаныма килдегез шул,
дирер. 37 Шул чагында гаделляр
жауаб биреб, Анар äйтерляр:
эй Ходай! ачыкканыңны кюреб, без Сине кайчан туйдырдык? жя кибенгянеңне (кюреб),
кайчан эчерттек? 38 Чит жирдя жöргяneңне кюреб, без Сине
кайчан кабыл алдык? жя жалангач икянеңне (кюреб), кайчан Сине кейендердек? 39 Синең
чирлягянеңне, жя өтөрмяндя
булганыңны кюреб, кайчан
Синең жаныңа кердек? дирерляр. 40 Шунда Падша аларга
жауабка äйтер: чыннаб äйтямен
сезгя: быларны Минем кече энеляремнен берсеня кылгач, Миңа
кылыуыгыз булды, дирер. 41
Аннары сул жагындагыларга
äйтер: эй каргаулылар! Минем
катымнан шайтанга, анын иптяшляреня äзерляб куйган мянге
утка китегез. 42 Ачыккан чагымда сез Миңа ашарга бирмядегез,
кибенгян чагымда Миңа эчертмядегез; 43 Чит жирдя жöргян
чагымда сез Мине кабыл кюрмядегез, жалангач чагымда Мине
кейендермядегез, чирлягян чагымда, өтөрмяндя чагымда сез
Минем жаныма килмядегез
шул, дирер. 44 Шунда алар да
Анар жауаб биреб äйтерляр: эй
Ходай! Синең ачыкканыңны,
жя кибенгянеңне, жя чит жирдя
жöргянеңне, жалангачлыгыңны,
жя чирлягянеңне, жя өтөрмяндя
булганыңны кюреб, без Синя
кайчан кызмят итмядек? дирерляр. 45 Шунда Ул аларга жауабка äйтер: чыннаб äйтямен сезгя:
быларны шушы кечкенялярнен
берсеня дя кылмагач, Миңа
кылмаганыгыз булды, дирер. 46
Аннары былар мянге азабка китярляр, ämмя гаделляр мянге
тормошка (керерляр), дигян.

26-нчы бюлем

Зач. 107. 1 Бу сюзлярне барысын да айтеб бетергяч, Іисусъ Ўз ойрянеўчеляреня айткян: 2 Тагы ике кöннян суң Пасха буласын белясез, шул чакта Адям Улын кадакларга тотоб бирерляр, дигян. 3 Шул кöннярдя архіерейляр, книгячеляр, калык башлыклары Каіафа атлы архіерейнен жортона жыйылганнар. 4 Алар Іисусны хайля белян тотоб алыб, ўтерергя киңяш иткянняр. 5 Алар айткянняр: алайда калык болганышмасын диб, мыны бяйрям кöннö (кылмыйык), дигянняр.

Зач. 108. 6 Іисусъ Виөаніядя кутырлы тянне Симоннын öйöндя утырган чакта, 7 Анын жанына бер катын сауыт белян кыйбатлы мѵро алыб килеб, Ул утырган кöйö, Анын башына койган. 8 Öйрянеўчеляр мыны кюреб, жаратмыйчы айткянняр: мыны ник ярям итте? 9 Бу мѵроны бик кыйбат сатыб, (акчасын) сораныучыларга бирергя мöңким эйе ич, дигянняр. 10 Іисусъ мыны белеб, аларга айткян: ник сез бу катынны жöдятясез? ул Миңа жакшы эш кылды. 11 Сораныучылар жалан сезнен белян ич, ämмя Мин жалан сезнен белян булмам. 12 Бу мѵроны тянемя койоб, ул Мине кюмярга äзерляде. 13 Чыннаб айтямен сезгя: бöтöн дöньядя кайда гна булса да шушы Евангеліе сöйлянелся, ул катынны иския тöшöрöб, анын ней кылганы да айтелер, дигян. 14 Шул чакта ун икенен берсе, Искаріоть Іуда дигяне архіерейлярга барыб, 15 Айткян: сез миңа ней бирерсез? мин Аны сезгя тотоб бирем, дигян. Алар аңар утыз кömöш тянкя бирмякче булганнар. 16 Шуннан суң ул Іисусны тотоб бирергя кöйлö багыт эзлягян. 17 Тöчö кюмяч кönняренен элекеге кönöндя, öйрянеўчеляре Іисуска килеб айткянняр: Синa пасха äзерлярга безгя кайда кушасың? дигянняр. 18 Ул айткян: калага шундый исемне кешегя барыб, аңар айтегез: Öйрятеўче айтя: инде багытым жакыннашты, синең öйöндя öйрянеўчелярем белян пасха кыларым диб айтте дигез, дигян. 19 Öйрянеўчеляре Іисусъ кушканча кылганнар, пасха äзерлягянняр. 20 Кич булгач, Іисусъ (килеб) ун ике öйрянеўчесе белян бергя утырган. 21 Ашаган чакта аларга айткян: чыннаб айтямен сезгя, сезнен арадан беряў Мине тотоб бирер, дигян. 22 Алар бик кайгыга тöшöб, берсе артыннан берсе Аңар айтя башлаганнар: эй Ходай, мин тöгölме? диб. 23

Ул аларга жауаб биреб äйткян: Минем белян бергя кулын тозлокка тыгыучы, шул Мине тотоб бирер. 24 Алайда Ädям Улы Ўз турында жазылганча бара, тик Ädям Улын тотоб биреўче кешегя жаман булыр, ул кешегя тыумаганы жакшырак булыр ыйы, дигян. 25 Шунда Аны тотоб биреўче Іуда да äйткян: эй Öйрятеўче, мин тöгöл ме? дигян. Іисусъ анар: син äйттең, дигян. 26 Ашаган чакта, Іисусъ икмяк алыб, аны бахилляб сындырган да öйрянеўчеляреня биреб äйткян: алыгыз, ашагыз, Бу Минем Тянем, дигян. 27 Аннары сауытны алыб, тау итеб, аларга биреб äйткян: мыннан барыгызда эчегез, 28 Бу Минем кюб кешеляр öчöн, жазыклар кичерер öчöн агызган жаңа законъ Каным. 29 Сезгя äйтямен: мыннан былай бу жöзöм жимешенен сыуын Атамнын падшалыгында сезнен белян бергя жаңа эчемнек эчясе конгя чаклы эчмямен, дигян. 30 Аннары иман жырлагач, Елеонъ тауына киткянняр. 31 Шунда Іисусъ аларга äйткян: бу тöндя сез барыгызда Минем турда шиклянерсез; жазылган шул: котöўчесен уатыб бетерем, котöўдяге сарыклары таралыб бетярляр, [1] диб. 32 Терелеб торгач, сезне Галилеяда карышы алырым, дигян. 33 Петръ Анар жауаб биреб äйткян: Синең турда барысыда шиклянсяляр дя, мин ич кайчанда шиклянмям, дигян. 34 Іисусъ анар äйткян: чыннаб äйтямен синa: шушы тöндя ätяч кычкыргынчы син Мине öч табкыр таңарсын, дигян. 35 Петръ Анар äйткян: ägяр миңа Синең белян бергя ўлярга туры кился дя, мин Сине таңмам, дигян. Бар öйрянеўчеляр дя шулай диб äйткянняр. 36 Шуннан суң Іисусъ алар белян Геөсиманія дигян урынга килгяч, анда öйрянеўчеляреня äйткян: Мин тегендя барыб теляк итеб килгенче, сез мында утырыб торогоз, дигян. 37 Аннары Петрны, Зеведейнен ике улын Ўзе белян алыб киткян дя, эче пошоб, кайгыра башлаган. 38 Шунда Іисусъ аларга äйткян: Минем жаным ўлярлек булыб кöйя, мында Минем белян уяу тороб торогоз, дигян. 39 Аннары алардан бер-аз читкя китеб, жöз тюбян жыгылыб, инялеб äйткян: эй Атам, мöңким булса, бу сауыт Миннян ўтсен эйе, алайда Мин телягянчя тöгöл, ämмя Син телягянчя (булсын), дигян. 40 Аннары öйрянеўчеляре жанына барыб, аларнын жоклаганын кюреб, Петрга äйткян: шу-

[1] Зах 13:7.

лай итеб, сез Минем белян бер гня сагат тя уяу тора алмадыгыз меней? 41 Алданмас өчөн, уяу торогоз, теляк итегез, тын уяу, әммя тян халсез, дигян. 42 Тагы икенче табкыр читкяряк китеб, былай диб инялгян: эй Атам, әгяр бу сауыт Миннян ӳтя алмаса, Мин аннан эчмей кала алмасам, айса Синең иркең булсын, дигян. 43 Кабат килеб, Ул тагы аларнын жоклаб жатканнарын кюргян, аларнын кюзлярен жоко баскан икян шул. 44 Тагынук аларны калдырыб, читкя китеб, өчөнчө табкыр шул сюзлярне әйтеб теляк иткян. 45 Аннары өйрянеӳчеляре жанына килеб, аларга әйткян: сез әле гел жоклаб жатасыз икян; мына инде сагат жакыннашты, Әдям Улы жазыклылар кулына тотоб биреля. 46 Торогоз, әйдягез, мына Мине тотоб биреӳче жакыннашты, дигян. 47 Ул мыны әйткян чагындук, ун икенен берсе Іуда килеб житкян; анын белян бергя архіерейлярдян, калык башлыкларыннан жибярелгян кюб кеше кылычлар, казыклар алыб (килгянняр). 48 Аны тотоб биреӳче аларга былай әйтеб билге куйган: мин Кемне ӳбсям, шул Ӳзе, Аны тотоб алыгыз, дигян. 49 Шул сяттюк ул Іисуска жакыннашыб, эй Өйрятеӳче, сөйөн! диб әйтеб, Аны ӳбкян. 50 Іисусъ анар әйткян: эй дус! син мында нейгя килдең? дигян. Шул чакта Іисуска жакын килеб, Аны кул белян тотоб алганнар. 51 Шунда Іисусъ белян бергя булганнарнын берсе кулын сузыб, кылычын алган да, архіерей колонын колагын чабыб өзгян. 52 Шунда Іисусъ анар әйткян: кылычыңны кире урнына тык, кылыч алыучылар барысыда кылычтан харяб булырлар шул. 53 Әлля син, Мин казерюк Атама ӳтенсям, Ул Миңа ун ике легіоннан да артык пяриштяляр жибярмяс диб уйлыйсың мы? 54 Шушылай буласы диб жазылган сюзляр ничек жиреня килер эйе суң? дигян. 55 Шул сяттюк Іисусъ калыкка әйткян: талаучыга чыккандый, кылычлар, казыклар алыб, сез Мине тотоб алырга чыккан, чиркяӳдя өйряткян чагымда, Мин көндя сезнен белян утырдым ич, әммя сез Мине тотоб алмадыгыз, дигян. 56 Бу барда пагамбярляр жазган жиреня килер өчөн булды, дигян. Шул чакта өйрянеӳчеляре барысыда Аны калдырыб качканнар.

Зач. 109. 57 Іисусны алыб китеӳчеляр Аны Каіафа атлы архіерейгя алыб барганнар; анда книгячеляр, оло кешеляр жыйылыб торганнар. 58 Шунда Петръ жыраклын Анын артыннан ар-

хіерей жортона житкенче барган; бетеўне кюрер өчөн, ул ишек алдына кереб, кызмятчеляр белян бергя утырган. 59 Архіерейляр, оло кешеляр, хокөм итеўчеляр барысыда Іисусны ўтертер өчөн, Анар карышы жалган айыб эзлягянняр; 60 Тик табалмаганнар: кюб жалган таныкчылар килгянняр, алайда (айыб) табмаганнар. Калдыгында ике жалган таныкчы килеб, 61 Äйткянняр: Ул äйтте: Алла чиркяўен жимереб, өч көндя аны торгозоб житкезерем диде, дигянняр. 62 Архіерей тороб Анар äйткян: быларнын Синa карышы таныклауларына Син ник бер жауаб та бирмейсен? дигян. 63 Іисусъ дяшмягян. Аннары архіерей Анар äйткян: тере Алланы алыб сороймын Синнян: äйт безгя, Алла Улы Христосъ Син ме? дигян. 64 Іисусъ анар äйткян: (дöрöс) äйттең; тагынук сезгя äйтямен: мыннан ары сез Кодрятленен уң жагында утырыб, кюк болотлары östöндя килеўче Ädям Улын кюрерсез, дигян. 65 Шул чакта архіерей ўз кеймнярен жыртыб äйткян: Ул Алланы курлый, тагы безгя нейгя таныкчылар? мына сез казер Анын Алланы курлаганын эшеттегез. 66 Сезгя ничек тея? дигян. Алар жауаб биреб äйткянняр: Аны ўтерергя тейеш, дигянняр. 67 Шул чагында Іисуснын жöзöня тöкöргянняр, башына сукканнар, кайсылары жанакларына сугыб, 68 Äйткянняр: эй Христосъ, Синa кем сукты? белеб äйт безгя, дигянняр. 69 Петръ тышта, ишек алдында утырган; анын жанына бер катын кызмятче килеб äйткян: син дя Галилея Іисусы белян эйең, дигян. 70 Ämмя Петръ барысынында алдында танғыб äйткян: син ней äйткянне белмеймен, дигян. 71 Ул кабкадан чыкканда, аны икенчесе кюреб, шундагыларга äйткян: бу да Назорей Іисусъ белян эйе, дигян. 72 Ул тагы бу кешене белмеймен диб карганыб танган. 73 Бер-ауыктан суң шунда тороучылар Петрга жакын килеб äйткянняр: чыннаб син алар арасыннан, сöйляшеўең дя кюрсятеб тора, дигянняр. 74 Шуннан суң ул: бу кешене белмеймен диб каргана башлаган, танa башлаган. Шул сяттюк ätяч кычкырган. 75 Петръ Іисуснын анар: ätяч кычкыргынчы син Мине öч табкыр танарсын диб äйткян сюзен исеня төшöргян. Аннары чыгыб китеб, бик интегеб жылаган.

27-нче бюлем

Зач. 110. 1 Иртя белян архіерейляр, калык башлыклары барысыда жыйылышыб киңяш итеб, Іисусны ӳтерергя куйганнар. 2 Аны бяйляб алыб киткянняр дя Понтій Пилатъ тюрягя итеб биргянняр.

Зач. 111. 3 Шул чакта Іисусны тотоб биргян Іуда, Аны айыблаганны кюреб, ӳкенеб, утыз кӧмӧш тянгкяне архіерейлярга, башлыкларга кайтарыб, 4 Ӓйткян: айыбсыз канны сатыб биреб, жазыклы булдым, дигян. Алар анар: безнен анда ней эшебез бар? ӳзең кара, дигянняр. 5 Ул аннары тянгкялярне чиркяӳгя ташлаб чыккан да, китеб асылынган. 6 Архіерейляр тянгкялярне алыб ӓйткянняр: быларны, кан бяясе булганга кюря, чиркяӳ казнасына салырга тейеш тӧгӧл, дигянняр. 7 Киңяш итеб, чит кешелярне кюмяр ӧчӧн, ул акчага чюлмякчедян жир сатыб алганнар. 8 Шунныктан ул жирне бӧгӧнгя чаклы кан жире диб ӓйтеля. 9 Шул чакта Іеремія пагамбяр арткылы ӓйтелеӳ жиреня килгян, ул ӓйткян: Израиль уллары бяялягяннен бяясен, утыз кӧмӧш тянгкяне алыб, 10 Ул акчаны чюлмякче жире ӧчӧн тюляделяр, Ходай миңа шулай ӓйтте, дигян. 11 Іисусъ тюря алдында торганда, тюря Аннан сораган: Син Іудея Падшасы мы? дигян. Іисусъ анар: (дӧрӧс) ӓйтясен, дигян. 12 Архіерейляр, калык башлыклары Аны айыблаб торганда, Ул бер дя дяшмягян. 13 Аннары Пилатъ Анар ӓйткян: Синга карышы ней чаклы таныклык иткяннярен эшетмейсен меней? дигян. 14 Іисусъ анын бер сюзеня дя жауаб бирмягян, тюрянен шунар бик исе киткян. 15 Тюрянен (Пасха) бяйряменя быгаудагыларнын берсен, калык телягянен жибяря торган жоласы бар икян. 16 Шул чакта аларнын быгауда тороучы Варавва атлы билгеле кешеляре булган. 17 Алар жыйылыб житкяч, Пилатъ аларга ӓйткян: икесенен кайсын жибяр диб телейсез: Варавваны мы, ӓлля Христосъ дигян Іисусны мы? дигян. 18 Ул аларнын Аны кӧнчӧлӧк белян тотоб биргяннярен белгян. 19 Шул арада, Пилатъ хокӧм урнында утырган чакта, катыны анар былай диб ӓйтергя жибяргян: Ул гаделгя бер нястя дя кылма, мин Анын ӧчӧн бӧгӧн тӧшӧмдя бик кюб азабландым шул, дигян. 20 Ӓммя архіерейляр, оло кешеляр калыкны: Варавваны жибярт, ӓммя Іисусны ӳтерт диб ӓйтергя котортканнар. 21 Аннары тюря алардан

тагы сораган: бу икенен кайсын жибяр диб телейсез? дигян. Алар: Варавваны, дигянняр. 22 Пилатъ аларга айткян: Христосъ дигян Іисуска суҥ ней кылыйым? дигян. Алар аҥар барысыда: Аны кадаклат, дигянняр. 23 Тюря айткян: Ул ничек усаллык кылды суҥ? дигян, аммя алар: Аны кадаклат диб бигряк тя шяб кычкырганнар. 24 Пилатъ ничек ится дя булыша алмаганын кюреб, аммя калыкнын бигряк тя болганганын кюреб, сыу алган да, калык алдында кулын жыуыб айткян: мин бу гаделнен канына айыблы тӧгӧл, ӱзегез карагыз, дигян. 25 Калык барда жауаб биреб айткян: Анын каны безгя, безнен балаларыбызга да (тӧшсӧн), дигянняр. 26 Шуннан суҥ алар (телягянчя) Варавваны жибяргян, аммя Іисусны кыйнатыб, кадакларга биргян.

Зач. 112. 27 Шул чакта тюрянен салдатлары Іисусны хокӧм урнына алыб килеб, Анын жанына бӧтӧн полкны жыйганнар. 28 Шунда Іисуснын кейемен салгызыб, Аҥар кызыл кейем кейгезгянняр; 29 Башына чянечкеле агач чыбыгыннан ӱрмя ӱреб кейгезгянняр; уҥ кулына таяк тотторганнар; аннары Анын алдында тезлянеб тороб, Аннан мыскыл итеб, айткянняр: эй Іудея Падшасы, сӧйӧн! аиб. 30 Аҥар тӧкӧргянняр, таягын алыб, башына сукканнар. 31 Аны мыскыллаб туктагач, östöндяге кызыл кейемне салгызыб, Ӱз кейемен кейгезгянняр, аннары кадакларга алыб киткянняр. 32 Чыгыб барган чакта, Киринеянын Симонъ атлы кешене очратыб, аҥар Іисуснын качын кютяртеб баргызганнар.

Зач. 113. 33 Голгоөа исемне Маҥгай урны дигян жиргя житкяч, 34 Іисуска эчяргя ӱт катыштырган серкя биргянняр, Ул аны татыб караган да, эчясе итмягян. 35 Іисусны кадаклаучылар Анын кейемнярен жирябя салыб ӧляшкянняр. 36 Аннары шунда Аны саклаб утырганнар. 37 Анын башы östöня айыбын кюрсятеб: Бу Іудея Падшасы Іисусъ диб жазыб куйганнар. 38 Шунда Анын белян бергя ике талаучыны кадаклаганнар: берсен уҥ жагына, икенчесен сул жагына. 39 Жаныннан узыучылар башларын селкеб, Аны курлаб, 40 Айткянняр: эй чиркяӱне жимереб, ӧч кӧндя торгозоб житкезеӱче! Ӱзеҥне Ӱзеҥ коткар; ягяр Син Алла Улы булсаҥ, качыҥнан тӧш, дигянняр. 41 Архіерейляр, книгячеляр, калык башлыклары, фарисейляр дя шулай мыскыллаб айткянняр: 42 Бютяннярне коткарган, аммя

Ўзен Ўзе коткара алмый. Ägяр Ул Израиль Падшасы булса, айса инде качыннан төшсӧн, шунда Аңар ышанырбыз; 43 Ул Аллага ышанган ыйы, ägяр Аңар жараулы булган булса, инде Аны Алла коткарсын; Ул Ўзе: Мин Алла Улы диб äйткян эйе, дигянняр. 44 Анын белян кадакланган талаучылар да шулай Аны курлаганнар. 45 Алтынчы сагаттян тугызынчы сагаткя чаклы бӧтӧн жир öстӧндя карангы булыб торган. 46 Тугызынчы сагат тирясендя Іисусъ каты тауыш белян кычкырыб äйткян: Или, Или! лама савахѳани? дигян. бу: эй Аллам, эй Аллам, Син Мине ник ташладың? дигян сюз була. 47 Шунда тороучыларнын кайсылары мыны эшетеб: Ул Ілія ны чакыра, дигянняр. 48 Шул сяттюк алар арасыннан берсе жӧгӧрӧб барыб, болот алыб, аңар серкя сеңдереб, аны таякка элеб, Іисуска эчяргя биргян. 49 Ўңгяляре äйткянняр: тукта äле, караб торойок, Ілія Аны коткарырга килер микян? дигянняр. 50 Іисусъ тагы каты тауыш белян кычкырыб, тынын чыгарган. 51 Шул чакта чиркяў шаршауы жугары кырыйыннан тюбян кырыйына чаклы икегя айырылган; жир титрягян, ташлар жарылганнар. 52 Каберляр ачылганнар, кюб ӱлгян изгелярнен тянняре терелгянняр; 53 Іисусъ терелеб торгач, алар каберляреннян чыгыб, арыу калага барыб, кюб кешелярга кюренгянняр. 54 Сотникъ та, анын белян бергя Іисусны саклаб тороучылар да, жир титрягянне, бютян эшляр булганны да кюреб, бик куркышыб äйткянняр: чыннаб Бу Алла Улы икян, дигянняр. 55 Анда тагы кюб катыннар да жыракты н караб торганнар; алар Іисуска Галилеяда эяреб, Аңар кызмят итеб жӧргянняр. 56 Алар арасында Марія Магдалина, Іаковъ белян Іосіянын анасы Марія, тагы Зеведей улларынын анасы да булган. 57 Кич булгач, Аримаѳеядан Іосифъ атлы бер бай кеше килгян, ул да Іисуснын öйрянеўчесе икян. 58 Ул Пилатка барыб, Іисуснын тянен сораган. Пилатъ тянне бирергя кушкан. 59 Іосифъ тянне алыб, аны таза киндер белян чырмаган; 60 Аннары аны ўзенен таш тауга тишеб жасаган жаңа кабереня куйган; кабер ауызына зур таш каблаб киткян. 61 Шунда Марія Магдалина, тагы бютян Марія да булган; алар кабер карышысында утырганнар.

Зач. 114. 62 Пятницанын иртягесен архіерейляр белян фарисейляр жыйылышыб, Пилат-

ка килеб, 63 Äйткянняр: эй тюря! теге жалганчынын тере чагында: öч көннян суҥ терелеб тором дигяне исебезгя төштö. 64 Шуҥар кюря Син Анын каберен öч көнгя чаклы саклатчы, öйрянеўчеляре тönня килеб, Аны урламасыннар, калыкка: Ул ўлгяненнян терелеб тордо димясенняр. Аннары сунгы алдауы элекегесеннян дя жаманырак булыр, дигянняр. 65 Пилатъ аларга äйткян: сезнен сакчыларыгыз бар, барыгыз, ўзегез белгянчя саклатыгыз, дигян. 66 Алар барыб, кабер жанына сакчылар куйганнар, ташын пичятлягянняр.

28-нче бюлем

Зач. 115. 1 Суббота ўткяч, атнанын элекеге көнöндя, таҥаткан чакта Марія Магдалина, тагы бютян Марія белян каберне кararга барган. 2 Кинят жир бик каты титрягян, Ходай пяриштясе кюктян төшöб, кабер жанына килеб, ауызындагы ташны аударыб, анын öстöня утырыб торган. 3 Анын төсö жяшен кюк, кейеме кар кюк ак икян. 4 Сакчылар аннан куркыб, калтрашыб ўле мясялле булганнар. 5 Пяриштя катыннарга боролоб äйткян: сез курыкмагыз, мин сезнен кадакланган Иисусны эзлей килгянегезне белямен. 6 Ул мында жук, Ул Ўзе äйткянчя, терелеб тордо. Килегез, Ходай жаткан урынны кюрегез. 7 Аннары тизеряк барыб, Анын öйрянеўчеляреня äйтегез: Ул ўлгян жиреннян терелеб торган, Ул сезне Галилеяда карышы алыр, Аны анда кюрерсез, дигез. Мына мин сезгя äйтеб бирдем, дигян. 8 Алар кабердян жятляб чыкканнар да, куркыб, бик сöйöнöшöб, Анын öйрянеўчеляреня хабяр итяргя жöгöргянняр; алар Анын öйрянеўчеляреня хабяр итяргя барган чакта, 9 Мына Иисусъ аларга очраб: сöйöнögöз! дигян. Алар жакын килеб, аягын тотоб, Аҥар башырганнар. 10 Шунда Иисусъ аларга äйткян: курыкмагыз! барыгыз, агай-энеляремя äйтегез, алар Галилеяга барсыннар, шунда Мине кюрерляр, дигян. 11 Катыннар барган чакта, сакчыларнын кайсылары калага кайтыб, ней булганны барысында архіерейлярга белдергянняр. 12 Архіерейляр башлыклар белян жыйылышыб киҥяш иткянняр дя, салдатларга байтак акча биреб, 13 Äйткянняр; сез тönня без жоклаганда, öйрянеўчеляре килеб, Аны урлаганнар диб

йтегез. 14 Ägяр ул баш тюрягя эшетелся, без аны кöйлярбез, сезне кайгыга калдырмабыз, дигянняр. 15 Сакчылар акча алыб, алар öйряткянчя кылганнар; шул сюз Іудейляр арасында бу кöнгя чаклы жяйелеб тора.

Зач. 116. 16 Ун бер öйрянеўче Іисусъ барырга кушкан тöшкя Галилеяга, тау öстöня киткянняр. 17 Шунда алар Аны кюреб, Анăар башырганнар, ăммя кайсылары шиклянеб торганнар. 18 Іисусъ жакын килеб, аларга äйткян: кюктя дя, жирдя дя Миңа äр-тöрлö кыуат бирелде. 19 Инде барыгыз, бар калыкларны да öйрятегез, аларны Ата, Ул, Святый Тын исеменя чумылдырыгыз. 20 Мин сезгя кушканны барын да кыларга аларны да öйрятегез. Мына Мин дöнья беткенче бар кöннярдя дя сезнен белян дигян. Аминь.

МАРКЪ ЖАЗГАН АРЫУ ЕВАНГЕЛІЕ

1-нче бюлем

Зач. 1. 1 Алла Улы Іисусъ Христоснын Евангеліесенен башы. 2 Пагамбярляр жазганча: мына Мин Синеҥ алдыҥнан Ўз пяриштямне жибярем, ул Синеҥ алдыҥнан жулыҥны äзерляб куяр; [1] 3 Ходайга жул äзерлягез, Аҥар туры сукмаклар жасагыз диб буш кырда кычкырыучынын ауазы [2] дигянчя, 4 Буш кырда чумылдырыучы Іоаннъ булган, ул жазыклар кичелер öчöн тяўбя итеў чумылдырыуын сöйлягян. 5 Шунда аҥар бötöн Іудея жагындагылар, Іерусалимдягеляр чыгыб, барысыда жазыкларын äйтеб, аннан Іорданъ сыуында чумылдырылганнар. 6 Іоаннын öстöндяге кейеме дöя жононнан, билендяге эзяре тиредян булган, ашамныгы сикерткя белян кыр балы булган. 7 Ул былай äйтеб сöйлягян: минем артымнан миннян Кыуатлы киля, мин Анын башмагынын кайышын эйелеб чишяргя дя тормоймын. 8 Мин сезне сыу белян чумылдырдым, äммя Ул сезне Святый Тын белян чумылдырыр, дигян.

Зач. 2. 9 Шул көннярдя Іисусъ Галилея Назаретыннан килеб, Іоаннан Іорданда чумылдырылган. 10 Іисусъ сыудан чыккан сяттюк, (Іоаннъ) кюк ачылыб, Іисусъ öстöня кюгярчен ряўешле булыб ингян Тынны кюргян. 11 Шунда кюктян ауаз килгян: Син Минем сöйöклö Улым, Синдя Минем ризалыгым, диб. 12 Шуннан суҥ тизюк Тын Аны буш кырга алыб барган. 13 Буш кырда Ул кырык көн торган, шайтаннан сыналган, кейекляр белян булган; анда Аҥар пярштяляр кызмят иткянняр. 14 Іоаннъ тотоб бирелгяч, Іисусъ Алла падшалыгынын Евангеліесен сöйляб, Галилеяга килгян. 15 Ул äйткян: инде багыт житте, Алла падшалыгы жакыннашты, тяўбя итегез, Евангеліегя ышаныгыз, дигян.

Зач. 3. 16 Галилея дингезе жаныннан ўтеб барганда, Іису-

---

[1] Мал 3:1.
[2] Ис 40:3.

съ дингезгя ау салыб торган Симонны, анын энесе Андрейне кюргян; алар балыкчылар икян. 17 Іисусъ аларга айткян: Минем артымнан барыгыз, Мин сезне кешелярне тотоучы итярмен, дигян. 18 Алар шундук ауларын калдырыб, Анын артыннан киткянняр. 19 Аннан бер-аз киткяч, Зеведей Іаковын, анын энесе Іоанны кюргян, алар да кимядя ауларын тёзятяляр икян. 20 Шул сяттюк Ул аларны чакырган; алар аталары Зеведейне жалчылары белян бергя кимядя калдырыб, Анын артыннан киткянняр. 21 Капернаумга килгянняр; килгяч суббота көннө Іисусъ синагогага кереб, ёйрятеб утырган. 22 Анын ёйрятеуеня исляре киткян, Ул аларны кодряте барын тойдороб ёйряткян шул, ämмя книгячеляр кюк тёгёл.

Зач. 4. 23 Аларнын синагогаларында бер женнянгян кеше бар икян, ул кычкырыб, 24 Айткян: эй Іисусъ Назарянинъ! безгя теймя, бездя Синең ней эшең бар? Син безне бетерергя килгян, Син Кем икянне белямен, Син Алланын Изгесе, дигян. 25 Іисусъ анар кисятеб айткян: дяшмя, анын эченнян чык, дигян. 26 Шул сяттюк жен аны калтратыб, бик каты тауыш белян кычкырыб, анын эченнян чыккан. 27 Шуннан суң барысы да куркышыб, бер берсеннян сорашканнар: бу ней хал? бу нейдей жаңа ёйрятеу? Ул шакшы тыннарга да кодрят белян кисятя, алар Аны тыңныйлар, дигянняр. 28 Аннары тизюк Анын хабяре бётён Галилея тиряляреня жяйелгян.

Зач. 5. 29 Синагогадан чыккач, (Іисусъ) тизюк Іаковъ белян Іоанны алыб, Симонъ белян Андрей ёйёня килгян. 30 Симонъ катынынын анасы тир кастасы белян жата икян; аны шундук Іисуска айткянняр. 31 Ул анын жанына барыб, кулыннан тотоб торгозган, шул сяттюк тир кастасы беткян; аннары ул аларга кызмят итя башлаган. 32 Кич булгач, кояш байыган чакта, Анын жанына бар чирлелярне, женнелярне китергянняр. 33 Бётён кала ишек тёбёня жыйылган. 34 Шунда Ул тёрлё чир белян азабланган кюб кешене сауыктырган, кюб женнярне (кешелярдян) кыуалаб чыгарган, женнергя Ул Христосъ икянне белгяннярен айтергя бойормаган.

Зач. 6. 35 Иртягесен бик иртя тороб чыккан да буш жиргя китеб, анда теляк иткян. 36 Симонъ да, анын белян булганнар да Іисусъ артыннан жёгёргянняр. 37 Аны табкач, Анар: Сине барда

эзлейляр, дигянняр. 38 Ул аларга äйткян: äйдягез жакындагы ауылларга, калаларга барыйык, Мин анда да сöйляргя тейеш, Мин шунын öчöн килдем шул, дигян. 39 Ул бötöн Галилеядя синагогаларда öйрятеб жöргян, женнярне дя кыуалаб чыгарган. 40 Шунда Анăр тяне кутырлаган бер кеше килеб, инялеб, Анын алдында тезлянеб тороб äйткян: телясяң, Син мине тазарта алыр ыйың дигян. 41 Іисусъ аны кызганыб, кулын сузыб, анăр тейенеб äйткян: телеймен, тазарын, дигян. 42 Іисусъ шул сюзне äйткяч тя, анын кутыры койолган, ул аннары тазарыб калган. 43 Іисусъ аны жибяргян чакта, анăр кисятеб, 44 Äйткян: анă бул, беряўгя дя бер сюз дя äйтмя, тик барыб, ўзенăне священникка кюрсятеб, тазарганыңа, Моисей кушканча, аларга таныклыкка бюляк китер, дигян. 45 Ämмя ул чыгыу белян, ней булганны сöйляб жяйелдеря башлаган, шунныктан аннары Іисусъ калага кюренеб керя алмаган, тик каладан тышта, буш жирлярдя гня торган. Шунда Анăр тöрлö жирдян килгянняр.

2-нче бюлем

Зач. 7. 1 Бер-ауык кöннярдян суң, Іисусъ тагы Капернаумга килгян; анда Анын бер öйдя икянен эшеткянняр. 2 Шул сяттюк кюб кеше килеб тулган, ишек катында да урын калмаган; Ул аларга сюз сöйлягян. 3 Шунда Анăр дюрт кеше бер сансызны кютяреб китергянняр. 4 Кеше кюблектян Іисуска жакынашырлык булмагач, алар Ул утырган öйнöн тюбясен ачыб, сансызны жаткан урны белян (Анын алдына) тöшöргянняр. 5 Іисусъ аларнын ышаныуын кюреб, сансызга äйткян: улым, синă жазыкларың кичереля, дигян. 6 Анда книгячеляр-нен берауыгы утыра икян, алар ўз кюнăлляренда уйлаганнар: 7 Ул ник былай Алланы курлый? Бер Алладан бютян кем жазыкларны кичеря алыр? дигянняр. 8 Іисусъ шундук Ўз тыны белян, алар ўз эчляренда шулай уйлаганны белеб, аларга äйткян: сез кюнăллярегездя ник алай уйлыйсыз? 9 Ней асатрак: сансызга жазыкларың кичереля диб äйтеў ме? älля тор да, урныңны алыб кит диб äйтеў ме? 10 Ämмя Ädям Улынын жир öстöндя жазыклар кичерергя кыуаты барын сез белсен диб, (äйтямен дигян дя сансызга äйткян): 11 Синă äйтямен: тор да, урныңны алыб,

öйöңя кайт, дигян. 12 Ул шундук торган да, урнын алыб, барысы алдында чыгыб киткян; барысыда исляре китеб, Алланы мактаб äйткянняр: мындый эшне без бер чакта да кюрмядек, дигянняр.

Зач. 8. 13 Іисусъ тагынук дингез жанына чыккан, бар калык Анын катына барган, Ул аларны öйряткян. 14 Узыб барган чакта, Ул сатлык мал акчасын жыя торган töштя утырган Алфей улы Левійне кюреб, анар äйткян: Минем артымнан бар, дигян. Ул тороб, Анар эяреб киткян. 15 Іисусъ анын öйöндя утырган чакта, Анын белян бергя öйрянеўчеляре, тагы кюб мытарлар, жазыклылар утырганнар; алар кюб икян, барысыда Анын белян жöргянняр. 16 Книгячеляр, фарисейляр, Ул мытарлар белян, жазыклылар белян ашаганны кюреб, Анын öйрянеўчеляреня äйткянняр: ник Ул мытарлар белян, жазыклылар белян бергя ашый, эчя? дигянняр. 17 Іисусъ мыны эшетеб, аларга äйткян: сауларга лекарь киряк töгöл, ämmя чирлелярга (киряк). Мин жазыклыларны тяўбягя öндярга килдем, ämmя гаделлярне töгöл, дигян.

Зач. 9. 18 Іоаннь öйрянеўчеляре белян фарисейляр öйрянеўчеляре ураза тотканнар. Шунда Іисуска килеб äйткянняр: Іоаннъ öйрянеўчеляре, фарисейляр öйрянеўчеляре ник ураза тоталар, ämmя Синең öйрянеўчелярең ней öчöн ураза тотмойлар? дигянняр. 19 Іисусъ аларга äйткян: кодаларга кеяў алар белян чагында ураза тотарга мöңким ме? Кеяў алар белян чагында ураза тотарга мöңким töгöл. 20 Алардан кеяў алыныр көнняр килеб житяр, житкяч, шул көннярдя ураза тотарлар. 21 Беряў дя тузган кеймгя агартмаган киндердян жамау салмый, жугыйса жаңа жамау тузган кеймне айырыр да, жыртыгы тагы да чагырак булыр. 22 Жаңа аракыны да беряў дя иске турсыкка салмый, жугыйса жаңа аракы турсыкны айырыр да, аракы да агар, турсыгы да äрям булыр; ämmя жаңа аракыны жаңа турсыкка тутырырга тейеш, дигян.

Зач. 10. 23 Бер суббота көннö Анар ашлык басыуыннан ўтеб барырга туры килгян; барган чакта Анын öйрянеўчеляре ашлык башларын öзöб-öзöб алганнар. 24 Фарисейляр Анар äйткянняр: кара, алар ник суббота көннö тейеш töгöлне кылалар? дигянняр. 25 Ул аларга äйткян: Давидъ ўзе дя, анын

белян булганнар да, ачыккач, жödягяч, ул ней кылганны бер чакта да укымадыгыз мы ялля? 26 Ничек ул Авіаөаръ архіерей багытында, Алла öйöня кереб, священниклярдян бютянгя беряўгя дя ашарга тейеш тöгöл китереб куйылган икмяклярне алыб, ўзе дя ашаган, ўзе белян булганнарга да биргян, дигян. 27 Аларга тагы айткян: суббота кеше öчöн, ямма кеше суббота öчöн тöгöл. 28 Шунныктан Ядям Улы субботага да башлык, дигян.

3-нче бюлем

1 Іисусъ тагы синагогага килгян; анда кулы короган бер кеше булган. 2 Іисусны айыблар öчöн, Ул бу кешене суббота көннö тöзятмяс ме диб, Аны караб торганнар. 3 Ул кулы короган кешегя айткян: уртага чыгыб тор, дигян. 4 Аннары аларга айткян: суббота көннö жакшылык кыларга тейеш ме, ялля усаллык кыларга мы? жанны сакларга тейеш ме, ялля ярям итяргя ме? дигян. Ямма алар дяшмягянняр. 5 Ул аларнын кюнелляре катыланганга кайгырыб, аларга ачыу белян караб, теге кешегя айткян: кулыңны суз, дигян. Ул сузган, сузгачук анын кулы икенчесе кюк сау булган.

Зач. 11. 6 Фарисейляр чыгыб, тизюк иродныкылар белян бергя, Іисусны ничек итеб бетерейек икян диб, Анар карышы киняш корганнар. 7 Ямма Іисусъ Ўз öйрянеўчеляре белян дингез жанына киткян. 8 Анын артыннан Галилеядан, Іудеядян, Іерусалимнян, Идумеядян, тагы Іорданнын ары жагыннан да кюб калык барган; Тиръ белян Сидонъ тирялярендя тороучы бик кюб кеше, Ул ней кылганны эшетеб, Анын жанына килгянняр. 9 Калык кюблектян, Ул Ўзен тыгызламасыннар диб, öйрянеўчеляреня Ўзе öчöн кимя äзерлярга кушкан. 10 Кюб (кешене) тöзяткян, шунар кюря жаралылары Анар тейенер öчöн, Анын жанына тыгылышыб килгянняр. 11 Женняр [1] дя Аны кюргяч, Анын алдында жыгылыб тороб, Син Алла Улы диб кычкырганнар. 12 Ямма Ул Ўзен билгеле итмясенняр диб, аларга бик каты кисяткян.

Зач. 12. 13 Аннары тау östöня менеб, Ўзе телягяннярне чакырыб алган, алар Анар килгянняр. 14 Аларнын ун икесен Ўзе белян бергя жöрöргя, сöйлярга жибярергя сайлаб куйган. 15 Аларга чирлярне тöзятергя, жен-

[1] Женнеляр.

нярне (кешедян) чыгарырга кыуат биргян. 16 Симонны Петръ диб атаб, 17 Зеведей улы Іаковны, анын энесе Іоанны Воанергесъ диб атаб куйган, Воанергесъ дигяне кюкряў уллары дигян сюз. 18 Андрейне, Филиппны, Варѳоломейне, Матѳейне, Ѳоманы, Алфей улы Іаковны, Ѳаддейне, Кананитъ (дигян) Симонны, 19 Искаріотъ Іудасын куйган, шушысы Іисусны тотоб биргян.

Зач. 13. 20 Аннары бер ойгя кергянняр: анда тагы калык кюб жыйылганныктан, аларга икмяк ашар хал дя булмаган. 21 Іисуснын жакыннары, Ул акылдан чыккан диб сойляшкянне эшетеб, Аны алыб китейек диб килгянняр. 22 Іерусалимнян килгян книгячеляр айткянняр: Анын эчендя веельзевулъ бар. Ул женнярне женняр башлыгынын кочѳ белян чыгара, дигянняр. 23 Ул аларны дяшеб алган да, аларга мясялляр китереб айткян: шайтан шайтанны ничек кыуалаб чыгарсын? 24 Ягяр падшалык ўзе ўз алдында айырылышса, ул падшалык тора алмас. 25 Жорт та ўзе ўз алдына айырылса, ул жорт тора алмас. 26 Ягяр шайтан да ўзеня ўзе карышылык итеб, айырылса, ул тора алмас, анын бетяр багыты житкян була. 27 Беряў дя кочлонон ойоня кереб, элеке кочлонон ўзен бяйлямяся, анын нястялярен талаб китя алмас, шул чакта гна анын ойон талаб китя алыр, дигян.

Зач. 14. 28 Чыннаб айтямен сезгя: ядям улларына бар жазыклары да кичерелер, ничек итеб курласалар да, курлаганнары да (кичерелер). 29 Тик кем Святый Тынны курласа, анар кичерелеў булмас гумергя, аммя ул мянгегя айыблы булыр, дигян. 30 (Мыны Ул) Анда жен бар дигяннярення кюря айткян. 31 Шунда анасы белян агалары килгянняр; алар ойнон тыш жагында тороб, Аны чакыртканнар. 32 Анын айлянясендя калык утырган. Анар айткянняр: мына анаң да, агаларың да, туталарың да тышта Сине чакыралар дигянняр. 33 Ул аларга айткян: кем Минем Анам? кем Минем агаларым? дигян. 34 Аннары айлянясендя утырыучыларга караныб айткян: мына Минем анам, мына Минем агаларым да. 35 Кем дя кем Алла иркен кылыб торса, шул Миня ага-эне, тута-сенел, ана да, дигян.

4-нче бюлем

Зач. 15. 1 Іисусъ тагы дингез жанында öйрятя башлаган. Анын жанына кюб калык жыйылган, шунныктан Ул кимягя кереб, дингез öстöндя утырган, ämмя калык бар да дингез жанында, жир öстöндя торган. 2 Ул аларны мясялляр белян кюб öйряткян; öйрятеб аларга äйткян: 3 Тыңнагыз äле: мына чячеўче чячяргя чыккан. 4 Чячкян чагында кайсы (бöртöгö) жул кырыйына тöшкян; кошлар очоб килгянняр дя аларны чюбляб бетергянняр. 5 Кайсысы ташлык жиргя тöшкян; анда балчык аз гна булган: балчык сай булганныктан алар тизюк тишелеб чыкканнар. 6 Кояш чыккач, алар шиңеб беткянняр; тамырлана алмаганга кюря, короганнар. 7 Кайсысы тигяняклеккя тöшкян; тигяняк ўсеб житкяч, аларны басыб алган, аннары алар жимеш китермягянняр. 8 Кайсысы жакшы жиргя тöшкян: алары тишелеб ўсеб жимеш китергянняр: кайсысы утыз, кайсысы алтмыш, кайсысы жöз (бöртöк) китергян, дигян. 9 Аннары аларга äйткян: эшетергя колагы бар кеше эшетсен, дигян.

Зач. 16. 10 Калык киткяч, Анын жанындагылар, ун ике (öйрянеўчесе) дя бергя Аннан мясял турысында сораганнар. 11 Ул аларга äйткян: сезгя Алла падшалыгынын жяшереклярен белергя бирелгян, ämмя теге тыштагыларга барысы да мясял белян äйтеля. 12 Алар жазыкларын кичерттермяс öчöн, (Аллага) кайтмас öчöн, кюзляре белян карасалар да кюрмейляр, колаклары белян эшетсяляр дя аңнамыйлар, дигян. 13 Аннары аларга äйткян: сез бу мясялне аңнамыйсыз меней? бар мясяллярне ничек аңнарсыз суң? 14 Чячеўче сюз чячя. 15 Жул кырыйына чячелгяне шушындый кешелярне белдеря: алар эченя сюз чячеля, тик эшеткян сятлярендюк шайтан килеб, аларнын кюңеленя чячелгян сюзне алыб китя. 16 Шунын кюк ташлык жиргя чячелгяне дя сюзне эшеткяч тя, аны тизюк сöйöнöч белян кабыл алган кешелярне белдеря; 17 Тик алар жяйелгян тамырлары жукка кюря, ныклыклары да булмаганга, эшеткян сюз öчöн суңыннан кайгы, жя кысаннык туры кился, шул сяттюк шикляня башлыйлар. 18 Тигяняклеккя чячелгяне сюзне былай тыңнаучыларны белдеря: 19 Бу гумернен сагышлары, байлыкка алданыулык, тагы бютян няпесляр дя аларга кереб, сюзне басыб

бетеряляр; аннары ул сюз жимеш китермей. 20 Ämмя жакшы жиргя чячелгяне мындыйларны белдеря: алар сюзне эшетеў белян кабыл алалар, аннары берсе утызлаб, икенчесе алтмышлаб, өчөнчөсө жөзляб жимеш китеря, дигян. 21 Аннары тагы аларга äйткян: эшямне сауыт астына, жя жата торган урын астына утыртыр өчөн китеряляр меней? аны эшямдялгя утыртырга (китеряляр) төгöл ме? 22 Кюренмей каласы бер жяшерен дя жук; жяшереб куйганнын да ич берсенен тышка чыкмый каласы жук. 23 Эшетергя колагы бар кеше эшетсен, дигян.

Зач. 17. 24 Аларга тагы äйткян: эшеткянегезгя аң салыгыз. Ничек ўлчяў белян ўлчясягез, ўзегезгя дя шулай ўлчянер, сез тыңнаучыларга арттырылыр да. 25 Барга бирелер, ämмя жукнын нейе бар, анысы да алыныр шул, дигян. 26 Тагынук äйткян: Алла падшалыгы кеше жиргя ташлаган орлокка ошаулы: 27 Ул (кеше) тöння дя, көндöз дя, жоклой да, тора да, ämмя орлок ничек тишелеб, ничек ўскянне белмей. 28 Жир ўзе жимеш китеря: элеке ул жяшел ужым ўстеря, аннары баш чыгарта, аннары башакны тöш белян тутыра. 29 Ашлык житкяч, ул (кеше) урыр багыт житкянгя кюря, тизюк уракчылар жибяря, дигян. 30 Аннары äйткян: Алла падшалыгын нейгя ошатыйык? жя аны ничек мясял белян äйтеб кюрсятейек? 31 Ул горчица орлогона ошаулы: ул орлокно жиргя чячкяндя, ул жирдяге барча орлоклардан да ыуагырак була; 32 Ämмя чячкячен, тишелеб чыга да, бар ўлямнярдян дя олорак була, зур тармаклар чыгара, анын кюлягясендя ауа кошлары килеб, куначлаб утырырлык була, дигян. 33 Шундый кюб мясялляр белян, алар тыңный алган тиңете, Ул аларга сюз сöйлягян. 34 Аларга мясялсез сöйлямягян, ämмя öйрянеўчеляреня аулакта бар турныда аңнаткан.

Зач. 18. 35 Шул көннö кич Ул аларга äйткян: теге жакка кичейек, дигян. 36 Аннары алар калыкны жибяреб, Аны кимядяге көйö, ўзляре белян бергя алыб киткянняр; Анын белян бютян кимяляр дя булган. 37 Шунда бик шяб дауыл кютярелгян; тулкыннар кимягя кереб, кимягя сыу тула башлаган. 38 Ämмя Ул кормада [1] мендяр салыб жоклаган икян. Аны уятыб, Аңар äйткянняр: эй Öйрятеўче! без бетябез, Син аңар көймöйсең меней? дигянняр. 39 Ул тор-

[1] Кимя башы.

ган да, жилне тыйыб, дингезгя йӑткян: тынычлан, басыл, дигян. Жил туктаб, тыб-тыныч булган. 40 Аннары аларга йӑткян: сез ник алай куркыучан? ничек сезнен ышаныуыгыз жук? дигян. 41 Шунда бик куркышыб, бер-берсеня йӑтешкянняр: Бу кем? жил дя, дингез дя Аны тыҥныйлар, дигянняр.

5-нче бюлем

Зач. 19. 1 Аннары алар дингезнен ары жагындагы Гадара жиреня килгянняр. 2 Ул кимядян чыккач та, Анҕар ӳлек куя торган урыннан чыккан женне кеше очраган. 3 Ул каберляр эчендя тора икян; ич беряӳ дя аны чылбырга да бяйляб тота алмаган. 4 Кюб табкыр аны быгаулаб, чылбырлаб караганнар, ӓммя ул чылбырларын ӧзӧб, быгауларын ыуатыб бетергян шул; шулай итеб аны тыярга беряӳнен дя кӧчӧ житмягян. 5 Ул жалан тӧння дя, кӧндӧз дя таулар арасында, каберлярдя кычкырыб, ташларга бярелеб жӧргян. 6 Ул Іисусны жыраклын кюреб, жӧгӧрӧб килеб, Анҕар жыгылыб башырган. 7 Аннары каты тауыш белян кычкырыб йӑткян: эй жугарыгы Алланын Улы Іисусъ! Синеҥ миндя ней эшеҥ бар? Алланы алыб Синҥа тилмерямен: мине азаблама, дигян. 8 Іисусъ анҕар йӑткян икян шул: эй шакшы тын! син бу кешедян чык диб. 9 Аннары: син ней атлы? диб сораган. Ул жауабка йӑткян: мин легіонъ атлы, без (мында) кюб шул, дигян. 10 Алар Анҕар: безне бу тирядян кыуыб жибярмясяня диб, бик ӳтенгянняр. 11 Шунда тау кырыйында зур табын дунгыз кӧтяляр икян. 12 Шакшы тыннар барысы да Анҕар ӳтенгянняр: безне дунгызлар эченя жибярче, без алар эченя керейек, дигянняр. 13 Шундук Іисусъ аларга бойорган. Шакшы тыннар чыгыб, дунгызлар эченя кергянняр; шул сяттюк кӧтӧӳ текя жардан дингезгя атылыб тӧшкян, ӓммя алар ике меҥняб икян, алар дингезгя батканнар. 14 Дунгыз кӧтӧучеляре жӧгӧрӧб кайтыб, калага да, ауылларга да белдергянняр; кешеляр ней булганны кюрергя чыкканнар. 15 Іисусъ катына килгяч, эчендя легіонъ [1] торган женнянгян кешенен кейенеб, акыллы утырганын кюреб, алар бик куркышканнар. 16 Кюргян кешеляр женне кешегя ней булыу турысында, дунгызлар турысында да аларга йӑткянняр. 17 Алар Іисус-

[1] Легіонъ кюб мен дигян сюз.

ка: безнен тирядян китсяня диб, ўтеня башлаганнар. 18 Ул кимягя кергяч, жен азабландырган кеше Аннан Анын белян бергя жөрөргя сораган. 19 Ämмя Іисусъ анар бойормаган: Ул äйткян: син öйöня ўзенгнекеляр жанына кайт та, Ходай синга ней кылганны, Ул синга изгелек иткянне аларга äйтеб бир, дигян. 20 Ул китеб, Іисусъ анар ней кылганны ун кала (дигян жирдя) сöйляб жöрöй башлаган. Барысынында исляре киткян.

Зач. 20. 21 Іисусъ кимягя утырыб, тагы икенче жакка кичкяч, Анын жанына бик кюб калык жыйылган. Ул дингез жанында икян. 22 Мына синагога башлыкларынын берсе, Іаиръ атлы кеше килгян: ул Іисусны кюреб, Анын аягы астына жыгылыб, 23 Анар бик ўтенеб äйткян: кызым ўляр чигендя жата, Син барыб анын öстöня кулларынгны салсана, ул сауыгыб, тере калсын ыйы, дигян. 24 Іисусъ анын белян киткян.

Зач. 21. 25 Анын артыннан кюб калык барган, алар Анар тыгыз иткянняр. Шунда ун ике жыл кан агыуы белян азабланган бер катын булган. 26 Ул кюб имчелярга им иттереб, тик кюб азаб кна кюргян, бар нястясен таратыб бетереб, ич тя пайда табмаган, ämмя бигеряк тя начарланган. 27 Ул Іисусъ турысында эшетеб, калык арасында артыннан килеб, Анын кейеменя тейенгян. 28 Ул äйткян икян: Анын кейеменя гня тейенсям дя сауыгырым диб. 29 Тейенеў белян анын кан агыуы туктаган; шундук тянендя чиреннян тöзялгянен тойган. 30 Шул сяття Іисусъ Ўзеннян кыуат чыкканны тойоб, калыкка боролоб äйткян: Минем кейememя кем тейенде? дигян. 31 Öйрянеўчеляре Анар äйткянняр: Ўзенгне калык тыгызлаганны кюря тороб, Минга кем тейенде? диб äйтясен, дигянняр. 32 Ämмя Ул мыны кылыучыны кюрмякче булыб, äйлянясеня караган. 33 Катын ўзеня ней булганны белеб, куркыб калтраб килгян дя, Анын алдында жыгылыб, Анар бар дöрöсöн äйтеб биргян. 34 Іисусъ анар äйткян: кызым! сине ышаныуынг коткарды, син тынычлык белян кит, инде чиренгнян сауыккан köйö тор, дигян. 35 Ул мыны äйткян чакта, синагога башлыгыннан килеб äйткянняр: кызынг ўлде, инде Öйрятеўчене нейгя öшяндерясен? диб. 36 Ämмя Іисусъ бу сюзне эшеткяч тя, синагога башлыгына äйткян: курыкма, ышаныб кна тор, дигян. 37 Петръ белян Іаковтан башка, тагы

Іаковъ энесе Іоаннан башка, Ул бютян бер кешегя дя Ўзе белян барырга кушмаган. 38 Синагога башлыгынын ӧйӧня баргач, анда булган тамашаны, ўкереб жылаганны кюргян дя, 39 Кереб, аларга йайткян: ник тамашаланасыз? нейгя жылыйсыз? кыз ўлмягян ич, жоклой гна, дигян. 40 Алар Аннан кӧлӧшкянняр. Ӓммя Ул барысында чыгаргач, кызнын атасы белян анасын, тагы Ўзе белян бергя булганнарны алыб, кыз жата торган тӧшкя кергян. 41 Кызны кулыннан тотоб, анға йайткян: талиѳа куми, дигян; бу: кызым, синға йайтямен, тор дигян сюз була. 42 Кыз шул сяттюк торган да, жӧрӧй башлаган: кыз ун ике жяшендя икян. Андагыларнын исляре киткян. 43 Іисусъ аларга: бу эшне беряў дя белмясен диб, бик нык кисяткян, кызга ашарга бирегез, дигян.

6-нчы бюлем

Зач. 22. 1 Аннан чыккач, Ул ўскян жиреня килгян; ӧйрянеўчеляре дя Анын белян барганнар. 2 Суббота житкяч, Ул синагогада ӧйрятя башлаган; эшетеўчелярнен кюбесе исляре китеб йайткянняр: Анға бу кайдан икян? Анға нейдей белемнек бирелгян? Мындый кодрятляр Анын кулыннан ничек була? 3 Ул балта остасы тӧгӧл ме? Марія улы тӧгӧл ме? Іаковъ белян Іосіянын, Іуда белян Симоннын энесе тӧгӧл ме Ул? Анын туталары да мында безнен арадала баса, дигянняр. Шулай итеб, Анын турысында шик тотканнар. 4 Ӓммя Іисусъ аларга йайткян: пагамбяр ўскян жирендяге кюк, туганнары арасындагы кюк, ӧйӧндяге кюк, бер жирдя дя кадерсез булмый, дигян. 5 Анда Анға бер кодрят тя кыларлык булмаган, тик бер-ауык чирлелярнен östӧня кулын салыб кна аларны сауыктырган. 6 Аларнын ышанмаганнарына исе киткян. Аннары йайляня тирядяге ауылларда жӧрӧб ӧйряткян.

Зач. 23. 7 Аннары ун ике (ӧйрянеўчесен) чакырыб алыб, аларны икешяр, икешяр жибяря башлаган; аларга женнярне (жиңяргя) кыуат биргян. 8 Жулга таяктан бютян бер нястя дя, кабчык та, икмяк тя, эзярлярендя акча да алырга кушмаган; 9 Тик аякларына башмак кна кеяргя кушкан, ике кат кейем кеяргя дя кушмаган. 10 Аларга тагы йайткян: бер-бер жирдя ӧйгя керсягез, аннан киткенче шул ӧйдя торогоз. 11 Ягяр кем дя кем сезне кабыл алмаса, сезне тыңнамаса,

сез аннан чыкканда, аларга таныклыкка аякларыгыздагы тупракны селкеб төшөрөгөз. Чыннаб йтямен сезгя: сорау көнөндя Содомъ белян Гоморрга ул калага караганда жиңелеряк булыр, дигян. 12 Алар китеб, тяўбя итегез диб сөйляб жөргянняр. 13 Кюб женнярне кыуалаб чыгарганнар, кюб чирлелергя май сөртөб тёзяткянняр.

Зач. 24. 14 Іисусъ исеме даныккан буйынча, Иродъ падша Анын турысында эшетеб, йткян: бу Чумылдырыучы Іоаннъ ўлгян жиреннян терелеб торган, шуңар кюря ул кодрятляр дя кыла, дигян. 15 Бютянняр йткянняр: бу Иліядыр диб, кайсылары: бу пагамбяр, жя пагамбярлярнен кайсы булса да берсеня ошаулы, дигянняр. 16 Ямма Иродъ эшетеб, бу мин башын кистергян Іоаннды, ул: ўлгян жиреннян терелеб торгандыр, дигян. 17 Шушы Иродъ ўз агасы Филиппъ катынын Иродіаданы ўзеня катын итеб, анын какында Іоанны тоттороб, бяйлятеб, өтөрмянгя жабтырган икян; 18 Іоаннъ Иродка: синга аган (Филиппнын) катынын ўзенгя катын итеб торорга жарамый диб йткялягян шул. 19 Иродіада Іоаннга ачыуы килеб, аны ўтертясе килгян, тик булдыра алмаган. 20 Иродъ Іоаннын гадел, изге кеше икянен белеб, аннан куркыб торган шул, аны саклаган, эшляренен кюбесен ул кушканча кылган, аны жаратыб тынгнаган. 21 Бер дя бер көннө Иродіадага көй килгян: Иродъ тыуган көнөн иския алыб, ўзенен тюряляреня, мең кеше башлыкларына, Галилеядагы калык башлыкларына сый жасаган. 22 Шунда Иродіаданын кызы кергян дя, бейеб, Ироднын ўзенен дя, кунакларынын да кюңелен табкан. Падша кызга йткян: сорасың килгянне миннян сора, мин синга бирем, дигян. 23 Миннян ней гня сорасаң да, падшалыгымнын жартысын (сорасаң да) бирем синга диб анар каргангган. 24 Кыз чыгыб, анасына: ней сорөйом? дигян. Ул йткян: Чумылдырыучы Іоаннын башын (сора) дигян. 25 Кыз шундук падша катына жятляб кереб сораган: миңа Чумылдырыучы Іоаннын башын казерюк табакка салыб биргянеңне телейем диб. 26 Падша кайгыга төшкян; алайда каргангганы буйынча, кунаклары алдында оятка калмас өчөн, анар бирмей калдырасы килмягян. 27 Шул сяттюк падша ўз сакчысын жибяреб, Іоаннын башын китерергя кушкан. 28 Ул барыб, өтөрмяндя анын ба-

шын кисеб, аны табакка салыб китергян дя, кызга биргян, кыз аны анасына биргян. 29 Іоаннын ӧйрянеўчеляре эшетеб, килгянняр дя анын тянен алыб, кабергя куйганнар.

Зач. 25. 30 [1]Апостоллар Іисусъ катына жыйылыб, ней кылганнарын, нейгя ӧйряткяннярен барысын да Анҕар айтеб биргянняр. 31 Ул аларга айткян: сез ӱзегез гня буш жиргя барыгыз да, бер-аз жал итегез, дигян. Килеўчеляр, китеўчеляр кюб булганныктан, аларга ашаргa да багыт булмаган. 32 Алар ӱзляре гня кимягя утырыб, буш жиргя киткянняр. 33 Калык алар киткянне кюргян, кюбесе аларны таныганнар. Бар калалардан да жяяўлеляр алар киткян жиргя жӧгӧрӧб барганнар; алардан алдан барыб житеб, Іисусъ катына жыйылганнар. 34 Іисусъ чыгыб, кюб калыкны кюргян, алар кӧтӧўчесез сарыклар кюк жӧргянгя кюря, аларны кызганган. Аннары Ул аларны кюб ӧйряткян. 35 Байтак багыт ӱткяч, ӧйрянеўчеляре Анҕар килеб айткянняр: мында буш кыр, инде багыт та кюб ӱтте; 36 Аларны жибяр, алар жакын тирядяге калаларга, ауылларга барыб, ӱзляреня икмяк алсыннар, аларнын ашарларына бер дя жук шул, дигянняр. 37 Ул аларга жауаб биреб айткян: аларга ашаргa сез бирегез, дигян. Алар Анҕар айткянняр: без ӱзебез барыб, ике жӧз динарійгя икмяк алыб аларга ашарга бирейек меней? дигянняр. 38 Ул аларга айткян: сезнен ничя икмягегез бар? барыгыз, карагыз әле, дигян. Алар барыб белеб: биш икмяк белян, ике балык бар, дигянняр. 39 Аннары аларга барысында жяшел ӱлям ӧстӧня ӧйӧр-ӧйӧр утыртырга кушкан. 40 Рят сайын жӧзяр кеше, иллешяр кеше утырганнар. 41 Биш икмяк белян ике балыкны алыб, кюккя таба караб, бахиллягян, аннары икмяклярне сындырыб, калыкка ӧляшергя ӧйрянеўчеляреня биргян. Ике балыкны да барысынада ӧляшкян. 42 Барысыда ашаб туйганнар. 43 Калган икмяк сыныкларын, балык кисяклярен ун ике карнаша тулук жыйганнар. 44 Икмяк ашаучылар ирляр гня биш меҥняб булганнар.

Зач. 26. 45 Шул сяттюк Іисусъ, Ӱзе калыкны жибяреб бетергенче, ӧйрянеўчеляреня кимягя утырыб, алдан ары жакка Виѳсаидага таба кичяргя кушкан. 46 Аларны жибяреб, Ӱзе тау ӧстӧня теляк итяргя менгян. 47 Кимя кич дингез уртасында булган, ӓммя Іисусъ жангызы гна

[1] Бер чакта

жирдя калган. 48 Жил карышы булганныктан, аларга жӧзярга читен икянен кюргян. Тӧннӧн дюртенче бюлемендя Ул алар катына дингез östӧннян жяяўляб килгян, алар жаныннан ўтеб китясе булган. 49 Ämмя алар Анын дингез östӧннян жяяўляб килгянен кюреб, кеше шяўляседер бу диб, кычкыра башлаганнар. 50 Алар барысы да Аны кюреб, курыкканнар шул. Шул сяттюк Ул алар белян сӧйляшя башлаб аларга äйткян: ныk торогоз! бу Мин, курыкмагыз, дигян. 51 Аннары алар катына кимягя кереб утырган, шундук жил басылган; алар ўз эчлярендя бик жӧдяўгя калыб, исляре киткян. 52 Жӧрякляре таштый катыга кюря, алар икмяклярга ней булганны кюреб, анга килмягянняр. 53 Аннары аннан кичеб, Геннисаретъ жиреня килгянняр дя, жарга килеб туктаганнар.

Зач. 27. 54 Алар кимядян чыгыу белян, (ул жак кешеляре) Аны таныб, 55 Шундагы бар тирягя жӧгӧрӧшкянняр; Анын кайда икянен эшетеб, чирлелярне урыннары белян шунда алыб киля башлаганнар. 56 Ул кая гна барса да, ауылларга мы, калаларга мы, кечкеня гня ауылларга мы, чирлелярне бар тӧштя дя урамнарга чыгарыб салганнар; кейеменен кырыйына гна булса да тейенсеннярля диб Анар ўтенгянняр; Анар тейенгянняре сауыкканнар.

7-нче бюлем

1 Іисусъ катына фарисейляр белян Іерусалимнян килгян книгячелярнен кайсылары жыйылганнар. 2 Алар Анын ӧйрянеўчеляренен кайсылары жыумаган, тазартмаган кул белян икмяк ашаганны кюреб, аларны ärлягянняр. 3 Фарисейляр, Іудейляр барысыда картлар кушканны тотоб, кулларын жакшылаб жыумыйчы, икмяк ашамыйлар шул. 4 Базардан кайткач та жыуынмыйчы ашамыйлар. Тагы бютян тӧрлӧ кюб жолаларны да тоталар: табак-сауытларны, кружкаларны, казаннарны, урыннарны койондоралар.

Зач. 28. 5 Аннары фарисейляр белян книгячеляр Аннан сораганнар: Синең ӧйрянеўчеляреңней ӧчӧн картлар кушканны тотмойлар, ämмя жыумаган кул белян икмяк ашыйлар? дигянняр. 6 Ул аларга жауаб биреб äйткян: сез кюз алдында гна кылыныучылар турысында Исаія пагамбяр, жазыуда äйтелгянчя, дӧрӧс äйткян: бу кешеляр ауыз-

лары белян Мине кадерлейляр, әммя кюнгелляре Миннян жырак тора. 7 Кеше уйлаб чыгарган бойорокларга, кеше өйряткянгя өйрятеб, алар Мине бушка кадерлейляр [1] диб. 8 Сез шу Алла бойорогон калдырыб, кеше кушканны тотасыз, кружкаларны жыуыу жоласын, тагы шунгар ошашлы бютян төрлө (эшляр дя) кюб кыласыз, дигян. 9 Аларга тагы әйткян: картларыгыз кушканны тотар өчөн, Алла бойорогон калдырыуыгыз жакшы мы? 10 Моисей әйткян ич: атанғны санна; тагы: атасына, анасына жаман әйтеүче үтерелсен, [2] дигян. 11 Әммя сез әйтясез: атасына, жя анасына: мин синға бирясе нястя корванъ дейеүче, (корванъ дигяне Аллага бюляк дейеү), 12 Үз атасына, жя анасына бер дя булышмаса да жарый дейсез. 13 Шулай итеб, сез картларыгыз кушканны кыларга куйыуыгыз белян Алла сюзен чиття калдырасыз; шунын кюк бютян төрлө (эшляр дя) кюб кыласыз, дигян.

Зач. 29. 14 Аннары Ул бар калыкны чакырыб алыб әйткян: Мине барыгыз да тынғнагыз да анғнаб алыгыз. 15 Кешене тыштан кергян ич-бер нястя шакшыландыра алмый, әммя эченнян чыкканы кешене шакшыландыра. 16 Эшетергя колагы бар кеше эшетсен, дигян. 17 Ул калык жаныннан өйгя кергяч, өйрянеүчеляре Аннан мясял турысында сораганнар. 18 Ул аларга әйткян: әле сез дя шулай анғнамыйсыз меней? кешене тыштан кергян ич-бер нястя шакшыландыра алмаганны анғыша алмыйсыз меней? 19 Ул анын кюнгеленя кермей ич, әммя карынына керя, аннары тышка чыга, шунын белян әрбер ашамнык тазара, дигян. 20 Тагы әйткян: кешенен эченнян чыкканы кешене шакшыландыра: 21 Эчтян, кеше кюнгеленнян усал уйлар, азгыннык итеү, уйнашлык, кеше үтереү, 22 Урлау, малга биренеү, жаманнык итеү, жумачылык, оятсызлык, кюремсез кюз, Алланы курлау, олосомаклык, акылсызлык чыга шул. 23 Бу усаллыклар барыда эчтян чыгалар, шулар кешене шакшыландыралар, дигян.

Зач. 30. 24 Аннары аннан китеб, Тиръ белян Сидонъ тирялареня барган; анда бер өйгя кереб, Үзен беряүгя дя белдерясе килмягян, алайда жяшерен кала алмаган. 25 Анын турысында бер женнянгян кызлы катын эшткян; ул килеб, Анын аягы астына жыгылыб башырган. 26 Бу катын

[1] Ис 29:13.
[2] Исх 20:12; 21:16.

жалган денне тотоучы булган, ул Сирофиникія жиренеке икян; ул Аңар: кызым эченнян женне чыгарсана диб инялгян. 27 Ämмя Іисусъ аңар äйткян: элеке балалар ашаб туйсыннар; икмякне балалардан алыб, этлярга ташлауы жакшы тöгöл шул, дигян. 28 Катын Аңар жауаб биреб äйткян: анысы дöрöс, эй Ходай! алайда этляр дя öстял астында балаларнын ыуалчыкларын ашыйлар ич, дигян. 29 Ул аңар äйткян: бу сюзең öчöн, бар кайт, кызың эченнян инде жен чыкты, дигян. 30 Öйöня кайткач, ул кызынын жене чыгыб, кызы урын öстöндя жатканны кюргян.

Зач. 31. 31 Тиръ белян Сидонъ тиряляреннян чыгыб, Іисусъ ун кала (дигян жир) арткылы тагы Галилея дингезе жанына килгян. 32 Шунда Аңар бер саңрау, сакау кешене алыб килгянняр дя анын öстöня кулыңны салсана диб, Аңар инялгянняр. 33 Іисусъ аны калыктан читкяряк алыб китеб, анын колакларына бармакларын тыгыб, тöкöрöб, анын теленя тейенгян дя, 34 Кюккя таба караб, эчтян сулыб, аңар äйткян: еффаөа, дигян, еффаөа дигяне ачыл дигян сюз. 35 Шул сяттюк анын колаклары ачылган, теленен бяйе чишелеб, ул чиста сöйляшя башлаган. 36 Іисусъ аларга мыны беряўгя дя äйтергя кушмаган. Тик аларга Ул ней хатле кисятся дя, алар бигеряк тя жяйелдергянняр. 37 Бик исляре киткян: барын да жакшы кыла, саңрауларны эшетя торган итя, телсезлярне сöйляшя торган итя, дигянняр.

8-нче бюлем

Зач. 32. 1 Шул көннярдя калык бик кюб жыйылыб, аларнын ашарларына бер нястя дя булмагач, Іисусъ Ўз Öйрянеўчелярен чакырыб алыб, аларга äйткян: 2 Мин бу калыкны кызганамын, алар Минем катымда инде öч көннян бирле торалар, аларнын ашар нястяляре дя жук. 3 Äгяр аларны öйляреня ач көйö жибярсям, аларнын жулда халляре бетяр, аларнын кайсылары жыракътын килгянняр шул, дигян. 4 Öйрянеўчеляре Аңар жауаб биргянняр: мында буш кырда аларны туйдырырлык икмяк каян аласы? дигянняр. 5 Ул алардан: сезнен ничя икмягегез бар? диб сораган. Алар: жидяў, дигянняр. 6 Ул аннары калыкка жиргя утырырга кушкан, кушкач, жиде икмякне алыб, (Аллага) тау иткян дя сындырыб, öйрянеўчеляреня калыкка öляшергя биргян; алар

öляшкянняр. 7 Аларнын тагы бер-аз балыклары да бар икян; Ул бахилляб аларны да öляшергя кушкан. 8 Барысыда ашаб туйганнар; калган сыныкларны жиде карнаша жыйганнар. 9 Ашаучылар дюрт менӈняб булганнар. Аннары аларны жибяргян. 10 Ӱзе шундук öйрянеӱчеляре белян кимягя утырыб, Далмануөа тиряляреня килгян.

Зач. 33. 11 Шунда фарисейляр килеб, Анын белян жиӈешя башлаганнар; Аны сынаб, безгя кюктян билге кюрсят, дигянняр. 12 Ул эчтян сулыб äйткян: бу тыума нейгя билге сорой? Чыннаб äйтямен сезгя: бу тыумага билге бирелмяс, дигян. 13 Аннары аларны калдырыб, жяня кимягя утырыб, икенче жакка кичкян. 14 Шул чакта Анын öйрянеӱчеляре икмякляр алырга онотканнар, кимядя Ӱзляре белян бергя бер гня икмякляре булган. 15 Ämмя Ул аларга кисятеб äйткян: карагыз, фарисейляр äчеткеченнян, Иродъ äчеткеченнян сакланыгыз, дигян. 16 Алар ӱз аралый: икмякляребез жукны äйтеӱедер диб уйлашканнар. 17 Iисусъ мыны белеб, аларга äйткян: ник сез икмякляребез жук диб уйлыйсыз? Äле дя тоймойсыз меней? äле дя анъыша алмыйсыз меней? 18 Кюӈелегез таштый кöйö меней? Кюзляре-гез булыб та кюрмейсез ме? колакларыгыз булыб та эшетмейсез ме? исегездя тöгöл меней? 19 Мин биш икмякне биш меӈ кешегя сындырыб ашаткач, сыныклар жыйыб ничя карнаша тутырдыгыз? дигян. Алар Анар ун икене, дигянняр. 20 Тагы жиде икмякне дюрт меӈ кешегя (сындырыб биргяч), калган сыныкларны ничя карнаша жыйдыгыз? дигян. Алар: жидене, дигянняр. 21 Шуннан суӈ аларга äйткян: сез ничек анамыйсыз? дигян.

Зач. 34. 22 Аннары Iисусъ Виөсаидага килгян; шунда Анар бер сукыр кешене китереб, мыӈар тейенсяня диб ӱтенгянняр. 23 Ул сукырны кулыннан тотоб, аны ауылдан житякляб чыгарган да анын кюзляреня тöкöрöб, анар кулларын салыб, аннан: бер-бер нястя кюрясен ме? диб сораган. 24 Ул караб караган да: узыб бара торган кешелярне агачлар кюк кня кюрямен, дигян. 25 Аннары тагы кулларын анын кюзляреня куйыб, анар: кара, дигян. Ул тöзялеб, бар нястяне дя айырмачык кюря башлаган. 26 Аннары аны öйöня былай äйтеб жибяргян: бу ауылга кермя, ауылда беряӱгя дя сöйляшмя, дигян.

Зач. 35. 27 Аннары Iисусъ Ӱз öйрянеӱчеляре белян Фи-

липпъ Кесаріясенен ауыллары-на барган. Жулда чагында Ул öйрянеўчеляреннян сораган: кешеляр Мине кем диб äйтяляр? дигян. 28 Алар жауаб биргянняр: Чумылдырыучы Іоаннъ диб, кайсылары Илія диб, äммя кайсылары пагамбярлярнен берседер диб äйтяляр, дигянняр. 29 Ул аларга äйткян: сез ўзегез Мине кем диб белясез? дигян. Петръ Анар жауаб биреб äйткян: Син Христосъ, дигян.

Зач. 36. 30 Іисусъ аларга Ўзе турысында беряўгя дя äйтергя кушмаган. 31 Аннары Ул аларны: Ädям Улы кюб азаб кюрясе диб, калык башлыклары, архіерейляр, княгячеляр Аны кабыл алмаслар, Аны ўтererляр диб, Ул öчöнчö кöннö терелеб торор диб, öйрятя башлаган. Ул бу турда айырмачык äйткян. 32 Петръ Аны читкяряк алыб китеб, Анар кире кагыб, äйтя башлаган. 33 Ämмя Ул боролоб, öйрянеўчеляреня таба караб, Петрны туктатыб äйткян: кит Миннян шайтан, син шу Аллага жараганны уйламыйсын, ämмя кешегя жараганны (уйлыйсын), дигян. 34 Аннары öйрянеўчеляре белян калыкны чакырыб, аларга äйткян:

Зач. 37. Мина эярясе килгян кеше, ўз иркен кылыуны ташласын да качын алыб, Минем артымнан барсын. 35 Жанын саклясы килгян кеше, аны жуяр шул, ämмя жанын Минем öчöн, Евангеліе öчöн жуйган кеше, аны саклар. 36 Кеше бötöн дöньяне жыйыб алса да, ämмя ўз жанына зыян китерся, анар ней пайда булыр? 37 Жя кеше ўз жанын ней биреб жола алыр? 38 Кем дя кем шушы жазыклы, азгын тыума арасында Миннян, жя сюзляремнян оялса, Ädям Улы да Ўз Атасынын олологонда арыу пяриштяляр белян бергя килгяч, аннан оялыр, дигян.

9-нчы бюлем

1 Ул аларга äйткян: чыннаб äйтямен сезгя: мында тороучыларнын кайсылары, Алла Падшалыгынын кодрят белян килгянен кюрмейче, ўлмясляр, дигян.

Зач. 38. 2 Аннары алты кöн ўткяч, Іисусъ Петрны, Іаковны, Іоанны алыб китеб, аларны гна алыб бейек тау öстöня менгян; Ул анда алар алдында ўзгяргян. 3 Кеймняре жалтраб торган, кар кюк бик ак булган, жир öстöндяге бер агартыучы да алай агарта алмас. 4 Шунда аларга Илія белян Моисей кюренеб, Іисусъ белян сöйляшеб тор-

ганнар. 5 Шул чакта Петръ Іисуска
йіткян: эй Ойрятеўче! безгя
мында тороргa жакшы; оч чатыр
коройокчы: берсен Синґа, бер-
сен Моисейгя, берсен Иліягя,
дигян. 6 Ул ней йіткянен дя бел-
мей калган, алар бик курыкканнар шул. 7 Шундук аларны болот
килеб кюлягялягян: болоттан:
Шушы Минем сойоклo Улым,
Аны тынґнагыз диб ауаз килгян. 8
Алар кинят йілляняляреня карангач, ўзляре белян Іисустан бютянне беряўне дя кюрмягянняр.
9 Тау östöннян төшкян чакта, Ул
аларга кюргяннярен, Ядям Улы
ўлгян жиреннян терелеб торгончы, беряўгя дя йітергя кушмаган.

Зач. 39. 10 Алар бу сюзне ислярендя тотоб, ўлгян жирдян терелеб тороу ней икян диб бер
берсеннян сорашканнар. 11 Аннары алар Іисустан сораганнар: бу
ничек княгячеляр элеке Илія килясе дейляр? 12 Ул аларга жауаб
биреб йіткян: дöрöс, Илія элеке
килеб, барын да рятлягя тейеш;
Ядям Улы да, Ўз турысында жазылганча кюб азабланырга, кимсетелергя тейеш. 13 Яммя Мин
сезгя йітямен: Илія инде, анын
турысында жазылганча, килде;
анґар телягяннярен кылдылар, [1]
дигян. 14 Аннары öйрянеўчеляре
катына килеб, алар йілянясендя
кюб калыкны кюргян; княгячеляр öйрянеўчеляре белян
жинґешкянне кюргян. 15 Шул
сяттюк Аны кюреб, бар калыкнын исе киткян; жöгöрöб килеб,
Анын белян кюрешкянняр. 16 Ул
княгячелярдян сораган: алар белян ней турысында жинґешясез?
дигян.

Зач. 40. 17 Калык арасыннан
беряў жауаб йіткян: эй Ойрятеўче! мин Синґа телсез тынны [2] улымны китергян эйем. 18
Кайда гна тотса да, ул аны жиргя жыга; ул тешлярен шыкырдатыб, кюбек чыгара, катыб китя;
мин öйрянеўчеляреня: ул тынны
кыуыб чыгарыгыз дигян эйем,
тик алар булдыра алмадылар,
дигян. 19 Іисусъ анґар жауаб биреб йіткян: эй ышаныусыз тыума! кайчанга чаклы сезнен белян
торойом? кайчанга чаклы сезгя чыдыйым? аны Минґа китерегез, дигян. 20 Аннары аны Анґар
китергянняр. Тын Аны кюреў
белян, чирлене калтраткан; ул
жиргя жыгылган да, кюбеген
чыгарыб, аунаб жаткан. 21 Іисусъ анын атасыннан сораган:
мынґар былай булыуы кюбтян
ме? дигян. Ул: баладанук, дигян.
22 Тын аны бетерер очön, кюб
табкыр утка, сыуга ыргыткала-

[1] Мал 4:5-6. 3Цар 19.

[2] Женне.

ды; ӓгяр Син бер-бер нястя кыла алсаӈ, безне кызганыб, безгя булыша кюр, дигян. 23 Іисусъ анӈар ӓйткян: ӓгяр син ӓз гня ышана алсаӈ да, ышаныучыга барын да кыларга мӧнӈким, дигян. 24 Шул сяттюк жегет атасы жылаб кычкырыб ӓйткян: ышанамын эй Ходай! ышанмаганыма булыша кюр, дигян. 25 Іисусъ калык жыйылганны кюреб, шакшы тынга кисятеб ӓйткян: эй телсез, саӈрау тын! Мин синӈа кушам, аннан чык, инде мыннан былай анӈар кермя диб. 26 Ул шундук аны каты калтратыб, кычкырыб чыккан; жегет ӱлгян кюк булган; кюбесе ӱлде инде ул дигянняр. 27 Ӓммя Іисусъ кулыннан тотоб, аны кютяргян, ул торган. 28 Іисусъ ӧйгя кергяч, ӧйрянеӱчеляре аулакта Аннан сораганнар: без аны ник чыгара алмадык икян? дигянняр. 29 Ул аларга ӓйткян: бу затны тик теляк белян ураза арткылы гна чыгарырга мӧнӈким, дигян. 30 Аннан чыгыб, алар Галилея арткылы ӱтеб барганнар. Іисусъ Ӱзен беряӱгя дя белдертясе килмягян, 31 Ул шу ул чагында ӧйрянеӱчелярен ӧйрятеб, аларга ӓйткян: Ӓдям Улы кешеляр кулына тотоб бирелер, Аны ӱтererляр, ӱтергяч, ӧчӧнчӧ кӧнӧндя терелеб торор, дигян. 32 Тик алар бу сюзлярне анӈамаганнар, ӓммя Аннан сорарга курыкканнар.

Зач. 41. 33 Капернаумга килгяч, бер ӧйдя чагында, Ул алардан сораган: сез жулда ӱз аралый ней турысында исябляштегез? дигян. 34 Алар дяшмягянняр, жулда ӱз аралый кем олорак диб сӧйляшкянняр икян шул. 35 Утыргач, ун икесен дя чакырыб алыб, аларга ӓйткян: кемнен оло буласы киля, ул барысыннанда кече булсын, барысынада кызмятче булсын, дигян. 36 Аннары бер баланы алыб, аны урталарына торгозоб, аны кочаклаб, аларга ӓйткян: 37 Кем Минем исемемя шушындый балаларнын берсен кабыл алса, ул Мине кабыл ала; Мине кабыл алыучы, Мине кабыл алмый, ӓммя Мине Жибяреӱчене (кабыл ала), дигян. 38 Шунда Іоаннъ Анӈар ӓйткян: эй Ӧйрятеӱче! без Синеӈ исемеӈ белян женнярне кыуалаб чыгарыучы кешене кюрдек, ӓммя ӱзе безгя эяреб жӧрмягянгя кюря, без аны туктаттык, дигян. 39 Іисусъ ӓйткян: аны туктатмагыз: Минем исемем белян кодрят кылган кеше, беряӱ дя Мине тизюк жаманный алмас. 40 Сезгя карышы тӧгӧл кеше, сезнен жаклы шул. 41 Кем дя кем Минем исемемя, сез Христосныкылар диб, сезгя бер сауыт сыу эчерся, чын-

наб äйтямен сезгя: ул сауабын алмый калмас, дигян.

Зач. 42. 42 Кем дя кем шушы Миңа ышаныучы кечкенялярнен берсен алдандырса, аңар муйнына тегермян ташы асыб, аны дингезгя ташласалар жакшырак булыр ыйы. 43 Äгяр сине кулың алдандырса, син аны кисеб ташла: синa сыңар куллы көйö терелеккя кереўе, ике кулың белян тамукка, сюнмей торган утка китеўдян жакшырак ич. 44 Анда аларнын кортлары да ўлмей, утлары да сюнмей. 45 Äгяр сине аягың алдандырса, аны кисеб ташла: синa аксак көйö терелеккя кереўе, ике аяк белян тамукка, сюнмей торган утка ташланыудан жакшырак ич. 46 Анда аларнын кортлары да ўлмей, утлары да сюнмей. 47 Äгяр сине кюзең кызыктырса, син аны сыуырыб ал: синa сыңар кюз белян Алла Падшалыгына кереўе, ике кюзең белян тамук утына ташланыудан жакшырак ич. 48 Анда аларнын кортлары да ўлмей, утлары да сюнмей. 49 Äркем ут белян тозланыр, [1] äр-бер корман да тоз белян тозланыр шул. 50 Тоз жакшы нястя; äгяр тознон тозлолого булмаса, аны ней белян тöзятерсез? Ўзегездя тоз булсын, ўз арагызда татулык булсын, дигян.

[1] Читеннек кюреў арткылы ныгайыуны, тазарыуны äйтеля.

10-нчы бюлем

1 Аннан киткяч, Iисусъ Iорданнын ары жагыннан ўтеб Iудея тиряляреня килгян. Анын катына тагынук калык жыйылган, Ул Ўз жоласынча аларны тагы öйряткян.

Зач. 43. 2 Фарисейляр жакын килеб, Аннан сынаб сораганнар: иргя катынын айырырга мöңким ме? дигянняр. 3 Ул аларга жауаб биреб äйткян: Моисей сезгя ней бойорган? дигян. 4 Алар äйткянняр: Моисей (катынга) айырыу жазыуын жазыб, айырыб жибярергя роксят иткян, дигянняр. 5 Iисусъ аларга жауаб биреб äйткян: кюңелегез катыга кюря, ул сезгя бу бойорокны жазган. 6 Баш булдырыудук Алла аларны ирле катынны иткян. [2] 7 Шуңар кюря кеше ўз атасын, анасын калдырыр да, 8 Ўз катынына кушылыр, аннары икесе бер тян булырлар; [3] шунныктан алар инде икяў töгöл, ämмя бер тян. 9 Алай булгач, Алла кушылдырганны кеше айырмасын, дигян. 10 Öйдя

[2] Быт 1:27.
[3] Быт 2:24.

öйрянеўчеляре бу турыда тагы сораганнар.

Зач. 44. 11 Ул аларга äйткян: кем ўз катынын айырыб, бютян катын алса, ул катыны östöннян уйнашлык итя. 12 Äгяр катын да ўз иреннян айырылыб, бютян иргя кится, ул да уйнашлык итя, дигян. 13 Анҕар балаларны китергянняр, Ул аларга тейенсен диб, ämмя öйрянеўчеляре китереўчелярне жибярмей торганнар. 14 Мыны кюргяч, Іисусъ сукыраныб, аларга äйткян: балаларга Миҥа килергя ирек итегез, аларны туктатыб тормагыз, Алла Падшалыгы шундыйларныкы шул. 15 Чыннаб äйтямен сезгя: кем Алла Падшалыгын бала кюк кабыл алмаса, ул анда кермяс, дигян. 16 Аннары аларны кочаклаб, östляреня кулын салыб, аларны бахиллягян.

Зач. 45. 17 Іисусъ жулга чыккан чакта, беряў жöгöрöб килеб, алдында тезлянеб тороб, Аннан сораган: эй изге Öйрятеўче! мянге тормошка урыннашыр öчön, мин ней кылыйым? дигян. 18 Іисусъ анҕар äйткян: ник син Мине изге диб äйтясеҥ? Беряў дя изге тöгöл, тик бер Алла гна (изге). 19 Бойорокларны белясен: уйнашлык итмя, ўтермя, урлама, жалган таныклык итмя, читлямя; атаҥны, анаҥны санна, [1] дигян. 20 Ул Анҕар жауаб биреб äйткян: эй Öйрятеўче! мин быларны барысында жяштянюк тоттом, дигян. 21 Іисусъ анҕар караб, аны жаратыб, анҕар äйткян: синҕа бер гня нястя житмей: бар, нейеҥ бар барысында сат та, жарлыларга öляш, синеҥ малыҥ кюктя булыр: аннары кил дя, качны алыб, Минем артымнан жöр, дигян. 22 Ул бу сюздян жöдяўгя калыб, кайгырыб, аннан киткян, анын малы кюб икян шул. 23 Аннары äйлянясеня караныб, Іисусъ Ўз öйрянеўчеляреня äйткян:

Зач. 46. Байларга Алла Падшалыгына кереўе ничек читен! дигян. 24 Öйрянеўчеляре Анын сюзляреннян абтраб киткянняр. Ämмя Іисусъ аларга жауабка äйткян: эй балалар! байлыкка ышаныб тороучыларга Алла Падшалыгына кереўе ничек читен! 25 Бай кешегя Алла Падшалыгына кереўдян дöягя иня кюзеннян ўтеўе асатрак, дигян. 26 Алар уза исляре китеб, ўз аралый: айсаҥ кем котола алыр диб? сöйляшкянняр. 27 Іисусъ аларга караб äйткян: кешеляргя бу мöҥким тöгöл, ämмя Аллага барда мöҥким шул, дигян. 28 Аннары Петръ Анҕар äйтя башлаган: мына без барында кал-

[1] Исх 20:12-17.

дырыб, Синға эярдек, дигян. 29 Іисусъ жауаб биреб йткян: чынаб йтямен сезгя: Минем өчөн, Евангеліе өчөн, өйөн, жя ага-энелярен, жя тута-сеңнелярен, жя атасын, жя анасын, жя катынын, жя балаларын, жя жирен-сыуын калдырган кеше беряў дя, 30 Әле шушы кысанныкларда торган чакта, өйляр, ага-энеляр, тута-сеңнеляр, аталар, аналар, балалар, жир-сыулар жөз өлөш артык алмый калыучы жук, әммя булясы гумердя мянге тормошны алмый калмас. 31 Алдагылар кюбесе артта булырлар, әммя арттагылар алда булырлар, дигян. 32 Іерусалимгя менеб барган чакта, жулда Іисусъ өйрянеўчеляре алдыннан барган, әммя алар Анын артыннан котлары чыгыб, куркышыб барганнар.

Зач. 47. Ун ике (өйрянеўчесен) чакырыб алыб, Ўзеня ней буласыны аларга тагы сөйлөй башлаган: 33 Мына без Іерусалимгя менеб барабыз; анда Ядям Улын архіерейлярга, книгячелярга тотоб бирерляр; Аны ўтерергя хокөм итярляр; Аны жалган деннелярга тотоб бирерляр; 34 Аннан мыскыл итярляр, Аны кыйнарлар, Анға төкөрөб тутырырлар, Аны ўтererляр, Ул өчөнчө көнөндя терелеб торор, дигян. 35 Шул чакта Зеведей уллары Іаковъ белян Іоаннъ Анар килеб йткянняр: эй Өйрятеўче! без сорасыны Син безгя кылсаң ыйы диб телейбез, дигянняр. 36 Ул аларга йткян: Мин сезгя ней кылганны телейсез? дигян. 37 Алар Анар: Ўз олологонда безнен беребезне уң жагыңа, икенчебезне сул жагыңа утыртсана дигянняр. 38 Іисусъ аларга йткян: ней сораганыгызны ўзегез белмейсез. Мин эчя торган сауыттагын эчя алырсыз мы? Мин чумыла торган чумылыу белян чумыла алырсыз мы? дигян. 39 Алар жауаб биргянняр: алырбыз, дигянняр. Іисусъ аларга йткян: Мин эчя торган сауыттагын эчярсез, Мин чумыла торган чумылыу белян дя чумылырсыз, 40 Әммя Ўземнен уң жагыма, жя сул жагыма утыртыу Минем иркемдя төгөл, тик кемгя әзерлягян, шул (утырыр), дигян. 41 Мыны эшетеб, унысы Іаковъ белян Іоанны жаратмаганнар. 42 Іисусъ аларны чакырыб алыб, аларга йткян: калыкларнын тюряляре аларны биляб торганны, ололары аларны ўз кул астларында тотканны сез белясез. 43 Сезнен арагызда алай булмасын: сезнен арада кем олорак буласы кился, ул сезгя кызмятче булсын; 44 Кем сезнен арада баш буласы кился, ул

барысына да кол булсын. 45 Шулай, Ädям Улы да Ўзеня кызмят иттерер öчöн килмяде, ämмя Ўзе кызмят итяр öчöн, кюб (кешелярне) жолар öчöн, Ўз жанын бирергя (килде), дигян.

Зач. 48. 46 Аннары Іерихонга килгянняр. Ул öйрянеўчеляре белян, кюб калык белян Іерихоннан чыккан чакта, Тимей улы сукыр Вартимей жул буйында сораныб утырган. 47 Бу Назорей Іисусъ дигянне эшеткяч, ул: эй Давидъ Улы Іисусъ! мине жарлыка диб кычкыра башлаган. 48 Кюбесе анґар кычкырыргa кушмаганнар; ämмя ул: эй Давидъ Улы! мине жарлыка диб бигеряк тя ныкъ кычкыра башлаган. 49 Іисусъ туктаб, аны чакырырга кушкан. Сукырны чакырыб, анґар äйткянняр: курыкма, тор, сине чакыра, дигянняр. 50 Ул öст кейемен салган да, тороб, Іисусъ катына килгян. 51 Іисусъ анґар жауабка äйткян: Мин синґа ней кылганны телейсен? дигян. Сукыр Анґар äйткян: эй Öйрятеўче! кюря торган булсам ыйы, дигян. 52 Іисусъ анґар äйткян: бар, ышаныуынґ сине коткарды, дигян. Ул шул сяттюк кюря башлаган; аннары жул белян Іисуска эяреб киткян.

11-нче бюлем

Зач. 49. 1 Іерусалимгя, Елеонъ тауына, Виөсфагія белян Виөанія атлы ауылларга жакыннашкач, Іисусъ Ўзенен ике öйрянеўчесен жибяреб, 2 Аларга äйткян: шушы алдыгыздагы ауылга барыгыз: анда кереў белян тизюк, бер кеше дя атланмаган, бяйляб куйган жяш ишякне очратырсыз; аны чишеб, алыб килегез. 3 Ägяр беряў сезгя: ней эшлейсез? дися, сез: Ходайга киряк диб жауаб бирегез, ул шундук аны биреб жибярер, дигян. 4 Алар барыб, урамда, кабка тöбöндя бяйляб куйган жяш ишякне очратканнар да аны чишеб алганнар. 5 Анда тороучыларнын кайсылары аларга äйткянняр: ней эшлейсез? ник ишяк колонон чишясез? дигянняр. 6 Öйрянеўчеляр аларга Іисусъ кушканча äйткянняр, äйткяч аларны жибяргянняр. 7 Жяш ишякне Іисусъ катына алыб килгянняр дя анын öстöня кейемнярен жяйгянняр. Іисусъ анын öстöня атланган. 8 Кюбесе кейемнярен жулга жяйеб барганнар; кайсылары агач ботакларын кисеб алыб, жулга тюшяб барганнар. 9 Алдан барыучылар да, арттан килеўчеляр дя былай кычкырганнар: Осанна! Ходай

исеменя Килеўче даннаулы! 10 Атабыз Давиднын Ходай исеменя киля торган падшалыгы даннаулы! эй жугарыдагы Осанна! диб.

Зач. 50. 11 Іисусъ Іерусалимгя килеб, чиркяўгя кергян; анда барында караб бетергяч, кич булганга кюря, ун ике (ёйрянеўчесе) белян Виѳаніяга киткян. 12 Икенче көннө алар Виѳаніядян чыккач, Анын ашасы килгян. 13 Жапраклы смоква агачын жыраклын кюреб, анда бер-бер нястя очратмам мы диб, (анын жанына) барган; тик барыб, анда жапрактан бютян бер нястя дя табмаган, ул чакта смоква багыты төгөл икян шул. 14 Іисусъ анга ёйткян: мыннан былай гумергя синнян беряў дя жимеш ашамасын! дигян. Мыны ёйрянеўчеляре эшеткянняр. 15 Аннары Іерусалимгя килгянняр. Іисусъ чиркяўгя кереб, чиркяўдя сатыу итеўчелярне, алыучыларны кыуа башлаган; акча алыштырыучыларнын өстяллярен, кюгярчен сатыучыларнын скямьялярен аударыб бетергян. 16 Чиркяў арткылы бер нястя дя алыб жөрөргя кушмаган. 17 Аларны ёйрятеб ёйткян: Минем ёйём бар калыкларга да теляк ёйө диб аталыр диб жазылмаган меней? ёммя сез аны талаучылар оясы иткянегез [1] дигян. 18 Мыны княгячеляр белян архіерейляр эшетеб, Аны ничек булса да бетерергя көй эзлей башлаганнар; Анын ёйрятеўеня бар калыкнын да исе киткянгя кюря, Аннан курыкканнар. 19 Кич булгач, Ул каладан чыгыб киткян. 20 Иртя белян узыб барышлый, смоква агачынын тамырына чаклы короб беткянен кюргянняр. 21 Петръ исеня төшөрөб, Анга ёйткян: эй Ёйрятеўче! кара, Син каргаган смоква агачы короган, дигян. 22 Іисусъ аларга жауаб биреб ёйткян:

Зач. 51. 23 Аллага ышанулыкны ныk тотогоз. Чыннаб ёйтямен сезгя: ёгяр кем ўз кюнеленда шиклянмейче, ёйткянемчя булыр диб ышаныб, шушы тауга: кютярелеб, дингезгя атыл дися, ул дигянчя булыр. 24 Шунныктан сезгя ёйтямен: телягегездя ней гня сорасагыз да, алырыгызга ышаныгыз, ышаныуыгызча сезгя булыр. 25 Теляктя торган чакта, кюктяге Атагыз сезгя жазыкларыгызны кичерсен дисягез, беряўгя-беряўгя ўпкягез булса, кичерегез. 26 Ёгяр сез кичермясягез, кюктяге Атагыз да сезгя жазыкларыгызны кичермяс, дигян.

Зач. 52. 27 Кабат тагы Іерусалимгя килгянняр. Ул чиркяў

[1] Іер 7:11.

эчендя жöргян чакта, Анын катына архіерейляр, княгячеляр, калык башлыклары килеб, 28 Анар айткянняр: Син мыны кем бойороуы белян кыласын? Мыны кыларга Синя кыуат кем бирде? дигянняр. 29 Іисусъ аларга жауаб биреб айткян: Мин дя сездян бер турда соройом, Миня жауаб биребгез, Мин дя сезгя мыны кем бойороуы белян кылганымны айтермен. 30 Іоаннын чумылдыруы кюктян булды мы, ялля кешелярдян ме? Миня жауаб биребгез, дигян. 31 Алар ўз аралый уйлаганнар: ягяр кюктян дисяк, Ул безгя: ник суң анар ышанмадыгыз? дирер; 32 Ммя кешелярдян дирергя, калыктан курыкканнар: Іоанны барда чын пагамбяргя санаганнар шул. 33 Шунныктан Іисуска жауаб биреб айткянняр: белмейбез, дигянняр. Іисусъ та аларга жауаб биреб айткян: Мин дя сезгя мыны кем бойороуы белян кылганымны айтмям, дигян.

12-нче бюлем

Зач. 53. 1 Аннары Іисусъ аларга мясялляр китереб айтя башлаган: бер кеше жözöм агачлары утыртыб, айлянясен койма белян айляндергян, эчендя (жözöм сыуын) агызгыч жасаган, башня торгозган, аннары аны бакчачыларга табшырыб, киткян. 2 Багыт житкяч, бакчачылардан бакчадагы жözöм жимешен алырга, бакчачылар катына кызмятчесен жибяргян. 3 Ммя алар аны тотоб, кыйнаганнар да, бер дя бирмей жибяргянняр. 4 Ул аларга тагы икенче кызмятчене жибяргян; анысынын да башын таш атыб тишкянняр дя, кадерсез итеб жибяргянняр. 5 Ул тагы бютянне жибяргян. Анысын да ўтергянняр; бютяннярен дя кюбесен жя кыйнаганнар, жя ўтергянняр. 6 Анын бик сöйгян бер гня улы бар икян; улымнан оялырлар диб калдыгында ул аларга ўз улын жибяргян. 7 Ммя бакчачылар бер берсеня айткянняр: бу атасы урнына каласы; айдягез, ўтерейек аны, аннары анар каласы мал безнеке булыр, дигянняр. 8 Аны тотоб ўтергянняр дя бакчадан чыгарыб ташлаганнар. 9 Бакча эясе инде ней кылар? Ул килеб, бакчачыларны ўтертер дя бакчаны бютяннярга бирер. 10 Мыны сез укымадыгыз меней: öй салыучылар жараусыз кюреб ташлаган таш почмак астына нигез булган, 11 Ходайдан булган бу, безнен кюз алдыбызда ис

китярлек [1] дигянне? 12 Шунда Аны тотоб алмакчы булганнар, тик калыктан курыкканнар: мясялне алар турысында айткянне анғнаганнар. Аны калдырыб, жанынан киткянняр.

Зач. 54. 13 Іисусны сюзеннян эляктерейек диб, Анын катына фарисейлярнен, иродныкларнын кайсыларын жибяргянняр. 14 Алар килеб, Анар айткянняр: эй Ойрятеучe! без Синең туры кеше икянеңне белябез, Син беряўгя дя жараулы булыйым димейсен, кешесеня караб кылмыйсын шул, аммя Алла жулына дöрöс öйрятясен. Кесаргя имана тюлярга тейеш ме, алля жук мы? бирейек ме, алля бирмейек ме? дигянняр. 15 Ул аларнын жумалауларын белеб, аларга айткян: ник сез Мине сыныйсыз? Миңа бер динарій китерегез, Мин аны кюрейем, дигян. 16 Алар китергянняр. Ул аларга айткян: бу кем töсö, кем исеме жазылган? дигян. Алар Анар: Кесарнеке дигянняр. 17 Іисусъ аларга жауаб биреб айткян: Кесарнекен Кесаргя, аммя Алланыкын Аллага биregез, дигян. Анар исляре киткян.

Зач. 55. 18 Анын жаына терелеб тороу булмас диб айтеучe саддукейляр килеб, Аннан былай диб сораганнар: 19 Эй Ойрятеучe! Моисей безгя: беряўнен агасы ўлеб, катынын калдырса, аммя балалар калдырмаса, анын катынын энесе алыб, агасына нясел булдырсын [2] диб жазган: 20 Жиде ага-эне бар ыйы: элекегесе катын алгач, ўлде, нясел калдырмады. 21 Аннары аны икенчесе алды: ул да ўлде, нясел калдырмады; öчöнчöсö дя шулай булды. 22 Шулай итеб, аны жидесе дя алыб, нясел калдырмадылар: барысыннан да суң катын да ўлде. 23 Терелеў кöнöндя, терелеб торгач, ул кайсына катын булыр? жидесе дя аны катынга алганнар ыйы шул, дигянняр. 24 Іисусъ аларга жауаб биреб айткян: сез шушынын белян, Алла жазыуын, Алла кыуатын белмейче, саташасыз меней? 25 Ўлгянняр терелеб торгач, öйлянмейляр дя, кеяўгя дя китмейляр, аммя кюктяге пяриштяляр кюк торалар. 26 Аммя ўлгянняр терелеб тороу турысында, Алла Моисейгя кыуак жанында: Мин Авраамъ Аллясы, Исаакъ Аллясы, Іаковъ Аллясы [3] дигянне Моисей книгяляренdя укымадыгыз меней? 27 Алла ўлгянняр Аллясы töгöл,

[1] Пс 117:22-23.

[2] Втор 25:5-6.

[3] Исх 3:6.

ämmя тереляр Алласы. Шулай итеб, сез бик саташасыз, дигян.

Зач. 56. 28 Княгячеляр арасыннан беряў килеб, аларнын жиңешкяннярен эшетеб, Ул аларга жакшы жауаб биргянне кюреб, Аннан сораган: бар бойорокларнын иң олосо кайсы? дигян. 29 Iисусъ аңар жауаб биргян: бар бойорокларнын иң олосо бу: эй Израиль, тыңна! Ходай Аллагыз бер Ходай. 30 Ходай Алланғны бар кюнелең белян, бар жаның белян, бар уйың белян, бар көчөң белян сöй. [1] Шушы иң оло бойорок. 31 Икенчесе дя шуңар ошаулы: жакынынғны ўзеңне сöйгян кюк сöй. [2] Былардан оло бютян бойорок жук, дигян. 32 Княгяче Аңар äйткян: жакшы (äйттең), Öйрятеўче, Алла бер, Аннан бютян Алла жук диб дöрöс äйттең. 33 Аны бар кюнел белян, бар уй белян, бар жан белян, бар көч белян сöйöў, тагы жакынны ўзеңне сöйгян кюк сöйöў, бар жандырыулардан да, корманнардан да артык, дигян. 34 Iисусъ ул акыллы жауаб биргянне кюреб, аңар äйткян: син инде Алла Падшалыгыннан жырак тöгöл, дигян. Шуннан суң беряў дя Аннан сорарга кыймаган. 35 Чиркяўдя öйрятя торган көйö, Iисусъ äйткян: княгячеляр Христосны ник Давидъ улы дейляр? 36 Давидъ ўзе Святый Тын тойдорган буйынча äйтя: Ходай Минем Ходайыма äйткян: дошманнарынғны аягың астына салгынчы, Минем уң жагымда утыр [3] диб. 37 Шулай, Давидъ ўзе Аны Ходай дигяч, Ул ничек суң анын улы була? дигян. Кюб калык аны кинянеб тыңнаган.

Зач. 57. 38 Iисусъ öйрятеб, аларга былай äйткян: княгячелярдян сакланыгыз: алар озон кейем кейеб жöрöўне, урамнарда кеше башырганны, 39 Синагогаларда алда утырыуны жараталар. 40 Алар, тол катыннарнын жортларын ашаб бетереўчеляр, кюренер öчөн гня озаклаб теляк итеўчеляр, артыгырак айыбланырлар, дигян. 41 Аннары Iисусъ (чиркяўгя) акча сала торган тартма карышысында утырыб, тартмага калык акча салганны караб торган; байларнын кюбесе кюб-кюб салганнар. 42 Шунда бер жарлы гна тол катын килеб, ике лепта салган, икесе бер кодрантъ [4] була. 43 Iисусъ Ўз öйрянеўчелярен чакырыб алыб, аларга äйткян: чыннаб äйтямен сезгя: бу жарлы тол катын акча

[1] Втор 6:4-5.
[2] Лев 19:18.
[3] Пс 109:1.
[4] Кодрантъ-жарты тейен.

тартмасына салыучыларнын барысыннан да кюберяк салды. 44 Барысыда артыгы бардан салдылар шул, әммя бу жарлы көйө нейе бар барын, бар тормошон салды, дигян.

13-нче бюлем

Зач. 58. 1 Іисусъ чиркяўдян чыккан чакта, Анын өйрянеўчеляренен берсе Анар әйткян: эй Өйрятеўче! кара әле, ничек ташлар, ничек каралдылар! дигян. 2 Іисусъ анар жауаб биреб әйткян: шушы зур каралдыларны кюрясең ме? мында таш өстөндя таш та калмас, барысында жимереб бетererляр, дигян. 3 Ул Елеонъ тауы өстөндя, чиркяў карышысында утырган чакта, Петръ, Іаковъ, Іоаннъ, Андрей Аннан аулакта сораганнар: 4 Әйтче безгя, бу кайчан булыр? былар буласы чакта ничек билге булыр? дигянняр. 5 Іисусъ аларга жауаб биреб әйтя башлаган: сак булыгыз, беряў-беряў сезне жанғыштырмасын. 6 Кюбесе Минем исемем белян килерляр, мин (Христосъ) дирерляр, кюбесен жанғыштырырлар да. 7 Сугышлар булганны, сугыш хабярлярен эшеткяч, курыкмагыз, былар булырга тейеш шул; алайда ул әле бетеў төгөл. 8 Калык калыкка, падшалык падшалыкка жабышыр; урны-урны белян жир титряр, ачлыклар булыр, калык болганыр. Былар азабларнын башланыуы гна, дигян.

Зач. 59. 9 Сез ўзегез сагайыгыз: сезне шу хокөмгя тотоб бирерляр, синагогаларда кыйнарлар; Минем сяятлей сезне тюряляр алдына, падшалар алдына житякляб итярляр, алар алдында (Минем турда) таныклык итяр өчөн. 10 Элгяре бар калыкларга да Евангеліе сөйлянергя тейеш. 11 Сезне тотоб биреўчеляр анда алыб барган чакта, ней әйтербез диб көйөнмягез, алдан уйламагыз, әммя шул сагаття сезгя ней бирелер, шуны әйтегез; әйтеўчеляр сез булмассыз шул, әммя Святый Тын (әйтер). 12 Агасы энесен, атасы улын ўлемгя бирер, балалары ата-аналарына карышы тороб, аларны ўтererляр. 13 Минем исемем өчөн сезне барда кюрялмаслар; алайда калдыкка чаклы тюзгяне котолор, дигян.

Зач. 60. 14 Данiилъ пагамбяр әйткянчя, [1] жирянгеч нястяляр тороргa тейеш төгөл урында жирянгеч нястяляр торганны

[1] Дан 9:27.

кюргяч, (укыган кеше анӈасын), Іудеядя тороучылар тауларга качсыннар. 15 Öй тюбясендя булганы öйöня тöшмясен, öйöмнян бер-бер нястя алыб китейем диб кермясен. 16 Басыуда булганы, кейememне алыб китейем диб, кире кайтмасын. 17 Ул кöннярдя ауырлы катыннарга, имчяк имезеўчелярга читен булыр. 18 Качарыгызга кыш туры килмясен эйе диб телягез. 19 Ул кönняр кайгылы булыр, анын кюк кайгы Алла булдырган дöнья була башлаганнан бирле ялегя чаклы булганы жук, булмас та. 20 Ягяр Ходай ул кöннярне кыскартмаса, бер тян дя котолмас ыйы, тик Ул Ўзе сайлаган сайланганнары какына ул кöннярне кыскартыр. 21 Ул чакта беряў сезгя: мына мында Христосъ, жя ана тегендя дейся, ышанмагыз. 22 Жалган христослар, жалган пагамбярляр чыгарлар; мöӈким булса, сайланганнарны да жаӈгыштырыр öчöн, кодрятляр кюрсяткян булырлар. 23 Ämмя сез сак торогоз; мына Мин сезгя барысында алданук äйттем, дигян.

Зач. 61. 24 Ул кöннярдя шундый кайгыдан суӈ кояш карангыланыр, ай ўз жактысын жактыртмас. 25 Жондозлар кюктян койолорлар, кюктяге чиреўляр дя кузгалышырлар. 26 Аннары болотлар öстöндя зур кодрят белян, оло дан белян килеўче Ädям Улын кюрерляр. 27 Ул чакта Ул Ўз пяриштялярен жибяреб, дöньянен дюрт жагыннан да жир кырыйыннан башлаб, кюк кырыйына чаклы, сайлаганнарын жыйдырыр.

28 Смоква агачыннан ошаш алыгыз: анын ботаклары жомошаб, жапрак жара башлагач, жяй жакын икянне белясез.

29 Шунын кюк былар барысыда булганны кюргяч, инде жакын, ишек töбöндя диб белегез.

30 Чыннаб äйтямен сезгя: шушы тыума беткенче, былар барысыда булыр, дигян.

Зач. 62. 31 Кюк белян жир бетярляр, ämмя Минем сюзлярем була торор. 32 Ул кöннö, ул сагатне бяряў дя белмей, кюктяге пяриштяляр дя, Улы да (белмей), тик Ата гна (беля). 33 Карагыз, уяу торогоз, теляк итегез, ул багыт кайчан буласын белмейсез шул. 34 Ул багыт жулга киткяндя жортон калдырыб, ўз кызмятчеляреня башкарыб тороргa кушыб, äр-берсеня ўз алдына эш биреб, кабка сакчысына жокламый тороргa кушыб киткян кешегя ошаулы. 35 Алай булгач, сез уяу торогоз: жорт эясенен кич ме, тöн уртасында мы, ätяч кычкырганда мы,

иртя белян ме, кайчан килерен белмейсез. 36 Тоймастын килеб, сезне жоклаган көйö очратмасын. 37 Сезгя äйткянне буганнарга да äйтямен: уяу торогоз, дигян.

14-нче бюлем

1 Пасхага, тöчö кюмяч көнняреня ике кön калгач, архіерейляр, книгячеляр Іисусны хайля белян тотоб алыб, ўтерергя кöй эзлягянняр. 2 Алайда калык болганышмасын диб, мыны бяйрям көннö (кылмыйык) дигянняр.

Зач. 63. 3 Ул Виѳаніядя кутырлы тянне Симоннын öйöндя утырган чакта, бер катын алавастръ сауыт белян кыйбатлы нардъ майы, катыштырмаган мѵро алыб килеб, сауытын ачыб, Анын башына койган. 4 Кайсылары мыны жаратмыйчы ўз-аралый äйткянняр: ник бу мѵроны äрям итте? 5 Мыны öч жöз динарійдян дя кыйбатырак сатыб, (акчасын) сораныучыларга öляшергя мöгким эйе ич, дигянняр. Катынга зарланганнар. 6 Ämмя Іисусъ äйткян: теймягез анга, ник сез аны жöдятясез? ул Миңа жакшы эш кылды. 7 Сораныучылар жалан сезнен белян ич, телягян чагыгызда аларга жакшылык кыла алырсыз, ämмя Мин жалан сезнен белян тöгöл. 8 Ул булдыра алганын кылды, тянемне алдан майлаб, кюмяргя äзерляде. 9 Чыннаб äйтямен сезгя: бöтöн дöньядя кайда гна булса да шушы Евангеліе сöйлянелся, ул катынны иске тöшöрöргя, анын ней кылганы да äйтелер, дигян.

Зач. 64. 10 Ун икенен берсе, Искаріотъ Іуда дигяне Іисусны архіерейлярга тотоб бирергя диб, алар катына барган. 11 Алар мыны эшеткяч, сöйöнöшкянняр, анар кömöш тянкяляр бирмякче булганнар; аннары ул Аны тотоб бирергя кöйлö багыт эзлягян. 12 Тöчö кюмяч көнняренен элеке көнöндя, пасха бярянен чалыр багытта, öйрянеўчеляре Анга äйткянняр: пасханы кайда ашасы итясен? без барыб äзерлярбез, дигянняр. 13 Öйрянеўчеляренен икесен жибяреб, аларга äйткян: калага барыгыз, анда сезгя кувшинъ белян сыу кютяреб барыучы кеше очорар, анын артыннан барыгыз; 14 Ул кергян öйнöн эяценя äйтегез: Öйрятеўче: Мин öйрянеўчелярем белян пасха ашасы бюлмя кайда? диб äйтя дигез. 15 Ул сезгя идяненя жяйгян, äзерляб куйган зур бюлмя кюрсятер, безгя шунда äзерлягез,

дигян. 16 Ойрянеўчеляре киткянняр. Калага килгяч, Ул аларга айткянчя, туры китереб, шунда пасха азерлягянняр. 17 Кич булгач, Ул ун ике (ойрянеўчесе) белян килгян. 18 Ашаб утырган чакта, Іисусъ айткян: чыннаб айтямен сезгя: Минем белян бергя ашаучы, сезнен арадан беряў Мине тотоб бирер, дигян. 19 Алар кайгыга тошоб, берсе артыннан берсе Анар: мин тогол ме, мин тогол ме? диб айтя башлаганнар. 20 Ул аларга жауаб биреб айткян: ун икегезнен берсе, Минем белян бергя тозлокка мана торганы; 21 Алайда Адям Улы Ўз турында жазылганча бара, тик Адям Улын тотоб биреўчегя жаман булыр, ул кешегя тыумаганы жакшырак булыр ыйы, дигян. 22 Ашаган чакларында Іисусъ икмяк алыб, бахиллягян дя сындырыб, аларга биреб айткян: алыгыз, ашагыз, бу Минем Тянем, дигян. 23 Аннары сауытны алыб, тау итеб, аларга биргян; аннан барысыда эчкянняр. 24 Шунда Ул аларга айткян: бу Минем кюб кешеляр очон агыза торган жана законъ Каным. 25 Чыннаб айтямен сезгя: инде Мин жимеш сыуын Алла Падшалыгында жана эчемнек эчяр кономя чаклы эчмямен, дигян. 26 Аннары иман жырлагач, Елеонъ тауына киткянняр. 27 Шунда Іисусъ аларга айткян: бу тоннo сез барыгызда Минем турда шиклянерсез, жазылган шул: котоучесен уатыб бетерем, сарыклары таралыб бетярляр [1] диб. 28 Аннары терелеб торгач, Мин сезне Галилеядя карышы алырым, дигян. 29 Петръ Анар айткян: барысыда шиклянсяляр дя, мин шиклянмям, дигян. 30 Іисусъ анар айткян: чыннаб айтямен синa: син богон шушы тондя, атяч ике табкыр кычкыргынчы, Мине оч табкыр танарсын, дигян. 31 Петръ тагы бигеряк ныклаб айткян: агяр минa Синeн белян бергя улярга туры кился дя, мин Сине танмам, дигян; барысыда шулай диб айткянняр. 32 Аннары алар Геосиманія дигян урынга килгянняр, килгяч ойрянеўчеляреня айткян: Мин барыб теляк итеб килгенче, сез мында утырыб торогоз, дигян. 33 Аннары Ўзе белян бергя Петрны, Іаковны, Іоанны алыб киткян дя куркыныб коёня башлаган. 34 Аларга айткян: Минем жаным ўлярлек булыб кoя, сез мында тора тороб, уяу торогоз, дигян. 35 Аннары бер аз китеб, жиргя жыгылыб, монким булса, бу сят Миннян узсын ыйы диб,

[1] Зах 13:7.

инялеб 36 Йайткян: эй Авва Ятей! Синӈа барда мӧнӈким, бу сауытны Миннян уздыр, алайда Мин телягянчя тӧгӧл, ӓммя Син телягянчя (булсын), дигян. 37 Аннары кайтыб, ӧйрянеӱчеляренен жоклаб жатканнарын очратыб, Петрга ӓйткян: Симонъ! жоклойсын меней? син бер гня сагат тя уяу тора алмадыӈ меней? 38 Алданмас ӧчӧн, уяу торогоз, теляк итегез, тын уяу, ӓммя тян халсез, дигян. 39 Тагы китеб, шул сюзне ӓйтеб инялгян. 40 Кайтыб, аларны тагы жоклаган кӧйӧ очраткан, аларнын кюзлярен жоко баскан икян шул; алар Анӈар ней жауаб бирергя дя белмягянняр. 41 Аннары ӧчӧнчӧ табкыр килеб, аларга ӓйткян: сез ӓле гел жоклаб жатасыз икян; бетте инде, сагат житте; мына Ӓдям Улы жазыклылар кулына тотоб биреля. 42 Торогоз, ӓйдягез, мына Мине тотоб биреӱче жакынна-шты, дигян.

Зач. 65. 43 Ул мыны ӓйткян сяттюк, ун икенен берсе Іуда килеб житкян; анын белян бергя архіерейлярдян, княгячелярдян, калык башлыкларыннан жибярелгян кюб калык кылычлар, казыклар алыб (килгянняр). 44 Аны тотоб биреӱче аларга былай ӓйтеб билге куйган: мин Кемне ӱбсям, шул Ӱзе, Аны тотоб алыгыз да саклаб кна алыб китегез, дигян. 45 Килеӱ белян Анӈар жакыннашыб, эй Равви, Равви! [1] диб Аны ӱбкян. 46 Аннары Аны куллары белян тотоб алганнар. 47 Шунда тороучыларнын берсе кылычын сыуырыб алыб, архіерей колонон колагын чабыб ӧзгян. 48 Шунда Іисусъ аларга ӓйткян: талаучыга чыккандый, кылычлар, казыклар алыб, сез Мине тотоб алырга чыккан. 49 Чиркяӱдя ӧйряткян чагымда, Мин кӧндя сезнен белян булдым, ӓммя сез Мине тотоб алмадыгыз; жазылганы жиреня килсен инде, дигян. 50 Ул чакта (ӧйрянеӱчеляре) барда Аны калдырыб качканнар. 51 Бер жегет жалангач тян östӧннян жабынгыч бӧркянеб, Анын артыннан барган; салдатлар ул жегетне тотканнар, 52 Тик ул жабынгычын калдырыб, алардан жалангач кӧйӧ качкан. 53 Іисусны архіерей катына алыб килгянняр; анӈар бар архіерейляр, княгячеляр, калык башлыклары жыйылганнар. 54 Петръ жырактын Анын артыннан архіерей жортона кергенче барган; анда кызмятчеляр белян бергя ут жанында жылыныб утырган. 55 Архіерейляр белян бӧтӧн синедріонъ Іисусны ӱтерер ӧчӧн,

[1] Равви-ӧйрятеӱче.

Анҕар карышы таныклык эзлягянняр, тик таба алмаганнар. 56 Кюбесе Анын өстөннян жалган таныклык иткянняр, тик бу таныклыклары житярлек булмаган. 57 Кайсылары тороб, Анын өстөннян жалган таныклык итеб äйткянняр: 58 Без Анын: шушы кул белян торгозган чиркяўне жимерем дя өч көннян суҥ кул белян торгозмаган бютян чиркяў торгозормын диб äйткянен эшеттек, дигянняр. 59 Андый таныклыклары да житярлек булмаган. 60 Аннары архіерей уртага тороб, Іисустан сораган: быларнын Синҕа карышы таныклауларына Син ник бер жауаб та бирмейсен? дигян. 61 Ämмя Ул дяшмягян, бер жауаб та бирмягян. Архіерей тагы сораб äйткян: Даннаулынын Улы Христосъ Син ме? дигян. 62 Іисусъ äйткян: Мин диб, мына Кодрятленен уҥ жагында утырыучы Ädям Улынын кюк болотлары өстөндя килгянен кюрерсез, дигян. 63 Шул чакта архіерей ўз кейемнярен жыртыб äйткян: тагы безгя нейгя таныкчылар? 64 Алланы курлаганны эшеттегез, сезгя ничек тея? дигян; алар барысыда: Аны ўтерергя тейеш дигянняр. 65 Аннары кайсылары Анҕар төкöря башлаганнар, жöзöн бöркяб, Анҕар сугыб, белеб äйт! дигянняр. Кызмятчеляр дя Анын жанҕакларына сукканнар. 66 Петръ тюбян, ишек алдында утырган чакта, архіерейнен бер катын кызмятчесе килгян дя, 67 Жылыныб торган Петрны кюреб, анҕар тегяляб караб äйткан: син дя Іисусъ Назарянинъ белян эйеҥ, дигян. 68 Ул танҕыб, син ней äйткянне белмейем, анҥамыйым дигян дя алдагы ишек алдына чыккан: шул сяттюк ätяч кычкырган. 69 Кызмятче катын аны тагы кюреб, шунда тороучыларга äйтя башлаган; бу алар арасыннан диб. Ул тагы танҕан. 70 Бер-ауыктан суҥ, шунда тороучылар Петрга тагы äйткянняр: чыннаб син алар арасыннан, син Галилеянеке, сöйляшеўеҥ дя шулай, дигянняр. 71 Ämмя ул: сез äйтя торган кешене белмейем диб карганыб танҕа башлаган. 72 Шундук ätяч икенче табкыр кычкырган. Петръ Іисуснын анҕар: ätяч ике табкыр кычкыргынчы, син Мине öч табкыр танҕарсын диб äйткян сюзен исеня төшöргян дя жылый башлаган.

15-нче бюлем

Зач. 66. 1 Шундук иртя белян архіерейляр, калык башлыклары, книгячеляр, бөтөн синедріонъ киңяш иткянняр дя, Іисусны бяйляб, Пилатка итеб биргянняр. 2 Пилатъ Аннан сораган: Син Іудея Падшасы мы? диб. Ул аңар жауаб биреб әйткян: (дөрөс) әйтясен, дигян. 3 Архіерейляр Аны кюб туры белян айыблаганнар. 4 Пилатъ Аннан тагы сораган: Син бер жауаб та бирмейсен ме? кара, Синa карышы ней чаклы таныклык итяляр? дигян. 5 Әммя Іисусъ мыңар да бер жауаб та бирмягян; Пилатнын шуңар бик исе киткян. 6 Ул аларга бяйрям сайын быгаудагыларнын берсен, алар сораганын жибяря икян. 7 Шул чакта бер Варавва атлы кеше ўз иптяшляре белян быгауда тора икян, алар калык болганышкан чакта, кеше ўтергянняр икян. 8 Калык Пилаттан ул аларга жалан кыла торганын кылсын диб кычкырыб сорой башлаган. 9 Пилатъ аларга жауаб биреб әйткян: телеймесез, мин сезгя Іудея Падшасын жибярем? дигян. 10 Ул архіерейлярнен Аны көнчөлөк белян тотоб биргяннярен белгян икян. 11 Әммя архіерейляр калыкны: безгя Варавваны жибяргянең жакшырак диб әйтергя котортканнар. 12 Пилатъ аларга тагы әйткян: сез Іудея Падшасы диб атый торганга мин ней кылсын диб телейсез? дигян. 13 Алар: Аны кадаклат! диб кычкырганнар. 14 Пилатъ аларга әйткян: Ул ничек усаллык кылды суң! дигян. Әммя алар: Аны кадаклат! диб бигеряк тя шяб кычкырганнар! 15 Аннары Пилатъ калык телягянне кылыйым диб, аларга Варавваны чыгарыб биргян, әммя Іисусны кыйнатыб, кадакларга биргян.

Зач. 67. 16 Салдатлар Аны жорт эченя, преторія дигян урынга житякляб китергянняр дя шунда бөтөн полкны жыйганнар. 17 Іисусны кызыл кейемгя кейендергянняр: башына чянечкеле агач чыбыгыннан ўрмя ўреб кейгезгянняр; 18 Аннары Анын белян исянняшкян булыб, эй Іудея Падшасы, сөйөн! диб әйтя башлаганнар. 19 Анын башына таяк белян сукканнар. Аңар төкөргянняр, алдында тезлянеб тороб, башырганнар. 20 Аны мыскыллаб туйгач, өстөннян кызыл кейемне салгызыб, Аңар Ўз кейемен кейгезгянняр: аннары Аны кадакларга алыб киткянняр. 21 Басыудан кайтыб узыб барыучы беряўгя, Киринеянеке Александръ белян

Руөъ атасы Симонга, Іисуснын качын кютяртеб баргызганнар.

Зач. 68. 22 Іисусны Голгоөа исемне Мангай урны дигян жиргя алыб килгянняр. 23 Анда Анҕар эчяргя смѵрна катыштырган аракы биргянняр, тик ул аны алмаган. 24 Аны кадаклаучылар, кемгя ней теяр диб, Анын кейемняреня жирябя салганнар, (жирябя чыкканча) öляшкянняр. 25 Öч сагат тирясе икян. Аны кадаклаганнар. 26 Айыбы Іудея Падшасы диб жазыб куйылган. 27 Анын белян бергя ике талаучыны кадаклаганнар: берсен уҥ жагына, икенчесен сул жагына. 28 Жазыудагы сюзнен: усаллар белян тингя саналган [1] дигяне жиреня килгян. 29 Жаныннан узыучылар башларын селкеб, Аны курлаб äйткянняр: эй чиркяўне жимереб, öч көндя торгозоб житкезеўче! 30 Ўзеҥне коткар, качтан төш, дигянняр. 31 Архіерейляр белян книгячеляр дя шулай мыскыллаб, бер-берсеня äйткянняр: бютяннярне коткарган, ämмя Ўзен коткара алмый. 32 Израиль Падшасы Христосъ инде качтан төшсön, без дя кюрер эйек, аннары ышаныр ыйык, дигянняр. Анын белян бергя кадакланганнар да Аны курлаганнар. 33 Алтынчы сагаттян тугызынчы сагаткя чаклы бötön жир öстöндя карангы булыб торган. 34 Тугызынчы сагаття Іисусъ каты тауыш белян кычкырыб äйткян: Элои! Элои! лама савахөани? диб, бу: эй Аллам! эй Аллам! Син Мине ник ташладын? дигян сюз була. 35 Мыны эшетеб, шунда тороучыларнын кайсылары äйткянняр: мына Иліяны чакыра, дигянняр. 36 Берсе жögöröб барыб, болотка серкя сеҥдереб, аны таякка элеб, Анҕар эчяргя биреб äйткян: туктагыз äле, караб торойок, Илія Аны (качтан) алырга килер микян? дигян. 37 Аннары Іисусъ тагы каты кычкырыб, тынын чыгарган. 38 Шул чакта чиркяў шаршауы жугары кырыйыннан тюбян кырыйына чаклы икегя айырылган. 39 Іисусъ карышысында тороучы сотникъ, Ул тынын шулай кычкырыб чыгарганны кюреб äйткян: чыннаб бу кеше Алла Улы икян, дигян. 40 Анда тагы жыраклын караб тороучы катыннар да булганнар, алар арасында Марія Магдалина, кече Іаковъ белян Іосія анасы Марія, тагы Саломія да булган; 41 Алар Іисуска Галилеяда чагында эяреб жöрöб, Анҕар кызмят иткянняр; анда тагы Анын белян бергя Іерусалимгя килгян бютян катыннар да кюб булган. 42 (Ул пятница суббота алдында-

[1] Ис 53:12.

гы кӧн булганга кюря), кич булгач.

Зач. 69. 43 Аримаѳеянын Іосифъ килгян, ул бик кадерле киҥяшче икян, ӱзе Алла падшалыгын кӧтя икян; ул кыйыуланыб Пилатка кереб, Іисуснын тянен сораган. 44 Іисусъ тиз ӱлгянгя Пилатнын исе киткян; сотникны чакырыб алыб, аннан: кюбтян ӱлде ме? диб сораган. 45 Сотниктан белгяч, тянне Іосифка биргян. 46 Іосифъ киндер сатыб алыб, Іисусны качтан алыб, киндергя тӧрӧб, таш тауга тишеб жасаган кабергя куйган, кабер ауызына таш каблаган. 47 Марія Магдалина белян Іосія Маріясы Аны кайда куйганны караб торганнар.

16-нчы бюлем

Зач. 70. 1 Суббота ӱткяч, Марія Магдалина, Іаковъ Маріясы, тагы Саломія барыб Іисуска сӧртӧргя диб, эйесле май сатыб алганнар. 2 Атнанын элекеге кӧнӧндя, бик иртя белян, кояш чыккан чакта, алар кабер катына килгянняр. 3 Килгяндя бер-берсе белян: безгя кабер ауызындагы ташны кем аударыр икян? диб сӧйляшкянняр. 4 Килеб карасалар, кюряляр, таш аударылган, ӓммя ул бик зур икян. 5 Кабергя кергяч, алар уҥ жакта утырган, ак кейем кейгян жегетне кюргянняр; бик курыкканнар. 6 Ул аларга ӓйткян: курыкмагыз, сез кадакланган Іисусъ Назарянинны эзлейсез; Ул терелеб тордо, мында жук, мына Аны куйган урын. 7 Ӓммя сез барыгыз, Анын ӧйрянеӱчеляреня, Петрга да ӓйтегез: Ул сезне Галилеядя карышы алыр, Ӱзе сезгя ӓйткянчя, Аны анда кюрерсез, дигез. 8 Алар чыгыб, кабер жаныннан жӧгӧрӧшӧб киткянняр; алар бик курыкканнар, калтрашканнар; курыкканныктан беряӱгя дя бер сюз дя ӓйтмягянняр.

Зач. 71. 9 Атнанын элекеге кӧнӧндя иртюк, терелеб торгач, Іисусъ иҥ элеке Марія Магдалинага кюренгян, Іисусъ аннан жиде женне кыуалаб чыгарган икян. 10 Ул кайтыб мыны Іисусъ белян жӧргяннярга, сулкылдаб жылаучыларга белдергян. 11 Ӓммя алар, анын: Іисусъ тере, мин Аны кюрдем дигянен эшетеб, ышанмаганнар. 12 Аннан суҥ Іисусъ ӧйрянеӱчеляренен икесеня жулда, бер ауылга барган чакларында, бютян тӧслӧ булыб кюренгян. 13 Алар да кайтыб, бютяннярга белдергянняр, ӓммя алар быларга да ышанма-

ганнар. 14 Калдыгында Ул ун бер (öйрянеўчесеня), бергя утырган чакларында кюренеб, ышанмаганнары öчöн, кюнгеллярен каты тотканнары öчöн, Аны терелеб торгач кюреўчелярга дя ышанмаганнары öчöн, аларны ярлягян. 15 Аннары аларга айткян: бötöн дöньягя жöрöб, булдырылганнарнын барысынада Евангеліене сöйлягез. 16 Ышанган кеше, чумылдырылган кеше котолор, ямма ышанмаган кеше айыблы булыр. 17 Ышанганнарга мындый билгеляр булырлар: Минем исемем белян женнярне кыуалаб чыгарырлар, жанa телляр белян сöйляшерляр; 18 Жыланнарны кулга алырлар, бер-бер ютергеч нястя эчсяляр дя, аларга зыян теймяс; чирлеляр östöня кулларын салырлар, алар сауыгырлар, дигян. 19 Шулай итеб, Ходай, öйрянеўчеляре белян сöйляшкяннян суң, кюкя кютярелеб, Алланын уң жагыннан утырган. 20 Ямма алар китеб, яр-бер жирдя Евангеліене сöйлягянняр; Ходай аларга булышкан, сюзне шундук булган билгеляр белян ныклаган. Аминь.

ЛУКА ЖАЗГАН АРЫУ ЕВАНГЕЛІЕ

1-нче бюлем

Зач. 1. 1 Безнен арада бӧтӧнняй билгеле эшляр турысында кюбесе инде сӧйляӳ тӧзӧй башладылар; 2 Безгя ул эшлярне Сюзне баштанук кюреӳчеляр, (Аҥар) кызмят итеӳчеляр айтеб бирделяр; 3 Шуҥар кюря, эй кадерле Ѳеофилъ, барысында баштанук тырышыб тикшергяч, мин дя синҥа ряттян жазасы иттем, 4 Синҥа элеке ӧйряткян нястянен ныk тӧбӧн белсен диб.

Зач. 2. 5 Іудея падшасы Иродъ кӧнняренда Авія няселенен чиратында Захарія атлы священникъ булган; анын катыны Ааронъ няселеннян икян, исеме Елисавета атлы булган. 6 Алар Ходайнын бар бойороклары, дӧрӧсляндергечляре буйынча шиксез тороб, икесе дя Алла алдында дӧрӧс булганнар. 7 Аларнын балалары булмаган. Елисавета бала тыудырмый икян, икесе дя кюб жяшяб картайганнар икян. 8 Бер табкыр Захарія ӳз чиратында Алла алдында чиркяӳ кызмятен иткян чакта, 9 Священникляр арасында булган жолача, жирябя сикерткяч, аҥар Ходай чиркяӳеня кереб, ладанъ эйесе чыгарыу ряте тейгян. 10 Ладанъ эйесе чыгарган чакта, кюб калык барда тыш бюлемдя теляк иткян. 11 Шул чакта аҥар ладанъ жандыра торган урыннын уҥ жагында Ходай пяриштясе кюренгян. 12 Захарія аны кюргяч, жӧдяб киткян, аҥар куркыу тӧшкян. 13 Ӓммя пяриштя аҥар айткян: курыкма Захарія, синеҥ теляген эшетелде, катыныҥ Елисавета синҥа ул тыудырыр, аҥар Іоаннъ диб ат куярсын. 14 Синҥа сӧйӧнӧч, кыуаныч булыр; анын тыуыуына кюб кешеляр сӧйӧнӧрляр. 15 Ул Ходай алдында оло булыр; аракыны да, ӳнгя исерткеч эчемнекне дя эчмяс, анасы эченнянюк Святый Тынга тулыланыр. 16 Израиль улларынын кюбесен Ходай Аллаларына кайтарыр. 17 Анын алдыннан Илія тыныдый тын белян, анын кыуатыдый кыуат белян, аталарынын кюҥеллярен

балаларына бороргa, карыш кешелярне гаделляр белян бер уйлы итяргa, äзерлягян калыкны Ходайга китереб куярга килер, дигян. 18 Захарія пяриштягя äйткян: мин мыны нейдян белерем? мин ўзем дя карт, катыным да картайыб беткян инде, дигян. 19 Пяриштя анăр жауаб биреб äйткян: мин Алла алдында тороучы Гавріилъ, мине Алла синеҥ белян сöйляшергя, синă бу арыу хабярне äйтергя жибярде. 20 Мына син шушы äйткян сюзляремнен ўз багытында булырына ышанмаганыҥ öчöн, шул эш буласы кöнгя чаклы дяшмей торорсон, сöйляшя дя алмассын, дигян. 21 Ул арада калык Захаріяны кötöб заркыб торган, ул чиркяўдя озаклагангa абтраб торганнар. 22 Ämмя ул чыккач, алар белян сöйляшя алмаган, чиркяўдя анăр кюренеў булганын белгянняр; аларга билгеляр белян гня анҥнаткан; шуннан суҥ ул телсез булыб торган. 23 Кызмят итя торган кöнняре ўткяч, ул ўз öйöня кайткан.

Зач. 3. 24 Шул кöннярдян суҥ анын катыны Елисавета буйга узган; биш ай кешегя белдермягян, ул äйткян: 25 Кешеляр арасындагы курлыгымны алыр öчöн, шушы кöннярдя Ходай минă шулай кылгандыр, дигян. 26 Алтынчы айда Алладан Гавріилъ пяриштя Галилеядяге Назаретъ дигян калага, 27 Давидъ няселеннян чыккан Іосифъ атлы иргя жяряшелгян кызга жибярелгян, кызнын аты Марія. 28 Пяриштя анын катына кереб äйткян: эй дяўлятле, сöйöн! Ходай Синеҥ белян; Син катыннар арасында даннаулы, дигян. 29 Марія аны кюргяч, анын сюзляреннян жöдяб киткян: былай äйтеб кюрешеўе ней белдереўе икян? диб уйлаб торган. 30 Пяриштя Анăр äйткян: эй Марія, курыкма! Син Алла алдында дяўлят табтыҥ. 31 Мына Син буйга узыб, Ул тыудырырсын, Анăр Іисусъ диб ат куярсын. 32 Ул оло булыр, Жугарыгынын Улы диб аталыр, Ходай Алла Анăр атасы Давиднын престолын [1] бирер; 33 Ул Іаковъ тыумасына гумергя падшалык итяр, Анын падшалыгы ич тя бетясе тöгöл, дигян. 34 Марія пяриштягя äйткян: минă ир жакыннашмаган кöйö, бу ничек булсын? дигян. 35 Пяриштя Анăр жауаб биреб äйткян: Синă Святый Тын инҙяр, Сине Жугарыгынын кыуаты бöркяр, шул сяятлей тыуасы Изге дя Алла Улы диб äйтелер. 36 Мына Синеҥ бала китермей диб äйтеля торган карендяшеҥ Ели-

[1] Падшалыгын.

савета, ул да картайган көнөндя буйга узыб улланды, аңар инде алтынчы ай; 37 Алланын бер гня сюзе дя булмый калмас шул, дигян. 38 Аннары Марія әйткян: мына мин Ходай мяндясе, айса миңа син әйткянчя булсын, дигян. Шуннан ары пяриштя Анын катыннан киткян.

Зач. 4. 39 Шул көннярдя Марія тороб, таулар жагына Іуда каласына ашыгыб барган. 40 Захарія өйөня кергяч, Елисавета белян исянняшкян. Елисавета Маріянын исянняшкянен эшеткяч, 41 Елисавета эчендяге бала уйнаклаб киткян; Елисавета Святый Тынга тулыланыб, 42 Зур тауыш белян кычкырыб әйткян: Син катыннар арасында даннаулы, Синнян тыуасы да даннаулы! 43 Ходайымнын Анасы миңа килеүе бу миңа ничек булды? 44 Исянняшкян тауышыңны колагым эшеткячтюк, эчемдяге балам сөйөнөб уйнаклады. 45 Ышанган Син, бахетле, Синга Ходайдан әйтелгян жиреня килер шул, дигян. 46 Шул чакта Марія әйткян: минем жаным Ходайны данный, 47 Минем кюңелем Коткарыучы Аллама сөйөня; 48 Ул Үз мяндясенен жыуашлыгына кюз салды, мыннан былай бар затлар да мине даннарлар шул; 49 Кодрятле миңа зурлык бирде, Анын исеме арыу. 50 Аннан куркыучыларга Анын изгелеге тыумыштан тыумышка тора. 51 Ул Үз кулынын кыуатын кюрсятте; кюңелляре олосомак уйлыларны таратты. 52 Кочлөлярне престолларыннан төшөргян, әммя жыуашларны кютяргян. 53 Ачыкканнарны дяүляткя туйдырган, әммя байсымакларны коро калдырган. 54 Үз мяндясе Израилне кабыл алды, 55 Аталарыбызга әйткянчя, Авраамга, анын няселеня мянгегя кыласы изгелеген исеня төшөрдө, дигян. 56 Марія анын белян өч айлаб торган, аннары өйөня кайткан. 57 Елисаветанын тыудырыр багыты житкян; ул ул тыудырган. 58 Кюрешеляре белян карендяшляре, Аңар Ходай зур изгелек кылганны эшетеб, анын белян бергя сөйөнөшкянняр. 59 Сигезенче көнөндя балага кисеү кыларга килгянняр; аны атасы исеме белян Захарія диб атамакчы булганнар. 60 Мыңар анасы әйткян: жук, ул Іоаннъ диб аталсын, дигян. 61 Аңар әйткянняр: няселендя андый исем белян атала торган беряү дя жук, дигянняр. 62 Аннары аңар ничек исем бирясе киля икян диб, атасыннан билгеляр белян сораганнар. 63 Захарія кечкеня гня такта сораб алган да: анын исеме Іо-

аннъ диб жазыб биргян. Барысынында исляре киткян. 64 Шул сяттюк анын ауызы, теле ачылган; ул аннары Алланы даннаб, сöйляшя башлаган. 65 Аларнын тиря жагында тороучыларнын барысынада куркыныч тöшкян; мынын барысы турысында да Іудеянен бötön таулык жагында сöйляшкянняр. 66 Эшетеўчеляр барысыда мыны кюнгелляреня салыб, бу бала нейдей булыр икян? дигянняр. Анда Ходайнын кулы торган. 67 Анын атасы Захарія Святый Тынга тулыланыб, пагамбярлек итеб айткян: 68 Израиль Алласы Ходай даннаулы, Ул Ўз калкына килеб, Анар котолоу кылды шул. 69 Ўз мяндясе Давидъ жортоннан безгя Коткарыучы чыгарды; 70 Аўäледянюк булган изге пагамбярляренен ауызыннан белдергянчя, 71 Безне дошманнарыбыздан, безне кюрялмый тороучыларнын барысынында кулыннан коткарасысын, 72 Аталарыбызга изгелек кыласысын, Ўзенен изге багадясен исеня алырын, 73 Атабыз Авраамга карганыб айткянен, 74 Безне, дошманнарыбыз кулыннан котолгач, курыкмыйчы. 75 Гумеребезнен бар könнярендя дя Ўз алдында арыулык белян, дöрöслöк белян Ўзеня табындыртасын (исеня тöшöрдö). 76 Эй бала, син дя Жугарыгынын пагамбяре диб айтелерсен, син шу Ходай алдыннан килеб, Анар алдан жул äзерлярсен, 77 Анын калкына жазыклары кичелеб котолоуны ангартырсын, 78 Аллабызнын арыу кюнгеленен изгелеге буйынча (котолоуны) ангартырсын; шул (изгелеге буйынча) безгя жугартын Кояш чыгышы, 79 Карангыда, ўлем карангысында утырыучыларны жактыртырга, аякларыбызны тыныч жулга ынгайларга килде. 80 Бала ўз-кöйö белян ўскян, тыны ныкланган; аннары Израилгя кюренер könöня чаклы буш кырларда торган.

2-нче бюлем

Зач. 5. 1 Шул könнярдя кесарь Августъ бötön жирдяге калыкны тикшереб жазарга кушкан. 2 Бу жазыу Кириній Сирія жирен биляб торганда элекенче жазыу булган. 3 Шул чакта барысыда жазылырга барганнар, äр-кайсы ўз каласына (барган). 4 Шулай Іосифъ та Галилеядан, Назаретъ каласыннан Іудеяга, Давиднын Виөлеемъ атлы каласына барган, ул шу Давидъ жортоннан, анын няселеннян икян. 5 Жазылырга диб ул ўзеня

жяряшелгян катыны Маріяны да алыб барган; Марія (ул чакта) жöклö икян. 6 Алар анда чагында, Анын тыудырыр багыты житкян. 7 Ул шунда ўзенен элек Улын тыудырган, Аны биляб, утлыкка салган, узгынчылар керя торган öйдя аларга урын табылмаган шул. 8 Ул жактагы кырда кötöўчеляр булганнар, алар тöння ўз кötöўлярен саклаб торалар икян. 9 Кинят аларга Ходай пяриштясе кюренгян, шундук аларга Ходайнын даны жактырган; алар бик курыкканнар. 10 Пяриштя аларга äйткян: курыкмагыз, мин сезгя зур сöйöнöч äйтям, ул бар кешелярга дя булыр: 11 Бögön сезгя Давидъ каласында Коткарыучы тыуды, Ул Ходай Христосъ Ўзе. 12 Мына сезгя билге: биляб салган köйö утлыкта жата торган Баланы очратырсыз, дигян. 13 Кинят ул пяриштя белян кюктяге бик кюб чиреўляр кюренеб, Алланы даннаб жырлаганнар: 14 Шököр жугарыгы Аллага, жир öстöндя тынычлык, кешелярга арыу ризалыгы диб. 15 Пяриштяляр алар катыннан кюккя кютярелгяч, кötöўчеляр бер-берсеня äйткянняр: äйдягез Виθлеемга, анда ней булганны кюрейек, безгя Ходай ней белдерде икян? дигянняр. 16 Алар ашыгыб барганнар да Марія белян Іосифны, тагы утлыкта жата торган Баланы очратканнар. 17 Кюргяч, Ул Бала турысында аларга ней белдерелгянне äйтеб биргянняр. 18 Эшетеўчелярнен барысынында аларга кötöўчеляр äйткян сюзлргя исляре киткян. 19 Ämмя Марія бу сюзлярне барысында ўз кюнгеленя салыб, исеннян жибярмей тоткан.

Зач. 6. 20 Кötöўчеляр ўзляреня äйтелгянчя барында эшеткянняреня, кюргянняреня Алланы даннаб, мактаб, кире кайтканнар. 21 Сигез көннян сунг, Баланы кистерер багыт житкяч, Аны анасы эчендя була башлагынчук пяриштя атаганча, Іисусъ диб атаганнар.

Зач. 7. 22 Моисей законы буйынча, тазарыу көнняре тулгач, алар [1] Аны Ходай алдына куярга диб, Іерусалимгя алыб килгянняр. 23 Ходай законында блай жазылган: элеке тыуган ир баланын äр-берсе Ходайга аталсын [2] диб. 24 Алар тагы Ходай законында äйтелгянчя, корманга ике кюгярчен, жя ике бала кюгярчен китерергя [3] диб килгянняр.

Зач. 8. 25 Ул чакта Іерусалимдя Симеонъ атлы кеше бул-

[1] Бала Іисуснын аталары
[2] Исх 13:2.
[3] Лев 12:6-8.

ган; ул гадел, изге тормошло, Израилнен сöйönöчön кötöб тороучы кеше икян; анда Святый Тын торган. 26 Анар Святый Тын элекюк айткян икян: Ходайнын Христосын кюрмейче ўлмяссен диб. 27 Тын тойдорган буйынча, ул чиркяўгя килгян. Бала Иисуска законъ жоласын кылар öчön, атасы белян анасы Аны чиркяўгя алыб килгяч, 28 Симеонъ Аны кулына алыб, Аллаы даннаб айткян: 29 Эй Ходай! Ўзең айткян буйынча, казер мин мяндяґне тынычландырыб жибярсен: 30 Инде минем кюзлярем 31 Син бар калыкларнын кюзе алдында äзерлягян коткарыуны, 32 Жалган деннелярне жактыртасы жактыны, Ўз калкыґ Израилнен данын кюрделяр, дигян. 33 Иосифнын да, Бала анасынын да Анын турысында алай айткянгя исляре киткян. 34 Симеонъ аларны бахиллягян; аннары Бала анасы Маріяга айткян: мына Бу Израиллярнен кюбесенен жыгылырына, торорона, кешелярнен Анын турысында сюзгя килереня жата. 35 Синеґ ўзеґнен дя ўзягеґнян кылыч ўтяр. Шулай кюб кюґеллярнен уйлары кюренер, дигян. 36 Анда Ассиръ рыуыннан чыккан Фануилъ кызы, катын пагамбяр Анна да бар икян; ул иргя китеб, ире белян жиде жыл торгач, тол калган, бик озак жяшяб картайган; 37 Тол köйö сиксян дюрт жяшкя житкян, тön, кön ураза тотоб, телякtя тороб, Аллага кызмят итеб, жалан чиркяўдя булган. 38 Шул чакта ул да жакын килеб, Ходайны даннаб Іерусалимъ кешеляренен коткарыуны кötöб торганнарынын барысынада Бала туры-сында сöйлягян. 39 Ходай законынча барында кылыб бетергяч, алар Галилеяга ўз калалары Назаретка кайтканнар. 40 Бала Ўз köйö белян ўскян, тыны ныкланган, белемнеккя тулыланган, Анда Алланын дяўляте торган. 41 Жыл сайын атасы белян анасы Іерусалимга Пасха бяйряменя жöргянняр. 42 Ул ун ике жяшендя чагында, алар шулай жолача тагы Іерусалимга бяйрямгя килгянняр. 43 Бяйрям кönняре ўткяч, öйгя кайткан чакта, бала Иисусъ Іерусалимда калган; анасы да Иосифъ та мыны белмягянняр, 44 Ämмя Ул бютян кешеляр белян киля торгандыр диб уйлаганнар. Кönnök жулны ўткяч, Аны карендяш-рыулары, белешляре арасыннан эзлей башлаганнар. 45 Табмагач, Аны эзляб, кире Іерусалимга кайтканнар. 46 Öч кönнян суґ Аны чиркяўдя очратканнар, Ул анда öйрятеўчеляр арасында аларны

тыңнаб, алардан сораб утыра икян. 47 Тыңнаучылар барысыда Анын акылына, биргян жауабларына исляре китеб торганнар. 48 (Атасы, анасы да) Аны кюргяч, исляре киткян. Анасы Аңар йткян: эй Улым! Син безгя ник былай кылдың? Мына атаң да, мин дя сине бик көйөнөб, эзляб жөрдөк, дигян. 49 Ул аларга йткян: ник суң сез Мине эзлядегез? сез ялля Миңа Атамнын кында булырга тейеш икянен белмядегез ме? дигян. 50 Ммя алар Ул аларга йткян сюзлярне аңнамаганнар. 51 Аннары Ул алар белян бергя китеб, Назаретка кайткан; анда аларга баш салыб торган. Анасы бу сюзлярне барысында ўз кюңелендя саклаб тоткан. 52 Ммя Іисусъ белемнекя дя буйга да ўсеб, Аллага да, кешелергя дя сөйөклө булган.

3-нче бюлем

Зач. 9. 1 Тиверій кесарнен падшалык итеўенен ун бишенче жылында, Іудеяда Понтій Пилатъ башлык булыб торганда, Галилеяда дюртенче өлөш падшасы булыб Иродъ торганда, анын агасы Филиппъ Итурея белян Трахонитъ жирендя дюртенче өлөш падшасы булыб торган чакта, Лисаній Авилинея жирендя дюртенче өлөш падшасы булыб торган чакта, 2 Анна белян Каіафа архіерейляр багытында, Захарія улы Іоаннга буш кырда Алладан сюз булган. 3 Шул чакта Іоаннъ жазыклар кичелер өчөн тяўбя итеў чумылдырыуын сөйляб, Іорданнын бөтөн тиря-жюнендя жөргян. 4 Бу турда Исаія пагамбяр сюзляренен книгясендя блай диб жазылган: Ходайга жул әзерлягез, Аңар туры сукмаклар жасагыз диб буш кырда кычкырыучынын ауазы диб; 5 Әр-бер жылга тулыб торсон, әр-бер тау да, тюбя жир дя тябяняклянсен, кыйык төшляр төзлянсенняр, шома төгөл жуллар шомарсыннар; 6 Аннары әр-бер тян Алланын коткарыуын кюрер, [1] диб. 7 Іоаннъ ўзеня чумылырга килгян калыкка йткян: эй жылан тыумалары! буласы кыйыннан качарга сезгя кем йтте? 8 Тяўбягя тейешле жимеш булдырыгыз; безнен атабыз Авраамъ диб кюңелегездя уйламагыз, мин сезгя йтямен: шушы ташлардан Авраамга балалар булдырырга Алланын кыуатыннан киля дим. 9 Балта инде агач төбөндя жата: жакшы жи-

[1] Ис 40:3-5.

меш китермей торган агачнын äр-кайсын кисяляр дя утка ташлыйлар, дигян. 10 Калык аннан: без суҥ ней кылыйык? диб сораган. 11 Ул аларга жауаб биреб äйткян: кемнен ике кейеме бар, ул аны кеймсезгя бирсен; кемнен ашамныгы бар, ул да шулай итсен, дигян. 12 Мытарлар да чумылдырылырга диб килеб, анар äйткянняр: эй öйрятеўче, без ней кылыйык? дигянняр. 13 Ул аларга жауаб биргян: алырга куйылганнан артыгын алмагыз, дигян. 14 Салдатлар да шулай аннан: без ней кылыйык? диб сораганнар. Ул аларга äйткян: беряўне дя рянжетмягез, äляклямягез, ала торган жалыгызга тук булыгыз, дигян. 15 Калык Мессіяны көтöб торганныктан, барысыда ўз кюҥелляренда Іоанны: бу Христосъ тöгöл микян? диб уйлаганнар. 16 Іоаннъ барысынада äйткян: мин сезне сыуда чумылдырам, ämмя миннян Кыуатлы киля, мин Анын башмагынын кайышын чишяргя дя тормоймын, Ул сезне Святый Тын белян, ут белян чумылдырыр. 17 Анын көряге кулында: Ул ындырын äрчер, бодайын клятеня жыяр, ämмя саламын сюнмяс утта жандырыр, дигян. 18 Калыкны öйрятеб, ул аларга бютян кюб сюзляр дя сöйлягян.

Зач. 10. 19 Іоаннъ дюртенче ölöшнö биляб тороучы Иродны, агасы катыны Иродіада сятлей, тагы бютян törлö жаман эшляре öчön дя оялтканга кюря, 20 Иродъ бар усал эшляреня öстяб, Іоанны öтörмянгя жабтырган. 21 Бар калык та чумылдырылгач, Іисусъ та чумылдырылганнан суҥ теляк иткян чакта, кюк ачылган, 22 Святый Тын кюгярчен ряўешле тянне булыб, Анын öстöня ингян, кюклярдян ауаз булган: Син Минем сöйöклö Улым, Синдя Минем ризалыгым! диб.

Зач. 11. 23 Іисусъ Ўз кызмятен итя башлаган чагында, утыз жяшлярдя икян. Кешеляр уйлаганча, Ул Іосифъ, Илій, 24 Матөатъ, Левій, Мелхій, Іаннай, Іосифъ, 25 Маттаөій, Амосъ, Наумъ, Еслимъ, Наггей, 26 Мааөъ, Маттаөій, Семеій, Іосифъ, Іуда, 27 Іоаннанъ, Рисай, Зоровавель, Салаөіиль, Нирій, 28 Мелхій, Аддій, Косамъ, Елмодамъ, Иръ, 29 Іосій, Еліезеръ, Іоримъ, Матөатъ, Левій, 30 Симеонъ, Іуда, Іосифъ, Іонанъ, Еліакимъ, 31 Мелеай, Маинанъ, Маттаөай, Наөанъ, Давидъ, 32 Іессей, Овидъ, Воозъ, Салмонъ, Наассонъ, 33 Аминадавъ, Арамъ, Есромъ, Фаресъ, Іуда, 34 Іаковъ, Исаакъ, Авраамъ, Өара, На-

хоръ, 35 Серухъ, Рагавъ, Фалекъ, Еверъ, Сала, 36 Каинанъ, Арфаксадъ, Симъ, Ной, Ламехъ, 37 Маѳусалъ, Енохъ, Іаредъ, Малелеилъ, Каинанъ, 38 Еносъ, Сиѳъ, Адамъ Улы, Алла Улы булган.

4-нче бюлем

Зач. 12. 1 Іисусъ Святый Тынга тулыланыб, Іорданнан кайткан; шуннан суҥ Аны Тын буш кырга алыб барган. 2 Шунда Аны шайтан кырык көн сынаган; шул көннярдя Ул бер нястя дя ашамаган, әммя ул көнняр ўткяч, калдыгында ачыккан. 3 Шунда шайтан Анҙар әйткян: әгяр Син Алла Улы булсаҥ, шушы ташка икмяк булырга куш, дигян. 4 Іисусъ анҙар жауаб биреб әйткян: кеше икмяк белян гня тора алмас, әммя Алланын әр-бер сюзе белян торор [1] диб жазылган, дигян. 5 Аннары Аны бейек тау өстөня меҥгереб, кюз ачыб кюз жомгончы, шайтан Анҙар дөньядяге бар падшалыкларны кюрсяткян. 6 Шунда шайтан Анҙар әйткян: шушыларнын барысында, аларнын эямен дя Синеҥ кулыҥа бирем, алар миҥа бирелгян шул, аны телясям кемгя бирямен. 7 Алай булгач, Син миҥа башырсаҥ, барыда Синеке булыр, дигян. 8 Іисусъ анҙар жауаб биреб әйткян: кит Миннян, шайтан! жазылган ич: Ходай Аллаҥа башыр, бер Анҙар гна кызмят ит [2] диб, дигян. 9 Аннары шайтан Аны Іерусалимга алыб барган; анда чиркяў тюбясенен кыыйына бастырыб, Анҙар әйткян: әгяр Син Алла Улы булсаҥ, мыннан тюбян сикер; 10 Жазылган ич: Сине Ўз пяриштяляреня саклатыр; 11 Алар Сине кулларына кютяреб барырлар, аягыҥ ташка сөртөнмяс, [3] диб. 12 Іисусъ анҙар жауаб биреб әйткян: тагы әйтелгян ич: Алла Ходайыҥны сынама [4] диб, дигян. 13 Бөтөнняй сынаб бетергяч, шайтан Анын жаныннан бер-ауыкка чаклы киткян. 14 Аннары Іисусъ тын кыуатына тулыланыб, Галилеяга кайткан; Анын турысында хабяр шундагы бөтөн тирягя жяйелгян. 15 Ул аларны синагогаларында өйряткян; Аны барысыда даннаганнар.

Зач. 13. 16 Аннары Іисусъ асралган каласына Назаретка килгян; анда Ўз гадятенчя, суббота көннө синагогага кереб, укыр өчөн аяк өстөня торган. 17 Анҙар Исаія пагамбяр княгясен биргян-

[1] Втор 8:3.

[2] Втор 6:13.

[3] Пс 90:11-12.

[4] Втор 6:16.

няр; Ул, книгяне ачыб, блай диб жазылган тӧшнӧ табкан: 18 Ходай Тыны Миндя; Ул Мине жарлыларга изге хабяр сӧйлярга майлады, кайгылы кюӈеллелярне тӧзятергя, тоткондагыларга котоласыларын, сукырларга кюря торган буласыларын йӓйтергя, интеккяннярне иркенгя чыгарыргa, 19 Ходайнын жакшы багытын сӧйлярга Мине жибярде [1] диб. 20 Аннары книгяне жабкан да, кызмятчегя биреб, утырган; синагогадагылар барысыда Аӈар тегяляб караб торганнар. 21 Шунда Ул аларга йӓйтя башлаган: книгядя сез эшеткян бу сюзляр бӧгӧн жиреня килде, дигян. 22 Барысыда Аӈар: эйе, дӧрӧс, дигянняр.

Зач. 14. Анын ауызыннан чыккан дяўлятле сюзлярга исляре китеб йӓйтешкянняр: Бу Іосифъ улы тӧгӧл ме суӈ? дигянняр. 23 Ул аларга йӓйткян: сез Миӈа оӈгай йӓйтеля торган сюзне йӓйтерсез: тӧзятеўче! Ўзеӈне Ўзеӈ тӧзят, мында да Ўзеӈ ўскян жирдя, Капернаумда кылганыӈны, без эшеткянне кыл диб йӓйтмей калмассыз, дигян. 24 Тагы йӓйткян: чыннаб йӓйтямен сезгя; ўскян жирендя бер пагамбярне дя кабыл кюрмейляр. 25 Чыннаб йӓйтямен сезгя: Илія пагамбяр кӧннярендя өч жыл да алты ай кюк биклянеб торгач, буган жирдя дя каты ачлык булган чакта, Израилдя тол катыннар кюб булган, 26 Булса да Илія аларнын берсеня дя жибярелмягян, тик Сидонъ Сарептасындагы тол катынга гна (жибярелгян). 27 Тагы шулай Елисей пагамбяр багытында да Израилдя кутырлы тяннеляр кюб булган, аларнын берсе дя тазартылмаган, тик Сирія кешесе Нееманъ гна (тазартылган), [2] дигян. 28 Мыны эшетеб, синагогадагы кешелярнен барысынында бик ачыулары килгян. 29 Шундук тороб, Аны каладан кыуыб чыгарганнар; калалары салынган таунын тюбясеннян тӧртӧб тӧшӧрӧйӧк диб, Аны шул тау тюбясеня алыб барганнар, 30 Ӓммя Ул аларнын урталарыннан ўтеб, читкя киткян.

Зач. 15. 31 Аннары Галилеядяге Капернаумъ каласына килеб, суббота кӧннярдя калыкны өйряткян. 32 Анын өйрятеўеня исляре киткян, Анын сӧйляўе кодрятле булган шул. 33 Синагогада шакшы тынны, женнянгян кеше бар икян; ул бик каты тауыш белян кычкырган: 34 Эй Іисусъ Назарянинъ! безгя теймя, бездя Синеӈ ней эшеӈ бар? Син безне бетерергя килгян; Син кем

[1] Ис 61:1-2.

[2] 4Цар 5:1, 14.

икянне белямен: Син Алланын Изгесе, дигян. 35 Іисусъ анҕар кисятеб äйткян: дяшмя, анын эченнян чык! дигян. Жен шундук ул кешене синагога уртасында жыгыб, анҕар бер зыян да тейермейче, анын эченнян чыккан. 36 Барысына да куркыныч тӧшкян; ӱз араларында äйтешкянняр: бу ней хал? Ул кодрят белян, кыуат белян шакшы тыннарга куша, алар шундук чыгыб китяляр? дигянняр.

Зач. 16. 37 Шуннан суҥ Анын хабяре бӧтӧн тиря жакка жяйелгян. 38 Синагогадан чыгыб, Іисусъ Симонъ ӧйӧня кергян; Симонъ катынынын анасы тир кастасы белян бик азабланыб жата икян: шундук анын турысында Анҕар ӱтенгянняр. 39 Ул анын катына килеб, тир кастасын туктаткан, каста шундук беткян. Ул шул сяттюк тороб, аларга кызмят итеб жӧргян. 40 Тӧрлӧ чир белян чирле кешеляре бар кешеляр барысыда, кояш байыган чакта, аларны Анын катына алыб киля башлаганнар. Ул äр-кайсынын östӧня кулларын салыб, аларны тӧзяткян. 41 Кюбесенен эченнян женняр дя кычкырыб чыгыб, äйткянняр. Син Алла Улы Христосъ, дигянняр. Ämмя Ул аларга: Ул Христосъ икянне белгяннярен äйтергя кушмаган. 42 Кӧн башлангач, Ул ӧйдян чыгыб, буш жиргя киткян. Калык Аны эзлей барган. Анын катына килгяч, бездян китмясяня диб, Аны жибярмей торганнар. 43 Ämмя Ул аларга äйткян: Мин бютян каладагыларга да Алла Падшалыгынын изге хабярен сӧйлярга тейеш, Мин шуҥар жибярелдем шул, дигян. 44 Аннары Галилеядяге синагогаларда сӧйляб жӧргян.

5-нче бюлем

Зач. 17. 1 Бер табкыр, Алла сюзен эшетер ӧчӧн, Іисусъ жанында калык тыгызланган чакта, Ул Геннисаретъ кюле жанында икян. 2 Шунда Ул кюл östӧндя торган ике кайыкны кюргян; балыкчылар кайыкларыннан чыгыб, ауларын жыуалар икян. 3 Кайыкларнын берсеня, Симонныкыҥар кереб, Іисусъ анҕар жардан бер-ауык жир китяргя кушкан; аннары, кайыкта утырган кӧйӧ, калыкны ӧйряткян. 4 Ӧйрятеб туктагач, Симонга äйткян: тугайгарак кит тя, ауыгызны сӧзяр ӧчӧн салыгыз, дигян. 5 Симонъ Анҕар жауабка äйткян: эй Ӧйрятеӱче! без тӧнӧ буйы тырыштык, тик бер нястя дя тота алмадык; алайда Синеҥ

сюзең буйынча, ауны салыйым, дигян. 6 Шулай кылгач, алар бик кюб балык тотканнар, кюблектян аулары жыртыла башлаган. 7 Аннары икенче кайыктагы иптяшляреня, булышырга килсенняр диб, кул айкаганнар. Алар килгянняр дя ике кайыкны да тутырганнар, кайыклары батарлык булган. 8 Мыны кюреб, Симонъ Петръ Іисуснын тезеня башырыб äйткян: эй Ходай! минем катымнан чыксана, мин жазыклы кеше шул, дигян. 9 Шул хатле балык тотканнарыннан анын ўзеня дя, анын белян бергя булганнарнын барысынада бик куркыныч тöшкян. 10 Зеведей уллары, Симонъ иптяшляре Іаковъ белян Іоаннъ да (бик курыкканнар). Іисусъ Симонга äйткян: курыкма, мыннан блай кешелярне тотоучы булырсын, дигян. 11 Аннары ике кайыкны да жарга чыгарыб, бар нястялярен дя калдырыб, Іисуска эяреб киткянняр.

Зач. 18. 12 Іисусъ бер калада чагында, бöтöн тяне кутырлаган бер кеше килеб, Іисусны кюреб, жöз тюбян жыгылыб, Аңар блай диб ўтенгян: эй Ходай! телясең, Син мине тазарта алыр ыйың, дигян. 13 Іисусъ кулын сузыб аңар тейенеб äйткян: телеймен, тазарын дигян. Шул сяттюк анын кутырлары койолган. 14 Іисусъ аңар беряўгя дя äйтергя кушмаган, тик священниккя барыб кюренеб, аларга таныклыкка, Моисей кушканча, тазарганы öчöн корман китерергя кушкан. 15 Алай булсада Анын турысында сюз бигряк тя жяйелгян. Аны тыңнар öчöн, чирляреннян тöзялер öчöн, Анын катына бик кюб калык жыйылышкан. 16 Ämмя Ул буш жирляргя китеб, теляк иткян.

Зач. 19. 17 Бер дя бер көннö, Іисусъ öйряткян чагында, шунда Галилеянен дя, Іудеянен дя тöрлö жирляреннян, Іерусалимнян килгян фарисейляр, законга öйрятеўчеляр дя бергя утырганда, чирле кешеляр тöзялгяннян Ходайнын кыуаты кюреня торган. 18 Шунда бер-ауык кешеляр бер сансыз кешене тюшяге белян кютяреб китергянняр дя, аны öйгя алыб керергя, Іисусъ алдына салырга тырышканнар. 19 Калык кюблектян аны кертер жул табмагач, öй тюбясеня менгянняр дя тюбяне ачыб, сансызны тюшяге белян уртага Іисусъ алдына тöшöргянняр. 20 Іисусъ аларнын ышаныуын кюреб, ул кешегя äйткян: синә жазыкларын кичереля, дигян. 21 Книгячеляр белян фарисейляр ўз аралый уйлаша башлаганнар: бу Алланы курлаучы кем икян? бер Алладан бютян

кем жазыкларны кичеря алыр? дигянняр. 22 Іисусъ, аларнын уйларын белеб, аларга жауаб биреб йайткян: сез кюнелегездя ней уйлыйсыз? 23 Ней асатрак йайтергя: синя жазыкларын кичереля диб ме, ялля тор да жöрö диб ме? 24 Ямма Ядям Улынын жир östöндя жазыклар кичерергя кыуаты барын сез белсен диб, (йайтямен дигян дя) сансызга йайткян: синя йайтямен: тор да урнынны алыб, öйöня кайт, дигян. 25 Ул шул сяттюк аларнын кюз алдында тороб, жаткан урнын алган да Алланы даннаб, öйöня кайтыб киткян. 26 Барысыда бик куркышканнар; Алланы даннаганнар, котлары чыгыб йайтешкянняр: без бöгöн ис китярлек эшляр кюрдек, дигянняр.

Зач. 20. 27 Шуннан суң Іисусъ чыккан да сатлык мал акчасы жыя торган тöштя утыра торган Левій атлы мытарны кюреб, анар йайткян: Минем артымнан бар, дигян. 28 Ул бар нястясен калдырган да тороб, Анар эяреб киткян. 29 Левій ўз öйöндя Анын öчöн зур сый жасаган; анда кюб мытарлар, бютян кешеляр дя алар белян бергя утырганнар. 30 Книгячеляр белян фарисейляр зарланыб, Анын öйрянеўчеляреня йайткянняр: сез ник мытарлар белян, жазыклылар белян бергя ашыйсыз, эчясез? дигянняр. 31 Іисусъ аларга жауабка йайткян: лекарь сауларга киряк тöгöл, ямма ауырыуларга киряк. 32 Мин жазыклыларны тяўбягя öндярга килдем, ямма гаделлярне тöгöл, дигян.

Зач. 21. 33 Алар Анар йайткянняр: Іоаннъ öйрянеўчеляре дя, фарисейляр öйрянеўчеляре дя ней öчöн онгай ураза тоталар, теляк тя итяляр, ямма Синекеляр ашыйлар да, эчяляр дя? дигянняр. 34 Ул аларга йайткян: туйдагы кодаларга кеяў алар белян бергя чагында, ураза тоттора алырсыз мы? 35 Ямма алардан кеяў алыныр кönняр килеб житяр, житкяч, шул кönнярдя алар ураза тотарлар, дигян. 36 Шунда аларга мясял йайткян: беряў дя жана кейемнян жыртыб алыб, иске кейемгя жамау салмый, салса, жана кейемне бозар, жана кейемнян алган жамауы иске кейемгя килешмяс. 37 Жана аракыны да беряў дя иске турсыкка салмый, жугыйса жана аракы турсыкны айырыр да, ўзе дя агар, турсык та ярям булыр. 38 Ямма жана аракыны жана турсыкка салырга тейеш, аннары алар икесе дя бötöн köйö тороррлар. 39 Тагы беряў дя иске аракыны эчкяч тя, шундук жана аракы эчясе килмяс, искесе жакшырак шул, дирер.

6-нчы бюлем

Зач. 22. 1 Пасханын икенче көнөннян сунгы субботанын элекесендя, Іисусъ ашлык басыуыннан ӳтеб барган чагында, Анын ӧйрянеӳчеляре ашлык башларын ӧзӧб, куллары белян ыуыб ашыйлар икян. 2 Фарисейлярнен кайсылары аларга айткянняр: ник сез суббота көннӧ кыларга тейеш тӧгӧлнӧ кыласыз? дигянняр. 3 Іисусъ аларга жауаб биреб айткян: Давидъ ӳзе дя анын белян булган кешеляр дя ачыккач, ул ней кылганны укымадыгыз мы ялля? 4 Ничек ул Алла ӧйӧня кереб, священниклярдян башка бютян бер кешегя дя ашарга тейеш тӧгӧл китереб куйылган икмяклярне алыб, ӳзе дя ашаб, анын белян булганнарга да биргян [1] дигян. 5 Аннары аларга айткян: Ӓдям Улы субботага да башлык, дигян. 6 Ул тагы ӳнгя суббота көннӧ синагогага кереб ӧйряткян. Анда унг кулы кароган бер кеше бар икян. 7 Книгячеляр белян фарисейляр Іисуснын айыбын табар ӧчӧн, Ул суббота көннӧ тӧзятмяс ме диб, Аны караб торганнар. 8 Ӓммя Ул аларнын уйларын белеб, кулы кароган кешегя айткян: тор да уртага чык, дигян. Ул торган да чыккан. 9 Шунда Іисусъ аларга айткян: Мин сездян соройом: суббота көннӧ ней кыларга тейеш: жакшылык мы, ялля усаллык мы? жанны сакларга тейеш ме, ялля ярям итяргя ме? дигян. 10 Алар дяшмягянняр. Аннары аларнын барысынада айлянеб караган да ул кешегя айткян: кулынгны суз, дигян, ул шулай иткян, шундук кулы икенчесе кюк сау булган. 11 Аларнын бик каты ачыулары килеб, ӳз араларында Іисуска ней кылыйык икян дейешкянняр.

Зач. 23. 12 Шул көннярдя Іисусъ теляк телягя тау östӧня менеб, тӧнӧ буйы Аллага теляк итеб ӳткязгян. 13 Кӧн булгач, Ӳз ӧйрянеӳчелярен чакырыб, алар арасыннан ун икене сайлаб, аларны апостолъ диб атаган: 14 Ӳзе Петръ диб атаган Симонны сайлаган, анын энесе Андрейне, Іаковны, Іоанны, Филиппны, Варѳоломейне, 15 Матѳейне, Ѳоманы, Алфей улы Іаковны, Зилотъ дигян Симонны, 16 Іаковъ улы Іуданы, Искаріотъ Іудасын, шушысы сунгыннан тотоб биреӳче булган.

Зач. 24. 17 Алар белян таудан тӧшӧб, Іисусъ бер тигез жирдя туктаб торган, анда

[1] 4Цар 21:1-6.

öйрянеўчеляренен дя кюбесе, тагы бötöн Іудеядан, Іерусалимнан, дингез жанындагы Тиръ белян Сидонъ жирляреннян килгян кюб калык та (туктаб торганнар). 18 Алар Аны тыңнар öчөн, чирляреннян сауыгыр öчөн килгянняр, тагы шулай женняр азабландыра торган кешеляр дя (килгянняр); алар сауыкканнар. 19 Іисустан кыуат чыгыб, барысында тöзяткянгя кюря, бар калык та Анар тейенергя тырышкан. 20 Ул кюзлярен öйрянеўчеляреня таба кютяреб караб, äйтя башлаган: жыуаш кюңеллеляр бахетле, Алда Падшалыгы сезнеке шул. 21 Äле ачыгыучылар бахетле, сез туклануырсыз шул. Äле жылаучылар бахетле, сез кюңеллелянерсез шул. 22 Ädям Улы öчөн сезне кешеляр кюрялмасалар, сезне айырыб жибярсяляр, сезне курласалар, исемегезне жаман итеб жяйелтсяляр, сез бахетле. 23 Шул көннö сöйönögöз, кыуанырыз, сезгя кюктя сауаб бик оло шул. Аларнын аталары пагамбярлярга шулай кылганнар.

Зач. 25. 24 Эй байлар, сезгя читен булыр, сез инде ўзегезгя теясе жыуанычны алдыгыз шул. 25 Эй äле туйыныб беткянняр, сезгя читен булыр, сез ачыгырсыз шул. Эй äле көлöўчеляр, сезгя читен булыр, сез сулкылдаб жыларсыз шул. 26 Бар кешеляр дя сезне жакшы диб сöйляшсяляр, сезгя читен булыр, аларнын аталары жалган пагамбярлярга шулай иткянняр шул. 27 Ämмя сез тыңнаучыларга äйтямен: дошманнарыгызны сöйögöз, сезне кюрялмый торганнарга жакшылык кылыгыз; 28 Сезне каргаучыларга арыулык телягез, сезне кыйырсытыучылар öчөн теляк итегез. 29 Жанагыңа суккан кешегя икенче жанагыңны да бороб тот; ирексезляб синең öст кейеменне алыучыга кюлмягенне алырга да ирек бир. 30 Синнян сораучыга äр-кемгя бир, äйбереңне алган кешедян кайтарыб сорама.

Зач. 26. 31 Сезгя кешеляр ней кылганны телясягез, ўзегез дя аларга шулай кылыгыз. 32 Ягяр сез ўзегезне сöйгяннярне гня сöйсягез, сезгя анын öчөн нейдей сауаб булсын? ўзлярен сöйгяннярне жазыклылар да сöяляр ич. 33 Ягяр ўзегезгя жакшылык кылганнарга гна жакшылык кылсагыз, сезгя анын öчөн ничек сауаб булсын? жазыклылар да шулай кылалар ич. 34 Ягяр бурычны кире кайтарыб алырбыз диб ышаныб торган кешелярегезгя гня бирсягез, анын öчөн сезгя нейдей сауаб булсын? жазыклы кешеляр дя биргян бурычларын кире алыр öчөн жазы-

клы кешелэргэ бурыч биряляр ич. 35 Әммя дошманнарыгызны сөйөгөз, жакшылык кылыгыз, бер нястя дя көтмөйче бурычка бирегез, сезгя бик оло сауаб булыр. Жугарыгынын уллары булырсыз. Ул шу тау итмей торганнарга да, усалларга да изгелекле. 36 Инде айсаң Атагыз ничек изгелекле, сез дя шулай изгелекле булыгыз.

Зач. 27. 37 Тикшермягез, сезне дя тикшермясляр; айыбламагыз, сезне дя айыбламаслар; кичерегез, сезгя дя кичерелер. 38 Бирегез, сезгя дя бирелер: сезгя кайтарган чагында сауытыгызга ўлчяўне тутырыб, селкеб, тыгызлаб, тюбялямя итеб салырлар; сез ничек ўлчяў белян ўлчясягез, сезгя дя шундый белян ўлчянер шул, дигян. 39 Аларга тагы мясял әйткян: сукыр сукырны житякляб жөртя алыр мы? икесе дя чокорга жыгылырлар төгөл ме? 40 Өйрянеўче өйрятеўчесеннян оло булмый, бөтөнняй өйрянеб житкяч тя, әр-кем тик өйрятеўчесе кюк кня булыр. 41 Ник туганың кюзендяге ботакка карыйсын, әммя ўз кюзендяге бюряняне сизмейсен? 42 Жя ўз кюзендяге бюряняне кюрмягяч, син туганыңа: эй туган! кая мин синең кюзеңнян ботакны алыйым диб ничек әйтя алырсын? Эй кюз алдында гна кылыныучы! элеке ўз кюзендяге бюряняне ал, аннары туганыңнын кюзендяге ботакны алырга да кюрерсен. 43 Начар жимеш китеря торган жакшы агач жук, жакшы жимеш китеря торган начар агач та жук; 44 Әрбер агач ўз жимешеннян беленя шул. Чянечкеле агачтан смоква жыймыйлар, кыуактан да жөзөм жыймыйлар. 45 Жакшы кеше ўзенен жакшы кюңел сауытыннан жакшыны чыгара, әммя жаман кеше ўзенен жаман кюңел сауытыннан жаманны чыгара: анын ауызы кюңел тулылыктан сөйлөй шул.

Зач. 28. 46 Ник Мине: Ходай, Ходай диб әйтясез, әммя ўзегез Мин әйткянне кылмыйсыз? 47 Минем катка килеб, сюзляремне тыңнаб, аларны кылыучы әркемнен кемгя ошаулы икянен сезгя әйтейем: 48 Ул жир казыб, тирян итеб, таш нигез салыб, анын өстөня өй торгозган кешегя ошаулы; сыу ташыб, шул өйгя бярелгян икян, бярелся дя, нигезен таш өстөня корганга кюря, ул өйнө урныннан кузгата алмаган. 49 (Сюземне) тыңнаб тороб, кылмаган кеше, өйнө нигезсез көйө коро жиргя гня салган кешегя ошаулы; сыу ташыб, ул өйгя бярелгян икян, шул сяттюк ул өй ауыб, бөтөнняй жимерелеб беткян.

7-нче бюлем

Зач. 29. 1 Іисусъ тынғнаган калыкка шул сюзлярен барында äйтеб бетергяч, Капернаумга кергян. 2 Бер сотникнын бик жараткан кызмятчесе чирляб, ўлярлек булыб жата икян. 3 Іисусъ турысында эшетеб, ул Анар кызмятчесен килеб тöзятсен эйе диб, Аны чакырырга Іудейлярнен калык башлыкларын жибяргян. 4 Алар Іисусъ катына килеб, Анар бик ўтенеб äйткянняр: Син анар мыны кыларга ул тейешле, 5 Ул безнен калыкны сöя шул, безгя синагога да салыб бирде, дигянняр. 6 Іисусъ алар белян киткян. Öйгя барыб житяргя бер аз калгач, сотникъ Анар дуслярын жибяреб äйттергян: эй Ходай! килеб борчолма, Син минем öйöмя керергя мин тейешле тöгöл шул. 7 Шунар кюря мин ўземне ўзем Синең катына барырга тейешле кюрмядем. Ämмя Син сюз гня äйт, кызмятчем сауыгыр. 8 Мин шу ўзем кеше кул астындагы кеше булсам да, ўз кулымда салдатлар тотам; берсеня: бар дисям, бара; икенчесеня: кил дисям, киля; кызмятчемя: мыны кыл дисям, ул кыладыр, дигян. 9 Іисусъ мыны эшетеб, анар исе киткян; Ўз артыннан килгян калыкка боролоб äйткян: сезгя äйтямен, Израилдя дя Мин бу хатле ышаныуны очратмадым, дигян. 10 Жибяргян кешеляр öйгя кайткач, чирле кызмятчене сау очратканнар.

Зач. 30. 11 Шуннан суң Іисусъ Наинъ дигян калага барган; Анын белян бергя öйрянеўчеляренен дя кюбесе, калыкнын да кюбесе барганнар. 12 Ул кала кабкасына жакыннашкан чагында, бер ўлекне, ананын бердян бер улын кютяреб чыгыб киляляр икян; ул катын тол икян; анын белян бергя каладан кюб калык килгян. 13 Катынны кюреб, Ходай аны кызганыб, анар: син жылама дигян. 14 Аннары жакын килеб, ўлекне итя торган урынга тейенгян; кютяреб барыучылар туктаганнар. Іисусъ äйткян: эй жегет, синa äйтямен, тор! дигян. 15 Ўлек тороб утырган да сöйляшя башлаган; Іисусъ аны анасына биргян. 16 Барысынада куркыныч тöшкян; Алланы даннаб äйткянняр: безнен арада оло пагамбяр кюренде, Алла Ўз калкына изгелек итте, дигянняр.

Зач. 31. 17 Іисусъ турысында былай дейеў бötöн Іудеяга, буган жяняшя тирягя жяйелгян. 18 Быларнын барысында öйрянеўчеляре Іоаннга кай-

тыб белдергянняр. 19 Іоаннъ ўз
ойрянеўчеляренен икесен чакырыб, Іисуска жибяреб, сораткан:
Килясе дигян Син ме, ялля бютянне котойок ме? диб. 20 Алар Іисуска килеб айткянняр: Чумылдырыучы Іоаннъ безне Синга:
Килясе дигян Син ме, ялля бютянне котойок ме? диб сорарга
жибярде, дигянняр. 21 Шул чакта Іисусъ кюб кешелярне чирляреннян, жараларыннан, жаман
тыннарыннан тозяткян, кюб сукырларны да кюря торган иткян. 22 Іисусъ аларга жауаб биреб
айткян: барыгыз, кайтыб, Іоаннга ней кюргянегезне, ней эшеткянегезне айтегез: сукырлар
кюря торган булалар, аксаклар
(тозок) жоройляр, кутырлы тяннеляр тазаралар, санраулар эшетяляр, ўлекляр тереляляр, жарлылар изге хабяр сойлойляр диб.
23 Аммя Минем турда шиклянмягян кеше бахетле, дигян. 24
Аннары Іоаннын жибяргян кешеляре киткяч, Іисусъ калыкка
Іоаннъ турысында айтя башлаган: сез буш кырга ней кюрергя
бардыгыз? жилдян тирбянгян
камышны мы? 25 Суң ней кюрергя бардыгыз? жомошак кейем
кейгян кешене ме? асыл кейем
кейеб, кубшы тороучылар падша жортонда торалар ич. 26 Суң
ней кюрергя бардыгыз? пагамбярне ме? Эйе, сезгя айтямен:
пагамбярдян дя олоно. 27 Мына
Мин Синең алдыңнан Ўз пяриштямне жибярямен, ул Синең
алдыңнан жулыңны азерляб
куяр диб жазылган ўзе шушы. [1]
28 Мин сезгя айтямен: катыннардан тыуганнар арасында Чумылдырыучы Іоаннан оло пагамбяр
беряў дя жук, аммя Алла падшалыгындагыларнын иң кечесе аннан оло, дигян. 29 Тыңнаб торган
бар калык та, мытарлар да Іоаннъ чумылдырыуы белян чумылдырылыб, Алла иркен жиреня
китергянняр. 30 Аммя фарисейляр, законъ белеучеляр Іоаннан
чумылдырылмыйчы, ўз турыларындагы Алла иркен кабыл алмаганнар.

Зач. 32. 31 Ходай айткян: бу
тыума кешелярен кемгя ошатыйым? алар кемгя ошаулы? 32
Алар урамда утырыб, бер берсеня кычкырыучы балаларга ошой;
алар айтяляр: без сезгя сыбызгы
уйнадык, сез бейемядегез; без
сезгя жыларлык жырыулар жырладык, сез жыламадыгыз дейляр. 33 Чумылдырыучы Іоаннъ
килде, икмяк тя ашамый, аракы
да эчмей; сез анда жен бар дейсез. 34 Адям Улы килде, ашый да,
эчя дя; сез айтясез: мына ашауны, эчемнек эчеуне жарата тор-

[1] Мал 3:1.

ган кеше, мытарларнын, жазыклы кешелярнен дусы, дейсез. 35 Белемнекне ўз оланнары барысыда дөрөсляделяр, дигян.

Зач. 33. 36 Фарисейлярнен берсе Іисусны ўзе белян бергя аш ашарга чакырган. Ул фарисей өйөня кереб утырган. 37 Мына шул каладагы бер жазыклы катын, Анын фарисей өйөня кереб утырганын белеб, алавастръ сауыт белян мvро алыб килгян; 38 Килгяч, Анын артында аягы катында тороб, жылый-жылый кюз жяшен Анын аякларына койоб, чяче белян сөрткян, сөрткяч, аякларын ўбеб, мvро белян майлаган. 39 Іисусны чакырыучы фарисей мыны кюреб, эченнян гня әйткян: әгяр Бу пагамбяр булса, Аңар кем тейенгянне, нейдей катын тейенгянне белер эйе, ул жазыклы катынна баса, дигян. 40 Іисусъ Аңар боролоб әйткян: Симонъ! Минем синға бер нястя әйтясем бар, дигян. Ул әйткян: эй Өйрятеўче, әйт, дигян. 41 Іисусъ әйткян: бер бурычка биреўченен бурычлы ике кешесе бар икян: берсенен биш жөз динарій [1] бирясе бар икян, әммя икенчесенен илле динарій. 42 Аларнын тюляр нястяляре булмагач, ул икесеня дя кичергян. Инде әйтче, аны кайсысы кюберяк сөяр? дигян. 43 Симонъ жауаб биргян: кюберяк кичергяне диб уйлыймын дигян. Ул аңар әйткян: син дөрөс әйттең, дигян. 44 Аннары катынга таба боролоб, Симонга әйткян: син шушы катынны кюрямесен? Мин синең өйөңя килдем, син Миңа аягымны жыуарга сыу да бирмядең, әммя ул Минем аякларыма кюз жяшен койоб, чяче белян сөрттө. 45 Син Мине ўбмядең, әммя ул Мин килгяннян бирле аякларымны туктаусыз ўбя. 46 Син Минем башымны май белян дя майламадың, әммя ул Минем аякларымны мvро белян майлады. 47 Шуңар кюря синға әйтямен: кюб сөйгяненя кюря, анын кюб жазыклары да кичереля; әз кичерелгян кеше, сөйөўендя әз сөя, дигян. 48 Катынга әйткян: синға жазыкларың кичереля, дигян. 49 Шунда Анын белян бергя утырыучылар ўз аралый сөйляшя башлаганнар: бу кем, жазыкларны да кичеря? диб. 50 Әммя Ул катынга әйткян: сине ышаныуың коткарды; тынычлык белян кайт, дигян.

[1] Динарійдя 21 тейен.

8-нче бюлем

Зач. 34. 1 Шуннан суң Іисусъ калаларда, ауылларда Алла Падшалыгынын арыу хабярен сöйляб жöргян, Анын белян бергя ун ике öйрянеўчесе дя. 2 Тагы жаман тыннардан, чирляреннян Ул тöзяткян катыннарнын да кайсылары (жöргянняр): эченнян жиде жен чыккан Магдалина Марія, 3 Иродъ жортон караб тороучы Хузанын катыны Іоанна, Сусанна, тагы бютян кюб катыннар да Анар ўз маллары белян булышыб жöргянняр. 4 Кюб калык жыйылышкач, Анар бар калалардан да кешеляр килгяч, Ул мясял айткян.

Зач. 35. 5 Чячеўче орлогон чячяргя чыккан; чячкян чагында кайсысы жул читеня тöшкян дя табталган, аны ауа кошлары да чюбляб бетергянняр. 6 Кайсысы таш öстöня тöшкян, ул тишелгяч тя, дымы булмаганга кюря, короган. 7 Кайсысы тигяняк арасына тöшкян, тигяняк ўсеб, аны баскан. 8 Кайсысы жакшы жиргя тöшкян, шунда ўсеб, бер бöртöккя жöз бöртöк китергян, дигян. Мыны сöйлягяч, кычкырыб айткян: эшетергя колагы бар кеше эшетсен, дигян. 9 Öйрянеўчеляре Аннан: бу мясял ней белдеря? диб сораганнар. 10 Ул айткян: сезгя Алла Падшалыгынын жяшереклярен белергя бирелгян, аммя бютяннярга мясялляр белян айтеля, алар караб та кюрмейляр, эшетеб тя анамыйлар. 11 Бу мясял мына мыны белдеря: орлок дигяне Алла сюзе. 12 Жул читеня тöшкяне шушындыйларны белдеря: алар тыңныйлар, аннары ышаныб котолмасыннар диб, шайтан килеб, аларнын кюңеленнян сюзне алыб китя. 13 Таш öстöня тöшкяне мындыйларны белдеря: алар сюзне эшетеў белян, сöйöнöб кабыл алалар, тик тамырлары жукка кюря, бер ауыкка ышаналар, аммя сыналганда бизяляр. 14 Тигяняклеккя тöшкяне мындыйларны белдеря: алары сюзне тыңныйлар, тик киткячтен, дöнья сагышлары, байлык, тормош рахатлекляре аларны басыб бетеряляр, шунныктан алар жимеш китермейляр. 15 Жакшы жиргя тöшкяне шушындыйларны белдеря: кайсы кешеляр сюзне эшеткяч, аны арыу, таза кюңеллярендя саклыйлар да тюземнек белян жимеш китеряляр, дигян. Мыны сöйлягяч, Ул кычкырыб айткян: эшетергя колагы бар кеше эшетсен диб.

Зач. 36. 16 Беряў дя эшямне жандыргач, сауыт белян кабламый, жя карауат астына куймый, әммя кереўчеляр жактыны кюрсен диб, эшямдялгя утырта. 17 Кюренмей каласы бер жяшерен дя жук, жяшереб куйганнын да беленмейче, кюренмейче каласы жук. 18 Инде айса тыңнауыгызга аң салыгыз; барга бирелер, әммя жуктан бар кюк тейгян нястясе дя алыныр шул, дигян. 19 Шунда Аңар анасы белян агалары килгянняр, тик калык булганнык-тан, Аңар жакын киля алмаганнар. 20 Аңар белдергянняр: анаң белян агаларың Сине кюряселяре килеб, тышта торалар, дигянняр. 21 Ул аларга жауаб биреб әйткян: Миңа ана, Миңа агалар Алла сюзен тыңнаучылар, аны кылыучылар, дигян.

Зач. 37. 22 Бер дя бер көннө Іисусъ ўз өйрянеўчеляре белян кимягя кереб, аларга әйткян: кюлнен теге жагына кичейек, дигян. Шундук киткянняр. 23 Барган чакларында, Ул жокога киткян. Кюл өстөндя дауыллы жил кютярелгян, аларга тулкыннар чайпыла башлаган, хатяр халдя булганнар. 24 Жанына килеб, Аны уятыб, әйткянняр: эй Өйрятеўче, Өйрятеўче! бетябез, дигянняр. Әммя Ул тороб, жилне дя, сыу тулкыннаныуын да тыйган; алар басылган, тыб-тыныч булган. 25 Аннары Ул аларга әйткян: сезнен ышаныуыгыз кая? дигян. Алар куркышыб, исляре китеб, бер берсеня әйтешкянняр: Бу кем бу? жилгя дя, сыуга да куша, алар Аны тыңныйлар, дигянняр.

Зач. 38. 26 Галилея карышысындагы Гадара жиреня килгянняр. 27 Іисусъ жарга чыккач, Аны кала кешеляренен берсе очраткан. Ул кеше кюбтяннян бирле женнянеб, кейем кеймейче, өйдя тормойчы каберлярдя тора икян. 28 Ул, Іисусны кюреб, кычкырган, Аңар жыгылыб башырыб, каты тауыш белян әйткян: эй жугарыгы Алланын Улы Іисусъ, Синең миндя ней эшең бар? мин Синя тилмерямен, мине азабламасана, дигян. 29 Іисусъ шакшы тынга шул кешедян чыгарга кушкан икян, ул аны кюб жылдан бирле азаблаган шул; аны чылбыр белян бяйляб, быгаулаб, саклаганнар; әммя ул чылбырларын өзгян; жен аны буш кырларга кыуыб жөрткян. 30 Іисусъ аннан сораган: син ней атлы? дигян. Ул әйткян: легіонъ, [1] дигян; анын эченя бик кюб женняр кергян икян шул. 31 Женняр Іисуска: безне төбсөз жиргя китяргя кушмасана диб ўтенгянняр. 32

[1] Легіонъ кюб мең дигян сюз.

Шундук тау өстөндя зур табын дунгыз көтөуе көтяляр икян; женняр Іисуска: безгя шушы (дунгызларга) керергя бойорсана диб ўтенгянняр. Ул аларга роксят биргян. 33 Женняр кешедян чыгыб, дунгызларга кергянняр; шундук көтөў текя жардан кюлгя атылыб батыб беткян. 34 Көтөўчеляр, былай булганны кюргяч, жөгөрөб киткянняр дя калага да, ауылларга да барыб белдергянняр. 35 (Кешеляр) ней булганны кюрергя чыкканнар; Іисусъ катына килгяч, эченнян женняр чыккан кешенен Іисуснын аягы жанында кейенеб, акыллы утырганын очратыб, бик куркышканнар. 36 Кюреўчеляр женнянгян кешенен ничек тёзялгянен аларга айткянняр. 37 Гадара тирясендяге бар калык Іисуска: бездян китя кюрсяня диб ўтенгянняр; аларга бик зур куркыныч тёшкян икян шул. Іисусъ кайыкка утырыб, кире киткян. 38 Эченнян женняр чыккан кеше Іисуска: мин Синеӈ белян булыр ыйым диб ўтенгян; ӓммя Іисусъ аны жибяреб айткян: 39 Ойоня кайт, сиӈа Алла ней кылганны айтеб бир, дигян. Ул китеб, бётён калага Іисуснын анар ней кылганын айтеб жёргян.

Зач. 39. 40 Іисусъ кире кайткач, калык Аны кабыл алган, Аны барысыда көтөб торганнар икян. 41 Шунда синагога башлыгы Іаиръ атлы кеше килгян дя Іисуснын аягы астына жыгылыб, Анӈар: ойомя керсяня диб инялгян. 42 Іаирнын ун ике жяшлярдя бер гня кызы бар икян, ул да ўляр чигендя жата икян. Іисусъ барган чагында, калык Анӈар тыгыз иткян. 43 Шунда ун ике жылдан бирле кан агыуы белян азаблана торган бер катын булган; ул бар малын лекарлярга биреб бетергян, тик ич берсе дя аны тёзятя алмаган; 44 Ул арттан килеб, Іисуснын кейеменен итягеня тейенгян, шул сяттюк кан агыуы туктаган. 45 Іисусъ айткян: Миӈа кем тейенде? дигян. Барысыда мин тёгёл дигяч, Петръ да Анын белян бергя булганнар да айткянняр: эй Ойрятеўче, Сине калык жак жактан тыгызлый ич, ӓммя Син Миӈа кем тейенде дисен. 46 Іисусъ айткян: Миӈа беряў тейенде, Мин Ўземнян чыккан кыуатны сиздем, дигян. 47 Катын, ўзенен жяшеренеб кала алмаганын кюреб, калтраб килеб, Анӈар жыгылыб башырган да бар калык алдында ўзенен Анӈар ней сябяблей тейенгянен, тейенгяч тя тёзялгянен айткян. 48 Іисусъ анӈар айткян: эй кызым, ныктор, ышаныуыӈ сине коткарды, тынычлык белян кайт, дигян. 49

Іисусъ мыны äйткян чакта, синагога башлыгына öйöннян беряў килеб äйткян: кызыҥ ўлде, Öйрятеўчене öшяндермя, дигян. 50 Ämмя Іисусъ мыны эшетеб, анар äйткян: курыкма, тик ышан гна, (кызыҥ) котолор, дигян. 51 Öйöня баргач, бер кешене дя кертмягян, тик Петрны, Іоанны, Іаковны, аннары кызнын атасы белян анасын гна (керткян). 52 Анын öчöн барысыда жылашалар, ўкерешяляр икян. Ämмя Іисусъ äйткян: жылашмагыз, ул ўлмягян, тик жоклаб кна жата, дигян. 53 Алар кыз ўлгянне белеб, Іисустан кölгянняр. 54 Ул барысын да чыгарыб, кызнын кулыннан тотоб дяшкян: эй кыз, тор! дигян, 55 Шундук кызнын тыны кире кайткан; ул шул сяттюк торган. Іисусъ анар ашарга бирергя кушкан. 56 Атасынын, анасынын исляре киткян. Ул аларга булган эшне ич беряўгя дя äйтергя кушмаган.

9-нчы бюлем

Зач. 40. 1 Іисусъ ун ике öйрянеўчесен чакырыб алыб, буган женнярне чыгарырга, чирлярне тöзятергя аларга кыуат, кодрят биргян. 2 Аларны Алла Падшалыгын сöйлярга, чирлелярне тöзятергя жибяргян. 3 Шунда Ул аларга äйткян: жулга бер нястя дя алмагыз, таяк та, кабчык та, икмяк тя, кömöш тя, икешяр кейемегез дя булмасын. 4 Бер-бер öйгя керсягез, шунда торогоз, шуннанук жулга чыгыгыз. 5 Ägяр дя бер-бер жирдя сезне кабыл алмасалар, сез шундагы каладан чыгышлый, аларга карышы таныклыкка аякларыгыздагы тупракны да селкеб тöшöрögöз, дигян. 6 Алар китеб, ауылларда жöрöб, äр-бер жирдя изге хабяр сöйлягянняр, (чирлелярне) дя тöзяткянняр.

Зач. 41. 7 Дюртенче ölöшнö биляб тороучы Иродъ, Іисуснын кылган эшлярен барысында эшеткяч, абтраб торган: кайсылары: бу Іоаннъ ўлгян жиреннян терелеб торгандыр дигянняр; 8 Кайсылары: Илія килгяндер дигянняр, ämмя кайсылары: боронго пагамбярлярнен берсе терелеб торгандыр дигянняр шул. 9 Иродъ äйткян: мин Іоаннын башын кистерттем, Бу, мин шундый эшлярен эшетя торган, кем икян суҥ? дигян. Аны кюрясе килеб жöргян. 10 Апостоллар кайткач, ўзляренен ней кылганнарын Іисуска äйткянняр. Ул аларны Ўзе белян алыб, Виөсаида дигян кала тирясендяге буш кырга аулакка киткян. 11 Калык мыны белеб, Анын артыннан барган;

Ул калыкны кабыл алыб, аларга Алла Падшалыгы турысында сöйлягян, чирлярен тöзяттерясе килгяннярен тöзяткян.

Зач. 42. 12 Кöн кичкя ауыша башлаган. Ун ике (öйрянеўчесе) Іисусъ жанына килеб, Анар йöткянняр: калыкны жибярче, алар тиря жактагы ауылларга кунарга барыб, шунда ашарларына табсыннар, без мында буш кырда шул, дигянняр. 13 Ämмя Ул аларга йöткян: аларга ашарга сез бирегез, дигян. Алар йöткянняр: безнен биш икмяк белян ике балыктан бютян нястябез жук, ялля без барыб, бу кешелярнен барысы öчöн дя ашамнык сатыб алыйык мы? дигянняр. 14 Алар анда ирляр гня биш менгняб бар икян. Ämмя Ул öйрянеўчеляреня йöткян: быларны рятляб, ряте сайын иллешяр кеше итеб утыртыгыз, дигян. 15 Алар шулай иткянняр, барысында рятляб утыртканнар. 16 Ул биш икмякне, ике балыкны алыб, кюккя таба караб, аларны бахиллягян дя сындырыб, калыкка öляшергя диб öйрянеўчелярня биргян. 17 Барысы да ашаб туйганнар; калган сыныкларны жыйыб, ун ике карнаша тутырганнар.

Зач. 43. 18 Бер багытта Іисусъ аулакта теляк иткян чакта, öйрянеўчеляре дя Анын белян булганнар. Ул алардан сораган: калык Мине кем диб йöтя? дигян. 19 Алар жауаб биреб йöткянняр: Чумылдырыучы Іоаннъ диб, кайсылары Илія диб, кайсылары боронго пагамбярлярнен берсе терелеб торгандыр диб йöтяляр, дигянняр. 20 Іисусъ аларга йöткян: сез ўзегез Мине кем диб белясез? дигян. Петръ жауаб биреб йöткян: Алланын Христосы диб белябез, дигян. 21 Ул аларга каты кисяткян: мыны беряўгя дя йöтмягез, дигян. 22 Тагы йöткян: Ädям Улы кюб азаб кюрясе, калык башлыклары, архіерейляр, книгячеляр Аны кабыл алмаслар, Ул ўтерелясе, öчöнчö кöннö терелеб торасы, дигян.

Зач. 44. 23 Аннары барысынада йöткян: Минем артымнан барасы килгян кеше, ўз иркен кылыуны ташласын да качын алыб, Минем артымнан барсын. 24 Жанын сакласы килгян кеше, аны жуяр, ämмя жанын Минем öчöн жуйган кеше, аны саклар. 25 Кеше бötöн дöньяне сöрöб алса да, ämмя ўзен жугалтса, жя ўзеня зыян китерся, анар ней пайда? 26 Кем дя кем Миннян, сюзляремнян оялса, Ädям Улы да Ўз олологында, Атасы олологында, арыу пяриштяляр олологында килгян чагында, аннан оялыр. 27 Мин сезгя чыннаб

йтямен: мында тороучыларнын кайсылары Алла Падшалыгын кюрмейче ўлмясляр, дигян.

Зач. 45. 28 Шушы сюзлярдян суң сигез көнняб ўткяч, Іисусъ Петрны, Іоанны, Іаковны алыб, тау östöня теляк итяргя менгян. 29 Теляк иткян чагында, Анын жözö ўзгяргян, кейеме агарыб, жалтраб торган. 30 Шунда ике ир Анын белян сöйляшеб торганнар, былар Моисей белян Илія булган. 31 Алар ололок белян кюренеб, Аңар Іерусалимдя ней буласыны, Ул ней кыласыны сöйляшкянняр. 32 Петрны да, анын белян булганнарны да жоко ауырайткан икян; алар уяныб китеб, Іисуснын олологон, тагы Анын белян бергя торган ике ирне дя кюргянняр. 33 Алар Іисусъ катыннан китя башлагач, Петръ Аңар йткян: эй Öйрятеўче, безгя мында тороргa жакшы; öч чатыр коройокчы: берне Синa, берне Моисейгя, берне Иліягя, дигян, ўзе ней йткянен белмягян. 34 Ул мыны йткян чагында, болот килеб, аларны кюлягялягян; болотка кергяч, алар бик курыкканнар. 35 Болоттан ауаз килгян: Шушы Минем сöйöклö Улым, Аны тыңнагыз диб. 36 Шул ауаз булган чагында Іисусъ жангызы гна калган. Öйрянеўчеляре мыны йтмей торганнар, ней кюргянярен шул көннярдя бер кешегя дя сöйляшмягянняр.

Зач. 46. 37 Икенче көннö, алар таудан тöшкяч, Іисусны кюб калык очраткан. 38 Калык арасыннан беряў кинят кычкырыб йткян: эй Öйрятеўче! Синa ўтенямен, улыма кюз салсана, ул минем беряў гня шул. 39 Аны жен тота, ул кинят кычкыра башлый, жен аны уатыб бетеря, ауызыннан кюбекляр чыгарта, аны бик азабланды-рыб, аннан азга гна китя. 40 Мин öйрянеўчеляреңя аны чыгартырга ўтенгян эйем, алар булдыра алмадылар. 41 Іисусъ жауаб биреб йткян: эй ышаныусыз, азгын тыума! сезнен белян кайчанга чаклы торойом? кайчанга чаклы сезгя чыдыйым? Улыңны мында китер, дигян. 42 Ул килгян чагында, жен аны жыгыб, калтрата башлаган; Іисусъ шакшы тынга кисяткян, кисяткяч, жегетне тöзятеб, аны атасына биргян. 43 Барысынын да Алланын олологына исляре киткян. Іисуснын бар кылган эшляреня барысынында исляре китеб торган чакта, Ул Ўз öйрянеўчеляреня йткян:

Зач. 47. 44 Сез бу сюзлярне колагыгызга салыгыз: Ädям Улы кешеляр кулына тотоб бирелер, дигян. 45 Тик алар бу сюзне аңнамаганнар, ул сюз аларга

карангы булган; алар аны тойоб житкезмягянняр, ämмя Аннан бу сюзне сорарга курыкканнар. 46 Аларга арабызда кайсыбыз оло икян диб уй тöшкян. 47 Іисусъ аларнын кюнгеллярендяге уйларын белеб, бер баланы алыб, аны Ўз алдында торгозоб, 48 Аларга äйткян: бу баланы Минем исемем какына кабыл алган кеше, Мине кабыл ала; ämмя Мине кабыл алган кеше, Мине Жибяреўчене кабыл ала: арагызда кайсыгыз иң кече, шул оло дигян.

Зач. 48. 49 Шунда Іоаннъ äйткян: эй Öйрятеўче, без Синең исемең белян женнярне кыуалаб чыгарыучы кешене кюрдек тя, ул безнен белян жöрмягянгя кюря, без аны туктаттык, дигян. 50 Іисусъ анар äйткян: туктатмагыз, сезгя карышы тöгöл кеше, сезнен жаклы шул, дигян. 51 Дöньядян китяр könняре житя башлагач, Анын Іерусалимгя барасы килгян. 52 Ўз алдыннан хабярчеляр жибяргян; алар китеб, Аны кабыл алырга äзерляр öчöн, Самарія жирендяге бер ауылга кергянняр. 53 Тик Аны анда кабыл алмаганнар, Ул Іерусалимгя барыучы ряўешле булган шул. 54 Мыны кюреб, Анын öйрянеўчеляре Іаковъ белян Іоаннъ äйткянняр: эй Ходай! телейемсен, Илія [1] кылган кюк без дя: кюктян ут тöшöб, аларны бетерсен диб äйтейек ме? дигянняр. 55 Ämмя Ул аларга таба боролоб, аларны тыйыб äйткян: ничек тынышта икянегезне белмейсез. 56 Ädям Улы кешелярнен жаннарын бетерергя килмяде, ämмя сакларга килде шул, дигян. Аннары икенче ауылга киткянняр.

Зач. 49. 57 Алар жулда чагында, беряў Іисуска äйткян: эй Ходай! Син кайда гна барсаң да мин Синға эяреб барым, дигян. 58 Іисусъ анар äйткян: тöлкölярнен önняре бар, ауа кошларынын да оялары бар, ämмя Ädям Улынын баш салыб жатыр урны да жук, дигян. 59 Ämмя икенчесеня äйткян: Минем артымнан бар, дигян. Ул äйткян: Эй Ходай! миңа элеке кайтыб, атамны кюмяргя роксят бирче, дигян. 60 Іисусъ анар äйткян: ўлеклярен кюмяргя ўлектейлярге калдыр, ämмя син барыб, Алла Падшалыгын сöйля, дигян. 61 Тагы беряў äйткян: эй Ходай, мин Синға эяреб жöрöрмен, тик Син элеке миңа öйöмдягеляр белян бахилляшергя роксят бир, дигян. 62 Ämмя Іисусъ анар äйткян: кулына сука тоткан кеше, кире боролоб карангаланса, Алла Падшалыгы öчöн ышангышлы тöгöл, дигян.

---

[1] 4Цар 1:10-12.

10-нчы бюлем

Зач. 50. 1 Шуннан ары Ходай тагы бютян житмеш öйрянеўче сайлаган да аларны Ўз алдыннан Ўзе барасы äр-бер калага, äр-бер жиргя икешяр-икешяр жибяргян. 2 Аларга äйткян: урасы ашлык кюб, ämмя эшчеляр äз; ашлык Эясеня ўтенегез, Ул урагына эшчеляр жибярсен эйе. 3 Сез барыгыз, Мин сезне бяряннярне бюреляр арасына жибяргяндей жибярямен. 4 (Ўзегез белян) кабчык та, жанчык та, башмаклар да алмагыз, жулда ич беряў белян дя исянняшкяляб жыуанмагыз. 5 Кайсы гна öйгя керсягез дя иң элеке: бу öйгя тынычлык булсын диб äйтегез. 6 Äгяр анда тынычлык улы булса, (телягян) тынычлыгыгыз анар килер, äгяр булмаса, ўзегезгя кайтыр. 7 Шул öйдя торогоз, аларнын нейе бар, шуны ашагыз, эчегез; эшляўчегя эшлягяне öчön бирергя тейеш ич. Öйдян öйгя кючеб жörмягез. 8 Бер-бер калага кергяч, сезне кабыл алсалар, сезгя куйган нястяне ашагыз; 9 Андагы чирлелярне тözятегез, аларга äйтегез: Алла Падшалыгы сезгя жакыннашты, дигез. 10 Бер-бер калага кергяч, сезне кабыл алмасалар, сез урамнарга чыгыб äйтегез: 11 Калагыздан безгя эяргян тузанны да сезгя селкеб töшöрöб калдырабыз, алай да Алла Падшалыгы сезгя жакыннашканны белегез, дигез. 12 Сезгя äйтямен: сорау könöндя Содомъ каласына ул калага караганда жиңелеряк булыр. 13 Айгай синға Хоразинъ! айгай синға Виөсаида! ägяр сездя булган кодрятляр Тиръ белян Сидонда булган булсалар, алар инде кюбтян алама кейем кейенеб, (башларына) кöл сибеб тяўбя итярляр эйе шул. 14 Алайда Тиръ белян Сидонга сорауда сезгя кюря жиңелеряк булыр. 15 Син дя, эй кюккя чаклы кютярелгян Капернаумъ, тамукка чаклы töшöрöлöрсен.

Зач. 51. 16 Сезне тыңнаучы кеше, Мине тыңный; сезне кабыл алмаган кеше, Мине кабыл алмый, ämмя Мине кабыл алмаган кеше, Мине Жибяреўчене кабыл алмый, дигян. 17 Житмеш öйрянеўче сöйönöшöб кайтыб, äйткянняр: эй Ходай! Синең исемең какына безне женняр дя тыңныйлар, дигянняр. 18 Ämмя Ул аларга äйткян: кюктян жяшен кюк атылыб töшкян шайтанны кюрдем. 19 Мына Мин сезгя жыланга да, скорпіонга да, дошманнын бар кöчöня дя басарга кыуат бирям, ич-бер нястя сезгя зыян тейермяс. 20 Алайда сезне женняр тыңнаганга

сöйöнмягез, ämмя исемнярегез кюктя жазылыулы булганга сöйöнöгöз, дигян. 21 Шул сагаття Іисусъ кюнелe сöйöнöб äйткян: эй Ätей, кюкнен, жирнен Ходайы! Син мыны белемнелярдян, акыллылардан жяшереб, балаларга кюрсяткянең öчön Сине данныймын. Эйе, Ätей, Синең иркең шулай булды шул дигян.

Зач. 52. 22 Аннары öйрянеўчеляреня таба боролоб äйткян: Миңа Атамнан äр-ней бирелеўле. Улнын кем икянен Атадан бютян беряў дя белмей, Атанын да кем икянен Улыннан башка, тагы Улы белдерясе килгян кешедян башка (беряўдя белмей). 23 Тагы öйрянеўчеляреня караб, аларга гна äйткян: сез кюря торганны кюреўче кюзляр бахетле. 24 Мин сезгя äйтямен: кюб пагамбярляр, падшалар сез кюря торганны кюряселяре килде, алайда кюрмяделяр; сез эшеткянне эшетяселяре килде, тик эшетмяделяр, дигян.

Зач. 53. 25 Мына законъ белеўче беряў урыннан тороб, Іисусны сынаб äйткян: эй Öйрятеўче, мянге тормошка урыннашыр öчön, мин ней кылыйым? дигян. 26 Ул анар äйткян: законда ней диб жазган, ничек диб укыйсын? дигян. 27 Ул жауаб биреб äйткан: Алла Ходайыңны бар кюнелең белян, бар жаның белян, бар көчөң белян, бар уйың белян сöй, [1] жакыныңны да ўзеңне сöйгян кюк сöй диб. 28 (Іисусъ) анар äйткян: син дöрöс жауаб бирдең; шулай кыл, тере торорсон, дигян. 29 Ämмя ул ўзен дöрöскя чыгарыр öчön, Іисуска äйткян: минем жакыным кем суң? дигян. 30 Іисусъ жауаб биреб äйткян: бер кеше Іерусалимнан Іерихонга төшöб бара икян, шунда талаучыларга очраган; алар анын östöннян кейемен салгызыб алыб, ўзен жаралаб, ўлярлек итеб калдырыб киткянняр. 31 Шул жулданук бер священниккя барырга туры килгян; ул аны кюргян дя узыб киткян. 32 Шунын кюк бер левитъ та шул урынга туры килеб, ул кешенен жанына барыб караган да узыб киткян. 33 Аннары бер Самарія кешесе атланыб бара икян; ул шул кешегя туры килеб, аны кюреб, кызганган. 34 Жакын килеб, анын жараларына май белян аракы сöртöб бяйлягян; аннары аны ишяге östöня атландырыб, узгынчылар кереб куна торган öйгя алыб барыб, анда анын öчön сагышланган. 35 Иртягесен киткян чагында, ике динарій чыгарыб, шул öйнön эяселя биреб

[1] Втор 6:4-5. Лев 19:18.

йткян: мынын өчөн сагышлансана; ягяр мыннан артык акча тотсаҥ да мин кайтышлый синға тюлярмен, дигян. 36 Суҥ инде талаучыларга туры килгян кешенен жакыны шул өч кешенен кайсысы диб уйлыйсын? дигян. 37 Ул йткян: анар изгелек иткяне, дигян. Іисусъ анар йткян: бар, син дя шулай кыл, дигян.

Зач. 54. 38 Жул белян бара торгач, Іисусъ бер ауылга кергян; шунда Марөа атлы бер катын Аны ўз өйөня алыб кергян. 39 Анын Марія атлы сеҥнесе бар икян, ул Іисуснын аягы жанына утырыб, Анын сюзен тыҥнаб утырган. 40 Ммя Марөа кюб сыйлар язерлярга сагышланыб жөргян, ул жакын килеб (Іисуска) йткян: эй Ходай, сеҥнем кызмятне жангызыма гна калдырганга Син көймөйсен меней? анар йтче, ул миға булышсын, дигян. 41 Іисусъ анар жауаб биреб йткян: эй Марөа, Марөа! син кюбкя сагышланыб жөрөйсен, киряклесе тик бер гня. 42 Марія арыу өлөшнө сайлаб алды, ул аннан алынмас дигян.

11-нче бюлем

Зач. 55. 1 Бер табкыр бер төштя Іисусъ теляк итеб туктагач, өйрянеўчеляре арасыннан берсе Анар йткян: эй Ходай, Іоаннъ ўз өйрянеўчелярен теляк итяргя өйряткян кюк, Син дя безне теляк итяргя өйрятче, дигян. 2 Ул аларга йткян: сез теляк иткян чагында, былай диб йтегез: эй кюктяге Атабыз, данны булыб торсон исемеҥ Синеҥ, килсен падшалыгыҥ Синеҥ, жирдя дя кюктягечя булсын иркеҥ Синеҥ. 3 Көннөк икмягебезне безгя көн сайын бир. 4 Жазыкларыбызны кичер, без дя безгя бурычлы булган ярбер кешегя кичерябез шул. Безне алданырга ирек жибярмя, жаманнан коткар безне диб. 5 Аларга тагы йткян: сезнен арагыздан берегезнен-берегезнен бер дусы булыб, шул дусына ул төн уртасында барыб йтся: эй дусым, миға ажяткя өч икмяк бирче, 6 Дусым жулга барышлый миға керде, анар куяр нястям жук шул дися, 7 Анын дусы өй эченнян анар жауаб биреб йтер: мине кумачаулама, инде ишегем бикляўле, балаларым да минем белян урында жаталар, мин тороб, синға биря алмыйым, дирер. 8 Мин сезгя йтямен: ягяр ул кеше тороб, дуслыгы какына анар бирмяся дя, китмей сораганына кюря, тороб, анар сораганынча бирер.

Зач. 56. 9 Мин дя сезгя
йытямен: сорагыз, сезгя бирелер; эзлягез, табарсыз; кагыгыз,
сезгя ачарлар. 10 Ӓр-бер сорауучы аладыр шул, эзляўче табадыр, кагыб тороучыга да ачалар.
11 Сезнен арадан кайсы ата, улы
икмяк сораса, анҕар таш бирер?
жя балык сораса, балык урнына анҕар жылан бирер? 12 Жя кюкяй сораса, анҕар скорпіонъ [1] бирер? 13 Шулай, сез ўзегез жаман
булыб та, балаларыгызга жакшыны биря белгяч, кюктяге Ата
Ўзеннян сораучыларга Святый
Тынны бигряк тя бирер, дигян.

Зач. 57. 14 Бер табкыр Іисусъ
(бер кеше эченнян) телсез женне кыуыб чыгарган; жен чыккач, телсез кеше сöйляшя башлаган; калыкнын исе киткян. 15
Аларнын кайсылары йытканняр:
Ул женнярне женняр башлыгы
веельзевулнын кöчö белян кыуыб чыгара, дигянняр. 16 Кайсылары Аны сынаб, кюктян билге
кюрсятче дигянняр. 17 Ӓммя Ул
аларнын уйларын белеб, аларга йытканн: ӓр-бер падшалык ўзе
ўз алдына айырылышса, буш
калыр; ўз алдына айырылышкан ӓр-бер жорт та бетяр. 18 Ӓгяр
шайтан ўзе ўз алдына айырылышса, анын падшалыгы ничек тора алыр? Ӓммя сез: Мин
женнярне веельзевулъ кöчö белян чыгара диб йытясез. 19 Ӓгяр
Мин женнярне веельзевулъ кöчö
белян чыгарам икян, сезнен уллырыгыз аларны кем кöчö белян
чыгаралар суҥ? Шул сяятлей
алар сезне айыблаучы булырлар.
20 Ӓгяр Мин женнярне Алла кыуаты белян чыгарам икян, инде
айса сезгя Алла Падшалыгы килеб житкян. 21 Кöчлö кеше ўз
öйöн корал белян саклаб торган
чагында, анын малы имен булыр. 22 Ӓгяр аннан кöчлö беряў
анҕар жабышыб, аны жинся,
анын ышаныб торган бар коралын да алыр, талаб алган (малын) да öляшер.

Зач. 58. 23 Минем белян бер
уйда тöгöлö, Миҥа карышы;
Минем белян бергя жыймаганы, тарата. 24 Шакшы тын кеше
эченнян чыккач, сыусыз жирлярдян тынычлык эзляб жöрöй;
табмагач, йытя: чыккан öйöмя
кайтыйым дей; 25 Кайткач, аны
себергян кöйö, йыбятлягян кöйö
очрата. 26 Аннары барыб, ўзе белян бергя тагы ўзеннян дя жаманырак бютян жиде тынны
алыб киля дя, кереб шунда торалар. Ул кешегя сунгысы элекегедян дя жаманырак була, дигян. 27
Ул мыны сöйлягян чагында, калык арасыннан бер катын ауаз
кютяреб, Анҕар йытканн: Сине

[1] Ўтererлек чага торган жяннек.

кютяреб жöргян корсак, Сине имезгян имчяк бахетле, дигян. 28 Ämмя Иисусъ äйткян: Алла сюзен тынҥнаб, аны кылыучылар бигеряк тя бахетле, дигян.

Зач. 59. 29 Калыклар жыйылышкан чагында, Иисусъ äйтя башлаган: бу тыума усал, ул билге эзлей, тик анҥар Иона пагамбяр билгесеннян бютян билге бирелмяс. 30 Иона пагамбяр Ниневия кешеляреня билге булган кюк, Ädям Улы да шушы тыумага билге булыр. 31 Тöшлöктяге катын падша бу тыума кешеляре белян сорауда тороб, аларны айыблар, ул шу Соломонъ белемнеген эшетергя жир читляреннянюк килгян, [1] ämмя мында Соломоннан да Оло бар. 32 Ниневия кешеляре бу тыума белян сорауда тороб, аны айыбларлар, алар шу Иона (пагамбяр) сöйляўеннян тяўбягя килделяр, ämмя мында Ионадан да Оло бар. 33 Беряўдя эшямне жандыргач, аны жяшерен урынга куймый, сауыт астына да куймый, ämмя кереўчеляр жакты кюрсенняр диб, эшямдялгя утырта, дигян.

Зач. 60. 34 Тян жактырткычы кюз; äгяр синеҥ кюзеҥ таза булса, бöтöн тянеҥ дя жакты булыр; äгяр кюзеҥ начар булса, бöтöн тянеҥ дя карангы булыр. 35 Инде айса кара, эчендяге жактыҥ карангы тöгöл ме? 36 Ägяр бöтöн тянеҥ жакты булса, бер карангы тöшö дя булмаса, жактырткыч ўз жактысы белян сине жактыртыб торган кюк, буган тöшöҥ дя жакты булыр, дигян. 37 Ул мыны сöйлягян чагында, бер фарисей Аны ўз öйöня ашка чакырган. 38 Ул барыб, анда утырган. Анын ашар алдыннан кулын жыумаганын кюреб, фарисейнен исе киткян. 39 Ämмя Ходай Анҥар äйткян: сез фарисейляр бу чакта табак-сауытыгызнын тышын тазартасыз, ämмя эчегез талаб алган нястя белян, жаманнык белян тулы. 40 Эй акылсызлар! тыштагын булдырыучы, эчтяген дя булдырган тöгöл ме? 41 Нейегез бар, шуннан садака бирегез, шунысы жакшырак булыр; шул чакта бар нястялярегез дя таза булыр.

Зач. 61. 42 Айгай сезгя, фарисейляр! сез бötнöктян, тминнан, äр-тöрлö бакча жимешляреннян дя унынчыölöшöн бирясез, ämмя турылыкны, Алланы сöйöўне чиття калдырасыз; быларын да кыларга киряк, тегелярен дя калдырырга киракмяс. 43 Айгай сезгя, фарисейляр! сез синагогаларда алда утырыуны, калык жыйылган жирдя кешеляр башырганны жаратасыз. 44 Айгай

[1] 3Цар 10:1-4.

сезгя, книгячеляр, фарисейляр, жумачылар! кюмелгян гроблар öстöннян кешеляр табтаб жöрöйляр, ўзляре аны белмейляр, сез дя гел шул гроблар шикелле, дигян. 45 Мынар карышы законъ белеўче беряў Іисуска айткян: эй Öйрятеўче, мыны айтеўең белян Син безне дя кур итясен, дигян. 46 Аммя Іисусъ айткян: сез законъ белеўчелярга дя читен: сез кешеляр öстöня кютяреб жöрöй алмаслык жöкляр саласыз, аммя ўзегез шул жöклярга бер бармагыгызны да тейереб карамыйсыз.

Зач. 62. 47 Айгай сезгя! Сез аталарыгыз ўтергян пагамбярлярга памятниклар торгозасыз. 48 Шунын белян сез аталарыгыз эшляреня таныклык итясез, алар белян бер уйдаш буласыз: алар пагамбярлярне ўтергянняр, аммя сез аларга памятниклар торгозасыз. 49 Шунар кюря Алла белемнеге айткян: мин аларга пагамбярляр, апостоллар жибярем, аларнын кайсысын ўтererляр, кайсысын кыуарлар, дигян. 50 Дöнья булдырылганнан бирле булган бар пагамбярлярнен тюгелгян каннары шушы тыумадан соралсын; 51 Авель каныннан башлаб, корман урны белян келяў öйö арасында ўтерелгян Захаріянын канына чаклы, чын айтямен сезгя, шушы тыумадан соралыр. 52 Айгай сезгя законъ белеўчелярга! сез белемнек ачкычын алдыгыз; ўзегез дя кермядегез, керясе килгяннярне дя кертмядегез, дигян. 53 Іисусъ аларга мыны айткян чагында, книгячеляр белян фарисейляр Анар бик каты жабышыб, кюб сюзляреня жауаб айттерергя тырышканнар; 54 Аны сагалаганнар, Аны айыблар öчöн, ауызыннан чыккан сюзеннян эляктерергя тырышканнар.

12-нче бюлем

1 Аннары калык менняб жыйылышыб, бер берсен тыгызлаб торган чагында, Іисусъ ин элеке Ўз öйрянеўчеляреня айтя башлаган: фарисейляр ачеткеченнян, жумалауларыннан сакланыгыз, дигян.

Зач. 63. 2 Жяшергян нястянен ич берсенен кюренмей калганы жук, жяшерендягенен беленмей калганы да жук. 3 Шунар кюря, сез карангыда айткян сюз, жактыда эшетелер, öй эченда колакка гна айткянегез, öй тюбясендя сöйлянер. 4 Мин сез дусларыма айтямен: тянне ўтереўчелярдян, аммя суныннан бер нястя дя кыла алмый тор-

ганнардан курыкмагыз. 5 Ämмя Мин сезгя кемнян куркырга кирякне äйтерем: ўтергяч, тамукка төшӧрӧргя кыуаты бардан куркыгыз, чыннаб äйтямен сезгя: шундыйдан куркыгыз. 6 Биш чыбчык ике ассарійгя сатыла төгӧл ме? алайда Алла аларнын берсен дя онотмый. 7 Ämмя сезнен башыгыздагы чячегез дя барысы да санаулы. Инде айса курыкмагыз, сез кюб чыбчыклардан кадерлеряк, дигян.

Зач. 64. 8 Мин сезгя äйтямен: кем дя кем Мине кешеляр алдында äйтеб белдерся, ÄдямУлы да Алла пяриштяляре алдында аны äйтеб белдерер. 9 Ämмя кем Мине кешеляр алдында танса, ул ўзе дя Алла пяриштяляре алдында танылыр. 10 Ädям Улына (курлык) сюз äйтеўче äркемгя кичерелер; ämмя Святый Тынга курлык äйткян кешегя кичерелмяс. 11 Сезне синагогаларга, тюряляр катына, башлыклар жанына китергян чакта, ничек жауаб бирербез, жя ней äйтербез диб кӧйӧнмягез. 12 Ней äйтясене Святый Тын сезгя шул сагаття öйрятер, дигян.

Зач. 65. 13 Калык арасыннан беряў Іисуска äйткян: эй Öйрятеўче, минем агама äйтсяня, калган малны мина айырыб бирсен, дигян. 14 Ämмя Ул шул кешегя äйткян: сезгя хокӧм итеўче итеб, жя сезне айырыучы итеб, Мине кем куйды? дигян. 15 Шунда аларга äйткян: карагыз, малга биренеўдян сакланыгыз, кешенен гумере малы кюбкя карамый ич, дигян.

Зач. 66. 16 Аннары аларга мясял äйткян: бер бай кешенен басыуда ашлыгы бик унган. 17 Ул ўз кюнгелендя уйлаган: мин ней эшлейем? ашлыгымны жыйыб салыр урным жук, дигян. 18 Аннары äйткян: мына ней эшлярем: амбарларымны уаттырым да зурырак амбарлар салдырыб, шунда бар ашлыгымны да, бар малымны да жыйыб куярым. 19 Аннары ўз жаныма äйтермен: эй жаным, синең инде кюб жылга житярлек жата торган кюб малың бар, инде тынычлан, аша, эч, кыуан дирем, дигян. 20 Тик Анғар Алла äйткян: эй акылсыз! шушы тӧндюк жанынгны синнян алырлар, äзерлягянең кемгя калыр суң? дигян. 21 Алла ӧчӧн жыймыйчы, малны ўзе ӧчӧн гня жыя торган кешегя шулай була, дигян. 22 Аннары öйрянеўчеляреня äйткян: шуңар кюря сезгя äйтямен: ней ашарбыз диб жаныгыз ӧчӧн кӧймягез, тянегез ӧчӧн дя ней кеярбез диб кӧймягез. 23 Жан ашамныктан, тян кеймнян кадерле. 24 Кар-

галарга карагыз: алар чячмейляр дя, урмыйлар да, аларнын клятляре дя, амбарлары да жук, алай да Алла аларны туйдыра; сез кошлардан кюб кадерле тёгёл ме? 25 Кем сезнен арадан кёйёнёб, ўз буйын бер гня терсяк буйы арттыра алыр? 26 Айса азга гна да кёчёгёз житмягяч, бютян нястяляр ёчён ник кёйёнясез? 27 Чячяклярга карагыз, алар ничек ўсяляр: эшлямейляр дя, эрлямейляр дя; Мин сезгя айтямен: Соломонъ бик данныклы булса да, аларнын берсе гня чаклы да кейеня алмаган. 28 Ягяр дя бёгён бар, аммя иртягя пичкя ташларлык кырдагы ўлямне Алла шундый кейендергяч, эй аз ышаныучылар, сезне бигряк тя жакшырак кейендермяс меней? 29 Алай булгач, сез ней ашарбыз, жя ней эчярбез диб эзлянмягез, сагышланмагыз. 30 Мындыйнын барын да бу дёнья кешеляре гня эзлейляр, аммя ул нястялярнен сезгя киряк икянен Атагыз белядер. 31 Бигряк Алла Падшалыгын эзлягез, аннары ул нястяляр барда сезгя östяб бирелер.

Зач. 67. 32 Эй кечкеня кётёў, курыкма! Атагыз сезгя падшалык бирергя кюнел итте шул. 33 Малларыгызны сатыгыз, садака бирегез, Ўзегезгя тузмый торган кабчыклар, кимемей торган мал кюктя азерлягез: анда бур да жакыннашмый, кёя дя теймей. 34 Малыгыз кайда булса, кюнелегез дя шунда булыр шул. 35 Билегезгя эзяр бяйляўле булсын, жактырткычларыгыз жаныб торсон. 36 Туйдан кайтасы эялярен кётёб тора торган кешеляр кюк булыгыз, алар эяляре кайтыб, ишек кагыу белян, анар ачарга азер торалар. 37 Эяляре кайтыб, уяу кёйё очраткан кызмятчеляр бахетле; сезгя чыннаб айтямен: ул билен бяйляб, аларны утыртыб, жакын килеб, аларга кызмят итеб жёрёр. 38 Ягярдя тённён икенче бюлемендя, жя ёчёнчё бюлемендя кайтыб та, аларны шулай (уяу кёйё) очратса, ул кызмятчеляр бахетле. 39 Сез белясез, ягяр жорт эясе бурнын кайсы сагаття килерен белся, ул уяу торор ыйы, ўз жортона казыб керергя ирек бирмяс эйе. 40 Сез дя азер булыгыз, Адям Улы сез уйламаган сагаттюк килер шул, дигян. 41 Шул чакта Петръ Анар айткян: эй Ходай! Син бу мясялне безгя гня айтямесенг, алля бар кешелергя дя ме? дигян.

Зач 68. 42 Ходай айткян: кызмятчеляреня багытында ўлчяб, икмяк бирсен диб, эяляре аларга башлык итеб куйган, акыллы, гадел жорт караучы кюк кем? 43

Эясе килгян чакта, анӷар шулай кылыб туры килгян кол бахетле. 44 Чыннаб айтямен сезгя: ул аны бар малына баш итеб куяр. 45 Ӓгяр ул кол ӳз кюӈелендя: эям тиз килмяс ӓле диб, кызмятче ирлярне дя, катыннарны да кыйнарга тотоноб, ӳзе ашаб, эчеб, эчкелеккя салынса, 46 Ул колнон эясе кол кӧтмягян кӧннӧ, ул уйламаган сагаття килеб, аны уртара чабыб ӧзяр дя аны денсезляр ӧлӧшӧня тӧшӧрӧр. 47 Эясенен иркен беля тороб, ӓзер булыб тормаган, анын иркен кылмаган кол бик каты кыйналыр. 48 Ӓммя белмейчен, кыйынга тейешле эш кылган кол ӓз кыйналыр.

Зач. 69. Кюб бирелгян ӓр-бер кешедян кюб соралыр да; кемгя кюб табшырылса, аннан исябе дя артык соралыр. 49 Мин жир östӧня ут тӧшӧрӧйӧм диб килдем, инде жана башласын ыйы диб бик телеймен. 50 Мин чумылыу белян чумылдырыласы; ул булгынчы бик интегям. 51 Ӓлля сез Мине жиргя тынычлык биргя килгян диб уйлыйсыз мы? Жук, сезгя ӓйтямен: Мин айырырга килдем: 52 Мыннан былай бер ӧйдяге биш кеше айырылышыр, ӧчӧсӧ икесеня карышы, икесе ӧчӧсӧня карышы торор: 53 Атасы улына карышы торор, улы атасына карышы торор; анасы кызына карышы торор, кызы анасына карышы торор; бейеме килененя карышы торор, килене бейеменя карышы торор, дигян. 54 Аннары Іисусъ калыкка да ӓйткян: сез кояш байышы жагыннан киля торган болотно кюргяч, шундук ӓйтясез: жаӈгыр жауар дисез, шулай була да. 55 Тӧшлӧк жагыннан жил исся, кызыу булыр дисез, була да. 56 Эй жумалаучылар! жирнен, кюкнен тӧсӧн айыра белясез, ӓммя шушы багытны ничек танымыйсыз суӈ? 57 Ней буласыны ник ӳзегездян караб белмейсез? 58 Даучыӈ белян бергя башлык жанына барсаӈ, жулда чагындук аннан котолорга тырыш, жугыйса ул сине тюря катына алыб кермясен; тюря сине азаблаучыга табшырыр, ӓммя азаблаучы сине ӧтӧрмянгя жабар. 59 Синӷа ӓйтямен: калдык полушкаӈны биреб бетермейчен, син аннан чыкмассыӈ, дигян.

13-нче бюлем

Зач. 70. 1 Шул чакта кайсы кешеляр килеб, Пилатъ Галилея кешеляренен каннарын китергян корманнарына катыштырганны Іисуска ӓйткянняр. 2 Іисусъ аларга жауаб биреб ӓйткян: бу Гали-

лея кешеляре Галилеянын буган калыгыннан да жазыклырак булганга кюря, шулай азабланнанардыр диб уйлыйсыз мы ялля? дигян. 3 Сезгя айтямен: жук; ягяр тяўбя итмясягез, барыгыз да шулай бетярсез. 4 Жя тагы Силоамъ башнясе ауыб, басыб ўтергян ун сигез кеше Іерусалимда тора торган кешелярнен барысыннан да айыблырак булганнардыр диб уйлыйсыз мы ялля? 5 Мин сезгя айтямен: жук; ягяр тяўбя итмясягез, барыгыз да шулай бетярсез, дигян. 6 Аннары бу мясялне айткян: беряўнен жёзём бакчасында утырткан смоковница агачы бар икян; ул анын жимешен эзлярга килгян, тик табмаган. 7 Аннары бакчачыга айткян: мына мин инде öч жылдан бирле бу смоковница агачыннан жимеш эзлярга килямен, тик табмыймын; аны кис, ул нейгя бушка урын алыб тора? дигян. 8 Бакчачы анар жауаб биреб айткян: эй эям, аны быйылга да калдырсана, мин анын айлянясендяге балчыгын казыб, тирес салыб карыйым: 9 Жимеш китермяс ме? ягяр дя китермяся, аны килясе жылны кисярсен, дигян.

Зач. 71. 10 Суббота könnö Іисусъ бер синагогада öйряткян. 11 Анда ун сигез жылдан бирле эчендя ялсезлек тыны торган бер катын бар икян; ул шуннан тартышкан икян, тöз тора алмый икян. 12 Іисусъ аны кюреб, ўз катына дяшеб алыб, анар айткян: эй катын, син инде ялсезлегеңнян котоласың, дигян. 13 Аннары анын öстöня кулларын салган, ул шул сяттюк тöзлянгян дя Алланы данный башлаган. 14 Шул чакта синагога башлыгы Іисуснын суббота könnö тöзяткянен ошатмыйчы, калыкка айткян: эш эшлей торган алты кön бар ич, тöзялергя шул könнярдя килегез, ямма суббота könnö килмягез, дигян. 15 Ходай анар жауаб биреб айткян: эй жумачы! сезнен яр кайсыгыз суббота könnö ўз ўгезен, жя ишяген утлыктан чишеб алыб, эчерергя алыб бармый меней? 16 Алай булгач, бу ун сигез жылдан бирле шайтан бяйляб тота торган катынны, Авраамъ кызын шул бяйдян котолдорырга суббота könnö тейеш тögöл эйе меней? дигян. 17 Ул мыны айткяндя. Анар карышы торган кешеляр барысыда оялганнар; бар калык та Анын данныклы эшляреня бик сöйöнгян.

Зач. 72. 18 Іисусъ айткян: Алла Падшалыгы нейгя ошаулы? Аны нейгя ошатыйым? 19 Ул горчица орлогона ошаулы; ул орлокно бер кеше алыб, ўз бакчасына утырткан; ул ўскян, зур агач бул-

ган, ботакларында ауа кошлары жяшенерлек булган, дигян. 20 Тагы äйткян: Алла Падшалыгын нейгя ошатыйым? 21 Ул äчеткеч апарага ошаулы; аны бер катын алган да öч ўлчяў онга катыштырыб, бары бергя äчеб житкенче, äчетергя куйган, дигян. 22 Аннары Ул калаларда, ауылларда жöрöб öйрятеб, Іерусалимга таба барган. 23 Беряў Анґар äйткян: эй Ходай! котолоучылар äз меней? дигян. 24 Іисусъ аларга äйткян: Тар кабкадан керергя тырышыгыз; сезгя äйтямен: кюбесе керергя эзлярляр, тик керя алмаслар шул. 25 Öйнöн эясе тороб, ишеген жабкач, сез тышта тороб, ишек кагыб äйтерсез: эй Ходай! эй Ходай! безгя ач, дирерсез; ämмя Ул сезгя жауаб биреб äйтер: сезнен кайдагы икянегезне белмеймен, дирер. 26 Шул чагында сез äйтерсез: без Синеґ алдында ашадык та эчтек тя, Син безнен урамнарыбызда öйряттеґ, дирерсез. 27 Ämмя Ул äйтер: сезгя äйтямен: сезнен кайдагы икянегезне белмеймен; эй дöрöссöзлöк кылыучылар, барыгыз да Миннян китегез, дирер. 28 Шунда Авраамнын, Исаакнын, Іаковнын, бар пагамбярлярнен дя Алла Падшалыгында икянен, ämмя ўзегезнен тышка кыуыб чыгарылганыгызны кюрерсез. Шул чакта жылау, теш шыкырдатыу булыр. 29 Шунда кояш чыгышыннан да, кояш байышыннан да, тöн жагыннан да, тöшлöктян дя килеб, Алла Падшалыгында урыннашырлар. 30 Мына алда буласы арттагылар бар, артта буласы алдагылар бар, дигян.

Зач. 73. 31 Шул кöннö фарисейлярнен кайсылары Іисуска килеб äйткянняр: чык, мыннан кит, Иродъ Сине ўтермякче була шул, дигянняр. 32 Ул аларга äйткян: барыб, ул тöлкöгя äйтегез: мына Мин бöгöн дя, танґда да женнярне кыуыб чыгарам, ауырыуларны тöзятям, öчöнчö кöннö бетерермен. 33 Алай да Миња бöгöн дя, танґда да, бöрсö кöндя жöрöргя тейеш äле, пагамбярнен Іерусалимнан бютян жирдя ўлгяне жук шул. 34 Эй пагамбярлярне ўтереб бетереўче, синґа жибярелгяннярне таш белян атыб ўтереўче Іерусалимъ, Іерусалимъ! тауык ўз чебешлярен канаты астына жыйган кюк, синеґ балаларынґны ничя табкыр жыясым килгян эйе, ämмя сез телямядегез. 35 Мына инде жортогоз сезгя буш кала. Мин сезгя äйтямен: мыннан былай Ходай исеменя Килеўче даннаулы диб сез äйтер багыт житкенче, Мине кюрмяссез, дигян.

14-нче бюлем

Зач. 74. 1 Бер табкыр суббота көннө Іисуска фарисей башлыкларынын берсенен өйөня кереб, аш ашарга туры килгян; алар Аны сагалаганнар. 2 Шунда Анын алдына водянка [1] белян чирлей торган кеше килгян. 3 Шул сяятлей Іисусъ законъ белеўчелярдян, фарисейлярдян сораган: суббота көннө төзятергя тейеш ме? дигян. 4 Алар дяшмягянняр. Аннары тейенеб, аны төзятеб жибяргян. 5 Шунда аларга äйткян: äгяр берегезнен ишяге, жя ўгезе койога төшся, суббота көннө булса да аны шундук койодан чыгармас мы? дигян. 6 Анын бу сюзеня алар жауаб äйтя алмаганнар. 7 Шунда чакырылган кунаклар тюрдяге урыннарны ничек сайлаганны кюреб, Ул аларга мясял äйткян: 8 Сине беряў туйга чакырса, син тюргя утырма, чакырылганнар арасында синнян кадерлесе булыб, 9 Сине дя, аны да чакырган кеше жанына килеб, сина: урнынгны мынар бир димясен; ул чакта син оялыб, ин тюбянге урынга утырырга тейеш булырсын. 10 Ämмя син чакырылгач, килеб ин тюбянге урынга утыр, сине чакырган кеше жанына килеб, сина: эй дусым, жугарырак утыр дисен; шул чагында синен белян бергя утырыучылар алдында кадерле булырсын: 11 Ўзен ўзе ололаучы äр-кем кечелянер, ämмя ўзен кечеляндереўче ололаныр шул, дигян.

Зач. 75. 12 Тагы Ўзен ашка чакырыучы кешегя дя äйткян: жя көндöз, жя кич аш жасаган чагында, син дусларынгны, агаэнеляренгне, карендяшляренгне, бай кюрешеляренгне чакырма, алар да бер-бер чакта мине чакырыб, минa кайтарсыннар диб. 13 Ämмя сый жасаган чагында, син жарлыларны, гареблярне, аксакларны, сукырларны чакыр: 14 Алар синa кайтара алмагангa кюря, син бахетле булырсын, синa гаделляр терелеб торганда кайтарылыр шул, дигян. 15 Мыны эшетеб, Анын белян бергя утырыучыларнын берсе Анар äйткян: Алла Падшалыгында аш ашасы кеше бахетле, дигян.

Зач. 76. 16 Іисусъ анар äйткян: бер кеше кич оло аш жасаб, кюб кешелярне öндягян. 17 Аш багыты житкяч, öндялгяннярга: инде барыгыз, барыда äзер диб äйтергя колон жибяргян. 18 Барысыда сюз берляшкян кюк, чигеня башлаганнар. Элекегесе анар äйткян: мин жир алдым, минa аны барыб карарга ки-

[1] Бирян дигян чир.

ряк, сиңа ўтенямен, миңа айыб итя кюрмя, дигян. 19 Икенчесе äйткян: мин биш пар ўгез алдым, аларны сынаб карарга барамын, сиңа ўтенямен, миңа айыб итя кюрмя, дигян. 20 Öчöнчöсö äйткян: мин öйляндем, шуннуктан бара алмыйым, дигян. 21 Аннары шул кол мыны ўз эясеня кайтыб äйткян. Шунда жорт эясе ачыуы килеб, ўз колона äйткян: бар тизеряк, кала урамнарыннан да, тыкырыклардан да очраган жарлыларны, гареблярне, аксакларны, сукырларны мында алыб кил, дигян. 22 Кол äйткян: эй эям, мин син кушканча кылдым, тагы да урын бар, дигян. 23 Эя колга äйткян: син тагы жулларга, киртя буйларына барыб, (очраганнарны) кыстаб алыб кайт, öйöм тулсын. 24 Мин сезгя äйтямен: теге öндялгяннярнен берсе дя ашымны ашамас; чакырылганнар кюб, ämмя сайланганнар äз шул, дигян.

Зач. 77. 25 Iисусъ белян бик кюб калык барган, Ул боролоб, аларга äйткян: 26 Миңа килеўче кеше атасын, анасын, катынын, балаларын, ага-энелярен, тута-сеңнелярен, тагы ўз жанын да жаратмас булмаса, Минем öйрянеўчем була алмас. 27 Качын кютяреб, Минем артымнан килмягяне дя Минем öйрянеўчем була алмас. 28 Кем сезнен арадан башня салдырасы булыб, элеке утырыб, ней катле чыгарын, аны торгозоб житкезергя житярлек малы барын санаб карамас? 29 Жугыйса нигезен салгач, аны торгозоб житкезя алмаса, кюргян кешеляр барда аннан кölярляр: 30 Бу кеше торгоза башлаган ыйы, тик бетеря алмады дирерляр. 31 Жя кайсы падша икенче падшага карышы сугышка барасы булгач, элеке утырыб, ўзеня карышы киля торган жегерме мең чиреўле падшага ўзенен ун меңне чиреўе белян карышы тороргa кöчö житярен, житмясен киңяшляшмяс? 32 Житмясен белся, теге жыракта чагындук, ул аңар татыулык турысында ўтенергя илчеляр жибярер. 33 Шулай, сезнен äр-кайсыгыз ўзенен бар нястясеннян айырылмаса, Минем öйрянеўчем була алмас. 34 Тоз жакшы нястя; ägяр тоз ўз кыуатын жугалтса, аны ней белян тöзятерсен? 35 Ул жиргя дя, тиреcкя дя жарамый, аны тышка чыгарыб ташлыйлар. Эшетергя колагы бар кеше эшетсен! дигян.

15-нче бюлем

Зач. 78. 15:1 Іисусъ катына Аны тыңнар өчөн мытарлар, жазыклы кешеляр барысы да жакынашканнар. 15:2 Фарисейляр белян книгячеляр жаратмыйчы әйткянняр: Ул жазыклыларны кабыл кюреб, алар белян бергя ашый, дигянняр. 15:3 Әммя Ул аларга шушы мясялне әйткян: 15:4 Кем сезнен арагыздан жөз сарыгы булыб, аларнын берсен жугалтса, туксан тугызын буш кырда калдырыб, жугалганын табкынчы эзлей бармас? 15:5 Аны табкач, сөйөнөб, жилкясеня кютяреб алыр да, 15:6 Өйөня кайтыб, дусларын, кюрешелярен чакырыб, аларга әйтер: минем белян сөйөнөшөгөз, мин жугалган сарыгымны табтым, дирер. 15:7 Сезгя әйтямен: кюктя дя шулай тяүбягя килгян бер гня жазыклы кешегя тяүбя итеү кирякле төгөл туксан тугыз гаделлярга сөйөнгяннян артыгырак сөйөнөшөрляр. 15:8 Жя кайсы катын ун драхмасы [1] булыб, бер драхмасын жуйса, аны эшям жандырыб, бюлмясен себереб, табкынчы тырышыб эзлямяс? 15:9 Әммя табкач, ўзенен дус катыннарын, кюреше катыннарын чакырыб әйтер: минем белян сөйөнөшөгөз, мин жуйган драхмамны табтым, дирер. 15:10 Сезгя әйтямен: тяўбя иткян бер гня жазыклы кешегя дя Алла пяриштяляре гел шулай сөйөнөшяляр, дигян.

Зач. 79. 15:11 Тагы әйткян: бер кешенен ике улы бар икян. 15:12 Аларнын кечесе атасына әйткян: әтей! малнын миңа теясе өлөшөн айырыб бирче, дигян. Атасы малын аларга өляшеб биргян. 15:13 Бер-ауык көн ўткяч, кече улы бар өлөшөн жыйыб алыб, жырак жиргя киткян; анда азгын тороб, малын таратыб бетергян. 15:14 Ул бар малын бетергяч, шул жакта бик каты ачлык булган, ул жөдяўгя калган. 15:15 Аннары барыб, шул жактагы кешелярнен берсендя тора башлаган; ул кеше аны басыуына дунгызлар котяргя жибяргян. 15:16 Ул шунда дунгызлар ашый торган кузакнын төшө белян корсагын тутырса да жаратасы икян, әммя аны да анар беряў дя бирмягян. 15:17 Аннары уйга төшөб, әйткян: минем атамнын ней чаклы жалчылары икмяккя тук булыб торалар, әммя мин ачлыктан ўлям, дигян; 15:18 Кая, торойом да атама кайтыб, анар әйтейем: әтей! мин кюккя [2] дя, синя да жазы-

[1] Кömөш тянкя, 20 тейенгя жакын.

[2] Аллага.

клы булдым, 19 Инде улыҥ диб
йтелергя дя тормоймын, ичма-
са мине жалчыларыҥ исябеня
алсана диб. 20 Аннары торган да
атасына киткян. Атасы аны жы-
рактын кюреб, бик кызганган да
жöгöрöб чыгыб, муйнына асы-
лыныб, аны ӳбеб торган. 21 Улы
анҕар йткян: тей! мин кюк-
кя дя синҕа да жазыклы булдым,
инде улыҥ диб йтелергя дя тор-
моймын, дигян. 22 Ммя атасы
ӳз колларына йткян: иҥ йбят
кеймне китереб, анҕар кейгезе-
гез, кулына жöзök, аякларына
башмаклар бирегез: 23 Симерт-
кян бызауны китереб суйыгыз;
ашыйык, сöйöнöшöйök, 24 Бу
улым ӳлгян эйе, терелде, жу-
галган ыйы, табылды шул,
дигян. Аннары сöйöнöшя баш-
лаганнар. 25 Оло улы басыуда
икян; ул кайтышлый, öйгя жа-
кыннашарак, жырлаган ауазлар,
сöйöнöшкян тауышлар эшеткян;
26 Бер кызмятчене чакырыб ки-
тереб, аннан: бу ней хал? диб со-
раган. 27 Ул анҕар йткян: энеҥ
кайтты, атаҥ аны исян карышы
алганы сятлей симерткян бы-
зауны суйдырды, дигян. 28 Ул
ӳпкяляб, кермей жöргян. Атасы
чыгыб, аны чакырган. 29 Ммя
ул атасына жауабка йткян:
мына мин ней катле жылдан
бирле синҕа кызмят итямен, ич
кайчан кушканыҥны кылмый
калдырганым жук; алай да син
миҥа дусларым белян бергя
сыйланырга бер чакта да кязя
бяряне дя бирмядеҥ. 30 Ммя
бу бар малын азгын катыннар-
га таратыб бетергян улыҥ кай-
ткач, анын öчön син симерткян
бызауны суйдырганыҥ, дигян.
31 Атасы анҕар йткян: эй улым,
син жалан минем белян, ми-
неке барда синеке; 32 Ммя бу
энеҥ ӳлгян эйе, терелде, жу-
галган ыйы, табылды, мыҥар
сöйöнöшöб кыуанышырга
тейеш эйе, дигян.

16-нчы бюлем

Зач. 80. 1 Аннары Ул Ӳз
öйрянеӳчеляреня дя йткян: бер
кеше бай булган, анын жорт ка-
раб тороучысы да бар икян; бай-
га анын турысында малыҥны та-
ратыб бетеря диб житкезгянняр.
2 Ул аны чакырыб алыб, анҕар
йткян: мин бу синеҥ турында
ней эшетямен? тоткан нястяҥ
турысында исяб бир, син инде
мыннан былай жортомны ка-
раб тора алмассын шул, дигян. 3
Шунда жорт караучы ӳз эчендя
йткян: мин ней эшлейем икян?
эям жорт караулыкны миннян
ала; (жир) казый алмыймын, со-

ранырга ояламын. 4 Инде жорт караучылыктан тёшкяч, кешеляр мине ўз ёйляреня алыб тотсоннар дисям, ней эшлярга белямен, дигян. 5 Аннары эясеня бурычлы кешелярне берян-берян чакырыб, элекегесеня айткян: синең эямя бирясең ней катле? дигян. 6 Ул айткан: жöз ўлчяў май (бирясем бар), дигян. Ул анар айткян: бурыч жазыуыңны ал да утырыб, тизеряк илле диб жаз, дигян. 7 Аннары икенчесеня айткян: синең бирясең ней катле? дигян. Ул жауаб биргян: жöз ўлчяў бодай, дигян. Анар да айткян: бурыч жазыуыңны ал да сиксян диб жаз, дигян. 8 Шуннан суң эясе дöрöс тöгöл жорт караучыны öннö кылганы öчöн мактаган; бу гумер уллары ўз затларында жакты уллярына кюря öннöряк. 9 Мин дя сезгя айтямен: сез дöрöссöзлöк малы белян ўзегезгя дуслар жасагыз, сез жарлылангач, алар сезне мянге жортка кабыл алсыннар ыйы.

Зач. 81. 10 Азда дöрöс кеше кюбтя дя дöрöс була, аммя азда дöрöс тöгöл кеше кюбтя дя дöрöс булмый. 11 Шулай, сез дöрöссöзлöк малында дöрöс булмагач, чын малны сезгя кем ышаныр? 12 Агяр сез жат малда дöрöс булмагач, ўзегезнекен сезгя кем бирсен? 13 Ич-бер кызмятче ике эягя кызмят итя алмас: жя берсен жаратмас, аммя икенчесен жаратыр; жя берсеня кюңелдян жöрöр, аммя икенчесеня кюңелсез гня жöрöр. Аллага да, байлыкка да кызмят итя алмассыз, дигян. 14 Мынын барысында акча сöйöўчян фарисейляр дя эшеткянняр, алар Аннан кölöшкянняр.

Зач. 82. 15 Ул аларга айткян: сез кешеляр алдында ўзегезне гадел итеб кюрсятясез, аммя Алла сезнен кюңеллярегезне беля: кешелярга кадерле нястя Алла алдында жирянгеч. 16 Законъ да, пагамбярляр дя тик Іоаннга чаклы гна; шул багыттан бирле Алла Падшалыгы сöйляня, äр-кем анар тырышыб кна керя. 17 Алайда законнын бер гня сызыгы жугалыуына кюря, кюк белян жир ўзгяреўе жиңелеряк. 18 Катынын айырыб жибяреб, бютян катын алган кеше äр-берсе уйнашлык итя, ире айырыб жибяргян катынны алыучы да äр-кем уйнашлык итя.

Зач. 83. 19 Бер кеше бай икян, ул порфирдан, виссоннан текян асыл кеймняр гня кейенгян, кöн сайын бик шяб сыйлар жасаб кна ўткяргян. 20 Тагы Лазарь атлы бер жарлы бар икян:

ул шул байнын кабкасы төбөндя кутырлы тянне көйö жаткан; 21 Байнын öстяленнян төшкян уалчыклар белян гня булса да туйынасы килгян; анын кутырларын этляр килеб жалаганнар. 22 Жарлы ўлгян, ўлгяч, пяриштяляр аны Авраамъ кочагына иткянняр; бай да ўлгян, аны кюмгянняр. 23 Ул тамукта азабланган чагында, кюзлярен кютяреб караган, карагач, жыраклын Авраамны, анын кочагында Лазарне кюреб, 24 Кычкырыб äйткян: эй Авраамъ ätей! миңа изгелек кылсана, Лазарне жибярсяня, ул бармагынын очон сыуга чылатыб, телемне салкыннандырсынчы, мин бу жалкында азабланам шул, дигян. 25 Авраамь äйткян: улым! син тормошоңда рахатляндең, ämмя Лазарь азабланды, шуны исеңя төшöр; казер инде ул мында сöйöнöб тора, ämмя син азабланасың; 26 Аннан былай тагы да безнен белян сезнен арада бик зур төбсöз урын куйылган, шунныктан мыннан сезнен катка кючясе килеўчеляр кючя алмыйлар, сезнен каттан безгя дя кючмейляр, дигян. 27 Аннары бай äйткян: айса синŋа ўтенямен, ätей, аны минем атам öйöня жибярсяня; 28 Минем биш агай-энем бар, (мындагы халне) ул аларга äйтеб кюрсятсен, алар да бу азаб урнына килмясенняр эйе, дигян. 29 Авраамъ анŋар äйткян: аларнын Моисейе бар, пагамбярляре бар, аларны тыңнасыннар, дигян. 30 Ул äйткян: эй Авраамъ ätей! жук, ägяр беряў-беряў аларга ўлгян жиреннян терелеб кайтса, алар тяўбя итярляр, дигян. 31 Шунда Авраамъ анŋар äйткян: Моисейне дя, бютян пагамбярлярне дя тыңнамагач, беряў-беряў ўлгян жиреннян терелся дя ышанмаслар, дигян.

17-нче бюлем

1 Аннары Iисусъ Ўз öйрянеўчеляреня äйткян: алданыулар булмый калмас, алайда алдандырыучы кешегя читен булыр: 2 Шушы кечкенялярнен берсен алдалаудан ул кешегя муйнына тегермян ташы асыб, дингезгя ташланганы жакшырак булыр ыйы.

Зач. 84. 3 Ўзегезне ўзегез сак тотогоз. Ägяр туганың синŋа карышы жазыкланса, аны анŋар äйтеб оялт; ägяр дя ўкенся, анŋар кичер; 4 Синŋа карышы көнöндя жиде табкыр жазыкланса да көнöндя жиде табкыр ўкенся, миңа кичеря кюр диб äйтся, анŋар кичер, дигян. 5 Апостоллар

Ходайга айткянняр: бездя ышаныуны арттырсана диб. 6 Ходай айткян: ягяр сезнен ышаныуыгыз горчица бөртөгө кюк кня булса да шушы смоковница агачына: мыннан кубтарылыб, дингезгя барыб утыртыл дисягез, ул сезне тыңнар ыйы. 7 Кем сезнен арадан, сукалый торган, жя көтөў көтя торган коло булыб, басыудан кайткач, аңар: кил тизеряк, өстял äйлянясеня утыр дирер? 8 Алай дейеў урнына аңар былай äйтмяс ме: миңа кичке ашны äзерляб куй да биленя эзяр бяйляб, мин ашаганда, эчкяндя, миңа кызмят итеб жöр, аннары ўзең дя ашарсың, эчярсең? диб. 9 Кушканны кылганы өчөн, ул шул колга тау итяр ме? итмяс диб уйлыймын. 10 Сез дя шулай, ўзегезгя кушканны барысын да кылыб бетергяч, äйтегез: без жараусыз коллар, без тик кыларга тейешлене гня кылдык шул, дигез. 11 Іерусалимга барышлый Иисусъ Галилея белян Самарія арасыннан ўткян.

Зач. 85. 12 Ул бер ауылга кергян чагында, Аны кутырлы тяннe ун кеше очратканнар; алар жыраĸтынук туĸтаб тороб, 13 Каты ауаз белян кычкырганнар: эй Öйрятеўче Иисусъ, безне жарлыка диб. 14 Ул аларны кюргяч, аларга äйткян: барыгыз, свящennиклярга кюренегез, дигян. Барган чагында, алар тазарганнар. 15 Аларнын берсесе ўзенен тözялгянен кюреб, зур тауыш белян Алланы даннаб, кире кайткан да Иисуснын аягы астына жыгылыб, 16 Аңар тау иткян; ул Самарія кешесе икян. 17 Шунда Иисусъ äйткян: ун кеше тазарган ыйыгыз тöгöл ме? тугызы кая суң? 18 Алар Аллага дан китерергя ничек кире килмяделяр, тик бу жат затныкы гна килгян? дигян. 19 Аннары аңар äйткян: тор да кайт, ышаныуың сине коткарды, дигян.

Зач. 86. 20 Фарисейляр Иисустан Алла Падшалыгы кайчан килер диб сорагач, Ул аларга жауаб биргян: Алла Падшалыгы кюренеб килмяс; 21 Мына ул мында, жя ана тегендя диб äйтмясляр; Алла Падшалыгы сезнен эчегездя шул, дигян. 22 Тагы öйрянеўчеляреня äйткян: мына көнняр килер, ул чакта Ädям Улынын көнняренен бер гня көнөн булса да кюрясегез килер, тик кюрмяссез. 23 Сезгя äйтерляр: мына Ул мында, жя ана тегендя дирерлер; сез бармагыз, эзлямягез. 24 Жяшен кюкнен бер кырыйыннан икенче кырыйына чаклы жалтраб, жяшняб киткян кюк, Ädям Улы да Ўз көнөндя шулай булыр. 25 Тик

элгяре Ул бик кюб азабланырга тейеш, шушы тыума Аны кабыл алмас.

Зач. 87. 26 Ной көннярендя ничек булган, Ädям Улынын көннярендя дя гел шулай булыр: 27 Ной кимягя керер көнгя чаклы, кешеляр ашаганнар, эчкянняр, öйлянгянняр, кеяўгя киткянняр, аннары сыу килеб, барысын да ўтереб бетергян. 28 Лотъ көннярендя дя шулай булган: ашаганнар, эчкянняр, сатыу-алыу иткянняр, агачлар утыртканнар, каралды житкереб торганнар, 29 Ämмя Лотъ Содомъ каласыннан чыккан көннö кюктян ут белян кюкерт жауыб, барысын да жукка чыгарган. 30 Ädям Улы килгян көннö дя гел шулай булыр. 31 Ул көннö беряў ўзе ой тюбясендя булыб, äйберляре öй эчендя булса, ул аларны алыб китейем диб тöшмясен; басыуда булганы да öйöня таба боролоб карамасын. 32 Лотъ катынын исегезгя тöшöрögöз. 33 Ўз жанын саклаган кеше, аны жуяр, ämмя жанын жугалткан кеше, аны терелтер. 34 Сезгя äйтямен: ул тöннö ике кеше бер тюшяктя булса, берсесе алыныр, икенчесе калдырылыр. 35 Ике катын бергя (кул) тегермяне тартсалар, берсесе алыныр, икенчесе калдырылыр. 36 Ике кеше басыуда булсалар, берсесе алыныр, икенчесе калдырылыр, дигян. 37 Мынгар карышы Iисуска äйткянняр: эй Ходай, бу кайда булыр? дигянняр. Ул аларга äйткян: ўлякся жаткан тöшкя бöркötляр жыйылыр, дигян.

18-нче бюлем

1 Ул тагы аларга жалан теляк итяргя, моңаймый тороргa киряклене мясял китереб äйткян.

Зач. 88. 2 Бер калада Алладан да курыкмаган, кешедян дя оялмаган тюря бар икян. 3 Шул каладук бер тол катын бар икян; ул тюрягя барыб, син мине даучымнан жакласана диб онгай äйтя икян. 4 Тик тюря озакка чаклы жакласы килмягян. Сунғыннан ўзеня ўзе äйткян: мин Алладан да курыкмасам да, кешедян дя оялмасам да, 5 Бу тол катын миңа тынгы бирмягянгя кюря, аны жаклыймчы, мыннан былай ул килеб, мине абтратмасын, дигян. 6 Аннары Ходай äйткян: дöрöс тöгöл тюрянен ней äйткянен эшетясез ме? 7 Алла Ўзеня көнö, тöнö тилмеря торган Ўзе сайлаган кешелярен, озак жакламаган кюк тейся дя жакламас меней? 8 Мин сезгя äйтямен: аларны тиз

жаклар. Тик Ädям Улы килеб, жир östöндя ышаныуны табар микян? дигян. 9 Тагы ўзлярен ўзляре дöрöска куйыб, ämмя бютяннярне кимгя куя торган кешелярга шушы мясялне äйткян.

Зач. 89. 10 Ике кеше чиркяўгя теляк итярга кергянняр: берсесе фарисей, икенчесе мытарь. 11 Фарисей тороб, ўз эченнян былай диб телягян: эй Алла! Синға тау итямен, мин бютян кешеляр кюк тöгöл: алар талаучылар, рянжетеўчеляр, уйнашлык итеўчеляр; бу мытарь кюк тя тöгöл: 12 Атнасында ике табкыр ураза тотам, бар эшляб табканымнан унынчы өлөшөн бирямен шул, дигян. 13 Ämмя мытарь жыраклын тороб, кюккя таба кюзен кютяреб карарга да кыймаган, тик ўз кюкрягеня ўзе суга-суга äйтеб торган: эй Алла, мин жазыклыга изгелекле бул диб. 14 Сезгя äйтямен: шушысы ўз öйöня тегесеннян артыгырак дöрöска чыгарылыб кайткан; ўзен ўзе ололаучы ар-кем кечегя калдырылыр, ämмя ўзен ўзе кечеляўче ололаныр шул, дигян.

Зач. 90. 15 Iисусъ тейенсен диб, Анар балаларны да китергянняр; öйрянеўчеляре мыны кюреб, аларны туктатыб торганнар. 16 Ämмя Iисусъ, аларны чакырыб алыб, äйткян: балаларга Миңа килергя ирек бирегез, аларны туктатыб тормагыз, Алла Падшалыгы шундыйларныкы шул. 17 Чыннаб äйтямен сезгя: Алла Падшалыгын бала кюк кабыл алмаган кеше, анар керя алмас, дигян.

Зач. 91. 18 Башлыкларнын берсе Iисустан сораган: эй изге Öйрятеўче, мянге тормошка урыннашыр öчöн, мин ней кылыйым? дигян. 19 Iисусъ анар äйткян: ник син Мине изге диб äйтясен? беряў дя изге тöгöл, тик бер Алла гна (изге). 20 Бойорокларны белясен: уйнашлык итмя, ўтермя, урлама, жалган таныклык итмя, атаңны, анаңны саннаб тор, дигян. 21 Ул äйткян: мин быларнын барысын да жяштянюк тоттом, дигян. 22 Мыны эшеткяч, Iисусъ анар äйткян: синға тагы бер гня нястя житмей; нейең бар барысын да сат та жарлыларга öляш, синең малың кюктя булыр, аннары килеб, Миңа эяреб жöр, дигян. 23 Ämмя ул мыны эшетеўе белян, кайгыга тöшкян, ул бик бай икян шул. 24 Iисусъ анын кайгыга тöшкянен кюреб, äйткян: байларга Алла Падшалыгына кереўе ничек читен! 25 Бай кешегя Алла Падшалыгына кереўдян дöягя иня кюзеннян ўтеўе асатрак, дигян. 26 Мыны эшеткян ке-

шеляр äйткянняр: кем котола алыр суҥ? дигянняр. 27 Іисусъ äйткян: кешеляр булдыра алмаганны Алла булдыра ала, дигян. 28 Шунда Петръ äйткян: мына без барын да калдырыб, Синҥа эярдек, дигян. 29 Іисусъ аларга äйткян: чыннаб äйтямен сезгя: Алла Падшалыгы өчөн, өйөн, жя атасын, анасын, жя ага-энелярен, жя тута-сеҥнелярен, жя катынын, жя балаларын калдырган кеше беряў дя, 30 Äле шушы багытта да артыгы белян алмый калганы жук, ämмя буласы гумердя мянге тормошно алыр, дигян.

Зач. 92. 31 Ун ике (өйрянеўчесен) читкя чакырыб алыб, аларга äйткян: мына без Іерусалимга менеб барабыз; Ädям Улы турысында пагамбярляр жазган сюз барда шунда жиреня килер: 32 Аны жалган деннелярга тотоб бирерляр, Аннан мыскыл итярляр, Аны курларлар, Анҥар төкөрөб тутырырлар; 33 Аны кыйнарлар, ўтererляр, Ул өчөнчө көннө терелеб торор, дигян. 34 Тик өйрянеўчеляре мыннан бер нястя дя анҥамаганнар; бу сюз аларга жяшерен булгаи, ней äйтелгянне анҥыша алмаганнар.

Зач. 93. 35 Іисусъ Іерихонъ каласына жакыннашкан чагында, бер сукыр кеше жул буйында сораныб утыра икян. 36 Ўзенен жаныннан ўтеб барган калыкны эшетеб, ул: бу ней? диб сораган. 37 Анҥар: Назорей Іисусъ киля дигянняр. 38 Аннары ул: эй Давидъ Улы Іисусъ, мине жарлыка диб кычкыра башлаган. 39 Алдан бара торган кешеляр анҥар дяшяргя кушмаганнар, ämмя ул: эй Давидъ Улы, мине жарлыка диб, бигеряк тя нык кычкырган. 40 Іисусъ туктаб, сукырны Ўз жанына китерергя кушкан; ул Анын катына килгяч, Іисусъ аннан сораган: 41 Мин синҥа ней кылганны телейсен? дигян. Ул äйткян: эй Ходай! кюря торган булсам ыйы, дигян. 42 Іисусъ анҥар äйткян: кюря торган бул, ышаныуыҥ сине коткарды, дигян. 43 Ул шул сяттюк кюря торган булган, аннары Анҥар эяреб, Алланы даннаб жöргян. Бар калык та мыны кюреб, Алланы мактаган.

19-нчы бюлем

Зач. 94. 1 Аннары Іисусъ Іерихонга кереб, кала эченнян барган. 2 Шунда мытарлар башлыгы Закхей атлы бай кеше 3 Іисусны кюрергя тырышкан, тик ўзе тябяняк булганга кюря, калык ар-

тында тороб, кюря алмаган; 4 Алга жöгöрöб узыб, Іисусны кюрер öчöн, смоковница агачына менгян, Іисусъ шул агачнын жаныннан узасы икян. 5 Іисусъ шул урынга житкяч, кюзе тöшöб Закхейне кюргян, кюргяч, анӈар äйткян: Закхей, тизеряк тöш, Минӈа бöгöн синеӈ öйöнӈя керергя киряк, дигян. 6 Ул ашыгыб тöшкян дя Аны сöйöнöб кабыл алган. 7 Мыны кюреб, бар кешеляр дя зарланганнар, Ул жазыклы кешегя керде дейешкянняр. 8 Ämмя Закхей тороб, Іисуска äйткян: эй Ходай, малымнын жартысын жарлыларга бирермен, ägяр беряӳне-беряӳне бербер туры белян рянжеткян булсам, дюрт ölöш кайтарырмын, дигян. 9 Іисусъ анӈар äйткян: бöгöн бу жортка котолоу килде, ул да Авраамъ улы шул, 10 Ädям Улы жугалганны эзляб табыб, коткарырга килде, дигян. 11 Алар мыны тыӈнаб торган чакта, Іисусъ шуӈар öстяб мясял äйткян; Ул Іерусалимга жакын булганга кюря, алар Алла Падшалыгы тиз ачыласы диб уйлаганнар икян.

Зач. 95. 12 Іисусъ äйткян: оло затлы беряӳ ӳзеня падшалык [1] алыб кайтырга жырак жиргя китясе булган. 13 Ул ӳзенен ун колон чакырыб алыб, аларга ун мина [2] биреб äйткян: мин кайткынчы булар белян сатыу итеб табышланыгыз, дигян. 14 Тик кала кешеляре аны кюрялмыйлар икян, алар анын артыннанук илчеляр жибяреб, анын безгя падша булыуын телямейбез диб äйттергянняр. 15 Ул кеше падша булыб кайткач, кömöш биргян коллары äр-берсе ней чаклы табыш иткянне белер öчöн, аларны чакырткан. 16 Элекесе килеб äйткян: эй эям, синеӈ бер минаӈ ун мина табыш китерде, дигян. 17 Эясе анӈар äйткян: жакшы, арыу колом; äздя дöрöс булганыӈа кюря ун каланы башкарыб тор, дигян. 18 Аннары икенчесе килеб äйткян: эй эям, синеӈ бер минаӈ биш мина табыш китерде, дигян. 19 Мынысына да äйткян: син дя биш калага баш бул, дигян. 20 Аннары öчöнчöсö килеб äйткян: эй эям, мына синеӈ минаӈ, мин аны жаулыкка тöрöб, саклаб тоттом; 21 Мин синнян куркыб тордом, син каты кеше шул: ӳзеӈ салмаганны аласын, ӳзеӈ чячмягянне урасын, дигян. 22 Эясе анӈар äйткян: эй жаман кол, сине ауызыӈнан чыккан сюзлярең белян айыбларым: минем каты кеше икянемне, салмаганны алганымны, чячмягянне урганымны син белгян, 23 Бел-

[1] Падша булыулык.

[2] Мина бер грябянкя кömöш.

гяч, ник суҥ кӧмӧшӧмнӧ табыш биреўчелярга биреб тормадыҥ? мин кайткач, аны табышы белян алган булыр ыйым, дигян. 24 Аннары шунда тороучыларга ӓйткян: аннан минаны алыгыз да ун минасы барга бирегез, дигян. 25 Аҥар ӓйткянняр: эй башкарыучы, анын ун минасы барла баса, дигянняр. 26 Сезгя ӓйтямен: барга бирелер, ӓммя жуктан нейе бар, анысы да алыныр. 27 Мин падшалык итеўне телямягян дошманнарымны мында китерегез дя минем алдымда ўтерегез, дигян.

Зач. 96. 28 Мыны ӓйтеб бетергяч, Іисусъ алга таба Іерусалимга менеб барган. 29 Виѳсфагія белян Виѳанія дигян ауылларга, Елеонъ исемне тауга жакыннашкач, ике ӧйрянеўчесен жибяреб, 30 Ӓйткян: алдагы ауылга барыгыз; шунда кергяч, ӧстӧня бер чакта да беряў дя атланмаган, бяйляб куйган, жяш ишякне очратырсыз, аны чишеб, алыб килегез; 31 Ӓгяр беряў-беряў сездян: аны ник чишеб аласыз? диб сораса, аҥар былай ӓйтегез: Ходайга киряк булды, дигез. 32 Жибярелгянняр барыб, Ул ӓйткянчя очратканнар. 33 Алар жяш ишякне чишеб алган чагында, анын эяляре аларга ӓйткянняр: ишяк колонон ник чишеб аласыз? дигянняр. 34 Алар жауаб биргянняр: ул Ходайга киряк булды диб. 35 Аннары аны Іисуска китергянняр; ишяк колоно ӧстӧня кейемнярен салыб, Іисусны анын ӧстӧня атландырганнар. 36 Ул атланыб барган чагында, (кешеляр) кейемнярен жул ӧстӧня жяйеб барганнар.

Зач. 97. 37 Аннары Іисусъ Елеонъ тауыннан тӧшя башлагач, Анын кюб ӧйрянеўчеляре барысыда бар кюргян кодрятляре ӧчӧн, сӧйӧнӧб, зур тауыш белян Алланы даннаб, 38 Ӓйткянняр: Ходай исеменя килеўче Падша даннаулы! кюктя тынычлык, югарыда даннау. 39 Шунда калык арасыннан кайсы фарисейляр Аҥар ӓйткянняр: эй Ӧйрятеўче, ӧйрянеўчеляреҥне тый, дигянняр. 40 Ӓммя Ул аларга жауаб биреб ӓйткян: Мин сезгя ӓйтямен: ӓгяр былар туктаса, ташлар кычкырырлар, дигян. 41 Калага жакыннашкач, аҥар караб, анын ӧчӧн жылый башлаб, 42 Ӓйткян: эй (Іерусалимъ), ичмаса син шушы кӧнӧндя гня булса да синҥа тынычлык китерер ӧчӧн кылынганны белсяҥче, тик ӓле ул синеҥ кюзляреҥнян жяшеренеўле. 43 Синҥа кӧнняр килер, ул чакта дошманнарыҥ синеҥ ӓйлянячнян жир казыб ӧйӧб, чырмаб алырлар, сине ӓр-бер жагыҥнан кысар-

лар; 44 Сине жимерерляр, Синең балаларыңны эчендя ўтерерляр, синең эченда таш өстөндя таш та калдырмаслар, син ўзеңя котолоу килгян багытны белмяденг шул, дигян.

Зач. 98. 45 Аннары чиркяўгя кереб, анда сатыу итеўчелярне, алыучыларны кыуыб чыгара башлаган; 46 Аларга äйткян: жазылган ич: Минем öйöм теляк öйö, ämмя сез аны талаучылар оясы иткянегез диб. 47 Аннары кöн сайын чиркяўдя öйряткян. Архіерейляр, книгячеляр, калык башлыклары Аны бетерергя кöй эзлягянняр, 48 Тик Анга ней кыларга ämял табмаганнар, бар калык та жаныннан китмейчен Аны тыңнаб торган шул.

20-нче бюлем

Зач. 99. 1 Шул кöннярнен берсендя, [1] Іисусъ чиркяўдя калыкны öйрятеб, изге хабяр сöйлягян чагында, архіерейляр, книгячеляр, калык башлыклары Анын жанына килеб, 2 Анга äйткянняр: äйтче безгя: Син мыны кем бойороуы белян кыласын? жя мындый кыуатны Синга кем бирде? дигянняр. 3 Ул аларга жауаб биреб äйткян: Мин дя сездян бер турыда соройом, 4 Минга äйтегез: Іоаннъ чумылдырыуы кюктян булды мы, ялля кешелярдян ме? дигян. 5 Алар ўз араларында уйлашканнар: кюктян дисяк, Ул äйтер: ник суң анга ышанмадыгыз? дирер. 6 Ягяр кешелярдян дисяк, бар калык безне таш атыб ўтерерляр, алар Іоанны пагамбяр диб ышаналар шул, дигянняр. 7 Аннары жауаб биреб äйткянняр: кайдан икянен белмейбез, дигянняр. 8 Іисусъ аларга äйткян: Мин дя сезгя мыны кем бойороуы белян кылганымны äйтмямен, дигян.

Зач. 100. 9 Аннары Іисусъ калыкка шушы мясялне äйтя башлаган: бер кеше жöзöм агачлары утыртыб, аны бакчачыларга табшырыб, ўзе озак багытка читкя киткян. 10 Багыт житкяч, бакчамнан жимешляр бирсенняр диб, бакчачыларга кызмятчесен жибяргян; ämмя бакчачылар аны кыйнаб, буш кайтарыб жибяргянняр. 11 Тагы икенче кызмятчесен жибяргян икян, алар мынысын да кыйнаб, мыскыл итеб, буш кайтарыб жибяргянняр. 12 Аннары тагы öчöнчöнö жибяргян, ämмя алар аныcын да жаралаб, кыуыб чыгарыб жибяргянняр. 13 Шул чакта жöзöм бакчасынын эясе äйткян: инде ней эшлейем икян? сöйгян

[1] Ис 56:7. Іер 7:11.

улымны жибярейем, аны кюреб, оялырлар ялля, дигян. 14 Ямма бакчачылар аны кюреб, ўз араларында уйлашыб йтешкянняр: бу атасы урнына каласы, йдягез, аны ўтерейек, анар каласы мал безнеке булыр, дигянняр. 15 Аны бакчадан чыгарыб, ўтергянняр. Бакча эясе инде аларга ней кылар? 16 Ул килеб, бу бакчачыларны ўтертер дя бакчасын бютяннярга бирер, дигян. Мыны эшеткян кешеляр йткянняр: алай булмасын ыйы! дигянняр. 17 Ямма Ул, аларга караб, йткян: ой салыучылар жараусыз кюреб ташлаган таш почмак астына нигез булган [1] диб жазылган сюз нейне белдеря? 18 Шул таш стоня жыгылган кеше уатылыр, ямма кем стоня шул таш тошся, аны сытар, дигян.

Зач. 101. 19 Шул чакта архіерейляр белян княгячеляр Іисусъ бу мясялне алар турысында йткянне белеб, Аны тотоб алырга кой эзлягянняр, тик калыктан курыкканнар. 20 Ўзляре Аны сагалаб тороб, Анар хайляле кешелярне жибяргянняр, алар ўзлярен изге торган кюк кюрсятеб, Аны башлыкларга, оло тюря кулына тотоб бирер очон, бер-бер сюзеннян эляктерсенняр диб. 21 Былар Аннан сораганнар: эй Ойрятеуче, без Синең дорос йткяненгне, дорос ойряткяненгне белябез, Син беряўгя дя кешесеня караб кылмыйсын, ямма Алла жулына дорос ойрятясен. 22 Без кесаргя имана бирергя тейеш ме, ялля жук мы? дигянняр. 23 Ул аларнын хайлялярен белеб, аларга йткян: ник сез Мине сыныйсыз? 24 Миңа динарій кюрсятегез: мында кем тосо, кем исеме жазылган? дигян. Алар: кесарнеке дигянняр. 25 Ул аларга йткян: айса кесарнекен кесаргя бирегез, ямма Алланыкын Аллага (бирегез), дигян. 26 Шулай итеб алар калык алдында Аны сюзгя эляктеря алмаганнар, Анын жауабына исляре китеб, дяшмяс булганнар.

Зач. 102. 27 Аннары терелеб тороу булмас диб йтеуче саддукейляр арасыннан кайсылары килеб, Іисустан сораганнар: 28 Эй Ойрятеуче! Моисей жазган безгя: беряўнен агасы катынны булыб, балалары жук койо ўлся, анын катынын энесе алыб, агасына нясел булдырсын [2] диб. 29 Жиде ага-эне бар ыйы, элекегесе катын алгач, баласыз ўлде; 30 Ул катынны икенчесе алды, ул да баласыз ўлде; 31 Аннары аны очончосо алды, шулай жидесе дя алдылар; алыб, балалар калдыр-

[1] Пс 117:22.

[2] Втор 25:5-6.

мыйчын ўлделяр. 32 Барысыннан да суҥ катын да ўлде. 33 Терелеб торгач, ул кайсына катын булыр? ул жидесенен дя катыны булган ыйы шул, дигянняр. 34 Іисусъ аларга жауаб биреб йайтқян: бу дөнья кешеляре өйляняляр дя, кеяўгя дя китяляр, 35 Ämмя ўлгян жирляреннян терелеб тороб, теге дөньядя булырга тейешле булганнар өйлянмейляр дя, кеяўгя дя китмейляр, 36 Ўляр халляре дя жук, алар пяриштялярга тиҥ, алар Алла уллары, терелеў уллары шул. 37 Ämмя ўлгянняр терелеб торасын кыуак жанында Моисей дя кюрсяткян, ул Ходайны Авраамъ Алласы, Исаакъ Алласы, Іаковъ Алласы диб йайтқян. 38 Алла ўлгянняр Алласы тögöл, ämмя тереляр Алласы; Аллага барда тере шул, дигян. 39 Мыҥар жауаб биреб, княгячелярнен кайсылары йайтқянняр: эй Öйрятеўче, син жакшы йайттеҥ, дигянняр. 40 Шуннан суҥ ичбер нястя турысында Аннан сорарга кыймаганнар. 41 Ул аларга йайтқян: Христосны ник Давидъ Улы диб йайтяляр? 42 Давидъ ўзе псаломнар княгясендя йайтя: 43 Ходай минем Ходайыма йайтқян: дошманнарыҥны аягыҥ астына салгынчы, Минем уҥ жагымда утыр [1] диб. 44 Айса Давидъ Аны Ходайым диб йайтқяч, Ул суҥ ничек анын улы була? дигян.

Зач. 103. 45 Бар калык тыҥнаб торган чагында, Ул Ўз öйрянеўчеляреня йайтқян: 46 Княгячелярдян сакланыгыз: алар озон кейем кейеб жöрöўне, калык жыйынында кеше башырганны, синагогаларда алда утырыуны, ашка жыйылган жирдя тюргя утырыуны жараталар; 47 Тол катыннарнын жортларын ашаб бетеряляр, кюренер öчöн гня озаклаб теляк итяляр; алар анын öчöн артыгырак айыбланырлар.

[1] Пс 109:1.

21-нче бюлем

1 Іисусъ кюзен кютяреб карагач, чиркяў тартмасына акча салыб торган байларны кюргян; 2 Шулай тагы ике лепта салган бер жарлы тол катынны кюргян; 3 Кюргяч, йайтқян: чыннаб йайтямен сезгя: бу жарлы тол катын барысыннан да кюберяк салды; 4 Тегеляр барда Аллага бюлякне артыклары бардан салдылар шул, ämмя бу катын жарлы кöйö бар барлыгын, бар тормошон салды, дигян.

Зач. 104. 5 Аннары кайсы кешеляр чиркяў турысында, ул бик асыл ташлар белян, китер-

гян бюлякляр белян äйбятлягян диб сöйляшкян чагында, 6 Іисусъ äйткян: мына кöнняр килер, мында сез кюря торган нястялярдян таш öстöндя таш та калмас, барысы да жимерелеб бетерелер, дигян. 7 Шунда Аннан сораганнар: эй Öйрятеўче, бу кайчан булыр? былар буласы багытнын билгеляре ничек? дигянняр.

Зач. 105. 8 Ул äйткян: сак булыгыз, сезне жангыштырмасыннар; кюбесе Минем исемем белян килерляр, мин (Христосъ) дирерляр. Ул багыт инде жакын: сез аларга эяреб жöрмягез. 9 Сугышлар булганны, калык болганышканны эшеткяч, курыкмагыз, былар элеке булырга тейеш шул, алайда ул äле бетеў тöгöл, дигян. 10 Аларга тагы äйткян: калык калыкка, падшалык падшалыкка карышы торор; 11 Урны-урны белян жир бик каты титряр, ачлык булыр, ўлят булыр, кот чыгаргыч нястяляр кюренер, кюктян зур билгеляр беленер.

Зач. 106. 12 Быларнын барысыннан да элгяре Минем исемем öчöн сезне тотоб алырлар, сезне кыуарлар, сезне синагогаларга, жя öтöрмяннярга итеб табшырырлар, сезне падшалар алдына, тюряляр алдына алыб барырлар. 13 Былар сезгя (Минем турда) таныклык итяр öчöн булыр. 14 Сез äйтясе жауабыгызны алдан уйлаб тороуны кюнгелегездя тотмагыз, 15 Мин Ўзем сезгя сюз дя, белемнек тя бирем, сезгя карышы тороучылар барысы да ул белемнеккя карышы бер сюз дя äйтя алмаслар, анар карышы тора алмаслар. 16 Ўз аталарыгыз, ага-энелярегез, туганнарыгыз, дусларыгыз да сезне тотоб бирерляр, кайсыларыгызны ўтererляр дя. 17 Минем исемем öчöн сезне барысыда кюрялмаслар. 18 Алайда башыгыздагы чячегезнен бöртöгö дя жугалмас. 19 Жаннарыгызны тюземнек белян саклаб торогоз. 20 Іерусалимны дошман чиреўляр чырмаб алганны кюргяч, анын бöлöб бетяре житте диб белегез. 21 Шул чакта Іудеядагылар тауларга качсыннар; кала эчендягеляр аннан чыксыннар: кала тирясендягеляр калага кермясенняр, 22 Ул кöнняр, жазылган [1] барыда жиреня килер öчöн, (Іерусалимга) кайтарасы кöнняр шул. 23 Ул кöннярдя ауырлы катыннарга, имчяк имезеўчелярга читен булыр. Ул чакта жир öстöндя бик зур ауырлык булыр, бу калыкка каты азаб булыр: 24 Кылыч жöзö белян чабылыб ўтерелерляр, тот-

[1] Зах 14:1-2.

кон итеб бар калыкларга да тотконнокка таратылырлар; жалган деннеляр багыты узгынчы, Іерусалимны жалган деннеляр табтарлар. 25 Кояшта, айда, жондозларда билгеляр булырлар, ämмя жирдя калыклар жödяшерляр, köйönöшöрляр; дингез дя шаулар, болганыр; 26 Курыкканныктан, дöньягя киля торган бялялярне köткяннектян, кешелярнен тыннары бетяр, кюктяге чиреўляр кузгалышырлар шул. 27 Шуннан суң болотлар öстöндя зур кыуат белян, ололок белян килеўче Ädям Улын кюрерляр.

Зач. 107. 28 Сез шул эшляр була башлагач, тöзлянеб, башыгызны кютярегез, сезнен котолоуыгыз жакыннаша шул, дигян. 29 Аннары аларга ошаш китереб äйткян: смоковница агачына да, бар агачларга да карагыз. 30 Алар жапрак жара башлагач, аны кюреб, жяй жакынны ўзегез белясез. 31 Шунын кюк бу билгеляр була башлаганны кюргяч тя, Алла Падшалыгы жакын диб белегез. 32 Чыннаб äйтямен сезгя: шушы тыума беткенче, былар барысы да булыр. 33 Кюк белян жир бетярляр, ämмя Минем сюзлярем торор. 34 Ўзегезне ўзегез сак тотогоз, кюб ашабэчеб, исереб, дöнья сагышларына биренеб, кюңеллярегезне ауырайтмагыз, ул кön сезгя тойластын килеб житмясен, 35 Ул кön бötön жир жözöндя тороучыларны барысын да ау кюк килеб каблар. 36 Шуңар кюря шушы буласы бялялярдян котолоб, Ädям Улы алдына килергя тейешле булыр öчön, жалан уяу тороб, теляк итегез, дигян.

Зач. 108. 37 Іисусъ köндöз чиркяўдя öйряткян, аннан чыгыб, тöннö Елеонъ исемне тау öстöндя ўткязгян. 38 Бар калык та Анын катына иртядянюк чиркяўгя Аны тыннарга жöргянняр.

22-нче бюлем

1 Тöчö кюмячляр бяйряме, Пасха дигян бяйрям жакыннашкан. 2 Шунда архіерейляр белян книгячеляр Аны ничек итеб ўтерергя köй эзлягянняр, тик калыктан курыкканнар. 3 Ун икенен берсе, Искаріотъ дигян Іуданын эченя шайтан кергян. 4 Іисусны ничек итеб тотоб бирясесен ул архіерейлярга, башлык кешелярга барыб сöйляшкян. 5 Алар сöйönöшкянняр, анар акча да бирмякче булганнар. 6 Ул аларга сюз биргян, Аны калык жук жирдя аларга тотоб бирергя köйлö багыт эзлягян. 7 Пас-

ха бярянен суя торган төчӧ кюмяч кӧнӧ житкян. 8 Іисусъ Петръ белян Іоанны жибяреб йӧткян: барыгыз, безгя ашарга пасха әзерлягез, дигян. 9 Алар Аңар йӧткянняр: безгя кайда әзерлярга кушасын? дигянняр. 10 Ул аларга йӧткян: мына сез калага кергян чагында, сезгя комган белян сыу алыб бара торган кеше очорар; анын артыннан барыб, ул кергян өйгя керегез, 11 Кергяч, өйнӧн эясеня йӧтегез: Өйрятеўче синға: Мин өйрянеўчелярем белян пасха ашасы бюлмя кайда? диб йӧтя дигез. 12 Ул сезгя идяненя жяйгян зур бюлмя кюрсятер, шунда әзерлягез, дигян. 13 Алар барыб, Ул аларга йӧткянчя туры китереб, шунда пасха әзерлягянняр. 14 Сагат житкяч, Ул шунда кереб утырган, Анын белян ун ике апостоллары да (булганнар). 15 Іисусъ аларга йӧткян: азабланыр алдымнан шушы пасханы сезнен белян ашасым бик килгян эйе; 16 Сезгя йӧтямен: мыннан былай Мин аны инде Алла Падшалыгында пасха иткенче ашамам, дигян. 17 Аннары сауытны алыб, тау итеб, йӧткян: мыны алыгыз да ўз арагызда соногоз; 18 Сезгя йӧтямен: Алла Падшалыгы килгенче, жӧзӧм жимешенен сыуын инде эчмямен, дигян. 19 Аннары икмяк алыб, тау итеб, сындырыб, аларга биреб йӧткян: Бу Минем сезнен өчӧн биря торган Тянем; мыны Мине исегезгя тӧшӧрӧр өчӧн кылыгыз, дигян. 20 Ашаганнан суң, тагы шулай сауытны биреб, йӧткян: бу сауыт Минем сезнен өчӧн агыза торган Каным белян куйган жаңа законъ. 21 Мына инде Мине тотоб биреўченен кулы Минем белян бер өстялдя. 22 Алайда Ӓдям Улы электен жазылганча бара, тик Аны тотоб биреўчегя жаман булыр, дигян. 23 Аннары өйрянеўчеляре бер берсеннян: мыны кайсыбыз кыласы икян диб сорой башлаганнар. 24 Шунда алар арабызда кайсыбыз ологa саналырга тейеш диб жиңешя башлаганнар. 25 Іисусъ аларга йӧткян: падшалар калыкларны тотоб торалар, калыкларны кул астларында тотоучылар жакшылык кылыучылар диб йӧтеляляр; 26 Ӓммя сез алай тӧгӧл: сезнен арада ологоз иң кече кюк булсын, башлык булыб тороучыгыз кызмятче кюк булсын. 27 Кем оло суң: утыра торганы мы, ӓлля кызмят итя торганы мы? Утыра торганы тӧгӧл ме? Ӓммя Мин сезнен арагызда кызмятче кюк булыб торамын. 28 Миңа ауырлык булган чагында, сез Минем белян бергя булдыгыз. 29 Миңа Атам багадя куйганча, Мин дя сезгя пад-

шалык бирергя багадя куямын, 30 Падшалыгымдагы ашымны сез дя ашасагыз ыйы, эчсягез эйе диб, аннары престолларга утырыб, Израилнен ун ике рыуына хокӧм итсягез эйе диб, дигян. 31 Аннары Ходай йӑткян: эй Симонъ, Симонъ! мына шайтан сезне бодай илягян кюк илярга сораган ыйы, 32 Тик Мин синеӈ турында, ышаныуыӈ кимемясен эйе диб телядем, син дя бер багытны ӳзеӈ ӳкенеб, туганнарыӈны ныгайт, дигян. 33 Ул Аӈар жауаб биргян: Эй Ходай, мин Синеӈ белян бергя ӧтӧрмянгя дя, ӳлемгя дя барырга әзер, дигян. 34 Іисусъ аӈар йӑткян: эй Петръ, Мин синӈа йӑтямен: бӧгӧн ӑтяч кычкыргынчы, син Миннян ӧч табкыр Аны белмеймен диб таӈарсын, дигян. 35 Аннары тагы аларга йӑткян: Мин сезне кабчыксыз, жанчыксыз, башмаксыз жибяргян чагында, сез бер-бер нястя киряксендегез ме? дигян. Алар: бер нястя дя киряксенмядек диб жауаб биргянняр. 36 Аннары Ул аларга йӑткян: әммя казер кабчыгы бары, аны да алсын, жанчыгын да алсын; кылычы жугы, кейемен сатыб, кылыч алсын; 37 Сезгя йӑтямен: Жазыуда Минем турда йӑтелгян сюзнен: усаллар белян тингя саналган [1] дигяне жиреня килясе; Минем турда йӑтелгян инде булыб бетя шул, дигян. 38 Алар йӑткянняр: эй Ходай, мына мында ике кылыч бар, дигяняр. Ул аларга: житяр, дигян.

Зач. 109. 39 Аннары Іисусъ аннан чыгыб, Ӳз гадятенчя Елеонъ тауына киткян. Анын белян ӧйрянеӳчеляре дя барганнар. 40 Урнына барыб житкяч, Ул аларга йӑткян: алданмас ӧчӧн, теляк итегез, дигян. 41 Ӳзе алардан таш атымы жиргя китеб, тезлянеб тороб, инялгян: 42 Эй Ӓтей! Син бу сауытны Миннян уздырасы итсяӈ эйе! тик Мин телягянчя тӧгӧл, әммя Син телягянчя булсын, дигян. 43 Шунда Аӈар кюктян пяриштя тӧшӧб, Аны ныкландырган. 44 Аннары кюӈеле интеккян чагында бигеряк тырышыб инялгян, Анын тире кан тамчылары жиргя тамган кюк булган. 45 Теляк итеӳеннян тороб, ӧйрянеӳчеляре катына кайтыб, аларнын кайгыдан жоклауларын очоратыб, 46 Аларга йӑткян: ник сез жоклойсыз? алданмыйык дисягез, торогоз, теляк итегез, дигян. 47 Ул мыны йӑткян чагында, калык килгян, калык алдыннан ун икенен берсе, Іуда атлысы килгян; ул Іисусны ӳбяргя диб, Аӈар жакынашкан. Ул аларга былай йӑтеб билге куйган икян: мин кемне

[1] Ис 53:12.

ўбсям, шул Ўзе дигян икян. 48 Іисусъ анҕар äйткян: эй Іуда, син Äдям Улын ўбеў белян тотоб бирясен меней? дигян. 49 Іисусъ жанындагылар, эш нейгя ауышканны кюреб, Анҕар äйткянняр: эй Ходай! кылыч белян чабмыйык мы? дигянняр. 50 Аларнын берсе архіерей кызмятчесенен уҥ колагын чабыб өзгян. 51 Шунда Іисусъ äйткян: теймягез, житяр, дигян; аннары колагына тейенеб, аны тözяткян. 52 Іисусъ Ўзеня карышы жыйылыб торган архіерейлярга, чиркяў башлыкларына, калык башлыкларына äйткян: талаучыны тотарга чыккандый, сез Мине тотарга кылычлар, казыклар алыб чыкканыгыз. 53 Мин сезнен белян кöн сайын чиркяўдя булдым, сез миҥа кул кютярмядегез; инде багыт сезнеке, карангылык ирке житте, дигян. 54 Аннары Аны алыб, житякляб архіерей öйöня китергянняр. Петръ жырактын барган. 55 Алар ишек алды уртасында ут жагыб, бары бергя утыргач, Петръ да алар арасына утырган. 56 Бер кызмятче катын анын ут жанында утырганын кюреб, анҕар тегяляб караб äйткян: бу да Анын белян бергя эйе, дигян. 57 Ämмя Петръ Іисусны таныб, катынга äйткян: мин Аны белмеймен, дигян. 58 Бер-ауык торгач, икенчесе Петрны кюреб, äйткян: син дя тегелярнен берсе, дигян. Петръ ул кешегя: жук, дигян. 59 Бер сагатляб ўткяч, тагы беряў туктаусыз äйтеб торган: чыннаб бу да Анын белян эйе, ул Галилея кешесе шул, дигян. 60 Ämмя Петръ ул кешегя äйткян: син ней äйткянне белмеймен, дигян. Шул сяттюк, ул мыны äйткян чакта, ätяч кычкырган. 61 Шул чакта Ходай боролоб, Петрга караган, карагач, Петръ Ходайнын анҕар: ätяч кычкыргынчы син Мине öч табкыр таҥарсын дигян сюзен исеня тöшöргян. 62 Аннары чыгыб китеб, бик тилмереб жылаган. 63 Іисусны тотоб торган кешеляр Аннан мыскыл иткянняр, Аны кыйнаганнар; 64 Аны бöркяб, Анын битеня сугыб, Аннан сораганнар: Синҕа кем сукканны белеб äйт, дигянняр. 65 Аннан бютян дя Анҕар кюб курлык äйткянняр. 66 Кöн булгач, калык башлыклары, архіерейляр, книгячеляр жыйылыб, Аны ўзляренен синедріоннарына алыб кергянняр, 67 Кергяч äйткянняр: Христосъ Син ме? äйт безгя, дигянняр. Ул аларга äйткян; сезгя äйтсям, сез ышанмассыз, 68 Ägяр сездян сорасам, сез Миҥа жауаб бирмяссез, Мине жибярмяссез дя. 69

Мыннан былай Ädям Улы кодрятле Алланын уң жагына утырыр, дигян. 70 Шунда барысы да äйткянняр: алай булгач, Син Алла Улы? дигянняр. Ул аларга жауаб биргян: Мин икянне (дöрöс) äйтясез, дигян. 71 Алар äйткянняр: безгя тагы ничек таныклык киряк? Без Ўз ауызыннан эшеттек инде, дигянняр.

23-нче бюлем

Зач. 110. 1 Аннары бöтöн жыйын кузгалышыб, [1] Iисусны Пилатка алыб барганнар. 2 Аны былай диб айыблый башлаганнар: без Анын безнен калыкны котортканын белдек, Ул кесаргя имана бирергя кушмый, Ўзен Падша Христосъ дей, дигянняр. 3 Пилатъ Аннан сораган: Син Iудей Падшасы мы? дигян. Ул анар жауаб биреб äйткян: (дöрöс) äйтясен, дигян. 4 Пилатъ архiерейляр белян калыкка äйткян: мин бу Кешедя бер айыб та табмыймын, дигян. 5 Ämмя алар туктаусыз äйтеб торганнар: Ул Галилеядан башлаб бу жиргя чаклы, бöтöн Iудеядя öйрятеб жöрöб, калыкны болгата дигянняр. 6 Пилатъ Галилея дигянне эшеткяч, сораган: Ул Галилеянеке меней? дигян. 7 Ул Иродъ жиренен кешесе икянен белгяч, Пилатъ Аны Иродка жибяргян, Иродъ ул көннярдя Iерусалимдя икян. 8 Иродъ, Iисусны кюреб, бик сöйöнгян, Аны кюбтянгя жауаб биргян: Мин икянне (дöрöс) äйтясез, дигян. 71 Алар äйткянняр: безгя тагы ничек таныклык киряк? Без Ўз ауызыннан эшеттек инде, дигянняр.

Зач. 110. 1 Аннары бöтöн жыйын кузгалышыб, [1] Iисусны Пилатка алыб барганнар. 2 Аны былай диб айыблый башлаганнар: без Анын безнен калыкны котортканын белдек, Ул кесаргя имана бирергя кушмый, Ўзен Падша Христосъ дей, дигянняр. 3 Пилатъ Аннан сораган: Син Iудей Падшасы мы? дигян. Ул анар жауаб биреб äйткян: (дöрöс) äйтясен, дигян. 4 Пилатъ архiерейляр белян калыкка äйткян: мин бу Кешедя бер айыб та табмыймын, дигян. 5 Ämмя алар туктаусыз äйтеб торганнар: Ул Галилеядан башлаб бу жиргя чаклы, бöтöн Iудеядя öйрятеб жöрöб, калыкны болгата дигянняр. 6 Пилатъ Галилея дигянне эшеткяч, сораган: Ул Галилеянеке меней? дигян. 7 Ул Иродъ жиренен кешесе икянен белгяч, Пилатъ Аны Иродка жибяргян, Иродъ ул көннярдя Iерусалимдя икян. 8 Иродъ, Iисусны кюреб, бик сöйöнгян, Аны кюбтянгя бирле кюрясе килеб торган икян, Анын турысында кюбне эшеткян икян шул, Аннан бербер кодрят кюрем диб торган. 9 Ул Iисустан кюб нястя турысында сораган, тик Ул анар ич тя жауаб бирмягян. 10 Архiерейляр белян книгячеляр Аны бик каты айыблаб торганнар. 11 Ämмя Иродъ ўз салдатлары белян Аны кимсетеб, Аннан мыскыл итеб туктагач, Анар жакты кейем кейгезеб, Аны Пилатка кире жибяргян. 12 Шул көннö Иродъ белян Пилатъ дусланышканнар, алар элеке бер берсеня дошман икян. 13 Аннары Пилатъ, архiерейлярне, башлыкларны, калыкны жыйдырыб, 14 Аларга äйткян: сез миня бу Кешене калыкны котортa диб китердегез; мына мин сезнен алдыгызда тикшердем, Анда сез кюрсятя торган айыбларнын берсен дя табмадым. 15 Иродъ та шулай табмаган, мин Аны анар жибяргян эйем, анда да Аны ўтертерлек бер айыбы да табылмаган; 16 Айса Аны кыйнатыб, жибярермен,

[1] Архiерейляр, книгячеляр, калык башлыклары

дигян. 17 Бяйрям какына ул аларга тотконда тороучы беряўне иркенгя жибярергя тейеш икян. 18 Ämмя бар калык кычкыра башлаган: Ул ўтерелсен, ämмя безгя Варавваны жибяр, дигянняр. 19 Варавва калада (калыкны) болгатканы өчөн, кеше ўтергяне өчөн, өтөрмянгя жабылган икян. 20 Пилатъ, Іисусны жибярясе килеб, жанадан тауыш кютяргян. 21 Ämмя алар: Аны кадаклат! кадаклат! диб кычкырганнар. 22 Ул аларга өчөнчө табкыр айткян: суң Ул нейдей усаллык кылды? Мин Аны ўтерерлек бер айыб та табмадым; инде Аны кыйнатыб, жибярермен, дигян. 23 Ämмя алар: Ул кадакланылсын диб бик каты кычкырыб торганнар; архіерейляр белян калык кычкырыб жинтянняр. 24 Пилатъ алар дигянчя булсын диб хокөм кылган: 25 Калыкны болгатканы өчөн, кеше ўтергяне өчөн өтөрмянгя жабылган кешене, ўзляре сораганны аларга биргян, ämмя Іисусны алар иркеня табшырган. 26 Аны алыб барган чакта, Киринеянын бер Симонъ атлы кешене басыуыннан кайтышлый туктатыб, анар качны кютяртеб, Іисусъ артыннан бардырганнар. 27 Іисусъ артыннан бик кюб калык барган, тагы кюб катыннар да Анын өчөн ўкереб, жылашыб барганнар. 28 Іисусъ аларга боролоб айткян: эй Іерусалимъ кызлары! Минем өчөн жылашмагыз, бигеряк ўзегез өчөн, балаларыгыз өчөн жылашыгыз: 29 Бала китермей торган катыннар, бала тыудырмаган корсаклар, бала туйдырмаган имчякляр бахетле диб айтер көнняр житяляр. 30 Шул чакта тауларга айтерляр: безнен өсткя ауыгыз! тюбя жирлярга: безне каблагыз! дирерляр. 31 Жяшяреб торган агачка мындыйны кылгач, коро агачка ней булыр? дигян.

Зач. 111. 32 Іисусъ белян бергя ике усалны ўтерергя алыб барганнар. 33 Мангай урны дигян урынга барыб житкяч, шунда Іисусны да, усалларны да берсен уң жакка, икенчесен сул жакка кадаклаганнар. 34 Іисусъ айткян: эй Ätей! Быларга [1] кичер, алар ней кылганнарын ўзляре дя белмейляр шул, дигян. Аннары Анын кейемнярен жирябя салыб өляшкянняр. 35 Калык караб торган; калык белян бергя башлыклар да мыскыл итеб айткянняр: бютяннярне коткарган, инде ул Алланын сайлаган Христосы булса, Ўзен Ўзе коткарсын, дигянняр. 36 Салдатлар да шулай Анын катына килеб, Анар серкя сузыб, Аннан мыскыл итеб,

[1] Кадаклаучыларга.

37 Äйткянняр: ägяр Син Іудей Падшасы булсаӈ, Ўзеӈне Ўзеӈ коткар, дигянняр. 38 Аннан жугары качта Грекчя, Римчя, Еврейчя тел белян жазган жазыу булган: бу Іудей Падшасы диб. 39 Кадакланган усалларнын берсе Іисусны курлаб, äйткян: Син Христосъ булсаӈ, Ўзеӈне дя, безне дя коткар, дигян. 40 Ämмя икенчесе аны тыйыб äйткян: ўзеӈя дя азабка бирелергя хокöм ителгяч, älля син Алладан курыкмыйсын мы? 41 Без дöрöс айыбландык, кылган эшляребезгя тейешлене алдык, ämмя Ул ич-бер начар эш кылмаган, дигян. 42 Аннары Іисуска äйткян: эй Ходай (Падшалыгыӈа) кергяч, Падшалыгыӈда мине исеӈя ал, дигян. 43 Іисусъ аӈар äйткян: чыннаб äйтямен сиӈа: бöгöнўк Минем белян жомакта булырсын, дигян. 44 Алтынчы сагат тирясе икян; тугызынчы сагатка чаклы бötöн жир карангы булыб торган. 45 Кояш карангыланган, чиркяўдяге чаршау урталый жыртылган. 46 Іисусъ каты тауыш белян кычкырыб äйткян: эй Ätей, тынымны Синеӈ кулыӈа табшырамын дигян дя тынын чыгарган. 47 Сотникъ шунда булган эшлярне кюреб, Алланы даннаб, äйткян: чыннаб Бу äўлея кеше икян, дигян. 48 Мыны кюргя жыйылышкан калык барысыда шунда булган эшлярне кюреб, кюкряклярeня суга-суга кайтканнар. 49 Іисусны белгян кешеляр барысыда, Анын артыннан Галилеядан килгян катыннар да мыны жыраклын караб торганнар. 50 Шул чакта беряў, киӈяш кешесе, арыу, гадел кеше, 51 Алар киӈяшеня, алар эшеня керешмягян кеше, Іудея жирендяге Аримаөея каласынын кешесе, Алла Падшалыгын кötöб тороучы Іосифъ атлы кеше, 52 Пилатка барыб, Іисуснын тянен сораган, Сорагач, 53 Аны качтан алыб, киндергя тöрöб, таш тауга тишеб жасаган кабергя куйган, анда аӈгынчы беряў дя куйылмаган икян. 54 Ул кön пятница кön икян, суббота житеб киля икян. 55 Галилеядан Іисуска эяреб килгян катыннар да шунда барыб кабергя караб, Іисуснын тянен куйганны кюреб торганнар. 56 Аннары кайтыб, мvро да, эйесле нястяляр дя äзерлягянняр. Суббота кöннö, бойорок кушканча, тыныч ўткяргянняр.

24-нче бюлем

Зач. 112. 1 Атнанын элекенче көнөндя иртюк шул катыннар, äзерлягян эйесле майларын алыб, кабер жанына килгянняр, алар белян бергя тагы бютян бер-ауык катыннар да килгянняр; 2 Килгяч, кабер ауызындагы таш аударылыб жатканны кюргянняр. 3 Алар каберга кергяч, Ходай Іисуснын тянен табмаганнар. 4 Алар мынгар абтырашыб торган чакта, кинят аларга жалтраб торган кейем кейенгян ике ир кюренгянняр. 5 Катыннар куркышыб, жözлярен жиргя таба каратыб торган чагында, (шул ирляр) аларга äйткянняр: ник сез терене ўлгянняр арасыннан эзлейсез? 6 Ул мында жук: Ул терелеб тордо; Анын сезгя Галилеядя чагында äйткянен: 7 Ädям Улы жазыклы кешеляр кулына табшырыласы, кадакланыласы, öчöнчö көнөндя терелеб торасы дигянен исегезгя төшöрöгöз, дигянняр. 8 Катыннар Анын сюзлярен исляреня төшöргянняр дя 9 Кабер жаныннан кайтыб, ун бер (öйрянеўчегя) дя, бютянняренен барысына да мынын барысын да белдергянняр. 10 Былар Магдалина Марія, Іоанна, Іаковъ анасы Марія, алар белян тагы бютян катыннар булганнар, апостолларга да мыны алар äйткянняр. 11 Апостоллар аларнын сюзлярен жалганга куйганнар, аларга ышанмаганнар.

Зач. 113. 12 Ämмя Петръ тороб, кабер, жанына жöгöрöб килеб, эйелеб карагач, анда жаткан кипеннярне гня кюреб, шул эшкя ўз кюнгелендя исе китеб кайткан. 13 Шул көннюк алар арасыннан икяў Іерусалимнян алтмыш стадія [1] чамасы жирдяге Эммаусъ дигян ауылга баралар икян. 14 Шунда бар булган эшляр турысында алар ўз аралый сöйляшеб барганнар. 15 Алар ўз аралый сöйляшеб, уйлашыб барган чагында, Іисусъ Ўзе аларга жакыннашыб, алар белян бергя бара башлаган. 16 Аларнын кюзляре тотлоккан, шунныктан алар Аны танымаганнар. 17 Ул аларга äйткян: сез ўз арагызда ней турысында сöйляшеб барасыз? сез нейлектян кайгылы? дигян. 18 Аларнын берсе Клеопа атлысы Анар жауаб биреб äйткян: Іерусалимдя шушы көннярдя ней булганны анда килгян кешеляр арасыннан älля бер Син гня белмейсең ме? дигян. Ул аларга: нейне? дигян. 19 Алар Анар äйткянняр: Назорей Іисуска ней булганны: Ул Алла алдында, бötön калык

[1] 60 стадія 10-12 чакырым.

алдында сюзе белян дя, эше белян дя кыуатлы пагамбяр эйе, 20 Безнен архіерейляр, башлыклар Аны ўтерергя тейешле итеб айыбларга тотоб биргянне. Аны кадаклатканны, дигянняр. 21 Ämмя без Израилне коткарасы кеше Улдыр диб ömötлянгян эйек, алай булса да шул эш булганга инде öчöнчö кön. 22 Безнен арадагы катыннарнын кайсылары безнен исебезне китерделяр: алар иртюк кабер жанына барганнар ыйы, 23 Анда Анын тянен табмыйчы кайтыб, аларга Іисусъ тере диб äйтеўче пяриштяляр кюренгянне äйттеляр. 24 Аннары кайсыларыбыз кабер жанына барыб, катыннар äйткянчя гел шулай очоратканнар, тик Ўзен кюрмягянняр, дигянняр. 25 Шунда Іисусъ аларга äйткян: эй анғсызлар, пагамбярляр алдан äйткяннен барысына да ышанырга озаклаучы кюнеллеляр! 26 Христосъ гел шулай азабланыб, Ўз олологына керергя тейеш эйе тöгöл ме? дигян. 27 Моисейдян, бар пагамбярлярдян башлаб, бар жазыуда Христосъ турысында äйтелгянне аларга анғнаткан. 28 Аннары алар бара торган ауылларына жакыннашканнар; Іисусъ тагы да арырак барасы кюк булыб торган. 29 Ämмя алар безнен белян калсана диб, Аны туктатыб торганнар, кön дя инде кичкя ауышты дигянняр. Ул кереб, алар белян калган. 30 Алар белян бергя утырган чагында, Ул икмяк алыб, аны бахиллягян дя сындырыб, аларга биргян. 31 Шунда алар кюзляре ачылыб, Аны таныганнар; ämмя Ул аларга кюренмяс булган. 32 Алар бер-берсеня äйткянняр: Ул безнен белян сöйляшеб, жазыудагы сюзлярне безгя анғнатыб килгян чагында, эчебездя кюнелебез эреб барды тöгöл ме? дигянняр дя. 33 Шул сяттюк тороб, Іерусалимгя кайтыб, ун бер апостолны, алар белян бергя булганнарны да бергя очоратканнар. 34 Апостоллар аларга: Ходай чыннаб терелеб торган, Симонга да кюренгян, дигянняр. 35 Былар да аларга жулда ней булганны да, Іисусны икмяк сындырган чагында таныганнарын да äйткянняр.

Зач. 114. 36 Алар бу турыда сöйляшеб торган чагында, Іисусъ Ўзе (кинят) алар уртасында тороб, аларга äйткян: тынычлык сезгя, дигян. 37 Алар каушаб китеб, куркынышыб, тын кюря торганбыз диб уйлаганнар; 38 Ämмя Ул аларга äйткян: ник куркасыз? шундый уйларны кюнелегезгя ник кертясез? 39 Минем кулларыма, аякларыма карагыз; бу

Мин Ўзем; Мине кул тейереб караб, жакшылаб кюрегез, тыннын Миндя кюргянегез кюк, ите, сөякляре булмый ич, дигян. 40 Мыны йткяч, аларга кулларын да аякларын да кюрсяткян. 41 Алар сөйönөчляреннян йле дя ышанмыйчын, исляре китеб торганда, Ул аларга йткян: сезнен мында бер-бер ашамныгыгыз бар мы? дигян. 42 Алар Анҕар бер кисяк пешергян балык, бер кисяк кярязле бал китереб биргянняр. 43 Ул алыб, алар алдында ашаган. 44 Аннары аларга йткян: Мин сезнен белян бергя чагында, Моисей законында, пагамбярляр жазыуларында, псаломнарда Минем турыда жазылган барысы да жиреня килер диб сезгя йткянемнен дöрöс булыуы шушы, дигян. 45 Шул чакта Ул жазыудагын анҕнарга аларнын уйларын ачылдырган. 46 Аннары аларга йткян: шушлай жазылган, Христосъ шулай азабланыб, ўлгян жиреннян öчöнчö кönöндя терелеб тороргa тейеш эйе, 47 Аннары Іерусалимнян башлаб, бар калыкларга да Минем исемемя тяўбя итеб, жазыклар кичерелеўе сöйлянергя тейеш эйе, дигян. 48 Сез шуҕар таныкчылар. 49 Мына сезгя Атам бирясе булганны жибярермен, ämмя сез жугартын кыуатка кейенгенче, Іерусалимъ каласында тора торогоз, дигян. 50 Аннары аларны каладан Виөаніяга чаклы алыб чыккан; шунда кулларын кютяреб, аларны бахиллягян. 51 Аларны бахиллягян чагында, алардан китя-китя, кюккя кютяреля башлаган. 52 Алар Анҕар башырганнар, аннары бик сöйönöшöб, Іерусалимгя кайтканнар. 53 Кайткач, жалан чиркяўдя Аллаҕы даннаб, ололаб торганнар. Аминь.

ІОАННЪ ЖАЗГАН АРЫУ ЕВАНГЕЛІЕ

1-нче бюлем

Зач. 1. 1 Союз äўäлтенюк булган, Союз Аллада булган, Союз Алла булган. 2 Ул äўäлтенюк Аллада булган. 3 Бар нястя дя Анын арткылы булган, ней гня булса да, Аннан башка ич нястя булынмаган. 4 Анда терелек булган, ул терелек кешелярга жакты булган. 5 Жакты карангыда жактырыб тора, карангы аны каблаб бетермей. 6 Алладан жибярелгян бер кеше булган, анын исеме Іоаннъ. 7 Ул таныклык итярга килгян, анын арткылы барысы да ышансыннар диб, ул Жактыны таныкларга килгян. 8 Ул ўзе жакты булмаган, тик Жактыны таныкларга жибярелгян. 9 Дöньягя килеўче äр-бер кешене жактырта торган чын Жакты булган. 10 Ул дöньядя булган, дöнья Анын арткылы булынган, тик дöнья Аны танымаган. 11 Ўзенекелярга килгян, Ўзенекеляр дя Аны кабыл алмаганнар. 12 Ämмя Ўзен кабыл алганнарга, Анын исеменя ышанганнарга, Алла олаларны булырга кыуат биргян; 13 Алар каннан тöгöл, тян няпесеннян дя тöгöл, ир няпесеннян дя тöгöл, ämмя Алладан тыуганнар. 14 Союз тяннянде, дяўляткя, чынныкка тулы кöйö, безнен белян тордо; без Анын олологон кюрдек, Атадан жангыз Тыуганнын олологодый олологон (кюрдек). 15 Іоаннъ Аны таныклаб, кычкырыб äйтя: миннян арттан Килеўче миннян алда булды диб äйткянем Ўзе шушы, Ул миннян алданук бар ыйы шул дей. 16 Анын тулылыгыннан без барыбыз да дяўлят öстöня дяўлят алдык; 17 Законъ Моисей арткылы бирелгян, ämмя дяўлят белян чыннык Іисусъ Христосъ аркылы булдылар шул.

Зач. 2. 18 Алланы беряў дя бер чакта да кюргяне жук; Аны тик Атанын куйынындагы жангыз тыуган Улы гна белдерткян. 19 Іудейляр Іерусалимнян священниклярне, левитлярне Іоаннга: син кем диб сорарга жибяргяч, ул мына былай таныклаган: 20 Ул äйтеб биргян, танмаган;

мин Христосъ тӧгӧл дигян. 21 Аннары аннан сораганнар: кем суӈ син? Син Илія ме? дигянняр; ул: жук дигян. Пагамбяр ме? дигянняр; ул: жук диб жауаб биргян. 22 Анӈар тагы äйткянняр: кем суӈ син? безгя безне жибяргяннярга жауаб бирергя киряк: син ӱз турында ней äйтерсен? дигянняр. 23 Ул äйткян: Исаія пагамбяр äйткянчя, Ходайга жулны тӧзятегез диб, буш кырда кычкырыучынын ауазы [1] мин, дигян. 24 Жибярелгян кешеляр фарисейляр икян. 25 Алар аннан тагы сораганнар: син Христосъ та булмагач, Илія да булмагач, пагамбяр дя булмагач, суӈ ник чумылдырасын? дигянняр. 26 Іоаннъ аларга жауабка äйткян: мин сыуда чумылдырам, ämмя сезнен уртагызда сез белмей торган Беряӱ тора. 27 Ул минем артымнан Килеӱче, ämмя Ӱзе миннян алда булды. Мин Анын башмагынын кайышын чишяргя дя тормоймын, дигян. 28 Бу эш Іоаннъ чумылдырган жирдя, Іорданъ жанындагы Виѳаварда булган.

Зач. 3. 29 Иртягесен Іоаннъ, ӱзеня таба килгян Іисусны кюреб, äйткян: мына Алланын дӧнья жазыгын Ӱз өстӧня алыучы Бяряне шушы. 30 Миннян арттан бер Кеше киля, Ул миннян алда булды, Ул миннян элеке бар ыйы дигянем Ӱзе шушы. 31 Мин Аны белмейдер эйем, ämмя Аны Израилгя кюрсятер ӧчӧн, сыуда чумылдырырга килдем, дигян. 32 Іоаннъ тагы таныклаб äйткян: кюктян Тын кюгярчен ряӱешле булыб инӈянне, Анын өстӧндя торганны кюрдем. 33 Мин Аны белмейдер эйем, ämмя сыуда чумылдырырга мине Жибяреӱче миӈа äйтте: Кем өстӧня Тын инӈянне, Анын өстӧндя торганны кюрсяӈ, Святый Тын белян чумылдырыучы шул Ӱзе диде. 34 Мин кюрдем, Алла Улы шушы икянне таныклаб äйттем, дигян.

Зач. 4. 35 Иртягесен тагы Іоаннъ ике ӧйрянеӱчесе белян тора икян. 36 Ул, киля торган Іисусны кюреб, äйткян: мына Алла Бяряне, дигян. 37 Аннан шушы сюзлярне эшеткяч, ӧйрянеӱчеляре икесе дя Іисуска эяреб киткянняр. 38 Іисусъ боролоб, аларнын килгянен кюреб, аларга: ней киряк сезгя? дигян. Алар Анӈар äйткянняр: эй Равви! Равви дигяне ӧйрятеӱче дигян сюз була: Син кайда торасын? дигянняр. 39 Ул аларга äйткян: äйдягез, кюрерсез, дигян. Алар барыб, Ул торган жирне кюргянняр, ул көннӧ Анын катында ӱткяргянняр. 40 Унынчы са-

[1] Ис 40:3.

гат тирясе икян. Іоаннан Іисусъ турысында эшетеб, Анҕар эяргян ике öйрянеўченен берсе Симонъ Петрнын энесе Андрей икян. 41 Ул агасы Симонны элеке очоратыб, анҕар äйткян: без Мессіяны очораттык, дигян; Мессія дигяне-Христосъ. 42 Аннары аны Іисусъ катына алыб килгян. Іисусъ Симонга таба караб äйткян: син Симонъ, Іона улы, син кифа диб аталырсын дигян. Кифа дигяне, (Петръ дигяне) таш дигян сюз.

Зач. 5. 43 Иртягесен Іисусъ Галилеяга бармакчы булгач, Филиппны очоратыб, анҕар äйткян: миҥа эяреб бар, дигян. 44 Филиппъ Андрей белян, Петръ белян бер каланыкы, Виөсаиданыкы икян. 45 Филиппъ Наөанаилны очоратыб, анҕар äйткян: без Моисей законда жазганны, Назаретнын Іосифъ улы Іисусны очораттык, дигян. 46 Ämмя Наөанаилъ анҕар äйткян: Назареттан бер-бер арыу нястя чыга алыр меней? дигян. Филиппъ анҕар äйткян: бар, кюр, дигян. 47 Іисусъ, Ўзеня таба килгян Наөанаилны кюреб, анын турында äйткян: мына, Израилнен чын кешесе, анда жумалаулык жук, дигян. 48 Наөанаилъ Анҕар äйткан: Син мине кайдан белясен? дигян. Іисусъ анҕар жауабка äйткян: Филиппъ сине чакырмастан элеке, син смоковница төбөндя чагында, мин сине кюрдем, дигян. 49 Наөанаилъ Анҕар äйткян: эй Öйрятеўче! Син Алла Улы, Син Израиль Падшасы, дигян. 50 Іисусъ анҕар жауабка äйткян: Мин миҥа сине смоковница төбөндя кюрдем дигянемя кюря, син ышанасын; мыннан кюбне дя кюрерсен, дигян. 51 Анҕар тагы äйткян: чын, чын сезгя äйтямен: мыннан былай ачылган кюкне, Алла пяриштяляре Ädям Улына төшöб, менеб жöргянне кюрерсез, дигян.

2-нче бюлем

Зач. 6. 1 Öчöнчö көннö Галилеянын Кана дигян каласында туй булган; Іисуснын анасы да шунда булган. 2 Іисусны да öйрянеўчеляре белян шул туйга чакырганнар. 3 Анда аракы житмягяч, Іисуснын анасы Анҕар äйткян: аларнын аракылары жук, дигян. 4 Іисусъ анҕар äйткян: эй äней, (анда) синең белян Минем ней эшебез бар? äле Минем сятем житмягян, дигян. 5 Анасы кызмятчелярга äйткян: Ул сезгя ней кушса, шуны кылыгыз, дигян. 6 Шунда Іудейляр жоласынча тазарыныр öчöн куйган, икешяр, öчяр ўлчяў сыу керешле алты таш чюлмяк бар икян. 7 Іи-

сусъ аларга äйткян: сауытларга сыу тутырыгыз, дигян. Алар тулук тутырганнар. 8 (Іисусъ) жяня äйткян: инде чайпыб алыгыз да туйда башкарыб жöрöўчегя итеб бирегез, дигян. Алар итеб биргянняр. 9 Башкарыб жöрöўче шул аракыга алмашкан сыуны татыб караган, ämмя бу аракыны кайдан алганны белмягян, тик сыуны чайпыб алган кызмятчеляр гня белгянняр; башкарыб жöрöўче шунда кеяўне чакырыб, 10 Анар äйткян: äр-бер кеше элеке жакшы аракыны сона, аннары житярлек эчкяч, чагырагын сона, ämмя син аракынын жакшысын мынгынчы саклаган, дигян. 11 Шулай итеб Іисусъ Галилеянын Кана дигян каласында элеке кодрятен кылыб, Ўз олологон кюрсяткян; шуннактан öйрянеўчеляре Анар ышанганнар.

Зач. 7. 12 Шуннан суң Іисусъ Ўзе дя, Анасы да, агалары да, öйрянеўчеляре дя Капернаумга барыб, анда бер-äз кöн торганнар. 13 Іудейлярнен пасхасы жакыннаша башлагач, Іисусъ Іерусалимга килгян. 14 Анда чиркяўдя ўгезляр, сарыклар, кюгярченняр сатыб тороучыларны, акча алыштырыб утырыучыларны очораткан, 15 Очораткач, баудан суккыч жасаб, чиркяўдян барысын да кыуыб чыгарган; сарыкларны да, ўгезлярне дя (кыуыб чыгарган); акча алыштырыучыларнын акчаларын чячкян, öстяллярен дя аударган. 16 Аннары кюгярчен сатыучыларга äйткян: быларны мыннан алыгыз, Атамнын öйöн сатыу öйö итмягез, дигян. 17 Шул чагында öйрянеўчеляре: öйöнѓ кюнѓел биреўлек мине алыб узды [1] диб жазылган сюзне исляреня тöшöргянняр. 18 Іудейляр шунѓар карышы Анѓар äйткянняр: Син былай кыларга кыуатынѓ барны безгя ничек билге белян кюрсятерсен? дигянняр. 19 Іисусъ аларга жауаб биреб äйткян: шушы чиркяўне жимерегез, Мин аны öч кöндя торгозормын, дигян. 20 Мынѓар Іудейляр äйткянняр: бу чиркяўне кырык алты жыл торгозганнар, ялля Син аны öч кöндя торгозорсон? дигянняр. 21 Ämмя Ул чиркяў диб Ўз тянен äйткян. 22 Ул ўлгяненнян терелеб торгач, öйрянеўчеляре Анын бу äйткянен исляреня тöшöрöб, жазылганга да, Іисусъ äйткян сюзгя дя ышанганнар. 23 Іисусъ пасха бяйрямендя Іерусалимда чагында, кюб кеше Ул кылган кодрятлярне кюреб, Анын исеменя ышанганнар. 24 Алай да Іи-

[1] Пс 68:10.

сусъ, аларнын барын да белгяне буйынча, аларнын ышаныуына биренебюк бетмягян; 25 Кешене кеше таныклаб тороуны киряксенмягян, кешенен эчендяген Ўзе белгян шул.

3-нче бюлем

Зач. 8. 1 Фарисейляр арасында Іудея башлыкларынын берсе Никодимъ атлысы бар икян. 2 Ул Іисуска тёння килеб йткян: эй Ёйрятеўче, без Синеӈ Алладан килгян Ёйрятеўче икянеӈне белябез, беряў дя, ягяр Алла анын белян булмаса, Син кылган кодрятляр кюк кодрятлярне кыла алмас шул, дигян. 3 Іисусъ анӈар жауаб биреб йткян: чын, чын синӈа йтямен: кем дя кем жанӈадан тыумаса, Алла Падшалыгын кюря алмас, дигян. 4 Никодимъ Анӈар йткян: кеше карт булгач, ничек тыусын? ул анасы эченя икенче табкыр кереб, тыуа алыр меней? дигян. 5 Іисусъ жауаб биргян: чын, чын синӈа йтямен: кем дя кем сыудан, Тыннан тыумаса, Алла Падшалыгына керя алмас. 6 Тяннян тыуган ўзе дя тян, ямма Тыннан тыуган, ўзе дя тын. 7 Минем синӈа: сезгя жанӈадан тыуарга тейеш диб йткянемя исеӈ китмясен. 8 Жил теляся кайда ися, анын тауышын да эшетясен, тик анын кайдан килеб, кайда киткянен белмейсен; Тыннан тыуган яр-кем шулай була, дигян. 9 Никодимъ Іисуска жауабка йткян: бу ничек булсын? дигян. 10 Іисусъ жауаб биреб, анӈар йткян: син Израиль ёйрятеўчесе, мыны да белмейсен ме? чын, чын синӈа йтямен: 11 Без белгянне сёйлёйбез, кюргянне таныклыйбыз; ямма сез безнен таныклауыбызны кабыл алмыйсыз. 12 Мин сезгя жирдягене йткяч тя, сез ышанмыйсыз, сезгя кюктягене сёйлясям, ничек ышанырсыз? дигян.

Зач. 9. 13 Кюктя тороучы, кюктян инӈян Ядям Улыннан башка беряўнен дя кюкка менгяне жук. 14 Моисей буш кырда жыланны кютяреб куйган кюк, Ядям Улы да шулай кютяреб куйылырга тейеш, 15 Анӈар ышаныучы яр-кем мянге тормошло булсын, ямма жугалмасын диб.

Зач. 10. 16 Алла дёньяне шул катле сёйдё, Ўзенен жангыз тыуган Улын да бирде, Анӈар ышаныучы яр-кем мянге тормошло булсын, ямма жугалмасын диб. 17 Алла Ўзенен Улын дёньягя дёньяне айыблар ёчён жибярмяде, ямма дёнья Анын арткылы котолсон диб (жибярде). 18 Анӈар ышаныучы айыбланмый,

ämmя ышанмаганы älюк айыблы, ул Алланын жангыз тыуган Улынын исеменя ышанмады шул. 19 Айыбланыу мынын öчön: дöньягя жакты килде, тик кешеляр, эшляре жаман булганга кюря, жактыдан бигеряк карангыны сöйдöляр. 20 Жаманны кылыучы äр-кем жактыны жаратмыйдыр, эшляре жаманга кюря, жаман эшляре кюренмясен диб, жактыга таба бармый. 21 Ämmя дöрöслöк кылыучы кеше, эшлярен Алла кушканча кылганга кюря, эшлярем кюренсен диб, жактыга таба барадыр.

Зач. 11. 22 Шуннан суң Иисусъ öйрянеўчеляре белян Іудея жиреня килгян, алар белян шунда торган: чумылдырган. 23 Іоаннъ да шулай Салимъ жанындагы Енонда чумылдырган, анда сыу бик кюб икян; кешеляр шунда килгянняр, чумылдырылганнар. 24 Іоаннъ ул чакта öтöрмянгя жабылмаган икян. 25 Шул чакта Іоаннъ öйрянеўчеляре Іудейляр белян тазарыныу турысында жингешкянняр. 26 Шунныктан алар Іоаннга килеб äйткянняр: эй öйрятеўче, синең белян бергя Іорданъ жанында булган Кеше, син таныклаган Кеше, мына Ул чумылдыра, бар да Аңар киляляр, дигянняр. 27 Іоаннъ жауаб биреб äйткян: кешегя кюктян бирелмяся, ул ўзе ўз öстöня ич нястя дя ала алмас. 28 Мин Христосъ тöгöл, ämmя тик Анын алдыннан жибярелгян гня дигянемя сез ўзегез миңа таныкчы. 29 Кыз жяряшелгян кеше кеяў дейеля, кеяў жанында тороб, аңар аң салыб тороучы дусы, кеяўнен тауышын эшетеб, сöйöня-сöйöня тора. 30 Инде мин шул сöйöнöчкя тулыландым: Аңар артырга, ämmя миңа кимергя тейеш. 31 Жугартын Килеўче барыннан да жугары; жирдян булган ўзе дя жир, жирнеке кюк сöйляшя дя; кюктян Килеўче барыннан да жугары. 32 Ул кюргянен, эшеткянен таныклый, тик Анын таныклауын беряў дя кабыл алмый. 33 Анын таныклауын кабыл алган кеше, Алла чын икянне кюрсятя. 34 Алладан жибярелгян Алла сюзен äйтя шул; Алла Тынны ўлчяб бирмей. 35 Ата Улны сöя, барын да Анын кулына биргян. 36 Улга ышаныучы мянге тормошло, Улга ышанмаган кеше ул тормошно кюрмяс, ämmя Алланын ачыуы анын öстöндя тора, дигян.

4-нче бюлем

1 Іисусъ Ўз турысында: Ул
ойрянеўчелярне дя Іоаннан кю-
беряк таба, аннан кюберяк чу-
мылдыра да дигянне фарисей-
ляр эшеткянне белгян. 2 Тик
Іисусъ Ўзе чумылдырмаган,
ойрянеўчеляре чумылдырган-
нар. 3 (Шул хабярне белгяч), Ул
Іудеяны калдырыб, тагы Галиле-
яга киткян. 4 Анар Самарія арт-
кылы ўтяргя киряк булган.

Зач. 12. 5 Шулай Іисусъ Са-
маріянын Сихарь дигян каласы-
на, Іаковъ ўз улы Іосифка ölöш
итеб биргян жирнен жанындагы
калага кергян. 6 Шунда Іаковъ
койосо бар икян. Іисусъ жул ба-
рыудан талыгыб, шул койо жа-
нына утырган. 7 Алтынчы сагат
тирясе икян. Шунда Самарія ка-
тыны сыу алырга диб килгян. Іи-
сусъ анар äйткян: Миня эчяргя
бирче, дигян. 8 Ойрянеўчеляре
ашамнык сатыб алырга калага
киткянняр икян. 9 Самарія кату-
ны Анар äйткян: ничек Син Іу-
дей булыб тороб, мин Самарія
катыныннан эчяргя соройсон?
Іудейляр Самарія кешеляре бе-
лян катышмыйлар ич, дигян. 10
Іисусъ анар жауаб биреб äйткян:
äгяр дя син Алла дяўлятен
белсяң, аннары Миня эчяргя
бирче диб синя äйтеўченен Кем
икянен (белсяң), син ўзең Аннан
сорар ыйың, Ул синя тере сыу
бирер эйе, дигян. 11 Катын Анар
äйткян: эй Кадерле! Синең сыу
алыр нястяң дя жук, койо ти-
рян, Син суң тере сыуны кайдан
алырсын? 12 Син älля бу койоно
биргян Іаковъ атабыздан да оло-
рак мы? мыннан ул ўзе дя эчкян,
балалары да, тыуарлары да (эч-
кянняр), дигян. 13 Іисусъ анар
жауаб биреб äйткян: бу сыуны
эчеўче äр-кем тагы эчясе килер;
14 Ämmя кем дя кем Мин биргян
сыуны эчся, анын гумергя эчя-
се килмяс; Мин анар биргян сыу
анда мянге тормошка ага торган
сыунын чишмясе булыр, дигян.
15 Катын Анар äйткян: эй Кадер-
ле! миня шул сыуны бирче, ми-
нем эчясем килмясен эйе, мында
сыу алырга да жöрöсö булма-
сам ыйы, дигян. 16 Іисусъ анар
äйткян: бар, мында иреңне ча-
кырыб кил, дигян. 17 Катын жа-
уаб биреб äйткян: минем ирем
жук, дигян. Іисусъ анар äйткян:
ирем жук диб син döröс äйттең:
18 Синең биш ирең бар ыйы,
älеге ирең дя синя ир töгöл,
анысын син döröс äйттең, дигян.
19 Катын анар äйткян: эй Кадер-
лем! инде мин синең пагам-
бяр икяненне кюрямен, дигян.
20 Безнен аталарыбыз (Алла-
га) шушы тау östöндя табын-

ганнар, ӓммя сез табына торган урын Іерусалимда дейсез, дигян. 21 Іисусъ анӷар ӓйткян: син Миӈа ышан, багыт килеб житя, ул чакта Атага бу тау өстөндя гня, Іерусалимда гна табынмассыз. 22 Сез нейгя табынганыгызны белмейсез, ӓммя без нейгя табынганыбызны белябез, котолоу Іудейлярдян шул. 23 Мына багыт житяр, инде житте дя, ул чакта дөрөс табыныучылар Атага тын белян, чыннык белян табынырлар. Ата Ўзеня шулай табыныучыларны эзлей шул. 24 Алла тын, Анӷар табыныучылар да тын белян, чыннык белян табынырга тейеш, дигян. 25 Катын Анӷар ӓйткян: Христосъ дигян Мессія килясене белямен; Ул килгяч, безгя барын да белдерер, дигян. 26 Іисусъ анӷар ӓйткян: Ул Мин Ўзем, синеӈ белян сөйляшеўче, дигян. 27 Шул чактук Анын өйрянеўчеляре килгянняр, аларнын Анын катын белян сөйляшеўеня исляре киткян, алайда ней соройсон Син? диб, жя анын белян ней турысында сөйляшясен? диб берсе дя ӓйтмягян. 28 Аннары катын чиляген калдырыб, калага кайтыб, кешелярга ӓйткян: 29 Барыгыз, мин ней кылганны барын да миӈа ӓйтеб биргян кешене кюрегез, Ул Христосъ тӧгӧл микян? дигян. 30 Алар каладан чыгыб, Іисусъ катына килгянняр. 31 Шул арада өйрянеўчеляре Анӷар: эй Өйрятеўче, аша инде дигянняр. 32 Ӓммя Ул аларга ӓйткян: Минем сез белмей торган ашамныгым бар, дигян. 33 Шул сяятлей өйрянеўчеляре ўз араларында ӓйтешкянняр: ӓлля Анӷар бер-бер кеше ашарга китерде микян? диб. 34 Іисусъ аларга ӓйткян: Минем ашамныгым Мине Жибяреўченен иркен кылыу, Анын эшен булдырыб житкезеў. 35 Сез: тагы дюрт айдан суӈ урак житяр дейсез тӧгӧл ме? Ӓммя Мин сезгя ӓйтямен: кюзлярегезне кютяреб, ашлыкларга карагыз, алар ничек агарганнар инде, урырга житкянняр. 36 Урыучы сауабын аладыр, мянге тормошка жимешляр жыядыр; шулай итеб, чячеўче дя урыучы да бергя сөйөнөшөрляр. 37 Берсе чячя, икенчесе ура дигян сюз мынӷар бик туры киля. 38 Мин сезне ўзегез эшлямягянне, бютянняр эшлягянне урырга жибярдем, ӓммя сез аларнын эшеня керештегез, дигян. 39 Ул миӈа ней кылганымны барын да ӓйтте диб катын таныклаган буйынча, шул каладагы Самарія кешеляренен кюбесе Іисуска ышанганнар. 40 Шуӈар кюря, самаряннар Анын катына килгяч,

бездя бер ауык торсана диб, Анҕар ўтенгянняр. Ул анда ике кён торган. 41 Анын Ўз сюзен эшеткяч, Анҕар тагы да кюберяк ышанганнар. 42 Аммя катынга айткянняр: инде без синеҥ сюзеҥ буйынча гна ышанмыйбыз, аммя ўзебез эшетеб, Ул чыннаб дöньяне котkарыучы Христосъ икянне белдек, дигянняр. 43 Ике кён ўткяч, Іисусъ аннан чыгыб, Галилеяга киткян. 44 Іисусъ Ўзе таныклаб айткян икян: пагамбяргя ўскян жирендя кадер булмый диб. 45 Ул Галилеяга килгяч, Галилея кешеляре, Анын Іерусалимда бяйрямдя бар кылган эшлярен кюргяннектян, Аны кабыл алганнар, бяйрямгя алар да барганнар икян шул. 46 Шулай Іисусъ тагы Галилеянын Кана дигян каласына, сыуны аракыга алмаштырган жиреня килгян.

Зач. 13. Падша жортонда тороучы бер тюря Капернаумда булган, анын улы чирлей икян. 47 Ул, Іисуснын Іудеядан Галилеяга кайтканын эшетеб, Анын катына килгян дя Анҕар: ўляр халгя житкян улымны барыб тöзятсяня диб ўтенгян. 48 Іисусъ анҕар айткян: сез, кодрятляр, билгеляр кюрмясягез, ышанмассыз, дигян. 49 Падша жортонда тороучы Анҕар айткян: эй Ходай, улым ўлгенче, барсана дигян. 50 Іисусъ анҕар айткян: бар кайт, улыҥ сау инде, дигян. Ул, Іисусъ айткян сюзгя ышаныб, кайтыб киткян. 51 Кайтыб барганда, жулда кызмятчеляре анҕар карышы очораганнар, улыҥ сауыкты дигянняр. 52 Ул алардан сораган: ул кайсы сагаття жиҥеляйде? дигян. Алар анҕар айткянняр: княген жиденче сагаття тир кастасы аны ташлады, дигянняр. 53 Атасы шуннан Іисусъ анҕар: улыҥ сау инде дигян сагат шул сагат булганын белгян. Шуннан суҥ ул ўзе дя, öйöндягеляре дя барысы да (Анҕар) ышанганнар. 54 Бу икенче кодрятне Іисусъ Іудеядан Галилеяга кайткач кылган.

5-нче бюлем

Зач. 14. 1 Шуннан суҥ Іудейлярнен бяйряме булган, шунда Іисусъ Іерусалимгя килгян. 2 Іерусалимда сарык кабкасы дигян кабка жанында чумына торган урын бар икян, анын жанында öстöн жабкан биш бюлмяле каралды булган, ул Еврейчя Виөезда [1] дейелгян. 3 Шул бюлмялярдя бик кюб чирлеляр, сукырлар, аксаклар, короган кешеляр сыу кузгалыуын көтöб жатканнар. 4

[1] Изгелек öйö.

ган сыуга Ходай пяриштясе багыты-багыты белян төшөб, сыуны болгата икян; болганыу белян сыуга иң элеке кергян кеше, нейдей чир белян чирле булса да, сауыга икян. 5 Шунда бер кеше бар икян, ул утыз сигез жыл чирлей икян. 6 Іисусъ анын жатканын кюреб, кюб багыттан бирле чирле икянен белеб, аңар äйткян: сау буласың киля ме? дигян. 7 Чирле Аңар äйткян: киля, эй Ходай, тик сыу болганган чагында, мине сыуга итеб кертер кешем жук, мин барыб житкенче, миннян алдан бютян кеше кереб житя, дигян. 8 Іисусъ аңар äйткян: тор, урнынгны ал да жöр, дигян. 9 Ул кеше шул сяттюк сауыккан; аннары урнын алган да китя башлаган. 10 Бу кöн суббота кöн икян. Шул сяятлей Іудейляр сауыккан кешегя äйткянняр: бöгöн суббота ич, синға урнынгны кютяреб жöрöргя тейеш тöгöл, дигянняр. 11 Ул аларга жауаб биргян: мине сауыктырыучы миңа äйтте: урнынгны ал да жöр диде, дигян. 12 Аннары аннан: синға урнынгны ал да жöр диб äйткян кеше кем? диб сораганнар. 13 Тöзялгян кеше Ул кем икянне белмягян; Іисусъ шунда булган калык арасына кергян икян. 14 Аннан ары Іисусъ аны чиркяўдя очоратыб, аңар äйткян: мына син сауыктың, инде жазыкланма, синға бигеряк тя жаман булмасын, дигян. 15 Шул кеше Іудейлярга барыб белдергян: мине сауыктырыучы Іисусъ икян, дигян. 16 Іисусъ шундый эшлярне суббота көннö кылганы öчöн, Іудейляр Аны кыса башлаганнар, Аны ўтерергя кöй эзлягянняр. 17 Іисусъ аларга äйткян:

Зач. 15. Атам älегя чаклы кыла, Мин дя кыламын, дигян. 18 Шуңар кюря Іудейлярнен Аны бигеряк тя ўтеряселяре килгян, Ул субботаны бозоу гна тöгöл, Алланы да Атам диб äйтеб, Ўзен Аллага тиң иткян шул. 19 Мыңар карышы Іисусъ аларга äйткян: чын, чын сезгя äйтямен: Атасы кылганны кюрмяся, Улы Ўз Ўзеннян ич ней кыла алмас: Атасы ней кылса, Улы да шулай шуны кыладыр шул. 20 Ата Улны сöя, Ўзе ней кылганны барын да Аңар кюрсятя шул; Аңар былардан да артык эшлярне кюрсятер, сезнен исегез дя китяр. 21 Ата ўлгяннярне терелткян кюк, тере тоткан кюк, Улы да теляся кемне терелтя. 22 Ата беряўгя дя хокöм итмей, ämмя бар хокömнö Улына табшырды, 23 Барысы да Улны, Атаны кадерлягянчя, кадерлясенняр диб. Улны кадерлямей торган кеше, Аны жи-

бяргян Атаны да кадерлямей, дигян.

Зач. 16. 24 Чын, чын сезгя айтямен: Минем сюземне тыңнаучы, Мине Жибяреўчегя ышаныучы мянге тормошло була, ул хокомгя тошмой, аммя ўлемнян терелеккя кючя. 25 Чын, чын сезгя айтямен: багыт житя, инде житте дя, ўлгянняр ул чакта Алла Улынын ауазын эшетерляр, эшеткяч тя терелеб торорлар. 26 Ата ничек Ўзендя терелекле, шулай Улга да Ўзендя терелекле булыуны бирде. 27 Аннары Анар хокöм итяргя дя кыуат бирде, Ул Адям Улы шул. 28 Мыңар исегез китмясен: кабердягеляр барысы да Алла Улынын ауазын эшетер багыт житя инде; 29 Жакшылык кылганнары (мянге) тороргa терелерляр, аммя усаллык иткянняре айыбланырга терелерляр. 30 Мин Ўз иркемнян ич ней кыла алмыймын, дигян.

Зач. 17. Эшеткянемчя хокöм итям, хокöмöм дöрöс, Мин шул Мине жибяргян Атам ирке булсын ыйы дим, аммя Ўз иркем тöгöл. 31 Агяр Мин Ўз турымда Ўзем гня таныкласам, Минем таныклауым чын тöгöл. 32 Минем турымда таныклаучы бютян бар; анын Минем турымда таныклаган таныклыгы чын икянне белямен. 33 Сез Іоаннга жибярдегез, ул чынны таныклады. 34 Алайда Мин кеше таныклауын киряксенмейем, тик мыны сез котолсон диб айтямен. 35 Іоаннъ жана торган, жактырта торган жактырткыч ыйы; сез анын жактысында бер-аз багыт кна сöйöнясöгöз килгян эйе. 36 Минем Іоаннъ (таныклауыннан) оло таныклыгым бар: Ата Миңа кылыб житкезергя биргян эшляр, шушы Мин кыла торган эшляр ўзляре Минем турыда Мине Ата жибяргянне таныклаб торалар шул. 37 Мине жибяргян Атам Минем турда тагы Ўзе дя таныклык итте. Аммя сез Анын тауышын да эшеткянегез жук, жöзöн дя кюргянегез жук. 38 Анын сюзе дя сездя тормой, Аннан жибярелгянгя ышанмыйсыз шул. 39 Жазыуларны тикшерегез, сез алар арткылы мянге тормошло булырбыз диб уйлыйсыз шул. Алар Мине таныклаб торалар. 40 Аммя сез тормошло булыр öчöн, Миңа килясегез килмей. 41 Мин кеше даннауын киряксенмейем, 42 Аммя Мин сезне белям: сездя Алланы сöйöўлек жук. 43 Мин Атам исеменя килдем, аммя сез Мине кабыл алмыйсыз; агяр дя бютян ўз исеменя кился, аны кабыл алырсыз. 44 Бер Алладан данналыуны эзлямейче, бер берегездян дан-

налыуны гна кабыл алгач, сез ничек ышана алырсыз? 45 Мин Ата алдында сезне айыблар диб уйламагыз: сезне айыблаучы, сез ышаныб тора торган Моисей бар. 46 Ägяр сез Моисейгя ышансагыз, Минa да ышаныр ыйыгыз. Моисей Минем турыда жазган шул. 47 Сез анын жазыуларына ышанмагач, Минем сюзляремя ничек ышанырсыз? дигян.

6-нчы бюлем

1 Шуннан суң Іисусъ Галилея-Тиверіада дингезенен ары жагына киткян. 2 Анын ауырыуларга кылган кодрятлярен кюргянгя кюря, артыннан кюб калык барган. 3 Іисусъ бер тау östönя менгян дя шунда öйрянеўчеляре белян утырган. 4 Іудейлярнен пасха бяйряме жакыннашыб киля икян.

Зач. 18. 5 Іисусъ кюз кютяреб караб, Анғар таба кюб калык килгянне кюргяч, Филиппка äйткян: аларны туйдырырга икмяк кайдан сатыб алыйык? дигян. 6 Ул мыны Филиппны сынаб äйткян, ämмя Ўзе ней кыларын белгян. 7 Филиппъ Анғар жауаб биргян: быларнын äр-берсеня аз-аз гна теярлек бирергя дя, ике жöз динарійлек икмяк тя житмяс, дигян. 8 Öйрянеўчеляренен берсе, Симонъ Петрнын энесе Андрей Анғар äйткян: 9 Мында бер малайнын биш арпа икмяге белян ике кечкеня балыгы бар; тик бу хатле кюб калыкка ул жук кна нястя, дигян. 10 Іисусъ äйткян: аларга утырырга кушыгыз, дигян. Ул төштя ўлям бик шяб икян. Шулай итеб биш менң кешеляб утырганнар. 11 Іисусъ икмяклярне алыб, (Аллага) тау итеб, öйрянеўчеляреня биргян, öйрянеўчеляре утырган кешелергя(öляшкянняр), шулай балыкларны да äр-берсеня телягянчя биргянняр. 12 Алар туйгач, Ул Ўз öйрянеўчеляреня äйткян: калган сыныкларны жыйыгыз, бер нястясе дя жугалмасын, дигян. 13 Биш арпа икмягенен ашаган кешелярдян калган сыныкларын жыйыб, ун ике карнаша тутырганнар.

Зач. 19. 14 Шул чакта Іисусъ кылган кодрятне кюргян кешеляр äйткянняр: дöньягя килясе пагамбяр чыннаб шушы, дигянняр. 15 Іисусъ, алар килеб, Аны кинят алыб, падша итмякче булганны белеб, жангызы гна тагы тау östönя менеб киткян. 16 Кич булгач, öйрянеўчеляре дингез жанына төшкянняр дя. 17 Кимягя кереб, дингезнен ары жа-

гына, Капернаумга киткянняр. Карангы була башлаган, ämмя Іисусъ алар катына килмей торган. 18 Каты жил чыккан, дингез тулкыннаныб торган. 19 Жегерме биш, жя утыз стадія [1] киткяч, алар дингез öстöннян жяяўляб килеб, кимягя таба жакыннашкан Іисусны кюреб, куркышканнар. 20 Ämмя Ул аларга äйткян: бу Мин, курыкмагыз, дигян. 21 Алар Аны кимягя алмакчы булганнар; шул сяттюк кимя алар бара торган жарга килеб туктаган. 22 Дингезнен ары жагында тора калган калык, Іисуснын öйрянеўчеляре кереб утырган кимядян башка, анда бютян кимя булмаганны, Іисусъ кимягя öйрянеўчеляре белян кермягянне, тик öйрянеўчеляре ўзляре гня утырыб киткянне иртягесен белгян. 23 Шул арада Ходай бахиллягян икмякне ашаган тöшкя Тиверіададан бютян кимяляр жакынук килгянняр. 24 Шулай Іисуснын да öйрянеўчеляренен дя анда жугын кюргяч, калык кимялярга кереб, Іисусны эзлей Капернаумга барган. 25 Аны дингезнен ары жагында очоратыб, Анар äйткянняр: эй Öйрятеўче, Син мында кай арада килдең? дигянняр. 26 Іисусъ аларга жауаб биреб äйткян: чын, чын сезгя äйтямен: сез икмяк ашаб туйынганыгызга кюря, Мине эзлейсез, ämмя кодрятляр кюргянегез öчöн тöгöл, дигян.

Зач. 20. 27 Сез черей торган ашамнык öчöн тырышмагыз, ämмя мянге тормошка тора торган ашамнык öчöн (тырышыгыз); аны сезгя Ädям Улы бирер; Алла Ата Анын öстöня Ўз билгесен салды шул, дигян. 28 Шунда Анар äйткянняр: Алла эшлярен кылыйык дисяк, без ней эшлейек суң? дигянняр. 29 Іисусъ аларга жауаб биреб äйткян: мына Алла эше: Ул Кемне жибярде, сез Шуңар ышаныгыз, дигян. 30 Алар Анар äйткянняр: без кюреб, Синa ышанырлык ничек билге кюрсятерсен? Син ней кыларсын? 31 Аларга ашарга икмяк кюктян биргян [2] диб жазганча, безнен аталарыбыз буш кырда манна ашаганнар, дигянняр. 32 Іисусъ аларга äйткян: чын, чын сезгя äйтямен: сезгя кюктян икмякне Моисей бирмяде, ämмя Минем Атам сезгя кюктян чын икмякне биря. 33 Кюктян инеб, дöньягя терелек биреўче Ўзе Алла икмяге, дигян. 34 Анар äйткянняр: эй Ходай! безгя шундый икмякне жалан бир, дигянняр.

Зач. 21. 35 Іисусъ аларга äйткян: терелек икмяге Мин

[1] Стадія-100 саж. чамасы.

[2] Пс 77:24. Исх 16:13-15.

Ўзем: Миңа килеўче ачыкмас, Миңа ышаныучы бер чакта да сыусамас. 36 Ämмя Мин сезгя äйттем: сез Мине кюреб тя ышанмыйсыз, дидем. 37 Ата Миңа биргяне барысы да Миңа килер, Миңа килеўчене тышка кыуыб чыгармам, 38 Мин шу Мине жибяргян Ата иркен кылыйым диб кюктян иңдем, ämмя Ўз иркемне төгöл. 39 Мине жибяргян Атанын ирке шушы: Ул Миңа биргяннен Мин берсен дя жугалтмасын, ämмя калдык көннö барысын да терелтеб торгозсон диб.

Зач. 22. 40 Мине Жибяреўченен ирке шушы: Улны кюреўче, Аңар ышаныучы äркем мянге тормошло булсын диб; Мин аны калдык көннö терелтеб торгозормын, дигян. 41 Анын: кюктян иңгян икмяк Мин Ўзем дигян сюзеня Іудейляр ачыулары килеб, зарланганнар. 42 Бу Іосифъ улы Іисусъ төгöл ме? без Анын атасын да, анасын да белябез ич. Ничек Ул: Мин кюктян иңдем диб äйтя? дейешкянняр. 43 Іисусъ аларга жауаб биреб äйткян: ўз аралый зарланышмагыз. 44 Мине жибяргян Ата тартмаса, Миңа беряў дя киля алмас; (Миңа килгянне) калдык көннö терелтеб торгозормын. 45 Пагамбярляр жазганнар: барысын да Алла öйрятер [1] диб. Атадан эшетеб öйрянгян äр-кем Миңа киля. 46 Атаны беряў-беряў кюргян дейеў төгöл бу; тик Аллядан Килгян гня Атаны кюрде. 47 Чын, чын сезгя äйтямен: Миңа ышанган кеше мянге тормошло, дигян.

Зач. 23. 48 Терелек икмяге Мин Ўзем. 49 Сезнен буш кырда манна ашаган аталарыгыз ўлгянняр. 50 Ämмя кюктян иңя торган икмяк шундый: аны ашаучы ўлмяс. 51 Мин кюктян иңгян тере икмяк: шушы икмякне ашаучы мянгегя торор. Мин бирясе икмяк Минем тянем; аны Мин дöнья тере торор öчöн бирем, дигян. 52 Шул чакта Іудейляр ўз аралый жиңешя башлаганнар: Ул безгя Ўз тянен ашарга ничек биря алыр? дейешкянняр. 53 Іисусъ аларга äйткян: чын, чын сезгя äйтямен: äгяр сез Ädям Улынын тянен ашамасагыз, канын эчмясягез, сездя терелек булмас. 54 Минем тянемне ашаучы, канымны эчеўче мянге тормошло була; калдык көннö Мин аны терелтеб торгозормын. 55 Минем тянем чын ашамнык, Минем каным чын эчемнек шул, дигян.

Зач. 24. 56 Минем тянемне ашаучы, канымны эчеўче Миндя тора, Мин дя анда (торам).

[1] Ис 54:13. Іер 31:34.

57 Мине тере тороучы Ата жибярде, Мин дя Атадан тере торам, Мине ашаучы да Миннян тере торор. 58 Мына кюктян инґян икмяк шушы; ул аталарыгыз ашаган манна кюк тöгöл: алар ўлгянняр, ämмя бу икмякне ашаучы мянгегя торор, дигян. 59 Быларны Ул Капернаумда, синагогада öйряткяндя äйткян. 60 Öйрянеўчеляренен кюбесе мыны эшетеб, äйткянняр: бу сюзляр бик сяйер, мыны кем тыґный алыр? дигянняр. 61 Иисусъ öйрянеўчеляренен мынар зарланганын Ўз эченнян белеб, аларга äйткян: сезне шушы шикляндеря ме? 62 Ägяр Ädям Улынын элгяре торган урына кютярелгянен кюрсягез, ней булыр? Тын тере итя, тян ич тя пайда итмей. 63 Мин сезгя äйтя торган сюзляр тын белян терелек. 64 Тик сезнен арада кайсылары ышанмый торганнары бар, дигян. Ышанмый торганнар кем икянне, Ўзен кем тотоб бирясен дя Іисусъ элгяртенюк белеб, 65 Äйткян: шунын öчöн Мин сезгя äйттем дя: ägяр Атамнан бирелмяся, Миґа беряў дя киля алмас диб, дигян. 66 Шуннан суґ öйрянеўчеляренен кюбесе Аннан айырылыб киткянняр, Анын белян жöрмягянняр. 67 Шул чакта Іисусъ ун икесеня äйткян: сезнен дя айырылыб китясегез килмей ме? дигян. 68 Симонъ Петръ Аґар жауаб биргян: эй Ходай, без кемгя барыбыз суґ? Синеґ мянге тормош сюзляреґ бар. 69 Без Сиґа ышандык та, Син тере Алланын Улы Христосъ икянне белдек тя, дигян. 70 Іисусъ аґар äйткян: Мин сезне ун икене сайлаб алдым тöгöл ме? алайда берегез шайтан, дигян. 71 Ул мыны Симонъ улы Искаріотъ Іудасы турысында äйткян; ул Іисуснын ун ике (öйрянеўчесенен) берсе булган кöйö, Аны тотоб бирергя жöргян шул.

7-нче бюлем

Зач. 25. 1 Шуннан суґ Іисусъ Галилеядя жöргян; Іудейляр Аны ўтерергя эзлягянгя кюря, Іудеядя жöрöсö килмягян. 2 Іудейлярнен чатыр кора торган бяйряме жакыннашкан. 3 Шул чакта Іисуснын агалары Аґар äйткянняр: Син мыннан чык та Іудеягя бар, öйрянеўчеляреґ дя Син кыла торган эшлярне кюрсенняр. 4 Беряў дя бер эшен дя жяшертен кылмый, ämмя ўзен билгеле итяргя тырыша ич; Син шундый эшлярне кылгач, инде Ўзеґне дöньягя кюрсят, дигянняр. 5 Анын агалары да Аґар ышан-

мыйлар икян. 6 Мынар карышы Іисусъ аларга äйткян: äле Минем багытым житмей, ämмя сезнен öчöн äр-кайчан багыт. 7 Сезгя дöнья кюремсезлек итя алмас, ämмя Миңа кюремсезлек итя, Мин анын эшляре жаманныгын таныклыйым шул. 8 Сез шушы бяйрямгя барыгыз, ämмя Мин бу бяйрямгя бармам, äле Минем багытым килеб житмягян шул, дигян. 9 Аларга шушыны äйткяч, Галилеяда калган. 10 Тик агалары барыб житкяч, Ул да кюренмейче килгян кюк кня бяйрямгя жяшерен килгян. 11 Бяйрямдя Іудейляр Аны эзлягянняр, Ул кайда икян? дигянняр. 12 Калык арасында Анын турысында тöрлöчя сöйляшеў булган; кайсылары: Ул арыу дигянняр, ämмя кайсылары: жук, тик калыкны гна алдандыра дигянняр. 13 Алайда Іудейлярдян куркыб, беряў дя Анын турысында калык алдында сöйляшмягян.

Зач. 26. 14 Бяйрямнен жартысында Іисусъ чиркяўгя кереб öйряткян. 15 Ул öйрянмягян кöйö, жазыудагыларны ничек беля диб, Іудейляр исляре китеб сöйляшкянняр. 16 Іисусъ аларга жауаб биреб äйткян: Минем öйряткянем Минеке тöгöл, ämмя Мине Жибяреўченеке. 17 Анын иркен кыласы килгян кеше бу öйрятеўне Алладан мы, ялля Ўземнян гня сöйлöйöм ме, белер. 18 Ўз ўзеннян сöйляўче ўзеня дан эзлей; ämмя данны Ўзен Жибяреўчегя эзляўче чын, Анда дöрöссöзлöк жук. 19 Сезгя законъ Моисей биргян тöгöл ме? Алай булса да сезнен берегез дя законча кыйланмый. Ней öчöн сез Мине ўтерергя жöрöйсöз? дигян. 20 Калык жауаб биреб äйткян: Синдя жен бардыр, Сине кем ўтерергя жöрöй? дигянняр. 21 Іисусъ мынар карышы аларга äйткян: Мин бер эш кылдым, анар барыгызнын да исегез китя. 22 Моисей сезгя кистереў куйган, тик ул Моисейдян тöгöл, ämмя аталардан калган, сез кешене суббота кöннö дя кистерясез; 23 Моисей законы бозолмас öчöн, кеше суббота кöннö дя кистерелгяч, Мин бötöн кешене суббота кöннö сауыктырган öчöн, Миңа ник ачыуыгыз киля? 24 Тыштан тикшермягез, ämмя дöрöс тикшереў белян тикшерегез, дигян. 25 Шунда Іерусалимъ кешеляренен кайсылары äйткянняр: ялля Шушыны ўтерергя жöрöйляр микян? 26 Мына, Ул кеше алдында сöйлöй, Анар бер сюз дя äйтмейляр, ялля Анын Христосъ икяненен чынын башлыклар белделяр микян? 27 Без Анын кайдан икя-

нен белябез, ämмя Христосъ килгяч, Анын кайдан икянен беряў дя белмяс, дигянняр. 28 Шунда Іисусъ чиркяўдя öйрятя тороб, кычкырыб äйткян: сез Мине дя белясез, Мин кайдан икянне дя белясез, Мин Ўз Ўземнян килмядем, ämмя Мине Жибяреўче чын, Аны сез белмейсез. 29 Мин Аны белямен, Мин Аннан шул, Мине Ул жибярде дя дигян. 30 Шунда Іисусны тотоб алырга келягянняр, тик беряў дя Анґар кул тейермягян, Анын сяте житмягян икян шул. 31 Калык арасыннан кюбесе Анґар ышанганнар: Христосъ килгяч, Бу кылган кодрятлярдян дя артык кодрятляр кылар меней? дигянняр. 32 Фарисейляр калык арасында Анын турысында шулай сöйляшкянне эшеткянняр. Шуннан ары фарисейляр белян архіерейляр кызмятчелярне Аны тотарга жибяргянняр. 33 Іисусъ äйткян: Минґа сезнен белян тороргa кюб калмады, Мин инде Жибяреўчемя китярмен. 34 Мине эзлярсез, тик табмассыз; Мин барасы тöшкя сез бара алмассыз, дигян. 35 Шул чакта Іудейляр ўз араларында äйтешкянняр: Ул без таба алмаслык жиргя кайда барырга келей? Älля Ул Еллиннар арасына таралган (Іудейляр) тора торган тöшкя барыб, Еллиннарны öйрятергя келей микян? 36 Мине эзлярсез, тик табмассыз, Мин барасы тöшкя сез бара алмассыз дигян сюзляре ней икян суґ? дигянняр.

Зач. 27. 37 Бяйрямнен калдык кöнö, оло кöнöндя Іисусъ тороб, кычкырыб äйткян: эчясе килгян кеше Минґа килеб эчсен. 38 Минґа ышанган кешенен, Жазыуда äйтелгянчя, эченнян тере сыу инґешляре агыб чыгарлар. [1] 39 Мыны Ул Ўзеня ышаныучылар аласы Тын турында äйткян; аларга äле, Іисусъ данналмаганга кюря, Святый Тын инґмягян икян шул. 40 Калык арасыннан кюбесе шул сюзлярне эшетеб, äйткянняр: чыннаб Ул пагамбяр икян, дигянняр. 41 Кайсылары: Бу Христосъ дигянняр. Ämмя кайсылары äйткянняр: Христосъ Галилеядан килер меней? 42 Жазыуда äйтелгян ич: Христосъ Давидъ няселеннян, Виθлеемнан, Давидъ тыуган жирдян килер [2] диб. 43 Шулай итеб, калык арасында Анын сятлей жинґешкянняр. 44 Аларнын кайсылары Аны тотоб алырга келягянняр, алайда беряў дя Анґар кул тейермягян. 45 Кызмятчеляр, архіерейляр белян фарисейляр жанына кайткач, былар

[1] Ис 12:3. Іоиль 3:18.
[2] Мих 5:2.

аларга äйткянняр: сез Аны ник алыб кайтмадыгыз? дигянняр. 46 Кызмятчеляр жауаб биргянняр: бу кеше сöйлягян кюк бер чакта да сöйлягян кеше жук, дигянняр. 47 Фарисейляр аларга äйткянняр: ялля сез дя алдандыгыз мы? 48 Башлыклар арасында, жя фарисейляр арасында беряў-беряў Анҕар ышанды мы суҥ? 49 Ämмя бу калык законны белмей, каргаулы ул, дигянняр. 50 Аларнын берсе, Иисуска тöння килгян Никодимъ, аларга äйткян: 51 Безнен законъ, кешенен сюзен элеке тыҥнаб алмаган кöйö, анын ней кылганын белмягян кöйö, кешене айыблый мы? дигян. 52 Мыҥар карышы анҕар äйткянняр: ялля син дя Галилеянеке ме? тикшереб кара, Галилеядян пагамбяр килгяне жукны кюрерсен, дигянняр. 53 Аннары барысы да öйляреня таралышканнар.

8-нче бюлем

1 Иисусъ Елеонъ тауына киткян. 2 Иртягесен тагы чиркяўгя килгян, бар калык та Анын катына килгян. Ул утырыб, аларны öйряткян.

Зач. 28. 3 Шунда книгячеляр, фарисейляр уйнашлыкта тотолган бер катынны алыб килеб, аны уртага торгозоб, 4 Иисуска äйткянняр: эй Öйрятеўче! бу катынны уйнашлыкта тоттолар; 5 Моисей законда шушындыйларны таш белян атыб ўтерергя кушкан, ämмя Син ней äйтерсен? дигянняр. 6 Аны айыблар öчöн бер-бер нястя табарбыз ялля диб, шулай Аны сынаб äйткянняр икян. Ämмя Иисусъ тюбян эйелеб, аларга карамыйчын, бармагы белян жиргя жазыб торган. 7 Аннары алар Иисустан тагы да сораб торгач, Ул кютярелеб, аларга äйткян: сезнен кайсыгыз жазыксыз, шул иҥ элеке анҕар таш атсын, дигян. 8 Тагы тюбян эйелеб, жиргя жазыб торган. 9 Алар мыны эшеткяч, ўз айыбларын кюҥелляре сиздеря торгач, ололары да, кечеляре дя барда, берсе артыннан берсе чыга башлаганнар. Тик бер Иисусъ кна, тагы уртада тора торган катын гна калганнар. 10 Иисусъ кютярелеб, катыннан бютян беряўне дя кюрмягяч, анҕар äйткян: эй катын! сине айыблаучылар кая? сине берсе дя айыбламады мы? дигян. 11 Ул жауаб биргян: эй Ходай, берсе дя (айыбламады) дигян. Иисусъ анҕар äйткян: Мин дя сине айыбламыйым; бар кайт, инде жазыкланма, дигян.

Зач. 29. 12 Иисусъ тагы калыкка сöйляб äйткян: Мин дöньягя

жакты; Минға эяргян кеше карангыда жӧрмяс, ämмя анын терелек жактысы булыр, дигян. 13 Шул чакта фарисейляр Анар äйткянняр: Син Ӱз турында Ӱзеҥ таныклык итясен, Синеҥ таныклыгыҥ чын тӧгӧл, дигянняр. 14 Іисусъ аларга жауаб биреб äйткян: Мин Ӱз турымда Ӱзем таныклык итсям дя, Минем таныклыгым чын; Мин кайдан килеб, кая барыуымны белямен шул, ämмя сез Минем кайдан икянемне, кая барыуымны белмейсез. 15 Сез тянчя тикшерясез, Мин беряӱне дя (алай) тикшермеймен. 16 Мин тикшерсям дя Минем тикшереӱем чын, Мин жангыз тӧгӧл, Мин Мине жибяргян Ата белян бергя шул; 17 Сезнен законыгызда да: ике кешенен иткян таныклыгы дӧрӧс диб жазылган [1] ич. 18 Мин Ӱз турымда Ӱзем таныклык итям, Минем турда Мине жибяргян Ата да таныклык итя, дигян. 19 Шул чакта Анар äйткянняр: Атаҥ кая? дигянняр. Іисусъ жауаб биргян: сез Мине дя, Минем Атамны да белмейсез; ägяр сез Мине белсягез, Минем Атамны да белер эйегез, дигян. 20 Бу сюзляр-не Іисусъ чиркяӱдя ӧйряткяндя, чиркяӱ казнасы саклана торган тӧштя сӧйлягян. Анын сяте äле житмягянгя кюря, Аны беряӱ дя тотоб алмаган.

Зач. 30. 21 Іисусъ аларга тагы äйткян: Мин китям, сез Мине эзлярсез, аннары жазыклы кӧйӧ ӱлярсез; Мин барасы тӧшкя сез бара алмассыз, дигян. 22 Шунда Іудейляр äйтешкянняр: älля Ул Ӱзен Ӱзе ӱтерясе була мы? Мин барасы тӧшкя сез бара алмассыз диб äйтя, дигянняр. 23 Ул аларга äйткян: сез тюбянгелярдян, Мин жугарыгылардан; сез шушы дӧньядян, Мин бу дӧньядян тӧгӧл. 24 Шуҥар кюря Мин сезгя: жазыклы кӧйӧ ӱлярсез диб äйттем дя; ägяр сез бу Мин икянгя ышанмасагыз, жазыклы кӧйӧ ӱлярсез шул, дигян. 25 Шул чакта Анар: Син кем суҥ? дигянняр. Іисусъ аларга äйткян: äле сезгя äйтеӱемчя, Мин баштанук тороучы. 26 Минем сезнен турда сӧйлясем, тикшерясем кюб, ämмя Мине Жибяреӱче чын, Мин Аннан ней эшеттем, шуны дӧньягя сӧйлӧймен дя дигян. 27 Алар Ул аларга Ата турында äйткянне анамаганнар. 28 Іисусъ аларга тагы äйткян: Ädям Улын кютяреб куйгач, бу Мин икянне белерсез, Ӱземнян ич-ней кылмаганымны да, ämмя Мин Атам Мине ӧйряткянчя сӧйлягянне дя белерсез. 29 Мине Жибяреӱче

[1] Втор 19:15.

Минем белян бергя; Ата Мине жангыз калдырмады, Мин жалан Анҕар жараганны кыламын шул, дигян. 30 Ул мыны сöйлягян чакта, кюб кеше Анҕар ышанганнар.

Зач. 31. 31 Шул чакта Іисусъ Ўзеня ышанган Іудейлярга айткян: Минем сюземдя торсагыз, сез Минем чын öйрянеўчелярем булырсыз, 32 Сез чынныкны белерсез, чынныk сезне иркен итяр, дигян. 33 Анҕар жауаб биргянняр: без Авраамъ няселе, бер чакта да беряўгя дя кол булыб торганыбыз жук; ник иркен булырсыз диб айтясен? дигянняр. 34 Іисусъ аларга айткян: чын, чын сезгя айтямен: жазык кыла торган яр-кем жазыкка кол; 35 Тик кол öйдя гумергя тормой, ямма ул [1] гумергя тора. 36 Айса Ул сезне иркен ится, сез чыннаб иркен булырсыз. 37 Сез Авраамъ няселе икянне белямен, алайда сез Мине ўтерергя жöрöйсöз, Минем сюзем сезгя сыймый шул. 38 Мин Атамнан кюргянемне айтямен, сез дя атагыздан кюргянне кыласыз, дигян. 39 Анҕар жауабка айткянняр: безнен атабыз Авраамъ, дигянняр. Іисусъ аларга айткян: сез Авраамъ оланнары булсагыз, Авраамъ эшлярен кылар ыйыгыз. 40 Ямма Мин Алладан эшеткян чынны айткян кешене сез казер ўтерергя жöрöйсöз; Авраамъ мыны кылмаган. 41 Сез атагызнын эшлярен кыласыз, дигян. Мынҕар карышы Анҕар айткянняр: без уйнашлыктан тыумаган, безнен Атабыз бер, Алла, дигянняр.

Зач. 32. 42 Іисусъ аларга айткян: ягяр Алла сезнен Атагыз булса, сез Мине жаратыр ыйыгыз, Мин Алладан чыгыб килдем шул; Мин Ўз Ўземнян килмядем, Мине Ул жибярде. 43 Сöйляўемне анҕамаганныгыгыз нейлектян? Сюземне тынҕный алмаганныгыгыздан. 44 Сезнен атагыз шайтан, сез атагыз телягянне кыларга келейсез; ул баштанук кеше ўтереўче булган, чыннykта тора алмаган, анда чыннык жук шул; жалганны сöйлягян чагында, ул ўзеннян сöйлöй, ул жалганчы, жалганнын атасы шул. 45 Ямма Мин чынны айткянгя кюря, сез Миҕа ышанмыйсыз. 46 Сезнен арадан кем Миндя жазык барын кюрсятер? Мин чынны айткяч, сез ник Миҕа ышанмыйсыз? 47 Алла кешесе Алла сюзлярен тынҕный; сез Алланыкы тöгöлгя кюря, тынҕнамыйсыз, дигян. 48 Мынҕар карышы Іудейляр жауаб биреб, Анҕар айткянняр: Сине Самарія

[1] Ата улы.

кешесе диб, Синдя жен бар диб без дөрөс äйтябез төгöл ме? дигянняр. 49 Іисусъ äйткян: Миндя жен жук; ämмя Мин Атамны кадерлеймен, сез Мине кадерсез итясез. 50 Алайда Мин Ўземя дан эзлямеймен, Эзляўче, хокöм Итеўче бар.

Зач. 33. 51 Чын, чын сезгя äйтямен: кем дя кем Минем сюземне тотса, ул ўлмяс гумергя, дигян. 52 Іудейляр Анар äйткянняр: инде Синдя жен барны белдек. Авраамъ да, пагамбярляр дя ўлгянняр, ämмя Син: кем дя кем минем сюземне тотса, ул ўлмяс гумергя диб äйтясен. 53 Син безнен Авраамъ атабыздан оло меней? ул ўлгян, пагамбярляр дя ўлгянняр, Син Ўзеңне кемгя куясын? дигянняр. 54 Іисусъ жауаб биргян: Мин Ўземне Ўзем даннасам, Минем даннауым буш; сез Аллабыз диб äйтя торган Атам Мине данналдыра. 55 Сез Аны белмядегез, ämмя Мин Аны белямен; ägяр дя Аны белмейем дисям, Ўзем сезгя ошаулы жалганчы булыр ыйым. Ämмя Мин Аны белям, сюзен дя тотам. 56 Атагыз Авраамъ Минем көнöмне кюрергя кюңелдян тордо: кюрде дя, сöйöндö дя дигян. 57 Іудейляр Анар äйткянняр: Синa äле илле жяш тя жук; Авраамны кюрдең меней? дигянняр. 58 Іисусъ аларга äйткян: чын, чын сезгя äйтямен: Авраамъ булмастан элекюк Мин бар, дигян. 59 Шул чакта Анар атар öчöн ташлар алганнар; тик Іисусъ кюренмяс булыб, урталарыннан ўтеб, чиркяўдян чыгыб, алга таба киткян.

9-нчы бюлем

Зач. 34. 1 Бара торгач, Іисусъ тыумыштанук сукыр кешене кюргян. 2 Öйрянеўчеляре Аннан сораганнар: эй Öйрятеўче! кем жазыкланган: ўзе ме, älля тыудырыучылары мы? ул ник сукыр тыуган? дигянняр. 3 Іисусъ жауаб биргян: ўзе дя, тыудырыучылары да жазыкланмаганнар, ämмя анда Алла эшляре кюренергя (шулай тыуган). 4 Мин Мине Жибяреўченен эшлярен кöн беткенче эшлярга тейеш; тöн килеб житяр, ул чакта беряў дя эшлей алмас. 5 Мин дöньядя чагында, Мин дöньягя жакты, дигян. 6 Шулай дигяч, жиргя тöкöрöб, тöкörögö белян балчык сыйыклаб, балчыкны сукырнын кюзеня жаккан да. 7 Анар äйткян: бар, Силоамъ сыуында жыуын, Силоамъ дигяне жибярелгян дейеў. Ул барыб жыуынгач, кюря торган булыб кайткан. 8 Шул чакта

кюрешеляре дя анын элеке сукыр икянен кюргян кешеляр дя äйтешкянняр: сораныб утырыучы кеше тöгöл ме бу? дигянняр. 9 Кайсылары: бу ул дигянняр; кайсылары: анар ошой дигянняр; ул ўзе дя: ул мин дигян. 10 Шунда аннан сораганнар: кюзляреҥ ничек ачылды? диб. 11 Ул жауаб биреб äйткян: Иисусъ дигян кеше балчык сыйыклаб, кюзляремя жакты да миҥа äйтте: Силоамъ сыуына барыб жыуын диде. Мин, барыб жыуынгач, кюря торган булдым, дигян. 12 Анар: Ул кайда? дигянняр. Ул: белмейем дигян. 13 Аннары шул элгяре сукыр булган кешене фарисейлярга алыб барганнар, 14 Иисусъ балчык сыйыклаб, анын кюзлярен ачылдырган кöн суббота икян. 15 Шул кешедян: ничек кюря торган булдыҥ? диб фарисейляр дя сораганнар. Ул аларга äйткян: Ул минем кюзляремя сыйык балчык жакты, аннары мин жыуындым да инде кюрям, дигян. 16 Шул чакта фарисейляр арасыннан кайсылары äйткянняр: бу Кеше Алладан тöгöлдöр, субботаны кадер итмей, дигянняр. Бютянняре äйткянняр: жазыклы кеше шундый кодрятлярне ничек кыла алсын? дигянняр. Шулай итеб, ўз араларында жиҥешкянняр. 17 Сукырга тагы äйткянняр: Анын турысында син ней äйтерсен? синеҥ кюзляреҥне Ул ачкан ич, дигянняр. Ул äйткян: Ул пагамбяр, дигян. 18 Іудейляр анын элеке сукыр икяненя дя, аннары кюзляре ачылганга да, шул кюзляре ачылган кешенен тыудырыучыларын чакырыб китергенче, ышанмаганнар. 19 Алардан сораганнар: сукыр тыуды диб äйтя торган улыгыз шушы мы? ул суҥ инде ничек кюря? дигянняр. 20 Анын тыудырыучылары аларга жауаб биреб äйткянняр: мынын улыбыз икянен дя, сукыр тыуганын да белябез; 21 Ämмя казер ничек кюря торган булганын белмейбез, анын кюзлярен кем ачканны да без белмейбез: ўзенен жяше житкян, ўзеннян сорагыз, ўз турысында ўзе äйтсен, дигянняр. 22 Аны тыудырыучылар Іудейлярдян куркыб, шулай диб äйткянняр; кем дя кем Иисусны Христось диб белся, ул кешене синагогадан айырырбыз диб Іудейляр сюз куйышканнар икян шул. 23 Ўзенен жяше житкян, ўзеннян сорагыз диб тыудырыучылары шунныктан äйткянняр. 24 Шул сяятлей элеке сукыр булган кешене чакырыб, анар äйткянняр: Аллага дан китер; ämмя без ул Кешене жазыклы диб белябез, дигянняр. 25

Ул аларга жауаб биреб äйткян: жазыклы мы Ул, анысын белмеймен, тик элгяре сукыр икянемне, ämмя казер кюря торган булганымны гна белямен, дигян. 26 Аннан жяня сораганнар: Ул синға ней кылды, кюзляреңне ничек ачты? дигянняр. 27 Аларга жауаб биргян: мин инде сезгя äйттем, сез тыңнамадыгыз; тагы ней эшетясегез киля? сез дя Анын öйрянеўчеляре буласыгыз киля меней? дигян. 28 Алар аны курлаб äйткянняр: син Анын öйрянеўчесе, ämмя без Моисей öйрянеўчеляре. 29 Моисейгя Алла сöйлягянне без белябез, ämмя Бу кайдан икянне белмейбез, дигянняр. 30 Кюзе ачылган кеше аларга жауаб биреб äйткян: Ул кайдан икянне белмягянегез, мына шунысы ис китярлек, ämмя Ул минем кюзляремне ачты. 31 Без белябез: жазыклыларны Алла тыңнамый, тик Алланы кадерляўчене, Анын иркен кылыучыны гна Алла тыңный. 32 Беряў-беряў сукыр тыуган кешенен кюзлярен ачканны гумердян бирле эшеткян жук; 33 Ул Алладан булмаса, ич-ней кыла алмас ыйы, дигян. 34 Аңар жауабка äйткянняр: син бötöнняй жазык эчендя тыуганың, син безне öйрятясен ме? дигянняр дя аны тышка кыуыб чыгарганнар. 35 Iисусъ, аны тышка кыуыб чыгарганны эшеткяч, аны табыб, аңар äйткян: син Алла Улына ышанасын мы? дигян. 36 Ул жауаб биреб äйткян: эй Ходай, Ул кем суң? мин Аңар ышаныр ыйым, дигян. 37 Iисусъ аңар äйткян: син Аны кюрдең, Ул синең белян сöйляшя, дигян. 38 Ул äйткян: эй Ходай, ышанамын дигян дя Аңар жыгылыб башырган. 39 Iисусъ äйткян: Мин бу дöньягя хокöм итяргя килдем, кюрмей торганнар кюрсенняр диб, ämмя кюря торганнар сукыр айсыннар диб, дигян. 40 Мыны эшеткяч, Анын катында булган фарисейлярнен кайсылары Аңар äйткянняр: älля без дя сукыр мы? дигянняр. 41 Iисусъ аларга äйткян: сез сукыр булсагыз, жазыгыгыз булмас ыйы, ämмя кюрябез дигянегезгя кюря, жазыгыгыз öстögöздя кала, дигян.

10-нчы бюлем

Зач. 35. 1 Чын, чын сезгя äйтямен: сарык абзарына ишектян кермейче, бютян жирдян менеб кереўче бур да, талаучы да, 2 Ämмя ишектян кереўче сарыкларнын котöўчесе. 3 Ишек саклаучы аңар ишекне ача, сарыклар анын тауышын

тыңныйлар, ул ўз сарыкларын аты-аты белян чакырыб, алыб чыга. 4 Ўз сарыкларын алыб чыккач, аларнын алдыннан бара, әммя сарыклар, анын тауышын белгянгя кюря, артыннан киляляр. 5 Жат кеше артыннан бармыйлар, әммя аннан качалар, жат кешенен тауышын белмейляр шул, дигян. 6 Іисусъ аларга шушы мясялне әйткян; тик алар Ул аларга ней әйткянне аңнамаганнар. 7 Шуңар кюря Іисусъ аларга тагы әйткян: чын, чын сезгя әйтямен: Мин сарыкларга ишек; 8 Миннян элгяре килеўчеляр ней катле булса да барысы да бурлар, талаучылар, әммя сарыклар аларны тыңнамадылар, дигян.

Зач. 36. 9 Мин ишек: кем дя кем Минем арткылы керся, ул котолор, керер дя, чыгар да, көтөлөр жир дя табар. 10 Бур урлар өчөн, ўтерер өчөн, харяб итяр өчөн гня киля. Мин кешеляр артыгы белян терелекле булсыннар диб килдем. 11 Мин арыу көтөўче: арыу көтөўче сарыклары өчөн ўз жанын биря. 12 Әммя жалчы, ўзе көтөўче булмаганныктан, сарыклары да ўзенеке төгөллөктян, киля торган бюрене кюреб, сарыкларны ташлаб кача; шунда бюре сарыкларны талаб тарата. 13 Жалчы кеше жалчы булганныктан кача, сарыклары өчөн дя көймөй. 14 Мин арыу көтөўче: Мин Ўземнекелярне белямен, Ўзенекеляр дя Мине беляляр. 15 Мине Ата белгянчя, Мин дя Атаны белямен; сарыклар өчөн жанымны да бирямен. 16 Минем тагы бютян сарыкларым да бар, алар бу абзарныкы төгөл; Мин аларны да китерергя тейеш, алар да Минем тауышымны эшетерляр; аннары бер көтөў, бер көтөўче булыр, дигян.

Зач. 37. 17 Ата Мине шушынын өчөн сөя: Мин жанымны бирямен, аны тагы алыр өчөн. 18 Миннян аны беряў дя (көчляб) алмый, әммя Мин аны Ўзем бирямен: Аны бирергя дя кыуатым бар, аны тагы алырга да кыуатым бар. Бу бойорокно Мин Атамнан алдым. 19 Шушы сюзляр сяятлей, Іудейляр ўз араларында тагы жиңешкянняр. 20 Аларнын кюбесе әйткянняр: Ул женнедер, акылсызлана Ул, Аны ник тыңныйсыз? дигянняр. 21 Кайсылары әйткянняр: бу сюзляр женне кешеneке төгөл, сукырларнын кюзлярен жен ача алыр меней дигянняр. 22 Іерусалимдя (чиркяўне) жаңарткан бяйрям житкян, ул чакта кыш икян. 23 Іисусъ чиркяўдя, Соломонныкы дейелгян ал бюлем-

дя жöргян. 24 Шунда Іудейляр Анын äйлянясеня жыйылышыб, Анҥар äйткянняр: Син безне озак жöдятеб торорсон мы? Син Христосъ мы, безгя туры äйт, дигянняр. 25 Іисусъ аларга жауаб биргян: Мин сезгя äйттем, сез ышанмыйсыз; Атам исеменя кыла торган эшлярем, шулар Мине таныклыйлар. 26 Алайда Мин сезгя äйткянчя, сез ышанмыйсыз, сез Минем сарыкларым арасыннан тöгöл шул, дигян.

Зач. 38. 27 Сарыкларым Минем тауышымны тыҥныйлар, Мин дя аларны белямен, алар да Минем артымнан киляляр. 28 Мин аларга мянге терелек бирямен, алар жугалмаслар гумергя; Минем кулымнан аларны ичкем талаб ала алмас. 29 Аларны Миҥа биргян Атам äр кемнян дя оло; аларны Атамнын кулыннан беряў дя талаб ала алмас. 30 Мин дя, Ата да-Без бер, дигян. 31 Шунда Іудейляр Аны ўтерейек диб, тагы ташлар алганнар. 32 Іисусъ аларга äйткян: Мин Атамнан сезгя кюб жакшы эшляр кюрсяттем; кайсысы öчöн Мине таш белян атыб ўтерергя келейсез? дигян. 33 Іудейляр Анҥар жауаб биреб äйткянняр: Сине таш атыб ўтерергя келяўебез арыу эш öчöн тöгöл, ämмя Алланы курлауыҥ öчöн, Син Ўзеҥ кеше кöйö, Ўзеҥне Алла итясен, дигянняр. 34 Іисусъ аларга äйткян: сезнен законыгызда жазылган тöгöл ме: Мин äйттем: сез аллалар [1] диб. 35 Алла сюзе äйтелгяннярне Ул аллалар диб äйтеб тя, жазылган бозолмагач, 36 Ата Ўзе арыулаб, дöньягя жибяргянгя, Мин Алла Улы диб äйткянем öчöн, Алланы курлыйсын диб ник äйтясез? 37 Äгяр Мин Атам эшлярен кылмыйым икян, Миҥа ышанмагыз; 38 Äгяр кылам икян, Ўземя ышанмасагыз, Ата Миндя, Мин Атада икянне белеб ышаныр öчöн, эшляремя ышаныгыз. 39 Шул чакта алар Аны тагы тотарга келягянняр, ämмя Ул аларнын куллары-на тоттормый киткян. 40 Аннары тагы Іорданнын ары жагына, элгяре Іоаннъ чумылдырган тöшкя барган да, шунда калган. 41 Анын катына кюб кеше килгян; алар: Іоаннъ бер тöрлö кодрят тя кылмаган ыйы, ämмя Іоаннын Мынын турында äйткяне барысы да чын икян диб, сöйляшкянняр. 42 Шунда кюб кеше Анҥар ышанганнар.

---

[1] Пс 81:6.

11-нче бюлем

Зач. 39. 1 Виѳанія ауылынын Лазарь атлы беряў чирлей икян; Марія ўз тутасы Марѳа белян шунда торалар икян. 2 Бу агасы Лазарь чирлягян Марія Ходайны мѵро белян майлаб, Анын аякларын чяче белян сөрткян Марія. 3 Алар туталы сеңнеле (икесе дя) Іисуска: эй Ходай! мына Син сөйгян кеше чирлей диб әйтергя кеше жибяргянняр. 4 Іисусъ, мыны эшеткяч, әйткян: бу чир ўлярга төгөл, әммя Алла данналыр өчөн, бу чир сябяблей Алла Улы данналыр өчөн, дигян. 5 Іисусъ Марѳаны да, анын сеңнесен дя, Лазарне дя сөя икян. 6 Ул, Лазарнен чирлягянен эшеткяч, шул тора торган урнында ике көн торган. 7 Шуннан суң өйрянеўчеляреня әйткян: тагы Іудеягя барыйык, дигян. 8 Өйрянеўчеляре Аңар әйткянняр: эй Өйрятеўче, іудейляр Сине таш атыб ўтерергя кляўляре кюбтян ме әле? Син тагы анда барасың, дигянняр. 9 Іисусъ аларга жауаб биргян: көн ун ике сагат төгөл ме? көндөз жөргян кеше, бу дөньянен жактысын кюргянгя кюря, сөртөнмөй. 10 Әммя төння жөргян кеше, жактысы жукка кюря, сөртөня, дигян. 11 Мыны әйткяннян суң, аларга тагы әйткян: дусыбыз Лазарь жокога китте, Мин аны уятырга барамын, дигян. 12 Өйрянеўчеляре әйткянняр: эй Ходай, жокога киткян булса, айса сауыгыр, дигянняр. 13 Іисусъ анын ўлгянен әйткян икян; әммя алар Ул гадятчя жоклау турысында әйтя диб уйлаганнар. 14 Шунда Іисусъ аларга туры әйткян: Лазарь ўлде; 15 Мин анда булмаганыма сезнен өчөн, сез ышанасыга кюря сөйөням; әйдягез, инде аңар барыйык, дигян. 16 Шунда игез дигян Ѳома өйрянеўчелярга әйткян: әйдягез, без дя Анын белян бергя ўлейек, дигян. 17 Іисусъ килгяндя Лазарнен кабердя жатыуына дюрт көн ўткян икян. 18 Виѳанія Іерусалимнан жакын гна, ун биш стадія [1] чамасы гна икян. 19 Іудейлярнен кюбесе Марѳа белян Марія катына аларны агалары кайгысыннан жыуатырга килгянняр. 20 Іисусъ киля диб эшеткяч, Марѳа Аңар карышы чыккан, Марія өйдя утыра калган. 21 Шунда Марѳа Іисуска әйткян: эй Ходай! Син мында булган булсаң, агам ўлмяс эйе; 22 Әммя әле дя белямен: Син Алладан ней гня сорасаң да, Алла Синя бирер, дигян. 23 Іисусъ аңар әйткян: аганг терелеб торор, дигян. 24 Марѳа Аңар

[1] 3 чакырымнаб.

äйткян: калдык көннө, терелеў багытында анын терелеб торорон белямен, дигян. 25 Іисусъ анҕар äйткян: терелтеўче, тере тотоучы Мин Ўзем; Миҥа ышаныучы ўлся дя терелеб торор; 26 Миҥа ышаныучы äр-бер кеше ўлмяс гумергя. Мыҥар ышанасын мы? дигян. 27 Марөа Анҕар äйткян: дöрöс, эй Ходай! Алланын дöньягя килеўче Улы Христосъ икяненҕя ышанамын, дигян. 28 Мыны äйткяч, ул кайтыб, жяшерен гня ўз сеҥнесе Марія-ны чакырыб, анҕар: Öйрятеўче мында, Ул сине чакыра, дигян. 29 Марія эшетеў белян, тизеряк тороб, Анын катына киткян. 30 Іисусъ äле ауылга кермягян икян, Ул Аны Марөа очораткан төштя тора икян. 31 Аны жыуатырга килгян, анын öйöндя булган іудейляр, Маріянын ашыгыб тороб, чыгыб киткянен кюргяч, ул кабергя жыларга бара торгандыр диб уйлаб, анын артыннан барганнар. 32 Марія Іисусъ туктаб торган урынга килгяч, Аны кюреб, Анын аягы астына жыгылыб, Анҕар äйткян: эй Ходай! äгяр Син мында булган булсаҥ, агам ўлмяс эйе, дигян. 33 Іисусъ, ул жылаганны, анын белян бергя килгян Іудейлярнен дя жылауларын кюргяч, Ўзе дя жаны белян көйöнöб, кюҥеле тулыб, 34 Äйткян: аны кайда куйдыгыз? дигян. Анҕар äйткяннар: эй Ходай! барыб кюр, дигянняр. 35 Іисуснын кюзляре жяшлянгян. 36 Шул чагында Іудейляр äйткянняр: кара, Ул аны ничек сöйгян, дигянняр. 37 Кайсылары äйткянняр: сукырнын кюзен ачыучы Бу мыны да ўлмягян көйö калдыра алмады микян ней? дигянняр. 38 Іисусъ тагы эченнян кайгырыб, кабер жанына килгян. Кабер тау кыуышында икян, ауызына таш каблаган икян. 39 Іисусъ äйткян: ташын алыгыз, дигян. Ўлекнен сеҥнесе Марөа Іисуска äйткян: эй Ходай! ул инде сасыган, анын кабердя жатыуына инде дюрт кön, дигян. 40 Іисусъ анҕар äйткян: äгяр син ышансаҥ, Алланын олологон кюрерсен диб Мин синҕа äйттем төгöл ме? дигян. 41 Аннары ўлек жаткан кабер ауызыннан ташны алганнар. Іисусъ кюзлярен кюккя таба кютяреб, äйткян: эй Ätей! Мине тыҥнаганыҥа Синҕа тау итямен. 42 Мине жалан тыҥнасыҥны Мин белядер эйем, тик мыны мында тора торган калык öчöн, Мине Син жибяргянгя ышансыннар диб äйттем, дигян. 43 Мыны äйткяч, Ул шяб тауыш белян кычкырган: эй Лазарь! чык тышка, дигян. 44 Шундук ўлек куллары, аяклары кипен-

нярга тӧргян кӧйӧ, бите жаулык белян бяйлягян кӧйӧ чыккан. Іисусъ аларга äйткян: аны чишегез, жӧрсӧн, дигян. 45 Марія катына килгян Іудейлярнен кюбесе шул чагында Іисуснын кылган эшлярен кюреб, Анӷар ышанганнар. 46 Кайсылары фарисейляр катына барыб, Іисусъ ней кылганны аларга äйткянняр.

Зач. 40. 47 Аннары архіерейляр белян фарисейляр синедріонны жыйыб, без ней эшлейек, бу кеше кюб кодрят кыла? дигянняр. 48 Äгяр дя Аны шул кӧйӧ калдырсак, барысы да Анӷар ышаныб бетярляр; аннары Римъ калкы килеб, жиребезне дя, калыгыбызны да ӱз кулына алыр, дигянняр. 49 Алярнын берсе, шул жылны архіерей булыб тороучы Каіафа аларга äйткян: сез бер нястя дя белмейсез, 50 Бӧтӧн калык ärям булгынчы, кешеляр ӧчӧн бер гня кешенен ӱлгяне безгя жакшырак булырын да уйламыйсыз, дигян. 51 Ул мыны ӱзлегеннян äйтмягян, ämмя шул жылны архіерей булганныгыннан, Іисуснын калык ӧчӧн ӱлясесен алдан äйткян. 52 Калык ӧчӧн гня тӧгӧл, ämмя Алланын таралган оланнарын бергя жыяр ӧчӧн дя ӱлясе. 53 Шул кӧннян суӷ Аны ӱтерергя куйганнар. 54 Шуӷар кюря Іисусъ Іудейляр арасында шуннан суӷ кюренеб жӧрмягян, ämмя аннан буш кырга жакын жакка, Ефраимъ дигян калага барыб, ӧйрянеӱчеляре белян шунда торган. 55 Іудейлярнен пасхасы жакыннашкан; бӧтӧн жирдян кюб кеше, тазарыныр ӧчӧн, пасха алдыннан Іерусалимгя килгянняр. 56 Алар Іисусны эзлягянняр, чиркяӱдя торган чакларында берсеня берсе äйтешкянняр: сез ничек уйлыйсыз? Ул бяйрямгя килмяс микян? дейешкянняр. 57 Ämмя архіерейляр белян фарисейляр, Аны тотоб алыр ӧчӧн, кем дя кем Анын кайда икянен белся, килеб äйтергя кушканнар.

12-нче бюлем

Зач. 41. 1 Пасха бяйряменнян алты кӧн алдан, Іисусъ, ӱлгян Лазарне тергезгян ауылына Виӧаніягя килгян. 2 Анда Іисуска аш жасаганнар, Марӧа кызмят иткян; Іисусъ белян бергя утырыучылар арасында Лазарь дя булган. 3 Ämмя Марія бер грябянкя ич-ней катыштырмаган нардъ дигян кыйбатлы мѵро алыб килеб, Іисуснын аякларын майлаган да Анын аякларын чяче белян сӧрткян; мѵронын тямне исе белян

бӧтӧн ӧй тулган. 4 Шул чагында ӧйрянеӳчеляренен берсе, Симонъ улы, Іуда Искаріотъ дигяне, Іисусны тотоб бирясе булганы айткян: 5 Ник бу мvроны ӧч жӧз динарійгя сатыб, (акчасын) сораныучыларга бирмяскя? дигян. 6 Ул мыны сораныучылар ӧчӧн сагышланыуыннан айтмягян, ӓммя ӳзе бурга кюря айткян: акча тартмасын ул тоткан, анда салганны ул алыб жӧргян. 7 Іисусъ айткян: анӷар теймягез, ул мыны Минем кюмелер кӧнӧмя саклаб тоткан; 8 Сораныучылар жалан сезнен белян ич, ӓммя Мин жалан сезнен белян булмам, дигян. 9 Іудейлярнен кюбесе Іисуснын шунда икянен белеб, Анын ӧчӧн гня тӧгӧл, ӓммя Ул ӳлгян жиреннян терелтеб торгозган Лазарне дя кюрейек диб килгянняр. 10 Архіерейляр Лазарне дя ӳтерергя куйганнар, 11 Анын сяятлей іудейлярнен кюбесе килеб, Іисуска ышанганнар шул. 12 Бяйрямгя килгян кюб калык икенче кӧннӧ Іисусъ Іерусалимгя киля диб эшетеб, 13 пальма чыбыклары тотоб, Анӷар карышы чыкканнар да: Осанна! Ходай исеменя килеӳче даннаулы, эй Израиль Падшасы! диб кычкырганнар. 14 Ӓммя Іисусъ жяш ишекkя таб килеб, анӷар атланган, былай диб жазылганча: 15 Эй Сіонъ кызы, курыкма! мына синеӈ Падшаӈ жяш ишяккя атланыб киля [1] дигянчя. 16 Анын ӧйрянеӳчеляре мыны элеке анӈнамаганнар икян, ӓммя сунӈыннан Іисусъ данналгач, бу Анын турында жазылганны да, Анӷар мыны жазылганча кылганны да исляреня тӧшӧргянняр. 17 Элеке Іисусъ белян булган кешеляр: Ул Лазарне кабердян дяшеб чыгарды, аны ӳлгяненнян тергезеб торгоздо диб таныклаганнар. 18 Іисуснын бу кылган кодрятен эшеткян буйынча, калык Аны карышы алган.

Зач. 42. 19 Фарисейляр ӳз араларында айтешкянняр: бер нярстя дя кылыб булмаганны кюрясез ме? кара, бӧтӧн дӧнья Анӷар эяреб бетя, дигянняр. 20 Табыныр ӧчӧн бяйрямгя килгян кешелярнен кайсылары Еллиннаръ икян. 21 Алар Галилеядагы Виѳсаиданын Филиппъ катына килеб, аннан сораганнар: эй кадерле! безнен Іисусны кюрясебез киля, дигянняр. 22 Филиппъ барыб, мыны Андрейгя айткян; аннары Андрей белян Филиппъ мыны Іисуска айткянняр. 23 Іисусъ аларга жауабка айткян: Ӓдям Улынын данналыр сагате житте. 24 Чын, чын сезгя айтямен: бодай бӧртӧгӧ жиргя тӧшӧб ӳлмяся,

[1] Зах 9:9.

ўзе гня тора; ägяр дя ўлся, кюб жимеш китеря. 25 Жанын сöйгян кеше- аны жугалтыр, ämмя бу дöньядя жанын жаратмас булган кеше- аны мянге тормошка саклар. 26 Миңа кызмят итеўче Миңа эярсен; Мин кайда, кызмятчем дя шунда булыр. Миңа кызмят итеўчене Минем Атам кадерляр. 27 Казер Минем жаным кöяляня башлады; ней äйтейем Мин? эй Ätей, бу сагаттян Мине коткар! Алайда Мин шушы сагат öчöн килдем. 28 Эй Ätей! исеменңне даннат, дигян. Шул чагында кюктян ауаз килгян: даннаттым, тагы да даннатырмын диб. 29 Шунда тороб, мыны эшеткян калык äйткян: кюк кюкеряўдер бу диб, кайсылары äйткянняр: Анғар пяриштя дяшкяндер, дигянняр. 30 Іисусъ мынғар карышы äйткян: бу ауаз Минем öчöн булмады, ämмя калык öчöн булды. 31 Казер бу дöньягя хокöм булды; казер бу дöньянен князе тышка кыуылыб чыгарылыр. 32 Мин жирдян кютярелгяч, барын да Ўземя тартыб алырмын, дигян. 33 Былай диб äйтеб, Ул ничек ўлясесен кюрсяткян. 34 Калык Анғар äйткян: без законнан эшеттек, Христосъ гумергя тора диб; Син суң Ädям Улы кютярелергя тейеш диб ничек äйтясен? Ул Ädям Улы кем суң? дигянняр. 35 Шунда Іисусъ äйткян: сезнен арада жакты тагы аз гна багыт торор; жакты бар чагында жöрöгöз, сезне карангы каблаб бетермясен; карангыда жöрöўче кайда барганын белмей, дигян.

Зач. 43. 36 Жакты оланнары булыр öчöн, жакты сезнен белян торган чагында, жактыга ышаныгыз, дигян. Мыны äйткяч, Іисусъ читкя китеб, алардан жяшеренгян. 37 Іисусъ алар алдында шул катле кодрятляр кылса да алар Анғар ышанмаганнар. 38 Шулай итеб, Исаія пагамбярнен: эй Ходай, бездян эшеткянгя кем ышанды? Ходайнын кыуаты кемгя кюренде? [1] дигян сюзе жиреня килгян. 39 Аларнын ышана алмаганнары, Исаія пагамбяр тагы äйткянчя, шушы сяятлей булган: 40 Аларнын кюзляре кюрмяс булган, кюңелляре таш кюк катыланган, кюзляре белян кюрмяс öчöн, кюңелляре белян анғамас öчöн, (Миңа) кайтмас öчöн, ämмя Мин аларны тöзятер эйем, [2] дигянчя. 41 Исаія мыны, Ходайнын олологон кюргяч, Анын турысында сöйлягян чагында, äйткян. 42 Алайда башлыкларнын да кюбесе Іисуска ышанганнар, тик синагогадан

[1] Ис 53:1.
[2] Ис 6:9-10.

айырмасыннар диб, фарисейляр сяятлей, ышанганнарын билгертмягянняр; 43 Алар Алладан данналыудан бигеряк кешедян данналыуны артык сöйгянняр шул. 44 Іисусъ тагы кычкырыб äйткян: Миңа ышаныучы Мине Жибяреўчегя ышана, ämмя Миңа тöгöл. 45 Мине кюреўче дя Мине Жибяреўчене кюря. 46 Мин жакты, Миңа ышаныучыларнын берсе дя карангыда калмасын диб, Мин дöньягя килдем. 47 Кем дя кем Минем сюзляремне эшетеб тя ышанмаса, Мин аны айыбламыйым; Мин дöньяне айыбларга диб килмядем, ämмя дöньяне коткарырга диб килдем шул. 48 Мине кабыл алмаганнын, сюземне тыңнамаганнын айыблаучысы бар: Мин äйткян сюз, аны калдык көннö айыблар, 49 Мин Ўземнян сöйлямядем шул; ämмя Мине жибяргян Атам Ўзе Миңа ней äйтергя, ней сöйлярга бойорок бирде. 50 Мин белямен: Анын бойорого мянге тормош. Шулай итеб, Мин ней гня сöйлясям дя, Миңа Ата äйткянчя сöйлöйöм, дигян.

13-нче бюлем

Зач. 44. 1 Пасха бяйряме алдыннан, Іисусъ бу дöньядян Атасына кючяр сагате житкянне белеб, дöньядяге Ўзенекелярне сöйöб, аларны ўлярлек булыб сöйгянен кюрсяткян. 2 Кич ашы ашаган чагында, Симонъ улы Іуда Искаріотнын кюңеленя Іисусны тотоб бирергя шайтан уй салгач, 3 Іисусъ барын да Ата Анын кулына табшырганны, аннары Ўзенен Алла жаныннан чыгыб, тагы Алла жанына китясесен белеб, 4 Аштан торган да öст кейемен салыб, сöлгö алыб, биленя чолгаган. 5 Аннары комганга сыу салыб, öйрянеўчеляренен аякларын жыуыб, Ўзеня чолгаган сöлгö белян сöртя башлаган. 6 Симонъ дигян Петрга килеб житкяч, Петръ Анар äйткян: эй Ходай, минем аякларымны Син жыуарсын меней? дигян. 7 Іисусъ анар жауаб биреб äйткян: Мин ней кылганны син äле белмейсен, ämмя суңыннан анарсын, дигян. 8 Петръ Анар äйткян: гумергя мин Синя аякларымны жыудырмам, дигян. Іисусъ анар жауаб биргян: äгяр Мин сине жыумасам, Минем белян öлöшöң булмас, дигян. 9 Симонъ Петръ Анар äйткян: эй Ходай, айса аякларымны гна тöгöл, кулларымны да, башымны да (жыу), дигян. 10 Іисусъ анар äйткян: жыуылганнын аякларын

гна жыуарга киряк, ул бӧтӧнняй таза шул; сез дя таза, тик барыгыз да тӧгӧл, дигян. 11 Ул Ӳзен тотоб биреӳчене белгян, шуӈар кюря айткян: сез таза, тик барыгыз да тӧгӧл, дигян.

Зач. 45. 12 Аннары аларнын аякларын жыугач, ӧст кейемен кейеб, тагы утыргач, аларга айткян: Мин сезгя ней кылганны белясез ме? 13 Сез Мине Ӧйрятеӳче диб, Ходай диб айтясез, алай диб айтеӳегез дӧрӧс, Мин шул шу. 14 Айса Мин Ӧйрятеӳче кӧйӧ, Ходай кӧйӧ, сезнен аякларыгызны жыугач, сез дя бер берегезнен аякларын жыуарга тейеш; 15 Мин сезгя кючергеч бирдем шул, Мин сезгя кылганны, сез дя кылсын диб. 16 Чын, чын сезгя айтямен: кол ӳз эясеннян оло тӧгӧл, жибярелгян дя аны жибяреӳчедян оло тӧгӧл. 17 Мыны белсягез, мыны кылсагыз, сез бахетле. 18 Минем айтеӳем барыгыз турысында да тӧгӧл, Мин сайлаганнарымны белямен; ӓммя жазылганнын: Минем белян икмяк ашаучы Миӈа ӳкчясен кютярде [1] дигяне буласы. 19 Ул булмастан элеке, казерюк Мин сезгя аны айтямен, ул булгач, Мин Христосъ икянгя сез ышансын диб. 20 Чын, чын сезгя айтямен: Мин жибяргянне кабыл алыучы Мине кабыл ала; ӓммя Мине кабыл алыучы Мине Жибяреӳчене кабыл ала, дигян. 21 Мыны айткяч, Іисуснын жан тынычы беткян, шунда таныклаб айткян: чын, чын сезгя айтямен: сезнен арадан беряӳ Мине тотоб бирер, дигян. 22 Шул чакта ӧйрянеӳчеляре, Ул кем турысында айткянне белмейчен, бер берсеня таба карашканнар. 23 Ӧйрянеӳчеляре арасыннан берсе, Іисусъ сӧя торганы, Іисуснын кюкерягеня сыйыныб утырган. 24 Симонъ Петръ анӈар бу кемне айтя икян диб сораргa билге кылган. 25 Іисуснын кюкерягеня сыйыныб утырыучы Анӈар айткян: эй Ходай, ул кем? дигян. 26 Іисусъ жауаб биргян: Мин кемгя бер сынык икмяк маныб бирем, шул ӳзе дигян дя сынык маныб, Симонъ улы Искаріоть Іудага биргян. 27 Шул сыныктан суӈ Іудага шайтан кергян. Шунда Іисусъ анӈар айткян: кыла торганыӈны тизеряк кыл, дигян. 28 Ул мыны анӈар нейгя айткянне утырыучыларнын берсе дя анӈамаган. 29 Тартма Іудада булганга кюря, кайсылары Іисусъ анӈар: безгя бяйрямгя киряклене сатыб алырга айтя диб, жя сораныучыларга бер-бер нястя бирергя айтя диб уйлаганнар. 30 Сынык алгач та Іуда чыгыб

[1] Ис 40:10.

киткян; ул чакта тӧн икян. 31 Ул чыккач, Іисусъ äйткян:

Зач 46. Казер Äдям Улы данналды, Анда Алла да данналды. 32 Анда Алла данналгач, инде Алла да Ӳзендя Аны данналдырыр, Аны тизюк данналдырыр. 33 Эй балалар! Миңа инде сезнен белян торорга кюб калмады; Мине эзлярсез, тик Мин Іудейлярга ничек: Мин барасы тӧшкя сез бара алмассыз диб äйттем, сезгя дя инде шулай äйтямен. 34 Сезгя жаңа бойорок бирямен, сез бер берегезне сӧйсягез эйе. Мин сезне сӧйгян кюк, сез дя шулай бер берегезне сӧйсягез эйе. 35 Äгяр сезнен арагызда бер берегезне сӧйӧулек булса, сез Минем ӧйрянеӳчелярем икянне барысы да шуннан белерляр, дигян. 36 Симонъ Петръ Аңар äйткян: эй Ходай, Син кая барасын? дигян. Іисусъ аңар жауаб биргян: Мин барасы тӧшкя син äле Минем артымнан бара алмассын, ämмя суңыннан артымнан барырсын, дигян. 37 Петръ Аңар äйткян: эй Ходай, казер мин Синең артыңнан ничек бара алмам икян? мин Синең ӧчӧн жанымны бирермен, дигян. 38 Іисусъ аңар жауаб биргян: Минем ӧчӧн жанынңны бирерсен ме? чын, чын синға äйтямен: ätяч кычкыргынчы, син Мине ӧч табкыр таңарсын, дигян.

14-нче бюлем

Зач. 47. 1 Кюңелегез шиклянмясен; Аллага ышаныгыз, Миңа да ышаныгыз. 2 Атамнын ӧйӧндя торор урын кюб, алай булмаса, Мин сезгя äйтер эйем: Мин сезнен ӧчӧн урын äзерлярга барам диб. 3 Барыб, сезгя урын äзерлягяч тагы килермен дя сезне Ӳз катыма алырмын, сез дя Мин торган тӧштя булсын диб. 4 Мин барасы тӧшнӧ сез белясез, жулын да белясез, дигян. 5 Ӧома Аңар äйткян: эй Ходай! кая барасынңны белмейбез, жулын да ничек беля алырбыз? дигян. 6 Іисусъ аңар äйткян: Мин Ӳзем жул, чыннык, терелек; Минем арткылы килмяся, Атага беряӳ дя киля алмый. 7 Сез Мине белсягез, Атамны да белер эйегез. Инде мыннан ары сез Аны белясез дя, кюрдегез дя, дигян. 8 Филиппъ Аңар äйткян: эй Ходай! безгя Атаны кюрсят, безгя шул житяр, дигян. 9 Іисусъ аңар äйткян: сезнен белян шул катле багыт торам, син Мине белмейсен ме Филиппъ? 10 Мине кюргян Атаны кюрде; син суң ничек безгя Атаны кюрсят диб

äйтясен? Мин Атада, Ата Миндя икянгя син ällля ышанмыйсын мы? дигян.

Зач. 48. Мин сезгя äйтя торган сюзлярне Ўземнян äйтмеймен; Миндя тора торган Ата эшлярне Ўзе кыла. 11 Мин Атада, Ата Миндя дигянемя Миңа ышаныгыз; алай дигянемя ышанмасагыз, шул эшляр буйынча Миңа ышаныгыз. 12 Чын, чын сезгя äйтямен: Мин кыла торган эшлярне Миңа ышаныучы да кылар, алардан да артык кылар; Мин Атама барамын шул. 13 Минем исемемя Атадан ней сорасагыз да Мин аны булдырырмын; Ата Улында данналсын диб. 14 Сез Минем исемемя ней сорасагыз да Мин булдырырмын. 15 Мине сöйсягез, бойорокларымны кылыгыз, 16 Мин дя Атага инялермен, Ул сезгя, сезнен белян гумергя тороргa, бютян Тынычландырыучы бирер. 17 Чынныk Тынын (бирер), дöнья Аны кабыл ала алмас, Аны кюрмей дя, белмей дя шул, äммя сез Аны белясез, Ул сезнен белян тора шул, сездя булыр да. 18 Сезне ўгей калдырмам: сезгя килермен; 19 Инде кюб калмады, дöнья Мине кюрмяс, äммя сез Мине кюрерсез; Мин тере торам шул, сез дя тере торорсоз. 20 Мин Атамда, сез Миндя, Мин сездя икянне шул кöннö белерсез. 21 Минем бойорокларымны тотоб, аларны кылыб торган кеше Мине сöя; Мине сöйöб торган кешене Атам да сöяр, аны Мин дя сöярмен, анар Ўземне кюрсятермен, дигян. 22 Искаріотъ Іуда тöгöл, äммя бютян Іуда Анар äйткян: эй Ходай, Ўзеңне дöньягя кюрсятмейче, безгя кюрсятясе килеўең нейлектян? дигян. 23 Іисусъ анар жауаб биреб äйткян: кем дя кем Мине сöйся, ул Минем сюземне кылар; аны Атам да сöяр, Без анар килербез, анда торор урын жасарбыз. 24 Мине сöймöй торган кеше сюзляремне кылмый; сез эшетя торган сюз Минеке тöгöл, Мине жибяреўче Аныкы. 25 Мин мыны сезгя, сезнен белян торган чагымда, äйттем. 26 Ата Минем исемемя жибярясе Тынычландырыучы, Святый Тын, сезне äр-нейгя öйрятер, Мин сезгя сöйлягянне барын да исегезгя тöшöрöр. 27 Сезгя тынычлык калдырамын, сезгя Ўз тынычлыгымны бирямен; сезгя тынычлыкны биреўем, дöнья биргянчя тöгöл, дигян.

Зач. 49. 28 Кюңелегез шиклянмясен, курыкмасын да. Сезнен каттан китямен, аннары сезгя тагы килермен дигянемне сез

эшеттегез; сез Мине сөйсягез, Мин Атага барамын дигянемя сөйөнөрсөз, Атам Миннян олорак шул. 29 Мына шушы айткянем булырдан элеке Мин сезгя айттем, ул булгачтын сез ышансын диб. 30 Инде Миңа сезнен белян сөйляшергя кюб калмады, инде бу дөньянен князе киля, анын Миндя ич нейе жук. 31 Ämмя Мин Атаны сөйгянне, Ата Миңа кушканча кылганны дөнья белсен: торогоз, мыннан китейек, дигян.

15-нче бюлем

Зач. 50. 1 Мин жөзөм агачынын чыны, Атам бакчачы. 2 Жимеш китермей торган Миндяге яр-бер ботакны Ул кисеб ала, ämмя жимеш китеря торган яр-бер ботакны ярчей, жимешне кюберяк китерсен диб. 3 Сезгя сөйлягян сюзем арткылы сез инде ярчелеўле. 4 Миндя торогоз, Мин дя сездя (торормын). Жөзөм агачында булмаган ботак ўз алдына ўзе жимеш китеря алмаган кюк, сез дя Миндя булмасагыз, шулай (жимеш китеря алмассыз). 5 Мин жөзөм агачы, ämмя сез ботаклар; кем дя кем Миндя торса, Мин дя анда торсам, ул кюб жимеш китеря, Миннян башка бер эш тя кыла алмассыз шул. 6 Кем дя кем Миндя тормаса, тышка, ботак кюк ташланылыр, короб бетяр, аннары шундый ботакларны жыйыб, утка ташлыйлар, шунда алар жаныб бетяляр. 7 Миндя торсагыз, Минем сюзлярем сездя торса, телягянегезне сорагыз, сезгя булыр. 8 Кюб жимеш китерсягез, öйрянеўчелярем булсагыз, шунын белян Атам даннылыр, дигян.

Зач. 51. 9 Мине Ата сөйгян кюк, Мин дя сезне сөйдöм; сөйöўлегемдя торогоз. 10 Ägяр бойорокларымны тотсагыз, сөйöўлегемдя торорсоз; Мин дя Атамнын бойорокларын тотканыма кюря, Атам сөйöўлегендя торамын. 11 Мыны Мин сезгя, Минем сөйөнöчöм сездя булсын диб, сезнен сөйөнöчöгöз тулы булсын диб яйттем. 12 Минем бойорогом шушы: Мин сезне сөйгян кюк, сез дя шулай бер берегезне сөйöгöз. 13 Кем дя кем ўз дуслары öчöн ўз жанын бирся, шул сөйöўлектян артык сөйöўлек жук. 14 Мин сезгя кушканны кылсагыз, сез Минем дусларым. 15 Мин инде сезне коллар диб атамыйым, эясе ней кылганны кол белмей шул; ämмя Атамнан эшеткянне барын да сезгя яйткянемя кюря, Мин сезне дус-

ларым диб атадым. 16 Мине сез сайламадыгыз, әммя сезне Мин сайлаб куйдым, барыгыз, жимеш булдырыгыз, жимешегез унъыб торсон диб; сез Минем исемемя Атадан ней гня сорасагыз да Ул сезгя бирсен эйе, дигян.

Зач. 52. 17 Сезгя кушамын: бер берегезне сөйөгөз. 18 Әгяр дөнья сезне кюрялмаса, белегез, ул Мине сездян элгяреряк кюрялмады. 19 Сез дөньядян булсагыз, дөнья ўзенекен сөяр эйе; әммя сез дөньядян булмаганга кюря, Мин сезне дөньядян сайлаганга кюря, дөнья сезне кюрялмый. 20 Сезгя кол эясеннян оло төгөл дигян сюземне исегездя тотогоз; Мине кыугач, сезне дя кыуарлар; Минем сюземне кылган булсалар, сезнекен дя кыларлар; 21 Әммя шунын барысын да сезгя Минем исемем өчөн кыларлар, Мине Жибяреўчене белмейляр шул. 22 Әгяр Мин килеб, аларга сөйлямягян булсам, аларга жазык булмас ыйы, әммя казер жазыклары өчөн айыбсыз булыр халляре жук. 23 Мине кюрялмаган кеше Атамны кюрялмый; [1] 24 Әгяр Мин алар арасында ич-бер кеше кыла алмаслык эшляр кылмаган булсам, аларга жазык булмас ыйы, әммя казер алар кюрделяр, алайда Мине дя, Атамны да кюрялмас булдылар; 25 Тик аларнын законында: мине бушка кюрялмадылар диб жазылган сюз жиреня килсен. 26 Мин сезгя Атадан жибяряе Тынычландырыучы, чыннык Тыны, Атадан чыга торган Тын килгяч, Ул Мине таныклар; 27 Сез дя шулай таныкларсыз, сез элгяртенюк Минем белян эйегез шул, дигян.

[1] Кюремсезлек итя.

16-нчы бюлем

Зач. 53. 1 Мыны Мин сезгя, сез шиклянмясен диб әйттем: 2 Сезне синагогалардан айырырлар. Шундый багыт житяр, әркем сезне ўтереўче ўтергяне белян Аллага жараулы эш кыламын диб уйлар; 3 Атаны да, Мине дя белмягяннекляреннян шулай кыларлар. 4 Әммя Мин мыны сезгя әйттем, ул багыт житкяч, Мин ул турда сезгя сөйлягянне иска төшөрсөнняр диб; Ўзем сезнен белян булганга кюря, башта Мин сезгя аны әйтмягян эйем. 5 Казер инде Жибяреўчемя китямен; алайда кая барасын диб Миннян берегез дя сорамый. 6 Тик Мин сезгя мыны әйткяннян кюнгелегез көйөк белян тулды. 7 Әммя Мин

сезгя чынны äйтямен: Минем барыуым сезнен өчөн жакшырак, Мин бармасам, сезгя Тынычландырыучы килмяс шул; äгяр барсам, Аны сезгя жибярермен. 8 Ул килеб, дöньягя жазыкны, дöрöслöкнö, хокömнö дя кюрсятер: 9 Жазык дигяне Миңа ышанмаганнык; 10 Дöрöслöк дигяне Мин Атама китеў; шунныктан сез Мине кюрмяссез; 11 Хокöм дигяне бу дöньянен князе айыбланыу. 12 Тагы сезгя кюбне äйтясем бар, тик сез казер сыйыштыра алмассыз; 13 Ämмя чыннык Тыны килгяч, Ул сезне äр-бер чынныкка öйрятер: Ул Ўзеннян сöйлямяс, ämмя эшеткянен сöйляр, буласыны сезгя белдерер; 14 Ул Мине данналдырыр, Минекеннян алыб, сезгя белдерер шул, дигян.

Зач. 54. 15 Атамнын нейе бар, барыда Минеке, шуңар кюря Минекеннян алыб, сезгя белдерер диб äйттем дя. 16 Бер аздан Мине кюрмяссез, аннары тагы бер аздан Мине кюрерсез, Мин Атага барамын шул, дигян. 17 Шунда Анын öйрянеўчеляренен кайсылары бер берсеня äйткянняр: бу ней äйтя Ул безгя: бер аздан Мине кюрмяссез, аннары тагы бер аздан Мине кюрерсез дей, аннары Атага барамын? дей. 18 Алар шулай бер аздан диб нейне äйтя Ул? нейне äйткянен белмейбез, дигянняр. 19 Іисусъ Ўзеннян аларнын сорасылары килгянен белеб, аларга äйткян: Мин бер аздан Мине кюрмяссез, аннары тагы бер аздан Мине кюрерсез диб äйткянемне бер берегездян сорашасыз мы? 20 Чын, чын сезгя äйтямен: сез сулкылдаб жылярсыз, ämмя дöнья кыуаныр; сез кайгылы булырсыз, тик сезнен кайгыгыз сöйöнöчкя алмашыр. 21 Катын кеше (бала) тыудырыр чакта кайгырыб тора, анын сагате житкян шул; ämмя бала тыудыргач, дöньягя тыуган кешегя сöйöнöўеннян кайгысын онота. 22 Сез дя казер шулай кайгылы; тик Мин сезне тагы кюрермен, сезнен кюнелегез сöйöнöр, сезнен сöйöнöчöгöзне сездян беряў дя ала алмас. 23 Шул көннö сез Миннян бер турда да сорамассыз, дигян.

Зач. 55. Чын, чын сезгя äйтямен: Атадан Минем исемемя ней сорасагыз да, сезгя бирер. 24 Мыңар чаклы сез Минем исемемя бер нястя дя сорамадыгыз; сорагыз, алырсыз, сöйöнöчöгöз тулы булсын. 25 Мыңар чаклы Мин сезгя мясялляр китереб сöйлядем, инде багыт житя, ул чакта Мин сезгя мясялляр китереб сöйлямям, ämмя Ата турысында сезгя туры белдерем.

26 Шул көннө сез Минем исемемя сорарсыз; Атадан сезнен турыда телярмен диб äйтмейем, 27 Сез Мине сöйгянгя кюря, Атадан чыкканыма ышанганыгызга кюря, Ата Ўзе сезне сöядер шул. 28 Мин Атадан чыгыб, дöньягя килдем; тагы дöньяне калдырыб, Атага китямен, дигян. 29 Öйрянеўчеляре Анҕар äйткянняр: мына Син инде туры сöйлöйсöн, бер-тöрлö мясял дя сöйлямейсен; 30 Син барын да белгянне дя, Синнян беряў-беряў сорауны киряксенмягяненҥе дя инде без кюрябез; шуҥар кюря Син Алладан чыкканга ышанабыз. 31 Иисусъ аларга äйткян: инде ышанасыз? 32 Мына сагат житя, инде житте дя, сез жак жакка таралышырсыз, Мине жангыз калдырырсыз; äммя Мин жангыз тöгöл, Ата Минем белян шул. 33 Мин мыны сезгя, Миндя тынычлансыннар диб äйттем; дöньядя кайгырырсыз, алай да ныk торогоз: Мин дöньяне жиҥдем, дигян.

17-нче бюлем

Зач. 56. 1 Иисусъ бу сюзлярне äйткяч, кюзлярен кюккя таба кютяреб äйткян: эй Атей! сагат житте: Улыҥны данналдыр, Улыҥ да Сине данналдырсын; 2 Син Анын кулына äр-бер тяннe бирдеҥ, Син Анҕар биргяннен барчасына Ул мянге терелек бирсен диб; 3 Äммя мянге терелек бу: Син бер гня чын Алланы, тагы Син жибяргян Иисусъ Христосны белеўлек. 4 Мин Сине жирдя данналдырдым, Син Миҥа кыларга табшырган эшне кылдым. 5 Син Мине казер данналдыр, эй Атей, Синеҥ Ўзеҥдяге дан белян, дöнья булырдан элеке Синдяге даным белян (данналдыр). 6 Син Миҥа дöньдян биргян кешелярге Мин Синеҥ исеменҥе белдерттем; алар Синеке эйе, Син аларны Миҥа бирдеҥ, алар сюзеҥне тоттолар. 7 Миҥа биргянеҥ барысы да Синнян икянне алар инде аҥнадылар, 8 Син Миҥа биргян сюзлярне Мин аларга äйтеб бирдем шул; алар кабыл алдылар, Мин Синнян чыкканны чыннаб аҥнадылар, Мине Син жибяргянгя ышандылар. 9 Мин алар турысында инялямен, бöтöн дöнья турысында тöгöл, тик шушы Син Миҥа биргянняр турысында гна инялямен, алар Синеке шул. 10 Минеке барда Синеке, Синеке барда Минеке; Мин аларда данналдым. 11 Мин инде дöньядя тöгöл, äммя алар äле дöньядя; Мин Сиҥа барамын.

Эй арыу Атей! шушы Син Миңа биргяннярне Ўз исемеңкакына сакла, ничек Без бер, алар да шулай бер булсыннар ыйы. 12 Мин алар белян дөньядя чагымда, аларны Синеңисемеңкакына саклаб тордом; шушы Син Миңа биргяннярне Мин сакладым; алар арасыннан жугалыу улыннан башкасы, беряў дя жугалмады; Жазыудагы шулай жиреня килер. 13 Ämмя Мин инде Синңа барамын; мыны дөньядя чагымда äйтямен, аларда Минем сöйöнөчöм тулы булсын диб. 14 Мин аларга Синеңсюзеңне äйтеб бирдем; дөнья аларны кюрялмас булды, Мин ничек дөньядян [1] төгöл, шулай алар да дөньядян төгöл шул. 15 Аларны дөньядян ал диб инялмеймен, тик аларны жаманнан сакла диб (инялямен). 16 Мин ничек дөньядян төгöл, шулай алар да дөньядян төгöл. 17 Ўз чыныңбелян аларны арыуландыр, Синеңсюзеңчыннык, дигян.

Зач. 57. 18 Син Мине дөньягя жибяргян кюк, Мин дя аларны дөньягя жибярдем; 19 Алар öчöн Мин Ўземне Ўзем арыуландырам [2] алар да чыннык белян арыулансыннар диб. 20 Алар турысында гна инялмеймен, ämмя аларнын сюзе буйынча, Миңа ышаныучылар турысында да инялямен: 21 Барда бер булсыннар ыйы, эй Äтёй, Син Миндя кюк, Мин Синдя кюк, алар да Бездя бер булсыннар ыйы; Мине Син жибяргянгя дөнья ышансын ыйы. 22 Син Миңа биргян данны Мин аларга бирдем: Без бер кюк, алар да бер булсыннар ыйы. 23 Мин аларда, Син Миндя; алар гел бер булыб житсенняр; Син Мине жибяргянне дя, Син Мине сöйгян кюк, аларны да сöйгяненгне дөнья белсен эйе. 24 Эй Ätей! Син Миңа биргянняр Мин булган төштя Минем белян бергя булсыннар ыйы диб телеймен, Син Миңа биргян данымны алар да кюрсенняр эйе, дөнья булдырыудан элеке Син Мине сöйдöң шул. 25 Эй гадел Ätей! дөнья Сине белмяде, ämмя Мин Сине белдем, былар да Мине Син жибяргянне белделяр. 26 Мин аларга Синеңисемеңне белдердем, тагы да белдерем, Син Мине сöйгян сöйöўлек аларда булсын ыйы. Мин дя аларда (булсам ыйы), дигян.

[1] Усаллардан төгöл. Ін 7:7.
[2] Ўзен Ўзе биреўе.

18-нче бюлем

Зач. 58. 1 Мыны äйткяч, Іисусъ öйрянеўчеляре белян Кедронъ чишмясенен ары жагына чыккан; анда агач бакчасы бар икян; шунда Ул Ўзе дя, öйрянеўчеляре дя кергянняр. 2 Бу урынны Аны тотоб биреўче Іуда да беля икян, Іисусъ öйрянеўчелярен жыйыб, шунда онғай баргалый икян шул. 3 Шунныктан Іуда архіерейлярдян, фарисейлярдян бер ауык салдатлар, кызмятчеляр алыб, панарлар, жактырткычлар, кораллар алыб, шунда килгян. 4 Ämмя Іисусъ, Ўзеня ней буласыны барын да белеб, аларга чыгыб äйткян: кемне эзлейсез? дигян. 5 Анғар жауаб биргянняр: Назорей Іисусны, дигянняр. Іисусъ аларга äйткян: ул Мин, дигян. Тотоб биреўче Іуда да алар белян бергя тора икян. 6 Іисусъ аларга: ул Мин диб äйткяч, алар кире чигеб, жиргя жыгылганнар. 7 (Іисусъ) алардан тагы сораган: кемне эзлейсез? дигян. 8 Алар: Назорей Іисусны, дигянняр. Іисусъ жауаб биргян: ул Мин диб Мин сезгя äйттем. Ägяр Мине эзлясягез, инде быларга теймягез, алар китсенняр, дигян. 9 Шулай итеб, Ул äйткян сюз: Син Минa биргяннярнен берсен дя Мин жугалтмадым дигяне жиреня килясе булган. 10 Симонъ Петръ жанындагы кылычын сыуырыб алыб, архіерей колонон уң колагын чабыб öзгян; кол Малхъ исемне икян. 11 Ämмя Іисусъ Петрга äйткян: кылычыңны кынысына тык; Миңа Ата биргян сауытны Мин эчмей калырым меней? дигян. 12 Шул чакта салдатлар, мең кеше башлыгы, Іудей кызмятчеляре Іисусны алыб, Аны бяйлягянняр дя Аны элеке Аннага алыб килгянняр. 13 Анна Каіафа катынынын атасы икян, ämмя Каіафа шул жылны архіерей булыб тора икян. 14 Калык öчön бер гня кешенен ўлгяне жакшырак диб Іудейлярга киңяш биргян Каіафа шушы булган. 15 Іисусъ артыннан Симонъ Петръ белян тагы бер öйрянеўче барганнар; бу öйрянеўче архіерейгя белеш икян, ул Іисусъ белян бергя архіерейнен ишек алдына кергян. 16 Ämмя Петръ кабка артында тышта торган. Аннары архіерейгя белеш икенче öйрянеўче чыккан да кабка саклаучы катынга äйтеб, Петрны керткян. 17 Шунда кабка саклаучы кызмятче катын Петрга äйткян: син дя бу кешенен öйрянеўчеляренен берсе тöгöл ме? дигян. Ул: жук дигян. 18 Сыуык булганга кюря, коллар белян кызмятчеляр ут жагыб, жылыныб торганнар;

Петръ да алар белян жылыныб торган. 19 Архіерей Іисустан Анын өйрянеўчеляре турысында, өйрятеўе турысында сораган. 20 Іисусъ анҕар жауаб биргян: Мин дөньягя айырмачык сөйлядем, Мин жалан синагогада, чиркяўдя, Іудейляр онҕай жыйылыша торган урыннарда өйряттем, жяшерен бер нястя дя сөйлямядем; 21 Ник Миннян соройсоҥ? эшеткян кешелярга ней ăйткянемне ўзляреннян сора, мына алар Мин ней ăйткянне беляляр, дигян. 22 Ул мыны ăйткяч, жакын тора торган кызмятчелярнен берсе, Іисуснын жанҕагына сугыб, ăйткян: архіерейгя Син шулай жауаб бирясен ме? дигян. 23 Іисусъ анҕар жауаб биргян: Мин жаман ăйткян булсам, жаманныгын кюрсят, ăгяр дя жакшы (ăйткян) булсам, Миҥа ник сугасын? дигян. 24 Шуннан суҥ Анна Аны бяйлягян көйö Каіафа архіерейгя жибяргян. 25 Симонъ Петръ жылыныб торган. Шунда анҕар ăйткянняр: син дя Анын өйрянеўчеляренен берсе тöгöл ме? дигянняр. Ул, жук диб, таҥган. 26 Архіерей кызмятчеляренен берсе, Петръ колагын чабыб өзгян кешенен карендяше ăйткян: бакчада мин сине Анын жанында кюрдем тöгöл ме? дигян. 27 Петръ тагы таҥган, шул сяттюк ăтяч кычкырган.

Зач. 59. 28 (Іудейляр) Каіафадан Іисусны преторія [1] дигян урынга алыб барганнар. Бу иртя белян булган. Алар шакшыланмыйык диб, пасха ашарга жараулы көйö торойок диб, преторія эченя кермягянняр. 29 Пилатъ алар катына чыгыб ăйткян: бу Кешене ней белян айыблыйсыз? дигян. 30 Алар анҕар жауаб биреб ăйткянняр: Ул усал булмаса, без Аны синҕа тотоб бирмяс эйек, дигянняр. 31 Пилатъ аларга ăйткян: Аны ўзегез алыгыз, Анҕар ўз законыгызча хокöм итегез, дигян. Іудейляр анҕар ăйткянняр: безгя беряўне дя ўтерергя ирек жук, дигянняр. 32 Шулай итеб, Іисусъ Ўзенен ничек ўлем белян ўлясесен анҕатыб ăйткян сюзе жиреня килергя тейеш булган. 33 Аннары Пилатъ тагы преторіяҕа кереб, Іисусны чакыртыб, Анҕар ăйткян. Син Іудей Падшасы мы? дигян. 34 Іисусъ анҕар жауаб биргян: син мыны ўзеҥнян ăйтясеҥ ме, ăлля синҕа Минем турыда бютянняр ăйттеляр ме? дигян. 35 Пилатъ жауаб биргян: мин Іудей меней? Сине миҥа Ўз калкыҥ белян архіерейляр тотоб бирделяр; Син ней кылдыҥ? дигян. 36 Іисусъ ăйткян: Минем падшалыгым

[1] Римъ тюрясе хокöм итя торган тöш.

бу дөньядян төгөл; падшалыгым бу дөньядян булса, кызмятчелярем Минем өчөн, Мине іудейляр кулына бирдермяскя тырышырлар ыйы; әммя казер Минем падшалыгым мыннан төгөл, дигян. 37 Пилатъ Анҕар әйткян: айса Син Падша? дигян. Іисусъ жауаб биргян: Падша икянемне син (дөрөс) әйтясен. Мин чыннықны таныкларга диб дөньягя тыудым да, килдем дя; чыннан булган әр-кем ауазымны тыҥный, дигян. 38 Пилатъ Анҕар әйткян: чыннык ней? дигян; шулай дигяч тя тагы іудейляр катына чыгыб, аларга әйткян: мин Анын бер айыбын да табмыймын. 39 Сезнен жолагызча Пасха бяйряменя беряўне мин сезгя иркенгя жибярергя тейеш; мин сезгя Іудей Падшасын иркенгя жибярейем ме, телейсез ме? дигян. 40 Шунда барысы да тагы кычкыра башлаганнар: Аны төгөл, Варавваны жибяр, дигянняр. Варавва талаучы икян.

19-нчы бюлем

1 Шуннан суҥ Пилатъ Іисусны алыб, Аны кыйнарга кушкан. 2 Салдатлар чянечкеле агач чыбыкларыннан ўрмя ўреб, Анын башына кейгезгянняр, өстөня кызыл кейем кейгезгянняр дя. 3 Эй Іудей Падшасы, сөйөн! диб әйтеб, Анын жаҥакларына сукканнар. 4 Пилатъ тагы чыгыб, аларга әйткян: мына мин Аны сезгя чыгарамын, Анын бер айыбын да табмаганымны сез белсен диб, дигян. 5 Шунда Іисусъ чянечкеле ўрмя кейгян көйө, кызыл кейем кейгян көйө чыккан. Пилатъ калыкка әйткян: мына ул Кеше! дигян. 6 Архіерейляр белян кызмятчеляр Іисусны кюргяч, былай диб кычкырганнар:

Зач. 60. Кадаклат Аны, кадаклат! дигянняр. Пилатъ аларга әйткян: ўзегез Аны алыгыз да кадаклагыз, мин Анын айыбын табмыймын, дигян. 7 Іудейляр анҕар жауаб биргянняр: безнен законъ бар, безнен законъ буйынча, Ул ўтерелергя тейеш, Ул Ўзен Ўзе Алла Улы итте шул, дигянняр. 8 Пилатъ, бу сюзне эшетеб, бигеряк тя курыккан. 9 Тагы преторіяга кереб, Іисуска әйткян: Син кайдан? дигян; әммя Іисусъ анҕар жауаб бирмягян. 10 Пилатъ Анҕар әйткян: миҥа да жауаб бирмейсен меней? әлля минем Сине кадаклатырга да, (иркенгя) жибярергя дя кыуатым барны белмейсен ме? дигян. 11 Іисусъ жауаб биргян: синҥа жугартын бирелмяся, Миҥа синеҥ ич тя кыуатыҥ булмас ыйы, дигян; шунҕар кюря Мине синҥа тотоб

биреўчегя жазык кюберяк булыр, дигян. 12 Шуннан ары Пилатъ Іисусны (иркенгя) жибярергя тырышкан. Ämмя Іудейляр кычкырганнар: Аны жибярсяң, син кесаргя дус тöгöл; ўзен ўзе падша итеўче ăр-кем кесаргя карышы киля диб. 13 Пилатъ бу сюзне эшеткяч, Іисусны тышка чыгарыб, лиөостротонъ дигян урынга, хокöм урнына утырган; ул урын Еврейчя Гавваөа дейелгян. 14 Бу кöн Пасха алдындагы пятница кöн икян, алтынчы сагат тирясе икян. Шунда Пилатъ іудейляргя äйткян: мына сезнен Падшагыз! дигян. 15 Ämмя алар: ал, ал, Аны кадаклат! диб кычкырганнар. Пилатъ аларга äйткян: сезнен Падшагызны кадаклатыйым меней? дигян. Архіерейляр жауаб биргянняр: безнен кесардян бютян падшабыз жук, дигянняр. 16 Аннары калдыгында Пилатъ Аны аларга кадакларга биргян. Алар Іисусны алыб киткянняр. 17 Іисусъ Ўз качын кютяргян кöйö, Еврейчя Голгоөа дигян маңгай урны дигян жиргя чыккан. 18 Шунда Аны кадаклаганнар; Анын белян тагы ике кешене, берсен бер жагына, берсен икенче жагына, уртага Іисусны кадаклаганнар. 19 Пилатъ качка жазыу жазыб куйган. Жазыуын: Назорей Іисусъ, Іудей Падшасы диб жазган. 20 Бу жазыуны іудейлярнен кюбесе укыганнар; Іисусны кадаклаган тöш каладан жырак тöгöл икян; жазыуы Еврейчя, Грекчя, Римчя жазылган. 21 Іудейлярнен архіерейляре Пилатка äйткянняр: Іудей Падшасы диб жазма, ämмя Ул Ўзе: Мин Іудей Падшасы диб äйтте диб (жаз), дигянняр. 22 Пилатъ жауаб биргян: бер жазгач жаздым инде, дигян. 23 Салдатлар, Іисусны кадаклагач, Анын кейемнярен алыб, дюрткя бюлеб, салдат сайын беряр кисяк айырганнар; хитонъ дигян кейемен дя (алганнар); ул хитонъ тегелмягян икян, ämмя бötönняй суккан икян. 24 Шуңар кюря алар бер берсеня äйткяннар: мыны жыртмыйык, ämмя жирябя салыйык, кемгя теяр; шулай итеб, Жазыуда: кейемняремне ўзляреня айырдылар, öст кейememя жирябя салдылар дигян сюз [1] жиреня килергя тейеш булган. Салдатлар шулай кылганнар.

Зач. 61. 25 Іисуснын качы тöбöндя анасы, анасынын сеңнесе Клеопа Маріясе, аннары Марія Магдалина торганнар. 26 Іисусъ, Ўз анасын, тагы шунда торган сöйöклö öйрянеўчесен кюреб, анасына äйткян: эй äней!

[1] Пс 21:19.

мына бу синең улың, дигян. 27 Аннары өйрянеўчесеня айткян: мына бу синең анаң, дигян. Шул көннян суң ул өйрянеўче аны алыб ўзендя тоткан. 28 Шуннан суң Іисусъ, инде барыда булыб беткянне белеб, Жазыудагы жиреня килсен диб, эчясем киля дигян. 29 Шунда бер сауыт тулы серкя бар икян. Салдатлар болотка серкя сеңдереб, камышка элеб, Анын ауызы катына китергянняр. 30 Іисусъ серкяне татыб карагач, булыб беттеляр дигян дя, башын салындырыб, тынын биргян. 31 Ул көн пятница көн икян; анын артындагы суббота бик зур көн булганга кюря, тянняр суббота көннө качларында калмасыннар диб, іудейляр Пилаттан, аларнын сыйырякларын ыуатыб, ўзлярен (качларыннан) алырга сораганнар. 32 Шуннықтан салдатлар барыб, Іисусъ белян бергя кадакланганнарнын элекегесенен дя, икенчесенен дя сыйырякларын ыуатканнар. 33 Ӓммя Іисусъ катына килгяч, Анын ўлеб беткянен кюреб, сыйырякларын ыуатмаганнар. 34 Тик салдатларнын берсе Анын кабыргалары арасына сөнгө белян чянечкян, шул сяттюк кан белян сыу аккан. 35 Мыны ўзе кюргян кеше таныклады, анын таныклауы чын; ул чынны айткянен белядер, сез ышансын диб (айтя). 36 Бу эш Жазыудагынын: Анын сөяге [1] ыуалмас дигяне жиреня килер өчөн булган. 37 Тагы шулай Жазыунын бютян төшөндя айтеля: сөнгө белян чянечкянгя жалыныб караб торорлар, [2] диб.

Зач. 62. 38 Шуннан суң Аримаөеянен Іосифъ Пилаттан Іисуснын тянен качтан алырга сораган; бу Іосифъ Іудейлярдян куркыб, Іисустан жяшерен өйрянгян икян. Пилатъ анар бойорган. Ул барыб, Іисуснын тянен (качтан) алган. 39 Тагы шулай элгяре Іисусъ катына тönня килеўче Никодимъ да килгян; ул смирна белян алойдан жасаган жöз литра [3] чамасы эйесле май алыб килгян. 40 Алар Іисуснын тянен алыб, эйесле май сöрткян кипеннярга төргянняр, гел іудейлярнен кюмеўе жоласынча кылганнар. 41 Іисусны кадаклаган төштя агач бакчасы бар икян; бакчада беряў дя куйылмаган жаңа кабер булган. 42 Шул кабер жакын булгач, іудейлярнен пятницасы сяятлей, Іисусны шунда куйганнар.

---

[1] Исх 12:46.
[2] Зах 12:10. Пс 21:17-18.
[3] Литра 1 грябянкя чамасы.

20-нче бюлем

Зач. 63. 1 Атнанын элекенче
кӧнӧндя карангы белян, иртюк,
Марія Магдалина кабер жанына
килгян, килгяч, кабер ауызын-
дагы таш аударылыб жатканны
кюргян. 2 Шундук жӧгӧрӧб кай-
тыб, Симонъ Петрга да, Іисуснын
бютян сӧйгян ӧйрянеўчесеня дя
килеб, аларга йӧткян: Ходай-
ны кабердян алыб киткянняр,
Аны кая куйганнарын белмей-
без, дигян. 3 Шул сяттюк Петръ
да, бютян ӧйрянеўче дя чыгыб,
кабер жанына киткянняр. 4 Алар
икесе дя бергя жӧгӧря башла-
ганнар, тик бютян ӧйрянеўче
Петрдан жятряк жӧгӧргян, ул
кабергя алдан килеб житкян. 5
Эйелеб карагач, анда жаткан ки-
пеннярне гня кюргян, ӓммя ка-
бер эченя кермягян. 6 Анын ар-
тыннанук Симонъ Петръ килеб
житкян; ул кабер эченя кереб,
анда жаткан кипеннярне гня
кюргян, тагы шулай 7 Іисуснын
башына чырмаган жаулыгы ки-
пенняр белян бергя тӧгӧл, ӓммя
тӧрӧлгян кӧйӧ бютян тӧштя ӱз
алдына жатканын (кюргян). 8
Аннары кабер жанына алдан ки-
лгян бютян ӧйрянеўче дя кер-
гян; ул кюреўе белян ышанган.
9 Іисусъ ӱлгян жиреннян тере-
леб торасыны алар Жазыудан
әле анӈамыйлар икян. 10 Шун-
нан суӈ ӧйрянеўчеляр ӱзляреня
кайтыб киткянняр.

Зач. 64. 11 Ӓммя Марія ка-
бер жанында жылаб торган.
Жылый торган кӧйӧ ул кабер
эченя эйелгян икян, 12 Анда ак
кейемне ике пяриштя утырган-
ны кюргян, берсе Іисусъ тяне
жаткан урыннын баш очонда,
икенчесе аягы очонда икян. 13
Алар анӈар йӧткянняр: эй катын,
син ник жылыйсын? дигянняр.
Ул аларга йӧткян: Ходайымны
алыб киткянняр, Аны кая куй-
ганнарын белмеймен, дигян. 14
Шуны йӧтеў белян артка боролг-
ган икян, шунда торган Іисусны
кюргян, тик Іисусъ икянне та-
нымаган. 15 Іисусъ анӈар йӧткян:
эй катын, син ник жылыйсын?
кемне эзлейсен? дигян. Марія
бу бакчачыдыр диб уйлаб, анӈар
йӧткян: эй кадерле! Аны син чы-
гарыб куйган булсаӈ, Аны кая
куйганыӈны миӈа йӧтсяня, мин
Аны алыб китяр эйем, дигян. 16
Іисусъ анӈар: эй Марія! дигян.
Марія боролоб, Анӈар йӧткян:
эй Раввуни! дигян. Раввуни
дигяне ӧйрятеўче дейеў. 17 Іи-
сусъ анӈар йӧткян: Миӈа тейен-
мя, Мин әле Атама менмядем
шул; ӓммя син Минем ага-эне-
ляремя кайтыб, аларга йӧт: Мин
Ӱз Атама, сезнен Атагызга, Ӱз

Аллама, сезнен Аллагызга меням, дигян. 18 Марія Магдалина кайтыб, Ходайны кюргянен дя, Ул анар мыны айткянне дя йырянеучелярга белдергян.

Зач. 65. 19 Атнанын шул элекеге конондюк, кич белян, Иисуснын йырянеучеляре бер йидя жыйылышыб, Іудейлярдян куркыб, ишеклярен бикляб утырган чакта, Іисусъ килеб, уртада тороб, аларга айткян: тынычлык сезгя! дигян. 20 Шуны айткяч, Ул аларга кулларын, аякларын, кабыргаларын кюрсяткян. Йырянеучеляр Ходайны кюргяч, сойоношкянняр. 21 Іисусъ аларга икенче табкыр тагы айткян: тынычлык сезгя! Мине Ата жибяргян кюк, Мин дя сезне жибярямен, дигян. 22 Шуны айткяч, ороб, аларга айткян: Святый Тынны алыгыз: 23 Сез кемгя жазыкларын кичерсягез, шунар кичерелер, кемгя кичермей калдырсагыз, шунар кичермей калдырылыр, дигян. 24 Ун икенен берсе, игез дигян Оома, Іисусъ килгян чагында, анда жук икян. 25 Бютян йырянеучеляр анар: без Ходайны кюрдек, дигянняр. Аммя ул аларга айткян: мин Анын кулында кадак жараларын кюрмясям, кадак жараларына бармагымны тейереб, кабыргаларына кулымны тейереб карамасам, ышанмам, дигян. 26 Шуннан сигез кон суң, йырянеучелар тагы бер йидя икян, Оома да алар белян бергя булган. Ишек бикле койо, Іисусъ килеб, урталарында тороб, тынычлык сезгя! дигян. 27 Аннары Оомага айткян: бармагынгны мында китереб, кулларымны караб кара; кулынгны китереб, кабыргаларыма тейереб кара, инде ышанмый торма, аммя ышаныб тор, дигян. 28 Оома Анар жауаб биреб айткян: Ходайым, Аллам! дигян. 29 Іисусъ анар айткян: син Мине кюргяненя кюря ышандын, кюрмягян койо ышаныучылар бахетле, дигян. 30 Іисусъ Уз йырянеучеляре алында да тагы бютян кодрятляр дя кюб кылган, алары бу книгягя жазылмаган. 31 Аммя булары сез Іисуснын Алла Улы Христосъ икяненя ышансын диб, ышаныб, Анын исеме какына терелек алсыннар диб жазылган.

21-нче бюлем

Зач. 66. 1 Терелеб торганнан суң, Іисусъ тагы Уз йырянеучеляреня Тиверіада дингезе жанында кюренгян; кюренеуе булай булган: 2 Симонъ Петръ, аннары игез дигян

Өома, тагы Галилеянын Кана каласынын Наѳанаилъ, Зеведей уллары, тагы бютян ике ӧйрянеўчесе бергя булганнар. 3 Симонъ Петръ аларга äйткян: мин балык тотарга барам, дигян. Алар анґар: без дя синеґ белян барабыз дигянняр. Барыу белян кайыкка кергянняр, ул тӧннӧ бер дя тотмаганнар. 4 Иртя белян Іисусъ жар östöндя тора икян; ӧйрянеўчеляре Анын Іисусъ икянен танымаганнар. 5 Іисусъ аларга äйткян: эй балалар! сезнен бер-бер ашамныгыгыз жук мы? дигян. 6 Алар Анґар: жук, дигянняр. Ул аларга äйткян: ауыгызны кайыкнын уњ жагыннан салыгыз, тотарсыз, дигян. Алар салганнар, балык кюблектян ауны тартыб чыгара алмаганнар. 7 Іисуснын сӧйгян ӧйрянеўчесе шул чакта Петрга äйткян: бу Ходай! дигян. Симонъ Петръ бу Ходай дигянне эшеткяч, ўзе жалангачка кюря, кейемен биленя чырмаб, дингезгя сикергян. 8 Бютян ӧйрянеўчеляр балыклы ауны тартыб, жарга кайык белян килеб туктаганнар. Алар жардан жырак тӧгӧл икян, ике жӧз терсяк буйы чамасы гна икян. 9 Жир östöня чыккач, жаккан утны, ут östöндя пешеб жаткан балыкны, аннары икмяк кюргянняр. 10 Іисусъ аларга äйткян: äле тоткан балыгыгызны китерегез, дигян. 11 Симонъ Петръ барыб, зур балыклар тулган ауны жиргя östöряб чыгарган; балык ней бары жӧз илле öч булган; шул катле кюб булса да ау жыртылмаган. 12 Іисусъ аларга äйткян: килегез, ашагыз, дигян. Ӧйрянеўчелярнен берсе дя, бу Ходай икянне белгянгя кюря, Аннан: Син кем? диб сорарга кыймаганнар. 13 Іисусъ жакын килеб, икмяк белян балыкны алыб, аларга биргян. 14 Бу инде Іисуснын ўлгяненнян терелеб торгач, ӧйрянеўчеляреня ӧчӧнчӧ табкыр кюренеўе.

Зач. 67. 15 Алар ашаганда, Іисусъ Симонъ Петрга äйткян: эй Іона улы Симонъ! син Мине былар сӧйгяннян артык сӧясен ме? дигян. Петръ Анґар äйткян: эйе, эй Ходай, мин Сине сӧйгянне Син белясен, дигян. Іисусъ анґар äйткян: бярняремне кӧт, дигян. 16 (Іисусъ) анґар тагы икенче табкыр äйткян: эй Іона улы Симонъ! син Мине сӧясен ме? дигян. Петръ Анґар äйткян: эйе, эй Ходай, мин Сине сӧйгянне Син белясен, дигян. Іисусъ анґар äйткян: сарыкларымны кӧт, дигян. 17 Тагы ӧчӧнчӧ табкыр анґар äйткян: эй Іона улы Симонъ! син Мине сӧясен ме? дигян. Ӧчӧнчӧ табкыр, син Мине

сöясен ме диб сораганыннан көйönöб, Петръ Анӷар äйткян: эй Ходай! Син барын да белясен, мин Сине сöйгянне дя белясен, дигян. Іисусъ анӷар äйткян: сарыкларымны көт, дигян. 18 Чын, чын синӷа äйтямен: син жяш чагында эзяреӈне ўзеӈ бяйляб, телягян жиреня жöрдöӈ; картайгач, кулларыӈны сузыб торорсон, сине бютян кеше бяйляр дя телямягян жиреня алыб барыр, дигян. 19 Мыны äйтеб, Ул Петрнын ничек ўлем белян ўлеб, Алланы данналдырасын билгерткян. Мыны äйткяч, анӷар: Минем артымнан кил, дигян. 20 Петръ боролоб караган икян, шунда Іисуснын сöйгян öйрянеўчесе, кичке ашта Анын кюкерягеня сыйыныб, эй Ходай! Сине кем тотоб бирер диб сораган öйрянеўченен ўз артыннан килгянен кюргян. 21 Аны кюргяч, Іисуска äйткян: эй Ходай, мыӷар ней булыр? дигян. 22 Іисусъ Петрга äйткян: Мин аны Ўзем килгенче тотасы итсям, анда ней эшеӈ бар? син Минем артымнан кил, дигян. 23 Шуннан туганнар арасында бу öйрянеўче ўлмяс диб сюз жяйелгян. Тик Іисусъ анӷар ул ўлмяс диб äйтмягян, ämмя Мин аны Ўзем килгенче тотасы итсям, синеӈ анда ней эшеӈ бар? дигян. 24 Мыны шул öйрянеўче ўзе таныклаб жазды; анын таныклауы чын икянне белябез. 25 Іисуснын тагы бютян кылган эшляре дя бик кюб, тик алары турысында айырым-айырым жазылган булса, жазган книгялярне бötön дöнья сыйдыра алмас ыйы диб уйлыймын. Аминь.

СВЯТЫЙ АПОСТОЛЛАРНЫН ЭШЛЯРЕ

1-нче бюлем

Зач.1 1 Элекеге княгямдя
мин сина жаздым, эй Феофилъ,
Iисуснын бар кылган эшлярен,
нейгя ӧйряткянен, ин аӱяленнян
башлаб, 2 Ӱзе сайлаб алган апос-
толларына Святый Тын арткылы
бойорок биреб, кюккя кютярел-
гян кӧнӧня чаклы. 3 Ул Ӱз азабла-
рыннан сун, кырык кӧн эченда
аларга кюренеб, Алла падшалыгы
турысында сӧйляб, кюб дӧрӧс
билгеляр белян Ӱзенен тере икя-
нен аларга кюрсяткян. 4 Аннары
Ул, аларны жыйыб, аларга былай
кушкан: Iерусалимнян китмягез,
Миннян эшеткянегезне, Ата бир-
мякче булганны кӧтӧб торогоз; 5
Iоаннъ сыуда чумылдырды, ӓммя
сез, мыннан бераук кӧннян сун,
Святый Тын белян чумылды-
рылырсыз, дигян. 6 Шунныктан
алар, жыйылышкач, Аннан: эй
Ходай, Син ӓлля шушы багытта
Израиль падшалыгын жаңадан
торгозасың мы? диб, сораган-
нар. 7 Ул аларга ӓйткян: Ата Ӱз
иркеня салган багытларны, жыл-
ларны белеӱ сезнен эш тӧгӧл. 8
Сезгя Святый Тын интяч, сез
кыуат алырсыз да Iерусалимдя,
бар Iудеяда, Самаріяда, жир-
нен кырыйларына чаклы Мине
таныкларсыз, дигян. 9 Мыны
ӓйткяч, Ул аларнын кюз алла-
рында кютярелгян, болот Аны
каблаб алыб, аларга кюренмяс
иткян. 10 Ул кютярелгяндя, алар
кюккя таба караб торган чакта,
ак кейемне ике ир кеше алар ал-
дында тороб, 11 Ӓйткянняр: Эй
Галилея кешеляре! Ник сез кюк-
кя караб торасыз? Шушы сез-
дян кюккя кютярелгян Iисусъ,
сез ӓле Анын кюккя кютярелгя-
нен кюргянчя, тагы шулай килер,
дигянняр.

Зач.2 12 Шуннан суң алар Іерусалимгя жакын гна, суббота кӧннӧ жӧрӧля торган жул чаклы гна жирдяге Елеонъ тауыннан Іерусалимгя кайтканнар. 13 Кайткач, бер бюлмягя кереб, шунда торганнар; анда Петръ, Іаковъ, Іоаннъ, Андрей, Филиппъ, Фома, Варфоломей, Матфей, Алфей Іаковы, Симонъ Зилотъ, Іаковъ Іудасы булганнар. 14 Алар бар да катыннар белян, Іисуснын Анасы Марія белян, Анын агалары белян бергя, бер кюнел белян келяў итеб, теляктя торганнар. 15 Шул кӧннярдя Петръ ӧйрянеўчелярнен уртасында тороб, äйткян: 16 (жыйылган кешеляр жӧз жегермеляб бар икян): Эй кадерле туганнар! Іисусны тотоб алыучыларны жӧртӧўче Іуда турысында жазыуда Святый Тын Давидъ арткылы алдан äйткян сюз жиреня килергя тейеш эйе. 17 Ул Іуда безгя кушылган ыйы, бу кызмятнен ӧлӧшӧн алган ыйы. 18 Тик ул дӧрӧссӧзлӧк малына жир алды; ўзе жыгылыб тӧшкяч, корсагы жарылган да бӧтӧн эче агыб беткян. 19 Бу эш Іерусалимдя тороучыларнын барысына да билгеле булды; ул жирне ўз телляренчя Акелдама диб атадылар, кан жире дигян сюз. 20 Псаломнар княгясендя жазылган: Анын жорто буш калсын, анда тороучы да булмасын, анын епископлыгын бютян алсын диб. 21 Ходай Іисусъ безнен белян торган чакта, безнен арада жӧргян чакта, Іоаннъ чумылдырыуыннан башлаб, 22 Ул бездян кюккя кютярелгян кӧнгя чаклы, безнен белян жалан бергя булганнар арасыннан беряў Анын терелеб тороуына безнен белян бергя танык булырга тейеш, дигян. 23 Шунда Варсава диб атала торган, Іустъ диб тя аталган Іосифны, тагы Матфйне икесен куйганнар. 24 Аннары теляк итеб äйткянняр: Эй Ходай, Син буганнарнын да кюнеллярен белеўче, шушы икесенен берсен, Ўзең сайлаганын кюрсят, 25 Іуда ўзе барасы урынга китяр ӧчӧн калдырган шушы кызмятнен, апостоллыкнын ӧлӧшӧн ул алсын, дигянняр. 26 Аларга жирябя салганнар, жирябя Матфйгя чыккан, чыккач, аны ун бер апостолларга кушылдырганнар.

2-нче бюлем

Зач.3 1 Пятидесятница дигян
бяйрям килеб житкяндя, алар ба-
рысы да бер кюнелдя тороб, бер-
гя булганнар. 2 Бик каты дауыл
чыгыб килгян кюк, кинят кюктян
шаулаган ауаз килеб, алар утырган
öйнö бötönняй тутырган. 3 Шун-
да аларга ут кюк айырым телляр
кюренеб, аларнын яр-берсеня бе-
ряр-беряр ингянняр. 4 Барысы да
Святый Тынга тулыланыб, бютян
телляр белян, аларга Тын бел-
дергянчя, сöйляшя башлаганнар.
5 Ул чакта Иерусалимдя иудейляр,
Алладан куркыныб тороучы ке-
шеляр, кюк астындагы яр-бер ка-
лыкнын кешеляре булганнар. 6 Бу
ауаз булгач, калык жыйылышыб,
яр-берсе ўз теленчя аларнын
сöйляшкянен эшетеб, жöдяб
торганнар. 7 Барысы да исляре
китеб, хайран булыб, ўз аралый
яйтешкянняр: Бу сöйляшеўчеляр
бар да Галилея кешеляре тöгöл
ме? 8 Ничек сунг без яр-беребез
тыуганнан бирле сöйляшя торган
телебезне эшетябез? 9 Без Пар-
фяннар, Мидяннар, Еламитлар,
Месопотамияда, Иудеяда, Кап-
падокияда, Понтта, Асияда, 10
Фригияда, Памфилияда, Египет-
та, Киринея жагындагы Ливия-
да тороучылар, Римнан килгян
кешеляр, Иудейляр, алар дененя
жана кергян кешеляр, 11 Критян-
нар, Аравитяннар аларнын без-
нен телляр белян Алланын ола-
логон сöйлягянярен эшетябез,
дигянняр. 12 Барысы да исляре
китеб, жöдяшеб бер-берсеня: Бу
ней хал? диб яйтешкянняр. 13 Кай-
сылары мыскыл итеб яйткянняр:
Алар аракы эчеб исергянняр диб.

Зач.4 14 Шунда Петръ ун
бер апостоллар белян тороб, ау-
азын кютяреб, аларга яйткян: Эй
Иудея кешеляре, эй Иерусалимдя
тороучылар бар да! Бу сезгя би-
лгеле булсын, минем сюзляремя
ан салыгыз. 15 Алар исерек тöгöл,
сез уйлаганча тöгöл, казер кöннön
öчöнчö сагате гня але. 16 Аммя бу
Иоиль пагамбярнен алдан яйткяне
жиреня киля. 17 Ул яйткян: Алла
яйтя: калдык кöннярдя Ўз Ты-
нымнан бар тяннелярга дя дяўлят
агызырмын; улларыгыз, кызла-
рыгыз пагамбярлек итярляр; же-
гетлярегез кюренеў кюря торган
булырлар; картларыгыз тöшляр
кюря торган булырлар. 18 Шул
кöннярдя ир колларыма да, ка-

тын колларыма да Ӱз Тынымнан дяӱлят агызырмын, алар пагамбярлек итярляр. 19 Жугары кюктя кодрятляр, тюбян жирдя билгеляр кюрсятермен, кан да, ут та, тӧтӧн чыгыуны да кюрсятермен. 20 Ходайнын оло, данны кӧнӧ житкенче, кояш карангыга, ай канга алмашыр. 21 Былай булыр: Ходай исеменя сыйыныучы ӓркем котолор, дигян.

Зач.5 22 Шул кӧннярдя Петръ калыкка ӓйткян: Эй Израиль кешеляре! Бу сюзлярне тынӈаб алыгыз, сез ӱзегез дя белясез: Назорей Иисусны, Анын артқылы сезнен арада кюрсяткян қыуатлары, кодрятляре, билгеляре белян Алла Ӱзе сезгя таныклаган кешене. 23 Шул Иисусны Алла Ӱзенен элгяртен куйылган киняше буйынча, алдан белгянечя, сезгя бирергя ирек итте, сез аны тотоб алыб, законсызланыучылар куллары белян кадаклаб ӱтердегез; 24 Тик Алла, ӱлемнен быгауын уатыб, Аны тергезеб торгоздо, ӱлемнен Аны туктатыб тороргa қыуаты житмягян шул. 25 Анын турысында Давидъ ӓйтя: Ходайны жалан алдымда кюрдем, мин каушамаска Ул минем унг жагымда шул. 26 Шунныктан кюӈелем қыуанды, телем дя сӧйӧндӧ; тянем дя ӧмӧт белян жиргя керер. 27 Син жанымны тамукка калдырмассыӈ шул, изгеня череӱ тейермяссеӈ. 28 Миӈа терелек жулларын белдерденӈ, ачык жӧзӧннян мине сӧйӧнӧчкя тулыландырырсыӈ дей. 29 Эй кадерле туганнар! Тӧб ата Давидъ турысында сезгя кыйыуланыб ӓйтергя роксят итегез: ул ӱлгян дя кюмелгян, анын кабере бу кӧнгя чаклы безнен арада. 30 Ул пагамбяр булганныгыннан, Алла аӈар анын няселеннян Христосны тянняндереб чыгартыб, Аны анын престолына утыртырым диб ӓйткянне белеб, 31 Ул Христоснын терелеб тороуы турысында алдан ӓйткян: Анын жаны тамукта калмас, тяне дя череӱне кюрмяс диб. 32 Шушы Иисусны Алла тергезеб торгоздо, мыӈар без барыбыз да таныкчылар. 33 Шулай итеб, Ул Алла қыуаты белян кюккя кютярелеб, Святый Тын бирелясе багадяне Атадан алыб, сез ӓле кюря торганны, эшетя торганны агылдырды. 34 Давидъ кюккя кютярелмяся дя ӱзе ӓйтя: Ходай минем Ходайыма ӓйткян: Минем уӈ жагыма утыр, 35 Мин дошманнарыӈны аягыӈ астына салгынчы

диб. 36 Инде Алла ирке буйынча, шушы сез кадаклаган Іисуснын Ходай да, Христосъ та икянен бётён Израилнен жорто ныкбелсен, дигян. 37 Мыны эшеткяч, аларнын кюнелляре жомошаган, алар Петрга да бютян апостолларга да айткянняр: Эй кадерле туганнар! Без ней эшлейек сун? дигянняр.

Зач.6 38 Петръ аларга айткян: Тяубя итегез, ар-берегез жазыклары кичелер очён, Іисусъ Христосъ исеменя чумылдырылсын; шунда Святый Тыннын дяулятен алырсыз. 39 Багадя сезгя, сезнен балаларыгызга, тагы Ходай Аллабыз чакырасы жырактагыларнын барысына да бирелгян шул. 40 Бютян кюб сюзляр белян дя таныклаб, ул былай диб угетлягян: Бу бозок тыумадан сакланыгыз, дигян. 41 Анын сюзен кюнелдян кабыл алганнары шунда чумылдырылганнар, ул коннё оч менгя жакын жан Христосъ жыйынына кушылганнар.

42 Алар жалан апостоллар ойряткянне тыннаб, бер киняштя булыб, икмяк сындырыуны кылыб, теляк итеб торганнар. 43 Яр-бер жан куркыныб торган; апостоллар Іерусалимдя кюб кодрятляр, билгеляр кылганнар. 44 Барысы да бик куркыныб торган ышаныучылар бар да бергя булыб, бар нястялярен дя бергя тотканнар. 45 Малларын, бар нястялярен сатыб, ар-берсенен кирягенчя, барысына да ояшеб торганнар. 46 Кён сайын чиркяудя бер уйда торганнар, ойлярендя икмяк сындырыб, сойёнёч белян, таза кюнел белян ашаб-эчеб, 47 Алланы мактаб, бётён калыкка сойкёмнё булыб торганнар. Ходай сакланыучыларны кён сайын жыйынга кушылдырган.

3-нче бюлем

Зач.7 1 Петръ белян Іоаннъ тугызынчы сагаттяге теляк багытында бергя чиркяугя барганнар. 2 Шунда беряу анаданук аксак тыуган кеше булган; аны кютяреб китереб, кён сайын чиркяунен ин эямне дигян ишеге тёбёня, чиркяугя кереучелярдян садака сораргa утырталар икян. 3 Ул, Петръ белян Іоаннын чиркяугя керергя килгяннярен кюреб, алардан садака сораган. 4 Петръ Іоаннъ белян анар тегяляб караб, айткян: Безгя карале, дигян.

5 Алардан бер-бер нястя алырга
ӧмӧт итеб, ул аларга тегяляб ка-
раган. 6 Петръ ӓйткян: Минем
кӧмӧшӧм, алтыным жук, алай да
нейем бар, сина шуны бирейем:
Назорей Іисусъ Христосъ исеме-
ня тор да жӧр, дигян. 7 Ун кулын-
нан тоткан да аны торгозган; шул
сяттюк анын табаннары да, тез-
ляре дя ныгайганнар. 8 Ул сикереб
тороб, жӧрӧӈ башлаган, Алланы
мактаб, сикеря-сикеря килеб,
алар белян чиркяӱгя кергян. 9 Бар
калык анын жӧргянен, Алланы
мактаганын кюргян; 10 Чиркяӱнен
ин эямне ишеге тӧбӧндя сораныб
утырыучы ул икянне белгянняр;
анар булган эшкя исляре китеб
куркыб торганнар.

Зач.8 11 Тӧзялгян аксак Пет-
ръ белян Іоаннь катыннан китмей
торганга кюря, бӧтӧн калык исе
китеб, чиркяӱнен Соломонныкы
дейелгян ал бюлмясеня жӧгӧрӧб
килгян. 12 Мыны кюреб, Пет-
ръ калыкка ӓйткян: Эй Израиль
кешеляре! Мынар нейгя исегез
китя, ник безне ӱз кыуатыбыз бе-
лян, жя арыулыгыбыз белян, аны
жӧрӧӈ торган иткянгя куйыб, без-
гя караб торасыз? 13 Авраамнын,
Исаакнын, Іаковнын Алласы,
аталарыбызнын Алласы Ӱз Улы
Іисусны данналдырды; сез Аны
тотоб бирдегез, Пилатъ Аны
жибярмякче булыб торганда, сез
Пилатнын кюзе алдында Аны
тандыгыз. 14 Сез Изгене, Гаделне
танъыб, безгя кеше ӱтереӱчене
бир диб тордогоз. 15 Аммя терелек
Башлыгын ӱтерттегез; Шушы-
ны Алла ӱлгяненнян терегезеб
торгоздо, мынар без таныкчы. 16
Анын исеменя ышаныу буйынча,
шушы сез кюря торганны, беля
торганны Анын исеме ныкланды-
рды, Аннан бирелгян ышаныу
сезнен барыгызнын алдыгызда
анар шушы тӧзялеӱне бирде. 17
Алай да, туганнар, сез дя, баш-
лыкларыгыз да мыны белмягян-
нектян кылганны мин белямен. 18
Алла Ӱзенен бар пагамбярляре-
нен ауызыннан Христосъ азабла-
насы диб алдан ӓйткяненчя.

Зач.9 19 Алай булгач, жа-
зыкларыгыздан тазарыр ӧчӧн,
ӱкенегез, Ходайга кайтыгыз, 20
Ходайдан сӧйӧнӧч багытлар ки-
леб житсен эйе, Ул сезгя элекген
билгертелгян Іисусъ Христосны
жибярсен эйе; 21 Алла Ӱзенен
бар изге пагамбярляренен ауы-
зыннан мянгедянюк ӓйткяненен
булыр багыты житкенче, Аны
кюк ӱзеня алыб тороргa тейеш

булган. 22 Моисей аталарга
äйткян: Ходай Аллагыз туган-
нарыгыз арасыннан сезгя минем
кюк Пагамбяр чыгарыр, Ул сез-
гя ней сöйляся дя, бар турыда да
Аны тынӈагыз. 23Ул Пагамбярне
тынӈамаган äр-бер жан калык
арасыннан жукка чыгарылыр,
дигян. 24 Самуилдан башлаб, ан-
нан сунгы сöйлягян пагамбярляр
барысы да шушы көннярне ал-
дан белгерткянняр. 25 Сез пагам-
бярлярнен уллары, Алланын Ав-
раамга: синеӈ няселеӈ арткылы
жирдяге бар калыклар да изгелек
табарлар диб äйтеб, аталарыбыз-
га биргян багадясенен уллары
сез. 26 Алла Ӱз Улы Iисусны тер-
гезеб, сезнен äр-берегезне бар
усал эшегездян тыйылдырыр
öчöн, Аны иӈ элеке сезгя изге-
лек итярга жибяргян.

4-нче бюлем

Зач.10 1 Алар калыкка сöй-
лягян чагында, священникляр дя,
чиркяӱне саклаучыларнын баш-
лыгы да, саддукейляр дя алар
катына килгянняр; 2 Алар калык-
ны öйряткянгя, ӱлгянняр тере-
леб торасын Iисустан кюрсятеб
сöйлягянгя, ачыулары килеб тор-
ганнар. 3 Аларны куллары белян
тотоб, кич булганга кюря, иртягя
чаклы карауылга жибяргянняр.
4 Сöйлягянне тынӈаучыларнын
кюбесе ышанганнар; Шундый
кешелярнен исябе биш меннӈяб
булган. 5 Иртягесен Iерусалимдя
iудейлярнен тюряляре, башлы-
клары, княгячеляре жыйылган-
нар, 6 Анна архiерей дя, Каiафа
да, Александръ да, архiерейляр
тыумасыннан бютянняр дя бул-
ганнар. 7 Апостолларны уртага
куйыб, сораганнар: Сез мыны
нейдей кыуат белян, жя нейдей
исем белян кылдыгыз? дигян-
няр. 8 Шул чакта Петръ, Святый
Тынга тулыланыб, аларга äйткян:
Эй калык тюряляре, Израилнен
башлыклары! 9 Äгяр чирле кеше-
гя жакшылык кылганга, ул ничек
тöзялде диб, бöгöн бездян жауаб
соройсоз икян, 10 сезнен барыгыз-
га, Израилнен бар калыгына да
билгеле булсын: сез кадаклаган,
äммя Алла ӱлгяненнян терелтеб
торгозган Назорей Iисусъ Хрис-
тоснын исеме белян бу кеше сез-
нен алда сау булыб тора. 11 Ул Iи-
сусъ, сез торгозоучылар жарамас
кюреб ташласагыз да, почмак ас-
тына нигез булган таш; бютян ич-

кем арткылы котолоу жук. 12 Без котолор өчөн кешелярга бирелгян бютян исем жук кюк астында, дигян.

Зач.11 13 Петръ белян Іоаннын кыйыулыгын кюреб, алар укымышлар төгөл, простой кешеляр икянне кюреб, исляре китеб торганнар; аларнын Іисусъ белян бергя жөргяннярен дя белгянняр. 14 Алар белян бергя торган төзялгян кешене кюреб, карышы сюз бер дя әйтя алмаганнар. 15 Аларга синедріоннан чыгыб китярга кушыб, ўз араларында сюзгя килеб, 16 әйткяннар: Бу кешелярга ней кылыйык? Аларнын айырмачык кодрят кылганнары Іерусалимдя тороучыларнын барысына да билгеле, без аны тана алмыйбыз. 17 Алай булгач, мыннан былай бу эш калык арасында жяйелмясен диб, аларга, бу исем турысында, бер кешегя дя сөйлямяскя куркытыб кисятейек, дигянняр. 18 Аларны чакырыб алыб, аларга Іисусъ исеме турысында ич тя сөйлярга дя, өйрятергя дя кушмаганнар. 19 Петръ белян Іоаннъ аларга жауаб биреб әйткянняр: Исябляб карагыз, Алла карышысында Алладан бигеряк сезне тынлау дөрөс ме? 20 Кюргянебезне, эшеткянебезне безнен сөйлямей әлебез жук, дигянняр. 21 Калык булганга кюря, шушы эш булыу сяятлей барысы да Алланы даннаган буйынча, аларга кыйын тейерер әлляре булмагач, аларны куркытыб жибяргянняр. 22 Бу кодрят белян төзялгян кеше кырык жяштян дя узган икян.

Зач.12 23 Аннан китеб, алар ўзляренекеляр катына кайтыб, аларга архіерейляр, башлыклар ней әйткянне сөйляшкянняр. 24 Алар тынлаб алыб, бер кюнел белян ауаз кютяреб, Аллага әйткянняр: Эй кюкне, жирне, дингезне, аларда ней бар барын да булдырыучы, буганнарны Тотоучы Алла! 25 Син Святый Тын белян ўз мяндяң, безнен атабыз Давидъ ауызыннан әйткян: Калыклар нейгя короштолар, калыклар ник булмасны уйлаштылар? 26 Жир падшалары алга чыгыб, князляре бергя жыйылыб, Ходайга да, Анын Христосына да карышы тордолар, диб. 27 Чыннаб бу калада Син майлаган, Синең изге Улың Іисуска карышы Иродъ та, Понтій Пилатъ та, жалган деннеляр белян, Израиль калыгы белян жыйылдылар. 28 Синең кулың, Синең киняшең алдан куйганны жиреня китере-

ргя диб. 29-30 Äле дя, эй Ходай, аларнын безне жаныуларына кюз сал, Ўзеннен изге Улыҥ Iисуснын исеме белян кодрятляр, билгеляр кыларга, чирлелярне тöзятергя Ўз кулынны сузган чагында, äле без мяндяляреня Ўз сюзенне ныкъ кыйыулык белян сöйлят. 31 Алар теляк иткяннян суҥ, алар жыйылган урын селкенеб киткян, барысы да Святый Тынга тулыланыб, Алла сюзен кыйыулык белян сöйлягянняр.

32 Ышаныучыларнын барысынын да бер кюнел, бер уй булган; беряў дя ўз малын бу минеке диб äйтмягян, äммя аларнын бар нястяляре бергя булган. 33 Ходай Iисусъ Христоснын терелеб торганын апостоллар зур кыуат белян таныклаганнар: аларнын барысында да оло дяўлят торган. 34 Алар арасында жöдяў кеше беряў дя булмаган: жире, жя öйö булганы барысы да, аларны сатыб, сатылган бяясен алыб килеб, 35 апостолларнын аяклары катына салганнар; кем нейгя жöдяў, анар шуны биргянняр. 36 Кипрда туган левитъ, апостоллар Варнава диб атаган Iосія да шулай иткян, Варнава дигяне - тынычлык улы дейеў; 37 Анын ўз жире бар икян, шуны сатыб, акчасын апостолларнын аяклары катына китереб салган.

5-нче бюлем

Зач.13 1 Ананія исемне бер кеше, ўз катыны Сапфира белян малын сатыб, 2 катыны белян бергяляшеб, саткан бяясен ким äйтеб, бер ауыгын гна китереб, апостолларнын аягы астына салган. 3 Шунда Петръ äйткян: Эй Ананія, син жир бяянне жяшереб, Святый Тынга жалганнарга, ўз кюнеленя шайтанга ник уй салдырттын? 4 Ўз кулындагы мал ўзеннеке тöгöл эйе меней? Мыны ней öчöн кюнеленя салдын? Син кешелярга тöгöл, äммя Аллага жалганнадыҥ, дигян. 5 Бу сюзлярне эштеккяч, Ананія тынсыз булыб жыгылган; мыны эшетеўчелярнен барысына да бик зур куркыныч тöшкян. 6 Жяшляр тороб, аны кюмярга äзерляб, чыгарыб кюмгянняр. 7 Мынар öч сагат ўткяч, ней булганны белмейче, катыны килеб кергян. 8 Петръ аннан сораган: Äйтче мина, жирегезне шушы катлегя саттыгыз мы? дигян. Ул äйткян: Эйе, шушы

катлегя, дигян. 9 Ӓммя Петръ анӑр ӓйткян: Сез ник алаӥ Ходайнын Тынын сынарга кюнештегез? Мына синең иренне кюмеӱчеляр ишектян кереб киляляр, сине дя алыб чыгарлар, дигян. 10 Кинят ул Петръ аягы жанына жыгылыб китеб, тынын чыгарган. Жяшляр кергяч, анын да ӱлеб жатканына таб булыб, аны ире жанына кюмгянняр. 11 Бӧтӧн жыйынга, мыны эшеткяннярнен барысына да зур куркыныч тӧшкян.

Зач.14 12 Апостолларнын куллары белян калык арасында кюб билгеляр, кодрятляр кылынган; бар да бер уйда булыб, чиркяӱнен Соломонныкы дигян ал бюлмясендя жыйылыб торганнар. 13 Чит кешелярдян алар жанына килеб тороргa беряӱ дя кыймаган, ӓммя калык аларны даннаган. 14 Ышаныучылар отородан оторо, кюб ирляр дя, катыннар да Ходайга кушылганнар. 15 Ышаныулык шул катле булган, чирлелярне дя тюшякляре белян, карауатлары белян урамнарга чыгарыб куйганнар, ичмаса ӱтеб барганда гна булсада, Петрнын кюляткясе аларнын берсеня-берсеня тӧшсӧн диб. 16 Шулаӥ кюбесе ӓйляня тирядяге калалардан Ierусалимгя жыйылышканнар, чирлелярне дя, шакшы тын азаблыӥ торганнарны да алыб килгянняр, алар барысы да тӧзялгянняр. 17 Архiерейнен дя, анын белян бергя саддукейляр ересеня катышканнарнын да бик кӧнчӧлӧкляре килеб, 18 апостолларны куллары белян тотоб, аларны калык ӧтӧрмяненя жабканнар. 19 Ӓммя Ходаӥ пяриштясе тӧння ӧтӧрмяннен ишеклярен ачыб, аларны чыгарыб, ӓйткян: 20 Барыгыз, чиркяӱдя тороб, шушы терелек сюзлярен барысын да калыкка сӧйлягез, дигян.

Зач.15 21 Алар тынӊаб бетереб, иртя белян чиркяӱгя кереб ӧйряткянняр. Шул арада архiерей дя, анын белян бергя булганнар да килеб, синедріонны, Израиль уларынын бар башлыкларын чакырыб китергянняр дя, апостолларны алыб килергя ӧтӧрмянгя кешеляр жибяргянняр. 22 Кызмятчеляре килеб, аларны ӧтӧрмяндя табмаганнар; кире кайтыб былаӥ диб ӓйткянняр: 23 Без ӧтӧрмянне бик нык биклягян кӧйӧ, карауылчылары ишек тӧбӧндя торган кӧйӧ очораттык, ӓммя ачкач, эчендя беряӱне дя табмадык, дигянняр. 24 Архiерей дя, чиркяӱне саклаучыларнын баш-

лыгы да, баш священникляр дя, бу сюзлярне эшеткяч, бу неӥ хал икян диб торганнар. 25 Беряӱ килгян дя аларга былаӥ диб житкергян: Мына сез ӧтӧрмянгя жабкан кешеляр чиркяӱдя тороб, калыкны ӧйрятяляр, дигян. 26 Шунда карауылчылар башлыгы кызмятчеляр белян барыб ӱзлярен калык таш атыб ӱтермясен диб курыкканныктан, апостолларны ирексезлямейчен гня алыб килгянняр. 27 Аларны китереб, синедріонъ алдына куйганнар; шунда архіерей алардан былаӥ диб сораган: 28 Бу исем турысында ӧйрятмягез диб без сезгя нык кисяттек тӧгӧл меӡ Мына сез ӧйрятеӱегез белян Іерусалимне тутырдыгыз, ул кешенен канын безнен ӧскя тӧшӧрӧргя келейсез, дигян. 29 Петръ да, бютян апостоллар да жауаб биреб äйткянняр: Кешелярдян бигеряк Аллага баш салырга тейеш. 30 Аталарыбызнын Алласы сез агачка кадаклаб ӱтергян Іисусны терелтеб торгоздо. 31 Алла Ӱзенен кыуаты белян Аны зурлаб, Израилгя тяӱбя итеӱ, жазыклар кичелеӱ бирергя диб, Коткарыучы да, Башлык та итеб куйды. 32 Бу турыда анар таныкчы без, тагы Алла Ӱзеня баш салыучыларга биргян Святый Тын, дигянняр. 33 Мыны эшеткяч, алар ачыуларыннан жарсыб, аларны ӱтерергя киняш иткянняр. 34 Шунда синедріонда беряӱ, законга ӧйрятеӱче, бар калык жарата торган, Гамаліилъ атлы фарисей тороб, апостолларны бер азга чыгарыб тороргa кушкан да, 35 Тегелярга äйткян: Эй Израиль кешеляре! Ӱз арагызда бу кешеляр турысындя, аларга неӥ кылганыгызны уйлаб карагыз äле. 36 Мыннан элгяре кюбтян тӧгӧл гня беряӱ Февда ӱзен ӱзе ялля нейдей оло кешегя куйыб торган ыйы, анар дюрт жӧзляб кеше дя эяргян эйе, тик аны ӱтерделяр, аннары аны тынаучылар барысы да таралыб беттеляр. 37 Аннан сунг ревизия багытында Галилея кешесе Іуда чыккан ыйы, ӱзеня байтак калык эйярткян эйе, ämмя ул да бетте, аны тынаучылар барысыда таралыштылар. 38 Äле дя сезгя äйтямен: бу кешеляр катыннан китегез, аларга теймягез; äгяр бу исяб, жя бу эш кешедян булса, ул ӱзюк бетяр; 39 äгяр дя Алладан булса, сез аны бетеря алмассыз; сак булыгыз, ӱзегез Аллага карышылык итеӱче булыб калмагыз, дигян. 40 Алар аны тынна-

ганнар; апостолларны чакырыб алыб, кыйнаганнар да, аларга Іисуснын исеме турысында сöйлямяскя кушыб, аларны жибяргянняр. 41 Ходай Іисуснын исеме какына кадерсез ителергя тейешле булганнарына сöйönöшöб, алар синедріоннан чыгыб киткянняр. 42 Кöн сайын чиркяўдя дя, öйлярдя дя Іисусъ Христосъ турысында туктамыйчы öйрятеб изге хабяр сöйляб жöргянняр.

6-нчы бюлем

Зач.16 1 Бу кöннярдя, öйрянеўчеляр кюбяйгяч, еллинистлар еврейлярга зарланганнар, кöн сайын кирякле нястяне öляшкяндя, безнен тол катыннарыбызны кимсетясез диб. 2 Шунда ун ике апостолъ, кюб öйрянеўчелярне жыйыб äйткянняр: Алла сюзен калдырыб, ашамнык öляшеў кызмятендя тороу безгя арыу тöгöл. 3 Алай булгач, туганнар, ўз арагыздан сынаган, белгян кешелярегезне, Святый Тынга, белемнеккя тулыларны, жиде кеше сайлагыз, бу кызмяткя аларны куярбыз. 4 Ämмя без жалан теляк итеўдя, сöйляў кызмятендя торорбыз, дигянняр. 5 Былай äйтеў бöтöн жыйынга ошаган: Святый Тынга тулы, нык ышаныучы кеше Стефанны, Филиппны, Прохорны, Никанорны, Тимонны, Парменны, Антіохіянын жалган деннелярдян кушылган Николайны да сайлаганнар; 6 аларны апостолларнын алдына куйганнар, апостоллар теляк итеб, алар öстöня кулларын салганнар. 7 Алла сюзе ўскян, öйрянеўчеляр дя Іерусалимдя бик кюбяйгянняр; іудей священникляренен дя бик кюбесе денгя баш салганнар.

Зач.17 8 Ышаныуга да, кыуатка да тулы Стефанъ калык арасында бик оло кодрятляр, билгеляр кылган. 9 Либертиннар, Киріниянықылар, Александріянықылар синагогасы дейелгян синагогадан кайсылары килеб, тагы Киликія белян Асія жиреннян килгянняренен кайсылары, 10 Стефанъ белян сюзгя киля башлаганнар, тик белемнелегеня, анын арткылы сöйлягян Тынга да карышы тора алмаганнар. 11 Ул чакта алар кайсыларын: ул Моисейгя дя, Аллага да курлык сюзляр äйткянне эшеттек диб äйтергя öйряткянняр. 12 Калык-

ны, башлыкларны, княгячелярне котортканнар да, Стефанга жабышыб, аны синедріонга алыб киткянняр. 13 Жалган таныкчыларны китереб куйганнар, булар äйткянняр: Бу кеше шушы арыу урынга да, законга да туктамый курлык сюзляр äйтя, диб; 14 Назорей Iисусъ бу урынны жимереб бетерер, безгя Моисейдян калган жолаларны ўнгяртер диб сöйляшкянне эшеттек, дигянняр. 15 Синедріонда утырыучылар барысы да Стефанга караб, анын жöзö пяриштя жöзö кюк булыб торганны кюргянняр.

7-нче бюлем

1 Шул чакта архіерей äйткян: Шушлай мы бу? дигян. 2 Стефанъ äйткян: Эй кадерле туганнар, эй аталар! тынгагыз äле. Даннаулы Алла, атабыз Авраамга, Харрангa кючкенче, Месопотаміяда, 3 äйткян: Ўз жиренънян, ўз няселенънян, атанг жортоннан чык та, Мин синя кюрсятясе жиргя бар, дигян. 4 Шуннан суң, ул Халдея жиренънян чыгыб, Харранда урыннашкан; атасы ўлгяннян суң, Алла аны аннан шушы äле сез тора торган жиргя кючергян. 5 Анар бу жирдя аяк табаны чаклы да ölöш бирмягян, ämмя ул баласыз чагындук, ул жирне анар, аннан суң буласы няселгя бирмякче булган. 6 Алла анар тагы äйткян: Синең няселең чит жиргя кючеб торор, анда дюрт жöз жыллаб коллокта, кысанныкта торор. 7 Ämмя Мин аларны коллокта тотасы калыкка хокöм итярмен; шуннан суң алар аннан чыгыб, бу урында Мина кызмят итярляр, дигян. 8 Шуннан суң ул, Исаакны тыудыргач, сигезенче könnö анар киселеў жоласын куйган. Ämмя Исаакъ Iаковны тыудырган, Iаковъ ун ике патріархларны тыудырган. 9 Iатріархлар кönчölök белян Iосифны Египеткя сатканнар, ämмя Алла анын белян булган. 10 Аны бар кайгыларыннан коткарган, анар белемнек биргян, аны Египетъ падшасы Фараонга жараулы иткян, Фараонъ аны Египеткя, ўзенен бар жортона башлык итеб куйган. 11 Аннары бöтön Египетъ жирендя, Ханаанъ жирендя дя ачлык булган, бик зур кайгы тöшкян, аталарыбыз ашамнык таба алмаганнар. 12 Iаковъ Египеття ашлык барын эшетеб, шунда аталарыбызны элеке таб-

кыр жибяргян. 13 Алар икенче табкыр баргач, Іосифъ агаларына ўзен таныткан, аннары Іосифъ рыуы Фараонга билгеле булган. 14 Іосифъ жибяреб, атасы Іаковны, ўзенен бар рыуын, житмеш биш жанны чакырыб алган. 15 Іаковъ Египеткя кючкян, анда ўзе дя, аталарыбыз да ўлгянняр.

16 Аларны Сихемга итеб, анда Авраамъ Сихемъ Емморынын оланнарыннан кömöш биреб алган каберга куйганнар. 17 Алланын Авраамга ант итеб биргян багадясенен жиреня килер багыты житя башлагач, калык Египеття ўрчеб, бик кюбяйгян. 18 Іосифны белмей торган бютян падша куйылгынчы шулай булган. 19 Ул падша безнен няселгя карышы жаман хайля тöзöб, аталарыбызны кыскан, балалары тере калмасыннар диб, аларны ташлаткан. 20 Шул багытта Моисей тыуган, ул Алла алдында жараулы булган. Ул атасы жортонда öч ай асралган. 21 Ämмя ташлангач, аны Фараонъ кызы алыб, ўз улы кюк итеб, ўзендя асраган. 22 Моисейне Египеттяге бар белемнеккя öйряткянняр, ул сюзгя дя, эшкя дя кыуатлы булган. 23 Кырык жяше тулгач, анын кюнеленя ўз туганнарын, Израиль оланнарын барыб кюреpгя уй тöшкян. 24 Аларнын берсе кыйырсытылганны кюреб, аны жаклаб, анын öчöн ўч кайтарыб, Египетъ кешесен ўтергян. 25 Алла анын кулы арткылы аларга котолоу биргянне туганнары аннарлар диб уйлаган икян, ämмя алар аннамаганнар. 26 Икенче кöннö аларнын кайсылары сугышкан чагында, ул килеб, аларны татыуландырырга димняб, äйткян: Эй кадерлеляр, сез бер тыуганнар ич, ник бер-берегезне кыйырсытасыз? дигян. 27 Жакынын кыйырсытыучы аны тöртöб жибяреб äйткян: Сине безгя башлык итеб, хокömче итеб кем куйды? 28 Княген Египетъ кешесен ўтергян кюк, ялля синең мине дя ўтерясең киля ме? дигян. 29 Моисей бу сюзлярне эшетеб, качыб киткян, китеб Мадіамъ жирендя читтян килеб тороучы булган; анда аннан ике ул тыуган. 30 Кырык жыл тулганнан сунг, Синай тауынын буш кырында анар жана торган чянечкеле кыуак жалкыны эчендя Ходай пяриштясе кюренгян. 31 Моисей мыны кюреб, кюргяненя исе киткян; айырмачык кюрейем диб, жакын килгяч, анар Ходайдан тауыш булган: 32 Мин синең

аталарынӈын Алласы, Авраамъ Алласы, Исаакъ Алласы, Іаковъ Алласы, дигян. Моисей куркыб калтраганныктан карарга да кыймаган. 33 Ходай анар äйткян: Аякларына кейгян нястяӈне сал, син тора торган урын арыу жир шул. 34 Мин калыгымнын Египеття кысанныкта торганын кюрямен, аларнын тилмергянен эшетямен, аларны коткарыйым диб тöштöм, инде айса бар, Мин сине Египетка жибярямен, дигян. 35 Шушы, сине безгя башлык итеб, хокöмче итеб кем куйды? диб алар кабыл кюрмягян Моисейне, чянечкеле кыуак эчендя кюренгян пяриштя арткылы Алла башлык итеб, коткарыучы итеб жибяргян. 36 Ул Египетъ жирендя дя, Кызыл дингездя дя, кырык жыл эчендя буш кырда да кодрятляр, билгеляр кылыб, аларны алыб чыккан.

37 Шушы Моисей Израиль оланнарына äйткян: Ходай Аллагыз сезгя туганнарыгыз арасыннан минем кюк Пагамбяр чыгарыр, Аны тыӈнагыз, дигян. 38 Синай тауы öстöндя äйтеб торган пяриштя белян бергя буш кырда, жыйын калык эчендя аталарыбыз белян тороучы Моисей ӳзе шушы, безгя äйтеб бирер öчöн, тере сюзлярне алыучы ул. 39 Аталарыбызнын аны тыӈнасылары килмягян, äммя аннан боролоб, кюӈелляpен Египеткя таба ауышстырыб, 40 Ааронга äйткянняр: Безгя аллалар жасаб бирче, алар безнен алдан барсыннар ыйы, безне Египеттян алыб чыккан Моисейгя ней булганын без белмейбез шул, дигянняр.

41 Шул кöннярдя бызау жасаб, сынга корман китереб, ӳз кулларынын эше алдында кыуанышканнар. 42 Алла алардан боролган, аларны кюктяге чиреӳлярга кызмят итярга калдырган, бу турда пагамбяр книгясендя жазылган: Эй Израиль жорто! Кырык жыл эчендя буш кырда сез Мина чалыб корман китердегез ме? 43 Молохнын чатырын, Ремфанъ дигян аллагызнын жондозон алдыгыз, аларга табынырга диб, сез аларнын сыннарын жасадыгыз. Мин сезне Вавилоннан да арырак кючермен диб. 44 Буш кырда аталарыбызнын келяӳ чатыры булган, Моисей белян Сöйлянеӳче аны Моисей ӳзе кюргянгя ошаулы итеб торгозорга кушкан. 45 Аны аталарыбыз Іисусъ Навивъ белян Алла аларнын жöзö алдыннан кыуган

калыклар жиреня алыб килгянняр. 46 Давидъ кöнняреня чаклы шул кöйö торган. Давидъ Алла карышысында изгелек табкан, 47 Іаковъ Алласына жир табарга бик телягян. 48 Соломонъ Аллага келяў öйö торгозган. 49 Ämмя Жугарыдагы кул белян торгозмаган келяў öйляpендя тора, пагамбяр äйткянчя: Кюк Минем престолым, жир Минем аяк астым дигянчя. 50 Ходай äйтя: Мина ничек öй, жя Минем тынычлыгыма нейдей урын торгозорсоз? Быларнын барысын да Минем кулым булдырды тöгöл ме? дей.

51 Эй каты муйыннылар, карышы кюнелле, тыннаусыз колаклы кешеляр! Аталарыгыз кюк сез дя Святый Тынга карышылык итясез. 52 Аталарыгыз пагамбярлярнен кайсын кыумадылар? Алар Изгенен килясен алдан äйтеўчелярне ўтерделяр, ämмя сез казер Аны тотоб биреўчеляр, ўтереўчеляр булдыгыз. 53 Сез пяриштяляр арткылы законъ алыб, аны сакламадыгыз, дигян. 54 Мыны эшетеб, алар жöрякляре белян жарсыб, анар тешлярен шыкырдатканнар. 55 Стефанъ Святый Тынга тулыланыб, кюккя таба караб, Алланын данын, аннары Алланын унг жагында тороучы Iисусны кюреб, äйткян: Мына, мин ачылган кюклярне, 56 Алланын унг жагында тороучы Адям Улын кюрямен, дигян. 57 Ämмя алар каты ауаз белян кычкырышыб, колакларын тыгыб, бергяляшеб анар жабышканнар. 58 Аннары каланын тыш жагына алыб чыгыб, аны ташлар белян атыб ўтеря башлаганнар. Таныкчылар ўз кейемнярен Савлъ атлы жегетнен аягы астына салганнар. 59 Стефанны таш атыб ўтерергя тотонганнар, ämмя ул теляк итеб äйткян: Эй Ходай Iисусъ, минем тынымны ал, дигян. 60 Аннары тезлянеб, каты ауаз белян кычкырган: Эй Ходай! Бу жазыкны аларга айыбка куйма, дигян. Шуны äйткяч, ул ўлеб тынычланган.

8-нче бюлем

1 Савлъ Стефаннын ўтерелеўен жаратыб торган. Шул кöннярдя Iерусалимдяге жыйынны бик каты кысканнар: апостоллардан бютянняре барысы да Iудеянын, Самаріянын тöрлö жакларына таралышканнар. 2 Алладан куркыучы кешеляр Стефанны

кюмгянняр, анын өчӧн бик жылашканнар.

3 Ӓммя Савлъ ышаныучыларны ӧйӏяреня кереб, ирлярен дя, катыннарын да өстӧряб китереб, ӧтӧрмянгя биреб интектергян. 4 Таралышканнары шул арада изге сюзне сӧйӏяб жӧргянняр.

Зач.18 5 Шулай Филиппь Самарія каласына килеб, андагыларга Христосны сӧйӏягян. 6 Филиппъ кылган кодрятлярне эшетеб, кюреб, калык анын сӧйӏягян сюзен бер кюнел белян тыннаган. 7 Аларнын кюбесен эченнян шакшы тыннар бик каты ӱкерешеб чыкканнар, сансызларнын, аксакларнын да кюбесе сауыкканнар. 8 Шул калада бик зур сӧйӧнӧч булган. 9 Калада Симонъ атлы бер кеше булган, ул шунын алдыннан гна ӱзен ӓлля нейдей олога куйыб, сихырлек кылыб, Самарія калкынын исен китергян. 10 Барысы да, олосо да, кечесе дя анар ан салыб ӓйткянняр: Бу Алланын оло кыуаты, дигянняр. 11 Ул сихырляӱе белян байтак багыт аларнын ислярен китергянгя кюря, аны ан салыб тыннаганнар. 12 Ӓммя Алла падшалыгы турысында, Иисусъ Христоснын исеме турысында изге хабяр сӧйӏяӱче Филиппка ышангач, ирляре дя, катыннары да чумылдырылганнар. 13 Симонъ ӱзе дя ышаныб чумылдырылган, аннары Филиппъ жаныннан китмягян; оло кыуатлар, кюб кодрятляр кылынганны кюреб, анын бик исе киткян. 14 Иерусалимдяге апостоллар, Самарія кешеляренен Алла сюзен кабыл алганнарын эшетеб, аларга Петръ белян Иоанны жибяргянняр. 15 Былар килеб, алар Святый Тынны алсыннар диб, алар өчӧн теляк иткянняр. 16 Святый Тын әле аларнын берсеня дя инмягян икян, алар тик Ходай Иисусъ исеменя гня чумылдырылганнар икян. 17 Шул чакта апостоллар алар өстӧня кулларын салганнар, алар Святый Тынны алганнар.

Зач.19 18 Апостоллар кулларын салыу арткылы Святый Тын бирелгянне кюреб, 19 Симонъ аларга акча алыб килеб, ӓйткян: Бу кыуатны мина да бирчегез, мин өстӧня кулымны салган кеше Святый Тынны алсын ыйы, дигян. 20 Ӓммя Петръ анар ӓйткян: Кӧмӧшӧн ӱзен белян бергя харяб булсын, син Алланын дяӱлятен акчага уйладын шул. 21 Мында сина ӧлӧш тя, катыш та жук, Алла карышысында синен кюнелен дӧрӧс тӧгӧл шул.

22 Инде айса бу жазыгына тяўбя
ит, Аллага инял, кюнелең уйла-
ганыҥ синә әлля кичерелер дя. 23
Синең әче ўткя тулыланганынны,
дөрөссөзлөк быгауында икяненне
кюрямен, дигян. 24 Симонъ жау-
аб биреб әйткян: Сез әйткяннен
берсе дя минә булмасын ыйы
диб, сез минем өчөн Ходайга
инялегез, дигян. 25 Алар таныкк-
лык итеб, Ходай сюзен сөйляб,
кабат Іерусалимгя кайтканнар,
Самаріянын кюб ауылларында
Евангеліене сөйлягянняр.

Зач.20 26 Ходай пярштя-
се Филиппка әйткян: Тор да
төшлөккя таба Іерусалимнян Га-
зага бара торган буш жулдан бар,
дигян. 27 Ул торган да киткян.
Шунда бер Ефіопія кешесе, ев-
нухъ, Ефіопіядагы катын падша
Кандакіянын санаты, анын бар
малын саклаучы, 28 Іерусалимгя
теляк итяргя килеўче, кайтыб бар-
ганда, арбада утырган көйө, Иса-
ія пагамбяр книгясен укый икян.
29 Тын Филиппка әйткян: Жакын
килеб, бу арбага жабыш, дигян.
30 Филиппъ жакын килеб, анын
Исаія пагамбяр книгясен укыга-
нын эшетеб, әйткян: Ней укыга-
нынны анныйсыҥ мы? дигян. 31 Ул
әйткян: Миня беряў дя аннатма-
гач, ничек анный алыйым, дигян;
аннары Филиппка ўтенгян: Ме-
неб минем белян утыр, дигян. 32
Ул жазыудан укыган төш былай
булган: Ул чалынырга сарык кюк
алыб барылган; кыркыучы ал-
дында дяшмей торган бярян кюк,
Ул ауызын ачмый торган. 33 Ул
кимсетелгян чакта, Аңар хокөм
кылынган, алай да Анын затын
кем әйтеб житкезя алыр? Анын
терелеге жирдян кютяреб алы-
на. 34 Евнухъ Филиппка әйткян:
Синә ўтенямен, әйтче: пагамбяр
мыны кем турысында әйтя: ўз
турысында мы, әлля бютян ту-
рысында мы? дигян. 35 Филип-
пъ ауызын ачыб, шул жазганнан
башлаб, аңар Іисусъ турысында
изге хабяр сөйлягян. 36 Жул белян
бара торгач, алар сыуга житкян-
няр: евнухъ әйткян: Мына сыу,
минә чумылдырылырга ней кома-
чау итя? дигян. 37 Филиппъ аңар
әйткян: Әгяр бар кюнеленнян
ышансаҥ, синә мөнким, дигян.
Ул жауаб биреб әйткян: Іисусъ
Христоснын Алла Улы икяне-
ня ышанамын, дигян. 38 Шун-
да арбасын туктатырга кушкан;
Филиппъ белян евнухъ икесе дя
сыуга кергянняр, Филиппъ аны
чумылдырган. 39 Алар сыудан

чыккач, евнухка Святый Тын ингян, шул сяттюк Филиппны Ходай пяриштясе жук иткян: шунда евнухъ аны кюрмяс булыб, ўз жулы белян сöйöнöб киткян.

Зач.21 40 Филиппъ Азотъ дигян калага барыб тöшкян; аннан Кесаріяга килгенче, бар калаларда да изге хабяр сöйляб жöргян.

9-нчы бюлем

1 Савлъ äле дя Ходайнын öйрянеўчеляреня чамасыз ачыу тотоб, аларны ўтерясе килеб, баш священниккя барган. 2 Шушы öйрятеўне кабыл алыучыларнын, ирлярен дя, катыннарын да, кемне табса шуны, бяйляб Іерусалимгя алыб кайтыр öчöн, аннан Дамасктагы синагогаларга жазыулар сораб алган. 3 Барган чагында, Дамаскка жакыннашкач, анар кюктян кинят жакты жактырган. 4 Ул жиргя жыгылган; аннары анар: Эй Савль, Савлъ! Ник син Мине кыуасын? диб äйтя торган ауаз эшеткян. 5 Ул äйткян: Эй Ходай, Син кем? дигян. Ходай äйткян: Мин син кыуа торган 1исусъ, сина ўзеннян Кыуатлыга карышы килеў читен, дигян. 6 Ул калтраб, кото чыгыб, äйткян: Эй Ходай! Мина ней кыларга кушасын? дигян. Ходай анар äйткян: Тор да калага бар; сина ней кыларга киряген äйтерляр, дигян. 7 Анын белян барыучы кешеляр, ауазны эшетеб, беряўне дя кюрмягянгя, шаккатыб торганнар. 8 Савлъ жирдян тороб, кюзе ачык булса да беряўне дя кюрмягян. Аны кулыннан житякляб, Дамаскка алыб килгянняр. 9 Ул öч кöн кюрмягян, ашамаган да, эчмягян дя. 10 Дамаскта Ананія атлы бер öйрянеўче булган; Ходай анар кюренеб äйткян: Ананія! дигян. Ул äйткян: Эй Ходай мына мин, дигян. 11 Ходай анар äйткян: Тор да туры урам дигян урамга бар, анда Іуда жортондагы Савлъ атлы Тарсъ кешесен сора; ул казер теляк итя; 12 анар кюреневў булды: ул кюзляре ачылсын диб, анар килеб, анын öстöня кул салган Ананія атлы кешене кюрде, дигян. 13 Ананія жауаб биргян: Эй Ходай, бу кешенен Іерусалимдя Синең изгеляреня ней усаллык кылганын мин кюб кешедян эшеттем; 14 мында да анар Синең исеменя сыйыныучыларнын барысын да бяйлярга

баш священниклярдян ирек бар, дигян. 15 Ходай Ананіяга äйткян: Бар, ул Минем калыклар алдында, падшалар алдында, Израиль оланнары алдында исемемне белдертергя сайлаган сауытым. 16 Минем исемем öчön ул ней катле азабланырга тейешле Мин анар кюрсятермен, дигян. 17 Ананія барыб öйгя кергян дя, анын öстöня кулын салыб, äйткян: Эй туган Савлъ! Син килгян жулда сина кюренгян Ходай Іисусъ, синең кюзляреҥ ачылсын диб, син Святый Тынга тулылансын диб мине жибярде, дигян. 18 Шул сяття анын кюзляреннян балык кабыгы койолган кюк булган; ул кинят кюря башлаган; аннары торган да чумылдырылган. 19 Аннары ашамнык ашаб, ўзен ныгайткан. Дамасктагы öйрянеўчеляр белян Савлъ бер ауык кöн торган.

Зач.22 20 Шул чактук Савлъ Іисусъ турысында Ул Алла Улы диб синагогаларда сöйлöй башлаган. 21 Бар тынҥаучылар да исляре китеб äйткянняр: Бу исемгя сыйыныучыларны Іерусалимдя кыуыучы кеше шушы тöгöл ме; мында да аларны бяйляб, баш свяшенниклярга итяргя диб килгян тöгöл ме? дигянняр. 22 Савлъ отородан-оторо ныкланган, Іисуснын Христосъ икяннеген айырмачык кюрсятеб, Дамаскта тороучы іудейлярне абтраткан. 23 Байтак багыт ўткяч, Іудейляр аны ўтерергя киняш кылганнар. 24 Савлъ аларнын бу киняшлярен белгян. Алар кöн-тöн аны ўтерергя диб кабка тöбöндя саклаб торганнар. 25 Öйрянеўчеляр тönня, аны алыб, тубалга утыртыб, кала коймасыннан тöшöрöб жибяргянняр. 26 Савлъ Іерусалимгя килеб, öйрянеўчелярга кушылырга тырышкан, тик анын öйрянеўче икяненя ышанмыйчы, аннан барысы да курыкканнар. 27 Варнава аны алыб, апостолларга китергян дя аларга, ул жулда чагында Ходайны кюргянне, анар Ходай ней äйткянне дя, аннары ул Дамаскта Іисуснын исеме турысында курыкмыйчы сöйлягянне дя äйткян. 28 Ул алар белян тороб, Іерусалимдя кереб чыгыб жöргяндя Ходай Іисусъ исеме турысында бик кыйыу сöйлягян. 29 Еллинистлар белян дя сöйляшеб тартышкан, алар аны ўтерергя келягянняр. 30 Туганнар мыны белеб, аны Кесаріяга жибяреб, Тарска озатканнар. 31 Ышаныучылар бötöн Іудеяда, Галилея-

да, Самаріяда да тыныч торганнар; Ходайдан куркыныб жӧрӧб, жыйынны рятлягянняр, Святый Тыннын тынычлыгында тороб кюбяйгянняр.

Зач.23 32 Петръ барысына да барыб караб жӧргян чагында, анӑр Лиддада тороучы изгелярга барырга туры килгян. 33 Анда ун сигез жыл тюшяктя сансызланыб жаткан бер Еней атлы кешене очораткан. 34 Петръ анӑр ӓйткян: Эй Еней! Сине Іисусь Христосъ тӧзятя: урнынӊан тор, дигян; шул сяттюк ул торган. 35 Лиддада, Ассаронда тороучылар барысы да аны кюргянняр, алар Ходайга ышанганнар. 36 Іоппіядя бер Тавифа атлы Серна диб ӓйтелгян ӧйрянеӳче катын бар икян: ул арыу эшляр кылыучы, кюб хайер биреӳче булган. 37 Шул кӧннярдя ул чирляб ӳлгян икян. Аны жыуыб гюрнячягя салганнар. 38 Лидда Іоппіягя жакын булганныктан, ӧйрянеӳчеляр Петрнын анда икянен эшетеб, анӑр ике кеше, безгя озакламыйчын гна килсення диб ӓйтергя жибяргянняр. 39 Петръ тороб, алар белян бергя киткян; килгяч, аны гюрнячягя алыб кергянняр. Андагы бар тол катыннар, Петрнын алдында жылашыб, Серна алар (Серна дигяне кыр кязясе дейеӳ) белян бергя торган чагында эшлягян кюлмяклярен. кейемнярен кюрсятеб торганнар. 40 Аларнын барысын да чыгарыб жибяреб, Петръ тезлянеб тороб теляк иткян дя, ӳлеккя таба боролоб ӓйткян: Тавифа, тор, дигян; ул кюзен ачыб жибяреб, Петрны кюреб, тороб утырган. 41 Петръ анӑр кулын биреб, аны торгозган; аннары, изгелярне, тол катыннарны дяшеб алыб, алар алдында аны тере кӧйӧ торгозган. 42 Бу эш бӧтӧн Іоппіягя билгеле булган; кюб кеше Ходайга ышанганнар. 43 Петръ Іоппіядя бер тирече Симонда байтак кӧнняб торган.

10-нчы бюлем

Зач.24 1 Кесаріяда Италійскій диб аталган полкнын жӧз кеше башлыгы Корнилій атлы бер кеше булган. 2 Ул изге тормошло булган, бар жорто белян Алладан куркыб, калыкка кюб садака биреб, жалан теляк итеб торган. 3 Кӧннӧн тугызынчы сагате чоронда анӑр кюренеӳ булган: ул ӳз жанына Алла пяриштя-

се кергянне айырмачык кюргян; пяриштя анар: Корнілій! дигян. 4 Ул анар караб, куркыб äйткян: Эй Ходай, ней? дигян. Пяриштя анар äйткян: Синең теляклярең дя, садакаларың да Алла алдында иска төшөрөлдөляр. 5 Инде айса Іоппіяга кешеляр жибяреб, Петръ диб атала торган Симонны чакырт. 6 Ул бер тиреченде Симонда тора, анын жорто дингез жарында; ул сина ўзең дя, бар жортоң да котолорлок сюзлярне äйтер, дигян. 7 Корнилій белян сöйляшкян пяриштя киткяч, ул ўз кызмятчеляренен икесен, тагы ўз жанында тороучы салдатларнын изге тормошлосон беряўне чакырыб алган да, 8 аларга барысын да äйтеб, аларны Іоппіяга жибяргян. 9 Иртягесен алар барган чагында, калага жакыннашкан чорда, алтынчы сагат тирясендя, Петръ öй тюбясеня теляк итяргя менгян. 10 Анын карыны ачыб китеб, ашасы килгян. Äзерлягян арада, анар зур куркыныч төшкян. 11 Ачылган кюкне, аннан анар жиргя таба төшöб киля торган, дюрт почмагыннан бяйлянгян оло аш жаулыгына ошаулы бер нястя кюргян. 12 Анын эчендя жирдяге дюрт аяклы төрлö жяннекляр, кейекляр, шыуышыб жöрöй торган жяннекляр дя, ауа кошлары да булган. 13 Анар ауаз да килгян: Эй Петръ! Тор да чалыб аша, дигян. 14 Петръ äйткян: Эй Ходай! Жук, минем төрлö шакшы нястяне, жя таза төгöлне бер чакта да ашаганым жук, дигян. 15 Шунда тагы икенче табкыр анар ауаз килгян: Алла тазартканны син шакшыга санама, дигян. 16 Бу öчкя чаклы булган, аннары кюренгян нястя тагы кюккя кютярелгян. 17 Петръ бу кюргян нястясен ўз кюңеленде нейгя журарга белмей торган чагында, Корнилій жибяргян кешеляр, Симонъ öйöн сораштырыб белеб, кабка төбöня килеб туктаганнар да, дяшеб сораганнар: 18 Петръ диб атала торган Симонъ мында тора мы? дигянняр. 19 Петрь кюргяне турысында уйлаб торган арада, Тын анар äйткян: Мына сине öч кеше эзлей: тор да, төшöб, ич тя шиклянмейче, алар белян бар, аларны Мин жибярдем шул, дигян.

Зач. 25. 21 Петръ төшкяч, Корнилій жибяргян кешеляргя äйткян: Сез эзлей торган мин ўзем, сез ней сябяблей килдегез? дигян. 22 Алар äйткянняр: Алладан куркыб тороучы, ары-

улык кылыучы бӧтӧн Іудея калыгы арыуга саный торган, жӧз кеше башлыгы Корнилій изге пяриштядян ӱз ӧйӧня сине чакырыб, синең сюзляреңне тыңнарга бойорок алды, дигянняр. 23 Петръ аларны чакырыб алыб сыйлаган; икенче көннӧ тороб, алар белян барган; анын белян Іоппіядагы туганнарнын да кайсылары барганнар. 24 Икенче көннӧ алар Кесаріяга килеб кергянняр; Корнилій туганнарын да, жакын дусларын да чакырыб, аларны кӧтӧб торган. 25 Петръ килеб кергяч, Корнилій аны карышы алыб, анын аягы астына жыгылыб башырган. 26 Петръ аны кютяреб алыб äйткян: Тор, мин ӱзем дя ädям, дигян. 27 Анын белян сӧйляшеб, ӧйгя кергян, анда жыйылган кюб кешелярне кюргян; 28 аларга äйткян: Сез белясез, Іудея кешесеня бютян зат кешеляре белян катышырга, жя жакынна-шырга кушылмаган: миңа Алла бер кешене дя шакшыга, жя таза тӧгӧлгя санама диб белдертте. 29 Шунын ӧчӧн мин чакырылгач, шиклянмейче килдем; инде айса сездян соройым: Мине ней сябяблей чакырдыгыз? дигян. 30 Корнилій äйткян: Дюртенче кӧн шушы сагаткя чаклы мин ураза тоттом, тугызынчы сагаття ӱз ӧйӧмдя теляк иттем: мына минем алдымда ак кейем кейгян кеше кюренеб тордо, 31 ул äйтте: Корнилій синең теляген эшетелде, садакаларың да Алла алдында иска тӧшӧрӧлдӧляр; 32 инде айса Іоппіяга жибяреб, Петръ диб аталган Симонны чакырыб китер; ул дингез жанындагы тирече Симонда тора, ул килеб синя äйтер, диде. 33 Шул сагаттюк мин синя жибярдем; инде синең килеӱең жакшы. Казер без барыбыз да Алладан синя ней кушылганны барын да тынныйык диб, Алла карышысында торабыз, дигян.

Зач.26 34 Петръ ауызын ачыб äйткян: Чыннаб, Алла кешенен жӧзӧня караб кылмаганны анныйым. 35 Бар калык та Алладан куркыучы, дӧрӧс кылыныучы Анар сӧйкӧмне. 36 Іисусъ Христосъ арткылы тынычлык турысында изге хабяр сӧйляб, Ул Израиль улларына сюз жибяргян: Ул барысынын да Ходайы. 37 Іоаннъ сӧйлягян чумылыудан суң, Галилеядан башлаб, бӧтӧн Іудеяда булган эшлярне белясез. 38 Назареттан чыккан Іисусны Алла сайлаб, Анар Святый

Тын да, кыуат та индерде; Алла Анын белян булганга кюря, Ул изгелекляр кылыб, женнянгяннярнен барысын да сауыктырыб жӧрдӧ. 39 Іудея жирендя, Іерусалимдя дя Ул кылган эшкя, Аны агачка кадаклаб ӳтергянняреня барысына да без таныкчы. 40 Шушыны Алла ӧчӧнчӧ кӧннӧ терелтеб торгоздо да Анар кюренергя ирек бирде. 41 Бар калыкка да тӧгӧл, тик Алладан алдан сайланыб куйылганнарга, Анын ӳлгяненнян терелеб торганыннан суң, Анын белян бергя ашаб эчеб жӧргян таныкчылары безгя гня кюренергя ирек бирде. 42 Ул безгя терелергя дя, ӳлгяннергя дя Алладан сайланыб куйылган Хокӧмче икяннеген таныклаб, кешелергя сӧйлергя кушты. 43 Анын турысында бар пагамбярляр, Анар ышаныучы ӓр-бер кеше Анын исеме белян жазыклар кичелеӳен алыр диб таныклык итяляр, дигян.

Зач.27 44 Петръ бу сюзлярне ӓйткян чагында, Святый Тын сюз тыннаучыларнын барысына да, интян. 45Петръ белян килгян ышаныучыларнын киселгянняренен жалган деннелергя Святый Тыннын дяӳляте интянне кюреб, исляре киткян. 46 Аларнын тӧрлӧ телляр белян сӧйляшкяннярен, Алланы ололаганнарын эшеткянняр шул. Шул чакта Петръ ӓйткян: 47 Бу безнен кюк Святый Тынны алганнарга сыу белян чумылырга кем ирек бирмяс? дигян дя, 48 Іисусъ Христосъ исеменя аларга чумылдырылырга кушкан. Аннары алар анар бераук кӧн бездя тор диб инялгянняр.

11-нче бюлем

1 Апостоллар да, Іудеяда тороучы туганнар да жалган деннелярнен Алла сюзен кабыл алганнарын эшеткянняр. 2 Петръ Іерусалимгя килгяч, киселгянняр анын белян сюзгя килеб, 3 ӓйткянняр: син киселмягян ирлергя кереб, алар белян аш ашаганын, дигянняр. 4 Петръ аларга былай диб рятляб ӓйтя башлаган: 5 Мин Іоппія каласында теляк итеб, онотолоб торган чагында кюренеӳ кюрдем: кюктян дюрт почмагыннан бяйлягян оло аш жаулыгына ошаулы мина бер нястя килеб тӧштӧ. 6 Мин кюз салыб аны караштырдым да, анда жирдяге дюрт аяклыларны, кейеклярне,

шыуышыб жӧрӧй торган жянneклярне, ауадагы кошларны да кюрдем. 7 Мин шунда: Эй Петръ, тор да чалыб аша диб айткян ауаз эшеттем. 8 Мин айттем: Эй Ходай, жук, минем ауызыма шакшы, жя таза тӧгӧл нястялярнен бер чакта да кергяне жук, дидем. 9 Мина кюктян ауаз икенче табкыр жауаб бирде: Алла тазартканны, син шакшыга санама, диб. 10 Бу ӧчкя чаклы булды да, барысы да кабат кюккя кютярелде. 11 Мына, шул сагаттюк Кесариядан мина жибярелгян ӧч ир кеше мин торган ӧй жанына килеб туктадылар. 12 Тын мина: Алар белян бер дя шиклянмейче бар диб айтте; минем белян бу алты туганнар да бардылар, без шул кеше ӧйӧня кердек. 13 Безгя ӱз ойӧндя анар изге пяриштя кюренеб айткян сюзлярне айтеб бирде: Иоппияга ир кешеляр жибяр дя Петръ диб аталган Симонны чакырт,

14 Ул сина син дя, бар жортон да котолорлок сюзляр сӧйляр, диде. 15 Мин сӧйлӧй башлагач, элеке безгя интян кюк, аларга Святый Тын инде. 16 Шул чакта Ходайнын: Иоаннъ сыуда чумылдырды, аммя сез Святый Тын белян чумылдырылырсыз диб айткян сюзе минем исемя тӧштӧ. 17 Шулай Алла без Ходай Иисусъ Христоска ышаныучыларга биргян кюк, аларга да шундый дяӱлятне биргяч, Аллага карышы тороргa мин кем сунъ? дигян. 18 Мыны эшеткяч, алар тынычланганнар да, айса жалган деннеляргя дя Алла терелеккя итя торган тяӱбяне биргян икян диб Алланы даннаганнар.

Зач.28 19 Ул арада Стефанъ ӱтерелгяч булган кысанныктан таралышкан ышаныучылар Финикияга, Кипрга, Антиохияга чаклы китеб, иудейлярдян башка беряӱгя дя сюзне сӧйлямейче ӱткянняр. 20 Аларнын кайсылары Антиохияга кереб, Ходай Иисусны айтеб, еллиннарга сӧйляӱчеляре, Кипръ кешеляре белян Киринея кешеляре икян. 21 Ходай кыуаты алар белян икян; кюб кешеляр ышаныб Ходайга кайтканнар. 22 Алар турысында Иерусалимдяге ышаныучылар жыйынына хабяр эшетелгян дя, алар Варнаваны Антиохияга жибяргяннар. 23 Ул килгяч, Алланын дяӱлятен кюреб, бик сӧйӧнгян дя, барысын да чын кюнел белян Ходайга биренеб тороргa димнягян. 24 Ул Святый Тынга да, ышаныуга да тулы

арыу кеше икян. Байтак калык Ходайга кушылган. 25 Аннары Варнава Савлны эзлергя Тарска киткян; аны табыб, Антіохіяга алыб киткян. 26 Алар жыл буйынчы келяў ӧйӧня жыйылышканнар да, байтак калыкны ӧйряткянняр; ӧйрянеўчеляр Христосныкылар диб инг элеке Антіохіяда атала башлаганнар. 27 Шул кӧннярдя Іерусалимнян Антіохіяга пагамбярляр килгянняр. 28 Аларнын берсе Агавъ атлысы тороб, Тын билгерткянчя, бӧтӧн дӧньядя каты ачлык булыр диб алдан äйткян. Ул ачлык кесарь Клавдій багытында булган. 29 Шул чакта ӧйрянеўчеляр äр-берсе ўзенен малыннан Іудеяда тороучы туганнарга булышырга куйганнар. 30 Жыйылганны Варнава белян Савлъ арткылы башлыкларга жибяреб, бу эшне житкезгянняр.

12-нче бюлем

Зач.29 1 Шул багытта Ирод ъ падша ышаныучылар жыйынындагыларнын кайсыларына усаллык кыларга кулын кютяргян. 2 Іоаннын агасы Іаковны кылыч белян ўтергян. 3 Бу іудейлярга ошаганны кюреб, тагы Петрны да тотоб алган; шул чакта, тӧчӧ кюмяч кӧнняре икян. 4 Петрны тотоб, Пасхадан суң калыкка алыб чыгарга исяб итеб, бер жулы дюртярляб ун алты салдатка сакларга кушыб, аны ӧтӧрмянгя утырткан. 5 Шулай итеб Петрны ӧтӧрмяндя саклаганнар; шул арада ышаныучылар жыйыны анын турысында Аллага бик тырышыб теляк иткян. 6 Ирод ъ Петрны алыб чыгасы иткяч, шул тӧннӧ, Петръ ике чылбыр белян быгаулаган кӧйӧ ике салдат арасында жоклаган, карауылчылар ӧтӧрмянне саклаганнар. 7 Мына Ходай пяриштясе килеб кюренгян дя, ӧтӧрмяндя жакты жактырган, пяриштя Петрнын жан башына тӧртӧб, тиз тор диб аны уяткан. Анын кулларыннан чылбыр тӧшкян. 8 Пяриштя анар äйткян: Биленне бяйля, аягынны кейен, дигян. Ул шулай кылган. Аннары анар äйткян: Кейеменне кейен дя минем артымнан бар, дигян. 9 Петръ чыгыб, анын артыннан барган, пяриштядян була торганнын чын икянен белмягян, äммя кюренеў кюря торганмындыр диб уйлаган. 10 Беренче кара-

уылдан, икенчесеннян дя ўткяч, калага чыга торган тимер кабкага килеб житкянняр. Кабка аларга ўз алдына ачылган. Чыгыб, бер урам ўткянняр дя, кинят пяриштя жук булган. 11 Шунда Петръ уйга килеб äйткян: Инде мин Алла Ўз пяриштясен жибяреб, Иродъ кулыннан да, іудей калыгы көткяннен барысыннан да мине коткарганын чыннаб белямен, дигян.

Зач.30 12 Аннары жак жакка караныб, Маркъ диб аталган Іоаннъ анасы Маріянын өйө катына килгян, анда кюб ышаныучылар жыйылышыб, теляк итеб торалар икян. Петръ кабканы дөбөрдяткяч, 13 Рода атлы кызмятче кыз тынҥарга чыккан. 14 Петръ тауышын эшеткяч, сөйөнөчөннян кабканы ачмыйчы жөгөреб, кереб, Петрнын кабка төбөндя торганын äйткян. 15 Тегеляр анҥар äйткянняр: Синеҥ акылыҥ бар мы? дигянняр. Ул гел ўзенекен äйткян. Алар äйткянняр: Бу анын пяриштясе, дигянняр. 16 Ул арада Петръ гел дөбөрдятеб торган. Ачкач, аны кюргянняр дя, шак катканнар. 17 Петръ аларга дяшмяскя кулы белян билге биреб, аны Ходай өтөрмяннян ничек чыгарганны аларга рятляб äйткян дя, бу турда Іаковка да, туганнарга да хабяр итегез, дигян. Аннары чыгыб, икенче төшкя киткян. 18 Көн таҥаткач, Петрга ней булган икян диб, салдатлар арасында бик болганышыу булган. 19 Иродъ Петрны эзляб табмагач, карауылчыларга хокөм итеб, аларны ўтерергя кушкан. Аннары ул Іудеядан Кесаріяга китеб торган. 20 Иродъ Тиръ белян Сидонъ кешеляреня ачыу тота икян; аларнын жагы падша жиреннян туйынганга кюря, алар бер кюнел белян анҥар килгянняр дя, падшанын жоклой торган урнын карый торган кешесе Властны ўз жаклары-на ауыштырыб, тынычлык сораганнар. 21 Куйылган көннө, падша кейемен кейеб, Иродъ хокөм урнына утырыб, аларга сөйлягян. 22 Калык кычкырган: Бу Алла ауазы, кешенеке төгөл диб. 23 Иродъ Аллага дан китермягян өчөн, анҥар Ходай пяриштясе кинят каза кылган, аны кортлар ашаганнар, ул улгян.

Зач.31 24-25 Алла сюзе ўсеб жяйеля килгян. Варнава белян Савлъ табшырылганны кылыб житкезгяч, ўзляре белян Маркъ диб аталган Іоанны алыб, Іерусалимнян Антіохіяга кайтканнар.

13-нче бюлем

1 Ышаныучыларнын Антіохіядагы жыйынында кайсылары пагамбярляр, өйрятеўчеляр булганнар: Варнава, Нигеръ диб аталган Симеонъ, Киринеянын Луцій, дюртенче өлөшнө биляб тороучы Иродъ белян бергя ўскян Манаилъ, аннары Савлъ. 2 Алар Ходайга кызмят иткяндя, ураза тотканда, Святый Тын әйткян: Мина Варнава белян Савлны Мин аларны чакырган эшкя айырыгыз, дигян. 3 Шул чакта ураза тотоб, теляк итеб, Варнава белян Савлга кул салыб, аларны жибяргянняр. 4 Святый Тын жибяргяч, былар Селевкіяга килгянняр, аннан сыу белян Кипрга киткянняр. 5 Саламинга килгяч, іудейлярнен синагогаларында Алла сюзен сөйлягянняр; ўзляреня булышырга Іоанны тотканнар. 6 Пафъ дигян калага тикле бөтөн атауны ўтеб, алар бер кешене, Варіисусъ атлы іудейне очратканнар. 7 Ул бу атаунын башлыгы Сергій Павелъ атлы, акыллы кеше белян бергя торган. Бу башлык Варнава белян Савлны чакырган да, Алла сюзен тыңнарга тырышкан. 8 Сихырче Елима (Елима дигяне сихырче дейеў) башлыкны ышандырмаска тырышыб, аларга карышылык иткян. 9 Павелъ диб тя аталган Савлъ Святый Тынга тулыланыб, анар тегяляб караб, әйткян: Эй төрлө хайлягя, усалыкка тулыланган шайтан баласы, әр-бер дөрөслөкнен дошманы! 10 Ходайнын туры жулларыннан ауыштырыуыннан туктарсын мы син? 11 Әле дя мына Ходайнын кулы синең өстөндя: син сукыр булырсын да, кояшны да бер аз багытка чаклы кюрмяссең, дигян. Кинят анар дөм карангы төшкян дя, ул әйлянгяляб жөрөб, житякляб жөртөўче эзлягян. 12 Шул чакта башлык, булган эшне кюреб, Ходайдан булган өйрятеўгя исе китеб, ышанган.

Зач. 32. 13 Павелъ да, анын жанындагылар да Пафадан сыу белян китеб, Памфиліядагы Пергія атлы калага килгянняр. Іоаннъ алардан айырылыб, Іерусалимгя кайткан. 14 Алар Пергіядан ўтеб, Писидія Антіохіясына килгянняр дя, суббота көннө синагогага кереб утырганнар. 15 Законны, пагамбярляр жазганны укыганнан сун, синагога башлыклары аларга

äйтергя жибяргянняр: Эй кадерле туганнар! Äгяр сезнен калыкка ўгет сюзегез булса, сöйлягез, диб. 16 Павелъ тороб, кулы белян билге биреб, äйткян: Эй Израиль кешеляре, Алладан куркыучылар, тыннагыз: 17 Бу калыкнын Аллысы безнен аталарыбызны сайлаб алган да, бу калык Египетъ жирендя торган чагында, аны кютярелдергян, аннары кодрятле кулы белян аларны аннан чыгарган. 18 Кырык жылга жакын буш кырда аларны туйдырган. 19 Ханаанъ жирендя жиде калыкны бетереб, аларнын жирен, аларга ölöшкя айырыб биргян. 20 Мыннан сунъ да дюрт жöз илле жылга жакын Самуилъ пагамбяргя тикле аларга тюряляр биреб торган. 21 Аннары алар падша сораганнар, аларга Веніаминъ няселенен Кисъ улы Саулъ атлы кешене биргян. Шулай кырык жыл ўткян. 22 Аны чикереб, аларга Давидны падшага кютяргян, анын турында таныклыб äйткян: Мин Ўз кюнелемя ошаган кешене, Іессей улы Давидны табтым; ул Минем бар телягянняремне булдырыр, дигян. 23 Мынын няселеннян Алла Ўз багадясе буйынча Израилгя Коткарыучы Іисусны торгозган; 24 Ул кюренер алдыннан гна Іоаннъ бар Израиль калыгына тяўбя итеў чумылдырыуын сöйлягян.

Зач.33 25 Іоаннъ ўз кызмятен тутырган чакта äйткян: Сез мине кем диб белясез ? Мин Ул тöгöл, äммя мына минем арттан киля, мин анын башмагынын кайышын чишяргя дя тормоймын, дигян. 26 Эй кадерле туганнар, Авраамъ няселенен оланнары, эй Алладан куркыучылар! Бу котолоу сюзе сезгя жибярелгян. 27 Іерусалимдя тороучылар да, аларнын башлыклары да, Аны танымыйчы, айыблаб, пагамбярлярнен суббота сайын укыла торган сюзлярен жиреня китергянняр ич. 28 Анын ўлемгя тейешле бер айыбын да табмагач, Пилаттан Аны ўтертергя сораганнар. 29 Анын турында жазылганны барын да кылыб бетергяч, качтан алыб Аны кабергя куйганнар. 30 Äммя Алла Аны ўлгяненнян терелтеб торгозган. 31 Ул Ўзе белян Галилеядан Іерусалимгя менгяннярга, казер дя Анар калык алдында таныкчы булыб тороучыларга кюб кönняр эчендя кюренгялягян. 32 Алла аталарыбызга биргян багадясен безгя, аларнын оланнарына, Іисусны терелтеб торгозоб, жиреня китер-

гянен äйтеб, без сезгя изге хабяр сöйлöйбез. 33 Шулай икенче псаломда да жазылган: Син Минем Улым, Мин Сине бöгöн тыудырдым, диб. 34 Аны ўлгяннярдян терелтеб торгозганын, Ул инде череўгя кайтмасны Алла былай äйткян: Мин Давидка адарынган ышангычлы изгелеклярне сезгя бирермен, дигян. 35 Шунын öчöн бютян тöштя да äйтя: Изгеня череў тейертмяссең, диб. 36 Давидъ ўз багытындагылар öчöн Алла иркеня кызмят итеб ўлгян дя, ўз аталарына кушылыб, череўне кюргян. 37 Ämмя Алла терелтеб торгозган Iисусъ череўне кюрмягян. 38 Шунăр кюря, эй кадерле туганнар, сезгя билгеле булсын: Анын какында сезгя жазыклар кичерелеў хабяре сöйляня. 39 Моисей законы арткылы сез дöрöсляня алмаганнын барысыннан да, Анын арткылы äр-бер ышаныучы дöрöсляня. 40 Сакланыгыз, пагамбярляр жазыуында äйтелгян сезнен öскя калмасын. 41 Анда былай жазылган: Эй кимсетеўчеляр, карагыз, исегез китсен, кюргяч, жукка чыгыгыз: мин шул сезнен көннярегездя шундый эш кыламын, äгяр беряў сезгя шундыйны сöйляшся, сез ул эшкя ышанмас ыйыгыз диб. 42 Павелъ белян Варнава iудейлярнен келяў öйöннян чыккан чакта, жалган деннеляр, килясе субботада бу сюзляр сöйлянсен диб ўтенгянняр. 43 Жыйыннары таралгач, iудейлярнен дя, жалган деннян ауышыб, Алланы кадерляўче булганнарнын да кюбесе Павелъ белян Варнава артыннан барганнар; былар аларга сöйляб, аларны Алла дяўлятендя нык тороргa ўгетлягянняр.

44 Икенче суббота көннö Алла сюзен тынăларга бöтöн кала кешесе диб äйтерлек жыйылган. 45 Iудейляр калыкны кюреб, көнчöлöккя тулыланганнар да, карышы äйтеб, курлаб, Павелнын сöйлягяненя карышылык иткянняр. 46 Шул чакта Павелъ белян Варнава кыйыуланыб, äйткянняр: Сезгя Алла сюзе иң элек сöйлянергя тейеш эйе; сез аны чикерясез, ўзегезне ўзегез мянге тормошка тейешсез итясез; шунăр кюря мына бу жалган деннелярга боролабыз. 47 Ходай безгя шулай бойорган шул: Син жир читендягелярга чаклы коткарыучы булсын диб, Мин Сине жалган деннелярга жакты булырга куйдым, диб. 48 Жалган деннеляр мыны эшетеб,

сӧйӧнӧшкянняр, Ходайнын сюзен даннаганнар; мянге тормошка алдан сайланганнар барысы да ышанганнар. 49 Ходай сюзе бар жирдя дя жяйелгян. 50 Алай булса да, іудейляр Алланы кадерлей торган катыннарны да, бютян кадерле катыннарны да, каланын бер дигян кешелярен дя, котортканнар, Павелъ белян Варнавага кысаннык китереб, аларны ӱз тиряляреннян кыуыб жибяргянняр. 51 Павелъ белян Варнава аякларындагы тупракны аларга селкеб ташлаб, Иконіяга киткянняр. 52 Ӧйрянеӱчеляр сӧйӧнӧчкя дя, Святый Тынга да тулыланганнар.

14-нче бюлем

1 Иконіяда алар бергя іудейлярнен синагогасына кергянняр дя анда сӧйляб, бик кюб іудейлярне дя, еллиннарны да ышандырганнар. 2 Ышанмый торган іудейляр туганнарга карышы жалган деннелярнен кюңеллярен жилкетеб котортканнар. 3 Алай да алар мында аларнын кулы арткылы билгеляр, кодрятляр кюрсятеб, Ӱз дяӱлятенен сюзен таныклый торган Ходайга ӧмӧт тотоб кыйыуланыб, байтак багыт уздырганнар. 4 Шул арада каладагы калык ике жакка айырылган: кайсылары іудейляр жаклы, кайсылары апостоллар жаклы булганнар. 5 Жалган деннеляр дя, іудейляр дя ӱзляренен башлыклары белян аларны курлыкка калдырыйык диб, ташлар белян атыйык диб аларга таба сӧрлӧгӧшкян чакта,

Зач.34 6 Алар мыны белеб, Ликаонъ калалары, Листрага, Дервіяга, аларнын тиряляреня киткянняр дя, 7 анда изге хабяр сӧйлягянняр. 8 Листрада анасы эченнян аксак кӧйӧ тыуган, аякларын кузгата алмый торган бер кеше утырган; ул бер чакта да жӧрмягян.

9 Ул Павелнын сӧйлягянен тыннаган; Павелъ анар тегяляб караб, анын саулык алырга ышаныуын кюреб, 10 зур тауыш белян йӧткян: Синңа Ходай Іисусъ Христосъ исеме белян йӧтямен, аякларынңа туры тор, дигян. Ул шул сяттюк сикереб торган да жӧрӧй башлаган. 11 Калык Павелнын ней кылганын кюреб, Ликаонь теле белян йӧтеб: аллалар кешелярга ошашлы булыб, безгя тӧшкян икян диб ауаз кютяргян.

12 Варнаваны Зевсъ диб, Павелны, сюз башлаучы булганга кюря, Ермій диб атаганнар. 13 Аларнын калалары карышысында тора торган Зевсъ сыннын корман китереўчесе кабка төбөня ўгезляр дя, ўргян чячякляр дя китереб, калык белян корман чалырга келягян. 14 Тик апостоллар Варнава белян Павелъ мыны эшетеб, кейемнярен айырыб, калык арасына кергянняр дя кычкырыб äйткянняр: Эй кадерлеляр! Сез ней эшлейсез? 15 Без дя сезнен кюк кешеляр, сез бу жалган аллалардан, кюкне, жирне, дингезне, аларда ней бар барын да булдырган тере Аллага кайтыгыз диб, без сезгя изге хабяр сöйляўчеляр. Жулларыннан 16 Ул ўткян няселлярдя бар калыкларга Ўз жöрöргя ирек биргян. 17 Алай булса да безгя кюктян жангырлар да, жимеш унa торган багытлар да биреб, безнен кюнелляребезне ашамныкка да, сöйöнöчкя дя тулыландырыб, изге эшляр кылыб, Ўзе турысында туктаусыз таныклык итеб торган, дигянняр. 18 Мыны äйтеб алар калыкны аларга корман чалмыйчы, äрберсен öйляреня кайтырга кöчкя кюндергянняр. 19 Шул арада, алар анда калыб öйряткян чагында, Антіохіядян дя, Иконіядан да кайсы іудейляр килеб, апостоллар кыйыуланыб сöйлягян чакта, алар бер дя чынны сöйлямейляр, барын да жалганныйлар диб äйтеб, калыкны алар катыннан китяргя кюндергянняр. Калыкны кюндереб житкезеб, Павелга ташлар белян атыб, аны ўлгянгя санаб, каланын тыш жагына чыгарыб салганнар. 20 Аны öйрянеўчеляр чырмаб алгач, ул тороб калага кергян дя, иртягесен Варнава белян Дервіяга чыгыб киткян.

Зач.35 21 Шул калага изге хабяр сöйляб, кюб кешелярне öйрятеб, кайтышлый алар Листрадан, Иконіядан, Антіохіядян узганнар. 22 Öйрянеўчелярнен кюнеллярен ныкландырыб, дендя ныk тороргa ўтенеб, безгя Алла падшалыгына кюб кöйöнöч арткылы керергя тейешле диб öйрятеб ўткянняр. 23 Ышаныучылар жыйыны сайын, кул салыб, аларга пресвитерлар куйыб, ураза тотоб, аларны алар ышанган Ходайга табшырганнар. 24 Аннары Писидія арткылы ўтеб, Памфиліяга килгянняр. 25 Пергіяда Ходай сюзен сöйляб, Атталіяга тöшкянняр. 26 Аннан сыу белян

Антіохіягя кайтканнар; шушы тöштян алар, Алла дяўляте булышкан буйынча, сöйляў эшеня киткянняр икян; ул эшне жиреня китермягянняр. 27 Шунда кайтыб, ышаныучыларны жыйыб, Алла ней кылганны, жалган деннелярга Ул ышаныу ишеген ничек ачканны äйткянняр. 28 Анда öйрянеўчеляр белян байтак багыт уздырганнар.

15-нче бюлем

1 Кайсылары, іудеядан төшöб, туганнарны Моисей жоласы буйынча киселмясягез, котола алмассыз диб öйряткянняр. 2 Павелъ белян Варнава аларга карышы тороб, кюб жинӗшеў булгач, Павелъ белян Варнаваны, алардан бютяннярне дя кайсыларын шушы эш белян Іерусалимгя, апостоллар, пресвитерлар жанына менярга куйганнар. 3 Шунӑр кюря аларны ышаныучылар озаткач, алар жалган деннелярнен Аллага кайтыуын сöйляб, Финикіяны да, Самаріяны да ўткянняр дя, бар туганнарга да оло сöйöнöч китергянняр. 4 Алар Іерусалимгя килгяч, ышаныучылар да, апостоллар да, пресвитерлар да аларны кабыл алганнар; аларга Алла ней кылганны, жалган деннелярга Ул ышаныу ишеген ачканны äйткянняр.

Зач.36 5 Шул чакта фарисейляр арасыннан ышаныучыларнын кайсылары жалган деннелярга киселеў жоласын кыларга, Моисей законын тотарга бойорорга киряк диб äйтеб карышы торганнар. 6 Апостоллар да, пресвитерлар да бу эшне тикшерергя жыйылышканнар. 7 Кюб жинӗшеў булгач, Петръ тороб, аларга äйткян: Эй кадерле туганнар! Минем ауыздан жалган деннеляр хабяр сюзен эшетсенняр дя, ышансыннар диб Алла ин элекe кöннярдян безнен арада мине сайлаганны сез белясез. 8 Кюнӗллярне белеўче Алла, безгя биргян кюк, аларга да Святый Тынны биреб, аларга да таныклык бирде; 9 Ышаныу арткылы аларнын кюнӗллярен тазартыб, безнен белян алар арасында бер дя айырмасын куймады; 10 безнен аталарыбыз да, без дя кютяреб жöрöй алмаган жöкнö, öйрянеўчеляр муйнына саласы булыб, ник сез Алланы сыныйсыз? 11 Ämмя без Ходай Іисусъ Христоснын дяўляте арткылы котолорбыз

диб ышанабыз, алар да шунын кюк, дигян. 12 Шул чакта бӧтӧн жыйын басылышкан, Варнава белян Павелнын Алла алар арткылы жалган деннеляр арасында нейдей билгеляр, кодрятляр кылганны рятляб ӓйткяннярен тынаганнар. 13 Алар ӓйтеб туктагач, Іаковъ сюз башлаб ӓйткян: Эй кадерле туганнар! Тынгагыз ӓле:

14 Алла ӱз исеменя жалган деннелярдян калык торгозасы булыб, ин элеке аларга кюз салганны Симонъ рятляб ӓйтте. 15 Мынын белян пагамбярлярнен сюзляре дя бер була, былай жазылган ич:
16 Сунъннан боролоб, Давиднын ауган чатырын жаңадан торгозормон, анын жимерелгян тӧшлярен жаңадан торгозормон да аны тӧзятермен. 17 Кешелярнен калганнары да, Минем исемем хабяр ителясе бар калыклар да Ходайны эзлясенняр эйе диб, быларны барын да кылыучы Ходай ӓйтя.
18 Аллага мянгедян бирле Ӱзенен бар эшляре билгеле. 19 Шушынар кюря мин жалган деннелярдян Аллага кайтыучыларны борчомаска киряк диб белямен. 20 Тик алар сыннарга китергян ашамныктан, уйнашлыктан, быуыб ӱтерелгяннян, каннан тыйылсыннар диб, ӱзляреня кылдырасы килмягянне, кешегя дя кылмасыннар диб аларга жазыб жибярергя киряк диб белямен. 21 Моисей законын ӓӱлеге няселлярдянюк кала сайын суббота кӧннярдя синагогаларда укыб, аны сӧйляӱчеляр бар шул, дигян. 22 Шул чакта апостоллар да, пресвитерлар да, бар ышаныучылар да ӱз араларыннан туганнар арасында башлык булыб тороучы ирлярне Варсава диб аталган Іуданы да, Силаны да сайлаб, аларны Павелъ белян, Варнава белян бергя Аніохіягя жибярясе иткяннняр. 23 Аларга ӱз куллары белян былай диб жазыб жибярясе булганнар: Апостоллар да, пресвитерлар да, туганнар да Антіохіядя, Сирія-да, Киликіяда тороучы жалган деннелярдян кайткан туганнарга: Сӧйӧнӧгӧз диб ӓйтябез. 24 Бездян киткяннярнен кайсылары, сезгя киселергя дя, Моисей законын тотарга да тейеш диб, шул сюзляр белян сезне шикляндереб, кюнеллярегезне, сезне болгатканнар диб эшеттек, ӓммя без аларга мыны кушмаган ыйык. 25 Шунар кюря без бер кюнел белян жыйылышыб, кешеляр сайлаб, аларны безнен сӧйӧкляребез Варнава бе-

лян, Павелъ белян сезгя жибярясе иттек. 26 Былар ўз жаннарын Ходайыбыз Iисусъ Христосъ какына биргян кешеляр. 27 Шулай без Iуда белян Силаны жибярдек, алар сезгя шунук сюз белян анӈатыб бирерляр. 28 Святый Тын да, без дя сезнен öскя бу киряклеdян башка бер гня артык ауырлык та салырга кюӈел итмядек. 29 Сез сын корманыннан, каннан, быуыб ўтерелгяннян, уйнашлыктан тыйылырга тейеш, ўзегезгя кылdырасы килмягянне, кешегя дя кылмагыз. Мыннан ўзегезне сакласагыз, жакшы кыларсыз. 30 Сау булыгыз диб. Шулай жибярелгян кешеляр Антiохiягя килгянняр дя, кешелярне жыйыб, жазыуны биргянняр. 31 Былар укыб чыгыб, бу ўгеткя сöйöнöшкянняр. 32 Iуда белян Сила, ўзляре дя пагамбяр булганга кюря, кюб сюз белян туганнарны ўгетляб ныкландырганнар. 33 Бер ауык торгач, туганнар аларны тынычлык белян апостолларга жибяргянняр. 34 Алай булса да, Сила анда каласы иткян; Iуда Iерусалимгя кайткан.

Зач.37 35 Павелъ белян Варнава, бютяннярнен кюбесе дя бергя öйрятеб, Ходай сюзен сöйляб, Антiохiядя торганнар. 36 Бер ауык көннян сунӷ Павелъ Варнавага äйткян: Äйдя тагы, без Ходай сюзен сöйлягян бар калаларда тороучы туганнарыбызны барыб кюрейек, алар ничек торалар икян, дигян. 37 Варнаванын ўзе белян Маркъ диб аталган Iоанны аласы килгян. 38 Äммя Павелъ äйткян: Бездян Памфиляда айырылганны, безнен белян без жибярелгян эшкя бармаганны ўзебез белян алмыйык, дигян. 39 Шулай итеб рянжешеў булган: шунӷар кюря алар берсеннян берсе айырылышканнар; Варнава Маркны алыб, сыу белян Кипрга киткян. 40 Павелъ, ўзен туганнар Алланын дяўлятеня табшыргач, Силаны сайлаб алыб киткян. 41 Ышаныучыларны ныкландырыб, Сирiяны да, Киликiяны да ўткян.

16-нчы бюлем

1 Ул Дервiяга, Листрага барыб житкян. Мына анда бер Тiмофей атлы öйрянеўче булган, анын анасы Христоска ышанган бер iудея кешесе икян, атасы еллинъ икян. 2 Листрада, Иконiяда тороучы туганнар бу Тiмофей турысында таныклык иткянняр. 3 Павелъ аны

ўзе белян алыб чыгарга келягян; аннары шул жирдя тора торган іудейляр сяятлеӈ анӈар киселеў жоласын кылган; бар да анын атасы еллинъ икянен беляляр икян. 4 Калалардан ўтеб жөрөб, алар ышаныучыларга Іерусалимдя апостоллар белян пресвитерлар куйганны кыларга äйтеб жөргянняр. 5 Шулай ышаныучылар ышанауда ныкланыб, көн сайын кюбяя килгянняр. 6 Фригіяне дя, Галатія жагын да ўткяч, Святыӈ Тын Асіяда сюз сөйлярга аларны ирек жибярмягян. 7 Мисіяга килеб житкяч, Вифиніяга барасы булганнар, тик Тын аларны ирек жибярмягян. 8 Мисіяны ўтеб китеб, Троадага төшкянняр. 9 Павелга төння кюренеў булган: бер Македонія кешесе анӈар инялеб äйтеб торган: Македоніяга барыб, безгя булышчы диб. 10 Шул кюренеўдян суӈ Ходаӈ быларга изге хабяр сөйлярга безне чакыра торгандыр диб уйлаб, шул сяттюк Македоніяга барасы булдык. 11 Шулаӈ Троададан чыгыб, без туры Самофракіяга, икенче көннө Неаполгя килдек. 12 Аннан Филиппыга килдек; Филиппы Македоніянын бу төшöндяге иӈ элекеге каласы, колонія. 13 Бу калада без бер ауык көн тордок. Суббота көннө без кала читеня сыу буйына чыктык; мында гадятчя келяў итя торган öй бар ыйы; шунда жыйылыб торган катыннар белян сöйляшеб утырдык. 14 Фіатира каласыныкы, Алланы кадерляўче, асыл кейемнек сатыучы бер Лидія атлы катын тыӈнаб тордо; Павелъ сöйлягян сюзлярга бик иӈ салыб торорга Ходаӈ анын кюӈелен ачкан икян. 15 Ул да, анын бар öйдягеляре дя чумылгач, безгя инялеб äйтте: Сез мине Ходайга ышаныучыга куйсагыз, минем öйöмя кереб торогоз диб безне кюндерде.

Зач.38 16 Бер табкыр без келяў öйöня барган чакта, алдагын äйтеўче бер кызмятче кыз безгя очорады; ул алдагын äйтеўе белян эяляреня кюб табыш китеря икян. 17 Павелъ белян безнен арттан ул былаӈ диб кычкырыб барды: Бу кешеляр жугарыгы Алланын мяндяляре, алар безгя котолоу жулын сöйлöйляр, диб. 18 Ул кюб көннө шулаӈ кылды. Павелнын ачыуы килеб, боролоб, женгя äйтте: Іисусъ Христосъ исеме белян сиӈа аннан чыгарга кушамын, диде. Жен шул сяттюк чыкты. 19 Шуннан суӈ анын эяляре табыш-

ланырга ӧмӧтляре ӧзӧлгянне кюреб, Павелъ белян Силаны тотоб алыб, иркен урынга башлыклар жанына ӧстряб алыб киттеляр. 20 Аларны тюрялярга алыб килеб ӓйттеляр: Бу кешеляр, іудейляр, безнен каланы болгаталар. 21 Без Римъ кешеляреня ӧйрянергя дя, кыларга да тейеш тӧгӧл жолаларны сӧйлӧйляр диб. 22 Калык та аларга карышы тордо; тюряляр аларнын кейемнярен жыртказлаб, аларны таяк белян кыйнарга куштылар. 23 Аларга кюб табкыр суккач, ӧтӧрмян карауылчысына нык сакларга кушыб, аларны ӧтӧрмянгя жабтылар. 24 Шундый бойорок алгач, ул аларны ӧтӧрмяннен эчке бюлмясеня кертеб жабкан да, аякларын тумранга беркеткян. 25 Тӧн уртасы чоронда Павелъ белян Сила теляк итеб, Алланы даннаб жырлаганнар; быгаудагылар аларны таннаб торганнар. 26 Кинят бик каты жир титрягян, ӧтӧрмяннен нигезляре селкенгян. Шул сяттюк бар ишекляр ачылган, барысынын да быгаулары бушаган. 27 Ӧтӧрмян карауылчысы уяныб, ӧтӧрмяннен ишекляре ачык икяннне кюреб, быгаудагылар качканнардыр диб уйлаб, кылычын чыгарыб, ӱзен ӱзе ӱтерергя келягян. 28 Тик Павелъ каты ауаз белян кычкырган: Ӱзеня бер усаллык та кылма, без барыбыз да мында диб. 29 Карауылчы ут сораб ӧтӧрмянгя жӧгӧрӧб кергян дя, калтраб, Павелъ белян Силанын аяк астына жыгылган. 30 Аннары аларны тышка чыгарыб ӓйткян: Эй кадерлеляр! Котолор ӧчӧн мин неӣ кылыйым? дигян. 31 Алар ӓйткянняр: Ходаӣ Іисусъ Христоска ышан, син дя, ӧйӧндягеляр барысы да котолорсоз, дигянняр дя, анӑр да, ӧйӧндягеляренен барысына да Ходаӣ сюзен сӧйлягянняр. 33 Тӧннӧн шул сагатендя ул аларны алыб, аларнын бар жараларын жыуган да, ӱзе дя анын бар ӧйӧндягеляре дя тизюк чумылганнар. 34 Аларны ӱз ӧйӧня алыб менеб, аш ӓзерлягян, Аллага ышаныуына ӧйӧндягелярнен барысы белян сӧйӧнӧшкянняр. 35 Кӧн башлангач, тюряляр теге кешелярне жибярсен диб ӓйтергя кала кызмятчелярен жибяргянняр. 36 Ӧтӧрмян карауылчысы бу сюзляр турында Павелга хабяр иткян: Тюряляр сезне чыгарырга диб жибяргянняр, инде айса чыгыб тынычлык белян китегез, дигян. 37 Павелъ аларга ӓйткян:

Без Римнен затлы кешелярен хокӧм кылмыйчы, калык алдында кыйнаб, ӧтӧрмянгя жабтылар, казер инде жяшертен чыгаралар менеӥ? Жук, килеб безне ӱзляре чыгарсыннар, дигян. 38 Кала кызмятчеляре бу сюзлярне тюряляргя ӓйткянняр; тюряляр, былар Римъ кешеляре икянне эшеткяч, курыкканнар. 39 Аннары килеб, безне айыбламагыз инде диб, аларны чыгарыб, каладан китяргя ӱтенгянняр. 40 Алар ӧтӧрмяннян чыгыб, Лидіяга килеб кергянняр; туганнарны кюреб, аларны сӧйӧндӧрӧб киткянняр.

17-нче бюлем

Зач.39 1 Алар Амфиполь белян Аполлонія дигян калаларны ӱтеб, Фессалоникага килгянняр; анда іудейлярнен синагогасы бар икян. 2 Павелъ ӱз гадятенчя алар катына кергян дя аларга ӧч субботада изге жазыулардан сӧйлягян. 3 Христоска азабланырга, ӱлгяненнян терелеб тороргa тейешле эйе, бу мин сезгя сӧйлӧй торган Іисусъ шул Христосъ диб аларга айырмачык ӓйтеб кюрсяткян. 4 Аларнын кайсылары, Алланы санный торган еллиннарнын да бик кюбесе, затлы катыннарнын да байтагысы ышаныб, Павелъ белян Силага кушылганнар. 5 Ышанмаган іудейлярнен кӧнчӧлӧкляре килеб, урамдагы жаман ӓшяке кешелярнен кайсыларын алыб, бергя жыйылышыб, кала кешелярен котортканнар; Іасонъ ӧйӧ жанына килеб, Павелъ белян Силаны калык катына чыгарырга эзлягянняр; 6 Аларны табмагач, Іасонны, туганнарнын да кайсыларын кала башлыкларына östряб алыб киткянняр; бу бӧтӧн дӧньяне аздырыучылар мында да килгянняр; 7 Іасонъ аларны кабыл алган; ӓммя алар барысы да бютян кешене, Іисусны падша диб, кесарнен кушканына карашылык итяляр диб кычкырышканнар. 8 Мыны эшеткян калык та, кала башлыклары да болганышканнар. 9 Тик, Іасонъ да, бютянняр дя сӧйлягян буйынча, башлыклар аларны жибяргянняр. 10 Туганнар озакламыйчы, шул тӧннюк Павелъ белян Силаны Веріяга жибяргянняр; алар анда килеб, іудейлярнен синагогасына киткянняр. 11 Мындагылар Фессалониклардан жакшы кюнеллеряк икян; алар бу дӧрӧс шулай микян

диб, кӧн сайын изге жазыуларны, шуларны тикшереб сӧйляӳне кюнӷелдян кабыл алганнар. 12 Аларнын кюбесе, еллиннарнын затлы катыннары да, ирляре дя байтагысы ышанганнар. 13 Верія да Павелъ Алла сюзен сӧйлягянне Фессалоника іудейляре белгяч, анда да килеб, калыкны котортоб болгатканнар. 14 Шуннан суӈ туганнар Павелны шул сяттюк дингезгя таба жибяргянняр; Сила белян Тімофей шунда калганнар. 15 Павелны озатыучылар аны Афиныга тикле алыб барганнар да, Сила белян Тімофейгя анын катына бик тиз килсенняр диб äйтергя бойорок алыб киткянняр.

Зач.40 16 Афиныда аларны кӧтӧб торган чакта, Павелнын бу сыннар белян тулган каланы кюреб жаны рянжеб торган. 17 Ул синагогада іудейляр белян дя, Алланы саннаучылар белян дя, урамда очорашыучылар белян дя кӧн сайын сӧйляшкян. 18 Епикурейскій, стоическій философлар диб атала торган белемне кешелярнен кайсылары анын белян сюзгя киля башлаганнар. Кайсылары: Бу буш сюзле неӈ äйтергя келеӈ? дигянняр; бютянняре: ул чит аллалар турысында сӧйляӳче бугаӈ диб äйткянняр, ул аларга Іисусь турысында, терелеб тороу турысында изге хабяр сӧйлягян икян. 19 Аны алыб, Ареопагъ дигян урынга китереб, äйткянняр: Бу син сӧйлӧӈ торган жаӈа ӧйрянеӳнен неӈ икянен без беля алырбыз мы? диб. 20 Син безнен колакларыбызга сяйер нястя эшеттерясеӈ, шунар кюря без мынын неӈ икянен белясебез киля, дигянняр. 21 Афины кешеляре барысы да, анда тороучы чит кешеляр дя, бер-бер жаӈа нястяне сӧйляб, жя тыннаб багыт ӳткяреӳне бик жараталар икян. 22 Павель Ареопагъ уртасында тороб äйткян: Эй Афины кешеляре! Мин сезнен бигеряк тя Алланы кадерляӳче икянегезне бар турыдан да кюрямен. 23 Мин ӳтеб, сезнен кадерле урыннарыгызны караштырыб жӧргян чакта, билгеле тӧгӧл Аллага диб жазылган корман урнығызны да очраттым. Мына шушы сез белмягян кӧйӧ кадерлеӈ торган Алланы мин сезгя сӧйлӧймен. 24 Дӧньяне дя, анда неӈ бар барын да булдырган Алла, Ӳзе кюкнен дя, жирнен дя Ходайы булганга кюря, кул белян салмаган келяӳ ӧйлярендя тора.

25 Ул бер-бер нястя киряксенгян
кюк, кеше кулынын кызмятен ки-
ряксенмей, ӓммя Ӱзе барысына
да терелек тя, сулау да, барын да
биря. 26 Бӧтӧн жирнен жӧзӧндя
тороргa диб, Ул бар ӓдям затын
бер каннан чыгарган; аларнын
торорона багытларны да, чикляр-
не дя алдан куйган, 27 Ул безнен
ӓр-кайсыбыздан жырак булма-
ганга кюря, алар Аны эзлясен-
няр, табсыннар, кюнелляре бе-
лен тойсоннар диб. 28 Без Анын
арткылы тере торабыз, кузгалыб
та жӧрӧйбез, бар булыб та тора-
быз, терелек тя итябез шул; шу-
лай сезнен стихлар тӧзӧӱчеляре-
гезнен дя кайсылары ӓйткянняр:
Без Анын заты да, диб. 29 Инде
айса без Алла заты була тороб,
Аллалыкны кеше ӱз осталыгын-
нан, ӱз уйыннан ошатыб жасаган
алтынга, жя кӧмӧшкя, жя ташка
ошаулы диб уйларга тейеш тӧгӧл.
30 Алай булгач инде, белемсезлек
багытларын калдырыб, Алла ка-
зер кешелярнен барысына бар
тӧштя дя тяӱбягя килергя куша. 31
Ул алдан белгертеб куйган кеше-
сен ӱлгяненнян терелтеб торгозоб,
Анар барысын да ышандырыб,
Анын арткылы дӧньядягелярга
дӧрӧс хокӧм итясе кӧнӧн куйган
шул, дигян. 32 Ӱлгянняр терелеб
торасыны эшеткяч, кайсылары
мыскыл итеб кӧлӧшкянняр, бю-
тянняре: Бу турыда сине бютян
чакта тыннарбыз, дигянняр. 33
Шуннан ары Павелъ алар ара-
сыннан чыккан. 34 Кайсылары
анар эяреб, ышанганнар; алар ара-
сында Ареопагъ кешесе Діонисій
дя, Дамарь атлы катын да, алар
белян бютянняр дя булганнар.

18-нче бюлем

1 Мыннан суң Павелъ Афи-
ныдан китеб, Коринфка килгян.
2 Клавдій падша бар іудейлярга
Римнян китярга кушканныктан,
мында Италіядан кюбтян тӧгӧл
гня бер Понтъ кешесе, Акила
атлы іудей, анын катыны При-
скилла килгянняр икян; быларн
ны табыб, Павелъ аларга килеб
кергян. 3 Ӱняре аларныкы белян
бер тӧрлӧ булганга кюря, аларда
калыб, эшляб торган; аларнын
ӱнярляре чатыр жасау булган. 4
Суббота сайын синагогада сӧй-
ляб, іудейлярне дя, еллиннарны
да ӧйряткян. 5 Сила белян Ті-
мофей Македоніядан килгяч, іу-
дейлярга Іисусны Христосъ диб

таныкларга Павелнын тыны аны бик кыстаган. 6 Алар карышылык итеб усал сюзляр äйткяч, ул ўз кейемнярен селкеб, аларга äйткян: Ўз каныгыз ўз башыгызга; мин таза, мыннан былай жалган деннелярга барам, дигян. 7 Аннан китеб, Алланы саннаучы бер Іустъ атлы кешенен öйöня килгян; анын öйö синагога жанында икян. 8 Синагога башлыгы Криспъ ўзенен бар жорто белян Ходайга ышанган; Коринфъ кешеляренен дя кюбесе тынһаб ышаныб, чумылганнар. 9 Ходай тöння Павелга кюренеб äйткян: Курыкма, сöйля, туктама: 10 Мин синең белян, шунныктан сиңа беряў дя усаллык кылмас; бу калада Минем кешелярем кюб, дигян. 11 Алар арасында Алла сюзен сöйляб, ул бер жыл да алты ай торган. 12 Шул арада Ахаія жирендя башлык булыб Галліонъ торган чакта, іудейляр бер киняштя булыб, Павелга жабышканнар да, аны хокöм урны алдына китергянняр. 13 Ул Алланы законда кушмаганча кадерлярга кешелярне öйрятя диб äйткянняр. 14 Павелъ жауабка ауызын ачарга торган чакта, Галліонъ іудейлярга äйткян: Эй іудейляр! Äгяр бер-бер тöрлö дöрöссöзлöк, жя усал уй булса, мин сезне тынһарга сябяб табар ыйым. 15 Ämмя жиһешеў, öйрятеў турысында, исемняр турысында, законыгыз турысында булгач, ўзегез тикшерегез: быларга минем хокöмче буласым килмей, дигян. 16 Аннары хокöм урны жаныннан аларны кыуыб жибяргян. 17 Еллиннар барысы да синагога башлыгы Сосфенны тотоб, хокöм урны алдында кыйнаганнар; Галліонъ бу турыда бер дя кайгырмаган. 18 Павелъ тагы байтак кöн торгач, туганнар белян бахилляшеб, адарынган буйынча, Кенхрейдя чячен кистереб, Сиріяга кимя белян киткян, анын белян Акила да, Прискилла да киткянняр. 19 Ефеска килеб житкяч, ул аларны анда калдырган; ўзе синагогага кереб, іудейляр белян сöйляшеб утырган. 20 Алар анар ўзляpендя озагырак тороpга ўтенгянняр, тик ул кюнмягян. 21 Алар белян бахилляшеб, аларга äйткян: Миңа килясе бяйрямне ничек булса да, Іерусалимдя ўткярергя тейеш; Алла бойорса, сезгя тагы кайтырмын, дигян дя Ефестан киткян; Акила белян Прискилла Ефеста калганнар.

Зач.41 22 Кесаріяга кереб чыккач, ул Іерусалимгя менеб, ышаныучылар жыйыны белян кюрешеб, Антіохіягя төшкян. 23 Анда бер ауык багыт ўткяргяч, аннан чыгыб, бар өйрянеўчелярне ныкландырыб, Галатія жагын да, Фригіяны да рятляб ўтеб жөргян. 24 Александріяда тыуган бер Аполлосъ атлы, сюзгя оста, жазыуны жакшы белеўче іудей Ефеска килгян. 25 Ул Ходай жулына өндялгян икян, шунар кюря ул Іоаннъ чумылдырыуын гна белся дя, Ходай турысында эч кюнеленнян кызыб айырмачык өйрятеб сөйлягян. 26 Ул синагогада кыйыуланыб сөйлөй башлаган. Аны эшетеб, Акила белян Прискилла аны кабыл алганнар да, анар Ходай жулын бигеряк айырмачык белдергянняр. 27 Ул Ахаіяга бармакчы булгач, туганнар андагы өйрянеўчелярга аны кабыл алырга димняб, жазыу жибяргянняр; ул анда килеб, ышаныучыларга дяўлят арткылы кюб булышкан. 28 Изге жазыудан Іисуснын Христосъ икянен кюрсятеб, бар калык алдында іудейлярне сюзе белян жинеб торган.

19-нчы бюлем

Зач.42 1 Аполлосъ Коринфта торган чакта, Павелъ жугарыгы жакларны ўтеб, Ефеска килгян; анда кайсы өйрянеўчелярне очратыб, 2 Аларга äйткян: Ышаныб, Святый Тынны алдыгыз мы? дигян. Алар анар äйткянняр: Без Святый Тын бар диб эшеткянебез дя жук, дигянняр. 3 Ул аларга äйткян: Сез суң ничек чумылдыгыз? дигян. Алар äйткянняр: Іоаннъ чумылдырыуы белян, дигянняр. 4 Павелъ äйткян: Іоаннъ кешелярга: минем артымнан Килеўчегя, Христосъ Іисуска ышансыннар диб äйтеб, тяўбягя китереў чумылдырыуы белян чумылдырган, дигян. 5 Мыны эшетеб, алар Ходай Іисусъ исеменя чумылганнар. 6 Аннары, Павелъ аларнын өсляреня кулларын салгач, аларга Святый Тын интян; алар төрлө телляр белян сөйляшеб, пагамбярлек итя башлаганнар. 7 Ней бары алар ун ике кешеляб булганнар. 8 Павелъ анда синагогага жөрөб, Алла падшалыгы турысында курыкмыйчы өйрятеб, ышанырлык итеб, өч ай сөйлягян. 9 Кайсылары, кюнел-

ляре катыланыб, калык алдында Ходай жулын жаманнаб ышанмаганга кюря, алардан китеб, ӧйрянеўчелярне айырыб алыб, кӧн сайын бер Тиранъ исемне кешенен ӧйрятя торган ӧйӧндя сӧйлягян. 10 Бу сӧйляўе ике жылга жакын булган; шунӈар кюря бӧтӧн Асіяда тороучылар, іудейляр дя, еллиннар да Ходай Іисусъ турысында сӧйляўне эшеткянняр. 11 Павелнын кулы арткылы Алла байтак кодрятляр кылган. 12 Шунӈар кюря чирлелярга анын тяненнян жаулыклар, бил баулары салганнар, салгач аларнын чирляре беткян, жаман тыннар да алардан чыкканнар. 13 Іудейлярнен женнярне кыуыб чыгарган булыб жӧрӧўчеляренен дя кайсылары усал тыннары бар кешелярга: Павелъ сӧйлӧй торган Іисусъ исеме белян сезгя чыгарга ӓйтябез диб, Ходай Іисусъ исемен ӓйтя башлаганнар. 14 Мыны іудейлярнен бер Скева исемне баш священникляренен жиде улы кылганнар. 15 Тик жаман тын жауаб биреб ӓйткян: Іисусны белямен, Павелъ да минӈа билгеле, сез кем сунӈ? дигян. 16 Жаман тыны бар кеше аларга атылыб жабышыб, аларны жинеб, аларга карышы шул катле кӧчяйгян: алар жалангач кӧйӧ, жараланыб, шул ӧйдян жӧгӧрӧб чыкканнар. 17 Бу бар Ефеста тороучы іудейлярга дя, еллиннарга да билгеле булган, аларнын барысына да куркыныч тӧшкян, Ходай Іисуснын исеме бик ололанган. 18 Ышаныучыларнын кюбесе килеб, ўз эшлярен ӓйтеб жяўлягянняр. 19 Сихырчелек итеўчелярнен байтагысы книгялярен жыйыб, барысы алдында жандырыб бетергянняр дя, аларнын бияляре исяблягянняр, ней бары илле мең кӧмӧшлек булган.

20 Ходайнын сюзе шул кадяр кыуатланыб арта килгян. 21 Бу эшляр булгач, кюнеленнян Македоніяны да, Ахаіяны да ўтеб, Іерусалимгя барасы булыб ӓйткян: Анда ӓзеряк торгач, минӈа Римне дя кюрергя тейеш, дигян. 22 Аннары анӈар булышыучыларнын икесен, Тімофей белян Ерастны Македоніяга жибяреб, ўзе бер ауык багытка Асіяда калган. 23 Шул багытта Ходай жулына карышы байтак болганышыу булган. 24 Бер Димитрій атлы кӧмӧшче Артемиданын келяў ӧйӧ шикелле кӧмӧш нястяляр жасаб, осталарга байтак табыш китереб тора икян. 25 Ул аларны да, шунын ише бютян

ўнярчелярне дя жыйыб äйткян: Эй дуслар! Безнен житеш тороуыбыз шушы ўнярдян икянне, сез белясез. 26 Äммя бу Павелъ кеше кулы белян жасала торган сыннар аллалар тögöл диб äйтеб, Ефеста гна тögöл, бötön Асіяда диб äйтерлек, байтак калыкны ышандырыб, ўзеня ауыштырганны сез кюрясез дя эшетясез дя. 27 Былай булса безнен ўняребез курга калыу гна тögöл, оло алла Артемиданын келяў öйö дя бер нястягя саналмаслык булыб калыр; алай гна тögöл, бötön Асія, дönья кадерлей торган аллабызнын ололого жукка чыгар, дигян. 28 Мыны эшеткяч, алар жарсыб, Ефеснын Артемидасы оло диб кычкырыша башлаганнар. 29 Болганган калык белян бötön кала тулган; Павелнын жулдашларын, Македонія кешелярен, Гаій белян Аристархны тотоб алыб, алар калык жыйыла торган урынга бергяляшеб кабаланыб киткянняр. 30 Павелъ калык арасына керергя келягяч, öйрянеўчеляре аны кертмягянняр. 31 Тагы шулай Асіядагы башлыкларнын да кайсылары анын дуслары, анар: калык жыйыла торган урынга барыб кюренмясен диб инялеб äйтергя жибяргянняр. 32 Ул арада кайсылары бер törlö, икенчеляре икенче törlö кычкырышканнар, жыйыннын ряте булмаган; кюбесе ней öчön жыйылганнарын да белмягянняр. 33 Іудейляр кюрсятеўе буйынча, калык арасыннан Александрны чакырыб чыгарганнар; Александръ кулы белян билге биреб, калык белян сöйляшясе булган. 34 Ул іудей икянне белгяч, Ефеснын Артемидасы оло диб барысы бер ауаз белян ике сагатляб кычкырыб торганнар, 35 рятне караб тороучы тюря калыкны тыйыб äйткян: Эй Ефесъ кешеляре! Ефесъ каласы оло алла Артемида белян Діопетка табынганны кем белмей? 36 Алай булгач, мыны бар да шулай диб белгяч, сезгя тынычланырга тейеш, бер дя акылсыз кылынырга тейеш тögöл. 37 Äммя сез Артемиданын келяў öйön дя таламаган, сезнен аллагызны да курламаган бу кешелярне тотоб китергянегез. 38 Äгяр дя Димитрійнен дя, анын белян бютян осталарнын да беряў-беряў östönнян жалыулары булса мынар хокöм урыннары да, тюряляр дя бар: бер-берсе östönнян шунда жалыуы бирсенняр. 39 Äгяр дя сез бютян бер-бер нястя

эзлясягез, ул эшкя законъ жыйынында хокӧм ителер.40 Бу жыйылыуыгызны дӧрӧслярга бер сябяб тя булмаганга кюря, без бӧгӧнгӧ жыйын аркасында болганыу ӧчӧн айыбланырлык булыб хатяр ялдя торабыз, дигян. Мыны яйтеб, ул жыйынны тараткан.

20-нче бюлем

1 Калык болганыуы басылгаднан суӈ Павелъ ӧйрянеӳчелярне чакырыб алыб, аларны ӳгетляб, алар белян бахилляшеб Македониягa барырга чыккан.2 Шул жакларны ӳтеб, ышаныучыларны кюб сюз белян ӳгетляб, Елладага килгян. 3 Ул анда ӧч ай торган; анар карышы иудейляр калыкны болгатканныктан, Сириягa китяргя торган чакта, анар Македония арткылы кайтырга уй тӧшкян. 4 Веріянын Пирръ исемне кешенен улы Сосипатръ, тагы Фессалоника кешеляре: Аристархъ белян Секундъ, Дервія кешесе Гаій, Тимофей дя, Асія кешеляре: Тихикъ белян Трофимъ аны Асіягa чаклы озата барганнар. 4 Алар алдан китеб, безне Троадада кӧтӧб тордолар. 5 Без тӧчӧ кюмяч кӧнняреннян суӈ Филиппыдан сыу белян китеб, биш кӧн эчендя аларга Троадага килдек; анда жиде кӧн тордок.

Зач.43 7 Атнанын элекеге кӧнӧндя, ӧйрянеӳчеляр жяшерек икмяген сындырырга жыйылгач, Павелъ иртягесен чыгыб китясе булыб, алар белян сӧйляшеб, жарты тӧнгя чаклы утырды. 8 Без жыйылган жугары бюлмядя жактырткычлар байтак ыйы. 9 Павелъ озак сӧйляб утырган чагында, бер Евтихъ атлы жегет, тярязя тӧбӧндя утырыб, каты жокога китеб, жоклаган кӧйӧ ауыб китеб, ӧйнӧӈ ӧчӧнчӧ катыннан тюбян жыгылыб тӧштӧ, аны ӳлгян кӧйӧ кютяреб алдылар.10 Павелъ тӧшӧб, анын ӧстӧня эйелеб, аны кочаклаб яйтте: Кумачауланмагыз, анын жаны эчендя шул, диде.11 Менеб, жяшерек икмяген сындырыб ашагач, таӈ аткынчы байтак багыт сӧйляде, аннары чыгыб китте.12 Шул арада малайны тере кӧйӧ алыб килделяр дя, байтак сӧйӧнӧштӧляр. 13 Без кимягя алдан килеб, сыу белян Ассъ дигян калага аннан Павелны аласы булыб киттек; ул ӳзе жяяӳ барасы булыб, безгя шулай кушкан ыйы. 14 Ул Ассъ каласында безгя

кушылгач, аны алыб Митилинага килдек. 15 Аннан сыу белян китеб, икенче көннө без Хіосъ атауы турысында туктаб тордок, иртягесен Самосъ атауына килеб туктадык, анда Трогиліяга кереб чыгыб, иртягесен Милитка килдек.

Зач. 44. 16 Ягяр мөнким булса, илленче көн бяйряменя Іерусалимдя булырга ашыкканга кюря, Павелъ Асіяда озакларлык булмасын диб, Ефеска кермей китяргя уйлады. 17 Милиттан Ефеска жибяреб, ул арыу жыйыннын пресвитерларын чакырыб алды. 18 Алар анар килгяч, ул аларга әйтте: Мин Асіяга килгяч тя элеке көнөмнянюк гел сезнен белян булганымны сез белясез; 19 іудейлярнен усал уйлары буйынча, мина туры килгян сыналыуларны кюреб, кюб кюз жяше койоб, жыуашланыб, Ходайга эшляб тордом; 20 пайдалы нястялярнен берсен дя, калык алдында, өйлярдя дя сезгя сөйлямейче, сезне өйрятмейче калдырмадым; 21 іудейлярга дя, еллинарга да Алла алдында тяүбяне, Ходайыбыз Іисусъ Христоска ышаныуны да әйтеб кюрсяттем; быларны барысын да сез белясез. 22 Мына мин инде казер, Тын тарткан буйынча, Іерусалимгя барам, анда мина ней очрасыны белмеймен. 23 Әммя Святый Тын мине быгау белян кайгылар көтя диб әйтеб, кала сайын таныклык итя. 24 Әммя мин бер нястягя дя карамыйым, үз тормошомны да кыйбатка куймыйым, тик Алла дяүлятенен изге хабярен сөйлягя Ходай Іисустан алган кызмятемне, бар эшляремне сөйөнөч белян кылыб житкезсям эйе дим. 25 Мына инде мин белямен: минем жөзөмне сез барыгыз да кюрмяссез, әммя мин сезнен арагызда жөрөб, Алла падшалыгын сөйлядем. 26 Шунар кюря бөгөнгө көннө барыгызнын каныннан мин таза икянемне сезгя таныклык итям; 27 Алланын бар иркен сезгя белдермейче калдырмадым шул. 28 Инде айса Ходай Алланын Үз каны белян табкан арыу жыйынын көтягя Святый Тын сезне көтөүчеляр итеб куйганга кюря, үзегезгя дя, көтөүегезгя дя аныгызны салыгыз. 29 Мин киткяннян сун, сезнен арага көтөүне кызганмый торган жаман бюреляр керерляр, мин мыны белямен. 30 Сезнен үз арагыздан да, үзляреня өйрянеүчеляр эяртеб алыр өчөн, бозок сюзляр сөйляүчеляр

чыгар. 31 Шунар кюря минем öч
жыл сезнен äр-берегезне кюз
жяшлярем белян кön-тön тукта-
мыйчы öйряткянемне истя тотоб,
уяу торогоз. 32 Äле дя, эй тугган-
нар, сезне Аллага табшырамын,
Анын дяўлятле сюзе сезне бигряк
тя öйрятеб, арыуланганнарнын
барысы белян бергя сезгяölöш
бирер. 33 Кömöш тя, алтын да,
кейем дя мин беряўдян дя телямя-
дем. 34 Минем кирякляремя, ми-
нем белян торганнарнын киряк-
ляреня дя минем шушы кулларым
кызмят иткянне ўзегез белясез. 35
Шулай тырышыб, älсезлярга бу-
лышырга, Ходай Iисуснын сюз-
лярен истя тотарга тейеш икянне,
мин сезгя бар турдан да кюрсят-
тем: Ул Ўзе äйткян шул: Алыудан
бигряк биреў бахетлеряк, диб. 36
Мыны äйткяч, ул тезлянеб, алар-
нын барысы белян теляк итте. 37
Шул чакта барысы да кюб жы-
лаштылар, Павелнын муйына
асылыныб, аны ўбеб тордолар. 38
Алар минем жözömне инде кюр-
мяссез диб аларга äйткян сюзеня
бигеряк köйöндöляр. Аннары аны
кимягя чаклы озата бардылар.

21-нче бюлем

1 Без алар белян айырыл-
лышыб, сыу белян киткяч, туры
барыб, Косъ каласына, икенче
könnö Родосъ атауына, аннан Па-
тарага килдек. 2 Аннан Финикія-
га бара торган кимя табыб, анар
кереб, сыу белян киттек. 3 Кипръ
кюренгяч, аны сулда калдырыб,
Сиріяга сыу белян бардык та,
Тиръ каласында туктадык: анда
кимядян жök бушатасы ыйы шул.
4 Öйрянеўчелярне табыб, анда
жиде кön тордок; алар Тын бел-
дерткян буйынча, Павелга Iеру-
салимгя бармаска äйттеляр. 5 Бу
könнярне ўткяргяч, без мыннан
чыгыб киттек, безне барысы да
катыннары-балалары белян ка-
ладан чыккынчы озата бардылар;
жар буйында тезлянеб теляк ит-
тек. 6 Аннары бер-беребез белян
бахилляшкяч, без кимягя кердек,
алар öйляреня кайтыб киттеляр.
7 Без Тирдан сыу белян китеб,
Птолемаидага килеб туктадык,
анда туганнар белян кюрешеб,
аларда бер кön тордок.

Зач.45 8 Иртягесен Павелъ
да, анын белян булганнар без дя
чыгыб, Кесаріяга килдек; анда
изге хабяр сöйляўче жиде діа-
коннын берсе Филиппнын öйöня

кереб, анда тордок. 9 Анын пагамбярлек итеўче дюрт кызы бар ыйы. 10 Без аларда кюб кöнняр торган арада, Іудеядан бер Агавъ атлы пагамбяр килде. 11 Безгя килеб, Павелнын эзярен алыб, ўзенен кулларын, аякларын бяйляб äйтте: Святый Тын былай äйтя: бу эзярнен эясен Іерусалимдя іудейляр шулай бяйлярляр дя, жалган деннеляр кулына табшырырлар, диде. 12 Мыны эшеткяч, без дя андагылар да Павелга: Іерусалимгя барма диб ўтендек. 13 Павелъ жауаб биреб äйтте: Сез неў эшлейсез, жылаб ник минем жöрягемне кайгыртасыз? Мин бяйлянеў гня тöгöл, Ходаў Іисусъ исеме какына Іерусалимдя ўлярга дя äзер шул, диде. 14 Аны димняб кюндеря алмагач, без Ходаў ирке булсын диб äйтеб, дяшмядек. 15 Бу кöннярдян суң без äзерлянеб Іерусалимгя киттек; 16 Кесаріядан да öйрянеўчелярнен кайсылары без кереб тороргa мöнким булырлык бер кюбтянге öйрянеўче Кипръ кешесе Мнасонга безнен белян бергя безне алыб бардылар. 17 Без Іерусалимгя килгяч, туганнар безне сöйöнöч белян кабыл алды. 18 Икенче кöннö Павелъ безнен белян Іаковка керде; пресвитерлар да барысы да килделяр. 19 Алар белян кюрешеб, Павелъ жалган деннелярдя анын кызмяте арткылы Алла неў кылганны äр-кайсын берян-берян рятляб äйтте. 20 Алар тыңнаб алыб, Алланы даннадылар да, анар äйттеляр: Эй туган, іудейлярнен ышанганнары неў кадяр мең икянне кюрясен; алар барысы да законга биренгян кешеляр. 21 Алар синең турында жалган деннеляр арасында тороучы бар іудейлярне, алар ўз балаларын кисмясенняр, жолаларынча кылынмасыннар диб äйтеб, син Моисейдян бизяргя öйрятясең диб эшеткялягянняр. 22 Алаў булгач, неў эшлярга киряк суң? Син килгянне эшетеб, калык жыйылмыў калмас. 23 Без сиңа äйтя торганны кыл äле: Бездя ўз öсляреня адарыныу алган дюрт кеше бар. 24 Аларны алыб, алар белян тазарын да, алар чячлярен кистерсенняр, алар öчöн китерясе корманнын чыгышын ўз öстöня ал; шуннан синең турында эшеткянняренен дöрöс тöгöл икянен, äммя синең законны саклаб тороуынны барысы да белерляр. 25 Ышанган жалган деннеляр турысында без: алар шундыў эшлярне бер дя кылмасыннар диб,

тик сын корманыннан, каннан, быуыб ӳтерелгяннян, уйнашлыктан ӳзлярен сакласыннар диб куйыб жаздык, дигянняр.

Зач. 46 26 Шул чакта Павелъ теге кешелярне алыб, алар белян тазарынышыб, икенче кӧннӧ келяӳ ӧйӧня кергян дя анда тазарыныу кӧнняренен кайчан бетеӳе турысында хабяр иткян, ул кӧннӧ ӓр-берсе ӧчӧн корман китерергя тейеш икян. 27 Жиде кӧн тулыб житясе чакта, Асія іудейляре, аны келяӳ ӧйӧндя кюреб, бар калыкны болгатканнар да, аны куллары белян тотоб алыб, 28 кычкырышканнар: Эй Израиль кешеляре, булышыгыз! Бу кеше калыкка да, законга да, бу урынга да карышы барысын да ӓр-бер жирдя ӧйрятя; ул гна тӧгӧл, тагы еллинларны да келяӳ ӧйӧня алыб кереб, бу арыу урынны шакшыландырган, дигянняр. 29 Мыннан элгяре алар анын белян калада Ефесъ кешесе Трофимны кюргянняр икян, аны Павелъ келяӳ ӧйӧня алыб кергяндер диб уйлаганнар икян. 30 Бӧтӧн кала кузгалган, калык жыйылышкан; Павелны тотоб алыб, аны келяӳ ӧйӧннян тышка ӧстряб чыгарганнар да, шундук ишеклярне биклягянняр. 31 Алар аны ӳтерергя келягяч, бӧтӧн Іерусалимъ болганды диб полкнын мең кеше башлыгына хабяр житкян. 32 Ул шул сяттюк салдатларны да, жӧз кеше башлыкларын да алыб, аларга таба ашыгыб килгян; алар мең кеше башлыгын да, салдатларны да кюреб, Павелны кыйнаудан туктаганнар. 33 Шул чакта мең кеше башлыгы жакыннашыб, Павелны тотоб алган да, ике чылбыр белян быгауларга кушыб, сораган: Кем ул, ней кылды? дигян. 34 Калык арасында кайсылары бер тӧрлӧ, икенчеляре икенче тӧрлӧ кычкырышыб торганнар; болганыу буйынча, ул айырмачыгын беля алмагач, крепостькя алыб барырга кушкан. 35 Павелъ баскычта чагында, калык кыскан буйынча, салдатларга аны кютяреб барырга туры килгян. 36 Бик кюб калык ул ӳтерелсен диб кычкырышыб барганнар. 37 Крепостькя кергян чакта, Павелъ мең кеше башлыгына ӓйткян: Мин сина бер нястя ӓйтергя жарый мы? дигян. Теге ӓйткян: Син грекчя белясең меней? 38 Бу кӧннярдян элекеряк калыкны болгатыб, буш кырга дюрт мең талаучы кешелярне алыб чыгыучы Египетъ кешесе

син ме ӓлля? дигян. 39 Павелъ ӓйткян: Мин іудей, Киликіянын билгеле каласы Тарсъ кешесе; сиңа инялямен, калыкка сӧйляргя миңа роксят итче, дигян. 40 Ул роксят иткяч, Павелъ баскычта тороб, калыкка кулы белян билге биргян; тыб тыныч булыб киткяч, еврей теленчя былай диб ӓйтя башлаган:

22-нче бюлем

Зач.47 1 Эй кадерле туганнар, эй аталар! Казер сезнен алдыгызда минем ӱземне ӱзем дӧрӧсляӱемне тыңнагыз! дигян. 2 Ул алар белян еврей теленчя сӧйляшя башлаганны эшеткяч, алар тагы да бигеряк тынычланганнар. 3 Шунда ул ӓйткян: Мин Киликія каласы Тарста тыуган, іудей кешесе, ул калада Гамаліилъ кулында ӧйрянеб ӱскян кеше, аталарыбызнын законына нык ӧйрятелгян, казер сезнен барыгыз кюк, Алла ӧчӧн тырышыучы кеше; 4 мин ул ӧйрятеӱне тотоучыларны, ирлярен дя катыннарын да бяйляб, ӧтӧрмянгя биреб, ӱлярлек итеб, кыудым. 5 Шулай минем турда баш священникъ тя, бар башлыклар да таныклык итяляр; мин алардан жазыу алыб, Дамаскта тороучы христіаннарны бяйляб, Іерусалимгя азабларга алыб килясе булыб, андагы туганнарга бардым. 6 Мин барган чакта, Дамаскка жакыннашкач, кӧн уртасы тирясендя мине кинят кюктян зур жакты жактыртты. 7 Мин жиргя жыгылдым да, миңа: Эй Савлъ, Савлъ! Ник син Мине кыуасын? диб ӓйткян ауаз эшеттем. 8 Мин жауаб бирдем: Эй Ходай, Син кем? диб. Ул миңа ӓйтте: Мин син кыуа торган Назорей Іисусъ, диб. 9 Минем белян барыучылар жактыны кюрделяр дя куркыштылар, тик миңа Ӓйтеӱченен ауазын эшетмяделяр. 10 Шул чакта мин ӓйттем: Эй Ходай! Неӥ кылыйым? диб. Ходай миңа ӓйтте: Тороб, Дамаскка бар, анда сиңа неӥ кыларга киряк не барысын да ӓйтерляр, диде. 11 Мин шул жактынын жалтрауыннан кюрмяс булганга кюря, минем белян барыучылар мине кулымнан житякляб Дамаскка иттеляр. 12 Бер Ананія атлы кеше, законча арыу тормошло, Дамаскта тороучы іудейляр барысы да жакшыга саный торган кеше, 13 миңа килеб, жакыннашыб, миңа ӓйтте: Эй

туган Савлъ! Кюря торган бул! диб. Мин шул сяттюк аны кюря башладым. 14 Ул мина әйтте: Безнен аталарыбызнын Алласы, син Анын иркен белсен дя, Изгене кюрсен диб, Анын ауызынын ауазын ашетсен диб, сине алдан сайлады. 15 Син ней кюргяненя дя, эшеткяненя дя бар кешеляр алдында Анар таныкчы булырсың шул. 16 Алай булгач, инде ник озаклыйсың? Тороб, чумыл да, Ходай Исусъ исемен теленя алыб, ўз жазыкларынны жыу, диде. 17 Мин Ерусалимгя кайткач, келяў өйөндя теляк иткян чагында, мина зур куркыныч төштө; 18 мин анын Ўзен кюрдем: Ул мина: Ашыгыб, тиз Ерусалимнян чык; мында Минем турымда синең таныклауынны кабыл алмаслар диде. 19 Мин әйттем: Эй Ходай! Мин Сина ышаныучыларны өтөрмянгя жабканымны, синагогаларда кыйнаганымны алар ўзляре беляляр. 20 Аннары Синең таныкчың Стефаннын каны тюгелгян чакта, ўзем дя анда тороб, анын ўтерелеўен дя жаратыб, ўтереўчелярнен кейемнярен саклаб торганымны да беляляр, дидем. 21 Шунда Ул мина әйтте: Бар, Мин сине жалган деннеляргя жырак жибярермен, диде. 22 Бу сюзеня чаклы аны тынңаганнар; аннары ауаз кютяреб кычкырышканнар: Мындый кешене жирдян бетер, анар тороргa да тейеш төгөл, диб. 23 Алар кейемнярен ташлаб, ауага тузан чөйөб, кычкырган арада, мең кеше башлыгы, аны крепостькя алыб керергя кушкан, анар карышы нейдей сябяб белян кычкырышканнарын белер өчөн, анда аны кыйнарга кушкан. 25 Аны кайышлар белян бәйляб сузыб жаткыргач, Павелъ шунда тороучы жөз кеше башлыгына әйткян: Сезгя хокөм кылмыйчы, Римнен затлы кешесен кыйнарга мөнким ме? дигян. 26 Мыны эшетеб, жөз кеше башлыгы, жакын килеб, мең кеше башлыгына: Кара, син ней кыласы буласың? Бу кеше Римнен затлы кешесе ич, диб хабяр иткян. 27 Шул чакта мең кеше башлыгы жакын килеб, Павелга әйткян: Әйтче мина, син Римнен затлы кешесе ме? дигян. Ул: Эйе, дигян.

28 Мең кеше башлыгы жауаб биргян: Мин ул затлы исемне кюб акчага алдым, дигян. Павелъ әйткян: Мин тыумыштанук шундый кеше, дигян. 29 Шуннан суң аны кыйнарга келяўчеляр шул сяттюк аннан чигенгян-

няр; әммя мең кеше башлыгы, ул Римнен затлы кешесе икянен белгяч, аны бяйлягяненя курыккан. 30 Иртягесен іудейляр аны нейлектян айыблаганнын дөрөсөн белясе килеб, аны быгаудан чишкян дя, баш священниклярга дя, бөтөн синедріонга да жыйылырга кушыб, Павелны алыб чыгыб, алар алдына куйган.

23-нче бюлем

1 Павелъ синедріонга караб әйткян: Эй кадерле туганнар! Мин бу көнгя чаклы бар арыу кюнелем белян Алла карышысында тордом, дигян. 2 Архіерей Ананія анын алдында тороучыларга анын ауызына сугарга кушкан. 3 Шунда Павелъ әнар әйткян: Эй буяган койма! Сине Алла кыйнар; син мина законча хокөм итярга утырасың, әммя үзең законга карышы мине кыйнарга кушасың, дигян. 4 Анда тороучылар әйткянняр: Алланын архіерейен курлыйсың меней? дигянняр. 5 Павелъ әйткян: Эй туганнар, ул архіерей икянен мин белмядем; изге жазыуда да жазылган шул: калыгынның башлыгына жаман сюз әйтмя диб, дигян. 6 Павелъ андагыларнын бер өлөшө саддукейляр, икенче өлөшө фарисейляр икянен белеб, синедріонда каты ауаз белян әйткян: Эй кадерле туган! Мин фарисей, фарисей улы; үлгянняр терелеб торорлар диб өмөт тотканга мина хокөм итяляр, дигян. 7 Ул мыны әйткяч, фарисейляр белян саддукейляр арасында даулашыу чыккан, жыйыннары икегя айырылган. 8 Саддукейляр терелеб тороу да, пяриштя дя, тын да жук дейляр икян, әммя фарисейляр тегесе дя, мынысы да бар диб әйтяляр икян. 9 Каты кычкырыш чыккан; фарисейляр жагындагы книгячеляр тороб даулашыб әйткянняр: Бу кешедя без бер төрлө усаллык та табмыйбыз; әгяр анар тын, жя пяриштя әйткян булса, Аллага карышылык итмябез, дигянняр. 10 Даулашыу бик көчяйгяч, мең кеше башлыгы, алар Павелны өзгяляб бетермясенняр диб куркыб, салдатларга аны алар уртасыннан төшөб алыб, крепостькя итярга кушкан. 11 Шул төннө Ходай анар кюренеб әйткян: Эй Павелъ, ныктор, син Іерусалимдя Минем турда таныклык иткян кюк, шулай сина Римдя дя таныклык итярга

тейеш шул, дигян. 12 Кӧн танатыу белян кайсы іудейляр усал уй тотоб, Павелны ӱтермейче ашамабыз да, эчмябез дя диб карганышканнар. 13 Шундый карганыучылар кырыктан да артык булганнар. 14 Алар архіерейлярга дя, башлыкларга да килеб йткянняр: Без Павелны ӱтермейче бер нястя дя ашамабыз диб ант итеб карганыштык. 15 Инде айса сез бӧтӧн синедріонъ белян казер мең кеше башлыгына анын турындагы эшне айырмачыгырак тикшерясе булган булыб, иртягя аны сезнен катка алыб чыгарга йтегез; без аны, ул килеб житкенче ӱтерергя язер, дигянняр. 16 Бу уй турысында Павелнын сеңнесенен улы эшетеб килгян дя крепостькя кереб, Павелга белдергян. 17 Павелъ жӧз кеше башлыкларынын берсен чакырыб йткян: Бу жегетне мең кеше башлыгына алыб барчы, анын анар йтясе сюзе бар, дигян. 18 Ул аны мең кеше башлыгы жанына алыб килеб йткян: Быгаудагы Павель, мине чакырыб, бу жегетне сина итяргя ӱтенде, анын сина йтясе сюзе бар, дигян. 19 Мең кеше башлыгы аны кулыннан житякляб, анын белян читкяряк китеб, аннан сорашкан: Синең мина ней йтясең бар? дигян. 20 Ул жауаб биргян: Іудейляр анын эшен айырмачыгырак тикшерясе булган булыб, син иртягя Павелны синедріонъ алдына чыгарсын диб, синнян сорарга киняш иттеляр; 21 тик син аларны тыңнама; алар арасыннан кырыктан да кюберяк кеше аны саклыйлар, алар аны ӱтермейче ашамаска да, эчмяскя дя карганыштылар; казер дя синең кушыуынны кӧтӧб язер торалар, дигян. 22 Шунда мең кеше башлыгы, мыны мина жяӱлягяненне беряӱгя дя йтмя диб йтеб, жегетне жибяргян. 23 Аннары жӧз кеше башлыкларынын икесен чакырыб алыб йткян: Мина ике жӧз жяяӱле салдат, житмеш атлыны, ике жӧз ук атыучыны язерлягез, алар тӧннӧн ӧчӧнчӧ сагатендя Кесаріяга барсыннар. 24 Павелны атландырыб Феликсъ атлы оло башлыкка озатыб жибяргя ишякляр дя язерлягез, дигян. 25 Аннары былай диб жазыу да жазган: Клавдій Лисій оло кадерле башлык Феликска сӧйӧнӧч телей! 27 Бу іудейляр тотоб алыб, ӱтерясе булган кешене, ул Римнен затлы кешесе икянен белгяч, мин салдатлар белян килеб, аны айырыб алдым; 28 Аннары аны ней

турыдан айыблаганнарын белясем килеб, аны аларнын синедріонына китердем. 29 Ӱз законнары турысында даулаша торган сюз өчөн аны айыблаганнарын, әммя анын ӱлемгя, жя быгауга тейешле бер айыбы да жук икянен белдем. 30 Іудейлярнен бу кешегя карышы усал уй тотканнары миңа житкяч, айыблаучыларга да анын өстөннян синең алдында әйтергя кушыб, мин аны тизюк сина жибярдем. Сау бул инде, дигян. 31 Шулай итеб салдатлар, ӱзляреня кушылган буйынча, Павелны алыб төння Антипатридага киткянняр. 32 Икенче көннө аны атлы салдатларга алыб барырга табшырыб, ӱзляре крепостькя кайтканнар. 33 Тегеляр Кесаріяга килеб, оло башлыкка жазыуны биреб, Павелны анын алдына китергянняр. 34 Башлык жазыуны укыб, Павелнын кайсы илнеке икянен сораган да, Киликіянықы икянен белгяч, әйткян: Айыблаучыларың килеб житкяч, мин сине тыннаб алырмын, дигян. Аннары Иродъ преторіясында карауылда тороргa кушкан.

24-нче бюлем

1 Биш көннян суң архіерей Ананія бютян башлыклар белян, тагы бер сюзгя оста кеше Тертуллъ белян килеб, оло башлыкка Павелъ өстөннян жалыуы биргянняр. 2 Павелны чыкырыб алгач, Тертуллъ аны айыблый башлаб әйткян: Эй бик кадерле Феликсъ, 3 бу калыкны төзөк тотоулык синең тырышыуыннан гна булганны, безнен зур тынычлыгыбыз синнян икянне айырмачык белеб, бар төштя дя сина төрлөчя жалан тау итябез. 4 Тик сине кюб кумачауламыйык диб, гадятенчя кече кюнеллеген белян безне кыска гна тыннаб алсана диб сина инялямен. 5 Бу кешенен калыкка зыян китереўче, бөтөн дөньядя тора торган іудейляр арасында болганышыу чыгарыучы, Назорей ересын жяйелтеўче икянен, 6 Тагы чиркяўебезне дя шакшыландырырга келягянен белеб, без аны тотоб алдык та ӱз законыбызча анар хокөм итярга келядек.

7 Әммя мең кеше башлыгы Лисій килеб, бик каты көчляб, аны безнен кулдан алды да сина жибярде, 8 без аны айыблаучыларга да сина барырга кушты. Син ӱзең айырмачык тикшереб,

без аны неӥ турдан айыблаганны барысын да ӱзеннян беля алырсыӈ, дигян. 9 Іудейляр дя бу дӧрӧс шулай диб ӓйтеб жюблягянняр. 10 Оло башлык Павелга сӧйлярга билге биргяч, ул жауаб биргян: Кюб жылдан бирле син бу калыкка дӧрӧс хокӧм иткяненне белеб, ӱз эшемне бигеряк тя кыйыуланыб жаклый алырмын. 11 Іерусалимгя Аллага башырырга килгянемя ун ике кӧннян ары жукны ӱзеӈ беля алырсыӈ. 12 Чиркяӱдя дя, синагогаларда да, калада да минем беряӱ белян дя сюзгя килгянемне, жя калыкны болгатыуымны алар табалмадылар. 13 Казер дя мине неӥ турдан айыблаганнарын кюрсятя алмаслар. 14 Тик сиӈа ӱзем ӓйтеб бирямен: Алар ересь диб ӓйткян ӧйрятеӱ буйынча, мин законда да, пагамбярлярдя дя жазганнын барысына да ышаныб, чыннабук аталарыбыз Алласына кызмят итямен, 15 ӱлгян гаделлярнен дя, гадел тӧгӧллярнен дя терелеб торасылары булырын кӧтӧб, ӧмӧтӧмне Аллага тотамын, алар ӱзляре дя шуны кӧтӧб торалар. 16 Шуӈар кюря мин ӱзем дя Алла алдында да, кешеляр алдында да жалан таза кюӈелем булсын ыйы диб тырышамын. 17 Мин кюб жылдан суӈ хайерне дя, бюляк итеб китергяннярне дя ӱз калыгыма бирергя килдем. 18 Шул арада алар мине чиркяӱдя кешесез дя, тауышсыз да тазарынган кӧйӧ очраттылар. 19 Аларнын кайсылары Асія іудейляре эйе, ӓгяр миӈа карышы бер-бер айыб табсалар, аларга синеӈ алдында тороб, мине айыбларга тейеш эйе. 20 Жя мин синедріонъ алдында торган чакта, миндя табкан дӧрӧссӧзлӧкне инде былар ӱзляре ӓйтсенняр. 21 Ул чакта мин алар арасында тороб, ӱлгяннярнен терелеб тороуына ӧмӧт тотканыма кюря сез миӈа казер хокӧм итясез диб каты ӓйткян эйем, ӓлля шул бер сюз гня мине айыблый мы? дигян. 22 Мыны тыннаб алыб, Феликсъ аларнын эшен туктатыб ӓйткян: Мин меӈ кеше башлыгы Лисій килгяч, сезнен эшегезне тикшерермен дя бу ӧйрятеӱ турысында айырмачыгырак белермен, дигян. 23 Жӧз кеше башлыгына Павелны карауылларга, тик аӈар кысаннык кылмаска, анын жакыннарынын ӓр-берсеня аӈар кызмят итяргя, жя анын катына килергя роксят итяргя кушкан. 24 Бер ауык кӧннян суӈ Феликсъ ӱз

катыны іудей кешесе Друзилла белян килеб, Павелны чакырыб алган да анын Іисусъ Христоска ышаныу турысында сөйлягян сюзен тыннаган. 25 Ул дөрөслөк турысында, тыйнаклык турысында, буласы хокөм турысында әйткяч, Феликсъ куркынычка төшөб, әнәр әйткян: Казергя китеб тор, багытым булгач, сине чакыртырмын, дигян. 26 Былай диб әйткяндя Павелъ ўзен жибяртер өчөн анар акча бирер диб өмөт иткян: шунныктан жаланук аны чакыргалаб, анын белян сөйляшкян. 27 Ике жыл ўткяч, Феликсъ урнына Порцій Фестъ кергян. Феликсъ, іудейлярнен кюнеллярен булдырасы килеб, Павелны быгауда калдырыб торган.

25-нче бюлем

1 Фестъ бу жакка килгяч, өч көннян суң Кесаріядан Іерусалимгя киткян. 2 Шул чакта баш священникляр дя, іудейлярнен затлы кешеляре дя килеб, Павелъ өстөннян анар жалыуы биреб, аны димняб, ул аларга изгелеген салыб, 3 Павелны Іерусалимгя чакырыб алсын диб ўтенгянняр, ўзляре усал уй тотоб, аны жулда ўтерясе булганнар. 4 Тик Фестъ жауаб биреб әйткян: Павелъ Кесаріяда карауылда тора, ўзем шунда тиз барасы булам. 5 Алай булгач, әгяр ул кешенен бер-бер айыбы булса, сезнен арадан барырга хале бары минем белян барсыннар да аны айыбласыннар, дигян. 6 Аларда бер сигез көнняб, жя ун көнняб торганнан суң, Фестъ Кесаріяга кайткан; икенче көннө хокөм урнына утырыб, Павелны алыб килергя кушкан. 7 Павелъ килгяч, Іерусалимнян килгян іудейляр анын тиря жагыннан тороб, анын өстөннян кюб зур айыблар әйтеб торганнар, тик аларнын дөрөсөн кюрсятя алмаганнар. 8 Ул ўзен дөрөсляргя әйткян: Мин іудей законына карышы, чиркяўгя карышы, кесаргя карышы бер усаллык та кылмадым, дигян. 9 Фестъ іудейларгя жараулы буласы килеб, Павелга жауаб биреб әйткян: Іерусалимгя барасың киля ме, мин анда синә бу турда хокөм кылар ыйым, дигян. 10 Павелъ әйткян: Мин кесарнен хокөмө алдында торам, минә шунда хокөм ителергя тейеш. Мин іудейлярнен бер нястя белян дя хатерлярен калдырмадым, син

аны бик жакшы белясең. 11 Шулай итеб, мин дөрөська чыкмасам, ўлемгя тейешле бер-бер нястя кылган булсам, ўлярга риза; әммя былар мине айыблардый бер эшем дя булмаса, беряў дя мине аларга тотоб биря алмас. Мин кесарь хокөмөн сороймын, дигян. 12 Шул чакта Фестъ киняш жыйыны белян сөйляшкяч, жауаб биргян: Син кесарь хокөмөн сорагач, кесаргя барырсың, дигян. 13 Берауык көн ўткяч, Агриппа падша белян Вереника Фестны котларга Кесаріяга килгянняр.

Зач.48 14 Алар анда кюб көнняб торгач, Фестъ Павелнын эшен падшага әйтеб былай дигян: Мында Феликстан быгауда калган бер кеше бар, 15 мин Іерусалимдя чагында, іудейлярнен архіерейляре дя, башлыклары да анын өстөннян жалыуы биреб, аны айыбларга сораб килделяр. 16 Мин аларга жауаб бирдем: Айыбланган кешенен айыблаучылары кюз алдында булмыйынчы, ул айыблаучылары алдында ўзен дөрөслярга ирек алмыйынчы, андый бер кешене дя ўлемгя тотоб бирергя Римъ кешеляренен гадяте жук, дидем. 17 Аннары алар мында килгяч, бер дя озаклатмыйчы, мин иртягесенюк хокөм урнына утырдым да, теге кешене алыб килергя куштым. 18 Айыблаучылар аны чырмаб алыб, мин кюнелемдя тоткан айыбларнын берсен дя кюрсятя алмадылар. 19 Тик алар ўзляренен Алласын кадерляў турысында, әлля нейдей бер ўлгян Іисусъ турысында, анын белян даулаштылар, әммя Павелъ аны тере диб әйтеб тордо. 20 Мин бу эшкя хокөм жасарга жөдяб, Павелга әйттем: Синең бу эшкя хокөм алырга Іерусалимгя барасың киля ме? дидем. 21 Тик Павелъ мине Августъ тикшерсен диб эшен калдырырга сорагач, мин аны кесаргя жибярер багытка чаклы карауылга биреб тотарга куштым, дигян. 22 Агриппа Фестка әйткян: Бу кешене минем дя тыңнасым киля, дигян. Теге әйткян: Иртягюк аны эшетерсең, дигян. 23 Икенче көннө Агриппа белян Вереника бик кубшы килеб, меңг кеше башлыклары белян, каладагы бер дигян затлы кешеляр белян хокөм жортона кергяч, Фестъ кушкан буйынча, Павелны алыб килгянняр. 24 Фестъ әйткян: Эй Агриппа падша, эй безнен белян утыра торган кешеляр барыгыз да! Бөтөн іудей

калкы минә Иерусалимдя дя, мында да бу кешегя карышылык итеб килделяр дя мыннан ары анар тере тороргa тейеш төгөл диб кычкырыштылар, сез шул кешене кюрясез. 25 Әммя мин анын ўлемгя тейешле кылган эшен бер дя табмадым; ул ўзе дя Августанъ хокөм сороймын дигяч, аны анар жибярмякче булдым. 26 Мин анын турында кесаргя айырмачык ней жазарга да белмеймен, шунныктан аны сезнен алдыгызга, эй Агриппа падша, бигеряк тя синең алдына китердем, тикшергяннян суң анын турысында бер-бер сюз жазыйым диб. 27 Быгаудагы кешене, айыбларын кюрсятмейенче жибяреў мина акылсыз эш кюк тея шул, дигян.

26-нче бюлем

Зач.49 1 Агриппа Павелга әйткян: Ўз турында синең ўзеня әйтергя роксят ителя, дигян. Шул чакта Павелъ кулын кютяреб, ўзен дөрөслярга әйтя башлаган: Эй Агриппа падша! 2 Иудейлярнен мине бар айыблауларына карышы бөгөн синең алдында ўземне дөрөслярга тейешле булганыма кюря, мин ўземне ўзем бахетлегя саныймын; 3 Бигеряк тя син иудейлярнен бар жолаларын, даулаша торган эшлярен дя белясең шул. Шунар кюря мине тюземнек белян тыннаб алырга синнян инялеб сороймын. 4 Мин тормошомны жяш чагымнан бирле башта ўз калыгым арасында Иерусалимдя ўткярдем, бу тормошомны бар иудейляр дя беляляр. 5 Әгяр алар таныклык итяселяре кился, мин ўз денебезнен бик кисятеб өйрятеўен тотоб, фарисей булыб торганны алар элгяредянюк беляляр. 6 Мин казер дя безнен аталарыбызга Алладан бирелгян багадягя өмөт тоткан өчөн хокөм алдында торам, 7 безнен ун ике няселебез көнөн-төнөн туктаусыз Аллага кызмят итеб, шул багадянен жиреня килеўен кюрергя өмөтлянеб торалар; эй Агриппа падша, мына шушы өмөт өчөн иудейляр мине айыблыйлар. 8 Инде Алла ўлгяннярне тергезеб торгозоуга сез ышанырлык төгөл диб уйлыйсыз меней? 9 Дөрөс, мина да Иисусъ Назорей исеменя кюб карышылык кыларга тейеш диб мин дя уйлаган ыйым. 10 Мыны мин Иерусалимдя кылдым да: архиерейлярдян роксят алыб, кюб

изгелярне мин ӧтӧрмяннярга жабтырдым, аларны ӱтергян чакта, мин шунӈар киняш биреб тордом. 11 Бар синагогаларда мин кюб табкыр аларны азаблаб, Іисусны курларга кӧчляб куштым; аларга карышы бик каты жарсыб, аларны чит калаларда да кыудым. 12 Мынын ӧчӧн архіерейлярдян роксят алыб, алар кушкан буйынча, Дамаскка барган чакта, 13 эй падша, мин жулда кӧн уртасында кюктян кояш жактысыннан да жактырак жакты кюрдем, ул мине дя, минем белян торганнарны да каблаб алды. 14 Без барыбыз да жиргя жыгылдык, мин еврей теле белян айткян ауаз эшеттем: Савлъ, Савлъ! Ник син Мине кыуасынӈ? Синӈа ӱзеннян кыуатлыга карышы килергя читен диб. 15 Мин айттем: Эй Ходай, Син кемӈ? дидем. 16 Ул айтте: Мин син кыуа торган Іисусъ; инде тороб, аягынӈа бас: Мин сине, кюргяненне, Мин синӈа белдерясене таныклаб кызмят иттерер ӧчӧн синӈа кюрендем, 17 іудей калкыннан да, жалган деннелярдян дя сине саклармын, казер Мин сине аларга жибярямен, 18 алар карангыдан жактыга, шайтан иреген нян Аллага кайтсыннар диб, Минӈа ышаныу арткылы жазыклар кичелеӱеня арыуланганнар белян бер ӧлӧшлӧ булсыннар диб, аларнын кюзлярен ачарга жибярямен, диде.

19 Шунӈар кюря, эй Агриппа падша, кюктян кюренеӱгя мин карышылык итмядем. 20 Аммя инг элеке Дамаскъ белян Іерусалимдя тороучыларга, аннары іудей жиренен бар тӧшӧндя дя, жалган деннелярга дя алар тяӱбягя килеб, тяӱбягя тейешле эшляр кылыб, Аллага кайтсыннар диб, сӧйляб жӧрдӧм. 21 Шунын ӧчӧн іудейляр мине чиркяӱдя тотоб алдылар да, ӧзгяляб бетерергя келяделяр. 22 Алай булса да мин Алладан булышыулык алыб, кечесеня дя, олосона да таныклык итеб, пагамбярляр дя, Моисей дя бу булмый калмас диб айткянчя аларныкыннан башка бер сюз дя айтмейче, 23 Христосъ азаблана сы ыйы, ӱлгяннярдян инг элеке терелеб тороб, іудей калыгына да, жалган деннелярга дя жактылык сӧйлясе эйе диб таныклаб, бу кӧнгя чаклы торамын, дигян. 24 Ул ӱзен дӧрӧсляб шулай жауаб биргян чакта, Фестъ каты ауаз белян айткян: Син Павелъ тилерясенӈ, кюб укымышлыгынӈ сине акылдан жаздыралар, дигян. 25

Ул äйткян: Эй кадерле Фестъ, жук, мин акылдан жазмыймын, äммя чыннык белян жакшы уй сюзлярен сöйлöймен. 26 Бу турда падша да беля, шунар кюря анын алдында мин кыйыуланыб äйтямен: Мынын берсенен дя анар жяшерен икяненя мин бер дя ышанмыймын: бу почмакта гна булган эш тöгöл шул. 27 Эй Агриппа падша, син пагамбярлярга ышанасын мы? Белямен, ышанасын, дигян. 28 Агриппа Павелга äйткян: Христосныкы булырга син мине аздан гна кюндермяден, дигян. 29 Павелъ äйткян: Аз мы, кюб ме, син гня тöгöл, äммя бöгöнгö кöннö мине тыңнаучылар барысы да, бу быгаулардан башка, минем кюк булсыннар ыйы диб Алладан сорар ыйым, дигян. 30 Ул мыны äйткяч, падша да, оло башлык та, Вереника да, алар белян утырыучылар да торгаллар; 31 аннары читкяряк китеб, üз аралый сöйляшкянняр: Бу кеше üлемгя тейешле, жя быгауда тотарлык бер нястя дя кылмый диб. 32 Агриппа Фестка äйткян: Äгяр бу кеше кесарь хокöмöн сорамаган булса, аны иркенгя жибярергя мöнким булыр ыйы, дигян. Шунныктан оло башлык аны кесаргя жибярясе булган.

27-нче бюлем

Зач.50 1 Безгя сыу белян Италияга китяргя эшлянгяч, Павелны да, быгаудагыларнын да кайсыларын Августъ полыгынын Юлия исемне жöз кеше башлыгына табшырдылар. 2 Без Адрамитъ кимясеня кереб, Асия жирляре тирясеннян барасы булыб киттек. Безнен белян Македониядагы Фессалоника кешесе Аристархъ та бар ыйы. 3 Иртягесен Сидонга килеб туктадык. Юлий Павелга сöйкömнök кылыб, анар дусларына барыб, аларнын кызмяте белян пайдаланырга роксят итте. 4 Аннан чыгыб китеб, жилляр карышы булган буйынча, без Кипрга жöзöб килдек. 5 Киликия белян Панфилияга карышы дингезне арткылы üтеб, Ликиядагы Мирыга килдек. 6 Анда жöз кеше башлыгы, Италияга бара торган Александрия кимясен очратыб, безне анар утыртты. 7 Кюб кöн äкерен гня барыб, Книдъ атауы турына килеб житкяч кня, безгя жил ынгайсыз булганга кюря, без Салмонъ карышысындагы

Критъ атауына киттек; 8 Салмонъ жаныннан кӧчкя гня чыгыб, Жакшы Пристанняр диб аталган бер урынга килдек, анын жанында Ласея каласы бар ыйы. 9 Шулай байтак багыт ӱткяч, сыу белян барыу да куркынычка калгач, ураза да ӱткянгя кюря, 10 Павелъ киняш итеб, аларга ӓйтте: Эй кешеляр! Теягян жӧкляр белян кимя ӧчӧн гня тӧгӧл, ӓммя безнен тормошобыз ӧчӧн дя бу жӧзӧб барыуыбыз кумачаулы, оло зыянны булырын мин кюрям, диде. 11 Тик жӧз кеше башлыгы Павелъ сюзляреннян бигеряк кимяне тоуучы белян кимя башлыгына ышанды. 12 Бу пристаньдя кышны ӱткярерлек булмагач, кюбесе аннан китяргя, мӧнким булса, Критъ атауынын тӧшлӧк белян кояш байышы арасыннан, тӧн белян кояш байышы арасыннан ися торган жилгя карышы Финикъ дигян пристаненя барыб житяргя, кышны анда ӱткярергя киняш бирделяр. 13 Тӧшлӧктян жил ися башлады, шунда алар инде телягянебез туры килде диб уйлаб, Критъ тирясеннян жӧзӧб киттеляр. 14 Тик аз гна багыттан сунг анар карышы эвроклидонъ дигян дауыллы жил кютярелде 15 Дауыл кимяне чырмаб алды да кимя жилгя карышы тора алмады, без тулкыннар ӧстӧндя аталыб жӧрдӧк. 16 Бер Клавдій диб аталган кечкеня атауга бярелеб, без кимядяге кайыкны кӧчкя гня тотоб калдык. 17 Аны кютяреб алдык та кимягя булышыб, аны чырмаб бяйлей башладык; сай жирдя туктамыйык диб куркыб, парусны тӧшӧрдӧк тя шул кӧйӧ атылыб жӧрдӧк. 18 Икенче кӧннӧ, каты дауыл булганга кюря, теягян жӧкнӧ кимядян ташлый башладылар. 19 Ӧчӧнчӧ кӧннӧ без ӱз кулларыбыз белян кимядян ӓйберлярне ташладык. 20 Шулай итеб кояш та, жондозлар да кюб кӧннян бирле кюренмягяч, бик кюб дауыллаб торгач, калдыгында безнен котолорбыз диб бер ӧмӧтӧбӧз дя калмады. 21 Шулай итеб озак ашамый торгач, Павелъ аларнын урталарында тороб ӓйтте: Эй кешеляр! Мине тынӈау киряк эйе, Криттан китяргя тейеш тӧгӧл эйе, шулай итсягез, бу кумачауларны да, зыянны да кюрмягян булыр ыйык. 22 Казер инде сезне тынычланырга ӱгетлеймен, сезнен арадан бер жан да жугалмас шул, тик кимя гня бетяр. 23 Мин кызмят итя торган минем Алламнын

пяриштясе шушы төннө мина кюренеб, 24 äйтте: Эй Павелъ, курыкма! Сина кесарь алдында тороргa тейеш: мына инде Алла синең белян барыучыларнын барысын да сина табшырды, диде. 25 Шунар кюря, эй кешеляр, кюнелегезне тынычландырыгыз, мин Аллага ышанамын, мина ничек äйтелгян, шулай булыр. 26 Безгя бер-бер атауга чыгарылыб ташланырга туры килер диде. 27 Без Адріатическій дигян дингездя атылыб жöрöй торгач, ун дюртенче төннө төн уртасы тирясендя кимячеляр бер-бер жиргя жакыннаша торганбыз диб анъыша башладылар. 28 Шунда тиряннеген ўлчягяч, жегерме сажин булды; аннары азырак барганнан суң тагы ўлчягяч, ун биш сажин булды. 29 Ташлы төшкя туры килмясен диб куркыб, кимя койорогоннан дюрт жякер төшöрдöляр дя көн башланыуын көтöб тордолар. 30 Шул арада кимячеляр кимядян качарга уй тотоб, жякерлярен кимя борноннан төшöргян кюк булыб, дингезгя кайык төшöря башлагач, 31 Павелъ жöз кеше башлыгы белян салдатларга äйтте: Äгяр алар кимядя калмасалар, сез котола алмассыз диде. 32 Шул чакта салдатлар кайык бауларын кистеляр, кайык төшöб китте. 33 Көн башланыр алдыннан, Павелъ барысын да сезнен ашамныксыз бер нястя дя кабмыйчы көтöб тороуыгызга бöгöн инде ун дюртенче көн диб, ашарга димняде. 34 Сезгя ашамнык кабыгыз диб ўтенямен, ул сезнен тормошогозны саклар; сезнен берегезнен дя башындагы чяче дя жугалмас диде. 35 Мыны äйткяч, икмяк алыб, ул барысы алдында Аллага тау итеб, сындырыб, ашый башлады. 36 Шул чакта тынычланыб, барысы да ашамнык кабтылар. 37 Кимядя без барыбыз ике жöз дя житмеш алты жан ыйык. 38 Ашаб туйгач, бодайны дингезгя ташлаштырыб, кимяне жинеляйтя башладылар. 39 Көн башлангач, жир икянен беля алмадылар, тик бер сöзяк жарлы дингез тамагын кюреб, мöнким булырлык булса, кимя белян шунда туктасы булдылар. 40 Якерлярне кютяреб, дингез белян киттеляр дя кимя койорогонын жеблярен чишеб, жил ынгайына кечкеня парусны кютяреб, жаргa таба тотоб киттеляр. 41 Борон жиргя туры килеб, кимя сай жиргя утырды; кимянен борно батыб, кузгалмас булды, койорого тул-

кын кыуаты белян бярелеб уатыла башлады. 42 Салдатлар быга-удагыларнын берсе-берсе жӧзӧб китеб качмасыннар диб, аларны ӱтермякче булдылар. 43 Тик жӧз кеше башлыгы Павелны сакласы килеб, аларны бу уйдан туктатты да жӧзя беля торган кешелярга, сыуга сикереб, жиргя чыгарга кушты. 44 Бютяннярнен кайсысына такталар östönнян, кайсысына кимянен бер-бер нястясе белян котолорга кушты. Шулай итеб барыбыз да жиргя чыгыб котолдок.

28-нче бюлем

Зач.51 1 Павелъ белян булганнар котолгач, атаунын Мелитъ диб аталганын белделяр. 2 Чит зат кешеляре безгя кюб сӧйкӧмнӧк кылдылар: шулай алар, жангыр да, сыуык та булганга кюря, ут жактылар да безнен барыбызны да кабыл алдылар. 3 Павелъ кюб чыбык жыйыб утка салган чакта, ут кызыуыннан чыгыб, анын кулына ехидна дигян жылан чырмалыб асылынды. 4 Чит зат кешеляре, анын кулына чырмалган жыланны кюреб, берсеня берсе äйттеляр: Бу кеше ӱтереӱчедер акыры, ул дингездян котолса да, аны Алла хокӧмӧ тере калырга ирек жибярмей, диделяр. 5 Ämмя ул жыланны утка селкеб ташлаб, бер зыян да кюрмяде. 6 Инде ул шешенер, жя кинят жыгылыб ӱляр диб кӧтӧб торганнар ыйы, тик озак кӧтӧб, анар бер зыян да булмаганны кюреб, уйларын ӱнгяртеб, бу Алладыр диб äйттеляр. 7 Шул урын тирясендя атау башлыгы Публій атлы кешенен ӱз жире бар икян: ул безне кабыл алыб, öч кӧн жаратыб кунак итте. 8 Публійнен атасы тир кастасы белян, эч ауыртыу белян азабланыб жата икян. Павелъ анын катына кереб, теляк итте дя анар кулын салыб, аны сауыктырды. 9 Бу эш булганнан сун атаудагы бютян чирле кешеляр дя килеб сауыктылар. 10 Безне бик кадерляделяр, киткян чакта да киряк äйберляр бирделяр. 11 Öч айдан сун, шул атауда кышны ӱткяргян Діоскуры диб аталган Александрія кимясеня утырыб, сыу белян киттек. 12 Сиракузыга килеб, анда öч кӧн тордок. 13 Аннан чыгыб, Ригіяга килдек; аннары бер кӧннян сун, тӧшлӧктян жил искяч, икенче кӧннӧ Путеолыга килдек. 14 Мында туганнарыбыз-

ны очраттык, алар безне жиде көн тороргa кыстадылар; аннары Римгя киттек. 15 Андагы туганнар безнен турда эшетеб, Аппія урамындагы өч Кунак Жортона чаклы безгя карышы чыктылар. Павелъ аларны кюреб, Аллага бик тау итте дя сӧйӧнӧб китте. 16 Без Римгя килгяч, жӧз кеше башлыгы быгаудагыларны салдатлар башлыгына табшырды; Павелга, аны саклаучы салдат белян, ӱз алдына айырым тороргa роксят булды. 17 Өч көннян суң Павелъ іудейлярнен затлы кешелярен чакырыб алды; алар жыйылгач, аларга әйтте: Эй кадерле туганнар! Калыкка карышы, жя аталарыбыз жолаларына карышы бер нястя кылмаган көйӧ, мин Іерусалимнян быгауда килеб, римняр кулына бирелдем. 18 Минем ӱлемгя тейешле бер айыбым да булмаганга кюря, алар миңа хокӧм итеб, мине иркенгя жибярмякче булганнар ыйы. 19 Тик іудейляр карышы торганга кюря, миңа кесарь хокӧмӧн сораргa киряк булды, алай булса да ӱз калыгымны бер-бер турдан айыблар өчӧн тӧгӧл. 20 Шушы сябяблей мин сезне кюрер өчӧн, сезнен белян сӧйляшер өчӧн, сезне чакырдым; Израиль ӧмӧтӧ какына мин шушы быгауларга чырмалдым диде. 21 Алар анар әйттеляр: Без Іудея жиреннян синең турда жазыу да алмадык, килгян туганнарнын берсе дя синең турда хабяр итмяделяр, бер жаманнык та әйтмяделяр. 22 Алай булса да бу ӧйрятеӱ турысында бар тӧштя дя даулашыу безгя билгеле, инде син ничек уйлыйсың, безнен синнян эшетясебез киля, диделяр. 23 Алар анар көнӧн билгеляб куйыб, бик кюбесе ул тора торган ӧйгя килделяр. Ул иртядян алыб кичкя чаклы, аларга Моисей законыннан да, пагамбярлярдян дя Іисусъ турысында таныклык итеб, ышандырыб, аларга Алла падшалыгын сӧйляде. 24 Кайсылары анын сюзеня ышандылар, бютянняре ышанмадылар. 25 Бер-берсе белян кюнешмейче, алар чыгыб барганда, Павелъ бу сюзлярне әйтте: Исаія пагамбяр арткылы безнен аталарыбызга Святый Тын арыу әйткян: 26 Бар, бу калыкка әйт: эшетеӱен эшетерсез, әммя анламассыз, карауын карарсыз, тик кюрмяссез. 27 Бу кешелярнен кюнелляре катыланган, алар колаклары белян дя кӧчкя эшетяляр, кюзлярен дя жомган-

нар, кюзляре белян кюрмяс өчөн, колаклары белян тыңнамас өчөн, кюңелляре белян аңнамас өчөн, Миңа кайтмас өчөн, әммя Мин аларны төзятер әйем, дигян. 28 Алай булгач, инде Алланын котолоуны жалган деннелярга жибяргяне сезгя билгеле булсын; алар тыңнарлар да, дигян. 29 Ул мыны әйткяч, іудейляр бер-берсе белян кюб даулашыб, әрепляшеб, киттеляр. 30 Павелъ ўзенекен ашаб-эчеб, ике жыл тулгынчы тордо, анар килгяннярнен барысын да кабыл алыб, 31 Бар кыйыулыгы белян Алла падшалыгын сөйляб, Ходай Іисусъ Христосъ турысында өйрятеб тордо.

СВЯТЫЙ АПОСТОЛЪ ІАКОВНЫН АРЫУ ЖЫЙЫНГА ЖИБЯРГЯН ЖАЗЫУЫ

1-нче бюлем

Зач.50 1 Іаковъ, Алланын, Ходай Іисусъ Христоснын мяндясе, таралыуда тороучы унике быуынга жазамын, сӧйӧнӧгӧз. 2-3 Эй туганнарым! Ышаныуыгызнын сыналыулары тюземнек китергянне белеб, тӧрлӧ сыналыуларга туры килгян чакта зур сӧйӧнӧч белян кабыл алыгыз, 4 сез ӓр турдан да тулы житеуле булыр ӧчӧн, бер жактан да житмяс булмас ӧчӧн; тюземнек тулы житешлекле булырга тейеш шул. 5 Ӓгяр арагыздан беряӱнен белемнеге житмяся, ич кемне дя ӓрлямей ӓр кешегя дя биреӱче Алладан сорасын - анар бирелер шул. 6 Тик ӓз гня дя шиклянмейче, ышанулык белян сорасын; шиклянеӱче жилляр белян кютярелеб китя торган динтез тулкынына ошаулы шул. 7 Андый кеше Ходайдан ней дя булса алырым диб уйламасын. 8 Андый ике тӧрлӧ уйлы кеше ӱзенен бар жулларында да ныk тӧгӧл. 9 Кимсетелеуле туган ӱзенен жугарылыгы белян мактансын, 10 ӓммя бай кеше ӱзенен кимсетелеуе белян кайгырсын, ул ӱлям чячяге кюк шинеб бетяр шул. 11 Кояш чыгыб, кызыуы башлангач, кызыуы белян ӱлямне кӧйдӧря, анын чячяге койолоб, бар эяме жукка чыга; шунын кюк бай кеше дя ӱз жулында шинеб бетяр. 12 Сыналыуларга тюзеб ӱткяря алган кеше бахетле, ул шу сыналыуда булыб, Ходай Ӱзен сӧйӧучелярга багадя итеб ӓйткян терелек венецын алыр. 13 Сыналган чакта беряӱ дя: Алла мине сыный диб ӓйтмясен, Алла усаллык белян сыналмый шул, Ӱзе дя беряӱне дя сынамый. 14 Ӓммя ӓр кем ӱзенен усал няпесляреня алданыулары, кызыгыулары белян сынала; 15 няпес жаралыб жазык тыудыра, инде кылган жазык

ўлем тыудыра. 16 Эй сӧйӧклӧ туганнарым, алданмагыз. 17 Ӓр-бер арыуны биреўлек, ӓр-бер тулы бюляк жугарыдан, жактылыклар Атасыннан киля, Ул ўнтяреўсез, Анда ўнтяреўнен кюляткясе дя ич тя жук шул. 18 Ўзе булдырганнарынын иң арыулысы булыр ӧчӧн, Ул Ўзе теляб безне чыннык сюзе белян тыудырган.

Зач.51 19 Шулай, сӧйӧклӧ туганнарым, ӓр кеше тыңнарга ӧлгӧр, сюзгя ӓкрен, ачыуга ӓкрен булсын, 20 кешенен ачыуы Алла дӧрӧслӧгӧн кылмый шул. 21 Шул сяятлей ӓр-тӧрлӧ шакшылыкны, калган ачыуны бетереб, кюңеллярегезгя утыртылган, жаннарыгызны котолдора ала торган сюзне сабырлык белян кабыл алыгыз. 22 Ўз-ўзегезне алдандырыб, сюзне тыннаучылар гна булмагыз, ӓммя башкарыучылар булыгыз. 23 Кем сюзне тыннаучы булыб та башкармый, ул ўзенен жӧзӧ ничек икянен кӧзгӧдян караучы кешегя ошаулы; 24 ул ўзеня карый да, кӧзгӧ катыннан киткячтюк, ўзенен нейдей икянен онота. 25 Ӓммя кем тулылыклы законны, иркеннек законын тӧбтян аннаб, аны тота, ул онота торган тыңнаучы тӧгӧл, ӓммя эшне башкарыучы булганга кюря, ўз эшлярендя бахетле булыр. 26 Ӓгяр арагыздан беряў ўзен Алла алдында дӧрӧс тороучы диб саный, ӓммя ўзенен телен тыймый, кюңелен алдандыра икян, анын Алланын бойорокларын тотам дейеўе буш. 27 Алла Ата каршында Алланын бойорокларын чиста, шиксез тотоулык - ул ўгейлярга, толларга кайгыларында булыша торган, ўзен дӧньядян шакшыландырмый саклый торган тотоулык шул.

2-нче бюлем

Зач.52 1 Эй туганнарым! данныклы Ходайыбыз Ісусъ Христоска кешенен кемнегеня караб айырмый торган ышаныу белян ышаныгыз. 2 Ӓгяр жыйыныгызга алтын жӧзӧк кейгян жакшы кейемне кеше керя икян, тагы начар кейемне жарлы да керя икян, 3 сез жакшы кейем кейгянгя караб анар ӓйтсягез: сиңа мында утырыу арыу диб, ӓммя жарлыга ӓйтсягез: син тегендя тор, жя мында минем аягым жанына утыр, диб, 4 ул чагында ўз арагызда элпяляб тикшереўчеляр, начар уйлы хокӧм итеўчеляр булмыйсыз мы?

5 Тыңнагыз, сӧйӧклӧ туганнарым!
ышаныуларында бай булсыннар,
Ӱзен сӧйӧучеляреня багадя иткян
Падшалыкка тейешле булсыннар
диб, Алла бу дӧньянен жарлы-
ларын сайлаб алган тӧгӧл ме?
6 Сез жарлыны кимсеттегез, сезне
суң кысыучылар байлар тӧгӧл ме,
сезне хокӧмгя тартыучылар да
шулар тӧгӧл ме? 7 Сезгя бирелгян
арыу исемне шулар жаманныйлар
тӧгӧл ме? 8 Жазыудагы: жакы-
ныңны ӱзеңне сӧйгян кюк сӧй,
дигян Падша законын кыласыз
икян, жакшы кылынасыз. 9 Ӓгяр
инде кешенен кемнегеня караб
кылынасыз икян, жазык кыла-
сыз, закон карышында айыблы
буласыз. 10 Беряӱ законнын бар
кушканын да кылыб, берсендя
гня жазыклана икян, барысын-
да да айыблы була. 11 Уйнашлык
итмя, Дейеӱче бит: ӱтермя дя,
дигян; шунныктан ӓгяр син уй-
нашлык итмейсең, ӓммя ӱтеря-
сең икян, шулай ук син законны
бозоучы буласың. 12 Иркеннек
законы буйынча хокӧм ителергя
тороучылар булганга кюря, шулай
сӧйлягез, шулай кылыныгыз да. 13
Изгелек кылмый торганга хокӧм
дя изгелексез, изгелек хокӧмнян
жугарырак кютяреля шул.

Зач.53 14 Ней пайда, туган-
нарым, ӓгяр беряӱ ышаныуым
бар диб ӓйтеб, анын ышаныу
буйынча кылган эшляре булмаса?
Андый кешене ышаныуы коткa-
ра алыр мы? 15 Ӓгяр ир туган мы,
жя кыз туган мы жалангач булыб,
кӧндялек ашарларына булмаса, 16
сезнен арадан беряӱ аларга: ты-
нычлык белян керегез, жылы-
ныгыз, тукланыгыз, дейся; ӓммя
тянняреня киряклене бирмяся,
ней пайда суң? 17 Шулай ышаны-
улыкнын эшляре булмаса, ӱзеня
ӱзе ул ӱле. 18 Шулай беряӱе: си-
нең ышаныуың бар, ӓммя минем
эшлярем бар; миңа эшляреңнян
башка ышаныуынны кюрсят, мин
эшлярем буйынча синa ышаны-
уымны кюрсятермен, диб ӓйтер.
19 Син Алла Бер диб ышанасың
икян, жакшы эшлейсең; женняр
дя ышаналар да, калтраб торалар.
20 Ышаныулык эштян башка ӱле
икянне белергя телейсенме син,
эй нигезлянмягян буш кеше? 21
Авраамъ атабыз ӱзенен улы Иса-
акны корманга ментезеб, эшля-
ре белян дӧрӧслянгян тӧгӧл ме?
22 Кюрясенме, ышаныуы анын
шушы эшлярен алыб барган, эш-
ляре белян ышаныуы тулылыкка
барыб житкян. 23 Шулай, Авра-

амъ Аллага ышанган, ышаныуы анар гаделлеккя саналган, ул Алланын дусты диб аталган, дигян Жазыудагы сюз жиреня килгян шул. 24 Кюрясезме инде, кеше эшляре белян дöрöскя чыга, ämмя бер ышаныуы белян гня тöгöл. 25 Шунын кюк уйнашчы катын Рaавъ та, кюзятеўчелярне ўзеня кунарга кертеб, аларны бютян жулдан жибяреб, эшляре арткылы дöрöскя чыккан тöгöл ме? 26 Ничек тян тыннан башка ўле, шулай эштян башка ышаныу да ўле.

3-нче бюлем

Зач.54 1 Эй туганнар, ўзебезнең артыгырак хокömгя тöшясе - безне белеб, бик кюбегез öйрятеўчеляр булмасын. 2 Без барыбыз да кюб жазыкланабыз шул; кем сюзендя жазыкланмый, бöтöн тянен дя тыярга кöчö житкянгя кюря, ул кеше житешеўле. 3 Мына без безгя буйсынсыннар диб, атларнын ауызларына ауызлык салабыз да, аларны тыйыб, бар тяннярен ўзебез дейгянчя жöртябез. 4 Мына каты жилляр белян жöртöлöўче кораблар, бик оло булсалар да, кечкеня боргоч белян боролоб, жöртöўче телягян жиргя баралар. 5 Шунын кюк тел дя кечкеня сан, ämмя кюбне эшлей; кюр äле, кечкеня гня ут нейдей кюб нястялярне жандыра. 6 Шулай тел дя ут, дöрöссöзлöкне эшляўче: тел саннарыбыз арасына урнашыб, бöтöн тянне шакшыландыра, ўзе дя тамук утыннан жалкынсыныб, булган тормошобызны кöйдöря. 7 Барча кейекляр, кошлар, шыуышыб жöрöўче жяннекляр, дингез жяннекляре кеше акылы белян тыйылган, тыйыла да шул. 8 Тик кешелярнен берсе дя телен тыя алмый, тел тыялмаслык жауызлык, ул ўлем агыуы белян тулган шул. 9 Шунын белян Алла Атаны данныйбыз, шунын белян ўк Аллага ошашлы итеб булдырылган кешелярне кагарлейбез. 10 Шул ук ауыздан даннау да, кагарь дя чыга, былай булырга тейешле тöгöл, сöйöклö туганнарым.

Зач.55 11 Бер ўк чишмянен ауызыннан тямне дя, äче дя сыу ага мы? 12 Эй туганнар, смоковница агачы май агачы жимешен биряме, жя жöзöм агачы смоква биряме? Шулай ук бер ўк чишмя дя тозло да, татлы да сыу агызмый. 13 Сезнен арагызда кайсыгыз анны, белемнекле икян, ул

ўзенен эшлярен арыу кылмышта, белемне сабырлыкта кюрсятсен. 14 Ӓгяр сезнен кюнӗлегездя ӓче кюремсезлек, жарсыу була икян, алайса мактанмагыз, чынныкка жалганнамагыз. 15 Бу белемнек жугарыдан килгян тӧгӧл, ӓммя жирдяге, жандагы, шайтанныкы. 16 Кайда кюремсезлек, жарсыу, шунда тӧзӧксӧзлек, бар начарлык та. 17 Жугарыдан интян белемнек, беренчедян, чиста шул, аннары тыныч, жыуаш, тыннаучан, изгелек белян, арыу жимеш белян тулы, кюз алдында кылынмый торган гадел. 18 Тынычлыкны саклаучылардан дӧрӧслӧк жимеше тынычлык белян чячеля шул.

4-нче бюлем

1 Сезнен дошманнашыуыгыз, сюз ирештереўлярегез кайдан? саннарыгыздагы кӧряшеўче усал няпеслярегездян тӧгӧл ме? 2 Киряксенясез, тик ала алмыйсыз, ўтерясез, кӧнчӧлӧклӧйсез, барыбер булдыра алмыйсыз, талашасыз да дошманнашасыз, сорамаганыгыз какына ала алмыйсыз. 3 Сорасагыз да ала алмыйсыз, сез шу жакшылыкка сорамыйсыз, усаллык ӧчӧн, ўз няпеслярегезгя тотоу ӧчӧн соройсыз. 4 Эй уйнашлык итеўче ирляр, катыннар, бу дӧнья белян дус булыу Аллага карышы икянне белмейсез ме ӓлля? шулай беряўенен бу дӧнья белян дус буласы киля икян, ул Аллага дошман була. 5 Ӓлля сез Жазыудагы: безне эчебездя тора торган тын кӧнняшеўгя чаклы сӧя, дигянне бушка ӓйтелгян диб уйлыйсыз мы? 6 Шулай булган сайын кюбряк дяўлятен биря, шунар кюря ӓйтелгян: Ходай олосомакларга карышы киля, жыуашларга дяўлятен биря, диб.

Зач.56 7 Шулай Аллага буйсыныб торогоз, шайтанга карышыб торогоз, ул сездян качар; 8 Аллага жакынайыгыз, Ул да сезгя жакынайыр; эй жазыклылар, кулларыгызны тазартыгыз; эй ике уйлылар, кюнӗлярегезне тӧзятегез. 9 Кайгырыгыз, кюз жяшлярегезне тюгегез, ўкереб жылагыз: кӧлӧўегез жылауга ӓйлянсен, сӧйӧнӧчӧгӧз кӧйӧнӧчкя ӓйлянсен.

Зач.57 10 Ходай карышында жыуашланыб торогоз, Ул сезне кютярер. 11 Эй туганнар! бер-берегезне жаманнамагыз: туганын жаманнаучы, жя ўз туганын

айыблаучы законны жаманный, законны айыблый: ӓгяр законны айыблыйсыӈ икян, син законны кылыучы тӧгӧл, ӓммя анар хокӧм итеўче. 12 Закон Куйыучы, хокӧм Итеўче бер гня, Ул коткара да, жукка чыгара да ала: бютянне айыблаучы син кем сунʔ 13 Мына сез: бӧгӧн жя иртягя беряр калага китярбез, анда беряр жыл тороб сатыу итярбез дя пайда алырбыз, дейеўчеляр, тыннагыз ӓле, 14 сез бит иртягя ней булырын белмейсез: сезнеӈ гумерегез ней сунʔ гумерегез ӓз гня багытка була да, сунынтын жукка чыга торган пар кюк. 15 Алай ӓйткенче былай ӓйтегез: Ходайга жараулы булса, исян булсак, шуны жя мыны кылырбыз, диб. 16 Сез олосомаклыгыгызда бушка мактанасыз, ӓрбер алай мактаныу жаманнык шул. 17 Кем сауаблык кыла белгян кӧйӧ дя кылмаса, анар жазык була.

5-нче бюлем

1 Эй байлар, сез эшетегез, сезгя килясе коточкоч кайгылар турысында жылагыз, ўкереб жылагыз. 2 Сезнен байлыгыгыз черегян, кейемнярегезне дя кӧя ашаб бетергян; 3 алтыннарыгыз, кӧмӧшлярегез тутыгыб беткянняр, аларнын тутыклары сезгя карышы таныкчы булырлар да, тяннярегезне ут кюк ашаб бетерерляр, сунгы кӧннягя сез байлык жыйдыгыз шул. 4 Мына басыуларыгызда урак урыучы эшчелярнен сез тотоб калган эш хакы ауазы жылаб кычкыра, урак урыучыларнын тилмереб жылау ауазы Саваофъ Ходайнын колагына керде. 5 Сез жирдя кюнел ачтыгыз да рахят кюрдегез, кюнелегезне чалынасы кӧнгя ӓзерлягяндей артык тукландырдыгыз. 6 Сез Гаделне айыбладыгыз да ўтердегез: ул сезгя карышылык итмяде. 7 Эй туганнар! Ходайныӈ килеўеня чаклы озак тюземне булсагыз ыйы. Мына жир эшкяртеўче дя жирдян кадерле жимешен кӧтя, шунын какына иртя жя суӈ жаӈгырны озак тюзеб кӧтӧб ала. 8 Шулай сез дя озак тюзегез, кюнелляргезне ныгытыгыз, Ходайнын килере жакыннаша шул. 9 Эй туганнар! бер-берегезгя зарланмагыз, шулай итсягез, айыблы булмассыз: мына хокӧм Итеўче ишек тӧбӧндя тора. 10 Эй туганнарым! Ходай исеме белян сӧйлягян пагамбяр-

лярне озак тюземнек белян каты азаблар кюреўлек кючергеченя алыгыз. 11 Мына без шул азабка тюзгяннярне бахетле диб äйтябез. Сез Іовъ тюземнеген эшеттегез, анын азабларын Ходай ничек бетергянне кюрдегез, Ходай кюб изгелекле, бик кызганыучан шул. 12 Эй туганнарым, инг элекюк кюк белян дя, жир белян дя карганмагыз, бер нястя алыб та карганмагыз; сезнен сюзегез: эйе, эйе, жя: жук, жук дейеў гня булсын; шулай итсягез, сез айыблы булмассыз. 13 Арагызда каты азабланыучы булса, теляк итсен; сöйöнöўче булса, псаломнар жырласын. 14 Чирляб жатыучыгыз булса, Жыйыннын священниклярен чакырсын, алар анын öстöндя теляк итеб, аны Ходай исеменя май белян майласыннар; 15 Ышаныб иткян теляк чирлене сауыктырыр, аны Ходай торгозор, жазыклар кылган булса, анар кичерелер. 16 Жантышларыгызны бер-берегезгя äйтегез, сауыгыр öчöн бер-берегез турысында теляк итегез; гаделнен тырышыб иткян теляге кюб булышыулык бирядер. 17 Илія пагябяр безнен кюк кеше булган; ул жангыр булмасын диб, тырышыб теляк иткяч, жирдя öч жыл да алты ай жангыр булмаган; 18 тагы да инялгян, инялгяч, кюк жангыр биргян, жир ўз жимешен ўстергян (3 Цар.18,42-45). 19 Эй туганнар! сезнең арадан беряў-беряў чын жулдан жазыб, аны кем гня булса да кире кайтарса, 20 белеб торсон, ул жазыклыны жалган жулдан кайтарыуы белян жанын ўлемнян коткарыр, кюб жазыкларын кичертер.

СВЯТЫЙ АПОСТОЛЪ ПЕТРНЫН АРЫУ ЖЫЙЫНГА ЖИБЯРГЯН БЕРЕНЧЕ ЖАЗЫУЫ

1-нче бюлем

Зач.58 1 Петръ, Іисусъ Христоснын апостолы, читтян килеб, Понтта, Галатіядя, Каппадокіядя, Асіядя, Віфиніядя таралган сайланганнарга жаза. 2 Алла Атанын алдан кюреўлеге буйынча, сез Іисусъ Христоска эйегергя, Анын Каны белян бёркёлёргя диб, Святый Тыннан арыуланганнар, дяўлят, тынычлык сезгя, алар сездя кюбяйсен. 3-4 Ходайыбыз Іисусъ Христоснын Атасы Аллабыз даннаулы, Ул Ўзенен оло изгелегеннян, Іисусъ Христосны ўлгяненнян терелтеб торгозоуы белян терелеккя, кюктяге дяўляткя ёмётлянергя безне жанадан тыудырды. Бу дяўлят черемейче, таза кёйё, кимемейче сезнен ёчён кюктя саклана шул; 5 сез калдык багытта ачылырга әзер булган котолоу ёчён Алла кыуаты белян ышаныулык арткылы сакланасыз. 6 Тёрлё сыналыуларда чагында, киряк булганча, казер әзряк кёйёнгяч, шул котолоу какында сёйёнёгёз; 7 сыналган ышаныуыгыз, утта сыналыб та жукка чыга торган алтыннан кюб кыйбатлырак булганга кюря, Іисусъ Христоснын кюренеўендя мактауга, кадергя, данга әйлянсен диб. 8 Аны кюрмягян кёйё сёясез, мынар чаклы Аны кюрмейче, әммя Анар ышаныб, әйтеб бетергесез данны сёйёнёч белян сёйёнясез, 9 ышаныуыгыз белян азакы багытта жаннарыгызга котолоу аласыз. 10 Пагамбярлярнен тырышыб эзлягянняре, тикшергянняре шушы котолоу булган, алар сезгя билгелянгян дяўлят турында алдан ук сёйлягянняр шул. 11 Аларда булган Христосъ Тыны кайсы жя кай багытта Христоснын азабланасын, азаблардан сунг килясе данын алдан кюрсяткянне тикшереб ёйрянгянняр. 12 Кюк-

тян ингян Святый Тын арткылы пагамбярлярнен казер сезгя сӧйлягянняре аларнын ӱзляреня тӧгӧл, ӓммя безгя кызмят итясе аларга ачык булган, мынар пяриштялярнен дя тӧшӧняселяре киля. 13 Шул сяятлей, сӧйӧклӧлярем, акылларыгызнын билен бяйляб, уяу тороб, Іисусъ Христосъ кюренгяндя сезгя алыб килясе дяӱлятка тулылык белян ӧмӧтлянеб торогоз. 14 Тынаучан балалар кюк булыгыз, элеке белмягян чакта булган азгын няпеслярегез белян жарашмагыз. 15 Ӓммя сезне чакырган Изгедян кючергеч алыб, ӱзегез дя бар кылмышларыгызда да изге булыгыз. 16 Жазылган ич: Мин изге булганга кюря, сез дя изге булыгыз, диб (Левит.19,2). 17 Ӓгяр инде ӓр-кемгя дя эшляреня караб гадел хокӧм Итеӱчене Ата диб ӓйтясез икян, жир ӧстӧндя читтян килеӱче кюк тороуыгызны куркыныч белян ӱткярегез. 18 Белясез ич, аталарыгыздан калган буш сагышлы тормошогоздан сез черей торган кӧмӧш, жя алтын белян жолоб алынмадыгыз, 19 ӓммя бозолоусыз, ин таза Бярян булган Христоснын бик кыйбатлы Каны белян жолоб алындыгыз. 20 Ул дӧнья жаратылыудан элеке алдан билгелянгян, ӓммя сезнен ӧчӧнгя сунгы багытларда кюренде. 21 Аллага Анын арткылы ышанасыз; сез Аллага ышаныб, ӧмӧтлянеб торор ӧчӧн, Алла Аны ӱлгяненнян терелтеб данналдырды. 22 Тын арткылы Чынныкка буйыныб, туганнарыгызны жумачылыксыз сӧйӧӱ ӧчӧн жаннарыгызны тазартыб, бер-берегезне жалан таза кюнелдян сӧйӧгӧз. 23 Черей торган орлоктан тӧгӧл, ӓммя черемей торган, мянгегя тора торган тере Алланын сюзе арткылы сез тыудырылган шул. 24 Шулай ӓр бер тян ӱлям кюк, ӓр бер кешенен даны ӱлямдяге чячяк кюк; ӱлям корогач, чячяге дя койола. 25 Ӓммя Ходай сюзе гумергя тора (Ис. 40, 6-8). Бу сезгя сӧйлянгян ӱзе шул арыу сюз инде.

2-нче бюлем

1 Шулай ӓр-бер усаллыкны, жаманныкны, кюз алдында кылыныуны, кӧнчӧлӧкнӧ, ӓр-тӧрлӧ усал сюзне калдырыб тороб, 2 жана тыуган балалар кюк, таза сюз сӧтӧн сӧйӧгӧз, шунын бе-

лян котолоу өчөнгя ўсегез. 3 Ходайнын ничек изгелекле икянен татыдыгыз шул. 4 Кешелярдян кире кагылган, ӓммя Алладан сайланган бик кыйбатлы тере Ташка, Іисусъ Христоска килеб, 5 Іисусъ Христосъ арткылы Аллага, Анын кюнеленя жараулы тын корманы китереў өчөн, ўзегез дя тере ташлар кюк, изге священство булыб, ўзегездян тын өйӧ житкезегез. 6 Жазыуда айтелгян шул: мына Мин Сіонда почмак астына тейешле, сайланган, бик кыйбатлы таш куямын, Анар ышаныучы оятлы булмас, диб. 7 Шулай Ул сез ышаныучылар өчөн бик кыйбатлы, ӓммя ышанмый торганнарга өй салыучылар жараусыз кюреб ташлаган, тик почмак астына нигез булган таш, абыныу ташы, сөртөнөб жыгылдырыу ташы булган шул. 8 Сюзгя буйсынмыйчы алар Анар абыналар, шунар кюря алар калдырылганнар да. 9 Ӓммя сез сайланган тыума, падша священствосы, изге калык, сезне карантылыктан Ўзенен кодрятле жактысына Чакырыучынын тулы икяннеген сөйлярга диб Ўз өлөшөня алынган кешеляре. 10 Кайчандыр калык төгөл эйегез, ӓммя казер Алла калыгы; кайчандыр жарлыкаусыз ыйыгыз, ӓммя казер жарлыкаулы. 11 Эй сөйөклөляр, читтян килеўчелярдян, жул барыучылардан сораган кюк, жанга карышы тора торган тян няпесляреннян читкя китеўегезне сездян сороймын; 12 шулай тороб жалган деннеляр арасында сауаблы тормош белян жяшясягез эйе, алар ней өчөн сезне жауызлар итеб жаманнаган булсалар да, сезнен сауаблы эшлярегезне кюреб, килгян көннярендя Алланы даннасыннар ыйы. 13 Шулай Ходай какына ӓр-төрлө кеше башлыкларына баш салыб торогоз, ин оло башлык булган падшага мы, 14 жя анын жауызларга жаза бирергя, жя жакшылык кылыучыларны мактарга аннан куйылган бютян башлыкларга мы. 15 Алланын ирке шулай шул, жакшылык кыла тороб, акылсыз кешелярнен белемсез ауызларын без кабларга тейеш. 16 Иркенняр кюк торогоз, тик иркеннек усаллыкны каблаб калдырыу өчөн төгөл, ӓммя Алла коллары кюк булыгыз. 17 Барысын да кадерлягез, туганныкны сөйөгөз, Алладан куркыгыз, падшаны кадерлягез. 18 Эй кызмятчеляр, эялярегезгя ӓр-чакта куркыныу белян баш салыб торогоз,

арыуларына, жыуашларына гна тӧгӧл, ӓммя катыларына да. 19 Ӓгяр кем Алла какын уйлаб, гаделсездян азаб кюреб кайгыларга тюзя икян, Аллага шул жараулы. 20 Ӓгяр айыбыгызга кюря сезне кыйнасалар, мынын ӧчӧн нейдей макталыу? ӓммя сауаблык кылыб азабларга тюзсягез, шул Аллага жараулы,

Зач.59 21 сез шунӷар чакырылган шул; шулай Христосъ та безнен ӧчӧн азабланыб, без Анын эзеннян барсын диб, безгя кючергеч калдырды. 22 Ул бер нейдей дя жазык кылмады, Анын ауызында жалганчылык булмады (Ис. 53, 9). 23 Ӱзеня усал сюз ӓйтсяляр дя, карышы ӓйтмяде, азабланыб та жаманнамады: ӓммя аны гадел хокӧм Итеӱчегя табшырды. 24 Безнен жазыкларыбызны Ӱз Тяне белян Ӱзен Кач агачына кютярде, без жазыклардан жолоноб, дӧрӧслӧк ӧчӧн жяшясенняр диб. Анын жаралары белян сауыктыгыз шул. 25 Сез шу адашыб жӧргян кӧтӧӱчесез сарыклар кюк эйегез, ӓммя казер Кӧтӧӱчегя, жанарыгызны Саклаучыга кайттыгыз.

3-нче бюлем

1 Шулай сез дя, катыннар, ӱз ирлярегезгя баш салыб торогоз, ирлярнен кайсылары сӧйлягян сюзгя баш салмый, андыйлар сюзсез, катыннарынын тормошы белян табылыулы булсыннар, 2 сезнен Алладан куркыучан таза тормошогозны кюреб. 3 Сезнен матурлыгыгыз чяч ӱреӱдя, алтын ӓйберляр тагыуда, жя кубшы кейемдя, шундый тыш кылмышта булмасын, 4 ӓммя кеше эч кюнеленда сабыр, дяшмяӱчян тынны булсын, шул черемей торган матурлык, шул Алла алдында кыйбатлы. 5 Шулай кайчандыр Аллага ӧмӧтлянеб торган изге катыннар да ирляреня баш салыу белян ӱзлярен эямнягянняр. 6 Шулай Сарра да Авраамны, эям, диб атаб, анӷар баш салган, ӓгяр жакшылык кылсагыз, бер нейдей куркынычтан да шиклянмейче сез анын оланнары буласыз. 7 Шулай сез дя, ирляр, теляк итеӱлярегезгя комачаулык булмасын ӧчӧн халсез сауытлар кюк булган катыннарыгыз белян, алар дяӱлятле тормошны бергя алыучылар булганга кюря, акыллы кыйланыгыз. 8 Инде барыгыз да бер уйда, читеннектя

булышыучан, туганнарча сӧйӧӱле, изгелекле кюнӈелле, татыулыкны сӧйӧӱче, тыйнаклы булсагыз ыйы. 9 Усаллыкка усаллык белян, жя ӓрляшеӱгя ӓрляшеӱ белян кайтармагыз; ӓммя ӱзегезнен бахиллекне алырга тейешле булырга диб чакырылганыгызны белеб, бахиллягез.

Зач.60 10 Кем тере торасы киля, кем жакшы кӧнняр кюреӱне сӧя? Теленӈне жаманнан, ауызынӈны жумалаб сӧйляӱдян тый; 11 жаманнан читкя кит, жакшыны кыл; татыулыкны ээля, аны тот. 12 Ходайнын кюзляре гадел кешелярдя, Анын колаклары алар телягендя шул: Ходай жӧзӧн жаманнык кылыучыларга тота, аларны жир өстӧннян бетерейем диб. 13 Ӓгяр арыулыкка тырышсагыз, сезгя кем жаманнык кылар? 14 Ӓммя дӧрӧслӧк какына кыйын кюрсягез, сез бахетле; аларнын куркытыуларыннан курыкмагыз да, жӧдямягез дя, 15 кюнӈелегездя Ходай Алланы жактыртыгыз. Сезнен ӧмӧтлянеӱегез турында сездян сораучы ӓр кемгя сабырлык белян, кадерлек белян жауаб бирергя ӓр кайчан ӓзер булыб торогоз. 16 Арыу кюнӈелле булыгыз, сезне жауыз диб жаманнаучылар сезнен Христосъ какына булган тормошогозны, арыулыгыгызны кюреб оятлы булсыннар. 17 Ӓгяр Алла иркеня жараулы булса, жауызлык кылыб азаб кюргенче, жакшылык кылыб азаб кюреӱе жакшырак шул. 18 Шулай Христосъ та безне Аллага китерер ӧчӧн безнен жазыкларыбыз ӧчӧн бер табкыр азабланды, Гадел гаделсезляр ӧчӧн, Тяне белян ӱтерелеб, Тыны белян жанадан терелде. 19 Тыны белян Ул карантыда тороучы тыннар катына тӧшӧб, 20 бер багытта Ной кӧнняренда, кимя жасаган багытта, Алланын озак тюземнеге аларнын тяӱбягя килеӱлярен кӧткяндя дя буйсынмаганнарга ӱгет сӧйлягян, анда бик ӓзляр гня, ней бары сигез жан гына сыу арткылы котолган. 21 Казер безне дя Иисусъ Христоснын терелеб тороуы арткылы шунар ошашлы булган чумылыу коткара, чумылыу тяннен шакшысын жыуыу тӧгӧл, ӓммя арыу кюнӈелдян Аллага багадя биреӱ. 22 Иисусъ Христосъ кюккя кютярелеб, Алланын ун жагыннан утырган, Анар пяриштяляр, башлыклар, бар чиреӱляр баш салыб торалар шул.

4-нче бюлем

Зач.61 1 Шулай Христосъ Тяне белян безнен өчөн азабланган кюк, сез дя шул уйда коралланыб торогоз, тяне белян азабланыучы жазык кылыудан туктый шул. 2 Шул сяятлей инде тяндяге калган багытыгызны кешелек няпесляре белян төгөл, әммя Алла ирке белян жяшяб ўткярсягез эйе. 3 Ўткян багытыгызда жалган деннеляр иркен кылыб шакшылыкта, азгынныкта, эчкелектя, чамасыз артык ашауда, мал жыйыуда, Аллага жирянгеч сыннарга кызмят итеўдя жөрөб жяшяўегез сезгя житяр инде. 4 Сезнен алар белян шул азгын тормошка катышмаганыгызга аларнын исляре китя, шунар жаманныйлар да. 5 Терелярне дя, ўлгяннярне дя тиздян хокөм итяргя Тороучыга алар жауаб бирерляр. 6 Шунар ўлгяннярга дя арыу хабяр булган, алар тянняре буйынча хокөмгя тартылсалар да, тыннары белян Алла дигянчя торсоннар диб. 7 Алай да барысына да бетеў инде жакын, шул сяятлей арыу акылда булыгыз, теляк итеўдя уяу торогоз. 8 Барыннан да кюбряк бер-берегезгя кюнелдян сөйөўлегегез булсын, сөйөўлек бик кюб жазыкларны каблый шул; 9 жулдан килеўчелярне кабыл алыуны сөйөгөз, бер-берегезгя зарланмагыз. 10 Алланын кюб төрлө дяўлятляренен арыу жорт житкезеўчеляре кюк, кем нейдей бюляк алган, шунын белян бер-берегезгя кызмят итегез. 11 Әгяр беряў сөйлөй икян, Алла сюзляре кюк сөйлясен; беряў кызмят итя икян, Алла кюбме биря шул көчө белян кызмят итсен, барында да Iисусъ Христосъ арткылы Алла данналсын диб. Анар дан, тотоучылык гумердян гумергя. Аминь.

Зач.62 12 Эй сөйөклөляр, сезне сынар өчөн жибярелгян утта сыналыулар кюк сыналыулар булганда, читляшмягез, сезнен өчөнгя бу ис киткеч жат булыб саналмасын. 13 Әммя шулай Христоснын азабланыуларына катышыуыгызга сөйөнөгөз, Анын даны кюренгяндя оло сөйөнөч белян сөйөнөб кыуанырсыз. 14 Әгяр Христосъ исеме какына сезне жаманныйлар икян, сез бахетле, данныклы Тын, Алла Тыны сездя тора шул: алардан Ул курлана, әммя сезнен белян

даннала шул. 15 Тик сезнен арадан бер-бер кеше жя ўтереўче, жя урлаучы, жя жауыз, жя чит äйбергя ўренеўче кюк азабланмасын ыйы; 16 äгяр Христосъ исемен жөртөўче булганга азаб кюрся, алайса оялмасын, äммя шундыйга керешеўле булганына тау итеб Алланы даннасын. 17 Хөкөм башланыу багыты Алла öйөннян шул, äгяр элек бездян башлана икян, Алланын арыу Евангеліесеня баш салмаганнарга нейдей бетеў булыр? 18 Äгяр гадел дя кöчкя гня котоласы икян, айса шакшы, жазыклы кайда булыр? 19 Шул сяятлей, Алла ирке белян азаб кюреўчеляр арыу эшляр кыла тороб, ўз жаннарын гадел Булдырыучыга табшырсыннар ыйы.

5-нче бюлем

1 Мин дя сезнен кюк көтөўче, Христоснын азабларына таныкчы, ачыласы булган данына катышчы, сезнен көтөўчеляре-гезгя инялямен: 2 Аллага жараулы итеб, ирексездян төгöл, äммя иректян, жирянгеч байлык öчöн төгöл, äммя кюнел биреб, ўзегездя булган Алла көтөўен көтөгöз, 3 Алла öлöшöня баш булган кюк төгöл, äммя көтөўгя кючергеч булыб; 4 жыйыннын көтөўчеляр Башлыгы килеб кюренгяч, сез даннын шинмей торган венецын алырсыз. 5 Шулай кечеляре-гез дя көтөўчелярга баш салыб торогоз: барыгыз да бер-берегезгя баш салыб, жыуашлык белемнегеня кейенегез: Алла шу олосомакларга карышы тора, жыуашларга дяўлятен индеря.

Зач.63 6 Шулай Алланын кыуатлы кулы астында жыуашланыгыз, багыты житкяч, Ул сезне кютярер; 7 бар сагышларыгызны Анар салыгыз, Ул сезнен öчöн сагышлана шул. 8 Айык булыгыз, уяу торогоз, сезгя карышы булган шайтан кемне дя булса жотарга эзляб, арыслан кюк ўкереб жöрöй. 9 Дöньядя булган туганнарыгызга да шундый ук азаблар очраганны белеб, ныклы ышаныуыгыз белян анар карышы торогоз. 10 Іисусъ Христосъ какына Ўзенен мя ге данына безне чакырыб алыучы äр-төрлö дяўляткя бай Алла Ўзе сез äз багытта азабланыучыларны тулыландырыб житкезсен, ныгайтсын, ныкландырсын, кузгалмый торган итеб беркетсен эйе. 11 Анар дан, тотоучылык

гумердян гумергя. Аминь. 12 Силуанъ арткылы шушыны сезгя кыскача жаздым, мин уйлыйым, сезгя ул ышанычлы туган диб, сезне ышандырыр өчөн, сезне жыуатыб шушы сез тора торган ышаныу Алланын чын дяўляте икянен таныкладым. 13 Вавилондагы сезнен кюк сайланылган жыйын да, минем улым Маркъ та сезне чын кюнелдян жаратыб калалар. 14 Бер-берегезне сөйөўлек белян ўбеб, чын кюнелдян жаратыгыз. Iисусъ Христосъ какына сезнен барыгызга да тынычлык булсын. Аминь.

СВЯТЫЙ АПОСТОЛЪ ПЕТРНЫН АРЫУ ЖЫЙЫНГА ЖИБЯРГЯН ИКЕНЧЕ ЖАЗЫУЫ

1-нче бюлем

Зач.64 1 Симонъ Петръ, Іисусъ Христоснын мяндясе, апостолы, Аллабызнын да, Коткарыучыбыз Іисусъ Христоснын да дöрöслöгö арткылы кыйбатлы бяяле ышаныулыкны безнен белян тиң алыучыларга жаза. 2 Аллабызны, Ходайыбыз Христосъ Іисусны белеўлектя сездя дяўлят, тынычлык кюбяйсен. 3 Безне Ўзенен даны, арыулыгы белян Чакырыучыны аннаб белеуебез арткылы тормошка, арыу тороуга кирякле äр-ней безгя Анын Аллалык кыуаты белян бирелгян; 4 Ўзенен даны, арыулыгы белян безгя бик оло, кыйбатлы бяяле багадяляр биргян, шулар арткылы сез дöньядя öстöннöк иткян черетеўче няпеслярдян ауышыб, Аллалыкка катышыучылар булсыннар диб. 5 Шул сяятлей шунар бар тырышыуыгызны салыб, ышаныуыгызда арыулык кылыуыгызны кюрсятегез, арыулык кылыуда тикшереб белеўлекне, 6 тикшереб белеўлектя тыйнаклыкны, тыйнаклыкта тюземнекне, тюземнектя сауаблы тормошны, 7 сауаблы тормошта туганнарны сöйöўлекне, туганнар сöйöўлектя сöйöўлекне кюрсятегез. 8 Äгяр былар сездя бар икян, кюбяйяляр икян, ул чакта Ходайыбыз Іисусъ Христосны аннаб белеўдя сез жимешсез, житешлексез калмассыз. 9 Кемдя былар жук икян, ул сукыр, кюзлярен жомган, ўзенен элеке жазыкларыннан тазарынуны оноткан.

Зач.65 10 Шунар кюря, эй туганнар! Христосныкы диб аталыуыгызны, сайланыуыгызны бигряк тя ныk кюрсятергя тырышыгыз, шулай кылсагыз, сез бер чакта да жангышмассыз. 11 Шулай итеб, сезгя Коткарыучы Ходайыбыз Іисусъ Христоснын

мянге Падшалыгына керергя иркен жул ачылыр. 12 Шул сяятлей мин сезгя бу турыда, сез аны белеб, бу чынныкта ныкторсагыз да, бер чакта да исегезгя тӧшӧрӧўдян туктамам. 13 Шушы тян ӧйӧмдя торган чагында, мыны исегезгя тӧшӧрӧб, сезне сиргякляндереўне дӧрӧскя куйамын: 14 Ходайыбыз Іисусъ Христосъ мина белдергянчя, бу ӧйӧмнӧ мина тиз ташларга туры килер диб белямен. 15 Ӓммя сез мыны сунъяннан да, мин мыннан киткяч тя, жалан исегезгя тӧшӧрсягез эйе диб, гел тырышырмын. 16 Без Ходайыбыз Іисусъ Христоснын кыуатын, Анын килеўен сезгя сӧйлядек, тик аны хайля белян тӧзӧгян ӓкеят кюк сӧйлямядек, ӓммя Анын олологон ўз кюзебез белян кюреб сӧйлядек. 17 Бик зур ололок эченнян Анар: Шушы Минем сӧйӧклӧ Улым, Анда Минем ризалыгым диб (Мф. 17,5) ауаз килгян чакта, Ул Алла Атадан дан белян кадер алды. 18 Бу кюктян килгян ауазны без Анын белян арыу тау ӧстӧндя торган чакта эшеттек. 19 Аннан былай тагы бездя пагамбярлярнен бик дӧрӧс сюзе бар; шул сюзгя сез, карангы тӧштя жактыртыб торган жактырткычка барган кюк, анг салыб тороуыгыз белян жакшы эш кыласыз; бу сезнен кюнелегездя Алланы белеўлек танг белеген, кӧн жактыра башлаган кюк булгынчы булырга тейеш.

Зач.66 20 Инг алдан шуны белегез: Жазыудагы пагамбярлярнен бер сюзен дя ўз-ўзеннян гня уйлаб тикшереб аннарга жарамый. 21 Пагамбярлек сюзе бер чакта да кеше иркеннян сӧйлянмягян шул, ӓммя аны Святый Тын билгерткян буйынча, Алланын изге кешеляре сӧйлягян.

2-нче бюлем

1 Калыклар арасында жалган пагамбярляр дя булган, сезнен арагызда да жалган ӧйрятеўчеляр булыр, ўзлярен жолоучы Ходайдан танъыб, харяб итеўгя китереўче бозоб ӧйрятеўне кертерляр, ўз-ўзлярен тиз харяб булыуга биреряр. 2 Бик кюбесе аларнын бозоклогона эярер, шулар аркылы чыннык жулы кимчелектя булыр. 3 Мал жыйыу няпеслеге какында сезне хайляле сюзляр белян ауларлар: аларга хокӧм кюбтян ӓзер, харяб булыулары да жокла-

мый. 4 Ӓгяр Алла жазыкланган пяриштялярне кызганмаган, ӓммя тамукнын карангылык быгаулары белян бяйляб, кыйын тейерер өчөн хокӧм кӧнӧня сакларга табшырган икян; 5 ӓгяр элеке дӧньяне дя кызганмаган, тик дӧрӧслӧк сӧйляӳче Ноӣ ӧйӧндяге сигез жанны гна саклаб калыб, бозоклар дӧньясен сыу белян бастырган икян; 6 Содомъ, Гоморра калаларын да жандырыб, жук итеӳгя хокӧм иткян, аларны кӧлгя ӓйляндереб, шулай булачак жазыклыларга кючергеч кюрсяткян икян; 7 тагы чамасыз бозоклок кылыучылар арасында жяшяӳдян алжыган гадел Лотны коткарган икян - 8 бу гадел кеше алар арасында торганда кӧн дя законсызлык эшлярен кюреб, эшетеб, гадел жаны белян азаблаган шул, -

Зач.67 9 инде алайса Ходаӣ арыулыкта тороучыларны алданыулардан ничек коткарырга, ӓммя законсызларны азаб кюрсятер өчөн хокӧм кӧнӧня ничек сакларга беля; 10 бигряк тя тян азгынныклары шакшылыгы артыннан жӧрӧӳчелярне, башлыкларга буйсынмыӣ торганнарны, каты сюзлелярне, ӳзляре дигянчя гня кылыныучыларны; алар кюктяге чиреӳлярне курлаудан да курыкмыйлар. 11 Пяриштяляр алардан кюбкя кыуатлырак, кӧчлӧряк булсалар да, ич кайчан аларга Ходаӣ алдында курлау хокӧмӧ кылмыйлар. 12 Ӓммя былар телсез тыуарлар кюк, ӳз телягянняре артыннан жӧрӧйляр, тотолоб жукка чыгыу өчөн гня тыуганнар, неӣ курлаганнарын анъышмыйлар, ӳз череӳляренде жукка чыгарлар. 13 Алар законсызлыкларына карата тейешлесен алырлар: кӧн дя рахятлектя аркылгынчы ашау-эчеӳдян тям табалар, шакшылар, шакшыландырыучылар, сезнен белян ашаб-эчеб, ӳз жалганныклары белян рахятлек табалар. 14 Кюзляре азгыннык кылмышына, туктаусыз жазыкка тулы, алар ныгымаган жаннарны кызыктыралар, кюнелляре мал жыйыуга биренгян, былар каргыш уллары. 15 Туры жулны калдырыб алар адашканнар, дӧрӧссӧзлӧк бюляген сӧйӧӳче Восоръ улы Валаамъ эзеннян киткянняр; 16 ӓммя анын законсызлыгы ачылган: телсез ишяк ӓдям ауазы белян телгя килеб, пагамбярне акылсызлыктан туктаткан. 17 Былар сыусыз чишмяляр, жилляр белян кыуылыб жӧрӧлӧӳче томанны болотлар, аларга мянге

карантылык урны äзерлянгян шул.
18 Кюпертелгян буш сюзляр сöйляб, жангышыучылардан кöчкя гня калышканнарны алар тян няпесеня, бозоклокка аулыйлар; 19 ўзляре череўлек коллары була тороб, аларга иркеннек бирмякче булалар: äммя кем кемгя жинелгян, ул шунар кол да була шул. 20 Ягяр Коткарыучы Ходайыбыз Іисусъ Христосны белеўлек арткылы дöнья шакшылыгыннан китеўчеляр жанадан да шуларга буталыб жинелсяляр, мындыйлар öчöн сунгысы элекесеннян дя жаманырак булыр. 21 Дöрöслöк жулларын белеб тя, ўзляреня бирелгян изге бойороктан кире киткенче, аларга дöрöслöк жулын белмяў жакшырак булыр ыйы. 22 Äммя äйтелгян чын мясял: эт ўз косогона кайта, жя: жыуылган дунгыз сазда ауларга бара, дигяне аларга бик туры киля.

3-нче бюлем

Зач.68 1 Эй сöйöклöляр, инде сезгя икенче жазыуымны жазамын, алар белян сезнен исегезгя тöшöрöб, таза уйларыгызны уятамын: 2 сез изге пагамбярлярнен элеке сöйлягян сюзлярен, сезгя апостолларыгыз житкергян Коткарыучы Ходайыбызнын бойорокларын исегездя тöшöрсönняр диб. 3 Иң алдан шуны белеб торогоз, калдык könнярдя ўз няпесляре буйынча жöрöўче, оятсызланыб мыскыллаучылар кюренерляр, 4 алар: кайда Христоснын килясе дигян багадясе? дöнья булдырылганнан бирле ничек аталарыбыз ўля башлаганнар, бар да шул килеш тора ич, дирерляр. 5 Былай уйлаучылар белмейляр шул: баштанук ничек Алла сюзе белян кюкляр дя, жир дя сыудан булдырылганны, сыу белян тöзöлгянне. 6 Шунар кюря ул багыттагы дöнья сыуга бастырылыб жук ителгян. 7 Äммя Алла Сюзе белян тотолоб тора торган казерге кюкляр дя, жир дя хокöм könöня бозок кешеляр-не бетерер öчöн утка сакланалар.
8 Эй сöйöклöляр, сездян бер шул жяшерен булырга тейеш тöгöл, Ходай алдында бер кön мең жыл кюк, мең жыл бер кön кюк. 9 Кайберяўляр озак диб уйлаганча, Ходай багадясен кылыб житкезеўне озаклатмый: äммя безгя озак тюзя, беряўнен дя харяб булыуын телямей, äммя барысынын

да тяўбягя килеўен телей. 10 Бур
тӧння килгян кюк, Ходайнын да
кӧнӧ шулай килер, шунда кю-
кляр шаулаб бетярляр, жирнен
нигезляре жаныб жимерелерляр,
жир дя, андагы булган эшляр дя
жанарлар. 11 Шулай бары да жи-
мерелясе булгач, сез изге, арыу-
сауаблы тормошта тороучыларга
нейдей булыу тейеш, 12 Алланын
килер кӧнӧн киряксенеб кӧтӧб то-
роучыларга? Анда кюкляр жал-
кыннаныб жаныб жимерелер,
жирнен нигезляре жалкыннан
эреб бетяр. 13 Без шул Анын ба-
гадясе буйынча, аларда дӧрӧслӧк
жяшей торган жаңа кюкне, жаңа
жирне кӧтябез. 14 Шул сяятлей,
эй сӧйӧклӧляр, мыны кӧткяндя
ўзегезне шакшыландырмыйчы
бозоксоз, таза кӧйӧ, татыулыкта
тотоб, Алла алдында кюренер-
гя тырышыгыз. 15 Ходайыбыз-
нын озак тюземнеген котолоу
диб санагыз, сӧйӧклӧ туганыбыз
Павелъ да ўзеня бирелгян белем-
неге белян сезгя шуны жазды. 16
Ўзенен бар жибяргян жазыула-
рында да ул шул турда әйтя: алар-
да анӊау ӧчӧн кайбер кыйыннык
бар, белемсезляр, ныгымаганнар
ўзляреня харяб булыр ӧчӧн баш-
ка Жазыулар кюк, аларны да бо-
зоб анӊыйлар. 17 Шулай сез, эй
сӧйӧклӧляр, шушынын турында
сезгя алдан әйтелгяннек буйынча
сакланыгыз, законсызлар алдан-
дырыуына алданыб, ўзегезнен
ныгытылыуыгыздан читкя китя
кюрмягез. 18 Әммя Коткарыучы
Ходайыбыз Ісусъ Христоснын
дяўлятендя, Аны белеўлектя
ўсегез. Анар дан булсын әле дя,
мянге кӧндя дя. Аминь.

СВЯТЫЙ АПОСТОЛЪ ІОАННЪ БОГОСЛОВНЫН АРЫУ ЖЫЙЫНГА ЖИБЯРГЯН БЕРЕНЧЕ ЖАЗЫУЫ

1-нче бюлем

Зач.68 1 Äўялтеннянўк булган, без эшеткян, ўз кюзляребез белян кюргян, ўзебез кюреб тороб аннаган, кулларыбыз тотоб караган терелек Сюзе турында жазамын. 2 Терелек кюренде шул, без Аны кюрдек тя, таныклыйбыз да, Атада булыб безгя кюренгян мянге терелек турында сезгя хабяр итябез. 3 Без ней кюргянне, ней эшеткянне сез дя безнен белян катышыулы булсыннар диб сезгя хабяр итябез. Безнен катышыулыгыбыз Ата белян дя, Анын Улы Іисусъ Христосъ белян дя шул. 4 Безнен сöйöнöчöбез тулы булсын диб мыны сезгя жазабыз да. 5 Мына без Аннан эшеткян арыу хабярне сезгя дя житкезябез: Алла жакты, Анда бер нейдей дя карангылык жук. 6 Äгяр дя без Анын белян катышыулыгыбыз бар диб äйтеб, ўзебез карангыда жöрöйбез икян, ул чакта без жалганныйбыз, чынлык буйынча кыйланмыйбыз. 7 Äгяр Ул жактыда булган кюк, без дя жактыда жöрöйбез икян, ул чакта безнен бер-беребез белян катышыулыгыбыз бар, Анын Улы Іисусъ Христоснын Каны безне äр төрлö жазыклардан тазартыр.

Зач.69 8 Äгяр жазыгыбыз жук диб äйтябез икян, ўз ўзебезгя жалганныйбыз, бездя чынлык булмый. 9 Äгяр жазыкларыбызны äйтеб таныйбыз икян, Ул ышанычлы да, гадел дя булганга кюря, безнен жазыкларыбызны кичерер, безне äр төрлö дöрöс-сöзлöктян тазартыр. 10 Äгяр дя без жазыкланмадык диб äйтябез икян, Аны жалганчы итеб кюрсятябез, Анын сюзе бездя жук та.

2-нче бюлем

1 Эй балаларым! сез жазыкланмасын диб мыны сезгя жазамын, ägяр дя кем жазыкланса, безнен бит Ата алдында жалбарыучы гадел Іисусъ Христосыбыз бар. 2 Ул безнен жазыкларыбыз öчöн Атанын кюнелен табыучы, безнеке öчöн гня тöгöл, ämмя бötöн дöнья жазыклары öчöн дя. 3 Без Аны анна б белеуебезне Анын бойорокларын кылыуыбыз буйынча белябез. 4 Ämмя кем мин Аны анна б белдем диб äйтеб, ўзе Анын бойорокларын кылмый икян, ул жалганчы, анда чыннык жук. 5 Кем Анын сюзлярен тота икян, анда Алланын сöйöўлеге чыннаб тулы, без Аллада икянебезне шуннан белябез дя. 6 Кем мин Аллада торам дей, ул кеше Христосъ кыйланган кюк кыйланырга тейеш.

Зач.70 7 Эй сöйöклöляр! Мин сезгя жана бойорок жазмыйым, ämмя äўялеге бойорокны, сездя баштанук булганны жазамын, äўялеге бойорок баштанук сез эшеткян сюз ўзе. 8 Шунын öстöня сезгя жана бойорок та жазамын, чыннаб Аллада да, сездя дя булганны: карангылык узыб бара, чын жакты инде жактырта. 9 Кем ўзен мин жактыда дей, ämмя ўзенен туганын кюрялмый, ул äле карангыда тора. 10 Кем ўзенен туганын сöя, ул жактыда тора, анда алданыулык жук. 11 Кем ўз туганын кюрялмый, ул äле карангыда тора, карангыда жöрöй дя, кая барганын да белмей, карангылык анын кюзен сукырайткан шул. 12 Эй балалар! Христосъ исеме какына сезгя жазыкларыгыз кичерелгянгя кюря сезгя жазамын. 13 Эй аталар! Баштанук Тороучыны сез таныганга кюря мин сезгя жазамын. Эй жегетляр! Сез жаманны жингянгя кюря сезгя жазамын. Эй малайлар! Сез Атаны таныганга кюря сезгя жазамын. 14 Эй аталар! Сез була башлаган чагы Жукны таныганга кюря мин сезгя жаздым. Эй жегетляр! Сез кöчлö булганга, Алла Сюзе сездя тороб, сез жаманны жингянгя кюря мин сезгя жаздым. 15 Бу дöньяне дя, дöньядя булган нястялярне дя сöйöб тормагыз, бу дöньяне сöйгян кешедя Атаны сöйöўлек жук. 16 Бу дöньядя булган нястяляр тян няпесе, кюз няпесе, тормош олосомаклыгы, былар Атадан тöгöл,

ӓммя бу дӧньядян чыгалар. 17 Бу дӧнья дя, анын няпесе дя узыб китяр, ӓммя Алла иркен кылыб тороучы гумердян гумергя торор.

Зач.71 18 Эй балалар! казер азакы багыт, сез антихристъ килер диб эшеткян буйынча, казер антихристлар кюб чыктылар, шунныктан без азакы багыт икянен белябез дя. 19 Алар бездян чыктылар, тик безнекеляр булмаганнар, ӓгяр безнекеляр булган булсалар, безнен белян калырлар ыйы, ӓммя алар чыктылар, шунын арткылы безнекеляр булмаганы ачыкланды да. 20 Шулай да, сез ӱзегез дя Изгедян майланылган, барын да белясез. 21 Минем сезгя жазыуым сез чынныкны белмейляр диб тӧгӧл, ӓммя сез аны белясез, тагы ӓр-бер жалганчылык чынныктан тӧгӧл икянне дя белясез. 22 Кем жалганчы сун? Іисуснын Христосъ икянен кире кагыучы тӧгӧл ме? Атаны да, Улны да кире кагыучы бу - антихристъ. 23 Улны кире кагыучы ӓр кем Атада да була алмый, Улны таныклаучы Атада да була. 24 Шулай баштанук сез ней эшеткян, шул сездя торсон, ӓгяр сез баштанук эшеткян сюз сездя торса, ул чакта сез Улда да, Атада да торорсоз. 25 Ул сезгя багадя итеб ӓйткян сюз мянге тормош ӱзе. 26 Мин мыны сезгя сезне жантыштырырга тырышыучылар булганга кюря жаздым. 27 Шулай Христостан алган майланыуыгыз сездя торганга кюря, беряӱ-беряӱ сезне ӧйрятеуе дя сезгя киряк тӧгӧл, шул майланыу ӱзе сезне барысына да ӧйрятя, ул чын да, жалгансыз да. Шунар кюря ул сезне нейгя ӧйряткян, шунда гна торогоз. 28 Шулай балалар, Христоста торогоз, Ул килеб кюренгян чакта Анын алдында кыйыулыгыбыз булыб, Анын алдында оятка калмас ӧчӧн. 29 Ул гадел икянне сез белясез икян, ӓр-бер дӧрӧслӧк кылыучы Аннан тыуган икянне дя белегез.

3-нче бюлем

1 Карагыз, кюктяге Ата безгя нейдей сӧйӧӱлек биргян, безне Алла оланнары булсыннар диб, шулай диб аталсыннар да диб. Дӧнья Аны танымаган, шунныктан безне дя белмей. 2 Эй сӧйӧклӧляр! Без бит казер Алла оланнары, тик нейдей буласыбыз ӓле ачылмаган. Тик шуны гна белябез: ачылгач, Анар ошашлы булыр-

быз, Ул ничек икянен кюрербез шул. 3 Анар шушындый ӧмӧтне тотоучы ӓр кем, Ул ничек таза, ӱзен дя шулай тазарта. 4 Жазык кылыучы ӓр кем законсызлык та кыла, жазык ӱзе законсызлык шул. 5 Сез белясез: Анда бит жазык жук, тик безне жазыклары-быздан тазартыр ӧчӧн Ул килеб кюренгян. 6 Анда тороучы ӓр кем жазыкланмый, жазыкланыучы ӓр- кем Аны кюрмягян дя, Аны татымаган да. 7 Эй балалар! сезне беряӱ дя алдандырмасын, ничек Ул гадел, дӧрӧслӧк кылыучы да шулай гадел була. 8 Кем жазык кыла икян, ул шайтаннан, башта бит шайтан жазыкланган. Шуна кюря шайтаннын эшлярен жимерер ӧчӧн Алла Улы дӧньягя кюренгян. 9 Алладан тыуган ӓр-кем жазык кылмый, Анын дяӱляте анда тора шул, Алладан тыуганга кюря, ул жазык кыла алмый.

Зач.72 10 Алла оланнары мы, шайтан оланнары мы икяне былай беленя; дӧрӧслӧкне кылмый торган, тагы ӱз туганын кюрялмый торган ӓр-кем Алладан тӧгӧл. 11 Сез баштанук эшеткян арыу хабяр шундый: без бер-беребезне сӧяргя тейеш. 12 Усалдан булган Каинъ кюк тӧгӧл, ул ӱзенен туганын ӱтергян, аны ней ӧчӧн ӱтергян? шунын ӧчӧн: анын эшляре усал булган, ӓммя туганы Авельнын эшляре гадел булган. 13 Эй туганнарым, ягяр дя дӧнья сезне кюрялмаса, мынар исегез китмясен. 14 Без туганнарыбызны сӧйгянебезгя кюря, ӱлемнян терелеккя кючкянебезне белябез. Туганын кюрялмый торган кеше, ӱлем тоткононда тора. 15 Туганын кюрялмый торган ӓр-кем кеше ӱтереӱче була, сез белясез, бер нейдей кеше ӱтереӱче дя ӱзендя тора торган мянге тормошта булалмый. 16 Сӧйӧӱлекне без шуннан татыб белдек: Ул безнен ӧчӧн жанын биргян, без дя шулай туганнарыбыз ӧчӧн жаныбызны бирергя тейеш. 17 Ягяр кем бу дӧньядя барлык белян торган кӧйӧ, ӱз туганынын жӧдяӱгя калганын кюря тороб, аннан ӱз кюнелен бикляся, анда Алланын сӧйӧӱлеге ничек тора алыр? 18 Эй балаларым, сюзебез белян гня, телебез белян гня сӧймӧйӧк, ӓммя эшебез белян, чынлык белян сӧйӧйӧк. 19 Шуннан чынлыкта икянебезне белербез дя, Анын алдында кюнелляребезне тынычландырырбыз. 20 Ягяр кюнелебез безне айыблый икян,

Алла бигряк тя айыбламас меней, Алла бит кюнелляребездян артыгырак беля, барысын да беля. 21 Эй сӧйӧклӧляр! ягяр кюнелебез безне айыбламый икян, алай булса безнен Аллага кыйыулыгыбыз булыр.

Зач.73 22 Ней гня сорасак та Аннан алырбыз, Анын бойорокларын тотабыз шул, Анын алдында Анар жараулыны кылабыз. 23 Анын бойорого шул: без Анын Улы Іисусъ Христоснын исеменя ышанырга тейеш, Ул безгя бойорганча, бер-беребезне сӧягя тейеш. 24 Кем Анын бойорокларын тота, ул Аллада тора, Алла да анда тора. Ул бездя торганны, без Ул безгя биргян Тыны буйынча белябез.

4-нче бюлем

1 Эй сӧйӧклӧляр! Яр-бер тынга да ышанмагыз, яммя тыннарны сынаб карагыз, Алладан микян алар, казер бит кюб жалган пагамбярляр дӧньягя чыктылар. 2 Алла тыны мы, жангыштырыучы тын мы икянен былай белегез: тяннянеб килгян Іисусъ Христосны таныклаучы яр-бер тын Алладан була; 3 яммя тяннянеб килгян Іисусъ Христосны таныкламый торган яр-бер тын Алладан булмый, яммя антихристъ тыны була, ул килер диб сез эшеткян эйегез, казер ул дӧньядя бар инде. 4 Эй балалар, сез бит Алладан, шунар кюря аларны жиндегез дя, сездя Тороучы дӧньядяге тыннан олорак шул. 5 Алар дӧньядян, шунар кюря дӧньячя сӧйлӧйляр дя, дӧннья аларны тынный да. 6 Без Алладан, Алланы белеўче безне тынный; кем Алладан тӧгӧл, ул безне тынамый. Чыннык тыны мы, жангыштырыучы тын мы икянен шунын буйынча белябез. 7 Эй сӧйӧклӧляр, бер-беребезне сӧйӧйӧк, сӧйӧўлек Алладан шул, яр-бер сӧйӧўлеккя тулы кеше Алладан тыуган, Алланы беля дя. 8 Кем сӧймӧй, ул Алланы татымаган, Алла Ўзе сӧйӧўлек шул. 9 Алланын сӧйӧўлеге безгя шуннан ачылган, Алла Ўзенен жангыз тыуган Улын без Анын арткылы терелек алсыннар диб дӧньягя жибяргян. 10 Сӧйӧўлеге шуннан тора: без Алланы сӧя башламаган кӧйӧ Ул безне сӧйӧб, Ўзенен Улын безнен жазыклары-бызны кичертеў ӧчӧн, Алланын

кюнелен табыр өчөн жибяргян. 11 Эй сөйөклөляр! ягяр Алла безне шулай сөйгян икян, без дя бер-беребезне сөяргя тейеш. 12 Аллаы беряў дя бер чакта да кюргяне жук; ягяр дя без бер-беребезне сөйсяк, бездя Алла тороуы була. 13 Без Аллада, Алла бездя торганны без Ул безгя Ўзенен Святый Тынын биргяннян белябез. 14 Ата Ўз Улын дөньяне Коткарыучы итеб жибяргянне без кюрдек тя, таныклыйбыз да. 15 Ісусны Алла Улы диб сөйляўче ăр-кемдя Алла тора, ул да Аллада тора. Без Алла безне сөйгян сөйөўлекне белдек, анăр ышандык та. 16 Алла сөйөўлек, сөйөўлектя тороучы Аллада тора, Алла да анда тора. 17 Сөйөўлек бездя шул хатле тулылана, безнен хокөм көнөндя дя кыйыулыгыбыз булыр, бу дөньядя Ул кылынганча кылынабыз шул. 18 Сөйөўлектя куркыныч жук, тулы сөйөўлек куркынычны кыуыб жибяря, куркынычнын азабы була шул; курыкканнын сөйөўлеге тулы булмый.

Зач.74 19 Инде айса Аны сөйөйөк, Ул безне иң элеке сөйгян шул. 20 Кем мин Аллаы сөям дей, ăммя ўз туганын кюрялмый, ул жалганчы була, ўз туганын кюреб тя сөймягян кеше, Аллаы кюргяне жук көйө ничек сөя алсын. 21 Аннан безгя шундый бойорок бар: Аллаы сөйөўче ўз туганын да сөяргя тейеш.

5-нче бюлем

1 Ісусны Христосъ диб ышаныучы ăр-кем Алладан тыуган, Тыудырыучыны сөйөўче ăр кеше Аннан тыуганны да сөя. 2 Без Алла оланнарын сөйөўебезне, Аллаы сөйөўлегебездян, Анын бойорокларын кылыуыбыздан белябез. 3 Безнен Алланын бойорокларын тотоуыбыз Аны сөйөўлек ўзе була, Анын бойорокларын тотоу ауыр төгөл. 4 Алладан тыуган ăр-кем бу дөньяне жиня, бу дөньяне жинтян жинеўлек, безнен ышаныуыбыз шул. 5 Кем дөньяне жиня суң, Ісуснын Алла Улы икяненя ышаныучы төгөл ме? 6 Бу Ісусъ Христосъ сыу белян, кан белян, тын белян килеўче, сыу белян гня төгөл, ăммя сыу белян дя кан белян дя, Анын турында Тын таныклый, Тын Ўзе чыннык шул. 7 Кюктя шуны Өчяў таныклый: Ата, Сюз, Святый Тын, бу Өчяў - Бер булыб

санала. 8 Жирдя дя өчяӳ таныклыйлар: тын, сыу, кан, бу өчөсө - бергя шул. 9 Ӓгяр дя без кеше таныклаганны да кабыл алабыз икян, Алланын таныклауы олорак ич, бу Алла таныклыгы шул, шунын белян Алла Ӳзенен Улы турысында таныклый. 10 Алла Улына ышаныучынын таныклыгы ӳз эчендя; ӓммя Аллага ышанмый торган кеше Аны жалган итеб кюз алдына китеря, ул шу Алла Ӳз Улы турысында таныклаган таныклауга ышанмый. 11 Бу таныклау шуннан тора: Алла безгя мянге тормош бюляк итеб биргян, бу мянге тормош Анын Улында тора. 12 Алла Улын белеӳченен мянге тормошы бар, ӓммя Алла Улын белмягяннен мянге тормошы да жук. 13 Мына мин сезгя, Алла Улынын исеменя ышаныучыларга, шушыны жаздым, сез Алла Улына ышаныучыларнын мянге тормошо барны сез белсенняр диб. 14 Мына безнен Анар нейдей кыйыулыгыбыз бар, ӓгяр Анын ирке буйынча ней сорасак та, Ул безне тыңнар. 15 Шулай без ней сорасак та Ул безне тыңнасыны инде белгяч, Аннан сораганыбызны аласыбызны да белябез. 16 Ӓгяр дя кем ӳз туганын ӳлем жазыгы булмаган жазыкланыуда кюря икян, анын өчөн теляк итсен, Алла анар ӳлем жазыгында булмаганга кюря терелек бирер. Ӳлемгя итеӳче жазык бар; ул жазык турында теляк итсен диб ӓйтмейем. 17 Ӓр-бер дөрөссөзлөк жазык була, алай да ӳлемгя итмей торган жазык та була. 18 Алладан тыуган ӓр-кемнен жазык кылмаганын без белябез, Алладан тыуган ӳзен саклый шул, усал анар кагыла алмый. 19 Ӳзебезнен Алладан булганыбызны, бөтөн дөнья усаллыкка батканны да без белябез. 20 Тагы Алла Улы килеб безгя чын Алланы белергя жакты да, анӈау да биргянне белябез, без Анын чын Улы Іисусъ Христоста торсоннар диб. Ул чын Алла да, мянге тормош та. 21 Эй балалар! Ӳзегезне сыннарга кызмят итеӳдян саклагыз. Аминь.

СВЯТЫЙ АПОСТОЛЪ ІОАННЪ БОГОСЛОВНЫН АРЫУ ЖЫЙЫНГА ЖИБЯРГЯН ИКЕНЧЕ ЖАЗЫУЫ

Зач.75 1 Сайланган анабызга, анын оланнарына да, аларны чыннык белян сөйгянемя кюря мин жыйын башлыгы жазамын, мин гня төгөл, әммя чынныкны таныучылар барысы да сөяляр. 2 Безнен эчебездя тора торган чыннык какына сөяляр, чыннык безнен белян гумергя торор. 3 Алла Атадан, Атанын Улы Ходай Іисусъ Христостан бирелгян дяўлят, изгелек, тынычлык чынныкта, сөйөўлектя сезнен белян булсын. 4 Без Атадан чынныкта тороу өчөн бойорок алганча синең оланнарынның шул чынныкта жөргяннярен табыб мин бик сөйөндем. 5 Эй анабыз! синә жанә бойорок жазмыймын, әммя баштанук бездя булган бойорокны жазамын, без бер-беребезне сөйсяк эйе. 6 Сөйөўлек ул шуннан тора, без Анын бойороклары буйынча жөрөргя тейеш, бу сез баштанук эшетеб, анын буйынча жөрөргя тейешле бойорок. 7 Казер кюб жангыштырыучылар, тяне белян килгян Іисусъ Христосны таныкламый торганнар дөньягя керделяр, мындый кеше жангыштырыучы да, антихристъ та. 8 Без иткян кызмятебезне жугалтмас өчөн, әммя тулы бюляк алыр өчөн сак торойок. 9 Христоснын өйряткянен тотмой торган, ул өйрятеўдя тормой торган әр-кем Алла белян булмый, әммя Христоснын өйрятеўен тотоучы Ата белян дя, Улы белян дя була. 10 Кем сезгя килеб, шушы өйрятеўне алыб килмяся, аны жортогозга кунак итеб кабыл алмагыз. 11 Мыны кылыучы анын усал эшляреня катышыучы була. 12 Сезгя кюб жазар

сюзем бар, тик кагазгя кара белян жазасым килмеӈ, әммя сезгя килеб, сезнен сөйөнөчөгөз тулы булсын диб, ауызга ауыз куйыб сөйләшеб утырырга өмөтөм бар.
13 Сайланган кыз кардәшеңнен оланнары сине кюнелдян жаратыб калалар. Аминь.

СВЯТЫЙ АПОСТОЛЪ ІОАННЪ БОГОСЛОВНЫН АРЫУ ЖЫЙЫНГА ЖИБЯРГЯН ӦЧӦНЧӦ ЖАЗЫУЫ

Зач.76 1 Мин жыйын башлыгы сӧйӧклӧ Гаийга, чыннаб аны сӧйгянемя кюря жазамын. 2 Эй сӧйӧклӧм! мин синең исянсау тороуың какында, синең жаның житешеўле булган шикелле, бар турдан да житешеўлеген какында теляк итямен. 3 Туганнар килеб синең ышаныуың турында, синең чыннykта жӧрӧўең турында таныклаб айткяч, мин бик сӧйӧндӧм. 4 Балаларым чыннykта жӧргянне эшетеўдян дя артык минем ӧчӧн бер сӧйӧнӧч тя жук шул. 5 Эй сӧйӧклӧм! син туганнар ӧчӧн дя, читтян килгянняр ӧчӧн дя эшляўең белян ышаныучыга килешлечя кылынасың. 6 Алар жыйын алдында синең сӧйӧўлеген турысында таныкладылар, ӓгяр Алла какына аларны тейешлечя жибярясең икян, син бик ӓйбят кыласың. 7 Алар шу жалган деннелярдян бер ней дя алмыйчы, Алла исеме какына жулга чыкканнар. 8 Чыннykка катышыучылар булыр ӧчӧнгя без шундыйларны кабыл алырга тейеш. 9 Мин жыйынга жазган ыйым, алай да аларда беренче буласы килеўче Диотрефъ безне кабыл алмый. 10 Шунар кюря ӓгяр дя мин киля калсам, анын кылган эшлярен, нейляр кылганын иска тӧшӧрӧрмен, безне усал сюзляр белян курлый, аннары анар гна риза булмыйчы, ўзе дя туганнарны кабыл алмый, кабыл аласы килеўчелярга дя ирек куймый, чиркяўдян ўк кыуыб чыгара. 11 Эй сӧйӧклӧм, усаллыкка ошарга тырышма, ӓммя арыулыкка ошарга тырыш. Кем арыулык кыла, ул Алладан, ӓммя усаллык кылыучы Алланы кюрмягян. 12 Димитрий турында барысы да, чыннык ўзе дя таныклаганнар, шулай ук без дя

таныклыйбыз, безнен таныклауыбыз чын икянне сез дя белясез. 13 Кюбне жазарлыгым бар, тик кагазгя кара белян, жазгыч белян жазасым килмей. 14 Ӓммя сине тиздян кюреб, ауызга ауыз куйыб сөйляшеб утырырга өмөтөм бар. 15 Сиңа тынычлык булсын. Сине дуслар кюңелдян жаратыб калалар. Дусларыңны исемняб кюңелдян жаратыуыбызны житкез. Аминь.

СВЯТЫЙ АПОСТОЛЪ ІУДАНЫН АРЫУ ЖЫЙЫНГА ЖИБЯРГЯН ЖАЗЫУЫ

Зач.77 1 Іуда Іисусъ Христоснын мяндясе, Іаковнын туганы, чакырыб алынганнарга, Алла Ата Ӱзе арыуландырганнарга, Іисусъ Христосъ Ӱзе саклаб калдырганнарга; 2 сездя изгелек, тынычлык, сӧйӧӱлек кюбяйсен. 3 Эй сӧйӧклӧляр! сезгя барыбызда булган котолоулык турысында жазасым килгян эйе, ӓммя бер тапкыр изгелярга бирелгян ышаныу турысында тырышырга ӧндяӱ сюзе жазыуны киряклеряк санаб, шуны жазарга уйладым. 4 Нейдейдер бозок кешеляр, ӓӱялтеннянӱк бу туры хокӧмгя билгелянгянняр жыйынга керделяр. Алар Алланын дяӱлятен азгын тормошларына ынтайлыйлар, бер гня булган Башкарыучы Аллаяны да, безнен Ходайыбыз Іисусъ Христосны да кире кагалар. 5 Мин сезгя, мыны белеӱчелярга, исегезгя тӧшӧрясем киля, Ходай калыкны Египет жиреннян коткарган, аннары ышанмаганнарын жук иткян. 6 Ӱзляренен олологон сакламаган, ӓммя ӱзляренен торган жирлярен ташлаган пяриштялярне дя, мянге быгауда, карангы жирдя оло хокӧм кӧнӧня саклаб тора. 7 Содомъ белян Гоморраны да, шуларга ошашлы азгыннык иткян алар тирясендяге калаларны да, бютян тейешсез тян артыннан жӧрӧӱчелярне мянге утнын азабына тӧшӧрӧб, кючергеч итеб куйган. 8 Бу шушындый уйда тороучыларга да гел шулай булыр, алар тяннярен шакшыландыралар, башлыкларны кире кагалар, оло башлыкларга усал сюзляр ӓйтяляр. 9 Архангелъ Михаилъ да Моисейнен тяне турысында ӓйтеб, шайтан белян сюз ирештергян чакта, анар каты хокӧм итергя кыйыучылык итмягян, ӓммя: Ходай сине тыйсын, дигян. 10 Ӓммя былар ӱзляре белмягян кӧйӧ усал сюзляр

äйтяляр; телсез терлекляр кюк булмышларыннан неӣ белсяляр, шунда ӱз-ӱзлярен черетяляр.

Зач.78 11 Кайгы аларга, алар шул Каинъ жулы белян баралар, Валаамъ шикелле тейешсез бюлякkя кызыгыб биренгянняр, Корей шикелле ӱзляренен кирелекляре белян харяб булалар. 12 Мындыйлар сезнен сöйöӱлек кичляpендя алдандырыучылар, сезнен белян бергя ашаб-эчеб, курыкмыйчы ӱз-ӱзлярен симертяляр. Былар жил белян кыуылыб жöртöлöӱче сыусыз болотлар, ике кат ӱлеб, жолконоб ташланылган, жимеш китермеӣ торган кöзгö агачлар. 13 Былар ӱзляренен шакшылыклары белян кюбек чыгарыучы дингез тулкыннары, адашыб жöрöӱче жондозлар, алар öчöн мянге карангылык урны äзерлянгян. 14 Алар турысында Адамнан башлаб жиденче булган Енохъ та пагамбярлек итеб äйткян: Мына Ходаӣ Ӱзенен бик кюб изге пяриштяляре белян килер, 15 барысына да хокöм итяр, алар арасындагы бозокларны кылган барлык бозок эшляpендя, жаман жазыклыларны Анар äйткян бар тöрлö каты сюзляpендя билгеле итяр, дейгян. 16 Былар бер неӣ белян дя кюнелляре тыныч булмыйчы зарланыб жöрöӱчеляр, ӱз няпесляре телягянне бозоклок, законсызлык белян кылыучылар, аларнын ауызлары да сюзлярне кюпертеб äйтяляр, ӱз пайдалары öчöн кешелярне жумалыйлар. 17 Ämмя сез, эй сöйöклöляр, безнен Ходайыбыз Іисусъ Христоснын апостоллары алдан äйткян сюзлярне исегездя тотогоз. 18 Алар сезгя: сунгы багытта сюгеӱчеляр, ӱзляренен бозок няпесляре дигянчя гня кылыныучылар килеб чыгарлар, диб äйткянняр эйе. 19 Былар бер тöрлö гня ышаныудан ӱзлярен айырыучылар, аларнын жаннары бар, ämмя аларда Тын жук. 20 Ämмя сез, эй сöйöклöляр, ӱзегезнен изге ышаныуыгызда ӱсегез, Святыӣ Тын öйряткянчя теляк итеб, 21 Ходайыбыз Іисусъ Христостан изгелек кöтöб, мянге тормош öчöн ӱзегезне Алланын сöйöӱлегендя саклаб торогоз. 22 Бер тöрлölярне тикшереб, аларга изгелекле булыгыз. 23 Икенче тöрлölярне куркытыб, уттан жолоб алыб коткарыгыз, куркытыб жазыкларын äйтеб кюрсятегез, алаӣ да аларнын тянняре белян шакшыланган кеӣемняреннян дя жирянегез. 24 Сезне жазыкка

жыгылыудан саклаб, бозолоусыз тотоб, Ӱзенен даны алдында сӧйӧнӧч белян китереб бастырырга кыуаты булган, 25 белемнедян белемне Бер Аллабызга, безне Коткарыучыбызга Ходайыбыз Іисусъ Христосъ арткылы дан, ололок, кыуат, тотоучылык бар гумерлярдян элгяре дя, äле дя, бар гумерлярдя дя. Аминь.

СВЯТЫЙ АПОСТОЛЪ ПАВЕЛНЫН РИМЪ КЕШЕЛЯРЕНЯ ЖИБЯРГЯН ЖАЗЫУЫ

1-нче бюлем

Зач.79 1 Павелъ, Алланын арыу хабярен сöйлярга диб сайланыб чакырылган Iисусъ Христоснын мяндясе. 2 Арыу хабярне Алла Ўзенен пагамбярляре арткылы Изге Жазыуларда багадя иткян, 3 арыу хабяр Анын Улы турысында, Ул тян жагыннан Давидъ няселеннян тыуган, 4 ўлгяненнян терелеб тороуы арткылы, изгелек Тыны буйынча, кыуатында Ходайыбыз Iисусъ Христоснын Алла Улы булыуы ачылган. 5 Анын исеме какына бар калыкларны да ышаныуга баш эйдерер öчöн Анын арткылы без дяўлят тя, апостоллык та алдык; 6 Iисусъ Христосъ чакырыб алганнарнын арасында сез дя бар шул. 7 Римдя тороучы Алланын бар сöйöклöляреня, изге булырга чакырылганнарга Атабыз Алладан да, Ходай Iисусъ Христостан да дяўлят, тынычлык булсын. 8 Ин элеке сезнен барыгыз öчöн, сезнен ышаныуыгыз бötöн дöньягя билгеле булган öчöн Iисусъ Христосъ арткылы Аллама тау итямен. 9 Анын Улы турысында изге хабяр сöйляб, тыным белян Анăр кызмят иткян Алла минă таныкчы, сезне туктаусыз иска аламын. 10 Кайчан булса да сезгя килергя Алланын ирке минă булышсын ыйы диб, телякляремдя жалан сороймын. 11 Сезне ныгайтыр öчöн нейдей дя булса тын бюляген сезгя бирергя диб, минем сезне бик кюрясем киля шул; 12 алай дейеўем: сездя дя, миндя дя булган ышаныу какында сезнен белян кюнĕлемне тынычландырасым киля. 13 Эй туганнар, сезгя шуны белдермей калдырасым килмей: мин кюб табкырлар килергя дяртляндем, алай да ялегя чаклы кумачаулык очораттым, бютян калыкларда-

гы шикелле, сездя дя бер тӧрлӧ жимешем булсын дигян эйем. 14 Мин еллиннарга да, варварларга да, белемнелярга дя, белемсезлярга дя тейешле; 15 мина дейгяндя, сез Римдя тороучыларга да арыу хабяр сӧйлярга мин äзер. 16 Мин шул Христосъ турысында арыу хабяр сӧйлярга оялмыйым, ул шу иң элек іудейлярга, аннары еллиннарга, шулай ук бар ышаныучыларга да котолдора торган Алланын кыуаты. 17 Жазыуда: гадел ышаныуы белян тере торор, дигянчя анда ышаныудан ышаныуга Алланын дӧрӧслӧгӧ ачыла.

Зач.80 18 Äр-бер бозоклокка, кешелярнен дӧрӧссӧзлӧгӧня, дӧрӧссӧзлӧкляре белян чынныкны каблаучыларга кюктян Алланын ачыуы да ачыла. 19 Алла турысында ней белергя икяне аларга билгеле, Алла шу аларга белдерткян. 20 Анын кюренмей торганнары, мянге кыуаты, Аллалыгы дӧнья булдырылганнан бирле булдырылган нястялярне тикшереб карагач кюреня, шуна кюря алар жауабсыз. 21 Äммя алар Алланы белеб тя, Аны Алла диб даннамаганнар, Ана тау итмягняр, äммя ӱз уйлары белян бушны гна уйлаганнар, аларнын уйсыз кюнелляре карангыланган; 22 ӱзлярен белемне диб санаб акылсызланганнар. 23 Ӱнгярмей торган Алланын данын черей торган кеше ошашына да, кошлар, дюрт аяклылар, шыуышыб жӧрӧй торганнарга алыштырганнар; 24 шуна кюря Алла да аларны кюнелляре телягян няпесляреня, шакшылыкка биргян, шулай алар ӱз тяннярен ӱзляре шакшыландырганнар. 25 Алар Алланын чынныгын жалганга алыштырганнар, Булдырыучы урнына булдырган нястягя табыныб кызмят иткяняр, Булдырыучы даннаулы гумергя. Аминь. 26 Шуна кюря Алла аларны оят няпеслярга биргян, аларнын катыннары гадятчя эшлярне гадяттян тышкары эшляре белян алыштырганнар. 27 Шулай ук ирляре дя гадятчя катынга жакыннашыу гадятен ташлаб, бер-берсеня няпесляре жалкыннанган, ирляр ирлярга шакшылык кылыб, шулай жангышканнары ӧчӧн ӱзляреня тейсене алганнар.

Зач.81 28 Алар ӱз кюнеллярендя Алланы иска алмаганнары ӧчӧн Алла аларнын уйларын жангышыуга биреб, жарамаган эшне кыларга калдырган; 29 шу-

лай алар ӓр-тӧрлӧ дӧрӧссӧзлӧкка, азгынныкка, жаманныкка, мал сӧйӧӳлеккя, усаллыкка, кюремсезлеккя, ӳтереӳгя, талашыуга, алдауга, усал кылмышка тулыланганнар; 30 алар усал сюзле, жала жагыучы, Алланы сӧймӧй торган, кыйырсытыучан, ӳзлярен мактаучан, олосомак, усаллыкны уйлаб табыучан, тыудырыучыларын тынӈамый торган, 31 жюнсез уйлы, усаллык кылыучан, сӧйӧӳлексез, татыуланмый торган, изгелексезляр. 32 Алар мындый эшляр кылыучылар ӳлемгя тейешле икянне, Алланын дӧрӧс хокӧмен беляляр, алай да кылыб кна калмыйлар, ӓммя шуларны кылыучыларны да кублыйлар.

2-нче бюлем

1 Шулай кичереӳлеген жук ӓр-бер бютянне айыблаучы кеше, син шу бютянне ней белян айыблыйсыӈ, шунын белян ӳк ӳзенне дя айыблыйсыӈ, син бютянне айыблауыӈ белян ӳзеӈ дя шуны ук кыласыӈ шул. 2 Мындый эшлярне кылыучыларга чыннаб Алланын хокӧме барын без белябез. 3 Шундый эшлярне айыблаб, ӳзе дя шулай ук кыйланыучы кеше, ӓлля син Алла хокӧменнян качарым диб уйлыйсыӈ мы? 4 Ӓлля син Алланын арыулык байлыгын, сабырлыгын, озак тюземнеген, кадерен белмейсенме? Алланын арыулыгы сине тяӳбягя таба алыб барганын аннамыйсынмы? 5 Ӓммя син ӳзенӈнен кирелегеӈ, тяӳбягя килмей торган кюнелеӈ белян Алланын дӧрӧс хокӧме ачыласы ачыу кӧнӧня ӳз-ӳзеня ачыу жыясын. 6 Ул ӓр-кемгя эшеня караб кайтарыр: 7 жалан жакшы эштя тороб, дан, кадер, ӳлемсезлек эзляӳчелярга мянге тормош бирер; 8 ӓммя карышы тороучыларга, чынныкка буйсынмыйчы дӧрӧссӧзлӧккя биренеӳчелярга ачыуын, жарсыулыгын китерер. 9 Усаллык кылыучы ӓр-бер кешенен жанына, иӈ элеке іудейга, аннары эллинга кайгы, кысаннык булыр! 10 Ӓммя жакшы эш кылыучы ӓр-бер кешегя, иӈ элеке іудейга, аннары эллинга дан, кадер, тынычлык булыр! 11 Алла беряӳнен дя жӧзӧня караб кылмый. 12 Законъ алмаган кӧйӧ жазыкланган кешеляр законъ буйынча тикшерелмейче жукка чыгарлар; законъ алган кӧйӧ жазыкланган

кешеляр законъ буйынча тикшерелерляр. 13 Алла карышысында законны эшетеўчеляр гня дöрöска куйылмас, аммя законны кылыучылар дöрöска куйылыр шул.

Зач.82 14 Жалган деннелярнен законнары булмаса да, булмышларыннан законча кылыныб торсалар, алар законсыз кöйö дя ўзляреня ўзляре законъ. 15 Законны эш аларнын кюнеллярендя жазылыулы икянне алар ўзляре кюрсятеб торалар: мыны аларда бер-берсен айыблаб, жя дöрöсляб тора торган уйлары белян кюнел тойдороулары таныклыйлар. 16 Былар бары да мин сöйлягянчя, Іисусъ Христосъ арткылы Алла кешелярнен жяшерен эшлярен тикшерясе кöннö кюренер. 17 Мына син іудей диб аталасын, законъ белян ўзенне тынычландырасын, Алла белян мактанасын, 18 Анын иркен белясен, законнан öйрянеб, ней арыуырак икянне анныйсын; 19 син ўзенне сукырларны житякляб жöртöўче диб, карангыда тороучыларга жакты диб, 20 белемсезлярне арыуга ын айлаучы, балаларны öйрятеўче, законнын чынныгы, аны белеўнен ўрняге диб саныйсын. 21 Ничек суң син бютянне öйрятеб, ўз-ўзенне öйрятмейсен? 22 Урламаска ўгетляб, ўзең урлыйсын? уйнашлык итмя диб äйтеб, уйнашлык итясең? сыннардан жирянясең, ўзең изге эшне курлыйсын? 23 Законъ белян мактанасың, аммя законга карышы килеб Алланы кадерсезлейсең? 24 Жазылган бит: сезнен хакта жалган деннеляр арасында Алланын исеме курлана диб. 25 Äгяр дя законны тотсаң, киселеў пайдалы, äгяр син законга карышы икянсең, синең киселеўең киселмягянгя алмашыр. 26 Äгяр киселмягян кеше законда куйылганны кылыб торса, анын киселмягяне киселеў булыб саналмас меней? 27 Булмышыннан киселмягян кöйö законны кылыб тороучы син законга карышы кылыныучыны Изге Жазыу буйынча, киселеў буйынча хокöм итмяс меней?

Зач.83 28 Тыш кылмышыннан гна кылыучы іудей төгöл, шулай ук тыш жактан тянне гня кистереў äле киселеў төгöл. 29 Аммя эч кюнеленнян кылыучы чын іудей, шулай ук, буквада гна төгöл, аммя тын белян кюнелендя булганы чын киселеў, аны мактау кешелярдян төгöл, аммя Алладан булыр.

3-нче бюлем

1 Шулай іудей булыунын нейдей арыулыгы бар сун, жя киселеўдян ней пайда бар? 2 Бар турдан да бик зур арыулыгы бар, бигряк тя аларга Алла сюзе бирелгянгя.

3 Тагы ней сун? ягяр дя кайберляре дöрöс булмасалар, аларнын дöрöссöзлöгö Алланын дöрöслöгön жукка чыгарыр менеи? 4 Ич жук. Алла дöрöс, ямма яр-бер кеше жалганчы, былай жазылганча: Син Ӱз сюзендя туры, хокömендя мине тейешлечя айыбларсын, дигянчя. 5 Ягяр безнен дöрöссöзлöгöбез Алланын дöрöслöгön ача икян, айса ней яйтербез? Алла ачыуын кюрсяткян чакта гаделсезлек кылмый мы сун? Мыны кеше исябе белян яйтямен. 6 Ич жук. Бютянчя ничек сун Алла дöньяне хокöм итсен? 7 Ягяр минем дöрöссöзлöгöм Алланын дöрöслöгön Анын даны öчön кютярелдеря икян, алайса нейгя мине ӱк жазыклы диб айыбларга? 8 Кайберляре безне: жакшылык килеб чыгар öчön безгя усаллык кыласы тöгöл ме, диб öйрятяляр икян диб, безгя усал сюз яйтяляр, былай дейеўчелярге Алланын дöрöс хокöме килер. 9 Шулай ничек сун? Безнен арыулыгыбыз бармы? Ич жук. Без бит инде житкереб яйттек, ничек іудейлар, шулай еллиннар да барысы да жазык астында. 10 Жазылган ич: гаделлек кылыучы жук, беряў дя жук, 11 анга килеўче жук, бер кем дя Алланы эзлямей; 12 бары бер жулы ауышканнар да жараусыз булганнар, арыулык кылыучы жук, беряў дя жук; 13 тамаклары ачкан гроб шикелле, телляре белян жумалыйлар, тел астларында аспидъ дигян жыланныкыдый загарь тора. 14 Ауызлары тулы каргау, жауызлык, читеннек тейеря; 15 аяклары кан тюгярге житез, 16 жулларында жимереў, харяб итеў; 17 алар татыулык жулын белмейляр, 18 Алладан куркыуны кюз алларында тотмойлар, диб.

Зач.84 19 Законъ ней яйтся дя, законъ астында тороучылар öчön яйткянен без белябез, шулай яр-бер ауыз жабылыр, бötön дöнья Алла алдында айыблы булыб калыр. 20 Законъ эшляре белян Алла алдында бер тян дя дöрöскя чыга алмас шул, тик законъ арткылы жазык беленя. 21 Ямма

казер законга карамыйчы Алланын дөрөслөгө кюренде, анын турында законъ да, пагамбярляр дя таныклык итяляр. 22 Алланын дөрөслөгө Iисусъ Христоска ышаныу арткылы ышаныучыларнын барысына да, берсенен дя айырмасы жук шул; 23 барысы да жазыкланганнар да, Алланын даныннан буш калганнар. 24 Христосъ Iисусъ арткылы жолоб алыб, Алланын дяўляте белян бушлай дөрөскя чыгарыб, 25 ышаныу арткылы Iисусъ Христоснын Каны белян элеке кылган жазыкларны кичертеўдя Ўзенен дөрөслөгөн кюрсятер өчөн, Алла Аны кюнелен табыу корманы итеб куйган. 26 Казер дя Алла озак тюземнеге багытында Ўзенен дөрөслөгөн кюрсятер өчөн Iисуска ышанучыларны дөрөскя чыгарыб, гадел булыб кюренсен диб. 27 Мактанасы нястя кайда сунъ? Ул бетерелгян. Нейдей законъ белян? Эш законы белян ме? Жук, әммя ышаныу законы белян.

Зач.85 28 Әммя без шуны белябез, законнын эшеня катышмыйчы, кеше ышаныу белян дөрөскя чыгарыла. 29 Әлля инде Алла бер iудейларнын гна Аллысы мы, жалган дендягелярнеке дя төгөл ме? Эйе, жалган дендягелярнеке дя шул. 30 Ышаныуда тороб киселгяннярне дөрөскя чыгарыучы бер ўк Алла, киселмягяннярне дя ышаныу арткылы дөрөскя чыгарыр шул. 31 Ничек, без ышаныу белян законны жугалтабыз мы? Ич жук, әммя законны ныгытабыз.

4-нче бюлем

1 Неи әйтейек, безнен атабыз Авраамъ тян жагыннан неи табкан сунъ? 2 Әгяр Авраамъ эшляре белян дөрөскя чыккан икян, ул макталырга тейеш, тик Алла алдында төгөл. 3 Изге Жазыу неи әйтя сунъ? Авраамъ Аллага ышанган, бу анар гаделлек булыб саналган, дей. 4 Эшне кылыучыга тюляў изгелек булмыи, әммя бурыч кайтарыу була шул.

Зач.86 5 Әммя эшне кылмаган көйө, бозокларны дөрөскя Чыгарыучыга ышаныб торган кешегя ышаныуы анар гаделлек булыб санала. 6 Шулай Давидъ та, Алла кемне эшеня карамыйчы гадел итеб чыгарса, аны бахетле диб саный. 7 Законсызла-

ныулары кичерелгян кешеляр, жазыклары бетерелгян кешеляр бахетле, 8 жазыгын Ходай кичергян кеше бахетле, дей. 9 Бу бахетлелек киселеўгя туры киля ме, ялля киселмягянгя ме? без яйтябез: Авраамнын ышаныуы анар гаделлеккя саналган, диб. 10 Кайчан саналган, киселгянче ме? Ялля киселгяч ме? Киселгяч тögöл, яммя киселгянче. 11 Киселеўнен билгесен ул киселмягян чактагы ышаныуынын гаделлеген пичятляў öчöн алган. Шулай ул киселмягян ышаныучыларнын барысына да гаделлек булыб саналсын диб, барысынын да атасы булган. 12 Шулай ук киселгяннярнен дя, тик киселгяннярнен гня тögöл, яммя атабыз Авраамнын киселеўгя чаклы булган ышаныуы артыннан, анын эзеннян жöргян кешелярнен дя атасы булган.

Зач.87 13 Авраамга да, анын няселеня дя дöньягя эя булыулыкнын багадясе законъ белян бирелмягян, яммя ышаныу гаделлеге белян бирелгян. 14 Ягяр дя законда гна ныгыб торыучылар теясене алыучылар булалар икян, ул чакта ышаныулык буш, куйылган багадя дя кылынмый. 15 Законъ бит ачыуны чыгара, законъ жук жирдя айыблы эш тя жук шул. 16 Шулай, куйылган багадя барысына да ўнгяреўсез изгелек буйынча ышаныудан булсын диб, законъ буйынча гна тögöл, Авраамнын тыумаларынын ышаныуы буйынча да булсын диб, ул барыбызнын да атасы шул. 17 Жазылган бит: Мин сине кюб калыкларнын атасы итеб куйдым Алла алдында, диб. Ул Анар ўлгяннярне дя тергезеўче диб, булмаганнарны да булдырыучы диб ышанган. 18 Ул öмöт тотоудан да арттырыб, ышаныб öмöт тоткан, шунын арткылы, синең няселең бик кюб булыр, диб яйтелгянчя, ул кюб калыкларнын атасы булган. 19 Ўзенен жöз жяшкя жакыннашкан тяне инде ўлелянгянен, Сарранын да эче инде ўлелянгянен белеб тя ышаныуда халсезлянмейче торган. 20 Аллянын биргян багадясендя ул ышанмаулык белян какшамаган, яммя Аллага дан китереб, ышаныуда нык торган. 21 Ул Анын кыуатлы икяненя, яйткянне булдырыб житкезясеня тулысы белян ышаныб торган. 22 Шул анар гаделлек булыб саналган да. 23 Алай да, анар саналган, диб жазылыу бер

анын ӱзе ӧчӧн гня тӧгӧл, 24 ӓммя безнен ӧчӧн дя; без Ходайыбыз Іисусъ Христосны ӱлгяненнян тергезеб Торгозоучыга ышаныучыларга да саналыр. 25 Ул безнен жазыкларыбыз ӧчӧн ӱлемгя бирелгян, безне дӧрӧскя чыгартыр ӧчӧн терелеб торган.

5-нче бюлем

Зач.88 1 Шулай ышаныу буйынча дӧрӧскя чыгарылыб, без Ходайыбыз Іисусъ Христосъ арткылы Алла белян татыуланыштык; 2 ышаныу буйынча Анын арткылы без шул дяӱлятне алырга тейешле булдык, шул дяӱляття тороб, Алла данына ӧмӧт тотоб мактанабыз. 3 Тагы анын белян гня тӧгӧл, ӓммя интегеӱдян тюземнек булганны белеб, интегеӱ белян дя мактанабыз; 4 тюземнектян белеӱлек була, белеӱлектян ӧмӧт тотоулык була; 5 ӧмӧт тотоу оятка калдырмый, безгя бирелгян Святый Тын арткылы Алланын сӧйӧӱлеге безнен кюңелляребезгя агызылган шул. 6 Христосъ, куйылган багыт житкяч, без ӓлсез чагында, бозок тормошлолар ӧчӧн ӱлгян. 7 Гадел кеше ӧчӧн беряӱ-беряӱ ӱляр менеӥ? Белмеймен, изгелек кылыучысы ӧчӧн гня ӱляр. 8 Алла безгя Ӱзенен сӧйӧӱлеген, Христосъ безнен ӧчӧн без жазыклы чагында ӱлгяне белян кюрсятя. 9 Шуңар кюря, Анын Каны белян дӧрӧслянгяч, инде Анын арткылы без ачыудан бигряк тя котолорбыз. 10 Без дошман булган кӧйӧ, Улынын ӱлеӱе арткылы Алла белян татыулангач, инде татыуланыб, Анын тормошо белян бигряк тя котолорбыз.

Зач.89 11 Ӓле бу гна тӧгӧл, Ходайыбыз Іисусъ Христосъ арткылы Алла белян казер татыуланыулык табкач, Алла белян дя мактанабыз. 12 Шулай, ничек бер кеше белян дӧньягя жазык кергян, жазык белян ӱлем кергян, ӱлем бар кешелярга дя кючеб жяйелгян, анда барысы да жазыкланганнар шул.

13 Законга катле дя дӧньядя жазык булган шул, тик закон булмаганга кюря жазык саналмаган. 14 Алай да Адамнан Моисейгя чаклы да ӱлем падшалык иткян, Адамъ айыбы кюк жазыкланмаганнар да ӱлем падшалыгы астында калганнар, Адамъ Килясенен тӧсӧ булган. 15 Ӓммя дяӱлятнен бюляге айыб эш кюк

тӧгӧл, ӓгяр дя беряӱнен айыбы кюблярне ӱлемгя тейешле иткян икян, бер Кеше Іисусъ Христоснын дяӱлятле бюляге, Алланын дяӱляте бик кюблярдя артыгы белян бигряк тя мул булыр. 16 Аннары бюляк беряӱ жазыкланганнын хокӧме кюк тӧгӧл; хокӧм бер айыб эш ӧчӧн айыбланырга булса, ӓммя дяӱлят бюляге кюб айыблардан дӧрӧскя чыгартыу ӧчӧн була.

Зач.90 17 Ӓгяр дя беряӱнен айыбы белян, шул беряӱ арткылы ӱлем падшалык иткян икян, гаделлек бюляген, дяӱлятне дя кюб итеб алыучылар бер Іисусъ Христосъ арткылы тере тороуда бигряк тя падшалык итярляр. 18 Шунныктан беряӱнен айыбы какында бар кешеляр дя айыблыга калган кюк, шулай Беряӱнен гаделлеге какында бар кешеляр дя терелек ӧчӧн дӧрӧскя чыгарылалар. 19 Ничек бер кешенен тынламаганы какында кюбляр жазыклы булганнар, шулай Беряӱнен тынлаучылыгы какында кюбляр дӧрӧскя чыгарлар. 20 Законъ бит сунъыннан килгян, законъ килеб айыблы эшлярнен кюбяйгянен кюрсяткян. Жазык кюбяйгяч, дяӱлят тя мулы белян арткан. 21 Ничек жазыкнын падшалык итеӱе ӱлемгя таба булган, шулай Ходайыбыз Іисусъ Христоснын гаделлеге арткылы дяӱлят тя мянге тормошка таба алыб барыу ӧчӧн падшалык итя башлаган.

6-нчы бюлем

1 Ней ӓйтербез? Дяӱлят кюбяйсен диб, безгя жазык эчендя калырга мы? Ич тя жук. 2 Без бит жазык ӧчӧн ӱлдек, ничек без анын эчендя жяшейек?

Зач.91 3 Без барыбыз да Іисусъ Христосъ какына чумылдырылганнар, Анын ӱлеӱеня дя чумылдырылганны ӓлля белмейсез ме? 4 Шунар кюря без Христоснын ӱлеӱеня чумылдырылыуыбыз арткылы Анын белян кюмелдек, Христосъ Алла Атанын даны белян ӱлгяненнян терелеб торган кюк, без дя шулай жаңа тормош белян торсак ыйы диб. 5 Без Христоснын ӱлеӱеня ошашлы булыб, Анын белян кушылгач, Анын терелеб тороуына да ошашлы булырбыз шул; 6 жазыклы тянебезне жиняр ӧчӧн, инде жазыкка коллок итмяс ӧчӧн, безнен иске кешелегебез Анын белян бергя кадакланганны

без белябез. 7 Ӱлгян кеше жазык
иркеннян чыгадыр шул. 8 Без
Христосъ белян ӱлгяч, Анын бе-
лян торорбыз диб тя ышанабыз;
9 Христосъ ӱлгяненнян терелеб
торгач, инде ӱлмей тора диб,
Анар ӱлемнен кыуаты житмей
диб белябез. 10 Ул бер гня табкыр
ӱлгян, ӱлеӱе жазык ӧчӧн булган;
инде тере торадыр, тороуы Алла
ӧчӧн.

Зач.92 11 Шулай сез дя ӱзе-
гезне жазык ӧчӧн ӱлгянгя са-
нагыз, ӓммя Ходайыбыз Iисусъ
Христосъ какына Алла ӧчӧн тере
торабыз диб белегез.

12 Шулай сез ӱзегезнен няпе-
слярегезгя буйсынышлы булыб,
сезнен ӱлемне тянегездя жазык
падшалык итмясен. 13 Санна-
рыгызны дӧрӧссӧзлӧккя корал
итеб жазыкка бирмягез, ӓммя ӱзе-
гезне ӱлемнян терелеккя кючкян
итеб, Алла карышысына китере-
гез, саннарыгызны дӧрӧслӧккя
корал итеб Аллага бирегез. 14 Сез
законъ астында тормойсоз, ӓммя
дяӱлят астында торасыз, шунар
кюря жазык сезгя баш булмасын.
15 Ничек сун? Без законъ астын-
да тӧгӧл, ӓммя дяӱлят астында
булгач, жазык кыла башлыйык
мы? Ич тя алай тӧгӧл. 16 Ӓлля сез
белмейсез ме? Кемгя сез ӱзегезне
кол итеб тыннаучылыкка биргя-
негез, сез шунын коллары, кемгя
буйсынасыз, жазык коло булыб
ӱлемгя таба мы; ӓлля тыннаучы
булыб дӧрӧслӧккя чыгарга мы? 17
Аллага тау итябез: сез башта жа-
зык коллары ыйыгыз, казер сезгя
биргян ӧйрятеӱгя ӱзегезне чын
кюнелдян тыннаучылар иттегез.

Зач.93 18 Сез жазыктан ир-
кенгя чыгарылыб, дӧрӧслӧк кол-
лары булдыгыз. 19 Сезнен тяне-
гез ӓлсезгя кюря, сезгя кешелек
исябе белян ӓйтямен: элеке сез
ӱз саннарыгызны шакшылыкка,
законсызлыкка, законга карышы
эшляр кыларга кол иткян кюк,
инде шулай саннарыгызны арыу
эшляр кыларга, дӧрӧслӧккя кол
итегез. 20 Сез жазыкка кол ча-
гында дӧрӧслӧктян айырылган
ыйыгыз. 21 Ул чакта сезнен ней-
дей жимешегез бар ыйы? Сезнен
эшлярегез шундый ыйы, ул эшля-
регездян инде ӱзегез дя ояласыз,
аларнын калдык чиге ӱлем шул. 22
Ӓммя инде сез жазыктан иркенгя
чыгарылыб, Алла коллары бул-
гач, сезнен жимешегез арыулык,
калдык чигегез мянге тормош.
23 Жазык ӧчӧн тюлямяккя ӱлем
булыр, ӓммя Ходайыбыз Iисусъ
Христось какына Алланын дяӱ-
ляте мянге тормош булыр.

7-нче бюлем

1 Эй туганнар! ялля сез белмейсез ме, мин законъ белеучелярга айтям: кеше исян чакта гна анар законнын какы бар.

Зач.94 2 Иргя киткян катын исян иреня законъ буйынча бяйляудя тора, ягяр дя ире улся, ул законъ белян киткян иреннян иркенгя чыгарыла. 3 Шунар кюря ире исян кой бютянгя чыкса, уйнашлык итеуче диб санала, ягяр дя ире улся, ул законъ буйынча иркен, бютян иргя чыкса да уйнашлык итеуче булмый. 4 Эй туганнарым, сез дя шулай Христоснын Тяне белян законъ очон улдегез, улгяненнян терелеб Торганныкы булыр очон, Аллага жимеш китерер очон. 5 Без тян буйынча торган чагында, законъ белян гня аннашыла торган жазыклы тян няпесляре безнен саннарыбызда улем жимеше китерер очон эшляделяр. 6 Аммя казер безне бяйляб торган законъ очон улеб, без аннан иркенгя чыктык, тик иске жазыу буквасы белян тогол, аммя тыныбыз жанарыб, Аллага кызмят итяр очон. 7 Ней айтербез сун? Ялля инде законъ жазык мы? Ич тя алай тогол. Мин жазыкны да белмягян эйем, законъ арткылы гна белдем. Мин кюнел салмауны да аннамас ыйым, ягяр дя законъ, кюнел салма, диб айтмяся. 8 Аммя жазык, бойороктан жай алыб, миндя торло кюнел салыулар чыгарды, жазык бит законнан башка уле. 9 Мин кайчандыр законсыз жяшядем, аммя бойорок килгяч, жазык терелде; 10 аммя мин улдем, шулай итеб тере торор очон бирелгян бойорок мине улемгя китерде. 11 Шулай жазык бойороктан жай алыб, мине алдандырды да, анын белян мине улеляндерде. 12 Шунар кюря законъ изге, бойорок та изге, гадел, арыу. 13 Ялля инде арыулык шулай мина улем китеря торган булыб чыкты мы? Ич тя алай тогол. Тик жазык, узе жазык булганга кюря, арыулык арткылы мина улем китеря. Шулай жазык, бойорок арткылы бигряк тя жазык була.

Зач.95 14 Законъ тын белян бирелгянен белябез шул; аммя мин тянне, жазыкка сатылганмын. 15 Мин шу ней кылганымны узем дя аннамыймын, узем телягянне кыла алмыймын шул,

ӓммя ӱзем кюрялмаганны кыламын. 16 Ӓгяр дя ӱзем телямягянне кылам икян, алайса законъ арыу икянгя риза буламын. 17 Аннары инде аны мин кылмыймын, ӓммя миндя тора торган жазык кыла. 18 Миндя, минем тянемдя арыулык жяшямягянне мин белямен, миндя шу арыулыкны киряксенеӱ бар, ӓммя аны кыларга булдыра алмыймын. 19 Мин киряксенгян арыулыкны кылмыймын, ӓммя киряксенмей торган усаллыкны кыламын. 20 Ӓгяр дя ӱзем телямягянне кылам икян, мыны инде мин кылмыймын, ӓммя миндя жяшей торган жазык кыла. 21 Мин шундый законъ табамын: арыуны кыласым килеб тя, усаллык кыламын. 22 Ӱземнен эчке кешелегемдя Алла законыннан рахятлек табамын. 23 Ӓммя мин саннарымда уйымнын законына карышы кӧряшеӱче бютян законъ кюрямен, ул минем саннарымда тора торган жазык законына мине тотконга кертя шул. 24 Эй мин мескен кеше! Кем мине бу ӱлемне тяннян котолдорор. 25 Ходайыбыз Иисусъ Христосъ арткылы Аллага тау итямен. Шул ук уйым белян мин Алла законына кызмят итсям, ӓммя тянем белян жазык законына кызмят итямен шул.

8-нче бюлем

1 Шулай казер Иисусъ Христосъ какына тян дигянчя тормойчы, ӓммя тын дигянчя тороучыларга бер нейдей хокӧм дя жук,

Зач.96 2 Тын тормошонын законы Иисусъ Христоста жазык законыннан да, ӱлемнян дя мине иркенгя чыгарды шул. 3 Тян белян ялсезляндергян законъ кӧчсӧзгя калгач, Алла Ӱзенен Улын жазыклы тянгя ошашлы итеб, жазык ӧчӧн корман итеб, жазыкны тяндя хокӧм иткян. 4 Шулай бу бездя, тян буйынча тӧгӧл, ӓммя тын буйынча тороучыларда законнын дӧрӧслянеӱе тулыб житсен ӧчӧн. 5 Тян буйынча тороучылар тян турында уйлыйлар, ӓммя тын буйынча тороучылар тын эшлярен уйлыйлар шул; 6 тян турында уйлау ӱлем китеря, ӓммя тын турында уйлау - терелек белян тынычлык китеря. 7 Тян турысында уйлау Аллага карышы дошманнык була шул, андый уйлар Алла законына буйсына алмый-

лар, аны булдыра да алмыйлар; 8 шунӈар кюря тян буйынча тороучылар Аллага жараулыны кыла алмыйлар. 9 Ӓммя сез тян буйынча тормойсыз, ӓгяр дя Алланын Тыны сездя торса, тын буйынча торасыз. Ӓгяр кемдя Христоснын Тыны жук икян, ул Аныкы да тӧгӧл. 10 Ӓгяр Христосъ сездя икян, алай булса тян жазык ӧчӧн ӱле, ӓммя тын гаделлек ӧчӧн тере була. 11 Кем Іисусны ӱлгяненнян тергезгян, Анын Тыны сездя тора икян, ул чакта Христосны ӱлгяненнян Тергезеӱче сездя тора торган Ӱзенен Тыны белян сезнен дя ӱлемне тяннярегезне тереляндерер. 12 Шулай, туганнар, тян буйынча тороргa без бит тянгя бурычлылар тӧгӧл. 13 Ӓгяр тян буйынча торасыз икян - ӱлярсез, ӓгяр тын белян тян эшлярен ӱлеляндерясез икян, ул чакта тере торорсыз.

Зач.97 14 Алла Тыны жӧртя торганнар барысы да Алла уллары булалар шул. 15 Сез шул тагы да куркыныб жяшяр ӧчӧн коллок тыны алмадыгыз, ӓммя улланыу Тыны алдыгыз, Анын белян: эй, Авва, Ӓтей! диб дяшябез. 16 Шул Тын инде безнен тыныбызга таныклый да, без Алла оланнары диб. 17 Ӓгяр оланнары икян, алай булгач, теясене алырга тороучылар, Алладан алырга тороучылар, Христосъ белян бергя алырга тороучылар, ӓгяр Анын белян бергя азабланабыз икян, Анын белян бергя данналырбыз да шул. 18 Мин уйлыймын: бездя ачыласы дан белян тинӈяштергян чагында казерге багытлы азаблар бер нястягя дя тормойлар диб. 19 Булдырылган нястяляр Алла улларынын ачыласын ӧмӧт белян кӧтӧб торалар шул. 20 Шулай, булдырылганнарнын сагышка буйсыныулары ӱз ирекляреннян тӧгӧл шул, ӓммя буйсындырыучынын ирке буйынча; 21 булдырылганнар ӱзляре дя череӱлек коллогоннан иркенгя чыгарылыб, Алла уллары данынын иркендя булырбыз диб ӧмӧт тотоб торалар.

Зач.98 22 Белябез шул, булдырылганнар барысы да бергялящеб, казергя чаклы ынгырашыб азабланалар; 23 алар гна тӧгӧл, ӓммя без дя, Тыннын башланыуы бездя булса да, тянебез жолоб алыныуны, улланыуыбызны кӧтя тороб, без дя ӱз эчебездя ынгы-

рашабыз. 24 Без шу ӧмӧт тотоулык белян коткарылган, кюренеб торганга ӧмӧт тотоу ӧмӧт тотоу тӧгӧл, ӓгяр кем ӧмӧт тотканын инде кюря икян, анар инде ӧмӧт тотар менеӥ. 25 Ӓммя без кюрмягянебезгя ӧмӧт тоткач, ул чакта тюземнек белян кӧтӧб торабыз. 26 Шулаӥ безнен ӓлсезлегебездя Тын да безне ныгайта, без бит неӥ турында, ничек теляк итяргя дя белмейбез, ӓммя ӓйтеб биргесез жамансылаб дяшеӱляр белян Тын Ӱзе безнен ӧчӧн жалбара. 27 Тында нейдеӥ уӥ икянне кюнеллярне тикшереб Сынаучы белядер шул, Ул шу Алла ирке белян изгеляр ӧчӧн жалбара.

Зач.99 28 Шунын ӧстӧня белябез: Алланы сӧйӧӱчелярга, Анын ризалыгы буйынча чакырылганнарга бар эшляр дя жакшылыкка кылына. 29 Шулаӥ Ул кемне алдан белгян, аларны Ӱзенен Улына ошашлы булырга диб алдан билгелягян, Ул кюб туганнары арасында иң олосо булсын диб. 30 Ул кемне алдан билгелягян, аларны чакырган, ӓммя кемне чакырган, аларны дӧрӧскя чыгарган, инде кемне дӧрӧскя чыгарган, аларны данналдырган да. 31 Мынар ӧстяб неӥ ӓйтейек? Ӓгяр дя Алла безнен жаклы икян, кем сун безгя карышы. 32 Кем Ӱзенен Улын да кызганмыйчы безнен барыбыз ӧчӧн ӱлемгя биргян икян, ничек Анын белян бергя безгя барын да бюляк итеб бирмяс? 33 Алланын сайлаганнарын кем айыблар, Алла бит аларны дӧрӧскя чыгарыр. 34 Кем хокӧм итяр? Христосъ Іисусъ ӱлгян дя, терелеб тя торган, Ул Алланын ун жагында, Ул безнен ӧчӧн жалбарыучы. 35 Кем безне Алла сӧйӧӱлегеннян айыра алыр, кайгы мы, кысаннык мы, кыуылыу мы, ачлык мы, жалангачлык мы, куркыныч мы, кылыч мы? жазылган шул: 36 Синең ӧчӧн кӧн дя сайын ӱтерелябез, безне суясы сарыкларга тиннейляр, диб (Пс 43, 23). 37 Ӓммя безне Сӧйӧӱченен кыуаты белян быларнын барысын да жиңеб чыгабыз. 38 Мин ышанамын шул; ӱлем дя, тормош та, пяриштяляр дя, башлыклар да, кыуатлар да, казерге дя, буласы да, 39 бейеклек тя, тиряннек тя, бютян беряр тӧрлӧ булдырылган нястя дя Ходайыбыз Іисусъ Христоста булган Алла сӧйӧӱлегеннян безне айыра алмас.

9-нчы бюлем

Зач.100 1 Христосъ какына чынны äйтямен, жалганнамыйым, Святый Тында тороучы ўз кюнелем дя мина таныклык итя, 2 минем öчöнгя бик зур кöйöк, кюнелемя туктаусыз азаб: 3 тян жагыннан ырыу булган туганнарым öчöн мин ўзем Христостан айырылырга теляр эйем, 4 алай дигянем, Израильляр öчöн улланыулык та, дан да, äйтеб калдырыу да, законъ куйылыу да, Аллага келяў итеў дя, адарыныулык та аларга, 5 аталар да аларныкы, тян буйынча Христосъ та алардан, Ул бар нястялярнен дя Алласы, мянгегя даннаулы. Аминь.

Зач.101 6 Äммя Алла сюзе булмый калмас, Израильдян тыуганнар барысы да Израильнекеляр тöгöл шул. 7 Шулай Авраамъ няселеннян тыуганнар да бар да Авраамъ оланнары тöгöл; äйтелгян шул: синең няселең Исаакта булыр диб. 8 Алай дигяне: тян оланнары бары да Алла оланнары тöгöл, äммя адарынылган оланнар нясел диб саналалар. 9 Äммя адарынылган сюз былай: шул багытта килермен, Сарранын улы булыр, дей. 10 Бер бу гна тöгöл, äммя атабыз Исаактан Ревекка да бер жулы ике ул белян ауырга калгач, анын белян дя шулай булган. 11-12 Алар äле тыуганчы ук, äле бер нейдей начарлык та, арыулык та кылмаган чакта ук, Алланын ризалыгы кылган эшлярдян тöгöл, äммя Чакырыучы сайлаганнан килсен öчöн, анар äйтелгян булган: олосо кечесеня буйсыныб торор диб. 13 Шулай жазылган да: Іаковны Мин жараттым, äммя Исавны сöймядем, диб. 14 Ней äйтербез сун? Äлля Аллада дöрöслöк жук мы? Ич тя алай тöгöл. 15 Ул бит Моисейгя äйтя: кемне жарлыкарга икян, жарлыкарым, кемне кызганырга икян, кызганырым, дей. 16 Шулай жарлыкау кеше телягяннян дя, тырышыудан да тормой, äммя жарлыкаучы Алладан тора. 17 Изге Жазыу фараонга äйтя шул: шунын öчöн Мин сине падша итеб куйдым да, синең öстöндя Ўземнен кыуатымны кюрсятейем диб, Минем исемем бöтöн жир öстöндя сöйлянсен диб, дей.

Зач.102 18 Шулай Ул кемне теляся жарлыкый, кемне теляся кюнелен катыландыра. 19 Мина син äйтерсең: ней өчөн суң Ул мине айыблый, Анын иркеня кем карышы тора алыр, диб. 20 Син ädям кем суң, нейгя Алла белян ирешясең? Жасалган нястя äйтер ме аны жасаучыга, син ник мине былай жасадың, диб. 21 Чюлмякляр жасаучы балчыкка баш төгөл меней? Шул ук бер изгян балчыгыннан бер сауытны кадерле нястягя тотар өчөн, икенчене тюбянгегя тотар өчөн жасамас мы? 22 Ней суң? Äгяр дя Алла Үзенен ачыуын кюрсятясе, кыуатын танытасы итеб, харяб итягя äзерлянгян ачыу сауытларын зур, озак тюземнек белян кызганган икян, 23 бу изге кюнеллеген кюрсятясе итеб, данналырга Үзе äзерлягян сауытлары өстөндя - безнен өстя Үзенен даны байлыгын бергя кюрсятер өчөн булган шул, 24 безне Ул іудейлярдян гня төгөл, äммя бютян калыклардан да чакырыб алды. 25 Осія пагамбяр дя äйтя: Үз калкым булмаганны Мин калкым диб атармын, сöйöклö булмаганны сöйöклöм диб äйтермен, диб. 26 Аннары аларга äйткян урында да: “Сез Минем калкым төгöл”, алар тере Алланын уллары диб аталырлар, дей. 27 Исаія Израиль турында дяшеб äйтя: Израиль улларынын саны дингез комо бöртöкляре чаклы булса да, тик калганнары гна котолорлар, диб. 28 Ходай жир өстöндя Үз эшлярен азагына чаклы дöрöслöк белян тизюк башкарыр, тяўкяллягян эшен булдырыб житкезер, дей. 29 Исаія алдан äйтя: Äгяр Саваофъ Ходай безгя нясел калдырмаган булса, без Содомъ кюк булыр ыйык, Гоморрага ошаулы булыр ыйык, дей. 30 Ней äйтейек: гаделлекне эзлямягян бютян калыклар гаделлек табканнар, ышаныудан гаделлек алганнар. 31 Äммя гаделлек законын эзляўче Израиль гаделлек законына барыб житя алмаган. 32 Нейлектян? шунныктан: алар аны ышаныудан эзлямягянняр, äммя законъ эшляреннян эзлягянняр, алар шу абыныу ташына абынганнар. 33 Жазылган шул: Мына Сіонда абыныу Ташы, сынаб жыга торган Таш куямын, Анар ышаныучы оятка калмас, диб.

10-нчы бюлем

Зач.103 1 Эй туганнар! Израиль котолсон ыйы диб кюнелем дя телей, Аллага да инялям. 2 Алар турысында таныклык итямен: алар Алла өчөн тырышыуын тырышалар, тик исяблямей тырышалар. 3 Алар Алла дөрөслөгөн аннамыйчы, анын урнына ўз дөрөслөклярен куярга көчянеб, Алла дөрөслөгеня эйекмягянняр. 4 Ăр-бер ышаныучынын дөрөслянереня законнын чиге Христосъ шул. 5 Моисей законъ арткылы дөрөслянеў турысында жазадыр: законны кылган кеше анын арткылы тере торор диб (Левит 18,5). 6 Ăммя ышаныу арткылы дөрөслянеў былай ăйтя: Христосны төшөрөргя кюккя кем менсен диб кюнелендя ăйтмя; 7 жя, жир астына Христосны ўлгян жиреннян торгозорга кем төшсөн диб ăйтмя, дей. 8 Жазыу ней ăйтя сун? Сина сюз жакын, ул ауызында да, кюнелендя дя, дей (Втор. 30, 12-14). Былай диб без сөйлөй торган ден сюзен ăйтямен. 9 Алай булгач, син ауызың белян Іисусны Ходай диб сөйлясяң, кюнелен белян Аны Алла ўлгян жиреннян тергезеб торгозган диб ышансаң, котолорсоң. 10 Кюнел белян ышаныу дөрөскя чыгара, ăммя ауыз белян сөйляў котолоу биря шул.

Зач.104 11 Жазыу ăйтя шул: Анар ышаныучы ăр-кем оятка калмас диб. 12 Мында іудей белян еллиннын арасында ич айырма жук. Анар дяшеб чакырыучыларга барысы өчөн дя Ул бай, барысына да бер ўк Ходай шул. 13 Ходай исемен дяшеб чакырыучы ăр-кем котолор шул. 14 Ăммя Анар äле ышанмаганнар Аны ничек дяшеб чакырыр сун? Анын турысында äле эшетмягянняр Анар ничек ышаныр сун, сөйляўче булмаса, ничек эшетер сун? 15 Жибярелгянняр булмаса, ничек сөйлярга сун? Жазылган шул: Арыулык сөйляўчелярнен, тынычлык, татыулык сөйляўчелярнен аяклары ничек матур, диб. 16 Ăммя арыу хабяр сөйляўне барысы да ышаныб тыннамаганнар, Исаія ăйтя шул: Эй Ходай, бездян эшеткянгя кем ышанды? диб. 17 Шулай, ышаныу эшетеўдян була, ăммя эшетеў Алла сюзеннян була. 18 Мин сороймын: ăлля алар эшетмягянняр ме, киресенчя, аларнын тауышы бötön жиргя жяйелгян,

аларнын сюзляре дöньянен бар кырыйларына житкян. 19 Тагы сорöйом: Израиль ăлля белмяде ме? Беренче Моисей ăйтя: Мин сездя кöнняшеўлек кузгатырым, калык белян тöгöл, сезне уйсыз калык белян жарсытырмын, дей. 20 Исаія кыйыуланыб ăйтя: Мине эзлямягянняр Мине табтылар, Мине сорамаганнарга Мин ачылдым, дей. 21 Израиль турында ăйтя: Мин кöн буйы тыннаусыз, кире калыкка кулларымны сузыб тордом, дей.

11-нче бюлем

1 Шулай тагы сорöйом: Алла Ўз калкын кире каккан меней? Ич тя алай тöгöл. Мин дя бит Израиль кешесе, Авраамъ нәселеннян, Веніаминъ быуыныннан.

Зач.105 2 Алла Ўз калкын кире какмаган, Ул аларны алдан ук белгян. Илія турында Жазыу ней ăйткянне ăлля белмейсез ме? Ничек ул Израильлярне айыблаб Аллага ăйтя: 3 Эй Ходай, Синең пагамбярляренне ўтерделяр, Синең корман урыннарынны жимерделяр, бер мин гня калдым, минем жанымны да эзлейляр, диб. 4 Алла анар ничек диб жауаб биря сун? Мин Ўземя жиде мең кеше саклаб тотам, алар Ваалъ алдында тезлярен сыгылтмадылар, дей. 5 Шулай дяўлят белян сайланган буйынча калганнары казерге багытта да сакланалар. 6 Алай дяўлят белян булгач, кылган эшкя караб тöгöл, алай булса, дяўлят инде дяўлят булмас ыйы. Ăгяр эшляреня караб булса, мында инде дяўлят булмый. 7 Ней сун? Израиль ней эзлягян, аны алалмаган, сайланганнар алганнар, бютянняре каты кюнеллелянгянняр; 8 былай жазылганча: Алла аларга жоклатыу тынын биргян, кюзляре белян дя алар кюрмейляр, бу кöнгя чаклы колаклары белян дя эшетмейляр, диб. 9 Давидъ та ăйтя: Сыйланыб утырулары аларга ау булсын, кыйын булсын, тозак булсын. 10 Алар-нын кюз аллары карангылансын, кюрмяс булсыннар, аларнын сыртлары жалан бöгöлöўле булсын, дей. 11 Шулай тагы сорöйом: Ăлля инде алар бöтöнняй жыгылыр öчöн абындылар микян? Ич тя алай булмас. Аларнын жыгылыуларыннан бютян калыкларга котолоу киля, аларда кончöлöк кузгатыр öчöн. 12 Ăгяр дя алар-

нын жыгылыулары дөньягя байлык, аларнын жарлыланыулары бютян калыкларга муллык икян, бу бигряк тя аларнын тулылыгы.

Зач.106 13 Сез бютян телдяге калыкларга аӥтямен: Мин бютян телдяге калыклар апостолы булганга кюря, ӱземнен иткян кызмятемне данныймын. 14 Ичмаса ӱземнен тян жагыннан туганнарымда кончӧлӧк кютярелдермям ме, аларнын кайсын булса да коткармам мы? 15 Ӓгяр аларнын кире кагыулары дөньягя татыулык икян, инде кабыл алыулары ӱлгяннян терелеӱ тӧгӧл менеӥ? 16 Ӓгяр башы арыу булса, бӧтӧнӧ дя арыу булыр, ӓгяр тамыры арыу булса, ботаклары да арыу булыр. 17 Ӓгяр кайбер ботаклары сыныб тӧшкянняр икян, ӓммя син, кыргыӥ маӥ агачы, алар урнына жабышыб ӱскянең дя, маӥ агачынын тамыры белян дя, дымы белян дя бергя булганын; 18 ботаклар алдында олосомакланыб кютярелмя, ӓгяр кютярелсяң, шуны исеня тӧшӧр, син бит тамырны тотоучы тӧгӧл, ӓммя тамыр сине тота. 19 Син ӓйтерсең: Ботаклар сыныб тӧшкянняр мин жабышыб ӱсяр ӧчӧн, диб. 20 Бик арыу, алар ышанмаганнарына кюря сыныб тӧшкянняр, ӓммя син ышаныуын белян торасың, олосомакланма, ӓммя курык. 21 Ӓгяр Алла агачыннан ӱскян ботакларны кызганмаган икян, кара, сине кызганыр микян. 22 Шулаӥ Алланын арыулыгын да, катылыгын да кюрясең, сыныб тӧшкяннярга катылыгы, Алланын арыулыгында жалан булсаң гна синя арыулыгы, алаӥ булмасаң, син дя кисеб ташланырсын. 23 Тегеляр дя ӱзляренен ышанмаганныкларында жалан тормасалар, тагы жабышыб ӱсярляр. Алла шу аларны тагы жабыштырыб ӱстерергя дя кыуатлы. 24 Ӓгяр дя син ӱзең ӱскян кыргыӥ маӥ агачыннан кисеб алыныб, элек бергя булмаган ӓйбят маӥ агачына жабышыб ӱскянең икян, былар бигряк тя ӱзляренен маӥ агачларына жабышыб ӱсярляр.

Зач.107 25 Эӥ туганнар! Бу жяшерекне сезгя белдермеӥ калдырасым килмеӥ, сез ӱз турыгызда жугары уйламасын диб; Израильнен кюнел катыланыуы бер ауыкка чаклы, жалган деннеляр тулысынча денгя кергенче булган. 26 Шулаӥ бӧтӧн Израиль котолор, жазылган шул: Сіоннан Коткарыучы килер, Іаковтагы бозоклокны бетерер, 27 жазы-

кларын өсляреннян төшөргянче, аларга бу әйтеб калдырыу Миннян, диб. 28 Изге хабяр жагыннан, сезнен өчөн алар дошман, әммя сайланганнар жагыннан, аталары какына Алланын сөйөклөляре. 29 Алланын чакырыуы да, бюляге дя үнгяреүсез. 30 Сез дя бит бер багытны Аллага тынныаусызлар ыйыгыз, әммя казер аларнын тынныаусызлыгы какында сез жарлыкаулы. 31 Шулай сез жарлыканыу өчөн алар да тынныаусызлар, алар үзляре дя жарлыкаулы булыр өчөн. 32 Алла шу барысын да тынныаусызлыкка биклягян, барысын да жарлыкар өчөн. 33 Эй Алланын байлыгынын, белемнегенен, белеүлегенен, тиряннегенен чиксезлеге, Анын алдан билгеляүен белеб житкезерлек төгөл, Анын жулларын тикшереб бетерерлек төгөл! 34 Кем сун Ходайнын уйын анналган, жя кем Анар киняшче булган? 35 Жя Ул тейешлене кайтарсын диб, кем Анар алдан биреб куйган. 36 Барысы да Аннан, Анын белян, Анар таба. Анар дан булсын гумердян гумергя. Аминь.

12-нче бюлем

Зач.108 1 Шулай, туганнар, Алланын арыу кюнеллеге белян сезгя үтенямен, акыл белян кызмят итяр өчөн үзегезнен тяннярегезне Аллага жараулы тере, изге корман итеб китерегез. 2 Бу гумергя ошашмагыз, әммя үзегезнен уйыгызны жанартыб үнгярегез, Алланын ирке ничек арыу, жараулы, житешеүле икянен белеү өчөн. 3 Мина бирелгян дяүлят буйынча сезнен әр-берегезгя әйтямен: Үз турыгызда уйларга тейешледян артыгын уйламагыз, әммя чамалаб, ышаныу буйынча әр-берегезгя Алла бюлеб биргянчя торогоз.

Зач.109 4 Безнен тянебез бер булса да, саннарыбыз кюб, әммя бар саннарнын да эшляре бер иш төгөл. 5 Шулай без дя кюб булыб Христоснын бер тяне булыб төзөлябез, тик саннар берсеннян берсе төрлөчя.

Зач.110 6 Шулай безгя бирелгян дяүлят буйынча, безнен төрлө кыуатларыбыз бар, шунар кюря, алдагыны белеүлеген бар икян, ышаныуга чамалаб сөйля; 7 кызмятен бар икян, кызмятендя тор; өйрятеүче икянсен, өй-

рятеўенне бел; 8 ўгетляўче икянсең, ўгетля; өляшеўче икянсең, турылык белян өляш; башлык икянсең, тырышыб башлык булыб тор; изгелек кылыучы икянсең, чын күңелдян изгелек кыл. 9 Сөйөүлек тыштан гына булмасын; жаманнан борологоз, арыуга эярегез; 10 бер-берегезне туган диб жомошак күңел белян сөйөгөз; бер-берегезне кадерляўне берегездян берегез арттырырга тырышыгыз; 11 тырышыуны киметмягез, тыныгыз жалкыннаныб торсон, Ходайга кызмят итегез; 12 өмөт тотоу белян жыуаныгыз; кайгыда тюзем булыгыз; жалан теляк итегез; 13 изгелярнен киряженя булышыучан булыгыз; жулчыларны кертергя тырышыгыз; 14 сезне кыуыучыларга жакшылык телягез, жакшылык телягез, әммя кагарлямягез. 15 Сөйөнөўче белян сөйөнөшөгөз, жылаучы белян жылашыгыз; 16 бер-берегез белян бер уйда булыгыз, жугарыдан уйламагыз, әммя жыуаш күңеллеляр артыннан барыгыз, күңелегез үз турыгызда олосомак булмасын; 17 усаллыкка карышы беряўгя дя усаллык кайтармагыз, әммя бар кешеляр алдында да арыулык турысында сагышланыгыз; 18 әгяр сезнен жактан мөмкимнек булса, бар кешеляр белян дя татыу торогоз. 19 Әй сөйөклөляр, үзегез өчөн үч кайтармагыз, әммя Алланын ачыуына урын бирегез, жазылган шул: Үч кайтарыу Мина, Үзем кайтарым, дей Ходай. 20 Шулай, әгяр дя синең дошманың ач икян, аны туйдыр, сыусаса, эчерт, син шулай кылыб анын башына жана торган кюмерляр жыйарсың. 21 Усаллык белян жинелмя, әммя усаллыкны арыулык белян жиң.

13-нче бюлем

Зач.111 1 Әр-бер кеше оло башлыкларга баш салыб торсон, Алла куймаса, башлык булмый шул, әммя бар башлыкларны да Алла Үзе куядыр. 2 Шуңар күря, башлыкка карышы килеүче Алла куйганга карышы киляер; әммя карышы килеүчеляр үз-үзляреннян айыблы булалар. 3 Башлык булыб тороучылар жакшы эш өчөн куркыныч төгөл, әммя жаман эш өчөн куркыныч. Башлыктан куркасың килмей икян, жакшылык кыл, кылсаң, ул сине мактар. 4 Башлык булыб тороучы Алла кызмятчесе

ич, ул сина жакшылыкка. Ӓгяр дя жаманнык кыласың икян, аннан курык, кылыч алыб жӧрӧўе бушка тӧгӧл шул: ул Алла кызмятчесе, жаманнык кылыучыга кыйын тейереўче. 5 Шунар кюря кыйын тейереўдян гня куркыб тӧгӧл, ӓммя оялыучан кюнел белян аларга баш салыб тороргa киряк. 6 Алар Алла кызмятчеляре булганга кюря, гел Анын эшендя торганга кюря, имана да тюлейсез. 7 Алай булгач, ӓр-берсеня тейешлене бирегез: имана куйганга - имана бирегез, тюляў куйганга - тюлягез, куркырга куйганнан куркыгыз, кадерлясене кадерлягез. 8 Бер-берегезне сӧйӧўдян башка бютян бер кемгя дя бурычлы булыб калмагыз, жакынын сӧйӧўче законны кылыб бетергян. 9 Бойороклар: уйнашлык итмя, ўтермя, урлама, жалган таныклык итмя, кеше нястясеня кюнел салма, дигянняр шушы: жакынынны ўзенне сӧйгян кюк сӧй, дигян бер сюзгя кереб беткян шул. 10 Сӧйӧўлӧк жакына усаллык кылмый, сӧйӧўлек ўзе законны кылыб бетереў шул.

Зач.112 11 Шулай, инде жокодан уяныр сагат житкян багытны белеб, тейешлечя кылыныгыз. Без ышаныб тора башлаган багытка караганда, казер безгя котолоу жакынырак шул. 12 Инде тӧн ӱтте, кӧн жакыннашты, алай булгач, карангылык эшлярен ташлаб, жактылык коралына кейенейек. 13 Кӧндӧз кеше ўзен рятле жӧрткян кюк, без дя ўзебезне бик рятле жӧртӧйӧк: жырлашыб бяйрям итеўгя, эчкелеккя, тян няпесляреня, азгынныкка, ызгышыуга, кӧнчӧлӧккя биренмейек; 14 Ходайыбыз Іисусъ Христоснын ошашына кейенегез, тян ӧчӧн гня сагышланыб, няпесляргя биренмягез.

14-нче бюлем

1 Ныk ышанырга хале житмягянне, сезнен белян бер уйда булмаса да, шиклянмейче кабыл алыгыз. 2 Беряў барын да ашарга жарый диб беля шул, ӓммя ӓлсез кеше бакча жимешлярен гня ашый; 3 ашый торганы ашамаганны кимсетмясен, ашамый торганы ашый торганны тикшермясен, аны да Алла кабыл алган шул. 4 Син чит мяндяне тикшереўче ўзең кем сунʔ Ул торса да, жыгылса да, ўз Ходайы алдында ич; аны Алла Ӱзе торгозор, аны

торгозорга Анын кыуаты житяр. 5 Беряў кöннян кöннö айыра, икенче беряў бар кöнняр дя тигез диб саный, äр-кем ўзенен уйына ошаганча кыйлансын.

Зач.113 6 Кем кöннярне айыра, Ходай öчöн айыра, кем кöннярне айырмый, Ходай öчöн айырмый. Кем ашый, Ходай öчöн ашый, ул Аллага тау итя, кем ашамый, Ходай öчöн ашамый, ул да Аллага тау итя. 7 Безнен беребез дя ўзе öчöн жяшямей шул, тагы бер кем дя ўзе öчöн ўлмей. 8 Жяшейбез икян, Ходай öчöн жяшейбез, ўлябез икян, Ходай öчöн ўлябез, жяшясяк тя, ўлсяк тя, äр чакта без Ходайныкы.

Зач.114 9 Христосъ ўлгяннярне дя, терелярне дя Ўз кулында тотар öчöн ўлгян дя, терелгян дя, терелеб тя торган. 10 Син нейгя суң ўз туганынны айыблыйсын? Жя син дя нейгя ўз туганынны кимсетясен? Без барыбыз да Христоснын хокöме карышысына килеб басарбыз. 11 Жазылган шул: Мин жяшейем, дей Ходай, бар быуыннар да Минем карышымда башырырлар, äрбер тел Алланы таныклар, диб. 12 Шулай безнен äр-кайсыбыз ўзе öчöн Аллага жауаб бирер. 13 Мыннан былай бер-беребезне тикшеря торган булмыйык, бигряк тя туганыбызны абындырырга, жя алдандырырга жай китермейек тагы диб уйлыйык. 14 Ходай Iисусъ какына мин белямен дя, ышанамын да: ўз-ўзеннян бер нястя дя шакшы тöгöл, тик кем таза тöгöл диб санаса, анын öчöн гня таза тöгöл. 15 Äгяр ашамнык öчöн туганынның кюнеле тынычсызлана икян, алайса син сöйöўлек буйынча кыйланмыйсың. Кем öчöн Христосъ ўлгян, аны син ашамныгың белян жукка чыгарма. 16 Сезнен арыулыгыгыз курлыкка калмасын. 17 Алла Падшалыгы ашамнык, эчемнек тöгöл шул, äммя Святый Тында гаделлек, татыулык, сöйöнöч. 18 Шушылар белян кем Христоска кызмят итя, ул Аллага да жараулы, кешеляр дя мактарлык шул.

Зач.115 19 Шулай татыулыкны, бер-беребезне арыуга öйрятеўне гня эзлейек. 20 Ашамнык какында Алланын эшен жимермя, бар да таза, тик кем алданыу öчöн ашый, анар гна начар. 21 Äгяр синең туганың былар белян алданса, абынса, жя älсезлянся, ит ашамаганың, аракы эчмягянең, жя бютян тöрлö андый эшляр эш-

лямягянең арыуырак. 22 Ägяр синен ышаныуыңбар икян, аны Алла алдында ўз эчендя тот; ўзе сайлаб алган эш öчöн ўзен айыбламаган кеше бахетле. 23 Ämмя шиклянеўче ашый икян, ышаныу белян булмагач, айыблы була, ышаныу белян булмаган äр-ней жазык шул. 24 Мянге багытлардан äйтелмей килгян жяшерекне ачыуда Iисусъ Христоснын öйрятеўе, минем изге хабяр сöйляўем белян, 25 мянге Алланын кушканы буйынча, пагамбярляр алдан жазган жяшерек казер килеб кюренгян, калыкларны ышаныуга эйектерер öчöн ул бар калыкларга да сöйлянгян; сезне ныгайтырга кыуаты булган, 26 белемнедян белемне, бер гня Аллага Iисусъ Христосъ арткылы дан булсын гумердян гумергя. Аминь.

15-нче бюлем

Зач.116 1 Без кöчлöляр, ўзебезгя гня жарарга тырышмыйчы, кöчсöзлярнен житешмягян жирен дя ўзебез кютярергя тейеш; 2 äр-кайсыбыз арыулык белян, габрят белян жакыныбызга жарарга тейеш; 3 Христосъ та Ўзеня жарарга тырышмаган шул, ämмя Жазыудагынын: Сине курлаучыларнын курлаулары Мина да тейде (Пс 68, 10), дигян. 4 Äўäле жазылганнын барысы да безгя ўгеткя жазылган, шул жазыудан жыуаныч белян тюземнек табыб, öмöт тотсоннар диб. 5 Тюземнек белян жыуаныч биреўче Алла, Христосъ Iисусъ öйряткянчя, сезгя бер-берегез белян бер уйда тороулыкны бирсен эйе; 6 шулай итеб, сез бер тыныш белян, бер ауыз белян Ходайыбыз Iисусъ Христоснын Атасы Алланы мактасагыз ыйы.

Зач.117 7 Шунар кюря, Христосъ сезне Алла данына кабыл алганча, сез дя шулай бер-берегезне кабыл алыб торогоз. 8 Шуны белямен: аталарга адарынганны кылыб житкезер öчöн, Алланын чынныгы какына, Iисусъ Христось киселгянняргя кызмят итеўче булган. 9 Ämмя Ўз изгелегеннян, алар Алланы даннасыннар диб, бютян калыкларга да кызмят итеўче булган. Жазылган шул: Шунын öчöн, эй Ходай, Сине жат калыклар эчендя сöйлярем, Синең исеменя жырларым, диб. 10 Тагы äйтелгян: Эй жат калыклар, Анын калыгы белян сöйöнöшöб кыуаныгыз, диб. 11 Тагы: Эй жат калыклар, ба-

рыгыз да Ходайны даннагыз, эй кешеляр, барыгыз да Аны мактагыз, диб. 12 Шулай Исаія да айтя: Иессейнен тамыры булыр, Ул тороб калыкларга баш булыр, жат калыклар Анар омот тотарлар, диб. 13 Омот тотоулык Алласы сезне ар-бер сойоночкя, тынычлыкка, ышаныуга тулыландырсын, сез Святый Тын кыуаты белян, омот тотоу белян байысагыз ыйы. 14 Туганнарым! Мин узем дя сезнен турыда ышанамын: сез дя арыулыкка тулы, ар-торло белеулекя дя тулы, бер-берегезне ойрятя аласыз. 15 Аммя мин, эй туганнар, азряк исегезгя тошорор очон, Алладан мина бирелгян дяулят буйынча, кыйыуланыбырак сезгя жаздым. 16 Мина жат калыкларда Иисусъ Христоска кызмят итеуче булырга, Алланын арыу хабярен сойляу изге эшен кыларга тейешле чыкты, Святый Тын арыуландырган буйынча, шушы сез жат калыкларны Аллага китереу, Аллага жараулы булсын диб.

Зач.118 17 Шулай мин Иисусъ Христоста тороб, Аллага тейешле эш турысында мактана аламын. 18 Жат калыкларны сюз белян дя, эш белян дя ышаныуга буйсындырыр очон Христосъ минем арткылы беряр нястя кылмый калдырды диб айтергя кыйыучылык итмейем; 19 билгеляр, кодрятляр кыуаты белян, Алла Тынынын кыуаты белян Христоснын арыу хабярен сойляу Иерусалимнян, анын тиря жюненнян башлаб, Иллирикка чаклы минем арткылы таралды; 20 шунын остоня, мин бютян кеше нигезеня торгозмас очон, Христоснын исеме инде билгеле булган жирдя тогол, аммя билгеле булмаган жирдя сойляргя тырыштым. 21 Былай жазылган шул: Анын турында хабяр алмаганнар кюрерляр, эшетмягянняр дя белерляр, диб. 22 Шушы мина сезгя килер очон кюб табкыр кумачаулык итте дя. 23 Бу жакларда казер мындый эш калмагач, кюбтянге жыллардан ук сезгя барасым килгяннектян, 24 Испаниягя барырга жулга чыккач та сезгя килермен, узыб барышлый сезнен белян кюрешермен, сез мине анда озатырсыз диб, озакламый бер ауык кна булса да сезнен белян бергя булыб кинянермен диб омот итямен. 25 Аммя казер мин изгеляргя кызмят итяр очон Иерусалимгя барамын. 26 Македония белян Ахаиадагылар Иерусалимдяге изгеляр арасындагы жарлыларга бер ауык булышыулык бирергя кюнел итяляр шул; 27 кюнел итя-

ляр дя, алар аларнын алдында бурычлы да. Жат калыклар да аларнын тын эшляреня керешеўле булгач, аларга да тянгя кирякленястя белян кызмят итяргя тейеш. 28 Шушыны кылыб, бу кюнел итеў жимешен аларга итеб биреб, мин сезнен жаклар арткылы Іспаніяга чыгыб китярем. 29 Мин сезгя килгяндя Христоснын арыу хабярен сöйляргя тулы бахиллек белян килермен диб ышанамын.

Зач.119 30 Шунын öстöня, эй туганнар, Ходайыбыз Іисусъ Христосъ какына, Тыннын сöйöўлеге белян сездян ўтенямен: Аллага минем öчön дя теляк итяргя минем белян бергя тырышсагыз ыйы; 31 бу - Іудеядяге ышанмый торганнардан котолор öчön, минем кызмятем Іерусалимдяге изгеляргя арыу жараулы булыр öчön шул; 32 äгяр дя Аллага жараулы булса, мин сезгя сöйöнöч белян килеб, сезнен белян тынычланыр öчön. 33 Тынычлык Алласы сезнен барыгыз белян булсын. Аминь.

16-нчы бюлем

Зач.120 1 Кенхрейя чиркяўенен диакониссасы безнен сеннебез Фіваны сезгя жибярямен. 2 Ходай какына, изгеляргя тейешлечя аны кабыл алыгыз, ул сездя ней киряксенся дя, анар булышыгыз, ул ўзе дя кюбляргя, мина да булышыучы булды. 3 Христосъ Іисуста минем белян бергя кызмят иткян Прискилла белян Акилага кюнелдян жаратыб калыуымны житкезегез, 4 алар минем жаным öчön башларын салдылар, аларга тау итеўче бер мин гня тöгöл, äммя жат калыкларнын бар жыйыннары да, тагы аларнын жорттагы чиркяўляре дя тау итяляр. 5 Минем öчön сöйöклö булган Епенетка кюнелдян жаратыуымны äйтегез, ул Христоста тороуны Ахаіада башлаучы булды. 6 Маріамга бик кюнелдян жаратыуымны äйтегез, ул безнен öчön кюб кызмят итте. 7 Андронікъ белян Іуніягя кюнелдян жаратыуымны äйтегез, алар минем тян жагыннан туганнарым, минем белян тотконда да булдылар, апостоллар арасында да данналдылар, алар миннян алдарак Христоска ышаныучылар. 8 Ходайда мина сöйöклö булган Амплійга бик кюнелдян жаратыуымны äйтегез. 9 Христоста безнен белян кызмят иткян Урбанга кюнелдян жаратыуымны äйтегез,

тагы мина сӧйӧклӧ Стахийга да. 10 Христосъ какына сыналган Апеллеска кюнелдян жаратыуымны айтегез, Аристовулъ жортондагы ышаныучыларга да кюнелдян жаратыуымны айтегез. 11 Минем тян жагыннан туганым Иродіонга бик кюнелдян жаратыуымны айтегез. Наркиснын жортондагы Ходайда булганнарга кюнелдян жаратыуымны айтегез. 12 Ходай какына кызмят итеучеляр Трифенага, Трифоска кюнелдян жаратыуымны айтегез. Сӧйӧклӧ сенел Персідага кюнелдян жаратыуымны айтегез, ул Ходай какына кюб эшляде. 13 Ходай какына сайланган Руфка, анын анасына да, минекеня дя бик кюнелдян жаратыуымны айтегез. 14 Асинкритка, Флегонтка, Ермга, Патровка, Ермійга, алар белян булган бютян туганнарга да кюнелдян жаратыуымны айтегез. 15 Филологка, Юліягя, Нирейга, анын сеннесеня дя, Олимпанга, алар белян булган бар изгелярга дя кюнелдян жаратыуымны айтегез. 16 Изге убеу белян бер-берегезне кюнелдян жаратыб торогоз. Христоснын бар жыйыннары да сезне бик кюнелдян жаратыб калалар.

Зач.121 17 Эй туганнар, сезгя инялямен, сез ойрянгян ойрятеугя карышыб айырылышыулар, алданыулар чыгарыучылардан сакланыгыз, алардан читкя ауышыгыз. 18 Андый кешеляр Ходайыбыз Іисусъ Христоска кызмят итмейляр, аммя уз корсакларына кызмят итеб, жомошак сюзляр белян жумалаштырыб, кече кюнеллелярне алдандыралар. 19 Сезнен ышаныуга буйсыныуыгыз барысына да билгеле, шунар кюря сезнен очон сойонямен дя, сезнен арыулыкка белемне, аммя усаллыкка кечесымак булыуыгызны телеймен. 20 Тынычлык Алласы озакламый сатананы сезнен аяк астыгызга салыб табтар. Ходайыбыз Іисусъ Христоснын дяуляте сезнен белян. Аминь.

21 Минем белян кызмят итеуче Тімофей, аннары тян жагыннан минем туганнарым Луцій, Іасонъ, Сосипатръ да сезне кюнелдян жаратыб калалар. 22 Бу жазыуны жазыучы мин, Тертій да, сезне бик кюнелдян жаратыб калам. 23 Мине дя, бютон жыйынны да тороргa кертеуче Гаій да сезне кюнелдян жаратыб кала. Каланын казнасын саклаучы Ерастъ та, анын туганы Квартъ та сезне кюнелдян жаратыб калалар. 24 Ходайыбыз Іисусъ Христоснын дяуляте сезнен барыгыз белян булсын. Аминь.

СВЯТЫЙ АПОСТОЛЪ ПАВЕЛНЫН КОРИНФЪ КЕШЕЛЯРЕНЯ ЖИБЯРГЯН БЕРЕНЧЕ ЖАЗЫУЫ

1-нче бюлем

Зач. 122 1 Павелъ Алланын ирке белян чакырыб алынган, Іисусъ Христоснын апостолы, аннары туганым Сосфенъ да. 2 Коринфта булган Алланын жыйынына, Іисусъ Христосъ какына арыуландырылганнарга, чакырыб алынган изгелярга, Ходайыбыз Іисусъ Христоснын исеменя ӓрбер урында, аларда да, бездя дя дяшеб чакырыучыларга,

Зач. 123 3 Атабыз Алладан да, Ходай Іисусъ Христостан да сезгя дяўлят белян тынычлык булсын. 4 Іисусъ Христосъ какына сезгя бирелгян Алланын дяўляте өчөн, сезнен өчөн Аллама туктаусыз тау итямен, 5 Анын арткылы сез барысына да байыдыгыз шул, ӓр-төрлө сюз белян дя, ӓр-төрлө белемнек белян дя, 6 Христосны таныклау сездя ныгыды шул. 7 Ходайыбыз Іисусъ Христоснын килеб кюренеўен көткяндя, сезгя бирелгяннярдя бер жактан да сезнен житмягян жирегез жук. 8 Ходайыбыз Іисусъ Христосъ көнөндя сезгя айыбсыз булыб кюренер өчөн Ул сезне азакка чаклы ныгайтыр. 9 Сезне Ўзенен Улы Ходайыбыз Іисусъ Христосъ белян катышыулы булырга чакырыб алган Алла ышанычлы.

Зач. 124 10 Эй туганнар! Сезгя Ходайыбыз Іисусъ Христосъ исеме белян инялямен: сез барыгыз да берне сөйлясягез эйе, сезнен арада айырылыу булмасын ыйы, сез бер тынышта, бер уйда берлянешсягез эйе диб. 11 Ӓммя Хлои исемне кешенен өйдягеляреннян сезнен турыда, эй туганнарым, мина билгеле булды, сез ўз арагызда ӓрепляшясез икян; 12 былай диб мыны ӓйтеўем: сездя мин Павелныкы, мин Аполлосныкы, мин Кифаныкы, мин Христосныкы диб

äйтеўчеляр бар икян. 13 Христосъ айырылган менеӣ? Павелъ сезнен өчөн кадакланылган менеӣ? Ӓлля сез Павелъ исеменя чумылдыгыз мы? 14 Тау Аллага, мин Криспа белян Гаиидан башка сезнен арадан беряўне дя чумылдырмадым, 15 беряў-беряў ул ўз исеменя чумылдырды диб äйтмясен диб. 16 Мин тагы Стефанъ жортондагыларны чумылдырдым, ämмя тагы беряўне-беряўне чумылдырганымны белмеймен; 17 мине Христосъ чумылдырырга жибярмяде шул, ämмя Христоснын Качы жукка чыгарылмасын диб, оста сюзляр белян äйтмейче сөӣлярга жибярде.

Зач. 125 18 Кач турысында сөӣлягян сюз харяб булыучыларга жюляр сюз кюк тея, ämмя без сакланыучыларга ул Алла кыуаты. 19 Жазылган шул: Белемнелярнен белемнеген жукка чыгарым, акыллыларнын акылын кире жибярем, диб (Исаія 29, 14). 20 Белемне кая? Книгяче кая? Бу дөньянен сораштырыучысы кая? Бу дөньянен белемнеген Алла акылсызлыкка чыгармады микян? (Исаія 33,18). 21 Дөнья кешеляре ўз белемнекляре белян Алланын ин оло белемнек икянен танымагач, Алла жюляр сымак дейелгян сөӣляў арткылы ышаныучыларны коткарасы иткян. 22 Іудейляр дя кодрят сораган булалар; еллиннар да белемнек эзлягян булалар; 23 ämмя без кадакланган Христосны сөӣлөӣбез, бу іудейлярга шикле тея, еллиннарга акылсызлык кюк тея; 24 ämмя өндялгяннярнен ўзляреня: іудейлярга дя, еллиннарга да Христосны Алла кыуаты, Алла белемнеге диб сөӣлөӣбез. 25 Алланын белемсез дигяне дя кешелярнекеннян белемнеряк, Алланын älсез дигяне дя кешелярнекеннян көчлөряк. 26 Шуны карагыз, туганнар, сез чакырылганнар кемняр сун, сезнен арада тян жагыннан белемнеляр дя кюб төгөл, көчлөляр дя кюб төгөл, оло затлылар да кюб төгөл. 27 Ämмя Алла белемнелярне курлыкка калдырыр өчөн бу дөньянен белемсезлярен сайлаб алган, көчлөлярен курлыкка калдырыр өчөн Алла бу дөньянен älсезлярен сайлаб алган; 28 дөньянен билгесезлярен, кимсетелгяннярен, бер нястягя дя тормаганнарын Алла сайлаб алган, билгелелярен бетерер өчөн, 29 бер тян дя Алла алдында мактаныб тормасын өчөн. 30 Анын кылыуы белян сез

дя Іисусъ Христоста, Ул сезнен өчөн Алладан килгян белемнек, гаделлек, арыуландырыу, лоб алыу булган. 31 Жазылганча: мактаныучы Ходай белян мактансын шул.

2-нче бюлем

1 Эй туганнар! Мин сезгя килгян чагында Алланы таныклауны билгертергя килдем, тик белемнек белян, оста сюзляр белян төгөл. 2 Мин шу сезнен арада Іисусъ Христостан башка, Анын кадакланыуыннан башка ич нәстя дя белмей торган булырга уйладым. 3 Мин сездя әлсезлектя, куркыулыкта, зур калтраулыкта булдым, 4 минем сюзем дя, сөйляүем дя кеше белемнегенен ышандырырдый әйткян сюзляреннян булмады, әммя тын кюренешеннян, кыуатыннан булды, 5 бу сезнен ышаныуыгыз кеше белемнегеннян булмасын, әммя Алла кыуатында ныгысын диб шул.

Зач.126 6 Белемнекне без ышаныуга житеү кешеляр арасында сөйлөйбез, әммя бу гумернен белемнеген төгөл, бу узыб китя торган гумернен кыуатларын да төгөл; 7 әммя Алла безне даналдырыр өчөн бар гумерлярдян элек билгелягян жяшерекле, бик кадерляб сакланган белемнеген сөйлөйбез, 8 аны бу гумердя тотоб тороучы башлыкларнын берсе дя татыб карамаган, әгяр дя татыган булсалар, данныклы Ходайны качка кадакламаслар ыйы шул.

Зач.127 9 Әммя жазылган шул: Аны кюз дя кюрмягян, колак та эшетмягян, кешенен кюңеленя дя кереб карамаган, Үзен сөйөүчелярга Алла ней әзерлягянне диб. 10 Әммя Алла безгя мыны Үзенен Тыны белян ачты, Тын шул барысына да, Алланын тиряндягеня дя ütеб керя. 11 Кешенен эчендя тора торган үз тынынан башка кешеляр арасыннан кем беля кешенен эчендя ней барны, шулай Алланыкын да беряү дя белмей, тик Алланын Үз Тыны гына беля шул. 12 Әммя без бу дөньянен тынын алмадык, әммя Алла безгя ней биргянне белер өчөн Алладан Тын алдык шул, 13 без шуны кеше белемнегеннян өйрянгян сюзляр белян төгөл, әммя Святый Тыннан өйрянгянне, тын эшлярен тын кешеляреня аннатыб сөйлөйбез. 14 Жан кешесе Алла Тынынан бул-

ганны кабыл алмый, ул шу аны акылсызлык диб саный, анный да алмый, анын турысында тын жагыннан тикшеря белергя киряк шул. 15 Ӓммя тын кешесе бар турыдан да тикшеря беля, ӓммя аны беряў дя тикшеря алмый. 16 Аны тикшеря алыр ӧчӧн кем сун Ходайнын уйын белгян? Ӓммя бездя Христоснын уйы бар.

3-нче бюлем

1 Эй туганнар, мин сезнен белян тын кешеляре кюк итеб сӧйляшя алмадым, ӓммя тян кешеляре кюк, Христостагы жяш балалар белян сӧйляшкян кюк сӧйляштем. 2 Мин сезне каты ашамнык белян тӧгӧл, ӓммя сӧт белян туйдырдым, сезнен кӧчӧгӧз житмейдер эйе шул, казер дя ӓле кӧчӧгӧз житмей. 3 Сез шул ӓле тян кешеляре, ӓгяр дя сезнен арада кӧнчӧлӧкляр, ирешеўляр, кюнешя алмаганныклар бар икян, сез тян кешеляре тӧгӧл меней? Кеше гадятляре буйынча кыйланмыйсыз меней? 4 Берегез: мин Павелныкы, икенчегез: мин Аполлосныкы диб ӓйткян чакта сез тян кешеляре тӧгӧл меней? 5 Павелъ кем? Аполлосъ кем? Кызмятне итеўчеляр гня, алар арткылы сез ышаныуны алган, шунын ӧстӧня Ходай ӓр-кайсына кюбме биргянча. 6 Мин утыртым, Аполлосъ сыу сибте, ӓммя ўстереўче Алла. 7 Шунар кюря утыртыучы да, сыу сибеўче дя бер нястя дя тӧгӧл, барысын да ўстереўче Алла. 8 Утыртыучы да, сыу сибеўче дя бер тӧрлӧ, ӓммя ӓр-кайсыбыз ўзенен кызмятеня карата бюляген алыр.

Зач.128 9 Без Алланын эшчеляре, ӓммя сез Алланын басыуы, Алланын каралдысы. 10 Мин Алла мина биргян дяўлят белян оста торгозоучы кюк нигез кордом, ӓммя бютян шул нигез ӧстӧня торгоза, тик ӓр-кайсын ничек торгозганынны кара. 11 Бер корган нигездян башка бютян нигезне беряў дя коралмас; ул нигез Іисусъ Христосъ. 12 Шушы нигез ӧстӧня беряў-беряў алтыннан, кӧмӧштян, асыл ташлардан, агачтан, печяннян, саламнан торгоза мы, 13 ӓр-кайсынын эше кюренер, хокӧм кӧнӧ кюрсятер: ут эчендя кюрсятелер, ӓр-кемнен эше ничек икяне ут арткылы сыналыр шул. 14 Кемнен торгозган эше исян калса, ул сауабын алыр; 15 ӓммя кем-

нен эше жаныб бется, ул зыянны булыр; алай да ўзе тик ут эченнян котолган кюк кня котолор. 16 Сез Алла ӧйӧ икянегезне, сездя Алла Тыны торганны ялля белмейсез ме? 17 Кем дя кем Алла ӧйӧн жимерся, анар Алла кыйын тейерер, Алла ӧйӧ арыу шул, ямма ул ӧй сез буласыз.

Зач.129 18 Беряў дя ўзен ўзе алдандырмасын, ягяр дя бу гумердя кем белемне булырга уйласа, белемне булыр ӧчӧн ул акылсыз булсын. 19 Бу дӧньянең белемнеге Алла алдында акылсызлык шул, жазылганча: Алла белемнелярне аларның жумалыкларында эляктерер, диб. 20 Тагы да жазылган: Ходай белемнелярнен уйларын белядер, алар буш сагыш, диб. 21 Шулай берегез дя кешеляр белян мактанмагыз, барысы да сезнеке шул. 22 Павелъ мы, Аполлосъ мы, Кифа мы, дӧнья ме, тормош мы, ўлем ме, казерге ме, буласы мы - барысы да сезнеке; 23 сез Христосныкылар буласыз, ямма Христосъ - Алланыкы.

4-нче бюлем

Зач.130 1 Шулай яр-кем безне Христоснын кызмятчеляре итеб, Алла жяшерегенен жортон торгозоучылар итеб аннасын. 2 Жорт торгозоучылардан яр-кайсы дӧрӧс булыуы сорала. 3 Мине сез тикшерясез ме, жя бютян кешеляр тикшеряляр ме, минем ӧчӧн бу бик жук нястя, ўз турымда мин ўзем дя тикшермейем. 4 Мин ўз турымда бер ней дя белмясям дя, ўземне дӧрӧслямейем, мине тикшереўче Ходай шул. 5 Шунар кюря багытыннан элгяре ич ничек тя тикшермягез, Ходай килер, Ул карантыда жяшеренгянне жактыртыр, кюнелдя уйлаганнарны ачыклар, шул чакта яр-кемгя макталыу Алладан булыр. 6 Эй туганнар, мин мыны сезнен какка ўзем турысында, Аполлосъ турысында яйтямен, сез жазылганнан артыгын уйламаска бездян ойрянсенняр диб, бер-берегез алдында кютярелеб китмясенняр диб. 7 Кем сине östön итеб куя? Синең нейең бар суң, ней ала алмадың? Ягяр дя алсаң, алмагандый булыб ник мактанасын? 8 Сез инде туйыныб беттегез, сез инде байыдыгыз, сез бездян башка падшалык итя башладыгыз. Эй сез, чыннаб та

падшалык итсягез, без дя сезнен белян падшалык итяр эйек.

Зач.131 9 Әммя мин уйлыймын: без сунъннан жибярелгяннярне Алла ўлемгя биреляселяр кюк итеб кюрсятте: без дөньягя дя, пяриштялярга дя, кешелярга дя жыйын калык караб тора торган нястя кюк булдык. 10 Без Христосъ какына акылсыз, әммя сез Христоста акыллы; без әлсез, әммя сез ныk; сез даннаулы, әммя без кадерсез; 11 шул катле әлегя чаклы ачлыкка да, кибенеўгя дя, жалангачлыкка да, кыйынга да чыдыйбыз, илдян илгя кючеб жөрөйбез, 12 ўз кулыбыз белян эшляб тырышабыз. Безгя жаман сюз әйтяляр, без жакшылык телейбез, безне кысалар, без тюзябез; 13 безне курлыйлар, без теляк итябез; без дөнья өчөн чюб шикелле, тупрак шикелле, барыннан да әлегя чаклы табталабыз. 14 Мыны сезне оялтыр өчөн жазмыйым, әммя сөйөклө балаларым кюк итеб, сезне ўгетлеймен. 15 Сезнен Христосъ турысында өйрятеўчелярегез меннъяб булса да, тик алар аталар кюк төгөл; мин изге хабяр сөйляўем белян сезне Іисусъ Христоста тыудырдым; 16 шунар кюря сезгя инялямен: мин Христоска ошашкан кюк, сез дя мина ошашыгыз.

Зач.132 17 Шунын өчөн дя Ходай какына сөйөклө, ышанычлы улым Тімофейне мин сезгя жибярдем дя, ул минем Ходай какына булган жулларымны, бар жыйыннарда да ничек өйряткянемне сезнен исегезгя төшөрөр. 18 Мин сезгя бармый торгач та, сезнен кай берлярегез олосомакланды. 19 Әммя мин, әгяр дя Ходайга жараулы булса, озакламый сезгя килермен дя олосомаклануычыларнын сюзлярен гня төгөл, әммя көчлярен сынаб белермен. 20 Алла Падшалыгы сюздя гня төгөл шул, әммя көчтя. 21 Сезгя ничек киряк? Сезгя таяк белян килергя ме, әлля сөйөўлек белян, жыуашлык тыны белян ме?

5-нче бюлем

1 Ышанычлы эшетелгян сюз бар, сездя азгыннык итеў барлыкка килгян, өстяўеня шундый азгыннык, андый жалган деннеляр арасында да эшетелгяне жук: кемдер ўз атасынын катыны белян тора икян. 2 Әммя сез мындый эшне кылыучы сезнен

арадан чыгарылсын өчөн жылау арыуырак буласы урынга, олосомакландыгыз. 3 Мин тянем белян чиття тороб, әммя тыным белян сездя булыб, сездя торган кюк ўземне тойоб, мындый эшне кылыучыны, 4 Ходайыбыз Іисусъ Христоснын исеме какына сез жыйылганда, минем тыным да сезнен белян булыб, Ходайыбыз Іисусъ Христоснын кыуаты белян бергяляб, 5 Ходайыбыз Іисусъ Христоснын көнөня тыны котолсон диб, тянен борчорга аны сатанага бирергя уйладым.

Зач.133 6 Ич ней белян дя сезнен мактаныр жирегез жук, әз гня әчеткеч апара бөтөн камырны әчеткянне әлля белмейсез ме? 7 Сез жаңа камыр кюк булыр өчөн иске әчеткечтян тазарыгыз, сез шул инде әчеткечсез, безнен Пасха, Христосъ, безнен өчөн чалынган шул. 8 Шунар кюря иске әчеткеч белян, бозоклок, жаманнык әчеткече белян бяйрям итя башламыйык, әммя чыннык, тазалыкнын төчө кюмячляре белян бяйрям итейек.

Зач.134 9 Мин жибяргян жазыуымда сезгя азгыннар белян катышмаска диб жазган ыйым, 10 алай да, бу дөньянен азгыннары белян, жя мал сөйөучеляр белян, жя талаучылар белян, жя сынга табыныучылар белян бөтөнняй ўк катышмаска төгөл, алай иткян чакта сезгя бу дөньядян чыгыб китяргя киряк булыр ыйы. 11 Әммя кем ышаныучы туган диб аталыб, ўзе азгын булыб калыучы, жя мал сөйөўче, жя сынга табыныучы, жя усал сюзле, жя эчкече, жя талаучы булыб калыучы белян катышмаска диб жаздым мин сезгя, мындыйлар белян бергя утырыб ашарга да киряк төгөл. 12 Нейгя суң мина тыштагыларны тикшерергя, сез эчтягелярне тикшерясез төгөл ме? 13 Тыштагыларны тикшереўче Алла. Ўз арагыздан бозоклокка бяйлянгянне чыгарыб атыгыз.

6-нчы бюлем

1 Сезнен арада кем бютян кеше белян исябкя кереб, ул изгелярдян хокөм ителмейче, бозоклардан хокөм ителергя кыйыучылык итя? 2 Изгеляр дөньяне хокөм итясен әлля сез белмейсез ме? Әгяр дя сез дөньяне хокөм итясе икян, кечкеня эшлярне гня тикшерергя сез жараулы төгөл меней? 3 Без пяриштялярне хокөм итясене

ӓлля белмейсез ме? Тормоштагы эшлярне тикшерергя сез бигряк тя жараулы тӧгӧл менеӥ? 4 Сез тормошта кюнешя алмаган ауырлыклар булган чакта, жыйында бӧтӧнняӥ билгесезлярне ӱзегезгя хокӧм итеӱче итеб куясыз. 5 Оятыгызга кюря ӓйтямен: ӓлля сезнен арада туганнар арасындагыны тикшеря алырлык акыллы беряӱ дя жук мы? 6 Туган туган белян хокӧм итешя, ӧстяӱеня ышанмыӥ торганнар алдында. 7 Сезнен ӱз арагызда даулашыуыгыз шунысы сезгя бик курлык. Ник суӈ сезгя кимсетелгян кӧйӧ калмаска? Ник сезгя ӓйберегезне алганга тюзмяскя? 8 Ӓммя сез ӱзегез кимсетясез, ирексезляб аласыз, шунын ӧстӧня туганнарыгызныкын. 9 Дӧрӧс тӧгӧлляр Алла Падшалыгына керя алмасны ӓлля белмейсез ме? Алданмагыз, азгыннар да, сынга табыныучылар да, уйнашлык итеӱчеляр дя, куллары белян шакшыланыучылар да, ирляр белян ирляр жатыучылар да, 10 бурлар да, мал сӧйӧӱчеляр дя, эчкечеляр дя, усал сюзлеляр дя, талаучылар да Алла Падшалыгына керя алмыйлар. 11 Сезнен кайӥ берлярегез шундыйлар ыйы: ӓммя сез жыуындыгыз, сез арыуландыгыз, Ходайыбыз Ісусъ Христоснын исеме белян, Аллабызнын Тыны белян сез дӧрӧскя чыгарылдыгыз.

Зач.135 12 Миӈа бар да роксят ителгян, тик барысы да пайдалы тӧгӧл; миӈа бар да роксят ителся дя, мин ӱземне берсеня дя жиндермеӥ тороргa тейеш. 13 Ашамнык эч ӧчӧн, эч тя ашамнык ӧчӧн, тик Алла тегесен дя, мынысын да бетерер; тян азгыннык ӧчӧн тӧгӧл, ӓммя Ходаӥ ӧчӧн, Ходаӥ да тян ӧчӧн. 14 Алла Ходаӥ Ісусны тергезгян, безне дя Ӱз кыуаты белян тергезер. 15 Тяннярегез Христосъ саннары икянне ӓлля белмейсез ме? Алаӥ булгач, Христосъ саннарын алыб, аларны уйнашчы саннары итейек менеӥ? Жук, бу эш була кюрмясен! 16 Уйнашчы катынкыз белян кушылыучы анын белян бер тян булганны белмейсез ме ӓлля? Ӓйтелгян ич: Икесе бер тян булырлар (Быт. 2, 24), диб. 17 Ӓммя Ходаӥ белян кушылыучы Ходаӥ белян бер тын буладыр. 18 Уйнашлыктан качыгыз; кеше кыла торган ӓр-бер бютян жазык тяннян тышкары була,

ӓммя уйнашчы ӱз тяненя карышы жазыклана. 19 Тяннярегез сезгя Алла биргян, сездя тора торган Святый Тыннын ӧйӧ икянне, сез ӱзегезнеке тӧгӧл икянне белмейсез ме ӓлля?

Зач.136 20 Сез кыйбатлы бяйя белян сатыб алынган ич. Шунӷар кюря тяннярегездя дя, жаннарыгызда да Алланы даннаб торогоз, алар Алланыкы шул.

7-нче бюлем

1 Сез мина жазган нястя турысында ӓйткяндя, кешегя катынга кагылмаганы арыу. 2 Ӓммя азгынныкка туры килмяс ӧчӧн, ӓр кемнен ӱз катыны булсын, ӓр катыннын да ӱз ире булсын, 3 ир катынына тейешлене кылыб торсон, катын да иреня шулай булсын; 4 катын ӱз тяненя баш тӧгӧл, ӓммя ире баш, шулай ук ир дя ӱз тяненя баш тӧгӧл, ӓммя катыны баш. 5 Бер-берегездян читкя ауышмагыз, тик ризалык белян багытлыча гна, ураза тотарга, телякkя тырышыу ӧчӧн гня, аннары тагы бергя булыгыз, тыйылыб торалмаганыгыз белян шайтан сезне сынамасын. 6 Алай да минем бу сезгя кушыб ӓйтеӱем тӧгӧл, ӓммя киняш итеб ӓйтеӱем. 7 Мин шу бар кешеляр дя минем кюк булсыннар ыйы диб телейем, алай да ӓр кемгя Алладан ӱзеня бирелгянчя, беряӱ былай, беряӱ тегеляй.

8 Ӧйлянмягян-китмягяннярга, тол калганнарга ӓйтям: аларга минем кюк калыу арыу. 9 Ӓммя инде тыйылыб тора алмасалар, ӧйлянсенняр, кеяӱгя китсенняр, жалкыннангынчы ӧйлянеӱе-китеӱе арыуырак шул. 10 Ӓммя ӧйлянгяннярга-киткяннярга мин кушмыйым, ӓммя Ходай куша: катын иреннян айырылмасын. 11 Ӓгяр дя айырыла икян, китмягян кӧйӧ калсын, жя ӱз ире белян татыуланышсын, ире дя катынын ташламасын.

Зач.137 12 Бютяннярга Ходай тӧгӧл, ӓммя мин ӓйтям: ӓгяр дя бер-бер туганнын ышанмый торган катыны бар икян, ӓгяр дя ул катын анын белян тороргa риза икян, ире аны ташламасын. 13 Катын да ышанмый торган ире булыб, ул анын белян тороргa риза булса, катын да аны ташламасын. 14 Ышанмый торган ир ышаныучы катыны белян жактырыла шул, шулай ышанмый торган катын да

ышаныучы ире белян жактырыла. Алай булмаса, сезнен балаларыгыз бозок булырлар ыйы, әммя казер алар изгеляр. 15 Әгяр ышанмый торганнын айырыласы киля икян, айырылсын, туган да, сенел дя мындый чакта бяйляўле төгөл, Ходай безне татыулыкка чакырган шул. 16 Син катын, нейлектян иренне коткара алмам диб белясең? Жя син ир, нейлектян катынымны коткара алмам диб уйлыйсың? 17 Әр-кем Алла анар ничек билгелягян, Ходай ничек чакырган, шулай кыйлансын. Мин бар жыйыннарга да шулай кушамын. 18 Кем киселгян көйө чакырылган икян, жяшермя, кем киселмягян көйө чакырылган икян, киселмя. 19 Киселеў дя, киселмягяннек тя бер нястя дя төгөл, әммя бар да Алланын бойрогон тотоудан тора. 20 Әр-кайсыг ничек чакырылган, шул исемдя калсын. 21 Кол килеш чакырылганыг икян, жөдямя, алай да иркеннеккя чыга аласын икян, арыуырагы белян пайдалан. 22 Ходайга чакырылган кол Ходайнын иркене шул, шулай чакырылган иркен кеше дя Христоснын коло. 23 Сез кыйбатлы бяягя сатыб алынганнар, кеше коллары булмагыз.

Зач.138 24 Кем нейдей исемдя чакырылган, туганнар, әркайсыгыз Алла алдында шулай калыгыз. 25 Кыз-жегет көйө тороу турысында Ходайдан кушкан сюз миндя жук, әммя Ходайдан изгелек алыучы кюк, сезгя киняш бирямен, Анар туры булыгыз. 26 Кешегя шул көйө калыуы әйбят диб, арыуырак диб саныйым. 27 Син катын белян кушылганыг икян, айырылыуны эзлямя, катынсыз калганыг икян, катын эзлямя. 28 Алай да, әгяр өйлянсяң дя жазыклы булмыйсың, әгяр кыз кеше кеяўгя чыкса да, жазыклы булмый, әммя мындыйларнын тян жагыннан сагышкөйөкляре булыр, әммя мин сезне кызганам шул. 29 Эй туганнар, сезгя әйтям, багыт инде кыска, катыннары булганнар катыннары жук шикелле булсыннар; 30 жылаучылар да жыламый торганнар кюк, сөйөнөўчеляр дя сөйөнмей торганнар кюк, сатыб алыучылар да табыш табмый торганнар кюк, 31 бу дөнья белян пайдаланыучылар да пайдаланмый торганнар кюк булсыннар, бу дөньянен төсө узыб бара шул. 32 Әммя мин сез сагышсыз булсагыз ыйы диб телеймен. Катынсыз кеше Ходай-

га ничек жараулы булырга диб, Ходай өчөн сагышлана; 33 әммя катынны кеше ничек катынга жарарга диб, дөнья турысында сагышлана; иргя киткян катын белян китмягян кыз арасында да айырма бар. 34 Иргя китмягян кыз Ходайга ничек жараулы булырга диб, тыны белян дя, тяне белян дя изге булыр өчөн Ходай өчөн сагышлана. Иргя киткян катын, ничек иремя жараулы булырга диб, дөнья өчөн сагышлана.

Зач.139 35 Мыны сезгя пайдагыз өчөн әйтямен шул, әммя сезне бяйляб тотар өчөн төгөл, әммя сез бютянгя алданмыйчы, арыу кылмыш белян туктаусыз Ходайга кызмят итсягез эйе диб. 36 Әгяр дя кем ўзенен кызына жяше житкян көйө шул көйө калыуы килешле төгөл диб саный икян, ул чакта ўзе телягянчя эшлясен, жазыкланмый, мындыйлар кеяўгя чыксыннар. 37 Әммя кем ўз кюнелендя ауышмаслык нык булыб, киряксенеў белян жөдямейче, ўз иркеня баш булыб, кюнелендя кызлыгын сакларга уйлаган икян, андый әйбят эшлей. 38 Шунар кюря, кызын кеяўгя биреўче әйбят кыйлана, әммя бирмей торганы бигряк тя әйбят кыйлана. 39 Ире исян чакта катын законъ белян иреня бяйляўле, әгяр дя ире ўлся, кемгя телей кеяўгя чыгарга иркеннек ала, тик Ходайда булганга. 40 Әммя шул көйө калса, ул бахетлеряк, бу минем киняшем, әммя мин Алла Тыны миндя дя бар диб уйлыйым.

8-нче бюлем

1 Сыннарга корманга китерелгян ашамныклар турысында без белябез, безнен шул барыбызнын да белеўлегебез бар, тик белеўлек кюнелне олосомакландыра, әммя сөйөўлек арыуга өйрятя. 2 Кем ўзен нястядер белям диб уйласа, ул белергя тейешлечя әле бер нястя дя белмей, 3 әммя кем Алланы сөя, ул кешегя Алладан белеўлек биреля. 4 Шулай сыннарга корманга китерелгянне ашауга тотоноу турысында без белябез: сын дөньядя бер нястя дя төгөл, бер Алладан башка бютян алла жук икянне дя белябез. 5 Алай да кюктя ме, жирдя ме алла диб атала торганнар булса да, шулай кюб аллалар, кюб башлыклар бар кюк тойолса да, 6 әммя без-

нен Алла Атабыз бер гня, Аннан бар да булган, без дя Анын өчөн, аннары бер Ходай Iисусъ Христосъ, Анын белян барысы да, без дя Анын белян булдырылган. 7 Әммя барысынын да белеүлеге мындый төгөл, кайберяўляр казергя чаклы биренгян кюнелляре белян сыннарны арыу диб саныйлар, сыннарга корманга китерелгян ашамныкны ашыйлар, шулай аларнын кюнелляре әлсез булганга кюря шакшылана.

Зач.140 8 Ашамнык безне Аллага жакын итмей, ашасак та, без бер нястя дя арттырмыйбыз, ашамасак та, бер нястя дя киметмейбез ич. 9 Алай да сак булыгыз, сезнен бу иркеннегегез әлсезляргя аздыргыч булмасын. 10 Әгяр дя беряў-беряў синең сыннар өйөндя, белгян көйө, өстял арасында ашаб утырганынны кюрся, анын кюнеле дя, әлсезлеге буйынча, сыннар корманын ашарга аны да кызыктырмас меней? 11 Синең беля тороб кылган эшеннян әлсез туганың әрям булыр, анын өчөн дя Христосъ ўлгян ич. 12 Шулай туганнарыгызга карышы жазыкланыб, аларнын әлсез кюнеллярен аздырыб, сез Христоска карышы жазыкланасыз. 13 Шунар кюря, ашамнык минем туганымны аздырса, туганымны аздырмас өчөн, мин гумергя ит ашамам.

9-нчы бюлем

1 Мин апостолъ төгөл меней? Мин ирекле төгөл меней? Мин Ходайыбыз Iисусъ Христосны кюрмядем меней? Сезнен Ходайда тороуыгыз минем эшем төгөл меней?

Зач.141 2 Бютяннярга мин апостолъ булмасам да, сезгя апостолъ, минем апостоллогымнын билгесе Ходайда тороучы - сез. 3 Мине айыблаучыларга жауабым шушы. 4 Безнен ашарга, эчярга иркебез жук меней? 5 Бютян апостоллар кюк, Ходайнын агалары белян Кифа кюк, ўзебез белян бергя катын туганыбызны алыб жөрөргя иркебез жук меней? 6 Әлля Варнава белян бер минем гня эшлямяскя иркебез жук мы? 7 Нейдей салдат бер-бер чакта ўз жаныннан ашаб кызмят итя? Жөзөм утырткан кеше ўз жимешен кем ашамый? Көтөў өткян кеше кем көтөўеннян сөт ашамый? 8 Мыны мин тик кеше исяблягянчя гня әйтям меней?

Законъ да шуны äйтя тögöл ме сун? 9 Шушы сяятлей Моисей законында жазылган: Ашлык суга торган ўгезнен ауызын бяйляб тотма, диб (Втор. 25, 4). Ўгезляр турысында гна сагышлана мы Алла? 10 Ялля бу безнен öчöн дя äйтелгян ме? Эйе, бу безнен öчöн жазылган: сукалый торган кеше ömöт тотоб сукаларга тейеш; ашлык суга торган кеше, кötöб торганын алырым диб, ömöт тотоб сугарга тейеш. 11 Äгяр без сезгя жаныгызга киряклене чячеб, сездян тянгя киряклене урыб алсак, бу кюб меней? 12 Сезгя бютяннярнен ирке бар икян, безнеке бигряк тя бар, булса да, без ул иркебез белян пайдаланмадык, Христоснын изге хабярен сöйляргя кумачаулык булмасын диб, без барысына да тюзябез.

Зач.142 13 Чиркяўдя изге эшне кылыучылар чиркяўдян туйынганны ялля белмейсез ме? Корман урнына кызмят итеўчеляр корманнан ölöш айырыб алалар. 14 Шулай Ходай да Евангеліе сöйляўчеляргя изге хабяр сöйляўдян туйыныб тороргa куша. 15 Ямма мин мындыйнын берсе белян дя пайдаланмадым. Мыны жазыуым да минем öчöн шулай булсын диб тögöл, кемдер минем данымны жукка чыгаргынчы, минем öчöн ўлгянем арыуырак. 16 Äгяр мин изге хабяр сöйлöйöм икян, мактанырлык минем бер нейем дя жук, бу мина кыларга тейешле эш шул, кайгы мина ягяр изге хабяр сöйлямясям. 17 Äгяр дя мыны ўз иркемнян кыламын икян, анын öчöн бюляк алырмын, ягяр дя кылыуым ўз иркемнян булмаса, алайса мин мина табшырылган кызмятне гня итеўче. 18 Ней öчöн суң миң бюляк? Шунын öчöн, Евангеліе сöйляб, Христосъ турында изге хабярне бушлай сöйлöйöм, сöйлягяндя ўземя тейешле хакым белян пайдаланмыйым.

Зач.143 19 Ўзем беряўгя дя кол булмаган köйö, мин ўземне барысына да кол иттем, ышаныучыларны кюбряк табыйым диб. 20 Іудейлярне табыйым диб, іудейляр öчöн мин іудей кюк булдым; законъ белян тороучыларны табыйым диб, законъ белян тороучылар öчöн мин законъ белян тороучылар кюк булдым; 21 законсыз тороучыларны табыйым диб, законсыз тороучылар öчöн мин законсыз тороучылар кюк булдым, алай да Алла

алдында законсыз булмадым, әммя Христосъ законын тоттом; 22 әлсезлярне табыйым диб, әлсезляр өчөн мин әлсез кюк булдым. Барысы өчөн дя, ичмаса бер азын гна булса да коткарыйым диб, мин барысына да ошарга тырыштым. 23 Мыны мин Евангеліе какына кыламын, Евангеліегя керешейем диб. 24 Жөгөрөштя бар да жөгөргянне, әммя бюлякне тик беряў гня алганны белмейсез ме әлля? Сез дя бюляк алыр өчөн, шулай жөгөрөгөз. 25 Жөгөрөшкя чыгыучылар барысы да барыннан да тыйылыб торалар, алар черей торган бюляк алыр өчөн тырышалар, әммя без черемей торганны алыр өчөн. 26 Шунар кюря мин ышангышсыз нястягя жөгөргян кюк жөгөрмөйөм, жилгя китясе өчөн көряшкян кюк көряшмейем, 27 әммя тянемне басылдырыб, жинярга тырышамын, бютняргя сөйляб, ўзем тейешсез көйө калмасам ыйы диб.

10-нчы бюлем

1 Эй туганнар! Сезгя бу турыны белдермейче калдырасым килмей: аталарыбыз барысы да болот астында барганнар, барысы да дингез арткылы ўткянняр; 2 барысы да Моисей артыннан болот эчендя килеб, чумылдырылырга кергян кюк, дингезгя кергянняр; 3 барысы да бер төрлө жан ашамныгы ашаганнар; 4 барысы да бер төрлө жан эчемнеге эчкянняр, буласыны белдереўче таштан чыккан жан эчемнеген эчкянняр; әммя бу таш Христосъ булган.

Зач.144 5 Тик Алла алар арасыннан әзляреня гня ризалык иткян, алар шу буш кырда жукка чыкканнар. 6 Былар безгя кючергеч булыб калганнар, алар няпесле булган кюк, без дя няпесле булмас өчөн. 7 Аларнын кайберляре шикелле сынга табыныучылар булмагыз, алар турында жазылган: калык ашарга-эчярга утырган, аннары тороб уйнарга тотонган диб. 8 Алар кюк азгыннык итярга тотонмойок, ничек аларнын кайберляре азгыннык иткянняр дя, бер көн эчендя жегерме өч мең харяб булган. 9 Алар кюк Христосны сынарга тотонмойок, ничек аларнын кайберляре Алланы сынаб, жыланнардан харяб булганнар. 10 Зарланмагыз да, ничек аларнын кайберляре зарланган-

нар да, Бетереўче кулыннан харяб булганнар. 11 Былар бар да алар белян булыб узган, безгя кючергеч булыб, без сунгы гумерлярга килеб житкяннярне өйрятер өчөн жазылган.

Зач.145 12 Шунныктан кем басыб торам диб уйлый икян, жыгылмыйым тагы диб, сакланыб тор. 13 Сезгя сыналыу килгян, бютян төгөл, кешелярга була торган; Алла туры, Ул сезгя көчөгөздян тышкары сыналыу жибярмяс, сыналган чагында сез тюзеб ўткяря алырлык итеб, жинеллеген дя бирер. 14 Шулай, сөйөклөлярем, сыннарга табыныудан качыгыз. 15 Мин мыны сезне уйлаб белеўчеляр итеб яйтям, минем яйткянем турында ўзегез уйлаб белегез: 16 без бахиллей торган бахилляў сауыты Христоснын Канына катышыу төгөл меней? Без сындыра торган икмяк тя Христоснын Тяненя катышыу төгөл меней? 17 Икмяк бер, шулай без дя кюбебез бер тян булыб, барыбыз да бер икмяктян өлөш алабыз шул. 18 Тян жагыннан булган Израилгя карагыз, корманга китергянне ашаучылар корман урнына керешеўле булмый меней? 19 Минем суң бу ней яйтеўем? Сын ул бер-бер төрлө нястя диб ме? Жя сыннарга китергян корман бер-бер төрлө нястя диб ме? 20 Жук, яммя жалган деннеляр сыннарга корман китереўляре белян, Аллага төгөл, аны женнярга китеряляр, яммя мин сезнен женняр белян катышыулы булыуыгызны телямейем. 21 Ходайнын Сауытыннан да, женняр сауытыннан да эчя алмассыз, Ходайнын өстяленя дя, женняр өстяленя дя керешеўле була алмассыз. 22 Ялля без Ходайнын ачыуын китерергя тяўкяллярбез ме? Без ялля Аннан көчлөряк ме?

Зач.146 23 Мина бар да роксят ителгян, тик бар да пайдалы төгөл, мина бар да роксят ителся дя, тик бар да арыуга өйрятмей. 24 Беряў дя ўзеня гня эзлямя, яммя яр-кайсың бютянгя пайдалыны эзля. 25 Базарда ней сатыла, кюнелегез тыныч булыр өчөн бер ней дя тикшермейче ашагыз; 26 жир дя, аны тутырыб тора торган нястяляр дя Ходайныкы шул (Пс. 23, 1). 27 Ягяр Аллага ышанмый торган беряў сезне чакырса, сезнен анда барасыгыз кился, кюнелегез тыныч булыр өчөн бер дя тикшермейче, анда сезгя куйылган нястялярне ашагыз.

Зач.147 28 Ӓгяр беряӱ сезгя ӓйтя икян, бу сыннар корманы диб, ул чакта сезгя ӓйткян кеше какына, кюнѣле тыныч булыр ӧчӧн, ашамагыз, жир дя, аны тутырыб тора торган нястяляр дя Ходайныкы шул. 29 Ӱз кюнѣлегез турысында димейем, ӓммя теге кешенеке турысында, нейгя суҥ минем иркеннегемне чит кеше кюнѣле айыблауы киряк? 30 Ӓгяр мин ашамныкны тау итеб ашыйым икян, нейгя суҥ мине ӓрлярга, минем Аллага тау итеӱем ӧчӧн менеӥ? 31 Шулай, ашасагыз да, эчсягез дя, бютян беряр эш кылсагыз да, барысын да Алла даны ӧчӧн кылыгыз; 32 іудейлярга дя, еллиннарга да, Алланын арыу жыйынына да алданыулык китермягез. 33 Шулай мин дя ӱз пайдамны гна эзлямейче, кюб кешелярга пайдалыны эзляб, алар котолсоннар диб, ӓр-бер турдан да ӓр-кайсына жарарга тырышам.

11-нче бюлем

1 Мин Христоска ошашкан кюк, сез дя мина ошашырга тырышыгыз. 2 Эй туганнар! Мин ӓйткянне исегездя тотканыгызга сезне мактыйым, мин кушканны мин ӓйткянчя тотасыз шул. 3 Тагы сезнен шуны белеӱегезне телеймен: ӓр-бер иргя баш Христосъ, катынга баш ире, Христоска баш Алла. 4 Башы жабык кӧйӧ теляк итеӱче, жя пагамбярлек итеӱче ӓр-бер ир ӱзенен башын оялта. 5 Ӓр-бер катын да башы ачык кӧйӧ теляк итеӱче, жя пагамбярлек итеӱче ӱзенен башын оялта, бу ӱзенен чячен кырган кюк була шул. 6 Ӓгяр дя катын башын бӧркясе килмяся, айса чячен кыркытсын, ӓгяр дя катынга чячен кыркыткан килеш, жя кырган килеш оят булса, айса башын каблаб жӧрсӧн. 7 Шулай ир башын кабларга тейеш тӧгӧл, ул шу Алланын ошашы да, даны да; ӓммя катын иренен даны.

Зач.148 8 Ир катыннан тӧгӧл шул, ӓммя катын ирдян. 9 Ир катын ӧчӧн булдырылмаган, ӓммя катын ир ӧчӧн булдырылган. 10 Шуна кюря катын ӱзеня баш кеше барлыгыннан пяриштяляр ӧчӧн башы ӧстӧндя билге тотарга тейеш. 11 Алай да ир катынсыз булмыӥ, Ходай какына катын да ирсез булмыӥ. 12 Катын ирдян булган кюк, шулай ир дя катын

арткылы, бар да Алладан шул. 13 Ӱзегез уйлаб карагыз, катынга башын бӧркямягян кӧйӧ Аллага теляк итеуе килешя ме сун? 14 Дӧнья булмышы ук сезне ӧйрятя бит, ягяр дя ир чячен ӱстерся, бу анар килешсезлек була ич. 15 Ямма катын чячен ӱстерся, бу анар килешлелек, анар шу чяче бӧркяӱ урнына бирелгян. 16 Ягяр беряӱенен сюз ирештерясе кился, Алланын жыйынында да, безнен дя андый гадятебез жук. 17 Ямма мыны айтеб куйыб сезне мактамыйым, сезнен шу жыйылыуыгыз арыуырак булырга тӧгӧл, ямма начарырак булырга. 18 Береннян, мин эшетям: сез чиркяӱгя жыйылган чакта, сезнен арада бюленешеӱляр дя була икян, быларнын кайсыларына ышанам да. 19 Сезнен арада тӧрлӧчя уйлаучылар да булырга тейеш, сезнен арадагы дӧрӧс уйлаучылар ачыкланыу ӧчӧн. 20 Алга таба айткяндя, сезнен жыйылыуыгыз шулай, Ходайнын кичке ашын ашарга жыйылган кюк тӧгӧл; 21 яр-кайсыгыз бютяннярдян алдан ӱзенен ашамныгын ашарга ашыга, шулай итеб кайсыларыгыз ач кала, кайсыларыгыз артыгын эчя. 22 Ашар-эчяр ӧчӧн алля сезнен ӧйлярегез жук мы? Ялля Алланын жыйынын кадерлямейсез ме? Шулай жуксыл кешелярне кимсетясез ме? Сезгя ней айтергя сун? Мынын ӧчӧн сезне мактарга мы? Мактамыйым.

Зач.149 23 Мин Ходайнын Ӱзеннян алганымны сезгя дя айтеб бирдем: Ходай Иисусъ, Ӱзе, азабына бирелясе тӧннӧ, икмяк алыб, 24 тау итеб, сындырыб айткян: алыгыз, ашагыз, бу - Минем сезнен ӧчӧн ыуалынган Тянем, мыны Мине исегезгя тӧшӧрӧр ӧчӧн кылыгыз, дигян. 25 Ашаганнан сун тагы шулай сауыт биреб айткян: бу сауыт - Минем сезнен ӧчӧн Каным белян куйган жана законъ; мыннан эчкян чагында, Мине исегезгя тӧшӧрӧр ӧчӧн кылыгыз (Лук 22, 19-20), дигян. 26 Шунар кюря сез бу икмякне ашаган сайын, бу сауыттан эчкян сайын Ходайнын ӱлгянен Ул килгенче белгертеб торасыз. 27 Алай булгач, бу икмякне тейешсез ашаучы, жя бу Ходай сауытындагын тейешсез эчеӱче Ходайнын Тяне, Каны карышысында айыблы буладыр. 28 Шунар кюря кеше ӱзен ӱзе бик сынаб кна, сагайыб кна бу икмякне кабсын, бу сауыттагын эчсен. 29 Бу Ходайнын Тя-

нен, Канын кадерлямейче тейешсез кӧйӧ кабкан кеше, эчкян кеше ӱзеня айыбка кабадыр да, эчядер дя. 30 Сезнен арадагы кюб кешенен ауырыб чирляб жатканныгы, байтагысынын ӱлгяне дя шунныктан буладыр.

Зач.150 31 Без ӱзебезне ӱзебез тикшерсяк, Алла хокӧмӧндя тикшерелмяс эйек; 32 ӓммя казер безне Ходай Ӱзе тикшереб, безгя кыйын тейеря, без бӧтӧн дӧнья белян айыблы булмасак ыйы диб. 33 Шунӷар кюря, туганнарым, кичке ашка жыйылганда бер-берегезне кӧтӧгӧз. 34 Сезнен жыйылыуыгыз айыбланыуга булмас ӧчӧн кем ач икян, ӧйӧндя ашасын. Калганнарын ӱзем килгяч тӧзятерем.

12-нче бюлем

1 Эй туганнар! Тыннын бюлякляре турысын сезгя белдермей калдырасым килмей. 2 Белясез бит, сез жалган дендя чагында, сезне кемдер алыб барган кюк, тауышсыз сыннарга жӧрдӧгӧз. 3 Шунӷар кюря сезгя ӓйтямен: Алла Тыны белян сӧйляӱче беряӱ дя Іисуска каргау сюзе ӓйтмяс, беряӱ дя Іисусны Ходай диб ӓйтя алмас, тик Святый Тын арткылы гна ӓйтя алыр.

Зач.151 4 Бюлякляр тӧрлӧчя, ӓммя Тын шул ук бер; 5 кызмятляр дя тӧрлӧчя, ӓммя Ходай шул ук бер; 6 кылмышлар да тӧрлӧчя, ӓммя барына да, барын да булдырыб житкезеӱче Алла шул ук бер. 7 Ӓр-кемгя Тыннын ачылыуы пайдага бирелә; 8 беряӱгя Тыннан сюз белемнеге бирелә, бютянгя шул ук Тын белян белеӱлек сюзе бирелә; 9 кайсына шул ук Тын белян ышаныу, кайсына шул ук Тын белян чирдян тергезеӱ бюляге бирелә; 10 кайсына кодрятляр кылыу, кайсына пагамбярлек итеӱ, кайсына тыннарны белеӱ, кайсына тӧрлӧ телляр, кайсына теллярне аннатыу бирелә. 11 Быларнын барысын да шул ук бер Тын, Анӷар ничек жараулы, шулай ӓр-кемгя айырым бюлеб, кылыб житкезя.

Зач.152 12 Тян беряӱ, ӓммя саннары кюб, алар кюб булсалар да, бер тяннен саннары булыб, бер тян булыб тоташкан кюк, Христосъ та шулай. 13 Без шул барыбыз да бер Тын белян бер тянгя чумылдык, іудейляр ме, еллиннар мы, коллар мы, иркен-

дягеляр ме, барыбыз да бер Тын белян эчертелгян. 14 Тян бер гня саннан тормой шул, ӓммя кюб саннардан тора. 15 Ӓгяр дя аяк ӓйтся: мин тянгя тейешле тӧгӧл, мин бит кул тӧгӧл диб, ӓлля шунын ӧчӧн гня ул тянгя тейешле тӧгӧл ме? 16 Ӓгяр дя колак ӓйтся: мин тянгя тейешле тӧгӧл, мин бит кюз тӧгӧл диб, ӓлля шунын ӧчӧн гня ул тянгя тейешле тӧгӧл ме? 17 Ӓгяр дя бӧтӧн тян кюздян гня торса, эшетеў кайда булыр ыйы? Ӓгяр бар да эшетеў булса, ис тойоу кайда булыр ыйы? 18 Ӓммя Алла, Ӱзеня ошаганча, саннарны барысын да тянне тоташтырырга ӱз урыннарына куйган. 19 Ӓгяр дя барысы да бер тӧрлӧ сан гна булса, тян кайда булыр ыйы. 20 Ӓммя казер саннар кюб, тян бер. 21 Кюз кулга ӓйтя алмый: син мина жараулы тӧгӧл диб, жя шулай ук баш та аякка ӓйтя алмый, сез мина киряк тӧгӧл диб. 22 Киресенчя, тяннен ӓлсезеряк диб тойола торган саннары бигряк тя кирягеряк; 23 саннарнын тяндя безгя бик арыу тӧгӧллярен кюбряк кастярлейбез; 24 бик матур тӧгӧл жирляребезне бигряк тя ӓйбятляб каблыйбыз, матур жирляребез каблауны киряксенмей дя. Ӓммя Алла чамалаб тянне тӧзягян, ӓлсезряк жирляреня кюбряк сагыш биргян, 25 тяндя айырылышыу булмасын, бар саннар да бер-берсе ӧчӧн тигез сагышлансын диб. 26 Шуна кюря бер сан сызлана икян, анын белян бар саннар да сызлана, бер сан рахятляня икян, анын белян бар саннар да сӧйӧнӧшяляр.

Зач.153 27 Сез дя Христоснын тяне, ӓммя тӧрлӧ саннары. 28 Алла арыу жыйында кайсыларын апостоллар итеб куйган, кайсыларын пагамбярляр итеб, кайсыларын ӧйрятеўчеляр итеб, тагы да, кайсына кодрятляр кыларга кыуат биргян, шулай ук тӧзятеўляр, булышыулыклар, башкарыулар, тӧрлӧ телляр бюляген биргян. 29 Бар да апостоллар мы? Бар да пагамбярляр ме? Бар да ӧйрятеўчеляр ме? Бар да кодрятляр кылыучылар мы? 30 Барысында да тергезеў бюляге бармы? Бары да тӧрлӧ телляр белян сӧйлӧйляр ме? Барысы да аннатыучылар мы? 31 Олорак бюлякляр ӧчӧн тырышыгыз, мин дя сезгя тагы да жугарырак кютяря торган жулны кюрсятермен.

13-нче бюлем

1 Ӓгяр дя мин кеше телляре белян дя, пяриштя телляре белян дя сӧйӧй белсям дя, сӧйӧўлегем булмаса, мин жангырый торган бакыр кюк, жя тауыш биря торган кимвал кюк кня. 2 Ӓгяр дя миндя пагамбярлек итеў бюляге бар икян, бар жяшереннярне дя белям икян, тӧрлӧчя белеўлегем дя, тауларны кючерерлек ышаныуым да бар икян, ӓммя сӧйӧўлегем булмаса - мин бер нястя дя тӧгӧл. 3 Ӓгяр дя мин бар малымны ӧляшеб бетерсям дя, тянемне жандырырга бирсям дя, ӓгяр дя минем сӧйӧўлегем булмаса, мина былардан бер пайда жук.

Зач.154 4 Сӧйӧўлек озак тюзя, арыу кюнелле була, сӧйӧўлек кӧнчӧлӧклӧ булмый, сӧйӧўлек ӧскя чыгарга тырышмый, олосомакланмый, 5 тыйнаксызланмый, ўзеня кирякне гня эзлямей, жарсымый, усаллыкны уйламый, 6 дӧрӧссӧзлӧккя сӧйӧнмей, ӓммя чынныкбелян бергя сӧйӧня, 7 барын да каблый, барсына да ышана, барына да ӧмӧт тота, барына да тюзеб ўткяря. 8 Пагамбярлек туктаса да, телляр дяшмяс булса да, белеўлек бетерелся дя, сӧйӧўлек бер кайчан да бетмяс. 9 Без шул бер ӧлӧш кня белябез, бер ӧлӧш кня пагамбярлек итябез, 10 тулы житешлек килеб урыннашкач, ул чакта бер ӧлӧш дигяне тукталыр. 11 Мин бала чагында балалар кюк сӧйляштем, балалар кюк уйладым, балалар кюк исяб жӧрттӧм, ӓммя инде ир булгач, балалар кюкне ташладым. 12 Казер без томанны пыяла арткылы кюргян кюк чамалаб кна кюрябез, ул чакта инде кюзгякюз кюрербез. Казер бер ӧлӧш кня белямен, ул чакта инде ўзем беленгян кюк, мин дя белермен. 13 Ӓммя казер шушы ӧчяў килеб тора: ышаныулык, ӧмӧт тотоулык, сӧйӧўлек, ӓммя алар арасында олорагы сӧйӧўлек шул.

14-нче бюлем

1 Сӧйӧўлектя торогоз, тын бюлякляре ӧчӧн тырышыгыз, бигряк тя пагамбярлек итяр ӧчӧн. 2 Кем таныш тӧгӧл телдя сӧйлӧй икян, ул кешелярга тӧгӧл, ӓммя Аллага сӧйлӧй, аны шу беряў дя анламый, ул тыны белян жяшеренне ӓйтя шул; 3 ӓммя кем пагамбярлек

итя икян, ул кешелярне өйрятер өчөн, ўгетляў өчөн, тынычландырыу өчөн äйтя. 4 Кем таныш төгөл телдя сөйлөй икян, ул ўзен гня өйрятя, äммя кем пагамбярлек итя икян, ул арыу жыйынны өйрятя. 5 Мин сез барыгыз да төрлө телляр белян сөйляшеўегезне телеймен, алай да пагамбярлек итеўегез сезгя арыуырак, төрлө телляр белян сөйляшеўче жыйынга ўгет бирерлек анната алмаганда пагамбярлек итеўе төрлө телляр белян сөйляўдян жугарырак шул.

Зач.155 6 Äгяр казер сезгя килеб, туганнарым, таныш төгөл телляр белян сөйлөй башласам, äгяр сезгя жя таныткычлар белян, жя белеўлек, жя пагамбярлек итеў, жя өйрятеў белян аннатыб бирмясям, сезгя нейдей пайда китерермен суң? 7 Сыбызгы, жя госля кюк тауыш чыгара торган жансыз äйберляр дя төрлөчя тауышлар бирмяся, ничек белергя суң сыбызгыда жя гöслядя ней уйнаганны? 8 Äгяр быргы билгелянгян тейешле тауышны чыгармаса, кем сугышка äзерляня башлар? 9 Шулай сез дя телегез белян аннашылмый торган сюзляр äйтсягез, сез ней сөйлягянне ничек белсенняр? Сез жилгя гня сöйлярсез. 10 Дöньядя ней катле төрлö сюзляр бар, аларнын äр-бере ней дя булса белгертя. 11 Äгяр дя мин сюз ней белгерткянне аннамасам, мин сöйляўчегя чит ил кешесе, сöйляўче дя мина чит ил кешесе. 12 Шулай сез дя тын бюлякляре өчөн тырышкан чакта, жыйынны өйрятер өчөн тынга байырга тырышыгыз. 13 Шунар кюря син, таныш төгöл тел белян сöйляшеўче, анната белеў бюляге булсын диб теляк ит. 14 Мин шу таныш төгöл тел белян теляк иткян чакта, минем тыным теляк ится дя, уйым жимешсез кала. 15 Ней кыларга суң? Тыным белян теляк итяргя басарым, уйым белян дя теляк итярем, тыным белян жырларым, уйым белян дя жырларым. 16 Син тыныг белян даннаганда жанында тора торган гадей кеше синең тау итеўеня ничек: аминь, диб äйтсең? Син ней äйткянне ул шу аннамый. 17 Син äйбят тау итясең, äммя бит бютян кеше ўгет алмый. 18 Аллама тау итямен: мин шу барыгыздан да кюбряк төрлö телляр белян сöйляшямен. 19 Äммя чиркяўдя таныш төгöл телдя менняб сюз äйткенче, бютяннярне дя öйрятясем килеб, уйым белян

биш сюз булса да äйтеуем жакшырак.

Зач.156 20 Эй туганнар! Уйыгыз белян балалар кюк булмагыз, усаллыкка жяш балалар кюк булыгыз, уйыгыз белян оло кешеляр кюк булыгыз. 21 Законда жазылган: Бютян телляр белян, бютян ауызлар белян бу калыкка сöйлярем, шул чакта да Мине тыннамаслар (Исаія 28, 11-12), дей Ходай, диб . 22 Шулай телляр билге булыб торалар, ышанычылар öчöн тöгöл, äммя ышанмый торганнар öчöн; пагамбярлек ышанмый торганнар öчöн тöгöл, äммя ышаныучылар öчöн. 23 Äгяр бötöн жыйын бергя жыйылыб, барысы да таныш тöгöл телляр белян сöйляшя башласалар, шунда сезнен жанга аннамый торганнар, жя ышанмый торганнар керсяляр, сез женнянсез икян диб äйтмясляр ме? 24 Äммя барысы да пагамбярлек иткян чакта, ышанмый торган, жя белмей торган беряў керся, шунда барысы белян дя анын дöрöссöзлö ö äйтеб кюрсятеля, барысыннан да хокöм ителя. 25 Шулай анын кюнеленен жяшеренняре беленя, ул тюбян жыгылыб, Аллага башырыб äйтер: чыннаб сезнен белян Алла тора, диб.

Зач.157 26 Инде ней суң, туганнар? Сез жыйылышкан чакта, сезнен äр-кайсыгызнын псаломы бар, öйрятеуе бар, теле бар, таныткычлары бар, аннатыуы бар, былар барысы да арылыкта кютярелеў öчöн булсын. 27 Äгяр дя кем таныш тöгöл тел белян сöйлöй икян, икяў сöйлягез, жя кюб булса öчяў, тик чираттан, беряў шуны аннатсын. 28 Äгяр дя анатыучы булмаса, жыйында дяшмей тор, ўзеня дя, Аллага гна äйт. 29 Пагамбярляр дя икяў, жя öчяў сöйлясенняр, бютянняре уйлаб тикшерсенняр. 30 Äгяр дя утыра торганнардан беряўгя Алладан ачылыу булса, беренчесе дяшмей торсон. 31 Сез шу барыгыз да берегез артыннан берегез пагамбярлек итя аласыз, барыгыз да öйрянеб, барыгыз да тынычлык алыр öчöн. 32 Пагамбярлек итеуче тыннар да пагамбярлярне тынныйлар. 33 Алла шу кöйсöзлöк Алласы тöгöл, äммя татыулык Алласы, изгелярнен бар жыйыннарында да шулай була. 34 Катыннарыгыз жыйында дяшмей торсоннар, аларга сöйляргя рöксят ителмягян шул, äммя законъ äйткянчя, буйсыныб тороргa тейеш. 35 Äгяр аларнын нейгядер öйрняселяре кился, анын турын-

да өйләрендә ирләреннән сорасыннар, жыйында катында сөйләү килешле төгөл шул. 36 Әлля Алла сүзе сездән чыккан мы? Жя бер сезгә гня барыб житкән ме? 37 Әгәр дә кем үзен пагамбәр диб, жя тын кешесе диб санаса, ул мин сезгә неӣ жазганны аннасын, бу шул Ходаӣ бойороклары. 38 Әгәр кемдер аннамаса, аннамасын. 39 Шулаӣ, туганнар, пагамбәрлек итеү өчөн күнелегезне бирегез, алаӣ да төрлө телләр белән сөйләшеүне дә тыймагыз; 40 тик барысы да арыу төзөлгән, тәртибле булырга тейеш.

15-нче бүлем

1 Эй туганнар! Мин сезгә сөйлягән, сез кабыл алыб, нык ышаныб тора торган Евангеліене тагы исегезгә төшөрөб әйтәмен: 2 мин сезгә өйрәткәнне мин сөйлягәнчә тотсагыз, ышаныуыгыз бушка гна булмаса, шул изге хабәр арткылы сез котоласыз. 3 Мин башта үзем алганны сезгә дә сөйлядем, Жазыуда әйтелгәнчә, Христоснын безнен жазыклар өчөн үлгянен, 4 Анын кюмелгянен, Жазыуда әйтелгәнчә, өчөнчө көнөндә терелеб торганын, 5 терелеб торгач, Кифага, аннары ун ике апостолларга күренгянен, 6 тагы бер табкыр биш жөздән дә артык туганнарга күренгянен, аларнын күбесе әлегә чаклы исән көйө торганын, кайсыларынын үлгянен; 7 аннары Іаковка да, тагы шулаӣ бар апостолларга да күренгянен; 8 барыннан да суң мин жараусызга да күренгянен сөйлядем. 9 Мин апостоллар арасында иң кечесе, апостолъ диб аталырга да тормоймын, мин Аллага ышаныучыларнын жыйынын кыудым шул. 10 Алаӣ булса да, мин Алла дәүләте белән тора торганча торамын; Анын дәүләте миндә буш тормады, мин аларнын барысыннан да бигряк тырыштым; алаӣ да мыны мин үзем кылмадым, әммя Алланын миндәге дәүләте кылды. 11 Алаӣ булгач, без: мин дә, алар да шулаӣ сөйлөйбез, сез дә шулаӣ диб ышандыгыз.

Зач.159 12 Әгәр Христосъ турысында, Ул үлгяненнән терелеб торган, диб сөйләня икән, нейгә суң сезнен каӣ берләрегез үлгянняр терелеб тороу жук диб әйтәляр. 13 Үлгянняр терелеб тороу булмаса, алайса Христосъ та терелеб тормаган. 14 Әгәр Христ-

тосъ терелеб тормаса, ул чакта безнен сӧйляўебез дя бушка гна, сезнен ышаныуыгыз да бушка. 15 Шунын өстӧня, ӓгяр ўлгянняр терелеб тормаса, Ул Ўзе терелтеб торгозмаган Христосны терелтеб торгоздо, диб таныклаб сӧйляб, Алла турысында без жалган таныкчылар булыб чыгар ыйык; 16 ӓгяр ўлгянняр терелеб тормаса, алайса Христосъ та терелеб тормаган. 17 Ӓгяр Христосъ терелеб тормаса, сезнен ышаныуыгыз да бушка, сез ӓле жазыкларыгыз эчендя торасыз. 18 Шунӓр кюря Христоста ўлеўчеляр дя харяб булганнар. 19 Ӓгяр без бу тормошта гна Христоска ӧмӧт тотоб торсак, ул чакта без бар кешелярдян дя бахетсезряк.

Зач.160 20 Ӓммя Христосъ ўлгяннярдян беренче булыб ўлгяненнян терелеб торган. 21 Ничек ўлем кеше арткылы булган, шулай ўлгянняр терелеб тороуы да Кеше арткылы була. 22 Ничек Адамъ арткылы барысы да ўляляр, шулай Христосъ арткылы барысы да терелеб тороорлар. 23 Ӓр-кайсы ўз ряте белян: беренче Христосъ, аннары Ул килгян чагында Христосныкылар; 24 Ул Падшалыгын Алла Атага табшырыб, ӓр-тӧрлӧ башлыкларны, ӓр-бер кыуатларны, кӧчлярне бетергяч, алар артыннан бетеў булыр. 25 Анӓр шу бар дошманнарын аягы астына жыгыб салгынчы падшалык итяргя тейеш. 26 Сунгы дошман - ўлем бетерелер, 27 шунын өчӧн Алла барысын да Христоснын аяк астына эйектергян, Анӓр барысын да эйектергян диб ӓйткян чакта, шул билгеле, Анӓр барысын да Эйектереўчедян башкасы барысы да эйеккян. 28 Анӓр барысы да эйеккяч, ул чакта Ул Ўзе дя Анӓр барысын да Эйектереўчегя эйегер шул, барысында да барысы да Алла булсын диб шул.

Зач.161 29 Икенчеляй ӓйткяндя, ўлгянняр өчӧн чумылыучылар неӥ кылалар сун? Ӓгяр дя ўлгянняр бӧтӧнняӥ терелеб тормасалар, алайса нейгя ўлгянняр өчӧн чумылалар? 30 Неӥ өчӧн без дя сагат сайын читеннеккя туры килябез? 31 Мин кӧн дя сайын ўлямен: эӥ туганнар! Мыны мин Ходайыбыз Іисусъ Христоста сезнен мактауыгыз белян таныклыйым. 32 Кеше исябе белян ӓйтямен; мин Ефеста кейекляр белян кӧряшкян чакта, мина неӥдеӥ пайда, ӓгяр дя ўлгянняр

терелеб тормаса? Ашарга-эчяргя тотонойок, барыбер иртягя ўлясе! 33 Алданмагыз, начарларга катышыулар арыу гадятлярне бозоб бетеря. 34 Тейешенчя айныгыз, жазыкланмагыз, сезне оялтыр өчөн айтямен: сезнен кайберлярегез Алланы белмейляр шул. 35 Аммя кем булса да айтер: ўлгянняр ничек терелеб торорлар, нейдей тян белян килерляр, диб. 36 Эй уйсыз кеше! Син чячкян орлок ўлмяся, терелянмей бит. 37 Син чячкян чагында буласы тянне чячмейсең, ничек туры киля, бодай мы, бютян беряр төрлө орлок мы, жалангач ашлык бөртөгө чячясең. 38 Аммя Алла анар Ўзе телягянчя, ар-бер орлокка ўз тяне итеб, тян биря.

Зач.162 39 Тян бар да бер төрлө гня төгөл. Адям тяне бютянчя, тыуар тяне бютянчя, балыкныкы бютянчя, кошныкы тагы бютянчя. 40 Аннары кюктяге нястяляр бар, жирдяге нястяляр дя бар; кюктягелярнен эяме ўз алдына, жирдягелярнеке ўз алдына. 41 Кояш эяме ўзе башка, ай эяме ўзе башка, жондозларнын эяме тагы ўзе башка, жондозларнын да берсенен эяме берсенекеннян айырым. 42 Ўлгяннярнен терелеб тороуы да шулай: черей торганы чячеля, черемясе чыга; 43 кадерсезе чячеля, кадерлесе чыга; көчсөзе чячеля, көчлөсе чыга; 44 жан тяне чячеля, тын тяне чыга; жан тяне бар, тын тяне дя бар. 45 Книгядя: Элекеге кеше Адамъ тере жан булган, диб жазылганча, сунгы Адамъ терелтеўче тын булган. 46 Аммя алдан тынныкы төгөл, тик жанныкы, аннары тынныкы;

Зач.163 47 беренче кеше жирдян балчыктан булган, икенче Кеше - кюктян килгян Ходай. 48 Балчыктан булган ничек, балчыктан булдырылганнар да шулай, Кюктяге ничек, кюктягеляр дя шулай. 49 Ничек без балчыктан булдырылганнын ошашын ўзебезгя кейеб жөрдөк, Кюктягенен ошашын да кейеб жөрөрбез. 50 Алай да, туганнар, сезгя шуны айтямен: тян белян кан Алла Падшалыгына керя алмаслар, черей торган черемей торган жиргя керя алмас. 51 Сезгя жяшеренне айтямен: без барыбыз да ўлмябез, тик барыбыз да ўнгярербез. 52 Кинят кня, кюз ачыб жомгончы, сунгы быргы тауышында: быргы таушы булыр шул, шунда ўлгянняр черемей торган булыб терелеб торорлар, аммя без ўнгярербез; 53 бу черей тор-

ганга черемей торган булыб кейенеў, бу ўля торганга ўлмей торган булыб кейенеў тейеш шул. 54 Бу черей торган тян черемей торган булыб кейенгяч, аннары бу ўлемне тян ўлемсез булыб кейенгяч, ул чакта жазылган сюз жиреня килер; жинеў ўлемне жоткан (Исаія, 25,3), диб.

55 Эй ўлем! Кая синең угың? Эй тамук! Кая синең жинеўчяннеген? дей (Осія. 13,1). 56 Ўлемнен угы - жазык, жазыкнын кочё - законъ. 57 Ходайыбыз Іисусъ Христосъ арткылы безгя бюляк итеб жинеўлек биреўче Аллага тау итябез.

Зач.164 58 Шулай, минем сойёклё туганнарым, сез ныk, кузгалмый торган булыгыз, сезнен кызмятегез Ходай алдында бушка тёгёл икянне белеб, Ходай эшендя ăр-кайчан житешеўле булыгыз.

16-нчы бюлем

1 Изгелярга киряклене жыйган чакта, мин Галатъ жыйыннарында кушканча эшлягез. 2 Атнаның элекеге конёндя сезнен ăр-кайсыгыз ўз аленнян килгян айберне айырыб куйсын да, ўзендя сакласын, мин килгяч жыйыб жёрмяс ёчён. 3 Мин килгяч, сез кемне сайлаб алган - шуларны, сез биргян айберлярне итеб табшырыр ёчён жазыу белян Іерусалимгя жибяререм.

Зач.165 4 Ăгяр мина да анда барыу килешле булса, алар минем белян барырлар. 5 Мин Македоніяне узгач сезгя килермен, мин шу Македонія арткылы барамын; 6 ăлля сездя ăзряк торормын, жя сез мине мин барасы жиргя озатыб куяр ёчён сездя кышлармын да. 7 Мин шу сезнен белян казер узыб киткяндя гня кюрешясем килмей, ăммя, Ходай бойорса, сездя бер ауык тороpга ёмётём бар. 8 Мин Ефеста илленче кён бяйряменя чаклы булырмын; 9 минем ёчён зур, кинг ишек ачылган шул, карышы килеўчеляр дя кюб. 10 Ăгяр дя сезгя Тимофей кился, карагыз, ул сездя куркынычсыз жирдя булсын, ул да шу минем шикелле Ходай эшен эшляўче. 11 Шунар кюря аны беряў дя какмасын, ăммя ул мина килеў ёчён аны тынычлык белян озатыгыз, мин шу аны туганнар белян бергя котям. 12 Ăммя Апполосъ туган турында айткяндя, ул

туганнар белян сезгя китсен диб мин аны бик сораган ыйым, тик анын казер ич тя барасы килмяде, әммя жайлы багыт булгач, ул килер.

Зач.166 13 Уяу торогоз, ышаныуда нык булыгыз, жөрякле булыгыз, нык торогоз; 14 барын да сөйөүлек белян кылыгыз. 15 Эй туганнар! Сезгя бу турыда ютенямен; Ахаіа дигян жирдя башлаб денгя кергян Стефанъ жамагатын сез белясез; аларнын изгелярга кызмят итяргя адарынганнарын да белясез; 16 сез дя шундыйларны, әр-кемгя булышыучыны да, тырышыучыны да кадер итегез. 17 Стефаннын, Фортунатнын, Ахаикнын килеуеня мин сөйөндөм: сез жук чагында, сезнен урынга килеб, 18 алар минем жанымны да, сезнекен дя тынычландырдылар; алар кюклярне кадер итегез.

19 Сезне Асіядагы жыйыннар кюнелдян жаратыб торалар; Акила белян Прискилла жорттагы жыйыннары белян Ходай какына сезне бик кюнелдян жаратыб торалар. 20 Бар туганнар да сезне кюнелдян жаратыб торалар. Бер берегезне арыу уй белян ўбеб, кюнелдян жаратыб торогоз. 21 Мин, Павелъ, кюнелдян жаратыб тороуымны ўз кулым белян жазамын. 22 Кем дя кем Ходай Іисусъ Христосны сөймөй икян - анафема булсын, маран афа. 23 Ходай килер. Ходайыбыз Іисусъ Христоснын дяўляте сезнен белян булсын. 24 Сөйөүлегем дя Іисусъ Христоста барыгыз белян булсын. Аминь.

СВЯТЫЙ АПОСТОЛЪ ПАВЕЛНЫН КОРИНФЪ КЕШЕЛЯРЕНЯ ЖИБЯРГЯН ИКЕНЧЕ ЖАЗЫУЫ

1-нче бюлем

Зач.167 1 Павелъ, Алла ирке белян Іисусъ Христоснын апостолы, тагы Тимофей туган да, Коринфта булган Алланын чиркяўеня, бётён Ахаіа буйлаб бар изгелярга дя: 2 Атабыз Алладан, Ходай Іисусъ Христостан сезгя дяўлят белян тынычлык булсын. 3 Ходайыбыз Іисусъ Христоснын Атасы Алла даннаулы, Ул изгелек Атасы, ăр-бер тынычлыкнын Алласы, 4 ăр-бер кайгыбызда безне тынычландырыучы, без дя шулай Алла ўзебезне тынычландырган тынычлык белян тёрлё пошаманда тороучыларны тынычландырсын диб. 5 Бездя Христоснын азаблары кюбяйгян катле, Христосъ арткылы безнен тынычлыгыбыз да кюбяя шул. 6 Ăгяр без кайгырабыз икян, сезне тынычландырыу ёчён, коткарыу ёчён кайгырабыз, ул котолоу без тюзгян азаблар кюк азабларга тюзеб ўткяреў белян урнына житя. 7 Сезнен турда безнен ёмёт тотоуыбыз да ныk; тынычланабыз икян, безнен азабларыбызга, тынычланыуыбызга сезнен керешкянегезне белеб, сезне дя тынычландырыр ёчён, коткарыр ёчён тынычланабыз.

Зач.168 8 Эй туганнар, безнен Асіядя булган кайгыбызны сезгя белдермей калдырасыбыз килмей, без шу чамадан тыш, кёчтян тышкары ауырлыкка туры килдек, тере калырбыз диб тя ёмётёбез калмады; 9 ўз-ўзебезгя ёмёт тотмойчы, ăммя ўлгяннярне тергезеўче Аллага гна ёмёт тотоб, ўз-ўзебезне ўлемгя бирергя

диб äзерлядек; 10 Ул безне шунын катле жакын ӳлемнян коткарды, коткара да, Анӷар ӧмӧт тотканыбызга кюря, тагы да коткарыр. 11 Бу сезнен безнен ӧчӧн иткян телягегез буйынча, кюб кешелярнен жалбарыуы буйынча, безгя бирелгян котолоу ӧчӧн, безнен ӧчӧн кюбляр тау итсенняр диб булды.

Зач.169 12 Безнен мактануыбыз кюнелебез тазалыгына таныклык шул, без дӧньядя, бигряк тя сездя Аллага жараулы чын кюнел белян, шушы тян белемнеге белян тӧгӧл, ӓммя Алла дяӳляте белян жяшядек. 13 Безнен сезгя жазганыбыз бютян тӧгӧл, ӓммя сез укыган, жя анӷаган, шулай азакка чаклы анӷарсыз диб ӧмӧт тотканым, 14 Ходайыбыз Ісусъ Христоснын кӧнӧндя без сезнен ӧчӧн макталыу, шулай сез дя безнен ӧчӧн макталыу буласыны сез бер катле анӷадыгыз инде. 15 Шушындый ышаныч белян сез икенче табкыр тагы дяӳлят алсыннар диб, мин элегряк тя сезгя килергя, 16 аннары сезнен арткылы Македоніягя узыб китяргя, Македоніядян тагы сезгя кайтырга тяӳкяллягян эйем; аннары сез мине Іудеягя озатыб жибярер эйегез. 17 Шушындый тяӳкяллегем булганда, мин жиӷел уй белян гня жӧрӧр эйем микян? Жя уйлаган эшем тян сагышы белян гня жӧрӧӳ буламы? Былай минем эшем: эйе, эйе, жя жук, жук дейеӳ гня ме? 18 Алла ышанычлы, безнен сюзебез сезгя: эйе, жя: жук, булмады. 19 Безнен белян: минем белян дя, Силуанъ, Тимофей белян дя сездя сӧйлягян Алла Улы Ісусъ Христосъ: эйе, жя: жук, булмады; ӓммя Анда: эйе, булды. 20 Алланын бирмякче булган бар нястяляре дя Анда: эйе, Анда: аминь, безнен арткылы Алланы даннау ӧчӧн.

Зач.170 21 Безне сезнен белян Христоста ныгайтыучы, безне майлаучы Алла. 22 Ул безне билгеляб, безнен кюнелебезгя билгегя Ӳз Тынын бирде. 23 Алланы жаныма таныкка куйыб äйтямен: мин мынгынчы Коринфка сезне кызганганныктан килмядем; 24 без сезнен сӧйӧнӧчӧгӧзне гня арттырырга тырышабыз, ӓммя сезне ышандырырга иркебез бар диб уйламыйбыз, сез ышаныуда ныкторасыз шул.

2-нче бюлем

1 Мин ӳз кюнелемдя уйладым
да, сезгя тагы кайгы китермейем
диб, барасы итмядем. 2 Мин сез-
не кайгыландырсам, миннян кай-
гы кюргян кешедян бютян кем
суң мине сӧйӧндӧрӧр?

Зач.171 3 Мына мин сезгя
шуны жаздым да: баргач, мине
сӧйӧндӧрӧр кешелярем мине кай-
гыга тӧшӧрмясенняр дидем; ми-
нем сӧйӧнӧчӧм сезнен барыгызга
да сӧйӧнӧчтер диб, мин барыгызга
да ышаныб торамын. 4 Мин бик
кайгырганныктан, жӧря-гем жан-
ганныктан сезгя бик жылаб жаз-
дым, сезне кайгыртыр ӧчӧн тӧгӧл,
ӓммя минем сезне ничек кюб сӧй-
гянемне белсенняр диб. 5 Ӓгяр дя
кем кайгырткан икян, мине гня
кайгыртмый, кюб ӓйтелмясен,
сезнен барыгызны да бер катле
кайгырта. 6 Мындыйга кюбегез-
дян шушы кыйын булгач, житяр.
7 Сезгя андыйны кичереб, ты-
нычландырыу арыуырак булыр,
ул бик ӳтя кайгырыб бетеренмясен
диб. 8 Шунар кюря анар сӧйӧулек
кюрсятеуегезне соройом. 9 Сез бар
турдан да тынначан микян диб
чыннykта белер ӧчӧн, мин мыны
жаздым да. 10 Ӓгяр кемгя нястя
ӧчӧндер кичерясез икян, анар мин
дя кичерям; мин дя кемгя нястя
ӧчӧн кичерсям, анар Христосъ
исеменнян сезнен ӧчӧн кичерям, 11
сатана безгя зыян салмасын диб;
анын усаллык уйлары безгя билге-
сез тӧгӧл шул. 12 Троадага Христо-
съ турысында изге хабяр сӧйлярга
диб килгяч, Ходайдан мина ишек
тя ачык ыйы, 13 анда мин туганым
Титны таба алмагач, тыныма ты-
нычлык табмадым, шунныктан
алар белян кичерешеб, мин Маке-
доніяга киттем.

Зач.172 14 Ӓммя тау Алла-
га, Ул безгя Христоста ӓр чак
жинеӳлек сӧйӧнӧчӧн биря, Ӳзе
турында белеӳлекнен тямне исен
безнен арткылы бар жирдя дя та-
рата. 15 Без шу котолоучыларда
да, харяб булыучыларда да Алла-
га Христоснын тямне исе: 16 бер
тӧрлӧляр ӧчӧн ӳлем китеря торган
ӳлем исе, икенчеляр ӧчӧн терелеккя китеря торган терелек исе.
Кем шушынар булдыклы? 17 Без
шу кюбляр шикелле Алла сюзеня
зыян китермейбез, ӓммя Алладан
алган итеб, Алла алдында Христоста тороб, чын кюнелдян сӧй-
лӧйбез.

3-нче бюлем

1 Ӓлля инде безгя сезнен белян
тагы танышырга киряк ме? Ӓлля
инде безнен ӧчӧн, кайберяўлярга
киряк кюк, мактау жазыуы сез-
дян, жя бездян сезгя киряк ме? 2
Сез - безнен бар кешеляр дя укый
торган, таный торган, безнен
кюнелляребезгя жазылган жа-
зыуыбыз; 3 сез - ўзегезне Хрис-
тоснын жазыуы итеб кюрсятясез,
кара белян жазылган тӧгӧл, ӓммя
тере Алланын Тыны белян, таш
такталарга тӧгӧл, ӓммя кюнел-
лярнен тян такталарына безнен
сӧйляў кызмяте арткылы жазыл-
ганыгыз.

Зач.173 4 Безнен Христо-
съ арткылы Аллада шушын-
дый ышанычыбыз бар; 5 бу ўз-
ўзебездян бер-бер нястяне, аны
ўзебезнеке итеб уйларга булды-
клыгыбыз бардан тӧгӧл, безнен
шу булдыклыгыбыз Алладан. 6
Ул безгя Жаңа Законга кызмят
итеўчеляр булырга булдыклык
бирде, буква белян тӧгӧл, ӓммя
тын белян; буква белян кызмят
итеў ўлеляндеря шул, ӓммя тын
терелек биря. 7 Ӓгяр таш такта-
га жазылган, ўлем китеря тор-
ган букваларга кызмят итеў шул
катле данны булган икян, Мои-
сейнен жӧзӧндяге ўнгяря торган
данына Израиль уллары карый
да алмаганнар, 8 алай булгач, тын
белян кызмят итеў бигряк тя дан-
нырак булмас менеи? 9 Айыбла-
ныуга кызмят итеў дя алай данны
булгач, дӧрӧскя чыгарыуга кыз-
мят итеўнен даны бигряк тя кюб
булыр. 10 Кешенен артыннан киля
торган бютян даны бигряк тя оло
булганныктан, элекке даны дан-
ны булыб та саналмый. 11 Ӓгяр дя
узыб китя торганы данны икян,
узыб китмей торганы бигряк тя
даннырак шул.

Зач.174 12 Шушындый
ӧмӧтӧбез булганга кюря, без оло
кыйыулык белян кызмят итябез;
13 Израиль уллары узыб китя тор-
ганнын азагына карамасын ӧчӧн,
жӧзӧня бӧркяў каблаган Моисей
кюк тӧгӧл без. 14 Ӓммя аларнын
уйлары сукырайган, Иске За-
конны укыган чакта шул бӧркяў
казергя чаклы да ачылмаган кӧйӧ
кала, ул шу Христосъ белян гня
ачыла. 15 Казергя чаклы, алар
Моисей княгялярен укыган чак-
та, аларнын кюнелляpендя бӧркяў
жата; 16 ӓммя Ходайга боролоб

дяшкян чакта, бу бӧркяӳ ачыла. 17 Ходай шу Тын, кайда Ходай Тыны, анда иркеннек. 18 Без барыбыз да ачык жӧз белян кӧзгӧдяге шикелле Ходайнын данына караб, Анын даныннан дан алыб, Анын ошашына керя барабыз, Ходайнын Тыны безне кертя шул.

4-нче бюлем

Зач.175 1 Шунӷр кюря, Алла изгелеге буйынча мындый кызмятебез булгач, без монаймыйбыз. 2 Ӓммя жяшерен булган оят эшлярне кире кагыб, хайля белян тотонмойчы, Алланын сюзен дя ӳнгяртмейче, ӓммя чынныкны ачыб, Алла алдында ӓр-бер кешенен таза кюнеленя ӳзебезне кюрсятябез. 3 Ӓгяр безнен арыу хабяр сӧйляӳебез жабык икян, ул харяб булыучылар ӧчӧн, 4 ышанмый торганнар ӧчӧн гня жабык; кюренмей торган Алланын тӧсӧ булган Христоснын даны турысында арыу хабярнен жактысы жактырмас ӧчӧн, аларнын уйларын бу дӧньянен алласы сукырайткан. 5 Без шу ӳзебезне сӧйлямейбез, ӓммя Ходай Ісусъ Христосны сӧйлӧйбез, без Ісусъ ӧчӧн сезнен колларыгыз;

Зач.176 6 карангыдан жакты жактыртыучы Алла, Ісусъ Христосъ арткылы Алланын олологон аннаб жактырылсыннар диб, безнен кюнеллярне дя жактырты. 7 Бу байлыкны без балчык сауытларда жӧртябез, бездяге искитярлек оло кыуат безнеке тӧгӧл, ӓммя Алланыкы икяне кюренсен диб. 8 Безне тӧрлӧ жактан кыссалар да, без кысылмыйбыз; без читен ӓлдя булсак та, ӧмӧт ӧзмӧйбез; 9 без кыуылсак та, ташланылмаган; безне бетерергя тырышсалар да, без бетмейбез. 10 Тянебездя Ходай Ісуснын тормошо кюренсен диб, ӓр-бер чакта без тянебездя Ісуснын ӳлеӳен жӧртябез. 11 Безнен ӳлемне тянебездя Ісуснын тормошо кюренсен диб, без Ісусъ какына тере кӧйӧнчӧ туктаусыз ӳлемгя бирелябез; 12 шулай итеб, бездя ӳлем, ӓммя сездя терелек кылыб тора.

Зач.177 13 Алай да, мин ышандым, шунӷр кюря сӧйлядем, диб жазылганча, бер ышаныу тынышында тороб, без дя ышанабыз, ышаныуыбыз буйынча сӧйлӧйбез: 14 Ходай Ісусны Тергезеӳче Алла шул Ісусъ арткылы безне дя тергезер диб, аннары сезнен

белян бергя Ӱз алдына куяр диб белябез. 15 Бары да сезнен өчөн шул: дяӱлятнен кюб бирелгяннеге бик кюбляр Алла данналырга тау итсенняр эйе диб. 16 Шунар кюря монаймыйбыз, ягяр безнен тышкы кешелегебез черей икян, ямма эчке кешелегебез көннян-көн жанара киля. 17 Безнен бу кыска багытта жинел гня азабланыуыбыз безгя чамасыз, мулы белян мянге данналыуны язерлей шул; 18 без кюреня торганга төгөл, ямма кюренмей торганга карыйбыз, кюреня торганы багытлы гна шул, ямма кюренмей торганы мянге.

5-нче бюлем

Зач.178 1 Без шул белябез: безнен жирдяге шушы жарлы гна өйөбез жимерелгяч, безнен Алладан бирелгян кюктяге торор жиребез, кул белян жасалмаган мянге өйөбез бар. 2 Шунныктан кюктяге торор жиребезгя кейенясебез килеб, без ухылдыйбыз. 3 Тик без кейенеб тороучылар да жалангачлар булыб калмасак ыйы. 4 Без шу бу жарлы гна өйөбездя тора тороб, ауырлыклар астында ухылдыйбыз; безнен шул чишенясебез килмей, ямма ӱлемне тянебез тере тороулык белян ӱнгярсен диб, кейенясебез киля. 5 Шушынын өчөн Алла безне булдырган да, безгя Тынынын билгесен дя биргян. 6 Шулай безнен яр-чакта да жаныбыз сөйөня; шуны белябез: тянебез эчендя чагында без Ходайдан чиття торабыз; 7 без шул кюреӱ белян төгөл, ямма ышаныу белян жөрөйбез; 8 безнен жаныбыз сөйөня, тянебездян чыгыб, Ходайда урыннашыу арыуырак диб, шуны телейбез. 9 Шунар кюря керсяк тя, чыксак та, бар кюнелебез белян Анар жараулы булырга тырышабыз.

Зач.179 10 Безгя барыбызга да Христоснын хокөме карышысына килеб басасы шул, яр-беребез дя тянендя торган чакта ул ней кылган, жакшыны мы, жаманны мы, кылган эшеня карата теясене алыр өчөн. 11 Шулай Ходайдан куркыулыкны белеб, без кешелярга аннатабыз. Аллага без ачык, сезнен таза кюнеллярегезгя да без ачыктыр диб өмөт итям. 12 Ӱзебезне сезгя жанадан китереб кюрсятмейбез, ямма сезгя безнен белян мактанырга жай бирябез, кюнелляренда булган белян мактанмыйчы, жөзляре белян

гня мактана торганнарга äйтер сюзегез булыр öчöн. 13 Äгяр без акылдан жазган булыб кюренябез икян, бу Алла öчöн, äгяр жыуаш булабыз икян, бу сезнен öчöн. 14 Äгяр Беряў барысы öчöн дя ўлгян икян, алайса барысы да ўлгянняр, диб уйлаучыларны Христоснын сöйöўлеге чырмый да ала шул.

Зач.180 15 Тере тороучылар ўзляре öчöн тормойчы, äммя алар öчöн Ўлеўче, аннары терелеб Тороучы öчöн торсоннар диб, Христосъ барысы öчöн дя ўлгян. 16 Шунар кюря мыннан башлаб без тян жагыннан беряўне дя белмейбез, äгяр тян жагыннан Христосны белгян булсак, казер инде белмейбез. 17 Шулай кем Христоста, ул жанадан булдырылган, боронгосо узыб киткян, казер бар да жана. 18 Ўзе белян безне татыуландырыб, безгя татыуланыу кызмятен биреўче Iисусъ Христосъ арткылы бар да Алладан. 19 Алла, кешелярнен айыблы эшлярен айыбка санамыйчы, Христосъ арткылы Ўзе белян дöньяне татыуландырган, безгя дя татыланыу сюзен биргян. 20 Шулай без - Христосъ исеменнян жибярелгянняр, Алла Ўзе безнен арткылы öндягян кюк, Христосъ исеменнян сорыйбыз: Алла белян татыуланыгыз. 21 Ул шу жазыкны белмягян Улын безнен öчöн жазыкка корман иткян, без Анын белян Алла алдында дöрöскя чыгарылыу öчöн.

6-нчы бюлем

Зач.181 1 Без, булышыучыларыгыз кюк булыб, сезгя ўтенябез, Алла дяўлятен сез бушка гна алмаган булсагыз ыйы. 2 Äйтелгян шул: Арыу багытта Мин сине эшеттем, котолоу кöнöндя синa булыштым (Исаія. 49, 8), диб. Мына инде арыу багыт, мына инде котолоу кöнö. 3 Без беряўгя дя, бер турдан да кумачаулык итмейбез, кызмят итеўебезне жаманнаб сöйляшмясенняр эйе диб; 4 бар турыдан да ўзебезне Алла кызмятчеляре кюк итеб кюрсятябез: кюб тюземнектя, кайгыда, нужалыкта, читен халлярдя, 5 кыйналыуда, öтöрмяндя, кыуылыуда, тырышыуда, тöннö теляктя ўткяреўдя, уразаларда, 6 тазалыкта, жакшы уйда, оло сöйöўлектя, изгелектя, арыу Тында, чын кюнелдян сöйöўлектя, 7 чынны сöйляўдя, Алла кы-

уатында, уң кулда да, сул кулда да дөрөслөк коралын тотоб, 8 кадерлектя, кадерсезлектя, жаманнауда, макталыуда тороуыбыз белян кюрсятябез; безне алдаучыга саныйлар, әммя без дөрөсляр; 9 без билгеле булмасак та, безне таныйлар; безне ўлгянгя саныйлар, әммя без тере; безне азаблыйлар, әммя без ўлмейбез; 10 безне көйөкляндеряляр, без жалан сөйөнябез; без жарлы, әммя кюбесен байытабыз; безнен бер нястябез дя жук, алай да барысы да безнен кулда.

Зач.182 11 Эй Коринфь кешеляре! Безнен ауызларыбыз сезгя ачык, кюнелебез дя кинг ачылган; 12 сезгя безнен арада кысан төгөл, әммя сезгя кюнеллярегездя кысан. 13 Балаларга әйткян кюк әйтямен, мина да шулай кайтарыгыз, сез дя ачык булыгыз. 14 Ышанмый торганнар белян чит камытка башыгызны тыкмагыз; гаделлек белян законсызлыкнын нейдей катышыулыгы бар? Жактылык белян карангылык ничек бергя була алсын? 15 Христосъ белян Велиаръ арасында нейдей кюнешеўлек булсын? Ышанычы кеше ышанмый торган белян ничек катышыб жөрсөн? 16 Алла чиркяўе белян сыннар жөртө ничек бер урында булсын? Алла әйткянчя: Аларда урыннашырмын, аларда жөрөрмен, аларнын Алласы булырмын, алар да Минем калкым булыр, дигянчя сез тере Алланын өйө буласыз шул. 17 Ходай әйтя: Алар арасыннан чыгыб, алардан айырылыгыз, шакшыга тейенмягез, аннары Мин сезне кабыл алырмын, дей. 18 Булганнарны тотоучы Ходай тагы әйтя: Сезгя Ата булырмын, сез дя Минем уларым, кызларым булырсыз, дей.

7-нче бюлем

Зач.183 1 Алай булгач, эй сөйөклөлярем, шушындый багадялярга өмөт тотоб, Алладан куркыныб тороб, арыулык кылыб, ўзебезне тян белян тыннын әртөрлө шакшылыгыннан әрчейек. 2 Безне кюнеллярегезгя кертегез: без бер кемне дя кимсетмядек, бер кемгя дя зыян салмадык, бер кемнян дя пайда эзлямядек. 3 Айыблар өчөн әйтмейем, мин элек тя әйткян эйем, бергяляб ўляр өчөн дя, жяшяр өчөн дя сез безнен кюнеллябездя, диб. 4 Мин сезгя

кюб ӧмӧт тотам, сезнен белян кюб мактанам, мин тынычлыкка да тулыландым, кӧӄӧнӧчӧбез булыб та, мул сӧӄӧнӧчтя торамын. 5 Без Македоніягя килгяч, тянебез бер нейдеӄ дя тынычлык табмады, тыш жактан безгя бяӄлянеӳчелярдян, эчебездян - куркыулык белян без тӧрлӧ жактан кысылдык. 6 Ӓммя жыуашларны тынычландырыучы Алла Титнын килеб житеӳе белян безне тынычландырды; 7 бер анын килеб житеӳе белян гня тӧгӧл, ӓммя ул: сезнен ничек кюнел биреӳегезне, жылауыгызны, сезнен минем турда жалан уӄлауыгызны безгя сӧӄляде, шулаӄ анын сезнен турда тынычланыуы белян без дя тынычландык, шуны эшетеб мин ӓле бигряк тя сӧӄӧндӧм. 8 Шунныктан ӓгяр мин жибяргян жазыуларым белян сезне кӧӄӧндӧргянемя ӳкенгянем икян, казер ӳкенмейем, мин шул кюрям: жибяргян жазыуым сезне кӧӄӧндӧргян икян, бу бер багытка гна. 9 Казер минем сӧӄӧнӧӳем сезне кӧӄӧндӧргян ӧчӧн тӧгӧл, ӓ мя сезнен кӧӄӧнӧӳегез тяӳбягя килер ӧчӧн булганга, сез шу Алла какына кӧӄӧндӧгӧз, шулаӄ итеб бездян бер нейдеӄ зыян да кюрмядегез.

Зач.184 10 Алла какына кӧӄӧнӧӳ ӳнгярмейче котолоу ӧчӧн тяӳбягя китеря шул, ӓммя дӧнья ӧчӧн кӧӄӧнӧӳ ӳлем китеря. 11 Тагы шуны карагыз: Алла какына кӧӄӧнӧӳ сезгя ничек тырышыулык китергян, нейдеӄ ӳкенеӳлек, айыбларга ничек жаратмыӄчы карау, нейдеӄ куркыулык, киряксенеӳ, жалан кюнелдян уӄлау, айыбынны эзляӳ китергян; бу эштя бар турдан да сез ӳзегезне таза итеб кюрсяттегез. 12 Шулаӄ, ӓгяр мин сезгя жазганым икян, бу кимсетеӳче ӧчӧн, жя кимсетелгян кеше ӧчӧн тӧгӧл, ӓммя безнен Алла алдында сезнен ӧчӧн нейдеӄ сагышыбыз бар икяне сезгя ачылсын диб жаздым. 13 Шунныктан сезнен тынычланыуыгыз белян без дя тынычландык. Тагы сез Титнын тынын тынычландырганыгызга кюря, анын сӧӄӧнӧчӧ белян без бигряк тя сӧӄӧндӧк; 14 шулаӄ мин анын алдында неӄ беляндер сезнен турда мактаныб оятлы булыб калмадым, ӓммя ничек без барыбыз да сезгя чынныкны ӓйткянчя, шулаӄ Титъ алдында да мактаныуыбыз чын булыб чыкты; 15 сез ничек аны куркыб, калтраб карышы алгансыз, шу-

ларны, сезнен барыгызнын да тынӈаучан икянегезне исеня төшӧрӧб, анын кюнӈеле сезне бик жакын итя. 16 Шулай бар турдан да сезгя ышаныб тора алганыма сӧйӧнямен.

8-нче бюлем

Зач.185 1 Эй туганнар! Македонія чиркяўляреня бирелгян Алланын дяўляте турысында сезгя белдерябез: 2 алар шу кайгыларга оло сыналыулар эчендя дя сӧйӧнӧчкя мул торалар, тирян жарлылык белян дя кече кюнӈеллелек байлыгына мул торалар. 3 Алар шу кӧчляреня кюря дя, кӧчтян тышкары да киряксенеб эшлейляр, мынӈар мин таныкчы. 4 Алар изгелярга кызмят итеў ӧлӧшӧня кереў ӧчӧн ўзляреннян бюляк алыуны бездян бик тырышыб сорадылар; 5 тик без ӧмӧт иткянне гня дя тӧгӧл, ӓммя алар элек Ходайга, аннары Алла ирке белян безгя ўз-ўзлярен дя бирделяр; 6 шунӈар кюря без Титны сорадык та, ул ничек сездя бу арыу эшне башлаган, шулай ук бетерсен дя, диб.

Зач.186 7 Ничек сез ышануда, сюздя, белеўлектя, кюнӈел биреўлектя, сезнен безгя сӧйӧўлегегездя мул торасыз, шулай бу арыу эштя дя мул булыгыз. 8 Мыны кушыб ӓйтеўем тӧгӧл, ӓммя бютяннярнен кюнӈелдян тырышыуы белян сезнен сӧйӧўлегегезнен дя чынныгын сыныймын. 9 Сез Ходайыбыз Іисусъ Христоснын дяўлятен белясез шул: Ул ничек бай була тороб, Анын жарлылыгы белян сез байысын диб, Ул шу сезнен ӧ ӧн жарлыланган. 10 Мыны кыла гна башлау тӧгӧл, ӓммя аны узган жылдан бирле ўк кыласыгыз килеб жӧрӧўчелярга мин киняш бирямен, ул шул сезгя пайдалы: 11 казер бу эшнен ўзен кылыб житкезегез, ўзегез бик кыласыгыз килгянне казер ӓлегез кушканча тулысы белян кылыб житкезегез. 12 Ӓгяр кюнӈелдян тырышыу булса, ул кемнен нястясе булганына караб кылына, ӓммя булмаганына караб тӧгӧл. 13 Бютяннярга жинӈеллек булыб, сезгя ауырлык булыу киряк тӧгӧл, ӓммя тигезлек булсын. 14 Казер сезнен мул булыуыгыз аларнын житмяслеген тутырыр ӧчӧн, тигезлек булыр ӧчӧн, аннары аларнын

муллыгы сезнен житмяслегегезне тутырыр өчөн булыр. 15 Жазылган шул: Кем кюб жыйган, анын артыгы булмаган, кем әз жыйган, житмей калмаган, диб.

Зач.187 16 Титнын кюнеленя сезнен өчөн шулай кюнелдян тырышыулык салган Аллага тау итямен; 17 аннан мин дя сораган ыйым, алай да, ул кюнелдян тырышыулыгы буйынча, үзе сезгя иреклей китте. 18 Без анын белян арыу хабяр сөйляүдя бөтөн чиркяүлярга мактаулы булган, 19 шунын өстөня, жакшылык кылыу өчөн чиркяүлярдян безнен белян жөрөргя сайлаб алган туганны жулдаш итеб жибярдек, бу эшкя сезнен кюнелдян тырышыуыгыз буйынча, Ходайнын Узенен даны өчөн без кызмят итябез; 20 безнен кызмятебезгя шушындый кюб китерелгян нястяляр ышаныб бирелгяннектян, беряў-беряў безнен турда начар уй уйламасын диб тя сакланабыз. 21 Безнен шул арыу булырга тырышыуыбыз бер Ходай алдында гна төгөл, әммя кешеляр алдында да. 22 Без алар белян бергя кюнел биреүлеген кюб табкыр, кюб турдан сынаб караган туганыбызны да жибярдек, ул казер дя сезгя зур ышанычы буйынча, бигряк тя кюнелен бирде. 23 Титъ турында әйткяндя, ул - минем иптяш, сездя бергя кызмят итеүче; туганнар турында әйткяндя, былар чиркяүлярдян жибярелгянняр, Христоснын даны. 24 Шулай чиркяүляр алдында үзегезнен сөйөүлегегезне аларга кюрсятеб бирегез, аннары безнен сезнен белян мактаныуыбыз дөрөс икянне дя кюрсятегез.

9-нчы бюлем

1 Алай да минем өчөнгя изгелярга булышыу турында сезгя жазыу артыгырак, 2 мин бит сезнен кюнелдян тырышканыгызны белям, Ахаія узган жылдан бирле үк әзер диб, Македонія кешеляре алдында сезнен белян мактанам да; сезнен кюнелдян тырышыуыгыз кюб кешелярне бюляклягян дим. 3-4 Минем сезнен белян мактаныуым бу турда бушка калмасын, әммя сез мин әйткянчя әзерлянеб торсоннар диб, минем белян Македонія кешеляре килгяндя сезне әзер төгөл көйө очоратыб, сез диб әйтмейем,

без оятка калмас өчөн, шундый ышанычлык белян мактандык бит, туганнарны мин шунын өчөн жибярдем дя. 5 Шунар кюря туганнарны сезгя алданырак барыб, кастярлей тороргa диб сорауны кирякле диб санадым да, алар сезнен алдан äйткян бахиллегегезне äзерлей торсоннар дидем. Сезнен ул бахиллек булсын шул, äммя ирексезляб алыу булмасын.

Зач.188 6 Шунын өстөня äйтямен: саран чячкяннен урыб алырына да аз, жумарт чячкяннен урыб алырына да кюб. 7 Äркайсыг кюнелен тартканча бир, äммя рянжеб, ирексез гня бирмя; Алла кюнелдян биреучене сöя шул. 8 Алла сезне äр-төрлö дяуляте белян байытырга кыуатлы; сезнен äр-чакта, äр-нейгя бар турыда да житешлегегез булыб, äр-төрлö жакшы эшкя бай булсагыз ыйы диб. 9 Жазылган шул: Малын жарлыларга öляшеб тараткан, анын дöрöслöгö гумердян гумергя тора, диб. 10 Ячеучегя орлок Биреуче, ашарга икмяк Биреуче сез чячкянне ундырыр, дöрöслöгöгöзнен жимешен ürчетер, 11 сезне бары белян дя äр-төрлö жумартлыкка байытыр өчөн шул жумартлык безнен арткылы Аллага тау иттеря шул;

Зач.189 12 бу кызмят итеу эше изгелярнен жуклыкларын гна тутырыб калмый, äммя кюбесендя мул итеб Аллага тау итеуне китеря. 13 Шушы кызмятнен эшен кюреб, алар сез таныклый торган Христоснын Евангелиесеня буйсынганыгызны кюреб, алар белян дя, барысы белян дя чын кюнелдян катышканыгыз өчөн Алланы данныйлар. 14 Сезнен өчөн теляк итеб, Алланын дяуляте сездя бик мулы белян булганга кюря, сезне бик жакын итяляр. 15 Алланын äйтеб бетергесез бюляге өчөн Анар тау итямен!

10-нчы бюлем

1 Мин - Павелъ, ўзем сезнен арагызда жыуаш, äммя кюз артында сезгя карышы батыр, сабырлык белян, Христосъ какына жагымнылык белян сезне димнейем. 2 Безнен турда: алар тянгя киряклечя гня кыйланалар, диб уйлаучы кайберяўлярга кулланырга уйлаган нык кыйыулыкны мин килеу белян кюрсятергя

тотоноргa туры килмясен диб сездян соройом. 3 Без шу тянгя кейенеб жӧрсяк тя, тян буйынча кӧряшмейбез. 4 Безнен жинешеўебезнен кораллары тян ӧчӧн тӧгӧл, ӓммя ныгытылган жирлярне жимереў ӧчӧн Алла белян кӧчлӧ; корган киняшлярне, 5 тагы Алланы белеўлеккя карышы кютярелгян олосомаклыкларны алар белян жимереб тӧшӧрябез, Христосны тынначылыкка ӓрбер кюнеллярне тотконга алабыз. 6 Сезнен тынначылыгыгыз урнына житкяч, ӓр-бер тынначысызлыкны туктатырга без ӓзер.

Зач.190 7 Кешенен кемнегеня карыйсыз мы? Кем ӱзен Христосныкы диб ышаныб тора икян, ул ӱзе буйынча тикшерсен, ул ничек Христосныкы, шулай без дя Христосныкы. 8 Сезне таратырга тӧгӧл, ӓммя торгозорга Ходай мина биргян кыуат белян мин бигряк тя мактанасы итсям дя, оятлы булыб калмас ыйым. 9 Алай да, мин тик жибяргян жазыуларым белян гня сезне куркыткан булыб кюренмясен. 10 Шулай беряў ӓйтя икян: Жибяргян жазыуларында ул каты да, кӧчлӧ дя, ӓммя ӱзе килеб сӧйляшкяндя жомошак, сӧйляшеўе дя искитярлек тӧгӧл диб. 11 Андый кеше белсен: без сюзляребездя, жибяргян жазыуларыбызда кюз артында ничек, ӱзебез эшебез белян дя шулай. 12 Ӱз-ӱзлярен кюрсятергя тырыша торганнар белян ӱз-ӱзебезне тинняштереб, алар белян чагыштырырга без кыйыучылык итмейбез шул, алар ӱзляре белян ӱзлярен ӱлчейляр, уйсызланыб ӱзляре белян ӱзлярен чагыштыралар. 13 Ӓммя без чамасыз мактанмабыз, ӓммя сезгя барыб житяр ӧчӧн Алла безгя билгелягян ӧлӧш катле мактанырбыз. 14 Без шул сезгя барыб житмягян кюк ӱзебезне кӧчяндермейбез, без инде Христоснын арыу хабярен сӧйляб сезгя дя барыб життек; 15 без чамасыз мактанмыйбыз, кеше кызмяте белян тӧгӧл, ӓммя сезнен ышаныуыгыз кюбяйгян сайын, сездя ӱзебезнен ӧлӧшнӧ дя кюбяйтербез диб, 16 шулай тагы сездян дя арырак Евангеліе сӧйлярга диб, ӓммя чит кешенен ӓзер ӧлӧшӧ белян мактанырга тӧгӧл диб ӧмӧт тотабыз. 17 Мактаныучы Ходай белян мактансын. Кем ӱзен мактый, ул жараулы тӧгӧл шул, ӓммя кемне Ходай мактый, шул жараулы.

11-нче бюлем

Зач.191 1 Эй сез, бер ауык булса да, минем уйсызлыгыма жомошагырак булсагыз ыйы, сез мина жомошаклык кылыгыз да. 2 Мин дя сезнен турда Алла какындагы кönняшеў белян кönняшямен, мин шу сезне Христоска таза кыз кюк итеб китерер öчön бер гня иргя жяряштем. 3 Ämмя куркам: жылан хайля белян Еваны алдаган кюк, Христоска туры кюнелле булыудан ауышыб, сезнен уйларыгыз бозокланыб китмясен дим. 4 Ägяр кемдер килеб, без сöйлямягян бютян Iисусны сöйлягян булса, жя сез алмаган бютян тынны алган булсагыз, жя сез кабыл алмаган бютян сöйляўне алган булсагыз, сез анар бик жомошак булыр ыйыгыз.

Зач.192 5 Ämмя мин уйлыйым: жугарыгы апостоллар карышысында минем бер житмяс жирем дя жук; 6 мин сюземдя жомошак булсам да, белемнегем тулы. Алай да без сезгя бар турдан да бötönняй билгелеляр. 7 Мин сездя Алланын Евангелiесен бушлай сöйляб, шулай сезне кютярер öчön ўземне тюбян төшöрöўем белян жазыкландым микян? 8 Сезгя кызмят итяр öчön бютян жыйыннардан тормошка киряклене алыб, аларга сагыш жасадым, сездя булганда житмяслеккя тюзсям дя, беряўне дя жödятмядем; 9 минем житмяслегемне Македониядян килгян туганнар тутырыб житкезделяр, мин бар турдан да сезгя жök булмаска тырыштым, тагы да тырышырмын. 10 Миндяге Христоснын чынныгы белян äйтямен: минем бу макталыуым Ахаiя жакларында да миннян алынмас. 11 Ник мин былай кыйланамын? Сезне сöймягяннектян ме? Аллага билгеле! 12 Алар ней белян мактаналар, мактаныуларында безнен кюк кюренясе килеб, бу жай эзляўчелярга жай бирмяс öчön мин ничек кыйланам, тагы да шулай кыйланырмын да. 13 Мындыйлар шул жалган апостоллар, алдандырыу кылыучылар, алар Христоснын апостолларынын кюренешен ўзляреня алганнар. 14 Бу искиткеч төгöл, сатана ўзе дя жакты пяриштянен кюренешен ўзеня ала; 15 шунар кюря ägяр анын кызмятчеляре дöрöслök

кызмятчеляренен кюренешен алалар икян, бу зур эш тӧгӧл, ӓммя аларнын азагы эшляреня карата булыр. 16 Тагы ӓйтям: кем булса да мине акылсызга санамасын, ӓгяр алай саный икян, мина мактаныр ӧчӧн, акылсыз диб булса да, мине кабыл алыгыз. 17 Ней ӓйтсям дя, Ходайдан ӓйтеуем тӧгӧл, ӓммя мындый мактаныуга батырлангач, акылсызлыктан ӓйткян кюк, 18 ничек кюбесе тян белян мактаналар икян, алайса мин дя мактанырмын. 19 Сез шул акыллы кешеляр, акылсызларга да иреклей тюзясез; 20 кемдер сезне кол ится дя, сезнекен ашаб бетерся дя, сезнекен алса да, сездян ӱзен ӧскя кютярся дя, кемдер сезнен битегезгя сукса да, сез тюзясез.

Зач.193 21 Оят булса да ӓйтямен: мындыйга безнен кӧчӧбез житмяде, беряӱ-беряӱ бербер эшен ӓйтеб мактанасы булса, мин дя, акылсызлыктан ӓйтямен, мактана алырмын диб. 22 Алар еврейляр булса, мин дя шулай; израильляр булса, мин дя шулай, Авраамъ няселе булса, мин дя шулай. 23 Алар Христосъ кызмятчеляре икян, акылсызлыктан ӓйтямен: мин артыгырак; мин алардан кюб табкыр артык читеннектя тордом, чамасыз жараландым, кюб табкыр ӧтӧрмяндя булдым, ӓлля ничя табкыр ӱлгяннян калдым. 24 Іудейляр мине кырыктан бер гня ким сугыб, биш табкыр кыйнадылар; 25 ӧч табкыр мине таяк белян кыйнадылар, бер табкыр ташлар атыб кыйнадылар, мин утырыб барган кимя ӧч табкыр уатылыб батты, мин тӧннӧ, кӧннӧ дингез тӧбӧндя ӱткярдем; 26 кюб табкыр жулда жӧрдӧм, иделляр ӧстӧндяге куркынычларны кюрдем, талаучылардан куркыб жӧрдӧм, няселдяшляремнян, жалган деннелярдян, кала эчлярендя, буш кырларда, дингездя, жалган туганнарым арасында кюб куркынычлар кюрдем; 27 ауыр эшляр эшляб кӧчлярем бетте, онгайук тӧннӧ жокламыйчы уздырдым, онгай ачыктым, сыусадым, онгай ураза тоттом, сыуыкка тундым, жалангач жӧрдӧм. 28 Тагы шушы ӓйтелгян кумачаулардан тыш, мина кӧн сайын кешеляр кюб-кюб жыйылды, бар жыйыннар ӧчӧн дя сагышланыб тордом. 29 Кайгырыб ӓлсезлянеӱченен кайсына мин кызганыб кайгырышмадым? Кызыгыб жангышыучынын кайсысы ӧчӧн мин кӧйӧнмядем? 30

Алай да мактанасы булсам, ӓлсезлегемне ӓйтеб кня мактанырмын.

Зач.194 31 Ходайыбыз Иисусъ Христоснын Атасы, мянге даннаулы Алла, мин жалганнамаганны белядер. 32 Арефа падшанын Дамаскъ тирясен тотоучы тюрясе, мине тотторасы итеб, Дамаскъ каласын карауыллатты; мине тяряздян тубалга утыртыб, кала коймасыннан тӧшӧрделяр, шулай итеб мин анын кулыннан котолдом.

12-нче бюлем

1 Мактаныу мина пайдалы тӧгӧл, жугыйса мин Ходай кюрсяткянне, кюргянняремне ӓйтясе итярмен. 2 Мин Христосъ какында бер кешене белямен; анар инде ун дюрт жыл; ул кеше тян белян ме, ӓлля тяннян башка мы, анысын белмейем, Алла беля; ул кеше кюкнен ӧчӧнчӧ катына алынды. 3 Ул кеше турысында белеӱен белямен, ӓммя тяне белян ме, тяннян башка мы, анысын белмейем, Алла беля; 4 тик ул жомакка алыныб, анда ӓйтеб житкезер хал жук сюзляр эшетте, ул сюзлярне кешегя ӓйтеб биря алырлык тӧгӧл. 5 Шундый кешене ӓйтеб мактана алырмын, ӓммя ӱзем белян мактанмам; белмейем, ӓлсезлегемне ӓйтеб мактансам гна. 6 Алай да, мактанасы итсям, акылсыз булмам, чынны ӓйтермен шул; тик мин, беряӱ-беряӱ минем турда миндя кюргяненнян, миннян эшеткяненнян артыгырак уйламасын диб, тыйылыб торам. 7 Кюргян чамасыз оло эшлярем белян олосомакланмас ӧчӧн, минем тянемя мине интектерергя ук кадалган, шайтан кызмятчесе бирелгян, мин олосомакланмасын диб. 8 Мин Ходайга аны миннян кыуыб жибяр диб ӧч табкыр инялдем. 9 Ӓммя Ходай мина ӓйтте: Минем синең ӧчӧн дяӱлятем житярлек, Минем кыуатым ӓлсезлектя кюренядер шул, диб. Шунар кюря мин, миндя Христоснын кыуаты торсон ыйы диб, ӱземнен ӓлсезлегем белян мактаныуны бигряк тя жаратырмын.

Зач.195 10 Шушынын буйынча мин ӓлсезлегемдя дя, кимсетелеӱемдя дя, жарлылыкта да, кыуылыуда да, Христосъ ӧчӧн кысанныкларда да кюнелем сӧйӧ-

ня, мин шу ӓлсез чакта кӧчлӧ. 11 Мактана торгач, мин акылсызланыб киттем, сез мине мынӑр ирексезлядегез, мине мактарга сезгя киряк эйе, минем бит жугары апостоллар карышында, мин жук кна нястя булсам да, бер житмягян жирем дя жук. 12Апостоллыгымнын билгесе сезнен алда, тӧрлӧчя тюзеӱляр белян, билгеляр белян, кодрятляр, кыуатлар белян булды. 13 Бютян жыйыннар карышында сезнен нейдей житмягян жирегез бардыр, белмейем: ӱзем сезгя жӧк булыб тормаганым булса гна, бу айыбымны минӑ кичерегез. 14 Мин ӧчӧнчӧ табкыр сезгя барырга ӓзер, алай да мин сезгя ауырлык китермям. Мин шу сезнекен эзлямейем, ӓммя сезне эзлейем. Ата-ана ӧчӧн кирякле ӓйберне балалар жыярга тейеш тӧгӧл, ӓммя ата-ана балалар ӧчӧн жыярга тейеш. 15 Мин ӱз ӓйберемне иреклей тотармын, сезнен жаннарыгыз ӧчӧн ӱземне дя кызганмам, мин сезне бик артык сӧйӧӱгя карамастан, сезнен мине сӧйӧӱегез кюб тӧгӧл. 16 Ӓйтейек: мин ӱзем сезгя ауырлык китермягянем, ӓммя хайляляб, начарлык белян сезне алганым; 17 алайса сезгя жибяргяннярнен беряресе арткылы мин сезнен бербер ӓйберегез белян пайдаландым мы сун? 18 Мин Титтан ӱтенеб, анын белян туганнарнын берсен жибярдем: Титъ сезнен беряр нястягездян пайдаланды мы сун? Без бер тын белян эшлямядек меней? Бер ӱк жулдан жӧрмядек меней? 19 Сез тагы, без сезнен алда гна ӱзебезне дӧрӧслӧйбез, диб уйламыйсыз микян? Без Христоста тороб Алла алдында ӓйтябез, бу бар да, сӧйӧклӧлярем, сезне ӧйрятер ӧчӧн.

Зач.196 20 Мин шу сезгя килгяч, мин телямягянчя сезне очоратмыйым тагы диб куркамын, шулай сезгя дя мине сез телямягянчя очоратыу киряк тӧгӧл. Сездя айырылышыулар, кюремсезлек, ачыучаннык, ызгышыулар, ӓлякляӱляр, жаманныклар, олосомаклыклар, тяртибсезлекляр очоратмасам ыйы; 21 килгяч, Аллам мине сездя кимсетмясен эйе дим, элек жазыкланыб та, шакшылыкта, азгынныкта, шулай элек кылган жарамаган эшляре ӧчӧн тяӱбягя килмягянняре какында аларнын кюбесе ӧчӧн жыларга туры килмясен эйе дим.

13-нче бюлем

1 Инде сезгя өчөнчө табкыр
барамын, ике жя өч таныкчынын
ауызындагы äр бер сюз ныкбулыр. 2 Мин алдан äйттем, тагы да
сездя торган кюк икенче табкыр
äйтямен: казер сездян чиття тороб, элек жазыкланганнарга да,
бютяннярга дя барысына да жазамын: тагы килгяч, кызганмам.

Зач.197 3 Миндя Христосъ
сӧйӧӧй микян диб, сез таныклаб
кюрсятеўне эзлейсез, сезнен өчөн
Ул кыуатсыз төгөл, äммя сезнен
эчтя кыуатлы. 4 Ул älсезлектя
качка кадакланган булса да, äммя
Алла кыуаты белян тере, без дя
Анда älсез булсак та, äммя Алла
кыуаты арткылы, Анын белян
сезнен эчегездя тере булырбыз.
5 Ӱз-ӱзегезне сынагыз, сез ышаныуда мы? Ӱз-ӱзегезне тикшереб
карагыз. Älля Iисусъ Христосъ сезнен эчегездя икянне, ӱзӱзегезне белмейсез ме? Сез неӥдей булырга тейешле булсагыз,
шундый төгөл менеӥ? 6 Без ничек
булырга тейешле, шулаӥ икянебезне белерсез диб өмөт тотам. 7
Сез ничек булырга тейешле, безгя шулаӥ кюренер өчөн бер неӥдей дя усаллык кылмасагыз ыӥы
диб Алладан телейбез. Äммя без
ничек булырга тейешле, шулаӥ
кюреня алмасак та, сез жакшылык кылсагыз ыӥы. 8 Без шул
чынныкка карышы көчлө төгөл,
äммя чыннык жагыннан көчлө. 9
Без älсез булыб, äммя сез көчлө
чакта сӧӥӧнябез, шул какта, сезнен житеўле булыуыгыз какында
без теляк итябез дя. 10 Шушынын өчөн дя мин ӱзем жук чакта
мыны жазамын да, ӱзем килгяч,
Ходаӥымнын мина жимерер өчөн
төгөл, äммя торгозор өчөн биргян
кыуаты белян сезгя каты булмаска диб. 11 Алаӥ да, эӥ туганнар,
сӧӥӧнөгөз, житеўле булыгыз,
тынычланыгыз, бер кюнелдя булыгыз, татыу торогоз, сӧӥӧўлек,
татыулык Алласы сезнен белян
булсын. 12 Бер-берегезне изгелек
белян ӱбеб, кюнелдян жаратыб
торогоз. Бар изгеляр дя сезне
кюнелдян жаратыб торалар. 13
Ходаӥыбыз Iисусъ Христоснын
дяӱляте, Алла Атанын сӧӥӧўлеге, Святыӥ Тыннын аралашыуы
сезнен барыгыз белян дя булсын.
Аминь.

СВЯТЫЙ АПОСТОЛЪ ПАВЕЛНЫН ГАЛАТЪ КЕШЕЛЯРЕНЯ ЖИБЯРГЯН ЖАЗЫУЫ

1-нче бюлем

Зач.198 1 Кешелярдян дя, кешеляр арткылы да сайланган тӧгӧл, ӓммя Іисусъ Христостан, Аны ӱлгяненнян тергезеб торгозган Атабыз Алладан апостолъ итеб сайланган Павелдан, 2 тагы минем белян бергя булган туганнарнын барысыннан - Галаттагы жыйыннарга:

Зач.199 3 Атабыз Алладан, Ходайыбыз Іисусъ Христостан сезгя дяӱлят тя, тынычлык, татыулык та булсын. 4 Ул Атабыз Алланын ирке буйынча, казерге усал гумердян безне коткарыр ӧчӧн Ӱзен Ӱзе безнен жазыкларыбыз ӧчӧн биргян. 5 Анар дан булсын гумердян гумергя. Аминь. 6 Христоснын дяӱляте белян сезне чакырыб алыучыдан бютян тӧрлӧ сӧйляӱгя сез ничек тиз ауышыб киткянегезгя исем китя. 7 Алай да ул бютян дя тӧгӧл, ӓммя сезне тынычсызландырыучы, тагы Христоснын арыу хабярен унгяртясе килеӱче кешеляр бар. 8 Ӓммя ӓгяр жя без, жя кюктян пяриштя сезгя без сӧйлямягянне сӧйлӧй башласа, анафема булсын. 9 Ничек без элек ӓйттек, шулай казер тагы да ӓйтямен: сез кабыл алмаганны, бютянне кем гня сӧйляся дя, анафема булсын. 10 Мин кешелярдян ризалык эзлейем ме, ӓлля Алладан мы? Кешелярга жараулы булырга тырышам мы? Ӓгяр мынар катле кешелярга жараргa тырышсам, мин Христоснын мяндясе дя булмас ыйым.

Зач.200 11 Эй туганнар! Мин сӧйлягян Евангеліе кеше чыгарган Евангеліе тӧгӧл икянен сезгя билгеле итямен: 12 мин аны кешедян алмадым, анар кешедян ӧйрянмядем, ӓммя мина аны Іисусъ Христосъ Ӱзе кюренеб бирде. 13 Минем элек іудей денендя торган чагымдагы тормо-

шомны, Алла жыйынын каты кысканымны, аны бөлдөргянемне сез эшеткянсез. 14 Іудей денендя торган чагында, мин аталарымнан äйтелеб калганны чамадан тышкары тырышыб кылыуым белян ўз затыбыздагы иптяшляремнен кюбесеннян арттырганны да эшеткянсез. 15 Анам эченнянўк мине сайлаучы, Ўз дяўляте белян мина дяшеўче Алла 16 миндя Ўз Улын кюрсятясе иткян, мин Аны жалган деннелярга сöйлясен диб, ул чакта мин тян белян, кан белян киняшляб тормадым, 17 Іерусалимдяге миннян алдан апостолъ булганнарга бармыйчы, Аравіягя киттем, аннан тагы Дамаскка кайттым. 18 Аннары öч жылдан суң Іерусалимгя Петръ белян кюрешергя бардым, баргач, анда ун биш кöнняб тордом. 19 Тик Ходай туганы Іаковтан башка бютян апостолларнын берсен дя кюрмядем. 20 Мин сезгя быларны Алла алдында жазам, жалганнамыйым. 21 Мыннан суң мин Сирія белян Киликія жакларына чыгыб киттем. 22 Іудеядяге Христоснын жыйыннарына мин ўзем билгеле булмадым. 23 Тик алар: бер багытны аларны кыуыучы, башта ўзе бетерергя жöрöўче казер ышанынын арыу хабярен сöйляб жöрöй икян диб эшеткянняр дя, 24 минем öчöн Алланы даннаганнар.

2-нче бюлем

1 Аннары ун дюрт жылдан суң Варнава белян, ўзем белян Титны да алыб, мин тагы Іерусалимгя бардым. 2 Мина ачылыу булган буйынча бардым да, анда айырата билгеле апостолларга ўземнен жат калыкларга сöйлягян арыу хабярне билгеле иттем. Мин бушка гна тырышмыйым микян, жя тырышмадым микян дидем. 3 Ämмя алар минем белян булган Титны да ул еллин булса да, киселергя кыстамадылар. 4 Ämмя Іисусъ Христоста булган безнен иркенегебезне кюзятеб, ўзляреня буйсындырырга диб, жяшереneб кня килгян жалган туганнарга 5 без бер сагаткя дя жул куймадык, арыу хабярнен чынныгы сездя саклансын диб, без аларга баш эймядек.

Зач.201 6 Ней беляндер айырата билгелеляр дя - алар кайчандыр ничек кня булсалар да, минем öчöнгя бер нейдей дя айырмасы жук, Алла кешенен жöзöня карамый - билгелеляр дя мина

бютян бер неӥ дя öстямяделяр. 7 Äле киресенчя, Петрга киселгянняр öчöн бирелгян кюк, миӈа киселмягянняргя арыу хабяр сöӥляргя бирелгянне кюреб, 8 Петрга апостоллыкта киселгяннярдя булышкан Святый Тын, миӈа да жат калыкларда булышты; 9 миӈа бирелгян дяўлят турысында белеб, баганалар диб санала торган Іаковъ та, Кифа да, Іоаннъ да миӈа да, Варнавага да бер кюнелдя булыу билгесеня кул бирделяр, безгя жат калыкларга, äммя аларга киселгянняргя барыу öчöн, 10 без жарлыларны истя тотар öчöн; ул эшне мин тöгяллек белян кылыб житкезергя тырыштым.

Зач.202 11 Петръ Антіохіягя килгяч, ул сюзгя килергя туры килгянгя кюря, мин ўзем анар карышы чыктым. 12 Ул шу Іаковтан кайберяўляр килеб житкенче, жат калыклар белян бергя ашады, алар килеб житкяч, киселгянняр алдында сакланыб, алардан чигеня башлаб, эшен жяшеря башлады. 13 Анын белян бергя бютян іудейляр дя шулаӥ жумаладылар, алар кюк жумаларга Варнава да ауышкан ыйы. 14 Шунда мин, алар туры кюнелдян Евангеліе чынныгы буйынча кылмаганны кюргяч, барысынын да алдында Петрга äйттем: äгяр син іудеӥ булыб та, іудейчя тормойчы, жат калыклар кюк торасын икян, нейгя сун жат калыкларны іудейляр кюк тороргa кушасын? дидем. 15 Без элеке булмыштан іудейляр, äммя жат калыклардан жазыклылар тöгöл;

Зач.203 16 кеше законъ буйынча кылыныуы белян дöрöслянмягянне, äммя Іисусъ Христоска ышаныуы белян гня дöрöслянгянне белгяч, без дя Христосъ Іисуска ышандык, Христоска ышаныу белян дöрöслянер öчöн, äммя законъ буйынча кылыныу белян тöгöл, законъ буйынча кылыныу белян ич-бер тян дя дöрöслянмяс шул. 17 Христоста дöрöслянеўне эзляб, ўзебез жазыклы булыб кюренсяк, Христосъ жазыкка кызмят итеўче була менеӥ? Жук, булмыӥ! 18 Ўзем уатканны ўзем жанадан торгозсам, мин ўземне ўзем айыблы итям ич. 19 Мин законъ арткылы законъ öчöн ўлдем, Алла öчöн торойом диб. Мин Христосъ белян кадакланылдым, 20 инде мин тормойом, äммя миндя Христосъ

тора, казер тянемдя торам икян, торсам, мине сӧйӧўче, минем ӧчӧн Ӱз жанын биреўче Алла Улына ышаныб торамын.

Зач.204 21 Алланын дяўлятен кире какмыйым, ӓгяр законъ белян дӧрӧскя чыгарылыу булса, Христоснын ўлеўе дя бушка.

3-нче бюлем

1 Эй уйсыз Галатъ кешеляре! Чынныкка буйсынмаска сезне кем алдандырды, Іисусъ Христоснын тӧсӧ сездя кадакланган шикелле кюз алдыгызда кюрсятелгяннярне? 2 Сездян шуны гна белясем киля: сез законъ эшляре буйынча алдыгыз мы Святый Тынны, ӓлля ышаныуга ӧйрятеў буйынча мы? 3 Сез шулай уйсызлар менеӣ, тын белян башлаб, казер тян белян бетерясез менеӣ? 4 Сез шул катле кюбкя тюздегез, ӓлля былар пайдасыз булыр мы? Эй, пайдасыз булмасын ыйы! 5 Сезгя Тынны Биреўче, сезнен арада кодрятляр Кылыучы законъ эшляре арткылы мыны кыла мы сун, ӓлля ышаныуга ӧйрятеў арткылы мы? 6 Шулай, Авраамъ Аллага ышанган, бу анӓр гаделлек булыб саналган. 7 Ышаныучылар Авраамъ уллары икянне аннагыз инде.

Зач.205 8 Изге Жазыу да, Алла жат калыкларны ышаныу арткылы дӧрӧскя чыгарганны алдан кюреб, Авраамга алдан билгерткян: Бар калыклар да синдя бахиллянерляр, диб. 9 Шулай ышаныучылар ышанган Авраамъ белян бахиллекне бергя алырлар. 10 Ӓммя законъ эшляре белян ныгытылыучылар барысы да каргаулык астында булалар, жазылган шул: законъ княгясендя неӣ жазылган, барсын да жалан кылыб тормаган ӓр-кем каргаулы, диб. 11 Ӓммя законъ белян беряў дя Алла алдында дӧрӧслянмягяне билгеле, гадел кеше ышаныу белян тере торор шул. 12 Ӓммя законъ ышаныудан тӧгӧл, тик кем аны кылыб тора, ул анын белян тере торор.

Зач.206 13 Христосъ безнен ӧчӧн кагарне Ӱз ӧстӧня алыб, законъ куйган кагардян безне жолоб алган, жазылган шул: агачта эленеб торган ӓр-кем кагарляўле, диб; 14 бу - Авраамга булган бахиллек Іисусъ Христосъ арткылы жат калыкларга да таралыр ӧчӧн, безгя бирмякче булган

Тынны ышаныу арткылы алыр өчөн шул.

Зач.207 15 Эй туганнар! Кеше тикшереў исябе буйынча айтямен: кеше ныгытыб айтеб калдырганны да беряў дя ўнгяртмей, анар остямей дя. 16 Аммя Авраамга да, аннан тыуганга да бирмякче булыулык бирелгян; айтелмягян бит тыумаларына да диб кюблек турында, аммя беряў турында айтелгян; “синнян тыуганга да” диб, бу Христосъ Ўзе. 17 Мин шуны айтям: башта Алла беркеткян Христосъ турысындагы бойорокно 430 жыл узган-нан суң килгян законъ ўнгяртмей, бирмякче булыулыкнын кочөн бетеўле итмей. 18 Агяр законъ буйынча атасынын айберсе кала икян, бу биремен дейгян буйынча тогөл, аммя Авраамга Алла биремен дейгяне буйынча биргян. 19 Законъ ней өчөн сун? Ул усаллыклар булганга кюря сунъннан, Авраам няселеннян Тыуасы килеб житкенче бирелгян, бирмякче булыу да Анар туры киля; тик законъ пярищтяляр арткылы уртада тороучынын кулы белян бирелгян; 20 аммя уртада тороучы беряў жагында гна булмый, аммя Алла бер. 21 Шулай Алланын багадяселя законъ карышы мы? Ич тя жук! Агяр дя законъ тере тота торган итеб бирелгян булса, чын гаделлек тя законнан булыр ыйы; 22 аммя ышаныучыларга бирмякче булыу Iисусъ Христоска ышаныу какында бирелсен өчөн, Изге Жазыу барысын да жазык астына биклягян.

Зач.208 23 Аммя ышаныу килеб житкенче без законъ саклауы астында биклянгян эйек, ышаныу ачыласы багытка чаклы. 24 Шулай, без ышаныу белян дөрөскя чыгар өчөн законъ безне балаларны житяклягян кюк, Христоска таба житякляб барыучы булган; 25 ышаныу килгяч, без инде житякляўченен житякляўе белян тогөл. 26 Сез шул барыгыз да ышаныу белян Христосъ Iисусъ какына Алла уллары; 27 сез барыгыз да Христосъ какына диб чумылганыгыз, Христосъ кыуатын кейенгянегез. 28 Казер инде иудей дя, жат калык та жук, кол да, иркендяге дя жук, ир заты да, катын заты да жук, аммя Iисусъ Христосъ какына сез барыгыз да бер. 29 Агяр дя сез Христосныкылар икян, алайса сез Авраамъ тыумалары, бирмякче булганны алырга тороучылар.

4-нче бюлем

1 Тагы айтейем: атасы урнына каласы малайы бала чагында барысына да эя булса да, колдан бер ней белян дя айырылмый; 2 ул атасыннан куйган багытка чаклы жортно караучыларга, ўзен караучыларга буйсыныб тора. 3 Шулай без дя балалар булыб торган чагында, дөньянен айберляреня кызмят иттек;

Зач.209 4 аммя багыт тулылыгы килгяч, Алла Ўзенен Бер гня тыуган Улын жибяргян, Ул кыздан тыуган, законга баш салыб торган, 5 законга баш салыб тороучыларны жолар өчөн, безне Ўз уллары итяр өчөн. 6 Сез уллары булганга кюря, Алла сезнен кюнелляpегезгя: эй Авва, Атей, диб дяшя торган Ўз Улынын Тынын жибяргян. 7 Шунар кюря син инде кол төгөл, аммя улы, улы булгач, Іисусъ Христосъ арткылы синең Алла дяўлятендя өлөшөң бар.

Зач.210 8 Аммя ул чакта Алланы белмейче сез кюб аллаларга кызмят иттегез, тик алар чынында аллалар төгөл. 9 Аммя казер Алланы белеб, тагы да бигряк, Алладан белеўлек алыб, нейгя суң ялсез жарлы айберляpнен башларына кабат кайтасыз, ўзегезне тагы аларга кызмяткя бирясегез киля. 10 Көннярне, айларны, багытларны, жылларны тикшереб торасыз. 11 Сезнен өчөн куркамын, мин сездя жукка гна кызмят итмядем микян дим. 12 Эй туганнар! Сездян сорайом: минем кюк булыгыз, мин дя бит сезнен кюк. Бер ней белян дя сез мине кимсетмядегез; 13 белясез ич: мин беренче табкыр ялсез тянем белян гня сезгя изге хабяр сөйлясям дя, 14 сез минем тянемнен сыналыуларына карамадыгыз, алардан жирянмядегез, аммя мине Алла пяриштясе кюк итеб, Христосъ Іисусъ кюк итеб кабыл алдыгыз. 15 Сез ничек бахетле эйегез! Сезнен турда таныклык итямен, ягяр бу эш була торган булса, сез кюзлярегезне сыуырыб алыб миня бирер эйегез. 16 Шулай ялля инде сезгя чынны айтеб, сезгя дошман булдым мы икян? 17 Сезнен өчөн көнняшеўляре таза төгөл, сез алар өчөн көнняшеб торсоннар диб, сезне айырасылары киля. 18 Мин сезгя килеб торганда гна төгөл, аммя яр-кайчан да арыулык өчөн көнняшеў жакшы. 19 Эй балаларым! Сездя

Христоснын ошашы кюренгенче, мин тагы сезне тыудырыу сызланыуында. 20 Казер мин сездя булыб, тауышымны ӱнтяртясем киля, мин шу сезнен турда анӈаб бетеря алмыйым. 21 Сез, законъ астында буласыгыз килеӱчеляр, äйтегез äле, älля сез законны тыннамыйсыз мы? 22 Жазылган шул: Авраамнын ике улы булган, берсе кол катыныннан, икенчесе иркендяге катыныннан, диб. 23 Ämмя кол катыныннан булганы тян жагыннан тыуган, иркендяге катыныннан булганы, анысы биремен дейеӱлек буйынча тыуган. 24 Мында ошаш китереб äйтеӱ бар, бу ике законъ: берсе Синай тауыннан коллокка тыудырыучы, бу Агарь; 25 Агарь шул Аравіядяге Синай тауын билгертя, бу казерге Іерусалимгя туры киля, ул шу ӱз оланнары белян коллокта тора; 26 ämмя кюктяге Іерусалимъ иркендя, ул безнен барыбызнын да анасы. 27 Жазылган шул: Жимешсез, тыудырмый торган катын, сӧйӧн; тыудырыу белян сызланмаган катын сӧйӧнӧб, дяшеб тауыш бир; ире булган катынга караганда, калдырылганнын оланнары бигряк тя кюбряк, диб.

Зач.211 28 Без, эй туганнар, биремен дейеӱлек буйынча Исаакъ жагыннан тыуган оланнар шул. 29 Ämмя ничек ул чакта тян жагыннан тыуганы тын жагыннан тыуганны кимсеткян, казер дя шулай. 30 Изге Жазыу ней äйтя сун? Кол катынны да, анын улын да кыуыб чыгар, кол катыннын улы иркендягенен улы белян бергя атасы урнына калмас, дей. 31 Шулай, туганнар, без колноко тӧгӧл, ämмя иркендягенен оланнары.

5-нче бюлем

1 Шулай иркеннектя торогоз, аны безгя Христосъ бюляк итеб биргян, тагы кабат коллокнон кул астына ӱзегезне тӧшӧрмягез. 2 Мына мин, Павелъ, сезгя äйтямен: ägяр сез киселеӱ жоласын кылсагыз, Христостан сезгя бер пайда да булмас. 3 Тагы киселеӱ жоласы кылынган äр-бер кешегя таныклаб äйтям, ул законны тулы итеб тотарга тейеш. 4 Сез, ӱзегезне законъ белян дӧрӧсляӱчеляр, Христостан киттегез дя дяӱлятян тӧшӧб калдыгыз; 5 ämмя без тын белян кӧтябез, ышаныу арткылы дӧрӧскя чыгарылырбыз диб ӧмӧт итябез. 6 Іисусъ Христоста киселеӱнен дя, киселмягян-

нен дя бер кӧчӧ да жук шул, ӓммя сӧйӧӳлек белян эшлей торган ышаныу кыуатлы. 7 Сез жакшы барадыр ыйыгыз; сез чыннык-ка буйсынмасын диб кем сезне туктатты? 8 Мындыйга димняӳ сезне Чакырыучыдан тӧгӧл. 9 Ӓз гня ӓчеткеч апара бӧтӧн камырны ӓчетя. 10 Мин Ходай какына сезгя ышанамын, сез инде бютянчя уйламассыз диб; ӓммя сезнен кюнелегезне болгатыучы, ул кем булса да, айыбланыуны ӧстӧня кютярер.

Зач.212 11 Эй туганнар, ӓгяр мин казер дя: киселергя киряк, диб сӧйляб жӧрсям, алайса нейгя суң мине кыуыб жӧртяляр? Ул чакта Качнын кызыктырыуы беткян! 12 Эй сезне болгатыучылар арагыздан алынсыннар ыйы! 13 Сез, эй туганнар, иркеннекя чакырыб алынган, тик сезнен иркеннегегез тянгя жараулыны кыларга жай китерер ӧчӧн булмасын, ӓммя бер-берегезгя сӧйӧӳлек белян кызмят итегез. 14 Бӧтӧн законъ бер сюзгя сыйыб беткян шул: Жакынынны ӳзенне сӧйгян кюк сӧй, диб. 15 Ӓгяр бер-берегезне кимерясез, ашыйсыз икян, сакланыгыз, бер-берегездян харяб булмагыз тагы. 16 Минем ӓйтеӳем: тын буйынча кыйланыгыз, ул чакта сез тян киряксенгянне эшлямяссез; 17 тян тынга карышы эшне киряксеня шул, ӓммя тын тянгя карышыны телей, алар бер-берсеня карышы киляляр; шулай сез дя ней киряксенясез, аны кылмыйсыз. 18 Ӓгяр сез тын ӧйряткянчя жӧрӧйсез икян, алайса сез законъ астында тӧгӧл. 19 Тян эшляре билгеле, алар: уйнашлык итеӳ, азгыннык, шакшылык, жараусызлык, 20 сынга табыныу, бозгочолок, дошманнык, ызгышыулар, кӧнчӧлӧк, жарсыулык, талашыулар, тӧрлӧчя тартышыулар, алданыулар, бозоб ӧйрятеӳляр, 21 кюремсезлек, ӳтереӳ, эчкечелек, тагы шунар ошашлы тяртибсезлекляр. Сезгя алдан ӓйтямен, элек тя ӓйткян эйем: былай кыйланыучылар Алла Падшалыгына керя алмыйлар.

Зач.213 22 Тын эшляре былар: сӧйӧӳлек, сӧйӧнӧч, татыулык, озак тюземнек, арыулык, изге кюнеллелек, ышаныу, 23 сабырлык, тыйнаклык. Мындыйлар ӧчӧн законъ да жук. 24 Ӓммя кем Христосныкылар, алар тяннярен няпесляре белян, киряксенеӳляре белян бергя Качка кадаклаганнар. 25 Ӓгяр без тын буйынча жяшейбез икян, тын буйынча кыйланырга да тейеш.

26 Бушка мактанырга тырышмыйык, бер-беребезне жарсытмыйык, бер-беребезгя кончолок итмейек.

6-нчы бюлем

1 Эй туганнар! Агяр кеше беряр торло жазыкка жыгылса, сез тындагылар, сыналыуга туры килмяс очон, ар-кайсын узенне чамалаб, жыуашлык тыны белян андыйны тозятегез.

Зач.214 2 Бер-беребезнен жогон кютярешегез, шулай итеб сез Христоснын законын кылыучылар булырсыз. 3 Агяр кем узе бер нястя дя тогол койо, узен кемдер диб саный икян, ул узен узе алдандырыучы. 4 Ар-кем узенен эшен сынаб карасын, ул чакта да бютян кешедян тогол, уз эченда гня мактаулы булыр; 5 ар-кем уз кютярямен алыб барыр шул. 6 Сюз белян арыуга ойрятеуче булса, ар-бер арыу нястянне ойрятеучен белян бюлеш. 7 Алданмагыз: Алла кимсетеля алмый; кеше ней чячся, шуны урыр; 8 уз тяненя чячеуче тяненнян черей торганны урыб алыр, тынга чячеуче тыннан мянге тормош урыб алыр. 9 Жакшы эш кыла тороб, монаймыйык, агяр алсезлянмясяк, уз багытында урыб алырбыз. 10 Шулай, багыт бар чакта бар кешелярга дя, бигряк тя уз денебездягеляргя жакшылык кылыйык. 11 Мин сезгя уз кулым белян ничек кюб жазганны сез кюрясез. 12 Тяняре белян мактанасы килеучеляр узляре Христоснын качы очон кысаннык кюрмяс очон гня сезне киселергя иректезлейляр; 13 ул киселеучеляр узляре дя законны тотмойлар ич, тик сезнен тянегез белян мактаныр очон гня сезне киселдертяселяре киля. 14 Аммя минем мактанасым килмей, мактансам, Ходайыбыз Исусъ Христоснын качы белян гня мактанырмын, ул качта минем очон донья, мин дя донья очон кадакланылган. 15 Исусъ Христосъ алдында киселеу дя, киселмгяннек тя бер нястягя тормой, Анар тик кешенен жанарыуы гна кирякле. 16 Шушы рят белян тороучыларга да, тагы шулай Алланын Израиленя дя тынычлык, изгелек булсын. 17 Алай да мина беряу дя ауырлык остямясен, мин тянемдя Ходай Исуснын жаралярын жортям шул. 18 Эй туганнар! Ходайыбыз Исусъ Христоснын дяуляте сезнен тынигыз белян булсын. Аминь.

СВЯТЫЙ АПОСТОЛЪ ПАВЕЛНЫН ЕФЕСЪ КЕШЕЛЯРЕНЯ ЖИБЯРГЯН ЖАЗЫУЫ

1-нче бюлем

Зач.216 1 Алла ирке белян Іисусъ Христоснын апостолы Павелдан Ефеста тороучы Іисусъ Христоска турылыклы изгеляргя; 2 Атабыз Алладан да, Ходайыбыз Іисусъ Христостан да сезгя дяўлят, тынычлык булсын. 3 Ходайыбыз Іисусъ Христоснын Атасы Алла даннаулы, Ул кюктя безне Іисусъ Христосъ какына Тыннын ăр-тӧрлӧ бахиллеге белян бахилляўче; 4 Ул безне Христосъ арткылы дӧнья булдырылыудан элек сайлаган, без Анын алдында сӧйӧўлектя изгеляр, бозолоусызлар булсыннар диб. 5 Ўзенен арыу ризалыгы буйынча, Іисусъ Христосъ арткылы безне Ўзеня уллыкка алырга алдан билгеляб, 6 Ўзенен дяўлятенен данын мактадырыр ӧчӧн Ул безне сӧйӧклӧ Улында дяўлятляндергян;

Зач.217 7 Алла дяўлятенен байлыгы белян жазыкларыбызны кичереб, Христоснын Каны белян безне жолоб алган; 8 дяўлятне Ул ăр-тӧрлӧ белемнектя, аннауда безгя мулы белян биргян; 9 Ўзенен ризалыгы буйынча, Христоста электянюк куйган Ўз иркенен жяшереген безгя ачкан; 10 кюктягелярне дя, жирдягелярне дя, барысын да Христоска эйектереб, бергя кушылдырыр ӧчӧн багытларнын тулылыгын куйган. 11-12 Барын да булдырыб Житкезеўченен Ўз ризалыгы белян безне алдан билгелягяне буйынча, без Христоска алданук ӧмӧт тоучылар, Анын даны макталыуга кызмят итяр ӧчӧн, Христосъ арткылы бирелясене алырга тороучылар булыб куйылдык. 13 Анда сез дя, сез котолоу ӧчӧн сӧйлягян

чыннык сюзен эшетеб, Христоска ышаныу арткылы, бирмякче булган Святый Тын белян Христоста пичятлянгян; 14 Христосъ ӧлӧшӧ булганнарны жолоб алыр ӧчӧн, Анын даны макталыр ӧчӧн Святый Тын безгя теясе ӧлӧшнӧн бездя тороучы билгесе.

Зач.218 15 Шунар кюря мин дя, сезнен Христосъ Іисуска ышанганыгызны да, бар изгелярга сӧйӧулегегезне дя эшетеб, 16 сезне телякремдя иска алыб, сезнен ӧчӧн туктаусыз Аллага тау итямен; 17 Ходайыбыз Іисусъ Христоснын Алласы даннаулы Ата сезгя Аны белер ӧчӧн белемнек Тыны, ачылыу Тыны бирсен эйе: 18-19 Анын чакыруынын ӧмӧтӧ нейдян торганны, изгеляр ӧчӧн Аннан теясе даннаулы ӧлӧшнӧн байлыгы ничек икянен, Анын тотоб тора торган кыуатынын без ышаныучыларда эшляб тороуы буйынча Анын кыуатынын ололого ничек чамасыз икянен сез белер ӧчӧн сезнен кюнел кюзлярегезне жактыртсын ыйы. 20 Шул кыуатын Ул Христоста кюрсятеб, Аны ӳлгяненнян тергезеб торгозоб, кюктя Ӳзенен н жагыннан утырткан. 21 Христосъ ӓр-бер Начальства, Власти, Силы, Господства диб атала торган пяриштяляр рятляреннян дя, бу гумердя гня тӧгӧл, ӓммя буласы гумердя дя атала торган, исемняня торган ӓр-бер исемнян дя жугарырак;

Зач.219 22 барысын да Анын аяк астына буйсындырган, барысыннан да жугары итеб, арыу жыйыннын Башы итеб куйган; 23 арыу жыйын - Анын Тяне, бар турдан да, барысын да тутырыб Житкезеӳченен тулыб житеӳе.

2-нче бюлем

1 Сезне дя, жаман эшлярегез, жазыкларыгыз буйынча ӳле булганнарны, 2 бу дӧньянен гадяте буйынча, ауада башлык булыб тороучы князнен, казер карышыу уллары арткылы эшляӳче тыннын ирке буйынча бер багытны сез жазыкларда жяшягяннярне, 3 шулар арасында без барыбыз да бер багытны ӳзебезнен тян няпесляребез буйынча, тян киряксенгянне, уйлаганыбызны кылыб житкезеб жяшягяннярне, булмышыбыздан бютянняр шикелле ачыу оланнары булганнарны,

Зач.220 4 изгелеккя бай Алла, безне сөйгян оло сөйөүлеге буйынча, 5 без жазык сябябеннян ўлгяннярне Христосъ белян бергя тереляндергян, сезне дяўляте белян коткарган; 6 безне Іисусъ Христосъ белян бергя терелтеб торгозган да Анын арткылы кюкляр өстөня утырткан; 7 шунын белян килясе гумерлярдя безгя Іисусъ Христоснын изгелеге какында бирясе чамасыз оло дяўлятенен байлыгын кюрсятер өчөн. 8 Сез инде ышаныуыгыз буйынча дяўлят арткылы котолган, бу котолоу ўзегездян тögöл, ăммя Алла бюляге; 9 беряў дя мактанмасын диб, ул котолоу эшлярга караб бирелмягян. 10 Без Анын булдырганнары, Ул безне Іисусъ Христосъ какына жакшы эшляр кыларга булдырган, ул эшлярне кыларга Алла безгя ăўяледян билгелягян. 11 Шулай сезнен исегездядер, бер багытны кул белян кылынган тян киселеўен кылганныктан киселгянняр диб атала торганнар, сезне тян жагыннан жат калыклар булганныктан, киселмягянняр диб атыйлар ыйы; 12 ул чакта сез Христоссыз ыйыгыз, Израиль жыйыныннан чиття эйегез, Алланын бирмякче булган бойороггоннан да чиття эйегез, өмөтögöз дя жук ыйы, дöньядя алласызлар ыйыгыз. 13 Ăммя казер сез Христосъ Іисуста, бер багытны жыракта булганнар, Христоснын Каны белян жакыннар булдыгыз.

Зач.221 14 Ул шу безне татыуландырыучы Христосъ, іудейляр белян жалган деннелярне бергя куйыб, алар арасында тора торган койманы жимергян; 15 дошманныкны Ўз тяненен азабы белян бетергян, иске бойорокляр законын Ўз öйрятеўе белян алмаштырган, шулай итеб, татыулык жасар өчөн, Ўзендя икедян бер жаңа кеше булдырган, 16 икесен бер тяндя итеб, Кач арткылы Алла белян татыуландырыр өчөн, анар кадакланыуы белян дошманныкны бетергян; 17 Ул килеб, сезгя, жыractагыларга да, жакындагыларга да татыулык сöйлягян; 18 шунар кюря тегеляр дя, булар да Анын арткылы гна, бер Тында тороб кна, Атага жакыннаша алабыз.

Зач.222 19 Алай булгач, сез инде жат тögöл, читтян килгянняр дя тögöл, ăммя изгелярнен каладашлары, Алланын ўзенекеляре. 20 Іисусъ Христосъ Ўзе почмак астына таш булыб, анын öстöня

апостоллар белян пагамбярляр корган нигезгя сез дя беркетеўле. 21 Шул нигез өстөндя бөтөн жорт төзөк салына килеб, Ходайда арыу өй булыб ўсядер; 22 анын өстөндя сез дя Святый Тын кыуаты белян Алла торордый урын ителясез.

3-нче бюлем

1 Шунар кюря дя мин, Павелъ, сезнен хакта Іисусъ Христоснын быгауда тороучысы булдым. 2 Сез инде эшеткянчя, мина сезнен өчөн Алла дяўлятенен жорт торгозоуы бирелгян. 3 Мина ачылыу арткылы жяшерек билгеле булды, анын турында жугарыда мин кыскача гна жазган да ыйым. 4 Христоснын жяшереген минем анлауымны сез укыб тикшеря аласыз. 5 Бу ädям улларынын элеке быуыннарына билгелянмягян, ämмя Святый Тын белян казер Анын апостолларына да, пагамбярлярга дя ачылган: 6 бер тян булыб төзөлөб, изге хабяр сөйляў арткылы Іисусъ Христоста Алланын бирмякче булганынын өлөшөня жат калыклар да керешсенняр диб, теясене бергя алырга тороучылар булсыннар диб; 7 Алла кыуатынын эше белян, Анын дяўлятенен бюляге белян мина бирелгян буйынча, мин мынар кызмят итеўче булдым.

Зач.223 8 Мина, бар изгелярдян дя ин кечегя, Христоснын тикшереб бетергесез байлыгын жат калыкларга сөйляр өчөн бу дяўлят бирелгян: 9 Іисусъ Христосъ арткылы барын да булдырган Алланын Ўзендя мянгедян жяшерен торган, Анын жорт төзөўенен жяшереге нейдян торганны бар кешеляр дя белсен диб, 10 Алланын төрлө белемнекляре арыу жыйын арткылы кюктяге башлыкларга, кыуатларга казер билгеле булсын диб шул. 11 Мянгедянюк билгеляб куйганын казер безнен Ходайыбыз Іисусъ Христосъ арткылы Ул булдырыб житкезгян; 12 безнен Анар ышаныубыз арткылы, Анар кыйыуланыб, өмөт тотоб барырлыгыбыз бар шул. 13 Шунар кюря сезнен өчөн минем көйөгөм булганга сез монаймагыз, ул бит сезнен өчөн данналыу. 14 Шунар кюря дя Ходайыбыз Іисусъ Христоснын Атасы алдында тезляремне сыгылтамын: 15 Анын белян кюктя

дя, жирдя дя äр-бер илляр исем алалар. 16 Ӱз данынын байлыгы буйынча эчке кешелегегездя Ӱзенен Тыны белян сезгя ныk берегеӱ бирсен эйе, 17 ышаныу белян Христосъ сезнен кюнеллярегезгя урнашсын ыйы. 18 Шулай сез сöйöӱлектя тамырланыб ныгыгач, неӥ киннек, неӥ озоннок, неӥ тиряннек, неӥ бейеклек икянне бар изгеляр белян бергя аннаб житсягез эйе; 19 Алланын бар тулылыгы белян дя тулыланыр öчöн, Христоснын аннаудан да жугары торган сöйöӱлеген аннаб житсягез эйе. 20 Бездя тора торган кыуаты белян, без неӥ сороӥбыз, неӥ турында уйлыйбыз, шуларнын барысыннан да тинняштергесез кюбряк кыла Алыучыга, 21 Иисусъ Христоста тороучы арыу жыйын арткылы бар тыумышларда да гумердян гумергя дан булсын. Аминь.

4-нче бюлем

Зач.224 1 Мына мин Ходай какына быгауда тороучы сезгя ӱтенямен: öндялгян исемегезгя Христосныкы дейелеӱгя килешлене кылыб торогоз; 2 тулы жыуашлык белян, сабырлык, озак тюземнек, сöйöӱлек белян бер-берегезгя и енкелек итеб торогоз; 3 татыулык белян бер тынышта тороргa тырышыгыз. 4 Сез Христосныкы диб аталыб, бер тöрлö öмöткя öндялгянгя кюря, инде бер тян, бер тыныш булдыгыз; 5 Ходай бер, ден бер, чумылдырыу бер, 6 барыбызнын да Атасы Алла бер, Ул булганнарны Башкарыучы, булганнар арткылы Кылыучы, барыбызда да Тороучы. 7 Безнен äр-беребезгя Христосъ Ӱзе чамалаб биргянчя дяӱлят бирелгян. 8 Шунар кюря äйтелгян: Син жугары кютярелгян, тоткондагыларны Ӱзеня коллокка алган, кешеляргя дяӱлят биргян, диб. 9 Кютярелгян дейеӱе нейне белдеря? Ул элеке жир астындагы урыннарга тöшкянне белдеря тöгöлме сун? 10 Тöшöӱче дя Ул, барын да Ӱзе белян тулы итяр öчöн, кюклярдян дя жугары кютярелеӱче дя Ул. 11 Ул кайсыларын апостоллар итеб, кайсыларын пагамбярляр итеб, кайсыларын изге хабяр сöйляӱчеляр итеб, кайсыларын кötöӱчеляр итеб, öйрятеӱчеляр итеб куйган; 12 Христосъ тяне, арыу жыйынны, торгозор öчöн, кешелярне арыуландырыб, Алла кызмятен итяр öчöн; 13 без барыбыз да Алла

Улына бер-төрлө ышаныб, Аны белеб, Христостагы арыулык чаклы арыулыкка тулы кешеляр булыб житсен өчөн.

Зач.225 14 Мыннан ары без кешелярнен жаман уйларына, жангыштыра торган оста хайля белян өйрятеўлярнен жиленя эяреб, балалар шикелле, какшаб ауышыб китмясяк эйе; 15 әммя чын сөйөўлек белян барысына да баш Христоска барыбыз кушылыб ўссяк эйе; 16 Аннан бөтөн тян, бар саннары белян тоташа килеб, әртөрлө бяйляўечляр белян ныгытылыб тозөля, ўзен-ўзе сөйөўлектя тозөр өчөн арыу жыйыннын әрбер саны да ўзенен эшенен чамасы белян килеб жабышыб ўся.

Зач.226 17 Шунар кюря мин әйтям дя, Ходай исеме белян кисятям дя: бютян калыклар ўзляренен буш уйлары белян кыйланган кюк, сез дя алай кыйланмагыз дим; 18 алар уйлары карангыланганныктан, кюнелляре катыланыб, белемнексез булганныктан, Алланын тормошоннан чит булыб, айырылганнар. 19 Алар тоймаслыкка барыб житеб, жулсызлыкка биренгянняр, әр-төрлө шакшылыкны туйымсызланыб кылалар. 20 Әммя сез Христосны алай диб белмядегез; 21 сез шу Анын турында эшетеб, Аннан өйряндегез, чыннык Іисуста шул. 22 Алдандыра торган, няпесляр белян черетя торган иске кешелекне, элекеге тормошогозны ташлаб, 23 уйыгызнын тыны белян жанарыб, 24 Алла ирке белян чыннык өчөн гаделлектя, изгелектя булдырылган жана кешелеккя кейендегез.

Зач.227 25 Шунар кюря әр-төрлө жалганны ташлаб, сез бер-берегезнен саннары булганга кюря, әр-кайсыгыз жакыны-гызга чынны сөйлягез. 26 Ачыуыгыз кился дя, жазыкланмагыз: ачыуыгыз багытында кояш байымасын, 27 шайтанга урын бирмягез. 28 Кем урлаган икян, мыннан ары урлама, әммя ўз кулын белян пайдалыны кылыб эшля, әйберенян киряксеня торганнарга да бюлеб бирешле булсын. 29 Ауызыгыздан ич нейдей дя черек сюз чыкмасын, әммя ышаныуга өйрятя торган арыу сюз гня чыгыб, тынаучыларга дяўлят китерсен. 30 Сезне жолоб алган көннө сезне пичятлягян Алланын Святый Тынын курландырмагыз. 31 Әртөрлө ўртялянеў, жарсыулык, ачыу, кычкырыулар, усаллык белян жаман сөйляшеўляр сездян айырылыб киткян булсын; 32 әммя

бер-берегезгя арыу, кызганыучан булыгыз; Алла сезгя Христосъ какына кичергян кюк, сез дя шулай бер-берегезгя кичерегез.

5-нче бюлем

Зач.228 1 Шулай, сӧйӧклӧ оланнары булганыгызга кюря, Аллага ошашырга тырышыгыз, 2 Христосъ безне сӧйӧб, Ӱзен безнен ӧчӧн Аллага тямне эйесле оло корман итеб китерергя биргян кюк, сез дя сӧйӧулектя торогоз. 3 Ӓммя изгелярга килешлечя, азгыннықнын, ӓр-тӧрлӧ шакшылыкнын, ӓйбер жыйыуны сӧйӧулекнен сездя исеме дя булмасын. 4 Шулай ук шакшы сюзляр ӓйтеӱ, буш сюзляр, кӧлкӧ сюзляр сӧйляшеӱ сезгя килешмей, ӓммя тау итеӱ гня булсын. 5 Ӓммя белегез: бер нейдей азгыннын да, шакшынын да, ӓйбер жыйыуны сӧйӧунен дя, ул шу сынга табыныуга тиң, Христосъ Аллабызнын Падшалыгында ӧлӧшӧ жук. 6 Беряӱ дя сезне буш сюзляр белян алдандырмасын, мынын ӧчӧн карышыулык улларына Алланын ачыуы тӧшя; 7 шунӷар кюря алар белян катышыулы булмагыз.

Зач.229 8 Бер багытта сез карангылык ыйыгыз, ӓммя казер Ходайдагы жактылык, шунӷар кюря жакты оланнарына килешлечя кылынығыз. 9 Тын эшляре былар: ӓр-тӧрлӧ арыулыкны, дӧрӧслӧкне, чынны кылыу. 10 Аллага ошой торганны сынаб белегез; 11 карангылыкнын пайдасыз эшляреня керешмягез, андый эшлярне ӓйтеб оялтыгыз. 12 Ул кешелярнен жяшерен кылган эшлярен ӓйтергя дя оят ич. 13 Кюреня торган нястя бары да жактыда беленя, ӓр-бер айырмачык кюреня торган нястя жакты ӱзе шул.

14 Шунӷар кюря ӓйтелгян: Эй жоклаучы, тор, ӱлгяненнян терел, сине Христосъ жактыртыр, диб. 15 Инде айса карагыз, сак жӧрӧгӧз, акылсызлар кюк булмагыз, белемнеляр кюк булыгыз; 16 багытны кыйбатка куйыгыз, кӧнняр алдаучан шул. 17 Уйсыз булмагыз, Алланын ирке ней икянен белергя тырышыгыз. 18 Кызыл аракыны да исерерлек эчмягез, ул кешене азгыннықка бирендеря; ӓммя Святый Тынга тулыланыгыз; 19 Ходайга ӱз кюнелегездя даннау жырыуларын жырлаб, псаломнар ӓйтеб, чиркяӱ жырыуларын, даннау сюзлярен китереб, ӱзегезгя ӱгет алдырыб торогоз.

Зач.230 20 Ходайыбыз Иисусъ Христоснын исеме какына Алла Атага бар нястя өчөн дя жалан тау итегез; 21 бер-берегезгя баш салыб, Алладан куркыныб торогоз. 22 Сез, катыннар, Ходайга баш салган кюк, ирлярегезгя баш салыб торогоз; 23 жыйынга баш Христосъ кюк, катынга баш ире; Ӱз тяне, жыйынны, Коткарыучы Христосъ Ӱзе. 24 Жыйын Христоска баш салыб торган кюк, катыннар да ӓр-бер эштя ирляреня баш салыб торсоннар.

Зач.231 25 Христосъ жыйынны сөйгян кюк, сез дя, ирляр, катыннарыгызны сөйөб торогоз. Христосъ жыйынны шул хатле сөйгян, анын өчөн Ӱз жанын биргян; 26 аны Ӱз сюзе белян тазартыб, сыуга жыудырыб арыуландырган; 27 жыйынны буялыусыз, жарасыз, жя бютян төрлөчя шиксез, таб-таза, бик арыу итеб данналдырыб Ӱз карышысына китергян. 28 Шулай, ирляр дя ӱз тянен сөйгян кюк, катыннарын сөйөб тотарга тейеш; катынын сөйөб тотоучы ӱзен-ӱзе сөйөӱче була. 29 Ӱз тяненя беряӱ дя кыйын тейермей, туйдырыб, жылытыб тота, Христосъ Ӱз жыйынын бик саклаб, кастярляб тоткан шикелле; 30 без Христосъ тяненен саннары, Анын Ӱз ите, Ӱз сӧяге. 31 Шунын өчөн кеше атасыннан, анасыннан айырылыб, катынына кушылыб, икесе дя бер тян булыб торалар. 32 Бу бик зур жяшерек: былай дигянем жыйын белян Христосъ кушылганны ӓйтеӱем.

Зач.232 33 Шулай ӓр-бер кеше ӱз катынын ӱзен-ӱзе сөйгян кюк сөйөб тотсон, катын да ӱз ирен кадерляб торсон.

6-нче бюлем

1 Эй балалар, Ходай какына ӱзегезнен тыудырыучыларыгызга баш салыб торогоз, мыны кылыу гаделлек шул. 2-3 Атанны, ананны саннаб тор, сина жакшы булыр, жирдя гумереҥ озон булыр, дигян сюз багадя итеӱлектя беренче бойорок. 4 Сез дя, аталар, ӱзегезнен балаларыгызны жарсытмагыз, ӓммя Ходай кушканга өйрятеб, аларга арыулык сендерегез. 5 Эй коллар, ӱзегезнен тян жагыннан булган эяляре-гезгя, Христоска баш салган кюк, туры кюҥел белян, куркыб-калтраб баш салыб торогоз; 6 кешегя гня жараргa тырышкан кюк кюз алдында гна кыйланмагыз, ӓммя

Христосъ коллары кюк, кюнелдян Алланын иркен кылыгыз; 7 кешелярга тёгёл, ӓммя Ходайга кюнел биреб кызмят иткян кюк кызмят итегез; 8 кол мы, иркендяге ме, кылган арыу эше буйынча ӓр-кем Ходайдан изгелек аласын белеб эшлягез. 9 Сез дя, эяляр, коллар белян каты булмагыз, кюктя сездян дя, алардан да оло Ходай барны белегез, Ул шу кешенен жёзёня караб кайтармый.

Зач.233 10 Азактан ӓйткяндя, эй туганнар, Ходай белян, Анын кодрятле кыуаты белян ныгайыгыз. 11 Шайтаннын хайлярeня карышы торор ёчён Алланын тёрлё коралларына кейенегез; 12 безнен жинешеуебез кан белян, тян белян тёгёл шул, ӓммя кюк астындагы жаман тыннар белян, бу дёнья карангылыгын тотоб тороучылар белян, аларнын тёрлё башлыклары, кыуатлары белян. 13 Шунар кюря жаман кёндя аларга карышы тороб, барысын да жинеб, нык тороб калыр ёчён сез Алланын бар коралларын алыгыз. 14 Биллярегезне чыннык белян бяйляб, дёрёслёк коралына кейенеб торогоз; 15 аякларыгызны кейенеб, татыулык сёйлярга ӓзер торогоз. 16 Барыннан да бигряк шайтаннын бар кыздырган укларын сюрелдерер ёчён ўзегезне ышаныу белян каблагыз; 17 котолдоргоч бюрек кейеб, Тын кылычын алыгыз, алай дигянем Алла сюзе.

Зач.234 18 Тын белян ӓртёрлё теляк-инялеўдя тороб, ӓр багытта теляк итегез, теляктя нык тороу белян бар изгеляр ёчён тырышыгыз. 19 Минем ёчён дя телягез, мина сюз бирелсен эйе, ауызымны ачыб, кыйыуланыб арыу хабярнен жяшереген белдерсям эйе; 20 шул какта мин быгауда илчелектя торам, мина бирелгянне кыйыуланыб тейешенчя сёйлёй алсам ыйы. 21 Минем эшляремне, жанымда нейляр барын сез белер ёчён Ходайда туры кызмят итеуче сёйёклё туган Тихикъ сезгя барын да сёйляр. 22 Шунын ёчён мин аны сезгя жибярдем дя, безнен турда сез белсен диб, ул сезнен кюнеллярегезне тынычландырсын диб.

23 Атабыз Алладан, Ходайыбыз Iисусъ Христостан туганнарга тынычлык, ышаныу, сёйёулек булсын. 24 Ходайыбыз Iисусъ Христосны ӱнгяреўсез сёйёучелярнен барысы белян Анын дяўляте булсын. Аминь.

СВЯТЫЙ АПОСТОЛЪ ПАВЕЛНЫН ФИЛИППЫ КЕШЕЛЯРЕНЯ ЖИБЯРГЯН ЖАЗЫУЫ

1-нче бюлем

Зач. 235 1 Іисусъ Христоснын мяндяляре Павелъ белян Тимофейдян Христосъ какына Филиппыда булган епископлар белян, діаконнар белян бергя бар изгелярга: 2 Атабыз Алладан да, Ходайыбыз Іисусъ Христостан да сезгя дяўлят, тынычлык булсын. 3 Сезне иска алганда ăрчакта да Аллама тау итямен; 4-5 изге хабяр сöйляўгя беренче кöннян башлаб казергя чаклы сез дя катышканга кюря ăр-чакта ăрбер телягемдя мин сезнен барыгыз öчöн дя сöйöнöч белян телягемне китерям; 6 сездяге жакшы эшне башлаучы Іисусъ Христоснын кöнöня чаклы кылыб торор диб тя ышанамын. 7 Сезнен турда минă шулай уйларга тейеш тя, мин шу шушы бигауда торганда да, арыу хабяр сöйляўне жаклаганда да, ныгытканда да, сез дяўлятгя керешеўчеляремне барыгызны да кюнелемдя тотамын.

Зач. 236 8 Алла таныкчы, мин сезнен барыгызны да Іисусъ Христоснын сöйöўлеге белян сöямен; 9 сезнен сöйöўлегегез тагы да белемнеккя, ăр-тöрлö тойомнокка бигряк тя, бигряк тя ўссен эйе диб теляк итямен, 10 сез арыуыракны анăнаб, Христоснын кöнöня таза да, абыныусыз да булсагыз ыйы. 11 Алланын данналыуы, мактальыуы öчöн сез Іисусъ Христосъ арткылы гаделлек жимешляреня тулылансагыз ыйы.

Зач. 237 12 Эй туганнар! Быларны сез белсягез эйе: бу минем белян булган халляр арыу хабярне сöйляўгя бигряк тя унышлык китерергя булыштылар; 13 шулай

Христосъ какына булган минем быгауларым бӧтӧн преторіягя дя, бютяннярнен барысына да билгеле булган. 14 Ходайда булган туганнарнын кюбчелеге минем быгауларым белян батырланыб, бигряк тя кыйыулык белян курыкмыйчы Алла сюзен сӧйлӧй башлаганнар. 15 Дӧрӧс, кайберяўляре кӧнчӧлӧк белян бигряк тя уздырыр ӧчӧн, бютянняре арыу кюнел тотоб Христосны сӧйлӧйляр. 16 Беряўлярнен уздырырга тырышыб Христосны сӧйляўляре таза тӧгӧл, алар минем быгауларымнын ауырлыгын арттырырга уйлыйлар; 17 ӓммя бютянняр, мин арыу хабяр сӧйляўне жакларга куйылганны белеб, сӧйӧўлек белян сӧйлӧйляр.18 Алай да, Христосны ничек кня сӧйлясяляр дя: кюнелдян ме, тыштан гна мы, мин шунар да сӧйӧням, сӧйӧнӧрмен дя. 19 Белямен шул: Іисусъ Христоснын Тыны булышкан буйынча, сезнен теляклярегез белян бу мина котолоу ӧчӧн пайдалы булыр.

Зач.238 20 Минем ышаныб ӧмӧт тотоб торганым шул: мин бер ней белян дя кур булмам, ӓммя ӓр-тӧрлӧ кыйыулыгым белян, ӓрчактагыча казер дя, жяшяўем белян ме, ўлемем белян ме, минем тянемдя Христосъ зурланыр. 21 Минем ӧчӧнгя тормош - Христосъ, ўлем - табыш кна. 22 Ӓгяр тянемдя тороуым минем эшемнен жимешен арттыра икян, айса ней сайларга да белмеймен. 23 Мине тегесе дя кызыктыра, мынысы да: тянемнян иркенгя чыгыб, Христосъ белян буласым да киля, мынысы тинняштергесез арыуырак шул; 24 ӓммя тянемдя калыу сезнен ӧчӧнгя кирягеряк. 25 Мин ышанычлы белямен: калырмын да, сезнен ышаныуда житешлегегез, сӧйӧнӧчӧгез ӧчӧн сезнен барыгыз белян булырмын; 26 минем икенче табкыр килеўемдя сезнен Іисусъ Христоста макталыуыгыз минем арткылы кюбяйсен эйе дим.

Зач.239 27 Тик Христоснын арыу хабяре кушканча тейешлечя гня жяшягез; мин килеб сезне кюрем ме, жя килмясям, Евангеліегя ышаныу буйынча бер кюнелдян тырышыб, бер тында торганыгызны эшетсям эйе; 28 карышы килеўчелярдян ич тя курыкмагыз: бу алар ӧчӧн харяб буласылары алдан билгелянеў, ӓммя сезнен ӧчӧн котолоу билгесе, бу - Алладан. 29 Сезгя шу Христо-

съ какына Анӈар ышаныб тороргa гна тӧгӧл, ӓммя Анын ӧчӧн азабланырга да бирелгян. 30 Сез миндя ней кюрдегез, казер ней эшеттегез, шундый тырышыулар белян тырышыгыз.

2-нче бюлем

1 Шулай ӓгяр дя Христоста тынычланыу бар икян, сӧйӧўлектян кюнел сӧйӧнӧчӧ бар икян, тыннын катышыулыгы, арыу кюнеллелек, жя кеше хален анналык бар икян, 2 ул чакта минем сӧйӧнӧчӧмне дя арттырыгыз, бер уйда булыгыз, шул сӧйӧўлектя торогоз, бер тында, бер уйда булыгыз; 3 мактаныр ӧчӧн, жя уздырыр ӧчӧн бер нястя дя эшлямягез, ӓммя жыуашлык белемнеге белян, берегез икенчегезне олоракка куйыгыз.

Зач.240 4 Ӓр-кайсыӈ ӱзеӈ ӧчӧн гня сагышланма, ӓммя ӓркайсыӈ бютянняр ӧчӧн дя сагышлан. 5 Сездя тойоулык Іисусъ Христосныкыча булырга тейеш. 6 Ул Алла ошашы була тороб, Ӱзен Алла белян тиӈ кюрсятеўне Алла белян тиӈняшеў диб санамаган; 7 ӓммя Ул мяндя ошашын алыб, кеше шикелле булыб, кюз кюрергя дя гел кеше булыб, Ӱзен Ӱзе кечеляндергян; 8 Ӱзен жыуашландырыб, ӱлярга дя риза булган, ӱлеўен дя Качта ӱлгян. 9 Шуӈар кюря Алла да Аны бик кютяргян, Анын исемен бар исемнярдян дя жугары иткян, 10 шул Іисуснын исеме алдында кюктягеляр дя, жирдягеляр дя, жир астындагылар да багыныб торсоннар диб; 11 бар калыклар да Ходай Іисусъ Христосъ Алла Атанын даны диб сӧйлясенняр диб.

Зач.241 12 Шулай, сӧйӧклӧлярем, ничек сез ӓр-кайчан тынналучан булдыгыз, мин сезгя килеб торганда гна тӧгӧл, бигряк тя казер мин жук чакта, куркыныб, калтраныб ӱзегезнен котолоу эшен кылыб торогоз. 13 Алла шу сездя Ӱзенен ризалыгынча, киряксенеўне дя, эшне дя кылдырыб тора. 14-15 Бу бозолган, азгын кюнелле тыума арасында сезгя Алланын курлый алмаслык, таза оланнары булыр ӧчӧн барысын да шиклянмейче, зарланмыйчы эшлягез; алар арасында сезнен терелек сюзен тотоб, жактыртмкычлар кюк дӧньядя жактырыб тороуыгыз.

Зач.242 16 Христоснын
кӧнӧндя мин макталыуга булсын
ыйы, бушка гна тырышмаганым,
бушка гна кызмят итмягянем диб.
17 Ӓгяр мин сезнен ышаныуыгызга
кызмят итеб, корман ӧчӧн корман
булам икян, ул чакта мин сӧйӧням,
сезнен барыгыз белян бергя сӧйӧ-
ням. 18 Бу какта сез дя сӧйӧнӧгӧз,
минем белян бергя сӧйӧнӧшӧгӧз. 19
Тиздян сезгя Тімофейне жибяре-
ргя Ходай Іисуста ӧмӧт тотам, мин
дя сезнен ӓлегезне эшетеб, тыным
белян тынычланыр ӧчӧн. 20 Сезнен
ӧчӧн шул катле кюнелдян сагыш-
ланырлык андый кюнел биреўчем
минем бютян беряў дя жук шул; 21
барысы да ўзляреня киряклене гня
эзлейляр, ӓммя Іисусъ Христос-
ка ней жараулыны эзлямейляр. 22
Тімофейнен ышанычлылыгы
сезгя билгеле: ул мин арыу хабяр
сӧйлягяндя, улы атасына кызмят
иткян кюк, мина кызмят итте. 23
Озакламый мина ней булырын
ўзем белеў белян шундук аны жи-
бярергя ӧмӧт тотам.

Зач.243 24 Ўзем дя тиздян
сезгя килерем диб Ходайда ыша-
нам. 25 Алай да сездян минем
кирягемя кызмяткя жибярелгян,
минем белян кызмят итеўче, ты-
рышыучы туганым Епафродитны
сезгя жибярергя киряк диб сана-
дым; 26 анын шу сезнен барыгыз-
ны да бик кюрясе килде, анын
чирлягяне сезгя барыб эшетелгяч,
бик кӧйӧндӧ. 27 Ул шу ўлем ӓлен-
дя чирле булды, ӓммя Алла аны
жарлыкады, аны гна тӧгӧл, кӧйӧк
östӧня мина кӧйӧк артмасын диб,
мине дя жарлыкады. 28 Шунар
кюря мин тизряк аны жибярдем
дя, сез аны тагы кюреб сӧйӧнӧш-
сӧнняр диб, минем дя кӧйӧгӧм ки-
месен диб. 29 Ходайда ӓр-тӧрлӧчя
сӧйӧнӧшӧб, аны кабыл алыгыз,
мындыйларны кадерлей торган
булыгыз. 30 Ул шу Христоснын
эше ӧчӧн тормошон куркынычка
туры китереб, ўлемгя жакын бул-
ды, сезнен мина булган кызмят-
нен житмягенен тутырыб житке-
зер ӧчӧн.

3-нче бюлем

Зач.244 1 Алай да, туганна-
рым, Ходай какына сӧйӧнӧшӧгӧз,
ул какта тагы жазарга минем ӧчӧн
ауыр тӧгӧл, ӓммя ул сезне ныгы-
тыу ӧчӧн. 2 Сакланыгыз этлярдян,
сакланыгыз усаллык эшляўче-
лярдян, сакланыгыз киселеўдян; 3
киселеў ул - без, Аллага тыныбыз

белян кызмят итеўчеляр, Іисусь Христосъ белян мактаныучылар, ӓммя тянгя гня ышаныб тороучылар тӧгӧл. 4 Алай да мин тянемя дя ышаныб тора алам, ӓгяр бютян беряў тяненя ышаныб торорга уйласа, мин кюберяк тя. 5 Мин сигезенче кӧндя киселгян, Израиль тыумасыннан, Вениаминъ няселеннян, еврейлярдян тыуган еврей, ӧйрянеўем буйынча фарисей, 6 кӧнчӧлӧгӧм буйынча Алланын жыйынын кыуыучы, законъ дӧрӧслӧгӧ буйынча — бозолоусыз.

Зач.245 7 Ӓммя минем ӧчӧн ӧстӧнӧряк булганнарны Христосъ какына мин буш нястя диб санадым. 8 Шулай минем Ходайым Іисусъ Христосны белеўлек барыннан да жугары булганга кюря, барысын да буш нястя диб саныйым; Анын ӧчӧн мин бар нястяне дя кире кактым, Христослы булыр ӧчӧн бар нястяне дя чюб диб саныйым. 9 Христоста табылыр ӧчӧн минем гаделлегем законнан килгян гаделлек тӧгӧл, ӓммя Христоска ышаныу артқылы килгян, ышаныу буйынча Алладан килгян гаделлек шул. 10 Аны анҥаб белер ӧчӧн, Анын азабларына керешеўле булыр ӧчӧн, Анын ӱлеўеня ошашлы булыр ӧчӧн, Анын терелеб тороуынын кыуатын белер ӧчӧн; 11 ӱлгяннярнен терелеб тороуына барыб житяр ӧчӧн. 12 Алай ӓйтеўем, мин инде барыб житкянемя, жя житешле булганыма тӧгӧл, ӓммя ӧмӧтлянеб тырышам, минҥа Христосъ Іисусъ килеб житкян кюк, мин дя барыб житмям микян дим. 13 Эй туганнар, мин ӱземне барыб житкян диб санамыйым, ӓммя тик арттагын онотоб, алга таба сузылыб, 14 барыб житясе урынга, Іисусъ Христосъ арткылы Алла чакырган жугарыгы кадерлеккя ӧмӧтлянеб тырышамын. 15 Шулай сезнен арада кем булыб житкян, шушылай уйларга тейеш; ӓгяр сез бер-бер нястя турында бютянчя уйласагыз, аны да Алла сезгя ачар. 16 Шулай итеб без нейгя житешкян, шуны уйларга тейеш, шундый рят белян жяшяргя тейеш. 17 Эй туганнар, сез минҥа ошарга тырышыгыз, бездя кюргян ошаш кючергечендя, шулай кыйланыучыларга да карагыз. 18 Ӓммя кюбесе, алар турысында мин жалан ӓйткян эйем, казер дя кюз жяшем белян ӓйтямен; Христосъ качынын дошманнары шикелле кыйланалар. 19 Алар-нын азакы кӧнӧ - харяб булыу,

аларнын алласы - корсаклары, аларнын даннары курлыкта, алар жирдягене гня уйлыйлар.

Зач.246 20 Безнен бит торасы жиребез кюклярдя, шуннан без Коткарыучыбыз Ходай Iисусъ Христосны котябез. 21 Ул безнен кимсетелгян тянебезне шул катле ӱнтяртер, ул Анын данныклы Тяненя ошашлы булыр, Ул кылыб житкезеӱче кыуаты белян барын да Ӱзеня буйсындыра.

4-нче бюлем

1 Шулай, минем сӧйӧклӧ, бик тя жакын иткян туганнарым, сез минем сӧйӧнӧчӧм, даным, шулай Ходай жулында торогоз, сӧйӧклӧлярем. 2 Ходай турында шулай ук уйларга Еводіяне дя димнейем, Синтихіяне дя димнейем. 3 Эй минем белян чын кюнелдян кызмят итеӱче, арыу хабяр сӧйлягяндя минем белян, Климентъ белян бергя тырышыучыларга, бютян минем кызмят итешеӱчеляремя дя булыш, аларнын исемняре терелек книгясеня жазылган шул.

Зач.247 4 Ходайга жалан сӧйӧнӧгӧз, тагы да айтям: сӧйӧнӧгӧз. 5 Сезнен сабырлыгыгыз бар кешелярга дя билгеле булсын, Ходай инде жакын. 6 Бер нястя ӧчӧн дя кӧймягез, аммя ар-кайчан теляктя тороб, инялеб, тау итеб телягянегезне Ходайга белдереб торогоз; 7 Алланын уй белян белеб житкезя алмаслык тынычлыгы сезнен кюнеллярегезне, исябляpегезне Iисусъ Христосъ какына саклар. 8 Аннары тагы, эй туганнарым, ней чын, ней кадерле, ней гадел, ней таза, ней сӧйӧклӧ, ней мактаулы, ней арыу, ней мактарга тейешле эш бар, сез шуларны гна исябляб торогоз. 9 Миннян нейгя ӧйряндегез, ней алдыгыз, ней эшеттегез, миндя ней кюрдегез, шуны кылыб торогоз; шулай итсягез, тынычлык биреӱче Алла сезнен белян булыр.

Зач.248 10 Сез минем ӧчӧн тагы да сагышлана башлаганга мин Ходайда бик сӧйӧндӧм, сез элек тя сагышландыгыз, тик сезгя тормоштагы халляр жай китермяделяр. 11 Мин мыны айтеӱем киряксенгянемя тӧгӧл, мин шу ӱземдя ней бар, шунын белян тук булыб тороpга ӧйряндем; 12 жуклык белян дя тора белям, муллык белян дя тора белям, бар турдан да барысына да ӧйряндем, тук-

лыкка да, ачлыкка тюзяргя дя, барлык белян дя, житмяслек белян дя тороргa öйряндем;[13] Iисусъ Христосъ мине ныгытканга кюря, барысын да булдыра алам. [14] Алай да минем көйөгөмя керешеўле булыб, сез жакшы эшлядегез. [15] Эй Филиппы кешеляре, сез белясез, арыу хабяр сөйляўемнен башында, мин Македонiядян чыккач, бер сездян башка, бер жыйын да мина булышлык итяргя, жя мине кабыл алырга да ашыкмады; [16] сез гня Фессалоникага да бер-ике табкыр минем кирягемя жибярдегез. [17] Мин мыны биргянне көткяннян äйтеўем төгöл, ämмя сезнен пайдагызга кюбяя торган жимешегезне эзлейем. [18] Мин барын да алдым, артыгы белян; Епафродиттан сез жибяргянне, тямне эйесле ладанъ кюк, тямне корман кюк Аллага жараулыны алгач, мин бик риза. [19] Минем Аллам Ўзенен данынын байлыгы белян Iисусъ Христоста сезнен дя äр-бер кирягегезне тутырыб житкезсен. [20] Безнен Атабыз Аллага дан булсын гумердян гумергя. Аминь. [21] Iисусъ Христостагы äр-бер изгене кюнелдян жаратыб торогоз, минем белян бергя булган туганнар сезне кюнелдян жаратыб калалар. [22] Сезне бар изгеляр дя, бигряк тя кесарь жортондагылар бик кюнелдян жаратыб калалар. 23 Ходайыбыз Iисусъ Христоснын дяўляте сезнен барыгыз белян дя булсын. Аминь.

СВЯТЫЙ АПОСТОЛЪ ПАВЕЛНЫН КОЛОССЪ КЕШЕЛЯРЕНЯ ЖИБЯРГЯН ЖАЗЫУЫ

1-нче бюлем

Зач.249 1 Алла ирке буйынча Іисусъ Христоснын апостолы Павелдан, аннары Тімофей туганнан 2 Колосста тороучы изгелярга, Іисусъ Христоста булган ышаныучы туганнарга: 3-5 Атабыз Алладан да, Ходайыбыз Іисусъ Христостан да сезгя дяўлят, тынычлык булсын. Кюктя сезгя диб äзерлянгянгя ӧмӧт тотоб, сезнен Христосъ Іисуска ышаныуыгыз, бар изгелярга дя сӧйӧўлегегез какында эшетеб, Атабыз Аллага да, Ходайыбыз Іисусъ Христоска да сезнен ӧчӧн теляк итеб, жалан тау итябез. Арыу хабяр сӧйлягяннен чын сюзен сез элек эшеткян эйегез. 6 Ул сюз бӧтӧн дӧньядя торган кюк, сездя дя тора; сез эшетеб Алланын дяўлятен чынныкта ничек анӈадыгыз, шул кӧннян башлаб, дӧньядяге кюк, сезнен арагызда да жимеш китереб ўскян-ўся бара. 7 Сез аны безнен белян кызмят итеўче сӧйӧклӧ, сезнен ӧчӧнгя Христоснын ышанычлы кызмятчесе Епафрастан ӧйрянгян эйегез шул; 8 ул сезнен тын белян сӧйӧўлегегезне безгя билгеле итте. 9 Шунар кюря без мыны эшеткян кӧннян башлаб, сез Алланын иркен белеўлеккя, тыннын äр-тӧрлӧ белемнегеня, анӈаулыкка тулылансыннар ыйы диб сораб, сезнен ӧчӧн теляк итеўдян туктамыйбыз. 10 Сез äр-турда да Аллага жараулыны кылыб, äр-бер арыу эштя жимеш китереб, Алланы белеўлеккя ўсеб, Аллага тейешлечя торсагыз ыйы. 11 Анын барын да булдыра ала торган данынын äр-тӧрлӧ кыуаты белян ныгайыб, äр-тӧрлӧ тюземнектя жакты кюнел белян сӧйӧнӧб,

Зач.250 12 Алла Атага тау итейек: Ул безне жактыдагы изгеляр өлөшөня керештерергя чакырыб алган; 13 безне карангылык тоткононнан чыгарыб, Ўзенен сөйөклө Улынын Падшалыгына керткян. 14 Анын Улынын каны арткылы без жазыкларыбыз кичерелеб, котолоу алдык. 15 Ул кюренмей торган Алланын ошашы, булдырылганнарнын ярберсеннян элек тыуган; 16 яр-ней Анын арткылы булдырылган: кюктягеляр дя, жирдягеляр дя, кюреня торган да, кюренмей торганы да, престолы, господства, начала, власти диб атала торган пяриштяляр рятляре дя, барысы да Анын арткылы, Анын очон булдырылган. 17 Ул барыннан да элек бар, барысы да Анын белян тора;

Зач.251 18 Ул арыу жыйын тяненен Башы; Ул - башланыу, ўлеклярдян иң элек башлаб терелеб тороучы да Ул, шунар кюря бар турдан да алда тороучы Ул. 19 Анда шу бар жактан да тулылык булыуы Атага арыу жараулы булган. 20 Кюктягелярне дя, жирдягелярне дя Ата Анын Качта агызган каны арткылы, Анын арткылы татыуландырыб, барысын да Ўзе белян татыулаштырган. 21 Сезне дя, бер багытта кюнелегез усал эшлярга ауышыулы булганныктан чит булганнарны, дошман булганнарны, 22 казер бозолоусыз, изгеляр, айыбсызлар итеб, Ўз карышысына китерер очон, Анын тяне белян, Анын ўлеме белян татыуландырды. 23 Агяр ышаныуда ауышмыйчы ныктор сагыз, ўзегез эшеткян, кюк астындагы бар булдырылган нястялярга дя сөйлянгян изге хабярнен омотоннян ауышмасагыз сез дя татыуланган. Мин, Павелъ, шул эшкя кызмят итеўче булдым.

Зач.252 24 Казер ўземнен азабларымда сезнен очон сөйонямен, Христоснын Тяне булган арыу жыйын очон ўземнен тянемдя житмягян көйөклярне тутырыб житкезямен. 25 Алланын электян куйган жорт житкезеўеня мин кызмят итеўче булдым; Алланын сюзен кылыб житкезер очон сезнен арагызда бу эш мина табшырылган, 26 гумерлярдян бирле тыумалардан жяшерен торганы казер Анын изгеляреня ачылган. 27 Бу жяшеректяге даннын байлыгы жат калыклар очон нейдей икянен Алла аларга кюрсятергя ризалык иткян, бу Христ-

тосъ данынын ӧмӧтӧ булыб, сездя Ӱзе тороуы. 28 Ӓр-бер кешегя акыл биреб, ӓр-бер белемнекка ӧйрятеб, ӓр-бер кешене Іисусъ Христоста житеӱ итеб, Алла карышысына китерер ӧчӧн без Аны сӧйлӧйбез. 29 Шунын ӧчӧн мин кызмят итямен дя, Анын миндя кыуатлы кылыб тора торган кӧчӧ белян тырышамын да.

2-нче бюлем

Зач.253 1 Минем сезнен ӧчӧн дя, Лаодикіядя, Іерапольдя булганнар ӧчӧн дя, тян жагыннан минем жӧзӧмне кюрмягяннярнен барысы ӧчӧн дя минем нейдей тырышыулыгым барны сез белсягез эйе диб телеймен; 2 аларнын кюнелляре сӧйӧӱлек белян катышыб тынычлансын, тулысы белян анна унын ӓр-тӧрлӧ байлыгы ӧчӧн Алла Атанын да, Христоснын да жяшеренен анна сыннар ыйы дим. 3 Христоста бар белемнекнен дя, белеӱлекнен дя жяшеренняре биклянгян шул. 4 Мыны мин сезне беряӱ-беряӱ хайлякяр сюзляр белян алдандырмасын диб ӓйтямен. 5 Мин шу тянем белян сездян айырым булсам да, тыным белян сездя тороб, сезнен Христоска ышаныуыгызнын ныклыгын, арыу тӧзӧлӧшӧгӧзне кюреб сӧйӧнямен. 6 Шуна р кюря Ходай Іисусъ Христосны сез ничек кабыл алдыгыз, шулай анда жӧрӧгӧз. 7 Христоста тамырланыб ныгыгач, сезгя ӧйрятелгянчя ышаныуда ныктороб, тау итеӱ белян ышаныуда ӱсегез.

Зач.254 8 Эй туганнар! Сак булыгыз, беряӱ-беряӱ сезне Христосъ кушканча ӧйрятмейче, белемнекка оста булыб ӧйряткяндей, буш нястялярга, картлар ӓйтеб калдырганга, дӧньялек тартканга ӧйрятеб кызыктырмасын; 9 Христоснын кешелегендя Аллалык тулы кӧйӧ тора шул; 10 сездя дя Христосъ какына тулылык бар; Ул ӓр-бер кыуатнын, башлыкларнын башлыгы. 11 Христоста сезгя жазыклы тян киселеӱ билгесеня, кул белян кылмаган, Ул Ӱзе куйган киселеӱ жоласы кылынган. 12 Анын какына чумылдырылыб, сез Анын белян кюмелдегез дя, Аны ӱлгяненнян терелтеб торгозоучы Алланын кыуатына ышаныу арткылы Анын белян терелеб тя тордогоз.

Зач.255 13 Сезне дя, жазык эчендя ӱле булганнарны, тянегез

дя киселмягяннярне, безгя бар жазыкларыбызны да кичереб, Христосъ белян тереляндерде. 14 Безгя карышы булган кул белян жазган жазыуны өйрятеуе белян жук итеб, Ул аны безнен арадан алыб, Качка кадаклаган. 15 Башлыкларнын, кыуатларнын көчөн бетереб, кыуаты белян аларны курлыкка калдырыб, алар өстөндя Ўзенен жинеуе белян данналган. 16 Шулай сезне ашамнык өчөн дя, эчемнек өчөн дя, жя бер-бер бяйрям өчөн дя, жя жаңа ай, жя суббота өчөн дя беряў дя айыбламасын; 17 бу буласынын кюляткясе, әммя тян Христосныкы. 18 Ўз иркеннян жыуаш кюнелле булган булыб, пяриштялргя кызмят иткян булыб, шулай ўзе кюрмягянгя керешеб, дөрөс уйламыйчы, ўзенен тян уйы белян олосомакланыб, Христоска тотонмыйчы, беряў дя сезне алдандырмасын; 19 баштан бөтөн тян, саннары белян, бяйлекляре белян тоташыб, бергя ныгыб, Аллада оло гяўдя булыб ўсядер.

Зач.256 20 Шулай әгяр дя сез бу дөнья өчөн Христосъ белян ўлгянсез икян, нейгя суң бу дөньядя тороучылар кюк былай диб куйылганны тотасыз: 21 кагылма, ашама, барыб тотонма, дигянне? 22 Былар кеше өйряткянняр, кеше бойороклары гна, куллангач, барысы да жукка чыга. 23 Былар, ўз уйың белян кызмят итеў, жыуашланыб тяненне жабыктырыу, тяненне туйдырыу турында кайгырмый тороулар белемнек булыб тик кюренеб кня торалар.

3-нче бюлем

1 Шулай әгяр сез Христосъ белян терелеб торган икян, алайса Алланын уң жагыннан Христосъ утыра торган кюктягене эзлягез; 2 жирдягене уйламагыз, әммя жугарыгыны уйлагыз. 3 Сез шул ўлдегез, сезнен тере тороуыгыз да Аллада Христосъ белян саклана.

Зач.257 4 Сезне тере тотоучы Христосъ кюренгян чакта, сез дя Анын белян ололокта кюренерсез. 5 Алай булгач, тяннярегезнен жирдян алынган саннарын ўлеляндерегез: азгынныкны, шакшылыкны, няпеслекне, жаманны теляўне, сынга табыныу белян тиң малга биренеўне ташлагыз; 6 андый эшляр өчөн карышыулык улларына Алланын ачыуы килядер. 7 Алар арасын-

да торган чагызда сез дя шундыйларга ошаулы булгаладыгыз. 8 Ӓммя казер инде сез барын да: ачыуны да, жаманныкны да, курлауны да, ауызларыгызнын оятсыз сюзлярен дя ташлагыз; 9 бер-берегезгя жалган сӧйляшмягез, иске кешелегегезне эшляре белян чишенеб ташлаб, 10 жаңа кешелеккя кейенегез, ул кеше аны Ӱзеня ошаулы итеб Булдырыучыны белеӱлек белян жаңарадыр. 11 Анын алдында еллиннын да, іудейнен дя, киселеӱнен дя, киселмягяннекнен дя, варваръ диб, скифъ диб аталган кешелярнен дя, кол кешенен дя, кол тӧгӧл кешенен дя айырмасы жук, ӓммя барысында да, бар турыда да бер Христосъ.

Зач.258 12 Сез Алланын сайлаганнары, изгеляре, сӧйӧклӧляре булганга кюря, инде изге кюнеллелеккя, арыулыкка, жыуашлыкка, сабырлыкка, озак тюзеӱлеккя кейенегез; 13 бер-берегезгя иненкелек итеб, бер-берегез белян рянжешкян чагында, каракарышы кичерешеб торогоз, сезгя Христосъ кичергян кюк, сез дя шулай кичерегез. 14 Барыннан да бигряк сӧйӧӱлеккя кейенегез, ул бар арыулыкларнын жыйыны. 15 Кюнеллярегезгя Алла тынычлыгы урыннашсын ыйы, сез шунар бер тян кюк ителеб бер жыйынга чакырылган; бер-берегез белян татыу булыуны сӧйӧгӧз. 16 Христосъ сюзе ӓр-тӧрлӧ белемнек белян сезгя мул урыннашсын ыйы; кюнелегездя Ходайны даннаб, арыу жырыулар жырлаб, сӧйӧнӧшӧб, псаломнар белян бер-берегезне ӧйрятеб, акылга китереб торогоз.

Зач.259 17 Барыгыз да неӣ кылсагыз да, сюз белян ме, эш белян ме, барысын да Ходаӣ Іисусъ Христосъ исеменя кылыгыз, Анын арткылы Алла Атага тау итегез. 18 Сез, катыннар, Ходаӣ какына килешлечя, ирлярегезгя буйсыныб торогоз. 19 Сез, ирляр, катыннарыгызны сӧйӧб торогоз, аларга каты булмагыз. 20 Сез, оланнар, бар турдан да тыудырыучыларыгызга тынналучан булыгыз, шулаӣ тороу Ходайга жараулы. 21 Сез, аталар, оланнарыгызны жарсытмагыз, алар моңайыб тормасыннар. 22 Сез, коллар, бар турдан да тян жагыннан ӱзегезнен эялярегезгя баш салыб торогоз, кешегя гня жарарга тырышыучылар кюк, кюз алдында гна кызмят итмягез, ӓммя

дөрөс кюнел белян Алладан куркыб кызмят итегез. 23 Ней кылсагыз да, Ходай өчөн кылган кюк, кюнелдян кылыгыз, әммя кешелярга кылган кюк төгөл, 24 Ходай кайтарган чакта теясене алырбыз диб белеб кылыгыз, сез шу Ходай Христоска кызмят итясез. 25 Әммя кем дөрөс эшлямяся, ўзенен дөрөссөзлөгө буйынча теясене алыр. Алла кешенен жөзөня караб кылмый шул.

4-нче бюлем

1 Эй эяляр, колларыгызга тейешлене гадел итеб кайтарыгыз, сезнен дя кюктя Ходайыгыз барын белегез,

Зач.260 2 тау итеў белян уяу тороб, жалан теляктя булыгыз. 3 Безнен өчөн дя теляк итегез, Алла безгя Христоснын жяшереген сөйляр өчөн сюзгя ишек ачсын ыйы, шунын өчөн мин быгауда торамын да, 4 минга сөйлярга тейешлене мин ачыклый алсам ыйы. 5 Багыт белян пайдаланыб, тыш жактагылар белян уйлаб кна жөрөшөгөз; 6 сезнен сюзегез әрчакта тоз белян тямнелянеб, дяўлятле булсын, әр-кемгя дя ничек жауаб бирергя сез белсягез эйе. 7 Минем турда барын да сезгя сөйөклө туган, ышанычлы кызмят итеўче, Ходайда минем белян эшляўче Тихикъ әйтер. 8 Аны мин шунын өчөн сезгя жибярдем дя, ул сезнен халлярегез турысында белеб, сезнен кюнеллярегезне тынычландырсын диб. 9 Сездян килгян ышаныучы безнен сөйөклө туганыбыз Онисимъ белян алар сезгя мында булган халлярнен барысын да сөйляб кюрсятерляр.

Зач.261 10 Минем белян бергя биклянеўдя жатычы Аристархъ та, Варнава туганынын улы Маркъ та сезне кюнелдян жаратыб калалар, анын турында сез кушыулык алган ыйыгыз: әгяр сезгя кился, аны кабыл алыгыз диб. 11 Шулай тагы Іустъ диб аталган Іисусъ сезне кюнелдян жаратыб кала; алар икесе дя киселгянняр арасыннан, алар Алла Падшалыгы өчөн бер ўзляре гня минем белян эшляўчеляр, минем сөйөнөчөм булыучылар. 12 Сезнен Епафрасъ сезне кюнелдян жаратыб кала, ул Іисусъ Христоснын мяндясе, Аллага ней жараулы, барысына да тулылансыннар ыйы, житешеўле булыб житсенняр эйе диб, сезнен өчөн әр-кайчан да ты-

рышыб теляктя тороучы. 13 Анын турында таныклык итямен: анын сезнен өчөн дя, тагы Лаодикія белян Іерапольдягеляр өчөн дя бик кюнел биреўлеге, сагышланыуы бар. 14 Сӧйӧклӧ врач Лука да, Димасъ та сезне кюнелдян жаратыб калалар. 15 Лаодикіядагы, Нимфандагы туганнарга да, анын өйөндяге жыйынына да кюнелдян жаратыб калыуыбызны äйтегез. 16 Бу жибяргян жазыу сездя укылгач, ул тагы Лаодикія жыйынында да укылсын диб сагыш тотогоз, Лаодикіядян килгянне сез дя укыгыз. 17 Архиппка äйтегез: кара, син Ходайдан нейдей кызмятне алган, шуны кылыб житкезергя тейеш, дигез. 18 Мин, Павелнын, сезне кюнелдян жаратыб калыуым ўз кулым белян жазыла, минем быгауларымны иска алыгыз. Сезнен барыгыз белян дя дяўлят булсын. Аминь.

СВЯТЫЙ АПОСТОЛЪ ПАВЕЛНЫН ФЕССАЛОНИКА КЕШЕЛЯРЕНЯ ЖИБЯРГЯН БЕРЕНЧЕ ЖАЗЫУЫ

1-нче бюлем

Зач.262 1 Павелъ, Силуанъ, аннары Тімофей Атабыз Аллада, Ходайыбыз Іисусъ Христоста тороучы Фессалоникадагы булган жыйынга жазалар. Аллабыз Атадан да, Ходайыбыз Іисусъ Христостан да сезгя дяўлят, тынычлык булсын. 2 Сезне теляклябездя исебезгя алыб, сезнен барыгыз өчөн дя Аллага жалан тау итябез; 3 сезнен ышаныулык эшегезне, сөйөўлек кызмятегезне, Ходайыбыз Іисусъ Христоска өмөт тоткан тюземнегегезне Алла Атабыз алдында туктаусыз иске алабыз. 4 Эй Аллага сөйөклө туганнар, сезне Алла сайлаганны белябез шул. 5 Безнен шу арыу хабяр сөйляўебез сездя сюз белян гня булмады, әммя Святый Тын белян, кыуат белян, кюб табкыр таныклаулар белян дя булды, без сездя сезнен өчөн нейдей булганны сез ўзегез дя белясез.

Зач.263 6 Шулай сез кюб көйөклярдя тороб та, Святый Тыннын сөйөнөчө белян безне кабыл алыб, Ходайга да, безгя дя ошашлы булырга тырыштыгыз; 7 шулай булыб Македоніядя, Ахаіадагы бар ышаныучыларга да сез кючергеч булдыгыз. 8 Ходай сюзе сездян башланыб, бер Македоніядя гня, Ахаіада гна сөйлянеб калмады, әммя сезнен Аллага ышаныуыгыз турысында бар жиргя дя барыб житте, мынын турында безгя бер ней дя сөйляб торасы да жук. 9-10 Без сезгя кереў ничек булганны, чын, тере Аллага кызмят итяр өчөн сез ничек сыннарны ташлаб Аллага

боролганны, Ул ўлгяненнян терелтеб торгозган Улын, килясе ачыудан безне жолоб аласы Iисусны казер сез кюктян кöткянне алар ўзляре äйтеб торалар.

2-нче бюлем

Зач.264 [1] Эй туганнар! Без сезгя ничек кергянне сез ўзегез дя белясез, ул пайдасызга булмады шул. [2] Äммя башта без Филиппыда азабларга тюздек, курлыкка чыдадык, сез белгянчя, безнен Аллабыз какына, Алла сюзен сöйляўне оло тырышыулык белян сезгя сöйлярга кыйыучылык иттек. [3] Безнен сöйляўебездя жангышыулык та жук, шакшы эшкя котортоу да жук, жаманнык та жук шул. [4] Ничек Алла арыу хабяр сöйляўне безгя ышаныб бирергя тейешле иткян, шулай без дя, кешелярга тöгöл, äммя кюнеллярне сынаб белеўче Аллага жараулы булсын диб сöйлöйбез. [5] Безнен шу сезнен арагызда бер кайчан да жумалаулык сюзе дя булмады, сез белгянчя, äйбер жыярга да телямядек. Мынар Алла таныкчы. [6] Без сездян дя, бютяннярдян дя кешедян данналыуны эзлямейбез. [7] Без Христоснын апостоллары булганга кюря, бик кирякле булыб та кюреня алыр ыйык, äммя сезнен арада тыйнак, балаларын туйдырыучы ўз балалары белян жагымны гна жöргян кюк булдык. [8] Шулай без сезгя кюнелебезне биргяннектян, бер Алланын арыу хабярен сöйляў белян гня каласыбыз килмяде, äммя сез безгя сöйöклö булганныктан, жаныбызны да сезгя бирясебез килде.

Зач.265 [9] Эй туганнар! Безнен кызмятебез, кöчöбез беткенче эшляўебез сезнен исегездядер äле, сезнен берярегезгя ауырлык китермяс öчön без тönня дя, кöндöз дя эш эшляб, Алланын арыу хабярен сездя сöйлядек. [10] Мынар сез дя, Алла да таныкчы: ничек сез ышаныучылар алдында без беряў дя сюз äйтмяслек гадел, изге кыйландык. [11] Сез белясез шул, сезнен äр-кайсыгызны, ата ўз оланнарын димнягян кюк, [12] без димнядек, сезне Ўз Падшалыгына, данына чакырыучы Аллага тейешлечя кылыныгыз диб ўгетлядек, öндядек, сезгя жалындык. [13] Шунар кюря без туктаусыз Аллага тау итябез, сез

шул бездян эшеткян Алла сюзен кабыл алыб, аны кеше сюзе итеб кня тӧгӧл, ӓммя Алла сюзе итеб кабыл алдыгыз, чыннаб ул шулай да, ул сез ышаныучыларда кылыб тороучы.

Зач.266 14 Сез шул, туганнарым, Христосъ Іисуста тороб Іудеядяге Алланын жыйыннарына ошашыучылар булдыгыз, андагылар іудейлярдян кысанныкка тюзеб ӱткяргян кюк, сезгя дя ӱз тыумаларыгыздан шулай тюзяргя туры килде. 15 Алар Ходай Іисусны да, Анын пагамбярлярен дя ӱтерделяр, безне дя кыуыб чыгардылар, шулай итеб Аллага да жараулыны кылмыйлар, бар кешелярге дя карышы киляляр. 16 Алар жат калыкларны коткарырыр ӧчӧн аларга сӧйлярге безгя дя кумачаулык итяляр, шулай алар ӱзляренен жазык сауытларын жалан тутыра киляляр, ӓммя аларга азакта Алланын ачыуы жакыннаша киля. 17 Эй туганнар, без кюнелебез белян тӧгӧл, кыска багытка гна жӧзӧбез белян сездян айырылыб тороб, бигряк тя сагыныб, сезнен жӧзлярегезне бигряк тя кюрергя тырыштык. 18 Шунар кюря сезнен жаныгызга барасыбыз килде; мин, Павелъ, бер ничя табкыр сезгя килергя уйладым, ӓммя сатана безгя кумачаулык жасады. 19 Кем сун безнен ӧмӧтӧбез, жя сӧйӧнӧчӧбез, жя макталыунын даны? Ходайыбыз Іисусъ Христосъ килгян чагында Анын алдында сез тӧгӧл ме сун?

3-нче бюлем

Зач.267 20 Сез шул безнен даныбыз да, сӧйӧнӧчӧбез дя.

1 Шунар кюря без башка тюзя алмыйчы, Афинада ӱзебез гня каласы иттек тя. 2 Сезнен жанга Христоснын арыу хабярен сӧйлягян чакта безнен белян бергя эшляӱче туганыбыз, Алланын кызмятчесе Тімофейне жибярдек, сезне ышаныуда ныгытыб, тынычландырсын диб, 3 бу кӧйӧклярдя беряӱ дя какшамасын диб. Безгя шулай тейеш икянен сез ӱзегез дя белясез шул. 4 Без сездя булган чакта да, азабка туры килербез диб сезгя алдан ӓйткян эйек, шулай килеб чыкты да, сез мыны белясез. 5 Шунар кюря мин дя бютян тюзя алмыйчы, сезнен ышаныуыгыз турысында белергя жибярдем, сынаучы сезне ничек сынаса да, безнен кызмятебез

жукка чыкмасын тагы диб. 6 Казер сездян Тімофей кайтыб, сезнен ышаныуыгыз, сӧйӧўлегегез турында арыу хабяр алыб кайткач, сез безне жалан арыу кюнел белян исегезгя тӧшӧрӧб, безнен сезне кюрясе килгян кюк, сез дя безне кюрясегез килгянне äйткяч, 7 без ўзебез кӧйӧктя, жӧдяўлектя булсак та, эй туганнар, сезнен ышаныуыгыз какында сезнен белян кюнелебез тынычланды. 8 Сез Ходайда нык торганда, без дя тере торабыз шул.

Зач.268 9 Сезнен ӧчӧн, сезнен какта Алла алдында без сӧйӧня торган бар сӧйӧнӧчляр ӧчӧн без Аллага нейдей тау итеўляр китерейек? 10 Сезнен жӧзӧгӧзне кюреб, сезнен ышаныуыгызда житмягян жирлярегезне тутырыр ӧчӧн тӧн-кӧн тырышыб кюнелдян теляк итябез. 11 Атабыз Алла Ўзе дя, Ходайыбыз Іисусъ Христосъ та жулыбызны сезгя таба ынгайласын ыйы. 12 Сезне Ходай ўз арагызда да, бар кешелярне дя сӧйӧўлеккя тулыландырсын ыйы, без сезне сӧйӧўлеккя тулыланган кюк, мулы белян тулыландырсын ыйы. 13 Ходайыбыз Іисусъ Христосъ бар изгеляре белян килгян чагында, Атабыз Алла алдында сезнен кюнеллярегезне бозолоусыз, изгелектя ныгайтсын ыйы. Аминь.

4-нче бюлем

Зач.269 1 Эй туганнар! Христосъ Іисусъ какына сезгя жалынабыз, сездян соройбыз: сез Аллага ничек жараулы булыр ӧчӧн нейляр кыларга икянне бездян эшетеб кабыл алгач, аны бигряк тя житешеб кылсагыз ыйы. 2 Ходай Іисустан без сезгя нейдей бойороклар биргянне сез бит белясез. 3 Алланын ирке сезне арыуландырыу шул, шунар кюря сез азгынныктан тыйылыб, 4 äр-кайсыгыз ўзенен сауытын, тянен изгелектя, кадерлектя саклясын. 5 Äммя Алланы белмей торган жалган деннеляр кюк, тян няпесляреня биренмягез. 6 Сез ўз туганыгыз белян законга карышы да, малга биренеў кылмышы белян дя кыйланмасагыз ыйы. Ничек без элек тя сезгя таныклаб сӧйлягянчя, алай кылыныучыга ўч кайтарыучы Ходай. 7 Безне шул Алла шакшылыкка тӧгӧл, äммя изгелеккя чакырган. 8 Шунар кюря буйсынмаучы, кешегя тӧгӧл, äммя безгя Ўзенен Святый Тынын биргян Аллага

буйсынмый. 9 Туганнарны сӧйӧӱ турында сезгя жазыу да киряк тӧгӧлдер, сез ӱзегез дя бер-берегезне сӧяргя Алладан ӧйрянгян шул. 10 Бӧтӧн Македонія жире буйлаб бар туганнар белян дя сез шулай кыйланасыз да. Жалыныб айтябез сезгя, туганнар, тагы да житешеӱле булыгыз, 11-12 тыштагылар алдында арыу кылмышта булыб, бер нястя дя киряксенмяс ӧчӧн, без сезгя кушканча, тыныч жяшяб, ӱз эшлярегезне ӱз кулларыгыз белян эшляб тороргa кюнел бирeб тырышыгыз.

Зач.270 13 Эй туганнар! Ӧмӧтӧ жук кешеляр шикелле кӧйӧнмясенняр диб, мин сезгя ӱлгян кешеляр турысын белдермей калдырасым килмей. 14 Без Іисусъ ӱлгяч, терелеб торганга ышанабыз; Анар ышаныб ӱлгян кешелярне дя Алла Анын белян терелтеб китерер. 15 Мыны без сезгя Ходай Ӱзе айткянне китереб айтябез; Ходайнын икенче килеӱеня чаклы ӱлмей калганнарыбыз ӱлгян кешелярдян элеке бармабыз. 16 Ходай Ӱзе зур тауыш белян, Архангелъ тауышы белян, Алла быргысынын тауышы белян кюктян килер, Христоска ышаныб ӱлгян кешеляр элеке терелеб торорлар. 17 Аннары ӱлмей калганнарыбыз алар белян бергя болот östöня ауага Ходай карышысына алынырбыз, алынгач, Ходай белян жалан бергя торорбыз. 18 Шушындый сюзляр белян бер-берегезне тыныchландырыб торогоз.

5-нче бюлем

Зач.271 1 Эй туганнар! Багытлар, куйылган кönняр турысында сезгя жазыу киряк тя тӧгӧл; 2 сез мыны ӱзегез дя айырмачык белясез, Ходайнын кönö тönня бур килгян кюк килер. 3 Кайчан: татыулык, куркынычсызлык, дирерляр, шунда кинят кня аларга харяб булыу килеб житяр, бу эчендя ауыры бар катынга сызланыу килеб житкян кюк булыр, качыб котола алмаслар. 4 Аммя, эй туганнар, сезгя бу кön бур кюк килеб житяргя сез карангыда тӧгӧл шул. 5 Сез шул барыгыз да жакты уллары, кön уллары; без тön, карангылык уллары тӧгӧл. 6 Шулай бютянняр шикелле жоклаб жатмыйык, аммя уяу тороб, айык акылда булыйык. 7 Жоклаучылар тönня жоклойлар ич, эчкечеляр дя тönня артыгын

эчяляр. 8 Без кӧн уллары булганга кюря, ышаныунын, сӧйӧўлекнен тимер бӧркяўеня кейенеб, ӧмӧт тотоб котолдора торган бюрек кейеб, айык акылда булыйык.

Зач.272 9 Безне шул Алла ачыуга диб билгелямягян, ӓммя Ходайыбыз Іисусъ Христосъ арткылы котолоу алырга диб билгелягян. 10 Без уяу торабыз мы, жоклойбыз мы, без Христосъ белян бергя жяшяр ӧчӧн Ул безнен ӧчӧн ўлгян. 11 Шунӷар кюря бер-берегезне ўгетляб торогоз, берегез икенчегезне ӧйрятеб торогоз, сез шулай эшлейсез дя. 12 Тагы, туганнар, сездян соройбыз: сездя кызмят итеўчелярне, Ходайда тороучы чиркяў башлыкларын, сезгя акыл биреўчелярне кадер итегез; 13 эшляре какына аларны бигряк тя сӧйӧўлек белян саннагыз, ўз арагызда да татыу булыгыз.

Зач.273 14 Тагы да, туганнар, сезгя ўтенябез: тыйнаксызларга акыл бирегез, ӓлсез кюнӷеллелярне жыуатыгыз, кӧчсӧзлярне ныгайтыб торогоз, барысына да озак тюземне булыгыз. 15 Карагыз, беряўгя дя усаллыкка усаллык белян кайтармагыз, ӓммя бер-берегезгя дя, бютяннярга дя арыулык кна эзлягез. 16 Ӓр-кайчан сӧйӧнӧгӧз. 17 Туктаусыз теляктя торогоз. 18 Барысы ӧчӧн дя тау итегез, Іисусъ Христоста сезгя Алланын ирке шулай шул. 19 Тынны сюндермягез. 20 Пагамбярлекне кимсетмягез. 21 Барын да сынаб карагыз да, жакшысына тотоногоз. 22 Ӓр-тӧрлӧ усаллыктан тыйылырга тырышыгыз. 23 Татыулык Алласы Ӱзе бар тулылык белян дя сезне арыландырсын ыйы, сезнен тынигыз да, жанигыз да, тянегез дя бӧтӧнняй тулы кӧйӧ Ходайыбыз Іисусъ Христосъ килгян чакка бозолоусыз саклансын ыйы. 24 Сезне Чакырыучы туры, Ул мыны кылыб житкезер. 25 Эй туганнар, безнен ӧчӧн дя теляк итегез. 26 Бар туганнарны да изге ўбеў белян ўбеб, кюнӷелдян жаратыуымны житкезегез. 27 Ходай исеме белян сезгя кисятеб ӓйтямен: бу жибяргян жазыуны бар изге туганнар да укыб чыксыннар. 28 Ходайыбыз Іисусъ Христоснын дяўляте сезнен белян. Аминь.

СВЯТЫЙ АПОСТОЛЪ ПАВЕЛНЫН ФЕССАЛОНИКА КЕШЕЛЯРЕНЯ ЖИБЯРГЯН ИКЕНЧЕ ЖАЗЫУЫ

1-нче бюлем

Зач.274 1 Павелъ, Силуанъ, аннары Тімофей Атабыз Аллада да, Ходайыбыз Іисусъ Христоста да булган Фессалоникадагы жыйынына жазалар. 2 Атабыз Алладан да, Ходайыбыз Іисусъ Христостан да сезгя дяўлят тя, тынычлык та булсын. 3 Эй туганнар! Ăр-кайчан без сезнен өчөн Аллага тау итяргя тейешле, шулай дөрөс тя, сезнен шул ышаныуыгыз ўся киля, арагызда барыгызнын да бер-берегезгя сөйөўлегегез дя кюбяя киля. 4 Шунăр кюря без бар кыуылыуларда, көйөклярдя тороб ўткяргян сезнен тюземнегегез, ышаныуыгыз белян, Алланын жыйыннарында сезнен ўзегез белян дя мактанабыз. 5 Бу Алланын гадел хокӧме булырын кюрсятя, сез Алла Падшалыгына тейешле булыр өчөн азабларга тюзясез дя. 6 Сезгя көйөк китереўчелярга кайгы белян кайтарыу Алла алдында гаделлек шул. 7 Ăммя сез көйөккя тюзеўчелярга, Ходай Іисусъ кюктян Ўзенен чиреўляренен пяриштяляре белян жалкыннаныб торган ут эчендя кюренгян чакта, безнен белян бергя сөйөнөч кайтарыу гадел. 8 Шул багытта Алланы белмягяннярга, Ходайыбыз Іисусъ Христоснын арыу хабяреня баш салмаганнарга ўч кайтарыр. 9-10 Безнен таныклауыбызга сез ышанганча, Ул Ўзенен изгелярендя данналырга диб, Анăр ышаныучыларнын барысында ул Көндя ис китярлек булыб кюренергя диб килгяндя, алар Ходайнын жӧзӧннян,

Анын кыуатлы данныннан айырылыб, кыйынга тейешле булыб, мянге-гя харяб булырлар. 11-12 Шунăр кюря без, Аллабыз сезне чакырылган эшегезгя жараулы итеб, ăр-бер ышаныу эшен кыуат белян кылыб житкезсен диб, Ходайыбыз Iисусъ Христоснын исеме сездя данналсын, Аллабызнын да, Ходайыбыз Iисусъ Христоснын да дяўляте буйынча, сез дя Анда данналсагыз ыйы диб, жалан сезнен өчөн теляк итябез.

2-нче бюлем

Зач.275 1 Эй туганнар! Сезгя жалбарабыз: Ходайыбыз Iисусъ Христоснын килеўе турысында, тагы Анăр безнен жыйыныуыбыз турысында 2 тын белян ме, сюз белян ме, жя, бездян килгян, диб äйтелгян жазыулар белян ме, Христоснын көнö килеб житя инде диб тынычсызланыб, кюнелегезне какшатмагыз. 3 Бер кем дя сезне алдандырмасын: башта Алладан бизеўлек килгенче, жазык кешесе, каряб булыу улы килеб кюренмейче, ул көн килмяс. 4 Аллага карышы килеўче, ўзен барыннан да жугары кютяреўче ўзен Алла диб, изге диб атаб, Алла кюк, Алла жортона кереб утырыр. 5 Исегездя тöгöл ме, мин сездя чагымда да мыны сезгя äйткян эйем. 6 Анăр ўз багытында ачылырга ней ирек жибярмягянен казер сез белясез шул. 7 Законсызлыкнын жяшерене инде эшляб тора шул, тик казер тотоб тороучы арадан алынмыйчы ул булыб житмяс. 8 Шул чакта законсызланыучы ачылыр, аны Ходай Iисусъ Ўзенен ауызындагы тыны белян ўтерер, Ўзенен килеўенен данны кюренеше белян жукка чыгарыр; 9 шул кешенен килеўе сатана кыуаты буйынча äр-төрлö көч белян, билгеляр белян, жалган кодрятляр белян, 10 каряб булыучылар өчөн äр-төрлö дöрöссöзлöк алдандырыуы белян булыр, бу ўзляре котолоу өчөн чыннык сöйöўлеген кабыл алмаганнары өчөн каряб булыучылар. 11 Шунын өчөн Алла аларга адашыулык кылыуны жибярер, шулай алар жалганга ышанырлар; 12 шунын белян чынныкка ышанмыйчы, дöрöссöзлöкне сöйöўчеляр барысы да хокömгя төшярляр.

Зач.276 13 Äммя без сезнен өчөн жалан Аллага тау итяргя

тейеш, Ходайга сӧйӧклӧ туганнарым, сезне шу Алла баштанук Тыннын арыуландырыуы арткылы, чынныкка ышаныу белян котолорга сайлаб алган. 14 Ходайыбыз Іисусъ Христоснын данына житешеўле булсыннар диб, безнен арыу хабяр сӧйляўебез арткылы Ул сезне чакырыб алды. 15 Шулай, туганнар, сюз белян ме, безнен жибяргян жазыу белян ме сез нейгя ӧйрянгян, шунар тотоноб ныкторогоз. 16 Ходайыбыз Іисусъ Христосъ Узе дя, безне сӧйӧб, дяўлятеня арыу ӧмӧт тотоулык белян мянге тынычлыкны биреўче Атабыз Алла да 17 сезнен кюнеллярегезне тынычландырсын, ӓр-тӧрлӧ сюздя дя, арыу эштя дя сезне ныгайтсын ыйы.

3-нче бюлем

1 Шулай, туганнар, Ходайнын сюзе сездя таралган кюк, бютян жирдя дя таралыб данналсын ыйы диб безнен ӧчӧн теляк итегез; 2 без тыйнаксыз, жаман кешелярдян котолсак ыйы, ышаныу барысында да тӧгӧл шул. 3 Ӓммя Ходай ышанычлы, Ул сезне ныгайтыб, жаманнан саклар; 4 без сезгя кушканны сез кыласыз диб, кыларсыз да диб, без Ходайда сезгя ышанабыз. 5 Ходай сезнен кюнеллярегезне Алланы сӧйӧўлеккя дя, Христоснын тюземнегеня дя ынгайласын ыйы.

Зач.277 6 Эй туганнар, сезгя Ходайыбыз Іисусъ Христосъ исеме белян кушыб ӓйтябез, сез бездян алган бойорок буйынча тормойчы, тыйнаксыз кыйланыучы ӓр-бер туганнан читкя китегез; 7 сез безгя ничек ошарга тырышырга икянне сез шул ўзегез дя белясез, без бит сездя тыйнаксызланмадык; 8 бер кемнен дя икмяген бушка ашамадык, ӓммя сезгя жӧк булмас ӧчӧн кӧн-тӧн эшляб кызмят иттек; 9 бу безнен сезгя какыбыз жуктан тӧгӧл, ӓммя безгя ошарга тырышсыннар диб, ўзебезне сезгя кючергечкя кюрсятясе иттек. 10 Без сездя булган чакта мыны сезгя кушыулык итеб ӓйттек: кемнен эшлясе килмяся, ул ашамасын да. 11 Ӓммя эшетябез: сездя кайберляре тыйнаксыз кыйланалар, бер ней дя эшлямейляр, ӓммя жукка сагышланалар. 12 Мындыйларны ўгетлейбез, Ходай Іисусъ Христосъ какына димняб ӓйтябез: алар тыныч кна эшляб,

ўз икмяклярен ашасыннар. 13 Сез, туганнар, жакшы эш кыла тороб моңаймагыз. 14 Ӓгяр кем шушы безнен жибяргян жазыуыбыздагы сюзлярне тыңнамаса, аны билгегя тотогоз, аны оялтыр өчөн анын белян жөрөшмягез; 15 тик аны дошман диб санамагыз, ӓммя туган итеб, анар акыл биregez. 16 Татыулык Ходайы Ўзе бар турдан да, ӓр-кайчан да сезгя татыулык, тынычлык бирсен, Ходай сезнен барыгыз белян дя. 17 Чын кюңелдян жаратыуымны мин, Павелъ, ўз кулым белян жазамын, бу билге булыб бар жазыуларымда да мин шулай жазамын: 18 Ходайыбыз Ісусъ Христоснын дяўляте сезнен барыгыз белян дя. Аминь.

СВЯТЫЙ АПОСТОЛЪ ПАВЕЛНЫН ТІМОФЕЙГЯ ЖИБЯРГЯН БЕРЕНЧЕ ЖАЗЫУЫ

1-нче бюлем

Зач.278 1 Коткарыучыбыз Алла, ӧмӧт тотканыбыз Ходай Іисусъ Христосъ кушкан буйынча Іисусъ Христоснын апостолы булган Павелдан 2 ышаныу буйынча чын улым Тімофейгя: Атабыз Алладан, Ходайыбыз Іисусъ Христостан дяўлят, изгелек, тынычлык булсын. 3 Мин Македоніягя киткян чакта, сине Ефеста тороб кайберяўлярне ўгетлярга сорадым, алар бютянгя ӧйрятмясенняр диб, 4 алар якеятляр белян, очо жук тыумышларны тикшереўляр белян багытларын уздырмасыннар диб, былар бит бик оло ирешеўляр кертяляр, ямма ышаныу белян Алланы белеўлек тӧгӧл. 5 Ямма минем ўгетляўемнен маганясе бу: таза кюнел белян, арыу уй белян сӧйӧўлек, жумачылыксыз ышаныу; 6 шуннан кайберяўляр бизеб, буш сюз сӧйляшеўгя ауышканнар; 7 алар законны ӧйрятеўчеляр буласылары киля, ямма ней яйткяннярен аннамыйлар, ней ныгытканнарын дя белмейляр.

Зач.279 8 Ямма без белябез, ягяр кем законны тейешлечя тотса, законъ арыу; 9 законъ гадел кеше ӧчӧн куйылмаганны, ямма законсызлар ӧчӧн, буйсынмый торганнар ӧчӧн, таза тӧгӧлляр, жазыклылар ӧчӧн, бозоклар, шакшылар, ата-аналарын рянжетеўчеляр ӧчӧн, кеше ўтереўчеляр, 10 азгыннар, ирляр белян ирляр жатыучылар ӧчӧн, кеше урлаучылар, ялякчеляр, терлекляр белян жатыучылар ӧчӧн, алдаучылар, биргян багадяне бозоучылар, дӧрӧс ӧйрятеўгя карышы килеўчелярнен барысы ӧчӧн куйылган

шул; 11 бахетле Алланын мина ышаныб табшырган данныклы арыу хабяре буйынча без шуларны белябез.

Зач.280 12 Ходайыбыз Иисусъ Христоска мина кыуат биргяненя тау итямен, Ул мине ышанычлы итеб санаб, шушы кызмяткя билгеляде; 13 мине, башта курлаучыны, кыуыучыны, кимсетеучене, белмягяннектян, ышанмаганныктан шулай кыйланганыма кюря Ул мине жарлыкады. 14 Ходайыбыз Иисусъ Христоснын дяуляте Иисусъ Христоска ышаныулык, сöйöулек арткылы мулы белян миндя ачылды. 15 Христосъ Иисусъ жазыклыларны коткарыр öчön дöньягя килгян диб äйтелгян сюз дöрöс тя, аны ышаныб кабыл алырга тейеш тя; шул жазыклылар арасында инг элекесе мин. 16 Иисусъ Христосъ Ўзенен озак тюзеулеген инг элеке миндя кюрсятте, Анар ышаныб, мянге тормошно аласыларга кючергеч итеб, Ул мине жарлыкады. 17 Гумерляр Падшасы, белемнедян белемне, ўнгярмей торган, кюренмей торган бер гня Аллага дан, кадер булсын гумердян гумергя. Аминь.

Зач.281 18 Эй улым Тімофей, синең турда булган пагамбярлек сюзляренен исябе буйынча, сина шундый кушыулык бирямен, син шул сюзляр белян кюнешеб, арыу кöряшче шикелле, кöряш алыб барсаң ыйы. 19 Арыу кюнелляре белян ышаныулары булыб та, быларны кире кагыб, кайберяулярнен ышаныу корабелляре жимерелде; 20 мындыйлар Именей белян Александръ, алар Аллаы курламаска öйрянсенняр диб, аларны мин сатанага бирдем.

2-нче бюлем

Зач.282 1 Шулай барыннан да элек теляк итеуенне, иняleуенне, жалбарыуынны, бар кешеляр öчön дя тау итеуенне соройом, 2 падшалар öчön, тагы бар башлыклар öчön; безгя тыныч, болганышыусыз, äр-törлö арыулыкта, тазалык белян тормошобызны ўткязер öчön; 3 Коткарыучы Аллабызга шул арыу, жараулы шул; 4 Анын бар кешелярне дя чынныкны белеугя китереб, котолдорасы киля. 5-6 Алла бер, кешеляр белян Алла арасында тороучы Кеше дя бер; Ул барын да жолоб алыр öчön

Ўзен биреўче Іисусъ Христосъ; ўз багытында таныклау шушылай булды, 7 шул таныклау какына мин, Христосъ какына чынны айтямен, жалганнамыйым, жат калыкларны ышаныуга, чынныкка өйрятер өчөн апостолъ итеб куйылганым да. 8 Шулай ар-бер жирдя ирлярнен ачыу тотмойчы, шиклянмейче таза кулларын кютяреб, теляк китереўлярен соройом. 9 Шулай ук катыннар да, килешлечя кейенеб, оятны белеб, таза акылда тороб ўзлярен матурласыннар, аммя чяч ўреўляре белян, алтын, кыйбатлы ташлар, кыйбатлы кейемняр белян төгөл; 10 аммя ўзлярен арыу кадерлелеккя адарынган катыннарга килешлечя арыу эшляр белян. 11 Катын бар турдан да буйсыныб, дяшмей тороулыкка өйрянсен; 12 аммя катынга өйрятергя, иреня баш булырга рөксят итмейем, дяшмей торорга тейеш. 13 Адамъ алдан булдырылган шул, аннары Ева; 14 Адамъ алданмаган, аммя катын алданыб, жазыкка жыгылган. 15 Алай да ягяр ышаныуда, сөйөўлектя, изгелектя, таза акылда торса, балалар китереў арткылы котолор.

3-нче бюлем

Зач.283 1 Ышанычлы сюз бар: ягяр кемнен епископъ булысы киля икян, арыу эш кыласы итя. 2 Тик епископъ бозолоусыз, бер гня катыннын ире, айык, таза акылдагы, арыу кылмышлы, гадел, читтян килгяннярне сөйөўче, өйрятя белеўче булырга тейеш; 3 эчкече булмасын, сугышыучы, жарсыу, мал сөйөўче булмасын, аммя көйлө, татыулыкны сөйөўче, акчага биренмей торган, 4 ўзенен жөртон жакшы караб тороучы, балаларын кадерляб, тынналучан итеб тота белеўче булсын. 5 Ягяр кем ўз жөртон да караб торорга жюне житмяся, ул Алланын арыу жыйыны өчөн сагышлык тотар мы? 6 Олосомакланыб, шайтан белян бергя айыбланырга туры килмяс өчөн, денгя жаңа кергянняр арасыннан булмасын. 7 Тиргяшкя туры килеб, шайтан ауына кермяс өчөн шулай ук бютян кешелярдян да анын турысында арыу таныклык булырга тейеш. 8 Діаконнар да шулай ук гадел, сюзендя тора торган, аракыга биренмей, малга кызыкмый торган, 9 деннен жяшереген таза кюнел-

ляренда саклый торган булырга тейеш. 10 Мындыйларны да алдан сынаб карарга киряк, ägяр бозолоусыз булсалар, кызмяткя алырга була. 11 Шулай ук аларнын катыннары да гадел, älякчян тöгöл, айык, бар турдан да ышанычлы булырга тейеш. 12 Діаконъ бер гня катыннын ире, üзенен балаларын, жöртон жакшы караб тороучы булырга тейеш. 13 Жакшы кызмят итеüчеляр üзляреня инг жугары урынны äзерлейляр шул, Христосъ Іисуска ышаныуда зур кыйыулыклары да булыр.

Зач.284 14 Озакламый синa килерем диб öмöтлянеб, быларны синa жазамын; 15 ägяр озакласам, Алла жöртонда син ничек эшляргя икянне белсен диб. Алла жöрто дигяне тере Алланын жыйыны, чынныкны ныгайтыучы багана. 16 Изге тормошнон жяшерене бик зур. Алла тяннянеб кюренгян, Тын белян Üзенен дöрöслöгöн белдергян, Üзен пяриштялярга кюрсяткян, калыкларга сöйлянгян, дöньядя ышаныу белян кабыл алынган, дан белян кюккя кютярелгян.

4-нче бюлем

1 Тын бит аннарлык итеб äйтя: азакы багытта кайберяüляр жангыштырыучы тыннарга, женняр öйрятеüеня аң салыб ышанудан бизярляр; 2 оятлары беткян жалган сюзлелярнен жумалаулары арткылы, 3 öйлянергя-китяргя жарамый диб, тагы, чынныкны белеüче ышаныучыларга тау итеб ашатмас öчöн Алла ней булдырган, шуны ашамныкка тотарга жарамый диб äйтеüчеляр арткылы алданырлар, дей.

Зач.285 4 Алланын бар булдырган нястяляре дя äйбят, ägяр тау итеб ашарга тотола икян, берсен дя айыбларлык тöгöл; 5 алар шул Алла сюзе белян, иман белян арыуланалар. 6 Туганнарга шушыны аннатыб, аларны ден сюзе белян туйдырыб, üзенң тотканга арыуга öйрятеү белян Іисусъ Христоснын арыу кызмятчесе булырсын. 7 Жараусыз öйрятеүлярдян, карчыклар äкеятляреннян читкя борол, арыу кылмышка üзенне кюнектер. 8 Тянне кюнектереү äзгя пайдалы, ämмя казерге тормошка да, буласы тормошка да бирелясе дигянне üз кюнелендя тотоб, изге кылмыш белян тороу барысына да пайдалы. 9

Бу сюз чын, аны ышаныб кабыл алырга тейеш. 10 Без тере Аллага, бар кешелярне дя, бигряк тя ышаныучыларны Коткарыучыга өмөт тотканыбызга кюря, тырышабыз да, курлык сюзлярга дя чыдыйбыз. 11 Син шушыны сөйляб, шунар өйрят. 12 Жяш диб сине беряў дя сансыз итмясен эйе; сюзең белян, тормошоң, жакшы тынышың белян, ышаныуың, таза тороуың белян ышаныучыларга кючергеч бул. 13 Мин баргынчы, син княгиляр укыб, ўгетляб, өйрятеб тор. 14 Алдан айтелгян буйынча, сина кул салыу арткылы бирелгян, синдя тора торган священниклек дяўлятен кимсетмяся тырыш. 15 Шушы турда сагышлан, шушы дяўляття тор, житешлеген барысынын да кюзеня кюренсен эйе. 16 Өйрятеўдя ўзеня дя аң сал, шунын белян жалан эшляб тор, шушы эш белян син ўзенне дя, сине тыңнаучыларны да коткарырсың.

5-нче бюлем

1 Картларны тиргямя, аммя ата итеб ўгетляб айт, ўзеннян кечелярне туганнар кюк итеб өйрят; 2 карчыкларны аналар кюк, кызларны ар-төрлө таза акыл белян сеннелярең кюк итеб ўгетля, 3 дөрөс торган тол катыннарны кадерля. 4 Әгяр бер-бер тол катыннын балалары, жя онокларының була икян, алар иң элеке ўз жамагатларын саннарга, тыудырыучыларына тейешлечя кадер кюрсятергя өйрянсенняр, Аллага шулай жараулы шул. 5 Жангыз башы тороучы дөрөс тол катын, Аллага өмөт тотоб, көн-төн иман укыб, теляктя тора; 6 аммя тян нянесен жаратыучы тере көйө ўлгян. 7 Аларга шушыларны аннат, алар бозолоусыз булсыннар. 8 Әгяр кем ўзенекеляр өчөн, бигряк тя өйөндягелярне өйрятер өчөн сагышланмый икян, ул деннян таныучы, ышанмаганнан да начарырак. 9 Тол катынны сайлаганда алтмыш жяштян ким булмасын, бер гня ирнен катыны булыб, 10 жакшы эшляре белян билгеле булсын; әгяр ул балаларын арыуга өйрятькян булса, читтян килгяннярне кабыл алган булса, изгелярнен аякларын жыуган булса, жөдяўлярга булышкан булса, әр-төрлө жакшы эшкя кюнел биргян булса, сайла.

Зач.286 11 Жяш тол катыннарны сайлама, алар шул Христоска карышы кубшылыкка биренеб, кеяўгя китяселяре киля.

12 Алар баштагы ышаныуларыннан бизгянгя кюря, айыбланырга тейешле булалар; 13 шунын өстөня алар эшсез булганга кюря, өйдян өйгя жөрөргя өйряняляр, шулай итеб эшсез гня булмыйлар, әммя сюз болгатыучы, сынаб жөрөўче, киряк төгөлне сөйляшеўче булалар. 14 Жяш тол катыннар кеяўгя китсенняр, алар балалар тыудырсыннар, жортларын караб торсоннар, дошманга усал сюз әйтергя жул куймасыннар, диб уйлыймын. 15 Кайберляре инде сатана эзеня боролдолар да шул. 16 Бер-бер ышаныучы ир, ышаныучы катыннын тол туганнары бар икян, аларга булышсын, жыйынга аларны жөк итяргя киряк төгөл, жыйын дөрөс тол катыннарга булышсын. 17 Тейешлечя башкарыб тороучы пресвитерларга мулы белян кадер кюрсятергя киряк, бигряк тя сюз сөйляб, өйрятеў кызмятен итеўчеляреня. 18 Жазыу да әйтя шул: ашлык суга торган ўгезнен ауызын бяйляб тотма, эшляўче ўзеня тейешле бюлякне алырга тейеш, диб. 19 Пресвитерны айыблауны, ике жя өч таныкчы булмаса, кабыл алма. 20 Жазыкланыучыларны бөтөнөсө алдында әйтеб кюрсят, бютянняр дя куркыныб торошло булсын. 21 Алла алдында, Ходай Iисусъ Христосъ алдында, сайланган пяриштяляре алдында сина инялеб әйтям, шушы алда әйткяннярне бер кимчелексез саклаб тот, ўз кюнел няпесең дигянчя гня бер ней дя кылма.

Зач.287 22 Бер кемгя дя ашыгыб кна кул салма, бютян кешенен жазыкларына керешеўле булма, ўзенне таза көйө сакла. 23 Мыннан ары бер сыу гна эчмя, әммя әзряк кызыл аракы да эч, бу синең ашказаның өчөн, жалан була торган чирляреңе өчөн. 24 Кайсы бер кешелярнен жазыклары кюренеб тора, алар туры ук айыбланыуга алыб баралар, кай берляренен сунъяннан ачылалар. 25 Шунын шикелле арыу эшляр дя ачык, әгяр алай булмаса да, жяшеренеб кала алмыйлар.

6-нчы бюлем

1 Кеше кулы астында тороучы коллар, тейешлечя кадер итеб, ўзляренен эялярен саннаб торсоннар, Алла исеменя дя, өйрятеўгя дя курлык булмасын диб. 2 Эяляре ышаныучылар

булсалар, колларны санга сукмыйчы гна тотарга тейеш төгөл, алар шу туганнар, әммя коллар бигряк тя эяляреня кызмят итяргя тейеш, алар шу ышаныучылар, сөйөклөляр, аларга жакшылык кылыучылар. Шушынар димняб өйрят. 3 Кем бютянгя өйрятеб, Ходайыбыз Іисусъ Христоснын таза сюзляреня, арыу кадерлеккя өйрятеўдя булмаса, 4 андый кеше олосомак, бер неў дя белмей, әммя сюз ирештереў, көряшеў няпесе белян бозолган, алардан шул көнчөлөк, ирешеўляр, усал сюзляр, жаман шиклянеўляр килеб чыга. 5 Чынныктан жырак торган кешеляр арасында бозолган уй белян бушка ирешеўляр чыга, кайсылары уйлыйлар: сауаблы тормош жирдяге байлыкны арттырырга кызмят итя диб; мындыйлардан читкя кит. 6 Сауаблы тормошта булганына тук булсаң - бу бик зур табыш. 7 Без шул дөньягя бер неў дя алыб килмядек, билгеле, мыннан бер неў дя алыб чыга да алмыйбыз. 8 Туйыныб тороргa ашамныгыбыз, кейяргя кейемебез булса, шунар тук булыйык. 9 Әммя байысы килеўчеляр сыналыуга да, ауга да туры киляляр, тагы бик кюб уйсыз, зыянны няпеслярга биреняляр; алар кешелярне читеннеккя туры китереб, каряб итяляр. 10 Бар усаллыкларнын да тамыры акча сөйөў шул, кайберяўляр шунар биренеб, ышаныудан ауышыб, ўз-ўзлярен кюб читеннеклярга туры китерделяр.

Зач.288 11 Син бит Алла мяндясе, мыннан кач, әммя дөрөслөктя, изге тормошта, ышаныуда, сөйөўлектя, тюземнектя, сабырлыкта житешеўле бул. 12 Ышаныунын арыу тырышлыгы белян тырыш, мянге тормошка тотоноб тор, син шунын өчөн чакырылган да, арыу таныклауны кюб танык чылар алдында таныкладың. 13 Барын да тере тотоучы Алла алдында, тагы Понтій Пилатъ карышында чынныкны таныклаган Іисусъ Христосъ алдында синя әйтеб калдырамын: 14 биргян бойорокно таза итеб, сюз әйтмяслек итеб, Ходайыбыз Іисусъ Христосъ килгенчегя чаклы тот. 15 Ул падшаларнын бер гня бахетле, кыуатлы Падшасы, башлыкларнын Ходайы мыны Ўз багытында ачар. 16 Бер гня Ўлемсез, жакынына бара алмаслык жактыда Тороучы, Аны кешеляр арасыннан беряў дя кюрмягян,

ӓммя кюря дя алмый, Анӈар кадер, тотоучылык булсын мянтегя. Аминь.

Зач.289 17 Бу гумердя бай тороучыларны ӱгетля, алар ӱз турларында жугары уйламасыннар, ышангышсыз байлыкларына ышаныб тормасыннар, ӓммя безне киняндереб, барын да мулы белян биреӱче тере Аллага ӧмӧт тотсоннар. 18 Алар жакшылык кылыб, сауаблыкка байысыннар, жумарт та, кеше белян жӧрӧшӧӱчян дя булыб, 19 мянге тормошка керер ӧчӧн, буласы тормошка арыу нигез итеб, ӱзляреня сауаблык байлыгы жыйсыннар.

20 Эй Тімофей! Пайдасыз буш сюзлярдян, жалган белемнеклярнен ирешеӱляреннян читкя боролоб, синӈа биргянне сакла; 21 андый эшкя биренеб, кайберяӱляр ышаныудан ауыштылар. Дяӱлят синеӈ белян булсын. Аминь.

СВЯТЫЙ АПОСТОЛЪ ПАВЕЛНЫН ТІМОФЕЙГЯ ЖИБЯРГЯН ИКЕНЧЕ ЖАЗЫУЫ

1-нче бюлем

Зач.290 1 Іисусъ Христостагы терелекне бирем дигян буйынча Алланын ирке белян Іисусъ Христоснын апостолы булган Павелдан 2 сөйөклө улым Тімофейгя: Атабыз Алладан, Ходайыбыз Іисусъ Христостан дяўлят, изгелек, тынычлык булсын. 3 Мин төб аталарымнан ук таза кюнел белян кызмят иткян Аллага тау итямен, ўземнен телякляремдя кöндöз дя, тöння дя туктаусыз сине иска аламын; 4 синең кюз жяшляренне исемя тöшöрöб, сөйöнöчкя тулыланасым килеб, сине кюрясем киля. 5 Синең жумачылыксыз ышаныуынны исемя китерям, бу ышаныу башта синең äбейең Лоидада, аннары синең анаң Евникада булды, ул синдя дя бар диб ышанамын. 6 Шунар кюря синең исеня тöшöрям: минем кул салыу арткылы синдя булган Алланын бюляген кайнарландырыб тор; 7 безгя шу Алла куркыулык тынын бирмяде, äммя кöчлöлöк, сөйöўлек, таза тороулык тынын бирде.

Зач.291 8 Шулай Ходайыбыз Іисусъ Христосны таныклаудан да, мин быгауда тороучыдан да оялма, äммя Алла кыуаты белян Христоснын арыу хабярен сöйляб, азабларга тюзеб тор. 9 Алла безне коткарыб, изгелеккя чакырыб алды, бу безнең эшляребезгя карата тöгöл, äммя Ўзенең ризалыгы белян Христосъ Іисуста гумерляр багытыннан элгяре безгя бирелгян дяўляте белян шул; 10 ўлемне жимереб, арыу хабяр сöйляў арткылы черемей тороулыкны, терелекне

кюрсяткян Коткарыучыбыз Иисусъ Христоснын кюренеўе белян казер шул ачылды. 11 Шунын өчөн дя мин ўгет сөйляўче итеб, апостолъ да, жат калыкларны өйрятеўче дя итеб куйылдым. 12 Шунын өчөн мин шушылай азабланамын да, әммя оялмыйым. Мин шу Кемгя ышанганымны белямен, мина бирмякче булганын азакы көнгя саклаб тороргa да Ул кыуатлы диб ышанамын. 13 Христосъ Иисуста ышаныу белян, сөйөўлек белян син миннян эшеткян таза өйрятеўнен ошашына тотон. 14 Сина биргян арыуны бездя жяшей торган Святый Тын белян сакла. 15 Бар Асія кешеляре дя мине калдырганны син белясең, алар арасында Фигеллъ белян Ермогенъ да. 16 Онисифорнын жортона Ходай изгелек бирсен, ул шу кюб табкыр мине тынычландырды, минем быгауларымнан да оялмады; 17 әммя Римдя булганда, бик тырышыб мине эзлягян, табты да. 18 Азакы көндя Ходайнын изгелеген табарга анар Ходай тейешле итсен; Ефеста ул мина кюбме кызмят иткянен син жакшырак белясең.

2-нче бюлем

Зач.292 1 Шулай, улым, Христосъ Иисуста булган дяўляття ныгай. 2 Кюб таныкчылар алдында син миннян неў эшеттең, шуны ышаныучы кешелярга сөйляб бир, алар да бютяннярне өйрятергя булдыклы булсыннар. 3 Иисусъ Христоснын арыу салдаты кюк, азабларга тюз. 4 Бер салдат та, башлыгына жараулы булыр өчөн, ўзен тормош сагышлары белян бяйлямей. 5 Әгяр беряў тырышса да, анын тырышыуы законсызлык белян булса, ул бюляклянеб данналмый. 6 Иген игеўдя эшляўче жимешляреннян беренче булыб ашаб кararга тейеш. 7 Мин неў әйткянне анна, Ходай сина бар турдан да аннаулык бирсен эйе. 8 Мин сөйлягян буйынча, Давидъ няселеннян чыккан, ўлгяненнян терелеб торган Ходай Иисусъ Христосны исендя тот; 9 Анын өчөн мин усал кеше кюк быгауда тороуга чаклы азабланам, әммя Алла сюзеня быгау жук. 10 Шунар кюря Христосъ Иисустагы котолоуны, мянге данны алсыннар диб, сайланганнар какына мин барысына да тюзямен.

Зач.293 11 Бу сюз дөрөс: ägяр без Анын белян ўлгянбез икян, Анын белян терелеб тя тороръбыз; 12 ägяр тюзсяк, Анын белян падшалык итярбез; ägяр тансак, Ул да бездян танар; 13 ägяр без ышанычлы төгөл икян, Ул ышанычлы булыб тора, Ўзеннян Ўзе таңа алмый. 14 Шушыны исляреня төшөрөб, сюз ирештереўгя керешмяскя Ходай алдында каты кисят, сюз ирештереў бер пайда да китермей шул, тик тыңнаучыларнын кюнеллярен биздеря. 15 Ўзенне Аллага жараулы итеб, оятка калмаслык эшляўче итеб, чыннык сюзен дөрөс сөйляб биреўче итеб кюрсятергя тырыш. 16 Ämмя киряк төгөл буш сюзлярдян читкя кит; алар шу бозоклокта тагы да бигряк житешеўле булырлар; 17 аларнын сюзляре начар чир кюк жяйелер, мындыйлар Именей белян Филитъ; 18 алар чынныктан бизеб, ўлгянняр терелеб тороуы булды инде диб, кай беряўлярнен ышаныуларын жимеряляр. 19 Ämмя Алланын ныk нигезе мындый пичят белян тора: Ходай Ўзенекелярне таныган, диб; тагы: Ходайнын исемен таныклаучы ăр-кем дөрөссөзлөктян бизсен, диб.

Зач.294 20 Ämмя оло жорттa тик алтын, жя көмөш сауытлар гна булмый, тагы агач, жя балчык сауытлар да була, бер төрлөляре кадерле нястягя, икенчеляре тюбянчек нястягя тотар өчөн. 21 Шулай кем мындый эштян таза булса, андый кеше кадерлек сауыты, арыуландырылган, Башкарыучыга кирякле, ăр-төрлө арыу эшкя жараулысы булыр. 22 Жяшўсмерлек няпесляреннян кач, ämмя дөрөслөккя, ышаныуга, сөйöўлекя тотоноб, барлык Ходай исемен дяшеб чакырыучылар белян таза кюнелдян татыулыкка тор. 23 Ансызлык белян, житмяс уй белян ирешеўлярдян читкя кит, алар талашыулык тыудырганны бел. 24 Ходай коллары талашырга тейеш төгөл, ämмя барысына да жагымны, öйрятеўчян, усаллыксыз булырга тейеш. 25 Карышы тороучыларны сабырлык белян öйрятергя киряк, аларга Алла чынныкны белдереб, тяўбягя китермяс микян диб, 26 алар шайтан ауыннан иркенгя чыксыннар диб; ул аларны ўз иркеня эляктереб алган шул.

3-нче бюлем

Зач.295 1 Шуны да бел: азакы көннярдя ауыр багытлар житяр. 2 Кешеляр ўзлярен гня сӧйӧўчян булырлар шул, акча сӧйӧўчян, олосомак, ўзляре дигянчя гня тороучан, усал сюзле, тыудырыучыларына буйсынмый торган, тау итмей торган, бозок, татыулыкны сӧймӧй торган, 3 татыуланышмый торганнар, жала жагыучылар, тыйнаксызлар, каты кюнеллеляр, арыулыкны сӧймӧй торганнар, 4 тотоб биреўчеляр, оятсызлар, кубшылар, Алланы сӧйӧўдян бигряк тямнене сӧйӧўчян булырлар; 5 тыш кюренештян изге тормошло, ӓммя эшляре белян аннан тантаннар. Мындыйлардан жырак тор. 6 Былар арасында шундыйлар да бар, алар кемнеклярен сиздермей гня ӧйлярга кереб, тӧрлӧ няпесляре артыннан жӧрӧўче, жазыкларга кереб баткан катын-кызларны алдандыралар; 7 ул катыннар ӓркайчан ӧйряняляр, бер кайчан да чыннык белемнегеня барыб житя алмыйлар. 8 Ничек Іанний белян Іамврий Моисейгя карышы торганнар, шулай былар да чынныкка карышы торалар, алар азгын уйлы, ышаныуда ӓлсез кешеляр; 9 ӓммя алар шуннан арыга житешя алмаслар, тегелярнен шулай булган кюк, быларнын да акылсызлыклары бӧтӧн калык алдында ачылыр.

Зач.296 10 Син мин ӧйряткянне тоттоң, тормошоннь, Аллага биренеўенне, ышаныуынны, жӧряклегенне, сӧйӧўлегенне, тюземнегенне минекечя иттең; 11 мин Антіохіяда, Іконіядя, Листрада кюргян кысанныкларны, азабларны син дя кюрденг; ул кысанныкларга мин тюзеб чыдадым, барысыннан да мине Ходай коткарды. 12 Христосъ Іисуста изге тормош белян торасы килеўчеляр барысы да шулай кысаннык кюрерляр. 13 Ӓммя жаман кешеляр, жалганчылар, ўзляре саташыб, бютяннярне дя саташтырыб, усаллыкка ӧлгӧрлянерляр. 14 Тик син ўзеня ӧйряткянне, синга ышаныб табшырганны, кемнян ӧйрянгяненне белеб нык тор. 15 Син кечкенядянюк Изге Жазыуларны белясең ич, алар синга Іисусъ Христоска ышаныб котолорга акыл, белемнек бирерляр.

Зач.297 16 Изге Жазыуларнын барысында Алла Тыны тора, алар ӧйрянер ӧчӧн пайдалы, дӧрӧссӧзлӧкнӧ ачыр ӧчӧн, дӧрӧслӧккя ынгайлар, гаделлекя ӱгетляр ӧчӧн, 17 Алла мяндясе житешеӱле, ӓр-тӧрлӧ арыу эшкя ӓзер тороучы булсын ӧчӧн.

4-нче бюлем

1 Шулай мин Алла алдында да, Ӱзенен кюренеб килеӱендя, Ӱзенен Падшалыгында ӱлгяннярга дя, терелярга дя хокӧм итясе Ходайыбыз Іисусь Христосъ алдында да сина кисятеб ӓйтямен: 2 ӱгет сюзе сӧйля, багытында да, багытсыз да ныктор, дӧрӧс тӧгӧлне ӓйтеб оялт, кисят, ӓр-тӧрлӧчя озак тюзеӱлек белян, ӱгетляӱ белян ӧйрят. 3 Шундый багыт та булыр шул, анда таза ӧйрятеӱне кабыл алмаслар, ӱз няпесляре телягянчя ӱзляреня алдандырыу сюзе сӧйляӱче ӧйрятеӱчеляр сайлаб алырлар; 4 колакларын чынны эшетеӱдян биздереб, ӓкеятлярга ауыштырырлар.

Зач.298 5 Ӓммя син бар турдан да сагайыб тор, кайгылы чагында тюземне бул, изге хабяр сӧйляӱ эшен кылыб, кызмятенне тутыр. 6 Мин инде корман буламын шул, минем дӧньядян кючяр багытым жакыннашты; 7 арыу тырышыулык белян тырыштым, тормошомны ӱткярдем, ышаныуны сакладым. 8 Мина казер дӧрӧслӧк венецы ӓзерляня, аны мина дӧрӧс тикшереӱче Ходай калдык кӧннӧ бирер, мина гна тӧгӧл, ӓммя Анын кюренеӱен сӧйгяннярнен барысына да бирер. 9 Минем жанга тиздян килергя тырыш.

Зач.299 10 Димасъ, казерге гумерне сӧйӧб, мине калдырды да Фессалоникага китте; Крискенть Галатіягя, Титъ Далматіягя китте, бер Лука гна минем белян. 11 Маркны ӱзен белян алыб кил, ул мина кызмят итяр ӧчӧн киряк. 12 Тихикны мин Ефеска жибярдем. 13 Килгян чакта фелоньны алыб кил, аны мин Троада да Карпта калдырган ыйым, книгялярне дя, бигряк тя кюннярен алыб кил. 14 Бакырчы Александръ мина кюб усаллык кылды, Ходай анар эшеня кюря кайтарсын; 15 аннан син дя саклан, ул безнен сюзляребезгя бик ныкарышы тордо. 16 Мин беренче жауаб тоткан чакта минем белян беряӱ дя жук ыйы, мине

бар да калдырдылар, бу аларга айыбка куйылмасын ыйы. 17 Минем арткылы арыу хабярне сöйляўне ныгайтыр öчöн, аны бар жат калыклар да эшетер öчöн Ходай мина килеб, мине ныгайтты, шулай итеб мин арыслан ауызыннан жолоб алындым. 18 Ходай мине яр-тöрлö усал эштян аралаб алыр да, Ўзенен Кюктяге Падшалыгы öчöн саклаб торор, Анар гумердян гумергя дан булсын. Аминь. 1

9 Акила белян Прискилланы да, Онисифоръ жортон да кюнелдян жаратыб каламын. 20 Ерастъ Коринфта калды, Трофимны чирле килеш мин Милитта калдырдым. 21 Кышка чаклы килергя тырыш. Сине Еввулъ, Пудъ, Линъ, Клавдий да, бар туганнар да кюнелдян жаратыб калалар. 22 Ходай Iисусъ Христосъ синен тыныҥ белян булсын. Сезнен белян дяўлят булсын. Аминь.

СВЯТЫЙ АПОСТОЛЪ ПАВЕЛНЫН ТИТКА ЖИБЯРГЯН ЖАЗЫУЫ

1-нче бюлем

Зач.300 1 Алла мяндясе Павелъ, Алланын сайлаганнары ышаныу буйынча, чынныкны белеб, арыу-гадел тормошка китереў өчөн, мянге терелеккя өмөт тотсоннар өчөн Іисусъ Христоснын апостолы булдым. 2 Сюзен ўнгяртмей торган Алла гумерляр багытыннан ук элеке шул мянге тормошно бирмякче булган. 3 Ўз багыты житкяч, Коткарыучы Аллабызнын кушыуы буйынча, Ўз сюзен ўгет сөйляўдя кюрсятеб, мина ышаныб табшырды. 4 Ышаныуыбыз бер булган чын улым Титка Атабыз Алладан да, Коткарыучыбыз Ходай Іисусъ Христостан да дяўлят, изгелек, тынычлык булсын. 5 Шунын өчөн мин сине Критта калдырдым да, кылыб житкермягян эшлярне син кылыб житкерсен диб, мин сина кушканча, бар калаларга да пресвитерлар куйсын диб. 6 Ул бозолоусыз, бер гня катыннын ире, балалары бозолоб жөрмягян, буйсынмыйчы, карышылыкта тороуда сюз чыгармаган ышаныучылар булырга тейеш. 7 Епископъ Алланын жорт житкезеўчесе булганга кюря, бозолоусыз, каты сюзле төгөл, ачыулы булмаган, эчмей торган, бяйлянчек төгөл, малга кызыкмый торган булырга тейеш; 8 аммя читтян килгяннярне сөйөўче, арыулыкны сөйөўче, таза уйлы, гадел, изге тормошло, тыйнак булырга тейеш; 9 өйрятелгян буйынча чын сюздя тотоноб тороучы, дөрөс өйрятеўдя ўгетлярга, карышы килеўчелярнен дөрөссөзлөгөн айтеб кюрсятергя көчө житешле булсын. 10 Буйсынмый торган, бушны сөй-

ляўчеляр, алдаучылар бик кюб шул, бигряк тя киселгянняр арасыннан; 11 андыйларнын ауызларын кабларга тейеш; оятсыз мал сöйöўлек буйынча тейешсез нястягя öйрятеб, алар бötöн жорт эчлярен бозолдоралар. 12 Алар арасыннан ук бер стихлар тöзöўче äйткян: Критъ кешеляре äр-кайчан жалганчылар, усал кейекляр, жалкау корсаклар, диб. 13 Былай таныклау сюзе дöрöс, шушынын буйынча аларнын каты итеб дöрöссöзлöклярен äйтеб кюрсят, алар таза ышанууда булсыннар. 14 Іудейляр äкеятляреня, чынныктан биздеря торган кеше тöзöгян эшлярга анг салмасыннар.

Зач.301 15 Таза кешеляр öчöн бар да таза, äммя шакшыланган ышанмый торганнар öчöн бер таза нястя дя жук, äммя аларнын уйлары да, кюнелляре дя шакшыланган. 16 Алар äйтяляр: Алланы белябез, диб, äммя алар жирянгеч, буйсынмый торган булганга кюря, бер арыу эш тя булдыра алмаганнарына кюря, эшляре белян Алладан таналар.

2-нче бюлем

1 Äммя син неи таза öйрятеў белян тиндяш, шуны äйт. 2 Картлар уяу кюнелле, töблö, таза уйлы, ышаныулы, сöйöўлектя, тюземнектя сау-таза булсыннар. 3 Шулай ук карчыклар да изгелярга килешле кейенсенняр, кеше сöйлямясенняр, эчкелеккя кызмят итмясенняр, арыуга öйрятсенняр; 4 жяш катыннарга ирлярен, балаларын сöйöб тороргa, 5 таза акылда булырга, чисталыкка, жортларын караб тороргa, арыулыкка, ирляреня буйсыныучан булырга акыл бирсенняр; Алла сюзе курланмасын ыйы. 6 Жегетлярне дя таза köйö тороргa ўгетля. 7 Бар турдан да öйрятеўдя таза итеб, тыйнак, бозолоусыз итеб, ўзенне арыу эшнен кючергече итеб кюрсят; 8 сюз таза-сау, курланмаслык булсын, карышы тороучы безнен турда бер начар сюз дя äйтя алмыйчы ўзе курлыкка калсын. 9 Колларны эяляреня буйсынырга, бар турдан да алар дигянчя кыларга, карышы сюз äйтмяскя, 10 урламаска, äммя бар турдан да ўзлярен арыу ышанычлы итеб кюрсятергя ўгетля, алар äр жаклаб та Коткарыучыбыз Алланын öйрятеўе белян матурлансыннар.

Зач.302 11 Алланын бар кешелярне дя котолдора торган дяўляте кюренде шул; 12 Ул безне бозоклокны, дöньялек няпесляpен ташлаб, бу гумердя шиксез, гадел, изге тороpга öйpятя; 13 оло Алла, Коткарыучыбыз Iисусъ Христоснын кюренясе олологон, без öмöтлянеб тора торган рахатлекне кöтöб торсоннар диб. 14 Шушы Iисусъ безне äp-тöpлö законсызлыктан жолоб алыр öчöн, арыу эшляр кыларга тырышыучан Ўзеня бер дигян калык сайлар öчöн Ўзен Ўзе безнен öчöн биргян. 15 Шушыларны äйт, ўгетля, äp-тöpлö ўзеня бирелгян кыуат белян дöpöссöзлöкне äйтеб кюрсят, сине беряў дя саннамый тороб кимсетмясен.

3-нче бюлем

1 Башлыкларга, илнен башлыкларына буйсынырга кирякне, äp-бер арыу эшкя äзер тороуны аларнын исляреня тöшöp. 2 Бер кемгя дя усал сюз äйтмяскя, жарсыу булмаска, ämмя тыныч булыб, бар кешеляр алдында да сабырлык кюрсятергя öйрят. 3 Без дя бит бер багытны уйсызлар, буйсынмый торганнар, адашканнар ыйык, тöpлö рахатлекляр няпесенен коллары булыб, усаллыкта, кончöлöктя жяшядек, жирянгеч булдык, бер-беребезгя кюремсез булдык. 4 Коткарыучы Аллабыз дяўлятен, ädямне сöйöўлеген кюрсяткяндя, 5 Ул безне кыласы дöpöс эшляребезгя караб коткармады, ämмя Ўзенен изгелеге буйынча, чумылыу арткылы жанадан тыудырыб, Святый Тын арткылы жанартыб коткарды; 6 шул Тынны Коткарыучыбыз Iисусъ Христосъ арткылы Ул безгя мулы белян индергян, 7 без Анын дяўляте белян дöpöскя чыгарылыб, öмöт тотоб тороуыбыз буйынча, мянге тормошта öлöшлö булсак ыйы диб. 8 Бу сюз ышанычлы, бу турыны син ныкландырсанг ыйы диб мин телеймен, Аллага ышанганнар арыу эшкя жят булырга тырышсыннар ыйы; бу шу кешеляр öчöн жакшы да, пайдалы да. 9 Кирякмягян тарткалашыулардан, узган няселлярне санаулардан, ирешеўлярдян, законъ турысында тартышыулардан читкя кит, алар пайдасыз буш нястяляр. 10 Денне бозоб öйpятеўчедян, анар бер-ике табкыр аннатканнан сун, аннан читкя

борол, 11 мындыйнын бозолганын, жазыкланганын, ул ўзен ўзе айыбланыуга биргянен бел. 12 Синең жанына мин Артемасны, жя Тихикны 13 законны белеўче Зинасны да, Аполлосны да бер турдан да житмяс нястяляре булмаслык итеб озатырга сагышлан. 14 Безнекеляр дя киряк чакта арыу эш кыларга өйрянсенняр, жимешсез кала кюрмясенняр. 15 Минем белян булганнар барысы да сине кюңелдян жаратыб калалар, ышаныуда тороучы безне сөйөучелярнен барысын да кюңелдян жаратыуыбызны житкер. Сезнен барыгыз белян дя дяўлят булсын. Аминь.

СВЯТЫЙ АПОСТОЛЪ ПАВЕЛНЫН ФІЛИМОНГА ЖИБЯРГЯН ЖАЗЫУЫ

1-нче бюлем

1 Іисусъ Христоснын быгауда тороучысы Павелдан, Тімофей туганнан безнең белян эшляўче сөйөклө Філимонга, 2 сөйөклө сеннебез Апфіягя, безнең белян тырышыучы Архіппка да, синең жорттагы арыу жыйынына 3 Атабыз Алладан, безнең Ходайыбыз Іисусъ Христостан сезгя дяўлят, тынычлык булсын. 4 Ўземнең телякляремдя жалан сине исемя алыб Аллама тау итямен, 5 Ходай Іисуска синдя булган ышаныуны, бар изгелярга дя тоткан сөйөўленгенне эшетямен. 6 Синең ышаныуга катышыуың Христосъ Іисустагы яр-төрлө арыулыкны анарга сездя эшлянеўле булсын дим. 7 Эй туган, синең белян изгелярнен кюнелляре тынычланганга кюря, без дя синең сөйөўлегеннян оло сөйөнөч белян жыуаныч алдык. 8 Шунар кюря сина ней кирякне кушарга Христоста зур кыйыулыгым булса да, 9 сөйөўлек белян сораганым арыуырак, бютян кеше төгөл, әммя мин - Павелъ карт, инде казер Іисусъ Христоснын быгауда тороучысы; 10 мин быгауда торган чакта тыудырган ўземнен улым Онисимъ турында синнян соройом: 11 бер багытны ул синең өчөн киряк булмады, әммя казер ул сина да, мина да кирякле, 12 мин аны жөрягемнян өзөб сина кайтарамын. 13 Мин быгауда тороб арыу хабяр сөйлягяндя, ул синең өчөн мина кызмят итсен диб, мин аны ўз жанымда тотасым килгян эйе; 14 әммя синең жакшы эшең ирексез булмыйчы, иректян булсын диб, синең ризалыгыннан башка бер ней дя эшлясе итмядем. 15 Әлля сина аны

бӧтӧнняйгя кабат алыр ӧчӧн, ул бер багытка шунын ӧчӧн дя айырылыб киткяндер; 16 казер инде кол итеб тӧгӧл, ӓммя колдан олорак итеб, бигряк тя минем ӧчӧн сӧйӧклӧ туган итеб, сиӈа бигряк тя тян жагыннан да, Ходай какына да туган итеб алыр ӧчӧн. 17 Шулай ӓгяр синеӈ минем белян катышыулыгыӈ бар икян, аны мине кабыл алган кюк кабыл ал. 18 Ӓгяр дя ул сине нейдер белян кимсеткян булса, жя бурычлы булса, аларны минеке диб сана. 19 Мин, Павелъ, ӱз кулым белян жазам: мин кайтарыб бирермен, син ӱз ӱзеӈ белян дя миӈа бурычлы икянен сиӈа ӓйтмейем дя инде. 20 Шулай, туганым, Ходай какына миӈа синнян пайда кюрергя жай бир, Ходай какына минем кюӈелемне тынычландыр. 21 Синеӈ тыӈнарыӈа ӧмӧт тотоб, сиӈа жаздым, мин ӓйткяннян син кюбряген дя эшлярсеӈ диб белям. 22 Шунын жанына миӈа бюлмя дя ӓзерля, сезнеӈ теляклярегез какына мин сезгя килермен диб ӧмӧт итям. 23 Минем белян Христосъ Ісусъ какына быгауда тороучы Епафрасъ сине кюӈелдян жаратыб кала, тагы минем белян эшляӱчеляр Маркъ, Аристархъ, Димасъ, Лука кюӈелдян жаратыб калалар. 24 Безнен Ходайыбыз Ісусъ Христоснын дяӱляте сезнен тыныгыз белян булсын. Аминь.

СВЯТЫЙ АПОСТОЛЪ ПАВЕЛНЫН ЕВРЕЙЛЯРГЯ ЖИБЯРГЯН ЖАЗЫУЫ

1-нче бюлем

Зач.303 1 Алла аталарыбызга пагамбярляр арткылы
äўялтеннян кюб табкыр тöрлöча
сöйлягян, 2 шушы калдык кöнняр
дя безгя Ўзенен дöньяне булдырган, теясене алыучы итеб куйган
Улы арткылы сöйляде. 3 Бу Ул
Атадагы даннын жактысы, Анын
ипостасенен ошашы, барын да
Ўзенен кыуатлы сюзе белян тотоб тороучы, Ўзе безне жазыкларыбыздан тазарткач, жугарыда Ололок урнынын уң жагыннан
утырган. 4 Ул пяриштялярдян ней
кадяр жугарырак булса, Анын
исеме дя алар алдында шул кадяр данныклырак шул. 5 Алла
пяриштялярнен кайсына кайчан
äйткян: Син Минем Улым, Мин
Сине бöгöн тыудырдым, диб;
тагы: Мин Анар Ата булырмын,
Ул Мина Ул булыр, диб? 6 Тагы
да, буган багытлардан элеке Тыуганны дöньягя жибяргян чакта
äйткян: Алланын бар пяриштяляре дя Анар башырсыннар, диб.
7 Пяриштяляр турысында äйтелгян: Пяриштяляренне тын кюк
итеб, кызмят итеўчеляренне жалкын ут кюк итеб жöртясен, диб. 8
Ämmя Ул турысында äйтелгян: Эй
Алла, Синен падшалык урнын
гумердян гумергя, падшалыгыннын таягы - дöрöслöк таягы; 9
Син дöрöслökне сöйгян, законсызлыкны кюрялмаган, шунар
кюря, эй Алла, Сине Аллан
сöйöнöч майы белян öлöштяшляреннян артык майлаган, диб.

Зач.304 10 Эй Ходай, баштук Син жирне корган, кюкляр
дя Синен кулларыннын эшляре;
11 алар бетярляр, ämmя Син шул
köйö торасын; алар бар да кейем

шикелле тузарлар; 12 Син аларны кейем кюк төрөрсөң, алар ўзгярерляр; әммя Син гел шул көйө торасың, гумерең бетмяс, диб. 13 Алла пяриштялярнен кайсына кайчан әйткян: Мин дошманнарынны аягың астына салгынчы, Минем уң жагымда утыр, диб. 14 Алар барысы да кешелярге котолоу алырга кызмят итярге жибяреля торган кызмятче тыннар төгөл ме?

2-нче бюлем

Зач.305 1 Шушы сяятлей без ышаныудан бизмяс өчөн эшеткянебезгя бик аң салыб торойок. 2 Пяриштяляр арткылы әйтелгян сюз нык тотолгач, ул сюзне тынамаган өчөн, аннан жазган өчөн тейешлечя кыйын алгач, 3 башта Ходай Ўзе сөйляб, Ўзеннян эшетеўчеляр безгя беркеткян зур котолоуны кадерсез итсяк, без сың шул кыйыннан ничек котолорбыз? 4 Бу котолоу Алладан билгеляр белян, кодрятляр белян, төрлө кыуатлар белян, Ўзенен ирке буйынча, Святый Тынны өляшеб биреўляр белян таныкланган бит. 5 Алла шу без сөйлөй торган буласы дөньяне пяриштялярге буйсындырмаган; 6 киресенчя, әле кемдер кайдадыр таныклаб әйткян: Ней нястя кеше? Алай да Син аны исендя тотасың ич, жя әдям улы ней? Син анар да изгелек итясен; 7 Син аны пяриштялярдян әз гня ким иткян, ололок белян, саннау белян аны кадерлягян, кулларың эшляреня аны баш итеб куйган; 8 барын да анын аягы астына эйелдергян, диб. Барысын да анар эйелдергяч, анар эйелдермей бер ней дя калдырмаган. Казер әле бар нястя дя анар эйелгянне кюрмейбез; 9 әммя Иисусъ ўлемгя тюзгяне какында дан белян, кадер белян данналганны кюрябез. Алланын дяўляте буйынча, Анар бар кешеляр өчөн дя ўлемне татыб карар өчөн Ул әз багытка гна пяриштялярдян ким булган. 10 Кем өчөн бар да булдырылган, Кем арткылы бар да булган, Анар, кюб оланнарны данга алыб килеўчегя, котолоуга башлаб барыучыга, быларны азабланыу арткылы кылыб житкезергя тейеш булган.

Зач.306 11 Арылаучы да, арыуланыучылар да, барысы бер Алладан шул; шул сяятлей Христосъ аларны туганнарым дирергя

курсынмый: 12 Исеменне туганнарыма белдерем, жыйын уртасында сине даннаб жырлармын, дей. 13 Тагы: мин Анар ӧмӧт тотармын, дей; аннары: мына мин ӱзем дя, мина Алла биргян балаларым да, дей. 14 Ӓммя балалар тянне, канны бул-ганга кюря, Ул да шулай Ӱзеня тян дя, кан да алган; ӱлем падшалыгын тотоб тороучы шайтаннын кыуатын ӱлеӱе арткылы бетерейем диб, 15 гумерляре буйынча ӱлемнян куркыб, коллокта торганнарны коткарыйым диб. 16 Ул тян белян канны Авраамъ няселеннян аласы иткян, ӓммя пяриштялярдян тӧгӧл. 17 Шунар кюря Ул, Алла алдында тороб, калыкны жазыкларыннан тазартырга изгелекле, чын Баш священникъ булыр ӧчӧн, бар туры белян дя туганнарга ошашлы булырга тейеш булган. 18 Алай булгач, Ул Ӱзе сыналыб, азабка чыдагач, инде ӱнгя сыналыучыларга да булыша алыр.

3-нче бюлем

Зач.307 1 Шулай, изге туганнар, кюктян чакырылыуга ӧлӧштяш булыучылар, безнен таныклый торганыбыз Кюктян жибярелгян Баш священникъ Ісусъ Христосны аннагыз шул. 2 Моисей Алланын бӧтӧн жортонда дӧрӧс булган кюк, Христосъ та Ӱзен Куйыучыга дӧрӧс булган. 3 Жортно торгозоучы жорто белян тинняштергяндя ней катле кадерлеряк, Моисей алдында Христосъ шунын катле олорак данга тейешле; 4 яр-бер жортно да кемдер житкезя шул, ӓммя барын да житкезеӱче Алла.

Зач.308 5 Белгертергя тейешлене таныклар ӧчӧн Моисей Анын бӧтӧн жортонда ышанычлы кызмят итеӱче икян, 6 ӓммя Христосъ Анын жортондагы Улы; ягяр дя без кыйыулыгыбызны, мактана торган ӧмӧтӧбезне калдыкка чаклы ныклык белян сакласак, Анын жорто без булабыз. 7 Шулай Святый Тын ӓйткянчя: ичмаса Анын тауышын бӧгӧн тынгнагыз, 8 буш кырда Мине сынаб ачыуымны китергян кӧннярдяге кюк, кюнеллярегезне катыландырмагыз, 9 анда аталарыгыз Мине сынадылар, эшляремне дя кюрделяр; ул зат Мине кырык жыл рянжетте. 10 Шунар кюря Мин ул тыумага рянжеб ӓйттем: алар кюнелляpендя жалан сата-

шалар, жулларымны белмяделяр; 11 шунар кюря Мин ачыуым килеб карганыб, алар тынычлыгыма кермясляр дидем, дей.

Зач.309 12 Сезгя тере Алладан читкя китмяс ючён, карагыз, туганнар, сезнен берярегездя ышанмый торган жаман кюнел булмасын. 13 Сезнен берярегезнен жазыкка алданыб кюнеле катыланмас ючён, айтергя булган чакта бер-берегезне кён сайын ўгетляб ойрятеб торогоз. 14 Ягяр башлаган тормошобызны ныклык белян калдыкка чаклы сакласак, без Христоска ялёштяш булабыз; 15 былай айтелгянчя: ичмаса Анын тауышын бёгён тыннагыз, зарланган чактагы кюк, кюнелляregезне катыландырмагыз, диб. 16 Эшетеўчелярнен кайберляре зарланганнар шул, тик Моисей белян Египеттян чыгыучыларнын барысы да тёгёл. 17 Кемгя суң Ул кырык жыл рянжегян, жазыкланыучыларга, сякляре буш кырда калганнарга тёгёл ме? 18 Кемгя карышы Анын тынычлыгына кермясляр диб карганган, буйсынмый торганнарга карышы тёгёл ме? 19 Шулай кюрябез: алар ышанмаганнарына кюря керя алмаганнар.

4-нче бюлем

Зач.310 1 Шунар кюря, Анын тынычлыгына кереўне бирем дейеў яле калыб торган чакта, сезнен арадан кемдер сунга калмасын диб сакланыйык. 2 Ул чактагыларга айтелгян кюк, арыу хабяр безгя дя сёйлянде, тик эшетеўчелярнен ышаныулары булмаганга кюря, эшеткян сюз аларда пайда китермягян. 3 Анын эшляре инде дёнья башланганда ук кылыб житкезелгян булган шул, Ул айткян: Мин ачыуым килеб карганыб айттем, алар Минем тынычлыгыма кермясляр, диб. Аммя без ышанган кешеляр Анын тынычлыгына керябез шул. 4 Бер урында жиденче кён турысында былай айтелгян: Жиденче коннё Алла Ўзенен бётён эшляреннян туктаб тынычланган, диб. 5 Тагы мында: Минем тынычлыгыма кермясляр, дей. 6 Шулай кайберяўлярга ул тынычлыкка керергя калган булса, аммя тегеляр, элек арыу хабяр сёйлянелгянняр, баш салмаганнары какында кермягянняр. 7 Тагы яле Ул нейдейдер "бёгён" дигян бер кён куйган: шулай озак багыт узганнан суң, Да-

видъ арткылы сöйляб, жугарыда äйтелгянчя: Ичмаса Анын тауышын бöгöн тынгнагыз, кюнеллярегезне катылandырмагыз, дей. 8 Äгяр Іисусъ Навинъ тынычлык китергян булса, сунъннан бютян кöн турысында äйтелгян булмас ыйы. 9 Шунар кюря Алланын калыгы öчöн äле алда суббота кöн, тынычлык кöнö кала. 10 Алла Ўз эшляреннян тынычланган кюк, Анын тынычлыгына кереўче дя ўз эшляреннян тынычланган шул. 11 Шулай алардан килгян кючергеч буйынча буйсынмаулыкка жыгылмас öчöн шул тынычлыкка керергя тырышыйык. 12 Алла сюзе тере шул, эшлярне кылыб тороучан, ике жагы да ўткен äрбер кылычтан да ўткенеряк, ул жанны, тынны, быуыннарны айырыуга чаклы, баш мейляреня чаклы ўтеб керя, кюнел уйларын, кыларга уйлаганнарны тикшеря. 13 Бер булдырылган нястя дя Аннан жяшерен тöгöл, Анын кюзе алдында бар да жалангач, бар да ачык; без Анар жауаб бирербез.

Зач.311 14 Кюклярне ўткян оло Баш священнигебез Алла Улы Іисуска тотоноб, денебездя ныk торойок; 15 безнен Баш священнигебез äлебез беткян чагында безне кызганыб, безгя булышырга äзер; Ул Ўзе дя безнен кюк бар турыдан да сыналган шул, тик жазыгы гна булмаган. 16 Шунар кюря изгелек алыр öчöн, кирякле багытта булышыучы дяўлят алыр öчöн, дяўлят биреля торган оло урынга кыйыуланыб жакыннашыйык.

5-нче бюлем

1 Кешеляр арасыннан сайлаб куйган äр-бер баш священникъ, кешеляр öчöн Аллага кызмят итяргя, жазыклар жолонор öчöн бюлякляр, корманнар китерергя куйыла. 2 Андый баш священникъ белемсезлярга, саташканнарга иненкелек итярлек була, анын ўзендя дя ялсезлек кюб була шул; 3 шунар кюря ул калык öчöн дя, ўзе öчöн дя жазыклардан жолонорга корман китерергя тейеш. 4 Бу ололокно беряў дя ўз ўзеннян алмый, ämмя аны, Ааронны чакырыб алган кюк, Алла чакырыб алган кеше гня аладыр. 5 Шулай Христосъ та Баш священниклек данын Ўз Ўзеннян алмаган, ämмя Анар аны: Син Минем Улым, Мин Сине бöгöн

тыудырдым, диб Ӓйтеўче биргян. 6 Бютян тӧштя дя ӓйтелядер: Мелхиседеккя ошаулы Син гумергя священникъ, диб. 7 Ул Ўзенен тяненен кӧннярендя кюз жяшляре белян кычкырыб, Аны ўлемнян коткара Алыучыга иялеб теляк китергян, Ўзенен кечелянеб кадер китереўе белян теляге эшетелгян. 8 Ул Атанын Улы булса да, алай да азабланыулары белян тынҥаучылыкка кюнеккян, 9 житеўле булыб, Аны тынҥаучыларнын барысы ӧчӧн дя мянге котолоуны Китереўче булган; 10 Мелхиседекъ олологондагы Баш священник диб Алладан аталган.

Зач.312 11 Бу турыда безгя кюб сӧйляшергя киряк эйе, ӓммя сез тынҥарга булдыксызга ӓйлянгянгя кюря, анҥатыб биреўе читен. 12 Узган багытны исябляганды, сезгя инде ӧйрятеўчеляр булырга бик багыт, ӓммя сезне Алла сюзенен беренче башларына жанадан ӧйрятергя киряк, сезнен ӧчӧн каты ашамнык тӧгӧл, ӓммя сӧт киряк шул. 13 Ӓр-бер сӧт белян туйыныучы, ул бала булганныгы какында, дӧрӧслӧк сюзендя белемсез була. 14 Каты ашамнык житеўле булганнарга килешя, аларнын шул тойомноклары жакшыны-жаманны айырга ӧйрянеб кюнеккян була.

6-нчы бюлем

1-2 Шунар кюря Христосъ турысында башлаб ӧйрятеўне калдырыб, тулысына ашыгыйык; ўлем эшляреннян китеб, Аллага ышаныуга, чумылыу турысында, кул салыу турысында, ўлгянняр терелеб тороу турысында, мянге хокӧм турысында ӧйрянеўгя жанадан нигез салырга тотонмойок. 3 Алай да мыны да эшлярбез, ӓгяр дя Алла ирек ится. 4 Инде бер табкыр жактырылыб, кюктяге бюлякне татыб караганнарны, Святый Тынга катышылы булганнарны, 5 Алланын арыу сюзен дя, буласы гумернен кыуатын да татыб караб, 6 аннары кабат айырылыб киткяннярне, алар жанадан Алла Улын курлаб, Аны ўз-ўзляредя качка кадаклаган чагында, кабаттан аларны тяўбягя китереб жанартыб булмый. 7 Кюб табкыр ўзеня жауган жангырны эчеб ўлям ўстеря торган жир, аны эшкярткян кешелярга пайдалы, Алланын бахил-

леген дя ала; 8 әммя чянечкеле агач, тигяняк ўстереўче жир пайдасыз, ул каргауга жакын тора, азактан ул утка жандырыла.

Зач.313 9 Алай да, сӧйӧклӧлярем, без былай сӧйлясяк тя, сез арыуырак әлдядер, котолоуга таба барасыздыр диб, сезнен турда ӧмӧт тотабыз. 10 Алла сезнен эшегезне, Анын исеме какына изгелярга кызмят итеб, кызмят итя тороб кюрсяткян сӧйӧўлегегезне оноторга Ул бит гаделсез тӧгӧл. 11 Сезнен әр-кайсыгызнын тулы ышанычлы ӧмӧт белян калдыкка чаклы шундый кӧнняшеўле тырышлык куйганын телейбез шул; 12 сез жалкауланмыйчы, әммя ышаныулык белян, озак тюзеў белян багадя ителгянне алыучыларга ошарга тырышсагыз ыйы.

Зач.314 13 Алла Авраамга багадя биргян чагында, ант итяргя Ўзеннян зур бер нястя дя булмаганга кюря, Ўзен Ўзе алыб ант итеб, 14 әйткян: Чыннаб, Мин синә бахиллек өстӧня бахиллек бирермен, синең няселенне ўрчегян сайын ўрчетермен, диб. 15 Авраамъ озак тюзгяннян сун, Алла багадя иткянне алган. 16 Кешеляр ўзляреннян олоно алыб ант итяляр, сюзнен чын икянен кюрсятергя иткян антлары тӧрлӧчя даулашыуларын бетерядер. 17 Шулай Алла да, багадяне аласы кешелярга бигряк тя Ўзенен ирке ўнгяреўсез икянен кюрсятер өчӧн ант итясе булган; 18 шушы ике нястядян: ант итеб, багадя биреўеннян Алланын жалганнамаганныгын кюреб, без, алдагы ӧмӧткя сыйыныб тороучылар, нык тынычланыу алдык. 19 Шул ӧмӧт безнен жаныбызга жякер шикелле ышангышлы нык нястя булды; ул ӧмӧт кюкнен иң эчтяге бюлеменя керядер; 20 ул урынга Мелхиседекъ рятенчя гумергя Баш священникъ булган Іисусъ безнен өчӧн алдан килеб кергян.

7-нче бюлем

Зач.315 1 Ул Мелхиседекъ Салимъ падшасы, жугарыгы Алланын священниге, ул Авраамъ падшаларны жинеб кайткан чакта аны очоратыб бахиллягян; 2 анар Авраамъ барысыннан да унынчы ӧлӧшӧн бюлеб биргян, береннян, дӧрӧслӧк падшасы диб билгелянгян исеме какында, аннары: Салимъ падшасы, алай

дигяне: тынычлык падшасы булганы какында; 3 ул атасыз-анасыз, тыумышы да саналмаган, кӧнняренен башы да жук, гумеренен азагы дя жук, Алла Улына ошаулы булыб, ӓр-кайчан священникъ булыб тора. 4 Кюрясез ме, Авраамъ патриархъ та ӱзенен табышынын иӊ арыуларыннан унынчы ӧлӧшӧн биргян кеше ничек оло. 5 Левитъ няселенен священиклек алыучы улларына законъ буйынча калыктан, алай дигяне: ӱз туганнарыннан, булар Авраамъ няселеннян тыусалар да, унынчы ӧлӧшӧн алырга дигян бойороклары бар. 6 Ӓммя Мелхиседекъ алар тыумасыннан чыккан тӧгӧл, алай да ул Авраамнан унынчы ӧлӧшӧн алыб, багадя бирелгян Авраамны бахиллягян.

Зач.316 7 Бер сюзсез, бахиллекне кече кеше оло кешедян алыуы дӧрӧс. 8 Моисей законынча, унынчы ӧлӧшнӧ алыучылар ӱля торган кешеляр, ӓммя Мелхиседекъ турысында тере тора диб таныклаб ӓйтеля. 9 Жяня тагы ӓйтейем: унынчы ӧлӧшнӧ алыучы Левій Авраамъ арткылы ӱзе унынчы ӧлӧшнӧ биргян; 10 Мелхиседекъ Авраамны очораткан чагында, Левій ӓле Авраамъ эчендя булган. 11 Левитларнын священниклеге арткылы тулы котолоу алырлык булгач - еврей калыгынын законы левитлар священниклеге белян торган - айса ник суӊ бютян священникъ Мелхиседекъ рятенчя аталыб чыгарга тейешле булган, ӓммя Ааронъ рятенчя тӧгӧл? 12 Священниклек ӱзгяргяч, законъ да ӱзгярергя тейеш булган шул. 13 Бу бары да Христосъ турысында ӓйтеля; Ул бютян няселдян чыккан, ул няселдян беряӱ дя корман урнына кызмят итмягян. 14 Безнен Ходайыбыз Іисусъ Христосъ Іуда няселеннян жактырылыб чыкканы билгеле, ӓммя Моисей Іуда няселеннян священниклек чыгар диб бер дя ӓйтмягян. 15 Жяня бигряк тя мыннан билгеле: Мелхиседекка ошаулы бютян Священникъ чыгар, дей; 16 бу бютян Священникъ бетмей торган тормошнон кыуаты белян чыгар, ӓммя тян законы - гадятчя тыуыу рятенчя тӧгӧл. 17Изге Жазыуда былай таныклаб ӓйтеля: Мелхиседеккя ошаулы син гумергя священникъ, диб.

Зач.317 18 Башта булган бойорокны алмаштырыу анын ӓлсезлеге буйынча, пайдасыз-

лыгы буйынча була; 19 Моисей законы бер нястяне дя тулылыкка китереб житкермягян шул, ямма Аллага безне жакыннаштыра торган арыуырак ёмёт тотоулык кертеля; 20 бу да багадясез гня булмаган. 21 Тегеляр шу багадясез гня священникляр булганнар, ямма Бу багадя белян булган, Анын турында яйтелгян шул: Ходай багадя куйган, багадясен ўзгяртмяс; Мелхиседеккя ошаулы Син гумергя священникъ, диб. 22 Шул арыуырак бойорокны урнына житкезеўче Iисусъ булган. 23 Шунын östöня, теге священникляр кюб булганнар, беряўгя гня гел тороргa ўлем ирек бирмягян шул. 24 Ямма Бу мянгегя тороучы булганга кюря, Анын бетмей торган священниклеге бар; 25 шунар кюря Анын арткылы Аллага килеўчелярне, алар ёчён жалбарырга яр-кайчан тере булганга кюря, яр-кайчан коткара ала.

Зач.318 26 Безнен Баш священнигебез изге, усаллыкка катышыусыз, шиксез, жазыклылардан айырылыулы, кюклярдян дя жугары кютярелеўле булырга тейеш. 27 Элекеге баш священникляр кюк, Анар башта ўз жазыгы ёчён, аннары калык жазыклары ёчён кён сайын корман китереў кирякле дя тёгёл, Ул инде кормангa Ўзен Ўзе бер табкыр китереўе белян мыны кылыб бетергян шул. 28 Законъ баш священникъ итеб ялсезлеге бар кешелярне куя, ямма карганыб яйтелгян сюз, законнан сун, гумергя бар турыдан да тулылыгы бар Улны куйган.

8-нче бюлем

1 Без сёйлягяннен олосо шушы: безнен кюклярдяге Ололок урнында ун жактан утырган Баш священнигебез бар, 2 Ул чын скиниядяге арыу урында арыу эш кылыучы, ул келяў чатырын Ходай Ўзе торгозган, ямма кеше торгозган тёгёл. 3 Яр-бер священникъ бюлякляр, кормaннар китерер ёчён куйыла, шунар кюря Мынын да нейдер китерер нястясе булырга киряк булган. 4 Ягяр дя Ул жирдя калган булса, священникъ тя булмас ыйы, мында законъ буйынча бюлякляр китереўче священникляр шул. 5 Моисейгя яйтелгян буйынча, алар кюктягенен ошашы, анын кюляткясе буйынча кызмят итяляр, ул скинияне жасарга тотонган ча-

гында äйтелгян: Кара, барысын да сина тау öстöндя кюрсятелгян ошаш белян жаса, диб. 6 Ämмя бу Баш священникъ ин арыу багадяляр белян ныгытылган ин арыу бойорокны жалбарыб алганы буйынча, бигряк тя жугарырак кызмятне алган.

Зач.319 7 Ägяр дя элекеге законнын житмяслеге булмаган булса, икенчегя урын да эзлярга киряк булмас ыйы. 8 Ämмя пагамбяр аларны тиргяб äйтя: Ходай äйтя: Мына кönняр килер, ул чакта Мин Израиль жорто белян дя, Iуда жорто белян дя жана бойорок килешермен; 9 Мин аларнын аталарын Египетъ жиреннян чыгарыр öчön кулларыннан житяклягян чакта килешкян бойорок кюк тögöл, алар шу Минем ул бойорогомда тормадылар, Мин дя аларны сакламадым, дей Ходай. 10 Мына шул кönнярдян суң Израиль жортона äйтелгян бойорогом, дей Ходай: Ÿземнен законнарымны уйларына салырмын, аларны кюнелляреня жазармын, аларнын Алласы булырмын, алар Минем калкым булырлар; 11 беряў дя жакынын да, туганын да: Ходайны бел, диб äйтеб инде öйрятмяс, барысы да кечесеннян башлаб олосона чаклы Мине белерляр шул; 12 Мин шу аларнын дöрöссöзлöкляреня жарлыкаучан булырмын, аларнын жазыкларын да, законсызлыкларын да бютян исемя алмам, дей. 13 «Жана" диб элекесенен тузганныгын кюрсяткян, ämмя тузган нястяляр, искеляр бетер öчöнгя жакын булалар.

9-нче бюлем

Зач.320 1 Элекеге скиниядя келяў итеунен ряте булган; ул дöньядягелярне арыуландыра торган урын булган. 2 Бу элекеге скинія былай торгозолган: анын элеке бюлемендя эшямдял белян öстял торган, аннары арыу икмякляр торганнар; бу бюлем арыу диб äйтелгян; 3 скиниянен икенче чаршауы артында арыудан арыу диб äйтеля торган бюлеме булган, 4 анда алтын кадило торган, аннары äйлянясен алтын белян тышлаган Законъ сандыгы торган; шундук тагы манна тутырган алтын сауыт торган, аннары Ааронnын чячяк аткан таягы торган, тагы законъ жазылган таш такталар торганнар. 5 Сандык öстöндяге тазарындыргыч-

ны Алланын данын кюрсятеўче херувимняр бöркяб торганнар. Былар турысында рятляб сöйляў казер кирякле дя тöгöл. 6 Шулай торгозолган скиніянен элекеге бюлеменя священникляр Аллага кызмят итяргя жалан кергянняр. 7 Икенче бюлеменя баш священникъ кня ўз жазыклары öчöн, калыкнын белмей жазыкланганы öчöн китергян корман канын алыб, жылында бер гня табкыр кергян.

Зач.321 8 Шушынын белян Святый Тын элекеге скинія торган чакта арыу урынга äле жул ачык тöгöл икянен кюрсятя. 9 Казерге багытнын ошашы ул скинія, анда бюлякляр, корманнар китеряляр, тик алар китереўченен кюнелен тулылаб булдырыб житкезмей; 10 ул ашамныклар, эчемнекляр, тöрлöчя жыуыныу гадятляре тянгя гня кирякле эшляр, тöзялеб житкенчегя чаклы гна куйылган. 11 Äммя буласы арыулыкларнын Баш священниге Христосъ элекеге скиніядян олорак та, жакшырак та кул белян жасалмаган скинія эчендя килеб, 12 арыу урынга элекеге кюк кязя каны белян, бызау каны белян кермягян, äммя Ўз каны белян арыу урынга бер гня табкыр кереб, мянгегя жолоулык алган. 13 Äгяр корманнык бызаулар каны, кязяляр каны, тагы жандырган тана кöлöн сибеў шакшыланганнарнын тяннярен тазартыб арыуландырган икян, 14 Святый Тын арткылы Ўзен Ўзе Аллага шиксез кöйö китергян Христоснын каны чын, тере Аллага кызмят итяргя кюнел тойоулыгыбызны ўлем эшляреннян бигряк тя тазартыр. 15 Шунар кюря Ул элекеге законъ багытында кылган жаман эшлярдян ўлеме белян жолоб алыб, мянгегя теясене алырга чакырылганнар багадя ителгянне ала алыр öчöн, Ул жаңа бойорокны жалбарыб алыучы булган. 16 Äйтеб калдырыу булган жирдя, äйтеб калдырыучынын ўлеме килеў дя кирякле, 17 äйтеб калдырыу кеше ўлгяннян суң гна эшлей башлый, äйтеб калдырыучы исян чакта анын кыуаты жук. 18 Шунар кюря дя элекеге законъ кансыз гна ныгытылмаган. 19 Моисей бöтöн калык алдында законъ буйынча бар бойорокларны да äйткяч, кызартылган жон белян сибкеч алган да, бозаулар канын, кязяляр канын сыу белян княгянен ўзеня дя, бар калыкка да сиб-

кян, 20 былай диб: бу кан Алла сезгя бойорок биргянгя, бойорок каны, диб. 21 Шулай тагы канны скиниягя дя, Аллага кызмят итя торган бар сауытларга да сибкян. 22 Барысы да дирерлек законъ буйынча кан белян тазарына, кан тюгелмейче кичерелеў дя булмый. 23 Шулай, кюктягенен ошашлары шушылар белян, кюкнен ўзенекеляр былардан арыуырак корманнар белян тазарырга тейеш булган.

Зач.322 24 Христосъ та, чын Арыу урыннын ошашы булган кул белян торгозолган скиниягя кермягян, аммя казер безнен очон Алланын жозо карышысында тороргa, кюкнен ўзеня кергян; 25 баш священникъ жыл сайын чит кан белян арыу урынга кергян кюк, Ўзен кюб табкыр китерер очон тогол шул. 26 Алай булса, донья башланганнан бирле Анар кюб табкыр азабланырга киряк булыр ыйы, аммя Ул гумерлярнен азагында Ўзенен корманы белян жазыкны жукка чыгарыр очон бер гня табкыр кюренгян. 27 Ничек кешеляргя бер табкыр гна ўлеб, аннары хокöм куйылган, 28 шулай Христосъ та кюб кешелярнен жазыкларын жолар очон бер табкыр Ўзен корманга китереб, икенче табкыр жазыклардан тазартыр очон тогол, аммя Аны котоб тороучыларны коткарыр очон кюренер.

10-нчы бюлем

Зач.323 1 Законъ чын айберлярнен ошашын тогол, аммя буласы арыулыкларнын кюлятксен ўзендя тотоб, жыл сайын шул ук бер корманнарны жалан китеря тороб, анын белян барыучыларны бер кайчан да тулы итя алмый. 2 Алай булса, аларны китереўдян туктарлар ыйы, корман китереўчеляр бер табкыр тазарыныб, ўзлярендя бер нейдей дя жазык барын тоймаслар ыйы шул. 3 Аммя корманнар белян жыл да сайын жазыклар иска тошороля; 4 бызаулар-кязяляр каны белян жазыкларны бетерергя момкин тогол шул. 5 Шунар кюря Христосъ доньягя кергян чакта айтя: Син корманны, бюлякне телямяден, Мина тян азерляден; 6 жазык очон корман жандырыу сорамадын; 7 шул чакта Мин айттем: мына барам, диб; книгядя Минем турда жазылган, эй Ал-

лам, Синең иркенне кылыуны телядем, дей. 8 Башта: корман да, бюляк тя, законъ кушканча жазык өчөн корман жандырыу да Син сорамадың, анар риза булмадың, дей; 9 аннары өстяб äйтя: эй Алла, мына Синең иркенне кыларга барам, дей. Икенчесен урыннаштырыр өчөн, беренчесен бетеря шул. 10 Шушындый ирке буйынча Iисусъ Христоснын тяне бер табкыр китерелеуе белян без арыуландырылган да. 11 Äрбер священникъ көн сайын кызмяття тороб, кюб табкыр шул ук корманны китеря, äммя алар бер кайчан да жазыкны жук итя алмыйлар. 12 Äммя Христосъ жазыклар өчөн бер корман китереб, гумерлеккя Алланын унг жагыннан утырган; 13 шуннан бирле Анын дошманнары Анын аяк астына салынганны көтя. 14 Ул шу бер китерелеў белян арыуланыучыларны гумерлеккя житеў иткян. 15 Бу турда сезгя Святый Тын да таныклый, äйтелгян шул: 16 Ходай äйтя: мына бойорок, шул көннярдян суң биря торган бойорогом: Мин законымны аларнын кюнелляреня салырмын, аны аларнын уйларына жазармын, 17 аларнын жазыкларын, законсызлыкларын бютян иска алмам, дей. 18 Жазыклар кичерелгян жирдя алар өчөн китерелеў дя киряк төгөл.

Зач.324 19 Шулай, туганнар, Iисусъ Христоснын Каны арткылы жана, тере жул белян Арыу урынга керергя кыйыулыгыбыз булгач, 20 аны Ул безгя чаршау арткылы, алай дейеў, Ўзенен Тяне арткылы жанадан ачкач, 21 Алла жорто өстöндя Оло священнигебез булгач, 22 керсез кюнел белян, тулы ышаныу белян бозок уйларыбыздан кюнелебезне жыуыб тазартыб, тянебезне чиста сыуда жыудырыб жакыннашыйык, 23 таныклый торган өмөтöбезгя ауышмыйчы тотонойок, багадя Биреуче ышанычлы шул. 24 Сöйöулеккя дя, жакшы эшкя дя кюнелляребезне дяртляндереб, бер-беребезгя аң салыб торойок; 25 кай беряулярнен шундый гадятенчя, ўзебезнен бергя жыйылыуыбызны калдырмыйык, ул көннөн жакыннашканын чамалаган сайын бигряк тя бер-беребезне ўгетлейек. 26 Äгяр дя без чынныкны белеулекне алгач та, ўз иркебездян жазыкланабыз икян, жазыклар өчөн бютян инде корман калмый; 27 äммя нейдейдер куркынычлы хокöм, карышылык

итеўчелярне ашарга äзер тора торган жарсыу ут кна көтöля. 28 Äгяр Моисей законыннан ауышкан кеше, ике жя öч таныкчы алдында рахимсез ўлемгя бирεля икян, 29 Алла Улын табтаб, бойорокно арыуландырган Канны изге диб санамаса, дяўлятнен Тынын курласа, ул ничек каты айыбланыб, кыйынга тейеш булыр диб уйлыйсыз? 30 Былай Äйтеўчене белябез бит: Ўч кайтарыучы Мин, Мин Ўзем кайтарым, дей Ходай; тагы да: Ходай Ўз калкына хокöм итяр, дей. 31 Тере Алланын кулына тöшöў куркыныч!

Зач.325 32 Баштагы көнняре-гезне исегезгя тöшöрöгöз, ул чакта сез чумылыб жактырылганнан сун, зур тырышыулык белян азабларга тюздегез; 33 жя сез ўзегез кимсетелеўляр, көйөкляр арасында тороб, бютяннярга караб торор нястя кюк булдыгыз, жя шундый ук äлдя тороучы бютяннярнен эшляреня ўзегез керештегез; 34 сез шу минем быгауларым öчöн дя кайгырдыгыз, äйберлярегезне талаб бетереўне дя, кюктя сезнен ўнгярмей торган арыуырак äйберлярегез бар диб белеб, сöйöнöч белян кабыл алдыгыз.

Зач.326 35 Шулай, ўзегезнен ömöт тотоб тороуыгызны ташламагыз, анын öчöн зур бюляк бирелергя тора шул. 36 Алланын иркен кылыб тороб, бирясе булганны алыр öчöн сезгя тюземнек киряк; 37 кюб калмады, бик тя кюб калмады, Килеўче килер, озакламас. 38 Гадел кеше ышаныу белян тере торор, äгяр дя кем какшый икян, анар Минем кюнелем риза тöгöл, дейелгян. 39 Без шу харяб булыр öчöн какшаучылардан тöгöл, äммя жаныбызны коткарыр öчöн ышаныуда торабыз.

11-нче бюлем

1 Ышаныу ул көтöб торганнын жиреня килеўе, тагы кюренмей торганга ышаныб тороу. 2 Ышаныуда боронголар таныклаб äйтелгян: 3 ышаныу буйынча Алла сюзе белян гумерляр булдырылганны анныйбыз, шулай итеб, кюренмей торганнан кюреня торган килеб чыккан. 4 Ышаныу белян Авель Аллага Каинныкыннан арыуырак корман китергян, ышаныу белян ул гаделлегеня таныклык алган, шуны анын бюлякляре турында Алла

таныклаб äйткян; ышаныу белян ул ўлгяннян суң да äле сöйлöй. 5 Ышаныу белян Енохъ теге дöньягя кючерелгян, ўлемне дя кюрмягян, Алла аны кючергянгя кюря, ул жукка чыккан. Ул шу кючерелгенче ўк, Аллага жараулы булдын, диб таныклык алган. 6 Äммя ышаныу булмаса Аллага жараулы булыб булмый, Аллага килеўчегя Ул бар икянгя, Аны эзляўчелярга Ул тейешлесен кайтарыучы икянгя ышаныу кирякле. 7 Ышаныу белян Ной äле кюренмягян нястя турысында ачылыу алган, арыу кюнел белян ўзенен жортондагыларны коткарыр öчöн кимя äзерлягян, ышаныу буйынча ул бöтöн дöньяне хокöм иткян, ышаныу буйынча гадел öлöшнö алырга тейешле булган.

Зач.327 8 Ышаныу белян Авраамъ теясе öлöш жирен алырга диб, Алланын чакырыуына буйсыныб, кая барганын да белмейче чыгыб киткян.

Зач.328 9 Ышаныу белян Авраамъ анар бирелясе жиргя, жат жиргя килгян кюк килгян, ул анда шул бирелясе жиргя öлöштяш буласы Исаакъ белян, Иаковъ белян бергя чатырлар эчендя торган; 10 шулай итеб, ул ўзеня нигезен корган кала булыр диб, аны Алла Ўзе оста торгозор диб котöб торган. 11 Ышаныу белян Сарра ўзе дя, бала китермей торган булыб та, орлокно кабыл алырга кыуат алган, ўзенен жяше оло булса да, бала тыудырган, бирясе Булыучынын ышанычлы икянен ул белгян шул. 12 Шунныктан бер кешедян, шунын катына ўлелянгян тяннян, кюктяге жондозлар чаклы кюб, дингез жарында ком бöртöкляре ничек кюб, шул катле кюб нясел тыуган. 13 Былар бар да ышаныу белян ўлгянняр, бирелясене алмаган köйö, аны жырактан гна кюреб сöйönöшöб, ўз-ўзляреня äйткянняр: без жир öстöндя узгынчылар, читтян килгянняр гня, диб; 14 шулай äйтеўчеляр ўзляренен тора торган калаларын эзлягяннярен кюрсятяляр. 15 Äгяр дя аларнын уйларында чыгыб киткян жирляре булса, боролоб кайтыу багытлары булыр ыйы. 16 Äммя алар арыуыракка, кюктягеняр тырышканнар, шунар кюря Алла да Ўзен аларнын Алласы диб äйтергя курсынмый, Ул шу аларга кала äзерляб куйган.

Зач.329 17 Ышаныу буйынча Авраамъ сыналыб, алган багадясе буйынча, бердян бер улы Иса-

акны корманга китергян; 18 шушы улы турысында äйтелгян икян: няселеҥ Исаакъ булыр, диб. 19 Ул уйлаган шул: Алла ӱлгяннярне дя терелтергя кыуатлы, диб; шунар кюря ул Исаакны билге итеб, терелеб торасы Христосны алдан белдереб, тере кӧйӧ кютяреб алган. 20 Буласыга ышаныб, Исаакъ Іаковъ белян Исавны бахиллягян. 21 Ышаныу буйынча, Іаковъ ӱлгян чагында Іосифнын улларын äр-берсен бахиллягян, аннары таягына таяныб тороб, Аллага башырган. 22 Ышаныу буйынча, Іосифъ ӱлгян чагында Израиль улларынын Египеттан чыгасын исляреня тӧшӧрӧб, ӱзенен сӧяклярен алыб чыгарга äйтеб ӱлгян. 23 Ышаныу буйынча, Моисейне тыугач, атасы белян анасы ӧч ай жяшереб тотканнар, алар баланын бик матур икянен кюреб, падша бойорогоннан да курыкмаганнар. 24 Ышаныу буйынча, Моисей ӱсеб житкяч, фараонъ кызынын улы диб аталасы килмягян; 25 äз багытны жазыклылар белян рахятлянеб торгончы, Алла калкы белян азабланыб тороуны жакшырак кюргян; 26 буласы сауабны алдан кюреб торганга кюря, ул Христосъ ӧчӧн азабланыуны Египетъ малыннан артыграк байлыкка санаган шул. 27 Ышаныу буйынча ул, падшанын ачыуыннан да курыкмыйчы, Египетны ташлаб киткян, ул шу кюренмей Торганны кюргян кюк ныk булган. 28 Ышаныу буйынча, элеке тыуганнарны ӱтереӱче кагылмый китсен ӧчӧн, ул кан тюгелеӱ, котолоу бяйряме кылган. 29 Ышаныу белян алар кызыл дингездян, коро жирдян ӱткян кюк ӱткянняр, шулай ӱтясе итеб, Египетъ кешеляре батыб ӱлгянняр. 30 Ышаныу буйынча, жиде кӧн äйлянеб чыккач, Іерихонъ каласынын койма лары жимерелеб тӧшкян. 31 Ышаныу белян азгын катын Раавъ, кюзятеӱчелярне татыулык белян карышы алыб, аларны бютян жул белян озатыб жибяреб, денсезляр белян бергя харяб булмаган.

Зач.330 32 Инде тагы неӥ äйтейем? Гедеонны, Варакны, Самсонны, Іеффайны, Давидны, Самуилны, бютян пагамбярлярне дя рятляб äйтергя багытым да житмяс. 33 Алар ышаныу буйынча падшалыкларны жинтянняр, дӧрӧслӧк кылганнар, бирелясене алганнар, арысланнарнын ауызларын жабканнар; 34 утнын кыуатын бетергянняр, ӱткен кылычтан

котолганнар, әлляре беткяндя ныгайганнар, сугышта нык торганнар, чит чиреўлярне кыуыб жибяргянняр; 35 катыннарга да ўлекляре терелтеб бирелгян. Кайсылары иркеннекне алмыйчы, терелеб торгач жакшы тормош алыр өчөн, азабка бирелеб ўлгянняр; 36 кайсылары курлауга, кыйналыуга, быгауда тороуга, өтөрмянгя жабылыуга тюзгянняр; 37 таш белян атылыб ўлгянняр, пычкы белян киселгянняр, азабта интектерелгянняр, кылыч белян чабылыб ўтерелгянняр, сарык тиресе кейеб, кязя тиресеня кабланыб, урыннан урынга кючеб жөргянняр, нужалыкка, кайгыга, жамангa тюзгянняр. 38 Аларга бөтөн бер дөнья дя тиң тормой, алай булса да, алар буш кырларда, тауларда, тау кыуышларында, жир чокорларында торганнар. 39 Былар барысы да ышаныуларын ўз тормошлары белян таныкласалар да, бирелясене алгынчы тормаганнар; 40 Алла безнен өчөн оло жакшылык кыласы булган шул, алар бездян башка гна тулы рахатлекне алмасыннар диб.

12-нче бюлем

Зач.331 1 Шуңар кюря без дя әйлянябездя болот кюк шул катле таныкчыларны кюреб, өстөбездяге әр-бер жөкнө, безне абындыра торган жазыкны ташлаб, алдагы ауыр тормошобызны тюземнек белян ўткязейек; 2 ышаныунын башлыгы, ышаныуны артгырыучы Iисуска карыйык, Ул Аңар тейешле сөйөнөч урнына, мыскыллауга карышы әйтмейче, качка кадакланыуга тюзгян, шулай Алла Престолынын уң жагыннан утырган. 3 Сез көчөгөз бетмяс өчөн, жаныгыз белян әлсезлянмяс өчөн, жазыклыларнын Ўзеннян шулай мыскыллауларына Тюзеўче турында уйлагыз. 4 Сез жазыкка карышы тырышыуыгызда әле каныгызны тюгеб көряшмядегез. 5 Сезне уллар итеб, сезгя бирелергя дигян жыуатыуны оноттогоз; әйтелгян бит: улым, Ходайнын жибяргян кыйынына аң салмый калма, Ул синең дөрөссөзлөгөнне әйткян чакта моңайма, 6 Ходай шу кемне сөя, аңар кыйын тейеря, кабыл алган әр-бер улны кыйный, диб. 7 Әгяр дя сез кыйынга тюзясез икян, Алла сезне Ўз уллары итеб

сезгя кылар; атасы бер дя кыйын тейермягян беряр улы бар менеӣ? 8 Ӓгяр дя барысына да тейешле кыйынсыз калсагыз, ул чакта сез законны балалар тӧгӧл, уллар да тӧгӧл. 9 Шунын ӧстӧня, ӓгяр дя без тян жагыннан тыудырыучыларыбыз безгя кыйын тейергянгя алардан курыкканыбыз икян, алайса тере торор ӧчӧн тыннарнын Атасына без бигряк тя буйсынырга тейеш тӧгӧл менеӣ? 10 Тыудырыучылар, ӱзляре булдырганча, кюб булмаган кӧнняр ӧчӧн гня безгя кыйын биргянняр, ӓммя Бу - пайда ӧчӧн, Анын изгелегендя безнен ӧлӧшӧбез булсын ӧчӧн безгя кыйын биря. 11 Ӓр-тӧрлӧ кыйын да багытында сӧйӧнӧч булмый, ӓммя кӧйӧк булган кюк тея, ӓммя анын арткылы ӧйрянеб, сунӌннан тыныч гаделлек жимешен китеря. 12 Шулай, тюбян тӧшӧргян кулларыгызны, ӓлсезлянгян тезляре-гезне ныгытыб, 13 ӱзегезнен аяклары-гыз белян туры жӧрӧгӧз, аксаклаб жулларыгыздан жазмас ӧчӧн, ӓммя арыуырак ынтайланыр ӧчӧн шул.

Зач.332 14 Бар кешеляр белян дя татыу булыб, изге торогоз, аннан башка бер кем дя Ходайны кюря алмас. 15 Чамалаб торогоз, беряӱ-беряӱ Алланын дяӱлятеннян жазмасын, беряр тӧрлӧ ӓче тамыр ӱсеб зыян салмасын, анын белян кюбляр шакшыланмасын; 16 сезнен арада беряр азгын, жя таза тӧгӧл кеше булмасын, андый, Исавъ шикелле, бер ашар ӧчӧн ӱзенен алдан тыуганныгын кире кага. 17 Сез бит белясез, шуннан сунг ул бахиллекне аласы кился дя, кире кагылган, ул турда кюз жяше белян сораса да, атасынын уйын ӱнтяртя алмаган. 18 Сез кабшаб карый торган, ут белян жалкыннана торган тауга жакыннашыб килмядегез, карангы жиргя, дӧм карангылыкка, жя дауылга, 19 быргы тауышына да тӧгӧл, эшетеӱчеляр, аларга тагы алга таба сюз сӧйлянмясен эйе диб сораган сӧйляшеӱ ауазларына да тӧгӧл. 20 Бойорок биреб ӓйтелеӱгя алар тюзя алмаганнар шул, ӓгяр кейек килеб тауга тейенся дя, ул таш белян атыб, жя ук белян атыб ӱтерелергя тейеш булган; 21 бу кюренеш шул катле кот чыккыч булган, Моисей дя ӓйткян: Мин куркыб калты-

рыйым, диб. 22 Ӓммя сез Сiонъ тауына, тере Алланын каласына, кюктяге Iерусалимга, чиксез кюб пяриштялярга жакыннашыб килдегез; 23 кюктя исемняре жазылган, сӧйӧнӧшӧб тора торган беренчелярнен арыу жыйынына, барына да хокӧм итеӳче Аллага, арыулыкка житеӳ булган гаделлярнен тынына, 24 жанa бойорокны жалбарыб алыучы Iисуска, Авель каныннан да арыуырак сӧйлӧй торган, сибеля торган Канга килдегез.

Зач.333 25 Карагыз, Сӧйляӳчедян сез дя кире чикмягез; ӓгяр дя тегеляр жирдя сӧйляӳчене тынмамаган ӧчӧн кыйыннан кача алмаганнар икян, шулай булгач, без кюктян Сӧйляӳчедян кире боролсак, бигряк тя кача алмабыз. 26 Ул чакта Анын тауышы жирне титряткян, казер дя Ул шундыйны бирясе булыб ӓйткян: Тагы бер табкыр жирне гня тӧгӧл, ӓммя кюкне дя титрятермен, дигян. 27 «Тагы бер табкыр» дигян сюзе, булдырылган нястя булганга кюря, титрей торганнын ӳнгяреӳен билгертя, кузгалмый торганы жалан торор ӧчӧн. 28 Шулай без кузгалмый торган Падшалыкны алгач, дяӳлятне саклыйык та, арыу кюнелдя, куркыуда тороб, анын белян Аллага жараулы итеб кызмят итейек, 29 безнен Аллабыз жандырыб ашый торган ут кюк шул.

13-нче бюлем

1 Туган сӧйӧӳлек сезнен арада тулыб торсон. 2 Читтян килеб жӧрӧӳчелярне сӧйӧӳне онотмагыз, анын арткылы кайберяӳляр белмягян кӧйӧ пяриштялярне кунак иткянняр. 3 Ӳзегез дя, быгауда алар белян торган кюк тойоб, быгауда тороучыларны исегездя тотогоз, ӳзегез дя тяндя торганга кюря азабланыучыларны да кюнелдян чыгармагыз. 4 Барыгызнын да кябенегез кадерле, жатышыгыз бозолоусыз булсын; азгын тороучыларны, уйнашчыларны Алла айыблый шул. 5 Акча сӧйӧучян кылмышлы булмагыз, ней бар, шунар тук булыгыз, Ул Ӳзе ӓйткян шул: Сине калдырмам, сине ташламам, диб. 6 Шулай без кыйыуланыб ӓйтябез: Минa булышыучы Ходай, шунар кюря мин курыкмам: кеше минa ней кылар? диб.

Зач.334 7 Сезгя Алла сюзе сӧйлягян ӱзегезнен ӧйрятеӱчелярегезне иска алыгыз, аларнын гумерляре азагына караб, аларнын ышаныуларына ошарга тырышыгыз. 8 Іисусъ Христосъ кичя дя, бӧгӧн дя, гумерляр буйына шул ук. 9 Тӧрлӧ жат, чит ӧйрятеӱлярга биренеб китмягез, кюнеллярне дяӱлят белян беркетеӱ жакшы эш шул, әммя ашамныклар белян тӧгӧл, аларга биренеӱчеляр алардан пайда алмаганнар. 10 Безнен корман урнысыз бар, скиніядя кызмят итеӱчелярнен аннан туйынырга хаклары жук. 11 Терлеклярнен каннарын жазыклардан тазартыр ӧчӧн баш священникъ арыу урынга алыб кергяч, тянняре тороргa тукталган урыннын тыш жагында жандырыла. 12 Шулай Іисусъ та, Ӱзенен Каны белян кешелярне арыуландырыр ӧчӧн, кабканын тыш жагында азабланган. 13 Шулай Анын курлыгын кютяреб, тора торган урыннын тыш жагына, Анын жанына чыгыйык; 14 безнен шул мында гел тора торган калабыз жук, әммя буласыны эзлейбез. 15 Шулай Анын арткылы Аллага туктаусыз мактау корманы китерейек, алай дигяне: Анын исемен ауызыбыз белян данныйык. 16 Шулай ук жакшылык итеӱне, бер-берегез белян катышыулы булыуны онотмагыз, андый корманнар Аллага жараулы шул.

Зач.335 17 Ӱзегезнен ӧйрятеӱчелярегезгя буйсыныб, баш салыб торогоз, алар шул жауаб тотарга тейешлеляр булганга кюря, жокомсрамыйчы сезнен жаннарыгыз ӧчӧн сагышланалар; алар мыны сӧйӧнӧч белян эшлясенняр, әммя кӧрсӧнӧб тӧгӧл, алай бит сезнен ӧчӧн пайдалы булмас. 18 Безнен ӧчӧн дя телягез: без ӱзебезне бар турдан да гадел тотканга кюря, кюнелебез арыудыр диб ышанабыз. 19 Мин тизряк сезгя кайтарылсын диб, мыны эшляӱегезне бигряк тя соройом. 20 Сарыкларнын оло Кӧтӧӱчесен, мянге бойорокны Каны белян куйыучы безнен Ходайыбыз Іисусъ Христосны ӱлгяненнян тергезеб торгозоучы татыулык Алласы 21 Ӱз иркен кыла торган әр-бер арыу эшегездя сезне булдырыб житкезсен, Іисусъ Христосъ арткылы сездя Ӱзеня жараулыны барлыкка китерсен; Анар дан булсын гумердян гумергя. Аминь.

22 Эй туганнар, сездян со-
ройом, бу ӱгетляӱ сюзен кабыл
алыгыз, мин шул сезгя кюб жаз-
мадым. 23 Белегез, безнен туга-
ныбыз Тімофей иркенгя чыгары-
лган, ӓгяр дя ул озакламый кился,
анын белян бергя мин дя сезне
кюрермен. 24 Ӧйрятеӱчелярегезне
барысын да, бар изгелярне дя
кюнелдян жаратыб торогоз.
Италіядягеляр сезне кюнелдян
жаратыб калалар. 25 Сезнен ба-
рыгыз белян дя дяӱлят булсын.
Аминь.

ИЗГЕ ІОАННЪ БОГОСЛОВНЫН ТАНЫТКЫЧЛАРЫ

1-нче бюлем

1 Ісусъ Христоснын танытқычлары, мыны Анар Алла биргян, озакламый нейляр булырга тейешлене Ул Ӱз мяндяляреня кюрсятсен диб. Ул мыны Ӱз пяриштясе арткылы жибяреб, мяндясе Іоаннга кюрсяткян. 2 Іоаннъ Алла сюзен таныклаган, тагы Ісусъ Христоснын таныткычын да, ӱзе ней кюргянне дя таныклаган. 3 Бу алдан ӓйтелгян пагамбярлек сюзлярен укыучы, тынаучылар да, мында жазылганны тотоучылар да бахетле, багыт инде жакын шул. 4 Іоаннъ Асіядяге булган жиде жыйынга жаза: Бар, булган, ӓле килясе дя Алладан, аннары Анын престолы карышында тороучы жиде тыннан, тагы Ісусъ Христостан сезгя дяӱлят, татыулык, тынычлык булсын. 5 Ышанычлы танныкчы булган Ісусъ Христосъ ӱлгяннярдян беренче терелеб тороучы, жир падшаларын да тотоб тороучы. Анар, безне сӧйӧб, Ӱз Каны белян жазыклары-быздан безне жыуыучыга, 6 Ӱз Атасы Аллага безне падшалар, священникляр итеб куйыучыга дан, тотоулык гумердян гумергя. Аминь. 7 Мына болотлар белян килер, Аны ӓр-бер кюз дя, Аны кадаклаучылар да кюрер, Анын алдында жирдяге бар тыумалар да ӱкерешеб жылашырлар. Шулай булыр. Аминь. 8 Ходай ӓйтя: Мин Альфа да, Омега да, башланыу да, бетеӱ дя, дей. Ул бар да, булды да, килясе дя, булганнарны Тотоучы да. 9 Мин сезнен туганыгыз Іоаннъ, Ісусъ Христоснын кӧйӧгӧндя, падшалыгында, тюземнегендя бергя булыучы,

Алла сюзе өчөн, Іисусъ Христосны таныклаган өчөн Патмосъ диб аталган атауда булдым. 10 Терелеў көнөндя мин тында булдым, шунда ўземнен артымда быргы ауазыдый көчлө ауаз эшеттем: ул ауаз әйтте: Мин Альфа да, Омега да, баштагы да, азакы да; 11 ней кюрясең, шуны книгягя жаз да, Асіядя булган жыйыннарга жибяр: Ефестагы, Смирнадагы, Пергамдагы, Фіатирадагы, Сардыдагы, Филадельфіядяге, Лаодикіядяге жыйыннарга, диде. 12 Бу минем белян сөйляшеўче кем ауазы икянне кюрейем диб, мин боролоб карадым, боролоб карагач, жиде алтын жактырткычлар кюрдем. 13 Шул жиде жактырткычлар уртасында әдям Улына ошаулы Беряўне кюрдем. Ул озон кейемгя кейенгян, кюкряген алтын эзяр белян бяйлягян; 14 Анын башы да, чячляре дя ап-ак, ак жон кюк, кар кюк, Анын кюзляре ут жалкыны кюк. 15 Анын аяклары пичтя кыздырылган жалтырауыклы бронзага ошаулы, Анын ауазы кюб сыулар шаулаган ауаз кюк; 16 Ул Ўзенен унг кулында жиде жондозно тотоб тора, Анын ауызыннан ике жагы да ўткен кылыч чыгыб тора, Анын жөзө ўзенен бөтөн кыуаты белян жактырта торган кояш кюк. 17 Мин Аны кюргяч тя ўле мясялле булыб, Анын аягы астына жыгылдым. Әммя Ул Ўзенен унг кулын мина салыб, мина әйтте: Курыкма, Мин беренче дя, азакы да, 18 тере тороучы да; ўле дя булдым, мына инде тере торам гумердян гумергя. Аминь. Тамукнын да, ўлемнен дя ачкычлары Ўземдя. 19 Син нейляр кюрдең, нейляр бар, аннары мыннан ары нейляр булырын шулай жаз. 20 Син Минем унг кулымда кюргян жиде жондоз, аннары жиде алтын жактырткычлар жяшереге шушы: жиде жондоз жиде жыйыннын пяриштясен билгертя, син кюргян жиде жактырткыч жиде жыйынны билгертя, диде.

2-нче бюлем

1 Ефестагы жыйыннын пяриштясеня жаз: Ўзенен унг кулында жиде жондозно тотоучы, жиде алтын жактырткычлар арасында Жөрөўче былай әйтя: 2 синең эшляренне белямен, кызмятенне, тюземнегенне, бозокларны кюрялмаганынны да белямен; ўз-

лярен апостоллар диб атаучыларны да сынаб карадыӊ, әммя алар андыйлар тӧгӧл, син аларны алдаучылар диб табтыӊ; 3 син кюб читеннеклярга тюзденӊ, тюземнегеӊ дя бар, Минем исемем өчӧн кызмят иттеӊ, тырышыуда әлсезлянмяденӊ. 4 Әммя сиӊа шул турда карышылыгым бар: син элекеге сӧйӧулегеннe ташладыӊ. 5 Шулай кай турдан жыгылганынны син исеня тӧшӧр дя тяӳбягя кил, эшляренӊe элекегечя кыл; әгяр дя алай итмясӊ, тяӳбягя килмясӊ, сиӊа озакламый килермен дя, синеӊ жактыртқычынны урныннан кючермен. 6 Алай да синдя шунысы жакшы: син Николаит кешеляренен эшлярен кюрялмыйсыӊ, андый эшлярне шу Мин дя кюрялмыйым. 7 Колагы бар кеше эшетсен, Тынын жыйыннарга неӥ әйткянен: Жиӊеб чыгыучыга Алланын жомак уртасында ӳся торган Терелек агачыннан ашарга бирермен. 8 Тагы Смирнадагы жыйыннын пяриштясеня жаз: Беренче дя, Азакы да, ӳле дя булган, мына казер тере Тороучы былай әйтя: 9 синеӊ эшляренӊe, кӧйӧгӧнне дя, жарлылыгынны да белямен: алай да син бай; ӳзлярен іудейляр диб атый торганнар сине курлаганны да белямен, тик алар іудейляр тӧгӧл, әммя сатана жыйыны. 10 Бер нястядян дя курыкма, сиӊа әле тюзярга киряк булыр. Мына шайтан сезнен арагыздан, сынар өчӧн, кайберлярегезне ӧтӧрмянгя жабар, ун кӧн чамасы кайгы-кӧйӧк кюрерсез. Ышаныуынны ӳлгенче сакла, сиӊа Терелек венецын бирермен. 11 Эшетергя колагы бар кеше эшетсен, Тыннын жыйыннарга неӥ әйткянен: Жиӊеб чыгыучы икенче ӳлемнен азабына туры килмяс. 12 Тагы Пергамдагы жыйыннын пяриштясеня жаз: Ике жагы да ӳткен кылыч Тотоучы былай әйтя: 13 синеӊ эшляренӊe белямен: син сатананын престолы тора торган жирдя жяшейсеӊ, Минем исемемне саклыйсыӊ, сезнен анда сатана жяшягян жирдя Минем дӧрӧс таныкчым Антипа ӳтерелгян кӧннярдя дя Миӊа ышаныудан таӊмадыӊ. 14 Алай да әзряк сиӊа карышылыгым бар, синдя Валаамъ ӧйряткянне тотоучылар бар, ул Валакны Израиль улларын алданыуга кертеб, аларны сыннар корманын ашарга, уйнашлык

итяргя өйряткян. 15 Шулай синдя Мин кюрялмый торган Николаит кешеляре өйряткянне тотоучылар да бар. 16 Тяўбя ит, алай итмясяң, сина тиздян килермен дя, аларга карышы Ўз ауызымдагы кылычым белян көряшермен. 17 Эшетергя колагы бар кеше эшетсен Тыннын жыйыннарга ней әйткянен: Жинеб чыгыучыга ашарга саклаб тоткан манна бирермен, тагы анар ак таш бирермен, ул ташта жана исем жазылган, ул исемне ташны алыучыдан башка беряў дя белмей. 18 Тагы Фіатирадагы жыйыннын пяриштясеня жаз: Алла Улы, Анын кюзляре ут жалкыны кюк, аяклары жалтырауыклы бронзага ошаулы былай әйтя: 19 синең эшляренне белямен: сөйөүлегенне, кызмятенне, ышаныуынны, синең тюземнегенне дя белямен, синең азакы эшляреңг элекегеляреннян кюбряк икянне дя белямен. 20 Әммя әзряк сина карышылыгым бар, син ўзен катын пагамбяр диб атый торган Іезавелга Минем мяндяляремне адашыу жулына кертеб, уйнашлык итеб, сыннар корманын ашарга өйрятергя ирек иттең. 21 Мин анар ўзенен уйнашлыгыннан тяўбягя килергя багыт бирдем, әммя ул тяўбягя килмяде. 22 Әгяр дя ўз эшляреннян тяўбягя килмясяляр, мына Мин аны каты чир тюшягеня саламын, анын белян уйнашлык итеўчелярне дя оло кайгыга төшөрямен. 23 Анын балаларын да ўлем белян каряб итярмен, шунда Мин эчлярне дя, кюңеллярне дя сынаб тикшереўче икянне бар жыйыннар да аннарлар, шулай сезнен әр- кайсыгызга эшляреня караб кайтарырмын. 24 Сезгя дя, Фіатирада бу өйрятеўне тотмаган бютяннярга дя, сатананын тиряннеге диб аталганны белмягяннярга әйтямен: Сезгя бютян ауырлык салмамын; 25 ўзегездя ней бар, Мин килгенче шуны гна тотогыз. 26 Кем жинеб чыгыб, азакка чаклы Минем эшляремне кылыб тора, анар жалган деннелярга баш булырга кыуат бирермен; 27 ул аларны тимер таяк белян көтөб жөртөр, балчык сауытлар шикелле алар уатылырлар, Мин дя шу Атамнан шундый кыуат алдым. 28 Тагы анар таң жондозон да бирермен. 29 Эшетергя колагы бар кеше эшетсен, Тыннын жыйыннарга ней әйткянен.

3-нче бюлем

1 Тагы Сардыдагы жыйыннын пяриштясеня жаз, Алланын жиде тынын Тотоучы, тагы жиде жондозны да Тотоучы былай äйтя: Синең эшляренне белямен: Син тере дигян исемне жöртясең, äммя син ӱле. 2 Уяу тор, ӱлемгя жакыннашкан мяндялярне ныгайт, Мин бит Аллам алдында синең жараулы булган эшляренне бöтöнняй табмыйым. 3 Син неӥ эшеткяненне, неӥ алганынны исеня тöшöр дя, шуны сакла, тяӱбя ит. Äгяр дя уяу тормасаң, Мин сине бур кюк килеб басарым, кай сагаття килеб басасымны да син белмяссең. 4 Алай да, Сардыда синең ӱз кейемнярен шакшыландырмаган бер ничя кеше бар, алар ак кейемгя кейенеб Минем белян жöрöрляр, алар тейешлеляр шул. 5 Жиңеб чыгыучы ак кейемняргя кейенер, анын исемен Терелек книгясеннян сöртöб ташламам, анын исемен Атам алдында да, Анын пяриштяляре алдында да таныкларым. 6 Колагы бар кеше эшетсен Тыннын жыйыннарга неӥ äйткянен. 7 Тагы Филадельфіядяге жыйыннын пяриштясеня жаз: Святый, Чынлык, Давиднын ачкычын Ӱзендя тотоучы, Ул ачса, бер кем дя жабалмыӥ, жабса, бер кем дя ача алмыӥ, былай äйтя: 8 Синең эшляренне белямен, мына Мин синең алдында ишеклярне ачтым, аларны бер кем дя жаба алмыӥ; синең кöчöң кюб тöгöл, алаӥ да Минем сюземне дя сакладың, Минем исемемнян танмадың да. 9 Мына ӱзлярен іудейляр диб атыӥ торганнар, äммя алар андыӥ тöгöл, жалганныйлар, алар сатана жыйыны. Мин шушылаӥ итярмен: алар килеб синең аякларың астына башырырлар да, шунда Мин сине сöйгянне белерляр. 10 Син ничек Минем тюземнек сюземне сакладың, жир öстöндя тороучыларны сынар öчöн бöтöн дöньягя килясе сыналыу багытыннан шулаӥ Мин дя сине сакларым. 11 Мына тиздян килермен, ӱзеңдя булганны тот, синең венецыңны беряӱ-беряӱ ала кюрмясен. 12 Жиңеб чыгыучыны Минем Алламнын жортонда багана итярмен, ул инде аннан чыкмас; анын öстöндя Алламнын исемен, Алламнын каласынын исемен, кюктян, Алламнан тöшкян жаңа Іерусалимнен исемен, Ӱземнен жаңа исемемне дя жазармын. 13

Колагы бар кеше эшетсен, Тыннын жыйыннарга ней äйткянен.
14 Тагы Лаодикіядяге жыйыннын пяриштясеня жаз: Аминь, Ышанычлы, Чын таныкчы, Алланын булдырган нястялярен Башлаучы шулай äйтя:
15 Синең эшляреңне белямен; син салкын да төгöл, кайнар да төгöл, син булсаң ыйы жя салкын, жя кайнар.
16 Ämмя син жылы гна, кайнар да төгöл, салкын да төгöл, шулай булгач, сине ауызымнан чыгарыб ташларым.
17 Син äйтясең шул: мин бай, байыдым, бер ней дя киряксенмейем диб; тик белмейсен: син бахетсез, кызганыч, жарлы, сукыр да, жалангач та.
18 Сиңа киңяш бирямен: син Миннян ут белян тазартылган алтын сатыб ал, байырсын; синең жалангачлыгыңнын ояты кюренмяскя ак кейем сатыб ал, кеярсең; тагы кюзляреңне кюз майы белян майла, кюрерсең.
19 Мин кемне сöям, аларнын жангышын äйтеб кюрсятям, кыйын да тейерям, шулай кюңеленне кайнарлатыб тот, тяўбя ит.
20 Мына ишек төбöгöздя басыб кагыб торам, äгяр дя кем дя кем Минем тауышымны эшетеб ишеген ачса, анар керермен дя Анын белян кичке ашта булырмын, ул да Минем белян булыр.
21 Жиңеб чыгучыга Минем белян престолымда утырырга бирермен, Мин дя шулай жиңеб чыгыб, Атам белян Анын престолында утырдым шул.
22 Колагы бар кеше эшетсен Тыннын жыйыннарга ней äйткянен.

4-нче бюлем

1 Шуннан суң мин карадым, мына кюктя ишекляр ачык, быргы ауазыдый мин эшеткян элеке минем белян сöйляшкян ауаз äйтте: Мен мында, мыннан суң нейляр булырга тейешлене сиңа кюрсятермен, диде.
2 Шул сяттюк мин Тын эчендя булдым, мына кюк östöндя престолъ тора, престолда Утырыучы да бар.
3 Бу Утырыучынын кюренеше яшма, сардис дигян асыл ташларга ошаулы, престолъ äйлянясендя салауат кюпере изумруд кюренешеня ошаулы.
4 Шул престолъ äйлянясендя тагы жегерме дюрт престолъ бар, престолларда утырыучы жегерме дюрт изге картны кюрдем, алар ак кейемгя кейенгянняр, башларында алтын ве-

нецлары бар ыйы. 5 Престолдан жяшенняр, кюкряўляр, ауазлар чыгыб торалар, утлы жиде жактырткыч престолъ алдында жаныб тора, алар Алланын жиде тынын билгертяляр. 6 Престолъ алдында кристаллга ошаулы пыяла дингез бар, престолъ уртасында да, престолъ äйлянясендя дя дюрт терелекле бар; алар алларыннан да, артларыннан да кюзляр белян тулганнар. 7 Беренче терелекле арысланга ошаулы ыйы, икенче терелекле бызауга ошаулы, öчöнчö терелекленен жöзö кеше жöзö кюк эйе, дюртенче терелекле оча торган бöркöткя ошаулы. 8 Дюрт терелекленен äр-кайсынын äйлянясеннян алтышар канатлары бар ыйы, эчляреннян алар кюзляр белян тулган, алар кöндöз дя, тöння дя ич тя тынычланмыйчы: Святъ, Святъ, Святъ булганнарны Тотоучы Ходай Алла, Ул булды да, бар да, килясе дя, диб дяшеб äйтеб торалар. 9 Шул терелеклеляр престолда Утырыучыга, гумердян гумергя Тороучыга тау иткяндя, дан, кадер китергян чакта, 10 жегерме дюрт изге карт престолда Утырыучынын алдында жыгылыб, гумердян гумергя Тороучыга башыралар да, üзляренен венецларын престолъ алдына куйыб äйтяляр: 11 Эй Ходай, Син данны, кадерне, кыуатны алырга тейешле, Син шу барын да булдырдың, бар да Синең иркең буйынча тора да, булдырылган да, дейляр.

5-нче бюлем

1 Аннары мин престолда Утырыучынын уң кулында тышыннан да, эченнян дя жазылыулы жиде пичят белян пичятлянгян книгя кюрдем. 2 Тагы мин кöчлö ауаз белян кычкырыб äйтеўче кыуатлы пяриштяне дя кюрдем, ул äйтте: Бу книгянен пичятлярен алыб, аны ачарга кем жараулы? диде. 3 Бу книгяне ачыб, анар кararга кюктя дя, жирдя дя, жир астында да бер кем дя булдыра алмады. 4 Бу книгяне ачыб укырга, анар кararга да жараулы беряў дя табылмаганга мин кюб жыладым. 5 Шунда изге картларнын берсе мина äйтте: Жылама, мына Іуда быуынынан, Давиднын тамырыннан чыккан арыслан жинде, Ул бу книгяне ачыб, анын жиде пичятен алырга булдыра ала, диде. 6 Аннары мин кара-

дым, мына престолъ уртасында, дюрт терелеклеляр уртасында, изге картлар уртасында кормангa чалынган шикелле Бярян тора, Анын жиде мӧгӧзӧ бар, жиде кюзе бар, алар Алланын бӧтӧн дӧньягя жибярелгян жиде тынын билгертяляр. 7 Ул килде дя престолда Утырыучынын уҥ кулыннан княгяне алды. Ул княгяне алган чакта, шунда дюрт терелекле дя, жегерме дюрт изге карт та Алла Бяряне алдында жӧз тюбян жыгылдылар, аларнын ӓр-кайсынын гӧсляляре дя, изгелярнен теляклярен билгертя торган ладань белян тулы алтын сауытлары да бар ыйы. 9 Алар былаӥ диб жаҥа жырыу жырлыйлар: Княгяне алыб, анын пичятлярен ыуатырга Син жараулы, Син шу чалынган булдыҥ, Ӱз Каныҥ белян безне ӓр-бер быуыннан да, телдян дя, калыклардан да, тыумалардан да Аллага сатыб алдыҥ, 10 Аллабызга безне падшалар, священникляр иттеҥ, без инде жир ӧстӧндя падшалык итярбез, диделяр. 11 Аннары мин престолъ ӓйлянясендя, терелеклеляр, изге картлар ӓйлянясендя кюб пяриштялярне кюрдем, тауышларын да эшеттем, аларнын саны ун меҥ табкыр ун меҥ, меҥ табкыр меҥняб бар ыйы; 12 алар оло ауаз белян ӓйттеляр: Чалынган Бярян кыуатны, байлыкны, белемнекне, ныклыкны, кадерне, кодрятне, данналыуны алырга жараулы, диделяр. 13 Аннары ӓрбер булдырылганнар, кюктягеляр дя, жирдягеляр дя, жир астындагылар да, дингездягеляр дя, анда булганнар бар да ӓйткянне мин эшеттем: Престолда Утырыучыга, Бярянгя дя бахиллек, кадер, дан, тотоулык булсын гумердян гумергя, диб. 14 Дюрт терелекле ӓйттеляр: Аминь! диб. Жегерме дюрт изге карт та, жыгылыб, гумердян гумергя Тороучыга башырдылар.

6-нчы бюлем

1 Аннары мин Бярян жиде пичят арасыннан беренчесен алганын кюрдем, шунда дюрт терелекленен берсе кюкрягян ауаз кюк ауаз белян ӓйткянен эшеттем, ул: Кил дя кара, диде. 2 Мин карадым: мына ак ат, анын ӧстӧндя утырыучы да бар, ул жяя тоткан, анар венецъ та бирелгян, ул жиҥеӱчян кеше кюк, жиҥеб чы-

гар өчөн чыкты. 3 Аннары Ул икенче пичятне алгач, икенче терелекленен: Кил дя кара, дигянен эшеттем. 4 Шунда бютян кызыл жирян ат чыкты, анын өстөндя утырыучыга кешеляр бер-берсен ўтерешсенняр диб, жир өстөннян тынычлыкны алырга бирелгян, тагы анар зур кылыч та бирелгян. 5 Ул өчөнчө пичятне алгач, өчөнчө терелекленен: Кил дя кара, дигянен эшеттем. Мин карасам, мына кара туры ат, анын өстөндя кулына ўлчяў тоткан утырыучы да бар. 6 Шунда мин дюрт терелекле арасында ауаз эшеттем. Ул әйтте: Бер уч бодай бер эш көнөня тюляў, өч уч арпа да бер эш көнөня тюляў, май агачлары белян жөзөм басыуларына зыян салма, диде. 7 Ул дюртенче пичятне алгач, дюртенче терелекленен: Кил дя кара, дигян ауазын эшеттем. 8 Мин карадым, мына саргылт төстяге ат, анын өстөндя утырыучынын исеме ўлем, ўлеляр падшалыгы да анын артыннан бара, аннары анар жирнен дюртенче өлөшөндя калыкларны кылыч белян, ачлык белян, каза белян, жир кейекляре белян ўтерергя кыуат бирелгян эйе. 9 Ул бишенче пичятне алгач, мин корман урны астында, Алла сюзе өчөн, Аны таныклауда булганнары өчөн ўтерелгяннярнен жаннарын кюрдем. 10 Алар каты ауаз белян кычкырыб әйттеляр: Эй Чын, Изге Тотоб Тороучыбыз, кайчанга чаклы безнен каныбыз өчөн жирдя тороучыларга хокөм итмейче, ўч кайтармыйчы торорсон? диделяр. 11 Аларнын әр-берсеня ак кейемняр бирелгян эйе, аннары аларга әйтелгян эйе; тагы аз гна багытка тюзеб тынычлансыннар диб, алар белян бергя кызмят иткянняр дя, туганнары да шулай булар кюк ўтерелеб, аларнын санын тутыргынчы диб. 12 Ул алтынчы пичятне алгач мин карадым, мына зур жир титряўляр булыб узды, кояш та карангы жонно кейем кюк карангыланды, ай да кан кюк булды. 13 Смоква агачы, каты жилдян селкенеб, житешмягян смокваларын койган кюк, кюктяге жондозлар да жиргя койолдолар. 14 Кюк тя төргяк кюк төрөлөб жяшеренде, әр-бер тау да, атау да ўзляренен урыннарыннан шыуыштылар. 15 Жир падшалары да, затлы кешеляр дя, байлар, мең кеше башлыклары да, көчлөляр дя, әр-бер кол, әр-бер иркендяге дя тау кыуышларына, тау жарыкларына

жяшеренделяр.16 Алар тауларга, ташларга äйтяляр: Безнен öскя тöшöгöз, престолда Утырыучынын жöзöннян, Бяряннен дя ачыуыннан безне жяшерегез, 17 Алланын ачыуынын оло көнö килеб житте шул, инде кем чыдаб тора алыр? диделяр.

7-нче бюлем

1 Шушыннан суң мин дöньянен дюрт почмагында торган дюрт пяриштяне кюрдем. Алар жир öстöня дя, дингез öстöня дя, ич нейдей агачларга да жил исмясен диб, жирнен дюрт жилен тотоб торалар ыйы. 2 Шулай тагы, кояш чыгышыннан кютярелеб чыккан, тере Алланын пичятен тоткан башка пяриштяне дя кюрдем. Ул каты ауаз белян кычкырыб, жиргя дя, дингезгя дя зыян китерергя бирелгян дюрт пяриштягя äйтте: 3 Безнен Аллабыз мяндяляренен мангайларына без пичятне салыб бетермейче, жиргя дя, дингезгя дя, агачларга да зыян тейермягез, диде. 4 Шунда мин пичят салынганнарнын санын эшеттем: пичят салынганнар Израиль улларынын бар быуыннарыннан да барлыгы жöз кырык дюрт мең эйе. 5 Іуда быуыныннан пичятлянгян ун ике мең, Рувімь быуыныннан пичятлянгян ун ике мең, Гадъ быуыныннан пичятлянгян ун ике мең, 6 Асиръ быуыныннан пичятлянгян ун ике мең, Нефалімъ быуыныннан пичятлянгян ун ике мең, Манассія быуыныннан пичятлянгян ун ике мең, 7 Симеонъ быуыныннан пичятлянгян ун ике мең, Левій быуыныннан пичятлянгян ун ике мең, Иссахаръ быуыныннан пичятлянгян ун ике мең, 8 Завулонъ быуыныннан пичятлянгян ун ике мең, Іосифъ быуыныннан пичятлянгян ун ике мең, Веніаминъ быуыныннан пичятлянгян ун ике мең. 9 Шушыннан суң мин карадым, мына бик кюб кешеляр, аларны бер кем дя санаб чыга алмас, алар äр-бер тыумадан, быуыннан, калыклардан, теллярдян ак кейемнярдя кулларына пальма чыбыклары тотоб, престолъ алдында, Алла Бяряне алдында тордолар. 10 Алар каты ауаз белян дяшеб äйттеляр: Котолоу престолда Утырыучы безнен Аллабызда, Бяряндя, диделяр. 11 Бар пяриштяляр дя престолъ äйлянясендя, изге картларнын, дюрт терелекленен äйлянясендя

тордылар, престолъ алдында жӧз тюбян жыгылыб, Аллага башырдылар: 12 Аминь! диб. Даннау, ололау, белемнек, тау итеӱ, кадерляӱ, кыуат, ныклык безнен Аллабызга гумердян гумергя. Аминь! диб. 13 Изге картларнын берсе сюз башлаб, миннян сорады: Бу ак кейемгя кейенгянняр кемняр алар, кайдан килгянняр алар? - диде. 14 Мин анар ӓйттем: Эй кадерлем, син белясең инде, дидем. Аннары ул мина ӓйтте: Былар шундыйлар, зур кайгы-кӧйӧк арасыннан килеӱчеляр, алар Бяряннен Каны белян ӱз кейемнярен жыудылар, ӱз кейемнярен агарттылар. 15 Шунын ӧчӧн казер алар Алла престолы алдында тороб, кӧн-тӧн Анын Изге Жортонда Анар кызмят итяляр. Престолъ ӧстӧндя Утырыучы да алар эченя кереб урнашыр. 16 Алар инде ачыкмаслар да, сыусамаслар да, аларны кояш та, бер нейдей эсселек тя пешермяс. 17 Престолъ уртасында тороучы Бярян аларны кӧтӧб жӧртӧр шул, аларны Терелек сыуынын чишмяляреня алыб барыр, Алла аларнын кюзляреннян ӓр-тӧрлӧ жяшлярен сӧртӧр, диде.

8-нче бюлем

1 Бярян жиденче пичятне алгач, жарты сагат чамасы кюк тауышсыз тордо. 2 Шунда мин Алла карышысында тороучы жиде пяриштяне кюрдем, аларга жиде бырсы бирелгян эйе. 3 Аннары бютян пяриштя дя килеб, алтын кадила тотоб корман урны алдына басты, анар кюб ладань бирелгян эйе, ул бар изгелярнен телякляре белян, аны престолъ алдындагы алтын корман урнына салсын диб. 4 Шунда пяриштянен кулыннан, изгеляр теляге белян, Алла алдында ладаннын тӧтӧнӧ кютярелде. 5 Аннары пяриштя кадиланы алды да, корман урнындагы ут белян тутырыб жир ӧстӧня сибте, шуннан ауазлар, кюкряӱляр, жяшенняр, жир титряӱляр китте. 6 Жиде бырсы тотоучы жиде пяриштя бырсыларын кычкыртырга ӓзерляделяр. 7 Беренче пяриштя бырсы кычкыртты: шунда боз жауымы белян ут, кан белян катышыб жиргя койолдылар, шунда агачларнын ӧчӧнчӧ ӧлӧшӧ жаныб бетте, бӧтӧн жяшел ӱлямняр дя жаныб бетеляр. 8 Икенче пяриштя бырсы

кычкыртты, шунда зур тау шикелле ут белян жаныб тора торган нястя дингезгя жыгылыб төштө, шунда дингезнен өчөнчө өлөшө канга алмашты, 9 дингездя жяшяўче булдырылган жанны нястялярнен өчөнчө өлөшө ўлеб бетте, кимялярнен дя өчөнчө өлөшө харяб булдылар. 10 Өчөнчө пяриштя быргы кычкырткач, кюктян жактырткычка ошаулы, жаныб тора торган зур жондоз жыгылыб төштө, ул инешлярнен, чишмялярнен өчөнчө өлөшөня төштө, 11 бу жондознон исеме ярем, шулай сыуларнын өчөнчө өлөшө ярем кюк булды, алар яче булганга кюря, ул сыуларны эчеб кюб кешеляр ўлделяр. 12 Дюртенче пяриштя быргы кычкырткач, кояшнын өчөнчө өлөшө, айнын да өчөнчө өлөшө, жондозларнын да өчөнчө өлөшө зыян кюрде, аларнын өчөнчө өлөшляре карангыландылар, көннөн дя өчөнчө өлөшө жактырылмады, төн кюк булды. 13 Аннары мин бер пяриштяне кюрдем, анын кюк уртасыннан очоб барганда каты ауаз белян айтеб барганын эшеттем, ул: Быргы кычкыртасы калган өч пяриштянен быргы тауышларыннан жир өстөндя тороучыларга кайгы, кайгы, кайгы, - диде.

9-нчы бюлем

1 Бишенче пяриштя быргысын кычкыртты, шунда мин кюктян жиргя жыгылыб төшкян жондозно кюрдем, анар төбсөз койонон ачкычы бирелгян эйе. 2 Ул төбсөз койоно ачты, шунда зур пичтян чыккан кюк, койодан төтөн чыкты, койодан чыккан төтөннян кояш та, ауа да карангыланды. 3 Төтөннян жир өстөня саранча чыкты, анар жирдяге скорпионнарныкы кюк кыуат бирелгян эйе. 4 Анар айтелгян эйе: Жирдяге бер нейдей ўлямгя дя, бер нейдей агачка да зыян жасамаска, аммя тик мантайларында Алла пичяте булмаган кешелярга гня зыян жасарга диб. 5 Анар аларны ўтермяскя, аммя биш ай азабларга гна бирелгян, анын азаблауы скорпион кешене чаккач азаблангандагы шикелле. 6 Шул көннярдя кешеляр ўлем эзлярляр, тик таба алмаслар, ўлярга телярляр, аммя алардан ўлем качар. 7 Саранчанын кюренеше сугышка әзерлянгян атка ошаулы ыйы, анын

башында алтынга ошаулы венецлар кейгян кюк, анын битляре кеше битляре кюк, 8 анын чячляре катын-кыз чячляре шикелле, анын тешляре арысланнарныкы кюк эйе. 9 Анын östöндя тимер каблауыч кюк каблауычлар ыйы, анын канатларынын шаулауы кюб атлар сугышка чабканда арбаларынын дöбöртяуе кюк эйе, 10 анын скорпионныкы кюк койороклары бар ыйы, койорокларында уклары бар ыйы, анын кыуаты биш ай кешелярга зыян жасар öчöн бирелгян эйе. 11 Ӳзеня баш падшасы анын тöбсöз урыннын пяриштясе эйе, анын исеме еврейчя Аваддонъ, грекчя Аполлионъ. 12 Бер кайгы узды, мына анын артыннан тагы ике кайгы киля. 13 Алтынчы пяриштя быргы кычкыртты, шунда мин Алла карышысында тора торган алтын корман урнынын дюрт мögöзöннян бер ауаз эшеттем, 14 ул ауаз быргы тоткан алтынчы пяриштягя äйтте: оло Евфратъ иделе жанына бяйлянгян дюрт пяриштяне жибяр, диде. 15 Шунда кешелярнен öчöнчö ölöшöн ӳтереӳ öчöн, шул сагаткя, кöнгя, айга, жылга äзерлянгян дюрт пяриштя иркенгя жибярелделяр. 16 Атлы чиреӳлярнен саны ике ун мең табкыр ун мең булдылар, анын санын мин эшеттем. 17 Ул атларны да, öсляренда утырыучыларны да кюренеӳ булганда мин былай кюрдем: аларнын öсляренда утлы гиацинтлы, кюкертле каблауычлар, атларынын башлары арыслан башлары кюк, аларнын ауызларыннан ут, тöтöн, кюкерт чыгыб тордо. 18 Шушы öч тöрлö казадан, аларнын ауызларыннан чыга торган уттан, тöтöннян, кюкерттян кешелярнен öчöнчö ölöшö ӳлеб беттеляр. 19 Атларнын кöчö ауызларында, аннары койороклярында ыйы шул, аларнын койороклары жыланнарга ошаулы, башлары да бар ыйы, шулар белян алар зыян китерделяр. 20 Бу казалардан ӳлмей калган бютян кешеляр ӳз кулларынын эшляреннян тяӳбягя килмяделяр, женнярга, тагы алтыннан, кömöштян, бакырдан, таштан, агачтан жасалган кюря дя, эшетя дя, жöрöй дя алмый торган сыннарга башырыудан туктамадылар. 21 Шулай алар ӳзляренен ӳтерешеӳляреня, кюрязялек бозоклогон кылыуларына, ӳз азгынныкларына, бурлыкларына тяӳбя китермяделяр.

10-нчы бюлем

1 Аннары мин кюктян төшөб киля торган кыуатлы башка пяриштя кюрдем, ул болотка кейенгян эйе, анын башы өстөндя салауат кюпере, жөзө кояш кюк, анын аяклары ут баганалар шикелле эйе. 2 Анын кулында ачык книгя бар ыйы, ул уң аягы белян дингез өстөня, сулы белян жир өстөня басты, 3 аннары арыслан кычкырган кюк, каты ауаз белян кычкырды, ул кычкыргач, шунда жиде кюкряў ўзляренен тауышлары белян сөйляштеляр. 4 Жиде кюкряў ўзляренен тауышлары белян сөйляшкяч, мин жазмакчы булган ыйым, тик кюктян мина әйткян ауаз эшеттем: Жиде кюкряў ней әйткянне жяшер, мыны жазма, диде. 5 Мин кюргян дингез өстөндя дя, жир өстөндя дя басыб тороучы пяриштя ўзенен кулын кюккя таба кютярде дя, 6 кюкне дя, андагы булганнарнын барысын да, жирне дя, андагы булганнарнын барысын да, дингезне дя, андагы булганнарнын барысын да булдырган, гумердян гумергя Тороучыга карганыб әйтте: Багытлар инде булмас, диб. 7 Әммя жиденче пяриштя бырысын кычкыртыб тауыш биргян көннярдя, Алла Ўзенен мяндяляре булган пагамбярляре арткылы сөйляткянчя, Анын жяшереннярe булыб бетяр, диде. 8 Мин кюктян эшеткян ауаз тагы минем белян сөйляшя башлаб әйтте: Бар, жир өстөндя дя, дингез өстөндя дя тороучы пяриштянен кулыннан ачык книгяне ал, диде. 9 Мин пяриштя жанына барыб, анар әйттем: Мина книгяне бирче, дидем. Ул мина әйтте: Ал да, аны ашаб бетер, ул синең эченда әче булыр, әммя ауызында бал кюк тямне булыр, диде. 10 Мин пяриштянен кулыннан книгяне алдым да, аны ашаб бетердем: ул ауызымда бал кюк тямне булды, ашаб бетергяч, минем эчемдя әче булды. 11 Аннары ул мина әйтте: Сина әле тагы кюб кешеляр арасында, тыумалар, калыклар, падшалар арасында пагамбярлек итяргя туры килер, диде.

11-нче бюлем

1 Аннары миңа ӳлчяӳ таягына
ошаулы таяк бирелде дя әйтелде:
Тор да, Алла Жортон да, кор-
ман урнын да, анын эчендя Ал-
лага табыныучыларны да ӳлчя,
дейелде. 2 Әммя Жортнын тыш-
кы ишек алдын айырыб калдыр,
анысын ӳлчямя, ул шу жалган
деннелярга бирелгян, алар изге
каланы кырык ике ай табтарлар,
диде. 3 Аннары Минем ике та-
ныкчыма кыуат бирермен, алар
ӧсляреня алама кейем кейенеб,
мең дя ике жӧз алтмыш кӧн па-
гамбярлек итярляр. 4 Былар ике
май агачы, бӧтӧн жирнен Алла-
сы карышысында тороучы ике
жактырткычлар. 5 Әгяр дя кем
аларга дӧрӧслӧк кылмаса, алар-
нын ауызыннан ут чыгыб, алар-
нын дошманнарын ашаб бетерер;
әгяр кем дя кем аларны кыйыр-
сытырга теляся, ул ӳтерелергя
тейешле булыр. 6 Алар ӳзляренен
пагамбярлек иткян кӧннярен-
дя, жир ӧстӧня жангыр жаумас
ӧчӧн, кюкне биклярга кыуат то-
талар, сыуларны канга алмашты-
рырга да, әгяр телясяляр, жир-
гя әр-тӧрлӧ казалар китерергя
дя кыуат тоталар. 7 Алар ӳзляре-
нен таныклык итеӳ кӧннярен бе-
тергяч, тӧбсӧз урыннан чыккан
кейек алар белян сугышыб, алар-
ны жи яр дя, аларны ӳтерер, 8
аларнын гяӳдялярен оло каланын
урамында калдырыр, ул кала тын
буйынча: Содомъ диб, Египе-
тъ диб атала; безнен Ходайыбыз
шунда кадакланган булган шул.
9 Кешелярне кюбесе, тыумалар,
калыклар, няселляр ӧч кӧн жа-
рым буйына аларнын тянняреня
караб жӧрӧрляр, аларнын гяӳдя-
лярен каберга салырга да рӧксят
итмясляр. 10 Жир ӧстӧндя торо-
учылар бу эшкя сӧйӧнӧшӧрляр,
кыуанышырлар, бер-берсеня бю-
лякляр жибярешерляр. Бу ике
пагамбяр жир ӧстӧндя тороучы-
ларны азаблаганнар шул, дире-
рляр. 11 Әммя ӧч кӧн жарымнан
сун аларга Алладан терелтеӳ-
че тын иняр, алар икесе дя то-
роб аякларына басарлар, шун-
да аларны караб жӧрӧӳчелярга
зур куркыныч тӧшӧр. 12 Шунда
алар кюктян аларга әйткян каты
ауаз эшетерляр: Мында менe-
гез, дигянне. Шунда алар болот-
лар ӧстӧндя кюккя менеб китяр-
ляр, әммя аларнын дошманнары
аларга караб калырлар. 13 Аннары
шул сагаття ӳк бик каты жир тит-

ряўе булды, каланын да унынчы ölöшö жимерелеб бетте, жир титряў багытында жиде мең кеше харяб булды, бютянняреня куркыныч төшöб, кюктяге Аллага дан китерделяр. 14 Икенче кайгы ўтте, мына тиздян öчöнчö кайгы киля. 15 Жиденче пяриштя быргы кычкыртты, шунда кюктя каты ауазлар жангырады, былай диб: Жир жöзö падшалыгы безнен Ходайыбызнын да, Анын Христосынын да падшалыгына ăйлянде. Ул падшалык итяр гумердян гумергя, диб. 16 Шуннан Алла карышысында, ўзляренен престолларында утыра торган жегерме дюрт изге карт та жöз тюбян жыгылыб Аллага башырдылар да, 17 ăйттеляр: Эй буганнарны Тотоучы Ходай Аллабыз! Сина тау итябез, Син бар да, булдың да, килясе дя, Син зур кыуатынны алдың да падшалык итя башладын шул, диб. 18 Жалган деннеляр загарлянделяр; Синең ачыу könöң килде, ўлгяннярга хокöм итяргя, Ўз мяндялярең булган пагамбярлярга, изгелярга, Синнян куркыучыларнын кечеляреня дя, ололарына да тейешле бюлякне биреў багыты житте, ăммя жирне харяб итеўчелярне харяб итеў багыты житте, диделяр. 19 Аннары кюктя Алла Жорто ачылды да, Анын Жортонда Анын законъ сандыгы кюренде, шунда жяшенняр, ауазлар, кюк кюкряўляр, жир титряўляр, каты боз жауымнары барлыкка килделяр.

12-нче бюлем

1 Аннары кюктя оло билге кюренде: мына бер катын, ул кояшка кейенгян, анын аяк астында ай, анын башында венец, ун ике жондоздан тора. 2 Анын эчендя ауыры бар ыйы, ул тыудырганда-гы азабтан, ауыртыуыннан кычкыра. 3 Тагы кюктя бютян билге дя кюренде, мына зур гна кызыл аждагы жылан, ул жиде башлы, ун мögözlö, анын башларында жиде падша бюреге, 4 анын койорого кюктян жондозларнын öчöнчö ölöшön эяртеб, жиргя жыгылтыб төшördö. Бу аждагы теге тыудырырга тейешле катын тыудыргач та, анын баласын ашарга диб, катын карышысына килеб басты. 5 Катын ир бала тыудырды, ул балага бар калыкларны да тимер таяк белян котöб жöртöргя тейешле, бала тыугач

та Аллага, Анын престолы жанына алынды. 6 Аннары катын буш кырга качты, анда мең дә ике жөз алтмыш көн анар туйыныб тороу өчөн Алладан урын әзерлянгян булган. 7 Мына кюктя сугыш булыб узды, Михаилъ белян Анын пяриштяляре аждагыга карышы сугыштылар, аждагы да, олологон жугалткан үзенен пяриштяляре белян аларга карышы сугыштылар, 8 әммя жинелмейче тора алмадылар, алар өчөн кюктя инде урыннар да табылмады. 9 Шунда оло аждагы, әүялеге жылан жыгыб төшөрөлдө, бөтөн жир өстөн алдандырыучы, шайтан диб, сатана диб атала торган жиргя жыгыб төшөрөлдө, анын белян бергя анын пяриштяляре дя жыгыб төшөрөлдөляр. 10 Шунда мин кюктя былай әйтя торган оло ауаз эшеттем: Казер Аллабызныӊ падшалыгы, кыуаты, коткарыуынын багыты, Анын Христосынын да кыуатынын багыты житте, безнен туганнарыбызны айыблаб тороучы бяреб төшөрөлдө шул, аларны ул Аллабыз карышында көн-төн айыблаб тордо, диб. 11 Алар аны Алла Бяряненен Каны белян, үзляренен Христосны таныклау сюзляре белян жинделяр, үлемгя чаклы үзляренен жаннарын да жяллямяделяр. 12 Шул сяятлей, кюкляр, анын өстөндя тороучылар, кыуанышыгыз! Кайгы жир өстөндя, дингез өстөндя тороучыларга: шайтан үзеня кюб багыт калмаганын белеб, сезгя каты жарсулык белян төштө, диб. 13 Аждагы үзенен жиргя жыгыб төшөрөлгянен кюргяч, ир бала тыудырган катынны эзляб, тотарга жөрөй башлады. 14 Әммя катынга зур бөркөтнен ике канаты бирелгян эйе, ул жыланнан качыб, үз урнына, буш кырга очоб китсен диб, анда багытлар, багыт, тагы жарты багыт туйыныб торсон диб. 15 Шунда жылан үз ауыз эченнян катын артыннан инеш шикелле сыу жибярде, аны инештя батырыйым диб. 16 Әммя жир катынга булышты, жир үзенен ауызын ачыб, аждагы ауыз эченнян жибяргян инешне жотто. 17 Шунда аждагы катынга жарсыды да, катын няселеннян булган, Алла бойорогон саклаучы бютянняр белян, Іисусъ Христосны таныклаучылар белян сугышка керешергя китте.

13-нче бюлем

1 Аннары мин динтез комо
өстөндя басыб тордом, шун-
да дингездян бер кейек чыкканны кюрдем, ул жиде башлы, ун мөгөзлө эйе, анын мөгөзлярендя ун падша бюреге бар ыйы, анын башларында Алланы курлау исемняре эйе. 2 Мин кюргян кейек барска ошаулы булды, анын аяклары айыныкы кюк, анын ауызы арыслан ауызы кюк; аждагы анар үзенен көчөн, престолын, оло кыуатын бирде. 3 Мин анын башларынын берсе үлем жарасы белян жаралганган шикелле кюрдем, әммя анын бу үлем жарасы төзялде, шунда бөтөн жирнен исе китеб, кейек артыннан барыб, кейеккя кыуат биргян аждагы жыланга башырдылар, 4 кейеккя дя башырдылар да әйттеляр: Бу кейеккя кем ошаша алыр, кем анын белян көряшя алыр, диделяр. 5 Анар олосомакланыб, Алланы курлаб сөйляшя торган ауыз бирелгян эйе, анар үз эшен кыларга кырык ике айга кыуат бирелгян. 6 Ул Алланы курлау өчөн, Анын исемен дя, тора торган урнын да, кюктя тороучыларны да курлау өчөн үзенен ауызын ачты. 7 Анар изгеляр белян сугыш алыб барырга, аларны жинярга дя кыуат бирелгян эйе, анар әрбер быуыннарны, калыкларны, няселлярне үз кулында тотарга кыуат бирелгян эйе. 8 Жир өстөндя тороучылар бар да, дөнья булдырылганнан ук чалынган Алла Бяряненен Терелек книгясендя исемняре жазылмаганнар, анар башырырлар. 9 Колагы бар кеше эшетсен! 10 Кем тотконга алыб кится, үзе дя тотконга китяр, кем кылыч белян ютерся, үзеня дя кылычтан ютерелеү тейешле булыр. Мында изгелярнен тюземнеге белян ышаныуы. 11 Аннары мин жирдян чыга торган бютян кейек кюрдем, анын бярянне-ке шикелле ике мөгөзө бар ыйы, ул да аждагы кюк сөйляште. 12 Ул анын алдында беренче кейеknен бөтөн кыуаты белян кыйлана, бөтөн жирне дя, анда тороучыларны да теге үлем жарасы төзялгян, беренче кейеккя башырырга куша; 13 оло билгеляр кыла, шундыйларны да: жир өстөня, кешеляр алдына кюктян ут та төшөря. 14 Анар кейек алдында кыларга бирелгян кодрятляр белян ул жир өстөндя тороучыларны алдандыра, жир өстөндя тороучы-

ларга, теге кылычтан жараланган жарасы булса да, тере тора торган кейекнен төсөн алар жасасыннар диб әйтя. 15 Анар кейекнен төсөня тын кертергя бирелгян булган, кейек төсө сөйляшсен дя, тагы кейекнен төсөня башырмаган әркемне ўтерергя булдыра алсын, диб. 16 Ул тагы шуны да эшляр: барысына да, кечелярга дя, ололарга да, байларга да, жарлыларга да, иркеннярга дя, колларга да ун кулларына, жя мангайларына сызык салыныр. 17 Шул сызык булмаган, жя кейекнен исеме, жя исеменен саны булмаган бер кемгя дя сатарга да, алырга да рөксят булмас. 18 Мында белемнек: кемнен уйы житя, шул кейекнен санын исябляб чыгарсын, бу сан шу кешенеке, ул сан - алты жөз алтмыш алты.

14-нче бюлем

1 Аннары мин карадым, мына Алла Бяряне Сіонъ тауында басыб тора, анын белян бергя мангайларында Анын Атасынын исеме жазылган жөз кырык дюрт мең кешеляр дя торалар. 2 Шунда кюктян кюб сыулар шаулаган кюк, каты кюк кюкрягян ауаз кюк ауаз эшеттем; тагы ўз гөслярендя уйный торган гөслячелярнеке кюк тауыш эшеттем. 3 Алар престолъ алдында, дюрт терелекле белян изге картлар алдында жана жырыу шикелле жырыу жырлыйлар. Шушы жирдян жолоб алынган жөз кырык дюрт меннян башка, бу жырыуга бер кем дя өйряня алмады. 4 Былар шул катыннар белян шакшыланмаганнар, алар кыз-жегет көйө тороучылар, быллар Алла Бяряне кая гна барса да, Анын артыннан барыучылар, алар кешеляр арасыннан беренче булыб Аллага да, Бярянгя дя жолоб алынганнар, 5 аларнын ауызларында жаманнык жук, алар Алла престолы алдында шиксезляр. 6 Аннары мин кюк уртасыннан очоб барыучы бютян пяриштяне кюрдем, ул жир өстөндя тороучыларга, әр-бер тыумаларга, быуыннарга, теллярга, калыкларга изге хабяр сөйляў өчөн мянге Евангеліене тоткан ыйы. 7 Ул оло ауаз белян әйтте: Алладан куркыгыз, Анар дан китерегез, Анын хокөм сагате житте шул, кюкне, жирне, дингезне, сыу чишмялярен Булдырыучыга башырыгыз, диде. 8 Анын артыннан тагы бю-

тян пяриштя ӓйтеб барды: жимерелде, жимерелде оло кала Вавилонъ, ул шу ӱ азгынныгынын жарсыулык аракысы белян бар калыкларны да туйгынчы эчертте, диде. 9 Алар артыннан өчөнчө пяриштя оло ауаз белян ӓйтеб барды: Кем кейеккя, жя Анын төсөня башыра, жя мантайына, жя кулына сызыкны ала, 10 ул Алланын ачыу сауытында сыйыкланылмаган, Анын жарсыуынын тулы аракысын эчяр, аннары изге пяриштяляр алдында, Бярян алдында ут эчендя, кюкерт эчендя азабланыр; 11 аларнын азабланыу төтөнө гумердян гумергя чыгыб, кютярелеб торор. Кейеккя, жя анын төсөня башыры-учылар, анын исеменен сызыгын алыучылар, көндөз дя, төння дя тынычлык табмаслар. 12 Мында Алла бойорогон тотоучыларнын, Іисуска ышаныучы изгелярнен тюземнеге. 13 Аннары мин кюктян мина ӓйткян ауаз эшеттем: Жаз, мыннан сун Ходай какына ӱлгян ӱлеӱчеляр бахетле, шулай булыр, дей Тын, алар ӱз кызмятляреннян тынычлык алырлар, кылган эшляре аларнын ӱз артларыннан бара. 14 Аннары мин карадым: мына жакты болот, болот өстөндя ӓдям Улына ошаулы беряӱ утыра, Анын башында алтын венець, Анын кулында ӱткен урак. 15 Аннары бютян пяриштя изге Жорттан чыгыб, болот өстөндя Утыручыга каты ауаз белян кычкырыб ӓйтте: Урагынны жибяр дя ур, урак багыты житте шул, жир өстөндя инде урасылар житештеляр, диде. 16 Болот өстөндя Утырыучы Ӱзенен урагын жир өстөня төшөрөб жибярде, шундук жир урылыб бетте. 17 Тагы бютян пяриштя кюктяге булган Жорт эченнян чыкты, анын да ӱткен урагы бар ыйы. 18 Тагы утка кыуаты булган ӱнгя пяриштя корман урныннан чыгыб, оло кычкырыу белян ӱткен урак тотоучыга ӓйтте: Ӱзенннен ӱткен урагынны жибяреб, жир өстөндя жөзөм жимешлярен кистер, анын шул жимешляре өлгөргянняр инде, диде. 19 Шунда пяриштя ӱзенен урагын жир өстөня төшөрөб жибярде дя, жир өстөндя жөзөмнярне кисеб, Алланын каты ачыуынын агызгычына ташлады. 20 Шунда каланын тыш жагында жилякляр агызгычта табталды, агызгычтан менң дя алты жөз стадий озоннокта, ат ауызлыгына житярлек кан акты.

15-нче бюлем

1 Аннары мин кюктя оло кодрятле ўнгя билге, сунгы жиде казаны тотоб тороучы жиде пяриштяне кюрдем, шулар белян Алланын жарсыуы бетясе эйе. 2 Тагы мин ут белян катыштырылган, пыялага ошаулы дингез кюрдем, кейекне, анын тёсён, анын сызыгын, исеменен санын жинеўчеляр шушы пыяла дингез östёндя Алланын гёсляренен тотоб торалар. 3 Алар Алла мяндясе Моисейнен жырыуын, тагы Алла Бяряненен жырыуын былай диб жырлыйлар: Эй буганнарны Тотоучы Ходай Алла! Синең эшлярең оло да, кодрятле дя. Эй изгелярнен Падшасы! Синең жулларың гаделлек белян чыннык. 4 Кем курыкмас Синнян, эй Ходай, Синең исемеңне кем даннамас, бер Син гня святъ, бар калыклар да килеб Синең алдында башырырлар, Синең хокёмняреңг инде ачылды шул, диделяр. 5 Шушыннан суң мин кюрдем, мына кюктя танықчылык келяўў чатырынын изге урны ачылды. 6 Изге урыннан жиде казаны тотоучы жиде пяриштя чыкты, алар чиста, жакты, житен кейемгя кейенгянняр, кюкрякляреннян алтын эзярляр белян бяйлягянняр. 7 Дюрт терелекленең берсе бу жиде пяриштягя жиде алтын сауыт бирде, ул сауытлар гумердян гумергя Тороучы Алланын ачыуы белян тутырылганнар ыйы. 8 Шунда Алла данынан, Анын кыуатыннан изге жорт тётён белян тулды, жиде пяриштянен жиде казасы койолоб бетмейче, изге урынга бер кем дя керя алмады.

16-нчы бюлем

1 Аннары мин изге урыннан жиде пяриштягя аўткян оло ауаз эшеттем, ул: Барыгыз, Алланын ачыуынын жиде сауытын жир östёня койогоз, диде. 2 Беренче пяриштя китеб, ўзенен сауытын жир östёня койдо, шунда кейекнен сызыгы булган, анын тёсёня башырган кешелярдя карарга имянгеч, каты, ўлекле жаралар барлыкка килде. 3 Икенче пяриштя ўзенен сауытын дингезгя койдо, шунда ўлгян кешеңеке кюк кан барлыкка килде.

Дингездяге бар жанны нястяляр дя ўлеб беттеляр. 4 Өчөнчө пяриштя ўзенен сауытын инешлярга, сыу чишмяляреня койдо, алар канга айлянде. 5 Шунда мин сыулар пяриштясен эшеттем, ул айтте: Гадел Син, эй Ходай, Син бар да, булдыг да, изге дя, шушылай булсын диб хокөм иттең шул. 6 Алар изгелярнен, пагамбярлярнен каннарын тюккянняреня кюря, Син аларга эчяргя кан бирдең, алар шунар тейешле шул, диде. 7 Мин тагы корман урныннан былай диб айткян бютянне дя эшеттем: Эй буганнарны Тотоучы Ходай Алла! Синең хокөмняреҥ чын да, гадел дя, диде. 8 Дюртенче пяриштя ўзенен сауытын кояшка койдо, анар кешелярне ут белян жандырырга бирелгян эйе. 9 Шунда кешелярне каты эсселек жандырды, аммя алар шушы казаларны кыуатында тотоучы Алланын исемен курладылар, Анар дан китерергя алар анга килмяделяр. 10 Бишенче пяриштя ўзенен сауытын кейекнен престолына койдо, шунда анын падшалыгы карантыланды, алар азабларыннан ўз теллярен чяйняделяр,11 шулай алар азабларыннан, жараларыннан кюктяге Алланы курладылар, ўз кулларынын эшляреннян тяўбягя килмяделяр. 12 Алтынчы пяриштя ўзенен сауытын оло Евфратъ иделеня койдо, кояш чыгышы жагындагы падшаларга жул äзер булыу өчөн, анын сыуы кибте. 13 ннары мин аждагынын ауызыннан, кейек ауызыннан, жалган пагамбяр ауызыннан бакаларга ошаулы, өч шакшы тын чыкканны кюрдем. 14 Былар кодрятляр билгеляр кылыучы жен тыннары ыйы, булгаҥнарны Тотоучы Алланын шушы оло көнөня сугышка жыяр өчөн, алар бөтөн дөньядяге жир падшаларына чыгалар. 15 Мына бур кюк килям: жалангач жөрмяс өчөн, ўзенен оятын кюрсятмяс өчөн ўзенен кейемен саклаучы, уяу тороучы бахетле. 16 Былар падшаларны еврейчя Армагеддонъ диб аталган урынга жыйды. 17 Жиденче пяриштя ўзенен сауытын ауага койдо, шунда кюктяге изге жорттагы престолдан каты ауаз жангырады: Булыб беттеляр, диб. 18 Аннары жяшенняр, кюкряўляр, ауазлар, оло жир титряў барлыкка килде, кешеляр жир өстөндя булганнан бирле алай булганы да жук, шундый жир титряў, шулай оло. 19 Оло кала да өчкя айырыл-

ды, жалган деннелярнен дя калалары жимерелделяр, оло Вавилонъ да, Алланын ачыуынын, жарсыу аракылы сауытын анӑр биреӳ өчӧн, Алла алдында иския алынды. 20 Ӓр-бер атау качты, таулар да калмады. 21 Илле кило ауырлыктагы боз да кюктян кешеляр өстӧня килеб тӧштӧ, боздан килгян каза өчӧн кешеляр Алланы курладылар, аннан килгян каза бик ауыр булды шул.

17-нче бюлем

1 Жиде сауытны тотоучы, жиде пяриштяляр арасыннан берсе килеб, минем белян сӧйлӓшеб, мина ӓйтте: Кил, кюб сыулар өстӧндя утырыучы, оло азгын катынга буласы хокӧмне мин сина кюрсятермен, 2 анын белян жир падшалары азгыннык кылдылар, анын азгыннык итеӳ аракысы белян жир өстӧндя тороучылар исерештеляр, диде. 3 Аннары мине тын белян буш кырга алыб китте, шунда мин бер катынны кюрдем, ул карангы-кызгылт тӧстяге кейек өстӧндя утырадыр ыйы. Ул кейек жиде башлы, ун мӧгӧзлӧ, бӧтӧнняй Алланы курлау исемняре белян тутырылган. 4 Ул катын порфирга, кызгылт кейемгя кейенгян, алтыннар белян, кыйбатлы ташлар белян, энжеляр белян матурланган, ӳзенен кулында азгынныгынын жирянгеч шакшылыклары тутырылган алтын сауыт тотоб тора. 5 Анын мангайында исеме, жяшерек жазылган: оло Вавилонъ, азгын катыннарга, жирдяге жирянгеч нястялярга ана, диб. 6 Мин бу катыннын изгелярнен каннарын, Ісусны таныклаучыларнын каннарын туйгынчы эчеб исергян кюрдем; аны кюргяч, минем бик тя, бик тя исем китте. 7 Мина пяриштя ӓйтте: Нейгя синең исең китя? Бу катыннын, аны кютяреб жӧрӧӳче жиде башлы, ун мӧгӧзлӧ кейекнен жяшеренен мин сина ӓйтямен, диде. 8 Син кюргян кейек бар ыйы, ул инде жук та, аннары тӧбсӧз жирдян чыгар да, харяб булыуга китяр; жир өстӧндя тороучыларнын, дӧнья булдырылганнан бирле булган Терелек княгясеня исемняре жазылмаганнарнын, кейек кюренеб, аннары бетеб, тагы кюренгянен кюреб исляре китяр. 9 Мында белемнекле булган уй. Жиде баш - катын утыра торган жиде тау-

ны билгертя, 10 аннары жиде падшаны билгертя. Аларнын бишесе жыгылдылар, берсе бар, бютяне әле килмягян, ул килгяч, анар озак тороргa төгөл. 11 Кейек тя, ул булган ыйы казер жук, анысы сигезенче, шул жиденен саныннан, аннары харяб булыуга китяр. 12 Син кюргян ун мөгөз ун падшаны билгертя, алар әле падшалык алмаган, әммя падшалар кюк кыуатны кейек белян бергя, бер гня сагаткя алырлар. 13 Алар бер уйны тоталар, ўзляренен көчлярен, кыуатларын кейеккя табшырырлар. 14 Алар Алла Бяряне белян сугыш алыб барырлар, әммя Бярян аларны жиняр, Ул шу падшаларнын Падшасы, башлыкларныҥ Ходайы, Анын белян булганнар да чакырылганнар, сайланганнар, дөрөсляр шул. 15 Аннары миҥа әйтте: азгын катын утыра торган, син кюргян сыулар кешелярне, калыкларны, няселлярне, теллярне билгертя. 16 Син кейектя кюргян ун мөгөз, былар азгын катынны кюрялмас булырлар, аны талаб бетererляр, жалангач калдырырлар, анын тянен ашаб бетererляр, аны утта жандырырлар. 17 Шулай Алла Ўз иркен кылдырырга аларнын кюҥелляреня салды шул, бер ирекне кылыб, Алланын сюзе булыб житкенче, аларнын падшалыкларын кейеккя бирергя кю елляреня салды. 18 Син кюргян катын жир падшаларына падшалык итеўче оло каланы билгертя, диде.

18-нче бюлем

1 Шушыннан суҥ мин кюктян төшя торган бютян пяриштя кюрдем, анын кыуаты бик оло ыйы, анын даныннан жир жөзө жактырылды. 2 Ул каты кычкырыб, көчлө ауаз белян әйтте: Жимерелде, жимерелде оло Вавилонъ, ул женняр тора торган урын ыйы, әр-бер шакшы тынны сыйындырыучы ыйы, әр-бер шакшы, имянгеч кошка килеб кунар урын булган ыйы, ул шу ўзенен азгынныгынын жарсыулык аракысы белян бар калыкларны да туйгынчы эчертте. 3 Жир падшалары да анын белян уйнашлык иттеляр, жир кюписляре дя анын кюб байлыгы белян байыб беттеляр, диде. 4 Мин кюктян былай әйткян бютян ауаз эшеттем: Минем калкым, сезгя анын жазыкларына катышмас, анын ка-

заларына туры килмяс өчөн анын эченнян чыгыгыз, 5 анын жазыклары инде кюккя чаклы житте шул, Алла да анын дөрөссөзлөклярен исеня төшөрдө. 6 Ул сезгя ничек кылды, анар да шулай кайтарыгыз, анын эшляреня караб, анар ике өлөш кайтарыгыз, анын сезгя аракы әзерлягян сауытында ўзеня ике өлөш әзерлягез. 7 Ул ней катле данналды, котороноб кюнел ачты, шунын катле анар азаб, кайгы кайтарыгыз. Ул шу ўз кюнелендя әйтя: Катын падша булыб утырам, мин тол төгөл, кайгы да кюрмямен, дей. 8 Шунар кюря бер көн эчендя анар азаблар, ўлем, жылау, ачлык килер, ут белян жандырылыр, анар хокөм итеўче Ходай Алла шулай көчлө шул. 9 Анын өчөн, анын белян азгыннык итеўче, котороноб кюнел ачыучы жир падшалары да, анын жанган төтөнөн кюргяч, ўкерешеб жылашырлар. 10 Анын азабыннан котлары чыгыб жыраклын тороб әйтерляр: Кайгы, кайгы синя, оло кала Вавилонъ, ныкала ыйын, әммя бер сагат эчендя синя хокөм килеб житте, диб. 11 Жирдяге кюписляр дя, аларнын тауарларын инде беркем дя сатыб алмаганга, анын өчөн ўкерешеб жылашырлар; 12 алтын, көмөш тауарларын, тагы кыйбатлы ташларын, энжелярен, виссоннарын, порфирларын, жепяклярен, кызыл кейемнярен, әр-төрлө тямне эйесле агачларын, әр-бер пел сөякляреннян жасалган сауытларын, әр-бер кыйбатлы агачтан, бакырдан, тимердян, мрамордан жасалган нястялярен, 13 корица, фимиамъ дигян тямне эйесле әйберлярен, миро майларын, ладаннарын, аракыларын, ўсемнек майларын, оннарын, бодайларын, терлекярен, сарыкларын, атларын, арбаларын, кеше тяннярен дя, жаннарын да беркем дя сатыб алмас. 14 Синдя инде синең жанына жарашлы жимешляр дя калмады, барлык көр жалтрауыклы нястяляр дя синнян китте, син инде аларны табмассын. 15 Быларнын барысы белян сатыу-алыу итеб, анын белян байыган, жыраклын тороб, анын азабыннан котлары чыгыб, ўкерешеб жылашыб, 16 былай әйтерляр: Кайгы, кайгы синя, эй виссонга, порфирга, кызыл кейемгя кейенгян, алтын белян, кыйбатлы ташлар белян, энжеляр белян матурланган, оло кала, 17 шундый байлык бер сагат эчендя харяб булды. Бар ко-

рабльне жөртөўчеляр, корабльдя жөзөб жөрөўчеляр, корабль кешеляре, бар дингездя сатыу-алыу итеўчеляр жыракта басыб тордолар, 18 анын жанган төтөнөн кюреб, кычкырыб жылаб әйттеляр: Бу оло калага тагы нейдей кала ошашлы, диделяр. 19 Аннары ўзляренен башларына көл сибеб, кычкырыб, ўкерешеб жылашыб дяштеляр: Кайгы, кайгы сина, эй оло кала, дингездя корабльляре булганнар бар да синең кыйбатлы нястялярең белян байыганнар ыйы, бер сагат эчендя жук булдың шул, диб. 20 Кюк тя, изге апостоллар да, пагамбярляр дя мынар кыуанышыгыз, сезнен хокөмегезне Алла анар булдырыб житкезде шул. 21 Бер көчлө пяриштя зур тегермян ташына ошаулы ташны алды да, аны дингезгя ыргытыб әйтте: Оло кала Вавилонъ да шушындый тизлек белян ташланыр, аннары ул инде булмас та, диде. 22 Гөсля уйнаучыларнын да уйнау тауышлары, жырлаучылар, сыбызгы уйнаучылар, быргы кычкыртыучылар да синдя эшетелмяс инде, бер нейдей төс төшөрөўчеляр дя, бер төрлө төс төшөрөўлек тя булмас, тегермян тауышлары да синдя эшетелмяс инде; 23 жактырткыч жактысы да синдя бютян жактырмас инде, кеяўнен дя, жяряшелгян кызнын да тауышлары синдя эшетелмяс инде, синең кюписляреҥ жирнен оло кешеляре эйе шул, ўзеннен сихерлеген белян бар калыкларны да адашыулык жулына алыб керден. 24 Анын эчендя пагамбярлярнен дя, изгелярнен дя, бар жир өстөндя ўтерелгяннярнен дя каны табылган шул.

19-нчы бюлем

1 Шушыннан суҥ мин кюктя кюб калык ауазыдый каты ауаз эшеттем, алар әйттеляр: Аллилуиа! Безнен Ходайыбызга коткарыу, дан, кадер, кыуат булсын; 2 Анын хокөмняре чын, гадел шул. Ул шу теге оло уйнашчы катынны, ўзенен уйнашлыгы белян жир жөзөн бозоб бетереўчене хокөм итеб айыблады, шулай анын кулыннан киткян Ўз мяндяляренен каннары өчөн тейешлесен кайтарды, диделяр. 3 Тагы икенче табкыр әйттеляр: Аллилуиа! Анын төтөнө чыгыб тора гумердян гумергя, диб. 4 Шул ча-

гында жегерме дюрт изге карт, дюрт терелекле престолда утырыучы Аллага жыгылыб башырыб ӓйттеляр: Аминь! Аллилуиа! диб. 5 Шунда престолдан былай диб ауаз чыкты: Эй Алланын бар мяндяляре, Аннан куркыучылар, кечеляр дя, ололар да безнен Аллабызны мактагыз, диб. 6 Тагы мин эшеттем: кюб калык ауазына ошашлы ауаз, кюб сыулар шаулаган шикелле, кӧчлӧ кюкряўляр шикелле ауаз, алар ӓйттеляр: Аллилуиа! Буганнарны Тотоучы Ходай Алла падшалыкка утырды шул; 7 Сӧйӧнӧшӧб, кыуанышыб Анар дан китерейек, Алла Бяряненен туйы килеб житте шул. Анын катыны да ўзен ӓзерляб житкезде, диб. 8 Анар чиста, жакты виссонга кейенергя бирелгян эйе, виссонъ дигяне: изгелярнен гаделлеге. 9 Шунда мина пяриштя ӓйтте: Жаз, Алла Бяряненен туй киченя чакырылганнар бахетле, диб; тагы мина ӓйтте: Былар Алланын чын, Ўз сюзляре, диде. 10 Мин анар башырмакчы булыб, анын аяклары астына жыгылдым, ӓммя ул мина ӓйтте: Кара, мыны кылма, мин сина да, Ісусны таныклауны тотоучы синен туганнарына да, сезнен белян бергяляб Аллага кызмят итеўче. Аллага башыр, Ісусны таныклау ўзе пагамбярлек тыны шул, диде. 11 Аннары мин кюк ачылыб торганны кюрдем, мына ак ат, анын östöндя Утырыучы Чыннык белян Дӧрӧслӧк диб атала, Ул гаделлек белян хокӧм дя итя, сугыш та алыб бара. 12 Анын кюзляре ут жалкыны кюк, Анын башында кюб ололок бюрекляре, Анын жазылган исеме бар ыйы, ул исемне Ўзеннян бютян, бер кем дя белмяде. 13 Ул кан белян кызылланган кейем кейгян эйе. Анар бирелгян исем: Алла Сюзе. 14 Кюктяге чиреўляр дя ак атларга атланыб, ак, чиста виссонга кейенеб, Анын артыннан бардылар. 15 Анын ауызыннан калыкларны кырыу ӧчӧн ўткен кылыч чыгыб тора. Ул аларны тимер таяк белян кӧтӧб жӧртя, Ул буганнарны Тотоучы Алланын ачыуынын жарсыуы аракысын изгечтя изя. 16 Анын кейемнярендя дя, жан башында да исем жазылган: падшаларнын Падшасы, башлыкларнын Ходайы, диб. 17 Мына мин кояш östöндя тороучы бер пяриштяне кюрдем: ул ауа уртасыннан очоб барыучы бар кошларга каты ауаз белян кычкырыб ӓйтте: Очоб килегез, Алланын

оло кичке ашына жыйылыгыз; 18 падшаларнын гяўдялярен ашарга, кöчлöлярнен гяўдялярен, меҥ кеше башлыкларынын гяўдялярен, атларнын да, алар öстöндя утырыучыларнын да гяўдялярен, бар иркендягелярнен дя, колларнын да, кечелярнен дя, ололарнын да гяўдялярен ашарга жыйылыгыз, диде. 19 Шунда мин кейекне, жир падшаларын да, аларнын чиреўлярен дя ат öстöндя Утырыучы белян, Анын чиреўляре белян сугышырга жыйылганнарын кюрдем. 20 Шунда кейек тя, анын алдында кодрятляр кылыб, шунын белян кейекнен сызыгын алыучыларны, анын тöсöня башырыучыларны саташтырыб тороучы жалганчы пагамбяр дя анын белян бергя эляктереб алынды да, икесе дя тере кöйö, кюкерт белян жана торган утлы кюлгя ыргытылдылар. 21 Ăммя бютянняре ат öстöндя Утырыучынын ауызыннан чыга торган кылыч белян ўтерелеб бетте, шулай бар кошлар да аларнын гяўдяляре белян тукландылар.

20-нче бюлем

1 Мына мин кюктян тöшкян пяриштяне кюрдем: анын тöбсöз урыннан ачкычы бар ыйы, ўзенен кулында зур чылбыр тоткан. 2 Ул, шайтан да, сатана да дигян аждагыны, äўялеге жыланны тотоб алды да, аны меҥ жылга быгаулады. 3 Калыкларны меҥ жыл ўтмейче саташтырмасын диб, аны тöбсöз урынга ыргытыб, шунда бикляб, анăр пичят салыб куйды. Шушыннан суҥ ул аз гна багытка иркенгя чыгарылырга тейеш. 4 Шунда мин престолларны, аларнын öстляндя утырыучыларны кюрдем, аларга хокöм итяргя бирелгян эйе. Аннары Іисусны таныклаган öчöн, Алла Сюзе öчöн башлары киселгяннярнен жаннарын да кюрдем, алар кейеккя дя, анын тöсöня дя башырмаганнар, мангайларына да, уҥ куллары-на да анын сызыгын алмаганнар, алар терелделяр дя, Христосъ белян меҥ жыл падшалык иттеляр. 5 Ăммя бютян ўлгянняр меҥ жыл ўтмейче терелмяделяр. Бу беренче терелеб тороу. 6 Беренче терелеб тороуга öлöштяш булыучы бахетле дя, изге дя. Аларны инде икенче ўлемнен кыуаты тотмой, äммя алар Алланын да, Христос-

нын да священникляре булырлар да, Анын белян мең жыл падшалык итярляр. 7 Мең жыл ўткяннан сун, сатана ўзенен жабылыуыннан иркенгя чыгарылыр, ул жирнен дюрт почмагында тороучы калыкларны, Гогны, Магогны да саташтырырга, аларны сугышка жыярга чыгар, аларнын саны: дингез комо шикелле. 8 Мына алар жирнен кинг урнына чыктылар да, изгелярнен туктаб тора торган урнын да, сӧйӧклӧ каланы да чырмаб алдылар. 9 Шунда кюктян, Алладан ут тӧшӧб, аларны ашаб бетерде.10 Ӓммя аларны саташтырыучы шайтан утлы, кюкертле кюлгя ыргытылды, анда кейек тя, жалган пагамбяр дя тӧння дя, кӧндӧз дя гумердян гумергя азабланырлар.11 Аннары мин оло, ак престолны, анын ӧстӧндя Утырыучыны кюрдем, Ул Утырыучынын жӧзӧннян кюк тя, жир дя качтылар, аларга инде урыннар да табылмады. 12 Шунда мин ўлгяннярне кечелярен дя, ололарын да Алла карышысында торганнарын кюрдем, анда книгяляр дя ачыб куйылган, тагы бютян книгя - Терелек книгясе дя ачыб куйылган: шунда ўлгянняр, книгялярдя жазылган буйынча, ўз эшляреня карата хокӧм ителделяр. 13 Шул чакта дингез дя ўзендя булган ўлгяннярне бирде, ўлем дя, тамук та ўзлярендя булган ўлгяннярне бирделяр, ӓр-бер кеше ўз эшляреня карата хокӧм ителде. 14 Ўлем дя, тамук та утлы кюлгя ташланылды, бу икенче ўлем. 15 Кем Терелек книгясеня жазылмаган булган, шул кеше утлы кюлгя ыргытылды.

21-нче бюлем

1 Аннары мин жана кюкне, жана жирне кюрдем, элекеге кюк тя, элекеге жир дя узыб киттеляр, дингезляр дя инде жук. 2 Аннары мин, Іоаннъ, жана, кюктян Алладан тӧшкян изге кала Іерусалимне кюрдем, ул ўзенен ире ӧчӧн матурланыб, жяряшелгян кыздый ӓзерлянгян. 3 Тагы мин кюктян былай диб ӓйткян каты ауаз эшеттем: Мына Алланын келяў чатыры кешеляр белян, инде Ул алар белян бергя торор, алар Анын калкы булырлар, Алла Ўзе алар белян булыб, аларнын Аллысы булыр. 4 Алла аларнын кюзляреннян ӓр-бер тӧрлӧ кюз жяшлярен сӧртӧр, ўлем дя булмас инде,

жылау да, ӓрнеб кычкырыу да, чир дя булмас инде, элекегеляр ӱтеб беттеляр шул. 5 Аннары престолда Утырыучы ӓйтте: Мына барын да жаңаны булдырамын, диде. Аннары мина ӓйтте: Жаз, бу сюзляр чын, дӧрӧс, диб. 6 Тагы миңа ӓйтте: Булыб беттеляр, Мин Алфа да, Омега да, башланыуы да, бетеӱе дя; кибенеӱчегя Терелек чишмясенен сыуын бушлай бирермен. 7 Жинеб чыгыучы барына да эя булыр, Мин анар Алла булырмын, ул да Минем улым булыр, диде. 8 Куркакларнын, ышанмыӣ торганнарнын, шакшыларнын, ӱтереӱчелярнен, уйнашчыларнын, бозгочоларнын, сынга табыныучыларнын, бар алдаучыларнын ӧлӧшӧ кюкерт белян жана торган утлы кюлдя. Бу икенче ӱлем. 9 Аннары сунгы жиде казаны тутырган жиде сауытны тотоучы жиде пяриштянен берсе, минем катыма килеб, миңа ӓйтте: Кил, мин синӑ бер катынны, Алла Бяряненен жяряшелгян кызын кюрсятейем, диде. 10 Аннары мине тын белян бейек, оло тау ӧстӧня кютярелдерде дя кюктян, Алладан тӧшкян оло кала изге Іерусалимне миңа кюрсятте. 11 Ул Алла данын тота. Анын жактырткычы кыйбатлы ташка ошаулы кристалл кюренешле, яшма дигян таш шикелле. 12 Анын зур, бейек стинясе бар, анда ун ике кабкасы бар, кабкалар ӧстӧндя ун ике пяриштя тора, кабкаларда Израиль улларынын ун ике быуыны исеме жазылган. 13 Кояш чыгышыннан ӧч кабка, тӧн жактан ӧч кабка, кӧн жактан ӧч кабка, кояш байышыннан ӧч кабка. 14 Кала стинясенен ун ике нигезе бар, аларда Алла Бяряненен ун ике апостолларынын исеме. 15 Минем белян сӧйляшеӱченен кулында каланы да, анын кабкаларын да, стинясен дя ӱлчяӱ ӧчӧн алтын таягы бар ыйы. 16 Кала дюрт почмаклы итеб торгозолган, анын озонного да киннеге кюк. Ул каланы таягы белян ун ике мең стадійгя ӱлчяде, анын озонного да, киннеге дя, бейеклеге дя бер тигез. 17 Анын стинясен дя ӱлчяде, кеше ӱлчяӱе белян жӧз кырык дюрт терсяк буйы булды, пяриштя ӱлчяӱе дя шулай. 18 Анын стинясе яшма дигян таштан торгозолган, ӓммя кала чиста пыялага ошаулы, чиста алтыннан тора. 19 Кала стинясенен нигезляре тӧрлӧ кыйбатлы ташлар белян матурланганнар: беренче нигезе яшма,

икенчесе сапфиръ, өчөнчөсө халкидонъ, дюртенчесе изумрудъ, 20 бишенчесе сардониксъ, алтынчысы сардоликъ, жиденчесе хризолитъ, сигезенчесе бериллъ, тугызынчысы топазъ, унынчысы хризопрасъ, ун беренчесе гиацинтъ, ун икенчесе аметистъ. 21 Ун ике кабка ун ике энжедян тора, әр-бер кабка бер энжедян. Каланын урамы ӱтя кюренмяле пыяла шикелле, чиста алтыннан тора. 22 Анын эчендя мин чиркяӱне кюрмядем, буганнарны Тотоучы Ходай Алла да, Бярян дя анар Ӱзе чиркяӱ шул. 23 Ӱзен жактыртыр өчөн кала кояшны да, айны да киряксенмей. Алланын даны Ӱзе аны жактырткан шул, Бярян дя анын жактырткычы. 24 Котқарылган калыклар анын жактысында жөрөрляр, жир падшалары да ӱзляренен даннауларын, кадерляӱлярен анын эченя китерерляр. 25 Анын кабкалары көндөз биклянмясляр, әммя төн анда булмас шул. 26 Калыкларнын даннауларын, кадерляӱлярен анын эченя китерерляр. 27 Анын эченя бер нейдей шакшы нястя дя, жирянгечлеккя, алдауга биренгян бер кем дя керя алмас, тик Алла Бяряненен Терелек книгясендя жазылганнар гна керерляр.

22-нче бюлем

1 Аннары мина Терелек сыуынын чиста инешен кюрсятте, ул кристалл кюк жакты, Алланын да, Бяряннен дя престолыннан чыгыб тора. 2 Анын урамы уртасында, инешнен теге жагыннан да, бу жагыннан да терелек агачлары ӱсяляр. Алар ун ике табкыр жимеш китеряляр, ай сайын ӱзляренен жимешлярен биряляр, жапраклары да калыкларны тӧзятеӱ өчөн. 3 Инде бер нейдей дя каргаулы нястя булмас, әммя анда Алланын да, Бяряннен дя престолы булыр, Анын мяндяляре Анар кызмят итярляр. 4 Алар Анын жӧзӧн кюрерляр, Анын исеме дя аларнын мангайларында булыр. 5 Анда инде төн дя булмас, жактырткычны да, кояш жактысын да киряксенмясляр, Ходай Алла Ӱзе аларны жактырта шул, алар гумердян гумергя падшалык итярляр. 6 Аннары мина әйтте: Бу сюзляр чын да, ышанычлы да. Изге пагамбярлярнен Аллысы Ходай озакламый нейляр булырга тейешлене Ӱз мяндяляре-

ня кюрсятер өчөн Ӱз пяриштясен жибярде, диде. 7 Мына тиздян килямен, бу книгянен пагамбярлек сюзлярен саклаб кылыучылар бахетле. 8 Мин, Іоаннъ, быларны кюрдем да, эшеттем дя, быларны эшеткяч тя, кюргяч тя мина кюрсяткян пяриштягя башырыйым диб, анын аяк астына жыгылдым. 9 Ӓммя ул мина ӓйтте: Кара, былай кылма, мин шул сина да, синең пагамбяр туганнарына да, бу книгянен сюзен саклаб кылыучыларга да сезнен белян бергяляб Аллага кызмят итеӱче, Аллага башыр, диде. 10 Тагы мина ӓйтте: Бу книгянен пагамбярлек сюзлярен бикляб пичятляб куйма, багыт жакын бит, диде. 11 Дөрөссөзлөк кылыучы тагы да дөрөссөзлөгөн кылсын әле, шакшы тагы да шакшылансын әле. Ӓммя гадел тагы да гаделлек кылсын, изге тагы да арыулансын әле. 12 Мына тиздян килямен: әр-кемгя эшеня тейешлене кайтарыу өчөн Минем бирясе бюлягем Ӱзем белян. 13 Мин Альфа да, Омега да, Башланыуы да, Бетеӱе дя, Беренче дя, Азакы да. 14 Ӱз кейемнярен жыуыб тазартыучылар бахетле, аларнын терелек агачына да, калага кабкалардан кереггя дя каклары булыр. 15 Ӓммя тыш жакта этляр, бозгочолар, уйнашчылар, ӱтереӱчеляр, сынга табыныучылар, әр-бер дөрөссөзлөкне сөйөӱчеляр, аны кылыучылар калырлар. 16 Мин, Іисусъ, мыны сезгя жыйыннарда таныклау өчөн Ӱземнен пяриштямне жибярдем. Мин Давидъ няселеннян, анын тамырыннан, иртянге жакты таң жондозо. 17 Тын да, жяряшелгян кыз да ӓйтяляр: Кил, диб. Эшетеӱче дя ӓйтсен: Кил, диб. Сыусаган кеше килсен, киряксенгяне терелек сыуын бушлай алсын. 18 Мин дя бу книгядяге пагамбярлек сюзен эшеткян әр-кемгя таныклаб ӓйтям: Ӓгяр кем аларга беряр нястя өстяся, анар Алла бу книгядя жазылган казаны салыр. 19 Ӓгяр кем бу книгянен пагамбярлек сюзлярен беряресен алыб ташласа, Алла аны терелек книгясендяге өлөштян, бу книгядя жазылган изге каладагы өлөштян буш калдырыр. 20 Мыны Таныклаучы ӓйтя: Чыннаб, тиздян килямен, дей. Аминь. Эй Ходай Іисусъ, кил! 21 Безнен Ходайыбыз Іисусъ Христоснын дяӱляте барыгыз белян булсын. Аминь.

ЭЧТЯЛЕГЕ

Сюз башы 2

Матөей жазган арыу Евангеліе 6

Маркъ жазган арыу Евангеліе 66

Лука жазган арыу Евангеліе 104

Іоаннъ жазган арыу Евангеліе 167

Святый апостолларнын эшляре 215

Святый апостолъ Іаковнын арыу жыйынга жибяргян жазыуы 280

Святый апостолъ Петрнын арыу жыйынга жибяргян беренче жазыуы 287

Святый апостолъ Петрнын арыу жыйынга жибяргян икенче жазыуы 295

Святый апостолъ Іоаннъ Богословнын арыу жыйынга жибяргян беренче жазыуы 300

Святый апостолъ Іоаннъ Богословнын арыу жыйынга жибяргян икенче жазыуы 307

Святый апостолъ Іоаннъ Богословнын арыу жыйынга жибяргян өчөнчө жазыуы 309

Святый апостолъ Іуданын арыу жыйынга жибяргян жазыуы 311

Святый апостолъ Павелнын Римъ кешеляреня жибяргян жазыуы 314

Святый апостолъ Павелнын Коринфъ кешеляреня жибяргян беренче жазыуы 341

Святый апостолъ Павелнын Коринфъ кешеляреня жибяргян икенче жазыуы 368

Святый апостолъ Павелнын Галатъ кешеляреня жибяргян жазыуы 386

Святый апостолъ Павелнын Ефесъ кешеляреня жибяргян жазыуы 395

Святый апостолъ Павелнын Филиппы кешеляреня жибяргян жазыуы 404

Святый апостолъ Павелнын Колоссъ кешеляреня жибяргян жазыуы 411

Святый апостолъ Павелнын Фессалоника кешеляреня жибяргян беренче жазыуы 418

Святый апостолъ Павелнын Фессалоника кешеляреня жибяргян икенче жазыуы 424

Святый апостолъ Павелнын Тімофейгя жибяргян беренче жазыуы 428

Святый апостолъ Павелнын Тімофейгя жибяргян икенче жазыуы 436

Святый апостолъ Павелнын Титка жибяргян жазыуы 442

Святый апостолъ Павелнын Філимонга жибяргян жазыуы 446

Святый апостолъ Павелнын Еврейлярга жибяргян жазыуы 448

Изге Іоаннъ Богословнын таныткычлары 469

Рекомендовано к публикации Издательским советом
Русской Православной Церкви ИС Р23-305-0112

Подписано в печать 10.05.2023. Формат 70×100 $^{1}/_{16}$.
Бумага офсетная. Печать офсетная.
Гарнитура «Times». Авт. л. 21,9. Усл. печ. л. 40,6.
Тираж 1000 экз. Заказ 02-23/06-1

ЛОГОС
ИЗДАТЕЛЬСКИЙ ДОМ
им. академика В.И. Андреева

420108, г. Казань, ул. Портовая, 25а.
Тел.: (843) 231-05-46, 231-08-71, 231-04-19.
E-mail: citlogos@mail.ru
www.logos-press.ru